- – Әни, синең теге конференцияң **ничәсендә** ачылды әле? – Октябрьнең унтугызында. (ibid.) "Mother, on what date, now, did that conference of yours begin (lit., open)?" "On the nineteenth of October."
- – **Ничәнче** бүлмә кирәк дисез әле? – Бишенче? (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) "Which room did you say you want? Number five?"
- Вәли Бай. **Күпме** сорыйсыз? Мүсин. Бишәр мең сорыйлар. (Фәтхи Бурнаш, Таң.) Wäli bai. How much are you asking? Müsin. They are asking five thousand each.
- Нуретдин. Җыенысы **күпме**, дисең? Давыт. Дүрт йөз утыз мең. Нуретдин. Безнең өлешкә **күпмесе** төшә? (Кәрим Тинчурин, Җилкәнсезләр.) Nuretdin. How much is the total you say? David. Four hundred and thirty thousand. Nuretdin. How much of that do we have to put up (lit., falls to our share)?
- Хәкимҗан. Исәнме, Гөлбикә! Гөлбикә. Бик әйбәт әле, Хәкимҗан абзый. Үзеңнең хәлләрең **ничек** соң? (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Khäkimjan. How are you, Gölbikä! Gölbikä. Very well so far, Uncle Khäkimjan. And how are things with yourself?
- Гөлсылу. **Нигә** алай иттегез инде? (Юныс Әминов, Очрашырбыз, Гөлсылу.) Gölsylu. Why then did you act like this?
- Шәмсенур. **Ник** абыеңны үртисең, Гөлсылу? (ibid.) Shämsenur. Why do you tease your older brother, Gölsylu?

- Нәҗилә. Бишлегә язганыңны **каян** беләсең? (ibid.) Najilä. How do you know that you wrote an "A" (lit., a five)?
- Ләбибә. Ай алла, аңа бирермен дип миннән 100 тәңкә акча алдың лабаса! Мөкатдимә. **Кайчан** алдым? **Кем** күрде? Аңа **кем** ышансын? (ibid.) Läbibä. O God, after all, you borrowed (lit., took) one hundred rubles from me to give to him! Möqätdimä. When did I borrow (take) them? Who saw it? Who do you expect to believe that?
- Хупҗамал. Гөлкәем, **кая** китәргә җыенганыңны беләсеңме син, юкмы? ... **Кая** карама очсыз-кырыйсыз урман, ди. Кыш көннәрендә чатнама салкын була, ди, ... (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Khupjamal. My dear Göl (short for Gölbikä), do you or don't you know where you are preparing to leave for? ... Wherever you look, there are boundless woods, they say. In winter it is extremely cold, they say, ... (Gölbikä is preparing to leave for Siberia.)
- Заһир икеләнеп торды: **кайда, кемгә** бара ул? (Таһир Таһиров, Галия.) Zahir hesitated. Where, to whom is he going?
- – **Кайда** эшләргә уйлыйсың, Булат? (ibid.) "Where do you think you will work, Bulat?"
- – Акча бирүченең Жоржик икәнлеген **кайдан** белдегез? (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "Where did you find out that it was Zhorzhik who gave me money?"

**[432]** Interrogative pronouns may be used in *indirect discourse:*

- Айсылу Мәрьямнең **кая** баруын сорады. (М.З. Зәкиев, Синтаксис һәм пунктуация.) Aisylu asked where Märyäm was going.
- Бер җиргә җыела торган ярлылар бер-берсен таныганга күрә: «Бу иптәшләре кичә **ни** эшләгән? Эш тапканмы, юкмы? **Күпме** акча тапкан? **Ни** эшләп тапкан?» кебек сөальләр белән көндәге гадәт буенча сөйләшә башладылар. (Мәҗит Гафури, Ярлылар.) Because the poor, gathering at the same place, knew each other, they began as a daily routine to talk about questions like "what these comrades did yesterday, whether or not they found work, how much money they earned, with what work they earned it".
- Кыз аның **нәрсә** әйтергә теләгәнен аңлады. (Рәфкать Кәрами, Очар кошлар белән янәшә.) The girl understood what he wanted to say.

**[433]** Interrogative pronouns are used to express *various emotions:*

- Садыйк. ... Үзең уйлап кара: соңгы ике-өч ел /jɪl/ эчендә генә **нихәтле** акчаларыбыз җилгә очты, акчалар гына түгел, акчалар белән бергә **нихәтле** матур хыяллар, **нихәтле** якты өметләребез тузанга тузды ... (Шәриф Камал, Матур туганда.) Sadiq. ... Try to think yourself: during the last two or three years alone how much money of ours has been squandered (lit., flew in the wind), (and) not only money, how many beautiful dreams, how many of our bright hopes have vanished (lit., crumbled into dust) together with the money ...
- – Ах, **нинди** матур сез бүген, Гөлшаһидә ханым. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) "Oh, how beautiful you are today, lady Gölshahidä."
- Мин инде байның: «Барысы **ничеү**?» – дип соравын көтеп күзләрем белән иләкләрне саный башладым. (Гариф Гобәй, Без үскәндә.) Expecting the rich man to ask how much they were altogether, I was already beginning to count the sieves with my eyes.
- Хәят өчен ул **ниләр** генә эшләмәде! (Гадел Кутуй, Илһам.) What didn't he do for Khäyat! (i.e., he did everything).

· Кичә бу вакытта **ничек** рәхәт иде. (Мәҗит Гафури, Ярлылар.) How pleasant it was yesterday at this time!
· **Нигә** форсаттан файдаланып калмаска! (Рәфкать Кәрами, Очар кошлар белән янәшә.) Why not take advantage of the opportunity.
· – Нурмөхәммәт абый, кадерлем, мин менә килдем. ... Күр әле, **никадәр** гүзәл икән бит Алсуың. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Өченче Вагон.) "Nurmökhämmät, my dear, here, I have come. ... Look please, how truly beautiful your Alsu is!"

*Note:* **Никадәр** has the expanded form **никадәрле**. The former pertains to both the literary language and the vernacular. The latter belongs more to the vernacular rather than to the literary language. However, the expanded form does occur also in contexts of literary works. Furthermore, compared with the more commonly used **никадәр**, **никадәрле** is felt to be "weightier", to sound "richer". For example: Чәйне кайнатып алып, ... чәй эчә башлады. Менә бу чәй **никадәрле** ләззәтле. (Мәҗит Гафури, Ярлылар.) Having brewed the tea, ... she began to drink tea. How delightful the tea was.

· [Җәмилә] ... өенә кайтып утырды. Бу өй **никадәрле** күңелсез. (ibid.) [Jämilä] ... returned home and sat down. How joyless this house is.
· [Баязитов] ... **никадәрле** генә тынычланырга тырышса да, бюро утырышында үзен гадәттәгечә иркен тота алмады. (Мирсәй Әмир, Ялантау кешеләре.) As much as [Bayazitov] tried to compose himself, he was unable to conduct himself as freely as usual at the office meeting.

*Note 1:* Interrogative pronouns may function as relative pronouns (see 446, 447).

*Note 2:* The pronoun **кайсы** can mean both 'which?' and 'which of?', 'some' and 'some of'. It obviously is a contraction of **кайсысы**, with **+сы** sometimes functioning as the possessive suffix, sometimes losing its original meaning and becoming part of the word.

· Габделхак. Сез шуларның **кайсын** сайладыгыз? (Шәриф Камал, Хаҗи әфәнде өйләнә.) Ghäbdelkhaq. Which one of those did you choose?
· – Күршеләрегезнең **кайсында** телефон бар? (Мәгъсүм Насыйбуллин Ярканат.) "Which of your neighbors has a telephone?"
· Өй эче кызлар белән тулы. **Кайсы** оек бәйли, **кайсы** яулык чигә, **кайсы** челтәр бәйли. (Мирсәй Әмир, Туң ачуы.) The house is crowded with girls. Some are knitting stockings, some are embroidering handkerchiefs, some are making lace.
· ... авылдагы кызларның **кайсы** кияүгә, **кайсы** шәһәргә китеп беткән иде. (Фоат Садриев, Авыш басу икмәге.) ... there were no girls left in the village, some of the girls having got married, others having gone to the city.
· **Кайсылары** Себергә, **кайсылары** Ташкент ягына. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) Some of them (were headed) for Siberia, some for Tashkent.
· Рәхилә. ... Алдыбызда төрле юллар. **Кайсыннан** китсәк, шул безнең гомер /ɢөmer/ юлыбыз булачак. (Хәй Вахит, Беренче мәхәббәт.) Räkhilä. ... Various paths lie before us. Whichever we may set out on will be our life's path.
· – Җомгадан башка көннәрнең **кайсы** да ярый миңа. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) "Any day suits me, except Fridays."

*Note:* The long form carries more weight, is more concrete. For example:

· Валентина. ... Кыяфәтләре! ... белмәссең: **кайсысы** егет тә **кайсысы** кыз. (Габдрахман Минский, Синең җырың.) Valentina. ... And their appearance! ... You won't know which (of them) is the boy and which (of them) the girl.
· Рәсим сорауларның **кайсысына** башта, **кайсысына** ахырда җавап бирергә дә белми торды. (Фаил Шәфигуллин, Өй салуның ние бар.) Räsim did not know which of the questions to answer first and which last.

# Generalizing Pronouns

**[434]** Generalizing pronouns are: һәр 'every', 'each', һәрбер 'each', 'every', 'everybody', 'everyone', һәркайсы 'every', 'each', 'everyone (of them)', һәркем 'everyone', 'everybody', 'each', һәрнәрсә 'everything', бар, барлык, барча(сы) 'all', 'whole', 'entire', бөтен 'all', 'whole', 'entire', һәммә 'all', 'whole', 'entire', 'each', 'every'.

**Һәр** and the compounds formed with **һәр** designate all persons, things, etc., of an unspecified number, amount, or quantity but refer to each of them *separately*. They are commonly used in the singular. **һәр** is always an adjective, **һәрбер** may be an adjective or a noun, **һәркем**, **һәркайсы** and **һәрнәрсә** are always nouns.

The pronouns **бар**, **барлык**, **барча**, **бөтен**, etc. designate a number, amount, quantity of persons, things, etc., *as a whole*. They may function as adjectives and as nouns and can be used in the singular and plural. When functioning as nouns, they often form a possessive relation with their antecedent. If the antecedent is not expressed, it is denoted by the respective possessive suffix on the pronoun.

- **Һәр** сүзгә җавап бар, **һәр** яхшыга савап бар. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) There is an answer to every word, there is a reward for every good (i.e., good deed).
- ... ул ... Гүзәлнең **һәрбер** хәрәкәтен күзәтеп тора-тора иде дә, соңыннан төзәтүләр кертә иде. (Гариф Гобәй /Ɠөbəj/, Ләйсән яңгыр.) ... he was watching Güzäl's every movement and afterwards correcting her (lit., he was introducing corrections).
- Нурия. ... Иртән тор да ашарга әзерлә, кич ашарга әзерлә! Аннан соң **һәрберсен** ашарга кыстап йөр. (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Nuriä. ... In the morning get up and prepare the food, in the evening prepare the food! Then keep entreating everyone to eat.
- Максудов. Анысы дөрес, Нурия, **һәрнәрсәнең** үз вакыты бар. (ibid.) Maqsudov. That is correct, Nuriä, everything has its time.
- **Һәркем** «яз» ди, **һәркем** аны эче, җаны белән сизә. **Һәрнәрсә** аның чиге булмаган матурлыгына, моңына баш ия ... (Галимҗан Ибраһимов, Яз башы.) Everybody says "spring", everybody feels it inside himself, in his heart. Everything bows to its boundless beauty, to its melody ...
- Әнә ерак таулар, урманнар, әнә матур гына дулкынланып күренә торган уҗым басуы, ..., – болар **бар** да бизәнгән, **бар** да хәтфәдәй үләннәр белән түшәлеп, сары, кызыл, ал чәчәкләр белән матурланганнар. (ibid.) Those distant mountains (and) woods there, that winter field there, which appears to sway beautifully, ..., these all are adorned, all covered with grass like velvet (and) beautified by yellow, red and scarlet flowers.
- **Бар** кешегә дә ярап бетә алмассың. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) One cannot please all people.
- **Бары** да шатланалар. (Мирсәй Әмир, Телефон.) All (of them) are glad.
- Разия. ... Җыелышта **барын** да ачык итеп әйт ... (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Razia. ... Say all (of it) frankly at the meeting ...
- Мин **барына** да риза ... (Риза Ишморат, Шайтан таягы.) I agree to all of it ...
- **Барыннан** да элек, мин аңа Мәҗит Гафуриның сәламен тапшырдым. (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Сәйфи Кудаш.) First of all, I conveyed Mäjit Ghafuri's greetings to him.

- Миңнулла. ... Анда тагын кемнәр була соң? Фатыйма. **Барысы** да үзебезнекеләр, чит кеше булмый. (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Mingnulla. ...? Who else will be there then? Fatima. All (of them) are ours (i.e., our people), there will be no strangers.
- Ләрия. Нигә миннән сорыйсыз аны? Нигә **барыгыз** да миңа текәләсез? (Аяз Гыйләҗев, Без унике кыз идек.) Läriä. Why do you ask me that? Why do you all stare at me?
- Самат. Мин **аларның барысы** белән уйныйм. (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күңел.) Samat. I play with all of them.
- – Мин **барысын** да бераздан сиңа аңлатырмын, – диде Фәрит. (Атилла Расих, Сынау.) "I shall explain all of it to you in a moment," said Färit.
- Галимҗан Ибраһимов иң элек кара тактага кечкенә-кечкенә түгәрәкләр сызды. Аннан соң ... бу вак түгәрәкләрнең **барчасын** бер зур түгәрәк белән әйләндереп куйгач, ... (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Сәйфи Кудаш.) Ghalimjan Ibrahimov first drew tiny circles on the blackboard. Then, ... surrounding all of these small circles with one large circle, (he began to speak).
- Кулдан килгән **барлык** чараны күрергә ... кирәк. (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) All possible measures must be taken ...
- ... Хәйрулла агайның өлешенә тигән җирнең **барлык** игене бурычны түләргә дә җитми иде ... (Кәрим Тинчурин, Кара көннәрдә.) All the corn of the land, which fell to uncle Kheyrulla's share, did not suffice to pay the debts ...
- Әмирҗан. Миңа монда күренергә ярамый. ... Садыйк. Алай булгач, менә нәрсә, балам, ... Тузларның **барлыгы** да кайсы кая китеп беттеләр ... (Шәриф Камал, Матур туганда.) Ämirjan. I must not be seen here. Sadiq. If that is so, here is what, my child ... Each of all the bigwigs have left for somewhere ...
- Керде, идарә йортындагыларның **барысына** да күз йөртеп, **бөтенесе** белән берьюлы исәнләште, ... (Фатих Хөсни, Авыл өстендә йолдызлар.) He entered (and), running his eyes over all of those in the administration building, he greeted all (of them) simultaneously, ...
- Бер сүз белән әйткәндә, малай урамда да **бөтенесен** үз кубызына биетте. (Гариф Гобәй, Ләйсән яңгыр.) In a word, on the street too, the boy made all (of them) dance to his tune.
- ... ул ... Ялтага ял итәргә килгән кешеләрне бик шатланып кабул итә. Үзен кызыксындырган **бөтен** хәлләрне сораша. (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Сәйфи Кудаш.) ... he gladly receives the people who came ... to Yalta for vacation. He asks about all the news which interests him.
- Күп тә үтмәде, әлеге шәригебез ... мәдрәсәдәге **бөтен** шәкертләрнең күзләренә чалына башлады. (ibid., Фәтхел Корбангалиев.) Soon, that same classmate of ours began to catch the eyes ... of all the students in the medrese.
- Һәрхәлдә, ул **бөтен** көчен, сәләтен җигеп, шуңа омтылырга тиеш. (Әмирхан Еники, Рәшә.) At any rate, he must muster all his strength, his talent, and strive for that (goal).
- Галимҗан аларның **һәммәсе** белән сөйләшергә сүз таба. (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Гөлсем Мөхәммәдова.) Ghalimjan finds something (lit., a word) to talk about with all of them.
- «Ул мәхәббәт, ул шатлык, ул якты тереклек, якты көннәр – **һәммәсе** үтте, **һәммәсе** калды...» – диләр. (Шәриф Камал, Иптәшемә.) They say, "That love, that joy, that brilliant life, those bright days – all that has passed, all that has been left behind..."

- Галия. Мин болай дип һич уйламаган идем, Рәүф иптәш... **һәммә** җир төзәтелгән, рәтләнгән, матурланган ... (Шәриф Камал, Ут.) Ghaliä. I never thought it would be like this, comrade Räüf... The whole place has been restored, put in order, beautified ...
- **Һәммә** башта бер хыял. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) So many men, so many dreams (lit., In each head is a dream).
- ... Кәбир ... мәҗлестәге **һәммә** сүзләрне, фикерләрне кире кагып, юкка чыгарачак. (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) ... Käbir ... will reject and disprove all words (and) thoughts (expressed) at the meeting.

*Note 1:* **Бар**, **барча**, **барлык**, **бөтен** and **һәммә** may limit, or refer to, nouns in the plural designating several individual persons, things, or places, as well as to nouns indicating a collective whole.

*Note 2:* Having the same meaning ('all', 'whole', 'entire'), the usage of these pronouns is determined by 1) subtle stylistic nuances within a given context; 2) personal preference or habit; 3) to avoid undesirable repetition of the same pronoun:

- [Зиннур] Эретеп ябыштырылган кыршауларны кат-кат карады. **Барысы** да тәртиптә сыман, **һәммәсе** үз урынында кебек, **барлык** кыршаулар да һични кермәслек һәм чыкмаслык итеп ябыштырылган төсле. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) [Zinnur] examined again and again the hoops which had been welded on. All seem to be in order, all appear to be in their place, all hoops seem to have been welded on, so that nothing could get in or out. (Z. examines the interior of a huge condenser.)

## Indefinite Pronouns

**[435]** Indefinite pronouns are formed by:
a) placing the particle **әллә** *before* the interrogative pronouns;
b) joining the suffix **+дыр**, **+дер**, **+тыр**, **+тер** to the interrogative pronouns.

| | | | |
|---|---|---|---|
| әллә кем | - | кемдер | somebody, someone |
| әллә нәрсә | - | нәрсәдер | something |
| әллә ни | - | нидер | something |
| әллә кайсы | - | кайсыдыр | somebody, someone |
| әллә нинди | - | ниндидер | some kind of, something like |
| әллә ничә | - | ничәдер | rather many (no one knows how many) |
| әллә никадәр ) | - | никадәрдер ) | rather, pretty many, a great many |
| әллә нихәтле ) | - | нихәтледер ) | |
| әллә ничаклы ) | - | ничаклыдыр ) | |
| әллә күпме | - | күпмедер | some (unknown quantity) |
| әллә ничек | - | ничектер | somehow, in some way |
| әллә нигә ) | - | нигәдер ) | for some reason (or another) |
| әллә ник ) | - | никтер ) | |
| әллә кайда | - | кайдадыр | somewhere, someplace |
| әллә кайдан ) | - | кайдандыр ) | from somewhere |
| әллә каян ) | - | каяндыр ) | |
| әллә кая | - | каядыр | to some place, somewhere |
| әллә кайчан | - | кайчандыр | sometime, sometime ago |

**[436]** The suffix **+дыр**, **+дер** (**+тыр**, **+тер**) is subject to vowel harmony. It is unstressed and always *follows* other suffixes (plural, possessive, inflective, etc.) joined to those indefinite pronouns which are nouns or function as nouns for example, кемгәдер 'to somebody, someone', нәрсәдәндер 'from something', кайсыларыдыр 'some of them'.

## Meaning and Use of the Indefinite Pronouns

Formed with **әллә** and **+дыр**, **+дер**, **+тыр**, **+тер**

**[437]** The meaning of indefinite pronouns formed with **әллә** and that of their counterparts with **+дыр**, **+дер**, etc. is not exactly the same, and they may therefore not be used interchangeably. Differences are rather subtle and may be discerned as follows:[1)]

The forms with **әллә** generally carry more weight than those with **+дыр**, **+дер**. In a sense, the logical emphasis is, therefore, often more on the pronoun than on the action or condition. Furthermore, indefinite pronouns formed with **әллә** merely point out persons, places, things, ideas, or time. There is no indication that the speaker desires to elucidate or define. Also, the indefinite pronouns formed with **әллә** and expressing time or place, may connote that the action, condition, or event took place or prevailed long ago, or that it occurred far away.

The forms with **+дыр**, **+дер**, etc. commonly carry no particular emphasis; primary attention is directed towards the action or state. The vagueness expressed by this category appears as though requiring elucidation, and it may have a connotation of *wondering, doubt, suspicion, embarrassment.* Also, the forms with **+дыр**, **+дер**, etc. may indicate that the speaker (narrator), the acting person or the person spoken of remembers, knows, or perceives the event, action or condition only vaguely.

*Note 1:* In praxis, it often appears that only the speaker (narrator), (who may be "wondering", "doubting", "suspecting") would need elucidation. The person spoken of would be the one able to elucidate, should he (she) so decide.

*Note 2:* The "person spoken of" may be the acting person, the subject of the sentence.

Furthermore, the following may be added:[2)]

The indefinite form with **әллә** appears as though it contained a certain "internal" element of definiteness, certainty, while in the form with **+дыр**, **+дер**, etc. there seems to exist an "internal" (additional) element of indefiniteness, uncertainty, whereby "definiteness" denotes higher degree of attention, "indefiniteness" lower degree of attention.

For example: **әллә кем** сөйли 'someone is speaking' (i.e., some interesting person is speaking; the listener sits up and takes notice); **кемдер** сөйли 'someone is speaking' (said as a mere statement that someone is speaking somewhere).

**[438]** Indefinite pronouns are used when the speaker (writer) does not wish, or is not able, to describe a person, thing, etc., in a more precise, specific manner, or when he (she) wants to express a quantity, measure, etc., in an indefinite way. Hence, indefinite pronouns may also be called "indefinite pronouns and numerals".

- – Синең шикелле шәкертләргә генә **әллә кем** бит ул! Без андыйларны куп күргән! ... Матур киемнәр киеп, зур бантиклар тагып йөргәч, синең шикелле шәкертләр аны **әллә кем** дип уйлыйлар. (Фатих Әмирхан, Урталыкта.) "He is somebody only to students like you! We have seen plenty of such! ... When he dresses smartly and tacks on large bows, students like you think he is somebody."

---

1) For the difference between indefinite pronouns formed with **әллә** and those formed with **+дыр**, **+дер** see also: В.Н. Хангилдин, Татар теле грамматикасы, Казан 1959, and: З.М. Вәлиуллина, К.З. Зиннәтуллина, М.А. Сәгыйтов, Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе, Казан 1972.

2) This information supplied by D. Phil. H. R. Qurbatov, of the Ghalimjan Ibrahimov Institute for Language, Literature and History of the Academy of Sciences of Tatarstan.

- Кинәт күрше бүлмәдән **кемнедер** чакырып еламсыраган бала тавышы ишетелде. (Атилла Расих, Ике буйдак.) Suddenly one heard from the adjacent room the whining voice of a child calling someone.
- **Кемдер** моңлы итеп баянда озын көй уйный. (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Someone is melancholy playing a long tune on the accordion.
- ... студентларның бу чыгып китешләре аның **әллә нәрсәсен**, йөрәгенә якын нәрсәсен җимерә иде. (Фатих Әмирхан, Урталыкта.) ... this walking out of the students was destroying something in him, something which was close to his heart.
- ... аның җаны **әллә нәрсәне** юксына, **әллә нәрсәне** сагына, моңлана иде. (ibid.) ... his heart was longing for something, it was pining, grieving for something.
- Ул миңа ... үз телендә **нәрсәдер** сөйли башлый. (Миргазиян Юныс, Юл язмалары.) ... he begins to tell me something in his own language.
- Исхак ... арткарак чигенде һәм **нәрсәгәдер** абынып егылды. (Аяз Гыйләҗев, Берәү.) Iskhaq moved back a little and, stumbling over something, fell down.
- Газизә ... **нәрсәдер** тегеп утыра иде. (Шәриф Камал, Таң атканда.) Ghäzizä was sitting, sewing something.
- – Абый, **әллә ни** бар! – Кайда? – Әнә, әнә, кыштырдый. (Аяз Гыйләҗев, Урамнар артында яшел болын.) “Uncle, there is something (there)!” “Where?” “There, something is rustling!”
- Айзат вагонга керде. Халык күп булса да, төн уртасы авышканлыктан, **әллә ни** тавыш, шау-шу юк иде. (Газиз Мөхәммәтшин, Йөрәктәге эзләр.) Aizat entered the (railway) carriage. Although it was crowded, there was no sound, no noise at all, for midnight had passed.
- Ышандымы ул минем бу ялганыма, юкмы – әйтә алмыйм, ләкин **нидер** сизенде булса кирәк. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) Whether or not she believed this lie of mine – that I cannot tell, but she must have sensed something. (For булса кирәк see 1010.)
- ... чынлап та **нидер** аны борчый иде булса кирәк. (ibid.) ... really, something appeared to be troubling her.
- Алар тирәсендә без дә – малайлар, кызлар – **ниндидер** уен корып, чыр-чу килеп йөри идек. **Кайсыдыр** шунда минем хакта сүз башлап җибәрде: ... (Мирсәй Әмир, Әби васыяте.) We too, boys and girls, were carrying on some kind of a game and making a din around them. Suddenly, someone there began to talk about me: ...
- **Кемнәрдер** сораулар бирделәр, **кайсыларыдыр** Мәснәвине, **кайсыларыдыр** Фәнүзәне яклап сөйләде. (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) Some people or other asked questions, and there were some others who spoke (in reply), supporting Mäsnäwi, and some others Fänüzä.
- Башта бу китаплар аның ихтыярын биләп алдылар. Ул **әллә нинди** ят дөнья эченә кереп китеп, яңа хисләр, яңа кичерешләр давылы эчендә бөтерелде ... (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) At first these books possessed his mind. He entered into some strange world and was gyrating in a storm of new emotions, of new experiences ...
- Менә бер заман **кайдадыр** бер кибет янында коточкыч тавышлар ишетелә башлый ... Анда **ниндидер** бер тәрбиясез калган бала тотылган булып чыга; чәлдергән, күрәсең ... (Мирсәй Әмир, Казан урамнарында.) Now, suddenly, somewhere in the vicinity of a shop, a terrible yelling starts up ... There, it turns out, some homeless boy (lit., a boy who has remained without an education) has been caught; it seems he has stolen (something) ...
- Ә ике йорт арасында **ниндидер** сөйләшүләр бара, **нәрсәдер** эшләргә җыеналар, мин моны сизеп торам ... (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) But between the two houses (i.e., families) some talks are going on. They are about to do something, I sense this ... (Expresses suspicion and doubt.)

- Шәһәрнең **әллә ничә** урынында яшел утраулар шикелле бакча-парклар күп. (Газиз Мөхәммәтшин, Йөрәктәге эзләр.) In rather many places of the city there are numerous gardens and parks, like green islands.
- – Төлкенең күзе яшел буламыни? – Төнлә шулай яшел булып күренә ул ... ут яктысында. Мин инде **әллә ничәне** күрдем, ... (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) "Can the eyes of the fox then be green?" "At night, in the glow of the (camp) fire, they look green like this. I have already seen quite a few, ..."
- – Бер генә колак белән тыңладым, анда да **әллә никадәр** акыллы сүз ишетеп калдым. (Фатих Хөсни, Җәй башы.) "I listened only with half an ear; even then I heard a good many clever words."
- ... диңгез өстендә **әллә нихәтле** акчарлаклар, өермәгә эләккән яфраклар төсле, буталып очыналар ... (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) ... over the sea a great many seagulls are flying about in a jumble, like leaves caught up in a storm ...
- **– Күпмедер** шулай телгә килә алмыйча барганнан соң, бу үз алдына әйткәндәй: ... дип куйды. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) "After walking like that for some while, unable to find words, he finally said, as though speaking to himself: ..."
- ... Санияләргә барып йөри башлаганнан бирле, Исхак **әллә ничек** үзгәреп китте. (Аяз Гыйләҗев, Берәү.) Since the time he had begun to frequent Saniä's house, Iskhaq somehow changed.
- Бүген якшәмбе, Курамшинның ял көне. Ул моны, **ничектер**, онытып җибәргән иде ... (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) Today was Sunday, Quramshin's day off. Somehow he had completely forgotten this ...
- **– Әллә нигә** аркам суыксынып тора. (Аяз Гийләҗев, Берәү.) "For some reason, my back feels a little cold."
- Нуруллалардан чыккач, ул **нигәдер** басу ягына борылды. (ibid.) After he left the Nurullas, he turned for some reason or other towards the field.
- **Нигәдер** минем бу турыда сөйләшәсем килми иде. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) For some reason or other, I did not wish to talk about this.
- Хәсән **никтер**, бу сораудан уңайсызланып, кызарып китте ... (Фатих Әмирхан, Урталыкта.) For some reason or other, Khäsän felt unconfortable and blushed from this question ...
- **Әллә кайларда** булып кайткан яңа иптәше булу ятим малайның китек күңелен беркадәр юатты да, ахры. (Аяз Гыйләҗев, Берәү.) Having a new friend, who had been to some faraway places, probably soothed to some degree the orphan's torn heart.
- **Әллә кайда**, еракларда калган туган иленә, **әллә кайчан** үткән бала чакларына күңеле китте. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) He longed for his native country, which lay (lit., remained) somewhere far away, for his childhood, which had passed sometime (long) ago.
- Әйе, **кайдадыр** ярларында пальмалар үсеп утырган шау диңгезләр бар ... (Әхәт Гаффар, Кашан җыры.) Yes, somewhere there are noisy seas on whose coasts palm trees grow ...
- Ай калыкмаган, **кайдадыр** яшеренеп тора. (Шәриф Камал, Таң атканда.) The moon has not risen; it is hiding somewhere.
- Фәйзи **каядыр** чыгып киткән, Фәрхи карчык зал якта **ниндидер** бер хатын белән сөйләшеп утыра. (Шәриф Камал, Таң атканда.) Feyzi has gone somewhere, (and) the old woman Färkhi is sitting in the saloon, talking with some woman.
- Булат, ..., сөйләп барганда, **кайдандыр, ниндидер** ... бер шау-шу ишетелә башлады. (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) While Bulat was speaking, ... some kind of noise began to sound (began to be heard) ... from somewhere.

- – **Каяндыр** тәвәккәллек килде, һәм мин шул ук көнне барысын да Нәҗипкә әйтеп, эшне берьюлы бетерергә булдым. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) "Somehow (lit., from somewhere) I got the courage and I decided to tell Näjip everything that same day, and, at the same time, to put an end to the matter."
- – Син аларны **әллә кайчан** онытткансың инде, Камил ... (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) "You have probably forgotten them (i.e., the letters) already – long ago, Kamil ..."
- Курамшинның калу-калмау мәсьәләсе, бәлки, **әллә кайчан** хәл ителгәндер инде?! (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) The matter of whether or not Quramshin would stay on had perhaps been already decided sometime ago!
- Хәдичәнең әтисе җибәрткән фаэтон һәм бер гади арба кунакларны **әллә кайчаннан** бирле көтә икән инде. (Атилла Расих, Ямашев.) The phaeton and an ordinary wagon, which Khädichä's father had sent, had been waiting for the guests for some time already.
- Аның бабасы да **кайчандыр** шушы юлдан йөргән ... (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) His grandfather too has walked along this road sometime ...

## Бер, берәр and берәү as Indefinite Pronouns

**[439]** The cardinal number **бер** 'one', the distributive number **берәр** 'one each', and the collective number **берәү** 'one of them', may function as indefinite pronouns. **Бер** then means 'some', 'someone', 'somebody', reduplicated – **бер-бер** – it means 'some'; **берәр** means 'some (kind of)', 'a certain', **берәү** 'someone', 'somebody'. **Бер** and **берәр** may be adjectives or nouns, **берәү** is always a noun.

- Тукта! Монда **берсе** йөри, Әхтәрҗан! (Нәкый Исәнбәт, Миркәй белән Айсылу.) Wait! There is someone walking here, Äkhtärjan!
- Хәзер аның иң курыккан нәрсәсе **бер-бер** көтелмәгән хәл: янгын, талану, югалту ... **бер-бер** кардәш-ыругы белән **берәр** хәл булып, моңардан ярдәм сорап килү. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) What now frightens him most is some unexpected event: fire, robbery, loss ... some accident happening to some relative and the request to him to help.
- – Телисезме, мин сезгә **берәүнең** башыннан кичкән ... кызыклы бер тарихын сөйлим. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) "If you wish, I will tell you an interesting story of what someone went through."
- ... төрле яктан ... кешеләр килә башлады. **Берәүләр** якындагы авыллардан ... килделәр, икенче **берәүләр** ерак илләрдән ... кайтып, хан янына йомышларын йомышларга ашыктылар. (Нурихан Фәттах, Әтил суы ака торур.) People began to arrive ... from various directions ... Some came from nearby villages, ... some others returned from distant countries ... and hurried to convey their messages to the Khan.
- – ... Китап ачучылар без. Фалчылар. Ишеткәнегез бардыр инде. ... – Безнең авылда да бар **берәү**, ногыт борчагы белән фал ача. (Нәзифә Кәримова, Карурманнан чыккан кешеләр.) "We interpret the (fortune) book. We are fortunetellers. You have most likely heard." ... "There is someone in our village too; he tells fortunes – reading beans."

# Compound Indefinite Pronouns Formed with бер, берәр, берәү

**[440]** United with interrogative pronouns, **бер**, **берәр**, **берәү** form compound indefinite pronouns.

**Бер** is *prefixed* to **нәрсә**, **ничә**, **никадәр** (**нихәтле**, **ничаклы**) to form **бернәрсә** 'something', **берничә** 'some', 'several', **берникадәр** (**бернихәтле**, **берничаклы**) 'to some degree'. It is *attached* to **кай** and **кайсы** to form **кайбер**, **кайсыбер** 'some'.

**Берәр** is placed before **кем** and **нәрсә** to form **берәр кем** 'somebody', 'someone', **берәр нәрсә** 'something'.

The plural of **берәү** is combined with **кай** to form **кайберәүләр** 'some of them'.

Examples:

- Габдулла үзенең иптәшләре белән **бернәрсәне** ачык төшенеп алды: Ниндидер галим булыр өчен укырга кирәк. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) Ghabdulla and his friends understood something (one thing) clearly: to become some educated person, one must study.
- Улының нигә өйләнмәвен дә **берникадәр** сизенә иде Маһибәдәр. (Аяз Гыйләҗев, Берәү.) Mahibädär sensed to some degree why her son was also not getting married.
- – Андый кешеләр **берничә** дистә елга, хәтта, мин әйтер идем, гасырга бер генә булалар. (Рәфкать Кәрами, Кошлар белән янәшә.) "Such people are only one in several decades, even in a century, I would say."
- – Күзгә күренеп үсәләр, ... Насыйп булса, быел **берничәсе** алма бирә башламасмы, дип торабыз, – диде Хөрмәтулла карт ... (Фатих Хөсни, Җәй башы.) "They (i.e., the apple trees) are growing visibly, ... We keep saying that, if it is granted, some of them will perhaps start bearing apples this year," said old Khörmätulla. (Lit., We keep saying: If it is granted, will some of them not start bearing apples?)
- – Синең **кайбер** сүзләрең, әлбәттә, дөрес. (Шәриф Камал, Матур туганда.) "Some of your words are, of course, true."
- – Сез ят кеше, ир кеше, шуңа күрә миңа **кайбер** нәрсәләрне сөйләве бик кыен булачак. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) "You are a stranger, a man; therefore, saying some things will be very difficult for me." (The speaker is a woman.)
- Биредә гомумән эреле-ваклы юллар бик күп икән. Аларның **кайберләре** борылып-борылып куе агачлыклар арасына кереп югалалар; ... (ibid.) On the whole, there turn out to be very many large and small (foot) paths here; some of them, winding along, run into dense groves and disappear; ... (For икән see 742, b.)
- Кич белән Мария аның **кайсыбер** нәрсәләренең төшкән төймәләрен тагып, сүтелгән җирләрен ямап бирде. (Фатих Әмирхан, Урталыкта.) In the evening Mary sewed the buttons back on which had come off some of his things, and she mended the spots which had become torn.
- – Юк, мин ашамыйм. ... Мин **берәр нәрсә** эчеп кенә утырам. (Галиәсгар /Ǥəliəsǥər/ Камал, Безнең шәһәрнең серләре.) "No, I am not eating. ... I'll sit and just drink a little something."
- Ул күзләрен ачканда П.П. та, башкалар да торып беткән, **кайберәүләр** чыгып та киткән иде. (Газиз Мөхәммәтшин, Йөрәктәге эзләр.) When he opened his eyes, P.P. and the others had already got up, and some of them were already gone.

## The Indefinite Pronouns
## фәлән, фәләнчә, фәлән-төгән, фәлән дә төгән, фәлән (дә) ... төгән, фәлән-фәсмәтән

**[441] Фәлән**, **фәләнчә** 'so and so', 'such and such'. They point out, in a general way, persons, places, or things whose name is either not specified, or not known, or whose name the speaker does not wish to mention at the moment of speaking. Joined to nouns (in writing connected with a hyphen), it adds a nuance of indefiniteness or indifference. **Фәлән** may function as an adjective, a noun, or as an adverbial modifier.

- Марина белә иде. ... Мәрвия үзе сөйләде. Бәхтигә хат язган иде ул. **Фәлән** көннең **фәлән** сәгатендә **фәлән** җиргә кил әле, бик кирәк, диде. (Кояш Тимбикова, Агым уртасында.) Marina knew. ... Märwiä told her herself. She had written Bäkhti a letter. "Please come at such and such a time on such and such a day to such and such a place; it's absolutely necessary", she (had) said.
- – Абый, мине дә эшкә алыгызчы? Җавап тагын шул ук: **Фәлән** конторага, **фәлән-фәләневич** янына. (Рафаил Төхфәтуллин, Агымсу.) "Uncle, please, take me on too?" The answer is again the same: (go) to such and such an office to Mr. So-and-so.
- Бер заман бер патшаның вәзире: «Мин патша булсам, **фәләнне фәлән**, ... итәр идем, ... – дип, ...» мактанган, ди. (Татар халык әкиятләре, Патша, вәзир, тегермәнче.) A king's minister once ... boasted (so they say): "If I were king, I would do certain things in a certain way ..."
- Берсе әйтә: «**Фәлән** йөз сум бирәм!» (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) One of them says, "I am giving you so many hundred rubles."
- **Фәлән** җирдә бик зур янгын булган, **фәлән** җирдә боз яуган, **фәлән** җирдә **фәләнчә** кеше суга баткан, **фәлән** кеше эссе булганлыктан, тәрәзә ачып яткан икән, өенә караклар кергән, **фәлән** җирдә эссе сугудан **фәләнчә** кеше вә **фәләнчә** хайван үлгән, дигән хәбәрләрдән башка хәбәрләр булмый. (Галиәсгар Камал, Эч пошканда.) There isn't (usually) any other news; besides that, at such and such place, there was a very big fire (they say); at such and such place there was a hailstorm (they say); at such and such place so and so many persons drowned (they say); because it was hot, such and such a man lay down with the window open (and) thieves entered his home (they say); at such and such place so and so many people and so and so many animals died of heatstroke (they say).

(For the use of the past tense II to relate non-witnessed action or condition see 967.)

- Өйнең әйләнәсендә **киртә-фәлән** юк. (Кәрим Әмири, Әсма.) Around the house there is no kind of a fence.
- Урман артында сыерлар мөгерәве, чыбыркы шартлаткан, эт өргән тавышлар ишетелде. Тиз генә сикереп тордым да, шушы гомер онытылып ятуым өчен үземне тирги-тирги, **сукмак-фәлән** карап тормый гына җәйләүгә таба йөгердем. (Әнисә Ибраһимова, Томан тарала.) One could hear the sounds of the cattle lowing behind the woods, of a whip cracking, of a dog barking. I quickly jumped up and, scolding myself for having forgotten this (side of) life, ran towards the (village) pasture without so much as keeping (observing, paying attention) to any kind of a path.

**[442] Фәлән-төгән**, **фәлән дә төгән**, **фәлән** (дә) ... **төгән**, **фәлән-фәсмәтән** 'this and that', 'one thing and another. These indefinite pronouns are likewise used to refer to or to enumerate, in a general way, persons, things, places, conditions, conversations, etc., without

naming or specifying them. Furthermore, they are used instead of specific words to express negative evaluation, to point out negative characteristics. They are therefore often used in contexts in which disregard, disparagement, or the speaker's negative attitude towards the subject matter are expressed. Like **фәлән** alone, **фәлән-төгән**, etc., may function as an adjective, as a noun, or as an adverbial modifier. Фәлән-фәсмәтән and фәлән-төгән are synonymous.

- Анысын афишада болай дип язарбыз: «Биш бүлектә зур концерт. Катнашалар: шәһәрдән килгән мәшһүр студентлар: **Фәлән-фәлән** улы, **фәлән-төгән** кызы һәм башкалар.» (Шәриф Камал, Матур туганда.) We shall write that on the poster like this: "Big concert in five parts. Participating are: famous students who have come from the city; the son of so and so, the daughter of so and so and others."
- Тормышның бик кыен чаклары булгалады. Әмма аналары бервакытта да «атагыз **фәлән дә** атагыз **төгән**» дип тел озайтмады. (Гомәр /Ɋөmər/ Бәширов, Җидегән чишмә.) Life was very difficult at times (lit., Life had very difficult times now and then). But their mother never made any disparaging remarks (or: never spoke ill of, vilified their father) like (lit., saying) "your father is this ... and your father is that" ...

(For frequentative verbs in -гала– /-ɣala-/, -гәлә– /-gələ-/, -кала– /-qala-/, -кәлә– /-kələ/ see 1309-1316.)

- Галия. ... Нәфисә карчык улы Гомәр дигән кеше. Килгән дә монда акыл сатып утыра. Сез дигән була, абыегызга тәэсир ясый алмадыгыз, ул ахмак, **фәлән-төгән** имеш. (Шәриф Камал, Ут.) Ghaliä. ... a man called Ghömär, old Näfisä's son. He came here and sat, talking big (giving unneeded advice). He said that I was unable to influence my (older) brother, that, as he put it, he is a fool, he is all kinds of (bad) things.
- Бер заман бер патшаның вәзире: «Мин патша булсам, **фәләнне фәлән, төгәнне төгән** итәр идем, шунсын шулай, монысын болай итәр идем, – дип ... мактанган, ди. (Татар халык экиятләре, Патша, вәзир һәм тегермәнче.) A king's minister once ... boasted (so they say): "If I were king, I would do certain things in a certain way, some other things in some other way, that thing I would do in that way, this thing I would do in this way."
- ... тиктомалдан Әдилә турында сүз башлый да минем күңел кылларын тарткалап карый. ... бер дә юкка Әдиләне яманларга тотына. Чигү-тегү эшен дә белми, имеш. **Фәлән дә төгән**, имеш. (Аяз Гыйләҗев, Язгы кәрваннар.) ... he suddenly begins to talk about Ädilä and tries to strike a chord in me (lit., to set my heartstrings vibrating). ... without any reason he starts to disparage Ädilä. Allegedly, she doesn't know embroidering or sewing either. Allegedly, she cannot do all kinds of things.
- Мин һәйкәл янына киләм дә уйланам: бу кешене өзелеп сөйгән берәр хатын-кыз булды микән бу дөньяда? Үзе исән чакта сагынып, саргаеп яраткан бердәнбер яры булганмы икән? Нишләптер бу хакта бер генә белешмәдә дә, энциклопедиядә дә язмыйлар. Ул фәлән-фәлән диңгезләрдә йөзгән, аның карамагындагы фәнни тикшеренү кораблары **фәлән дә төгән** дип аталган, аның исеме белән фәлән бугаз атала. (Мәдинә Маликова, Янартаулар яктысында.) I step up to the statue and I am thinking: "Has there perhaps been in this world a woman who loved this man dearly? When he was alive did he himself perhaps have a one and only sweetheart whom he longed for, whom he loved and worried about? How come that they do not write about this either in guidebooks or in the encyclopedia. He has sailed such and such seas, the research vessels under his command carried such and such names, such and such strait is named after him."

*Note:* The above refers to the statue in Petropavlovsk-Kamchatski of the French navigator La Pérouse.

- ... кайбер иптәшләр куркытып маташтылар: халык җәнҗал чыгарыр, **фәлән-фәсмәтән**, имеш. (Шәриф Камал, Матур туганда.) ... some comrades tried to frighten (us): People would start a brawl and what not.
- – ... син аларның берсенә дә ышанырга тиеш түгел. Буген алар сиңа дуслык күрсәтәләр, Каюм абзый, син шулай безгә дус, **фәлән-фәсмәтән**, дип торалар икән, иртәгә шул ук кешеләрнең сине сатулары бик мөмкин. (ibid.) "... you must not believe any one of them. Today they show you friendship, telling you: Uncle Qayum, you are such a friend to us, and what not. Tomorrow it is very possible that the same people will betray you."

## Negative Pronouns

**[443]** Negative pronouns are formed by prefixing **бер** or **һич** 'not a', 'no', to interrogative pronouns: беркем (дә) – һичкем 'nobody', 'no one', бернәрсә (дә) – һичнәрсә 'nothing', берни (дә) – һични 'nothing', бернинди (дә) – һичнинди 'none whatever', берничек (дә) – һичничек 'in no manner', 'in no way', беркайда (да) – һичкайда 'nowhere', беркая (да) – һичкая 'to nowhere', беркайдан (да) – һичкайдан 'from nowhere', беркайчан (да) һичкайчан 'never'.

Both categories of negative pronouns are synonymous and both require the predicate of the sentence to stand in the *negative*.

Negative pronouns formed with **бер** are often used with the intensive particle **да**, **дә**.

*Note:* Negative pronouns may be formed only from interrogative pronouns whose meaning permits this.

Examples:

- Фатыйма. ... Мин синнән бары шуны гына үтенәм: ... **Беркемгә бернәрсә** сөйләмә. (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Fatima. ... I beg of you only this: ... Do not tell anybody anything.
- Бүген алар бер-берсенә **берни** эндәшмәделәр. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Today they did not say anything to one another.
- Барысы да үз урынында иде, **бернигә беркем** тимәгән иде ... (ibid.) Everything was in its place, no one had touched anything, ...
- – Ул чакларда әле Нәҗип белән минем арада дуслык дип әйтерлек **берни дә** юк иде. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) "At that time there was not yet anything between Näjip and me that could be called friendship."
- – Безнең **беркемгә дә бернинди** вәгъдә биргәнебез юк. (ibid.) "We have not given any promise to anybody."
- – Мин моны теләми идем әле, мин моңа **берничек тә** әзер түрел идем. (ibid.) "I did not want this, yet I was not ready for this in any way."
- – ... әйләнеп кайтсак, авылдан **беркая да** китмибез. (Аяз Гыйләҗев, Берәү.) "... if we return, we shall not go anywhere away from the village."
- ... кайсы гына якка күз салсаң да, **беркайчан да** адәм кулы тимәгән карт дала сузылып ята. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) ... in whichever direction you look, there stretches the ancient steppe, which the human hand has never touched.
- Инде хәзер бу далада **беркайчан да** туктап-тынып тормаячак эш башланды. (ibid.) Work has already begun now in this steppe which will never cease.
- Минем мондый сүз һәм киңәшне **һичкемнән** ишеткәнем юк иде әле. (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Сәйфи Кудаш.) I had not yet heard such talk and advice from anybody.

- Галия. Синең хезмәт юлың җимерелә икән, аңа **һичкем** гаепле түгел. Бары син үзеңне гаепләргә тиеш. (Шәриф Камал, Ут.) Ghaliä. If your career is destroyed, it is nobody's fault. You must blame yourself alone for it.
- Рәүф. Галия! Бу ни бу? ... Еларлык **һичнәрсә** булганы юк. (ibid.) Räüf. Ghaliä! What is this? ... After all, nothing has happened to cry about.
- Галия. ... Карагыз әле, нишләп сез миңа барып чыкмыйсыз? Мин үзем **һичкайда** чыгып йөрмим, бер ялгызым бүлмәдә гел укып утырам. (ibid.) Ghaliä. ... Look please, why don't you come to see me. I do not go out anywhere. I am always sitting all alone in my room, reading.
- Кызның **һичкайчан** мондый күңелле кичәләрдә булганы юк ... (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) The girl had never been at such lively parties ...
- – Ни сөйлисең син, ...? **һични** аңламыйм... (Ранис Газизов, Күккә ябышкан болыт.) "What are you saying there, ...? I don't understand anything."
- Риан үзен, электәгечә үк, **һичнигә** исем китми дигән сыман һавалы тота. (Гурий Тавлин, Афәт.) Rian behaves haughtily, just as before, as though he doesn't care a straw.
- Дөреслек – безнең якта. Һәм моны дәлилләү дә **һичнинди** кыенлык тудырмый. ( Индус Таһиров, Татарстан: кичә, бүген, иртәгә.) The truth is on our side, and proving it does not create any difficulty whatsoever.
- Әмма ләкин бер генә теләген ул **һичничек** тә җиңә алмады. Бу аның Ләйләне күз кырые белән генә булса да бер күреп каласы килү теләге иде. (Әмирхан Еники, Төнге тамчылар.) However, one desire he could in no way overcome, try as he might (lit., in any way). This desire of his was to see Leylä once (again), even if only with the corner of his eye.

**[444] Һич**, **бер** and **берәү** may function independently as negative pronouns:

- Галия. Мин болай дип **һич** уйламаган идем, Рәүф иптәш ... (Шәриф Камал, Ут.) Ghaliä. I never thought that it was like this, comrade Räüf ...
- Аның бу авылда **һич** кардәш вә якыннары юк иде. (Шәриф Камал, Тормыш көе.) In this village he did not have any brothers or (other) relatives.
- Керде Исхак, өстәл янына утырды һәм гомерендә **бер дә** күргәне булмаган шоколад конфетны беренче мәртәбә шунда ашады ... (Аяз Гыйләҗев, Берәү.) Iskhaq entered, sat down at the table, and there, for the first time, he ate chocolate candy, which he had never seen in his life.
- Тагын кичкә хәтле **бер дә** сөйләшмичә эшлидер идек. (Шәриф Камал, Курай тавышы.) Again we worked until evening without speaking at all. (For **-дыр**, **-дер** on conjugated verbs see 980.)
- Ул вакытта Мохтар аңа ничектер **бер дә** әһәмият бирмәгән иде. (Шәриф Камал, Таң атканда.) At that time, Mokhtar had somehow not paid any attention to him.
- Хаты нәрсә турында булды аның? **Берәү дә** белмәде. Чөнки ул моны **берәүгә дә** күрсәтмичә, **берәү** белән дә киңәшмичә язды. (Фатих Хөсни, Җәй башы.) What was her letter about? No one knew because she wrote it without showing it to anybody, without consulting anybody.

**[445] Һич** and **бер** (**берәү**) may be united to express categorical negation:

- Галия. ... Боларны мин сезгә үз итеп сөйлим, башка **һичбер** кешегә сөйләгәнем юк. (Шәриф Камал, Ут.) Ghaliä. I am telling you these things, regarding you as my close friend. I have not told them to anyone else.
- Без **һичбер** нәрсәгә карамыйча, **һичбер** нәрсә уйламыйча кызу-кызу алга атладык. (Давыт Юлтый, Кан.) We marched on quickly without looking at anything, without thinking anything.

- «Мин яман», дигәнне **һичберәүдән** ишетмәссең. (Proverb.) Nobody says of himself that he is bad. (Lit., You will not hear from anybody: “I am bad”.)

## Relative Pronouns

**[446]** In the Tatar literary language subordination is mostly rendered by participial or adverbial constructions. However, although not accepted as a norm in the literary language, in the vernacular and in poetry *simple* relative pronouns are sometimes used.[1)]

For example:

- Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз, **кайсылар** безне үлемдәй каплаган. (Һади Такташ, – М.З. Зәкиев, Хәзерге татар әдәби теле.) We are throwing off the rotten burdens which have covered us like death.
- Утыр аулакка, **кайда** һич кеше юк. (Габдулла Тукай, ibid.) Sit down at a secluded place where there is no one.

**[447]** Relative pronouns are more commonly used in *pairs* both in the literary language and in the vernacular. Such pairs consist mostly of an interrogative pronoun in the subordinate clause and a demonstrative pronoun in the main clause. Both relative pronouns agree in number, but not necessarily in case, the latter depending on the construction of their own clause. *The subordinate clause precedes the main clause.*

Examples:

- **Кем** чанасына утырсаң, **шуның** җырын җырларсың. (Proverb.) He who pays the piper calls the tune. (Lit., You sing the song of him in whose sleigh you sit).
- – Әти аннан башка бер-бер сүз әйттеме? – ди патша кызы. Малай әйтә: – Әйтте, кылычны **кем** алып килсә, кызымны **шуңа** бирәм дип әйтте ... (Татар халык әкиятләре, Тире Такыя.) The king’s daughter says, “Did my father say anything besides that?” The youth (lit., boy) says, “He did, he said ‘I’ll give my daughter to him who brings me the sword’ ...”
- **Бай әйтә боларга:** «**Кем дә кем** кызымны алып кайтса, кыз **шуңарга** була», – ди. (ibid. Серле балдак.) The rich man says to them, “Whoever brings back my daughter, the girl will be his.”
- – Эссе, – диде Усман ... да, **күпер астыннан** үткән киң арык буена төшеп, битен юа башлады. (Әбрар Шәмин, Янар таулар[1] кичкәндә.) "It's hot," said Usman ... and, descending to the broad irrigation ditch which passed under the bridge, he began to wash his face.
- **Көймә астыннан** ... балык көтүе узып бара иде. (Миргазиян Юныс, Энҗе эзләүчеләр.) A school of fish ... was passing under the boat.

c) 'under', 'underneath' (garment, etc.):

- Өстендә – сырып теккән кыска бишмәт. **Бишмәтенең астыннан** чуар чәчәкле күлмәге күренеп тора. (Нәзифә Кәримова, Карурманнан чыккан юлчылар.) She has on a short, quilted overcoat. Her dress of a gaily colored, floral pattern, is visible under her overcoat.

d) 'from under' (subordination, influence, etc.):

- Туганнан алып безне әниләр саклап үстерә. Усеп җиткәч тә без әни **канаты астыннан** бөтенләйгә чыга алмыйбыз. (Миргазиян Юныс, Бәйрәм.) From birth

[1] more recent spelling: янаргау

on mothers care for and raise us. Even after we have grown up, we cannot completely get away from under a mother's wings.

- – Андый кеше, чыннан да, бар икән. ... унҗиденче елның декабрендә җинаять җаваплылыгына тартылуы мәгълүм. Хөкем булганчы ук, **сак астыннан** качкан. (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем элмәге.) "It turns out that such a person does indeed exist. ... It is known that in December 1917, he was made answerable for a crime. (But) just before the trial he escaped from custody."

**[470] аша** (verbal adverb of аш 'rise', 'exceed').

a) 'through' (a place, thing):

- – Сез, дускай, **Аю-Ятар аша** үтмисезме? (Газиз Мөхәммәтшин, Йөрәктәге эзләр.) "Don't you, my friend, pass through Ayu-Yatar?"
- Халык **бакча аша** өйгә кереп-чыгып йөри. (Фәтхи Бурнаш, Адашкан кыз.) The people are entering and leaving the house through the garden.
- **Капка аша** авылның ... урамы күренеп тора. (ibid.) Through the gate, a street of the village ... is visible.
- Өстән бик куе тоелса да, аста **томан аша** сукмак, елга ярының кызыл балчык да, өянке ботаклары да күренә иде. (Фоат Садриев, Шаһзаманов эше.) Although from above the fog appeared to be very dense, below, the path, as well as the red clay of the river bank and the willow branches were visible.
- Ул арада «Волга» кузгалып киткән, аның артындагы кызыл утлар **яңгыр аша** сибелеп, кечерәя барып җемелди иде. (Мәдинә Маликова, Фидая.) Meanwhile, the "Volga" pulled away. Its red rear lights were glittering through the rain, becoming smaller and smaller. ("Volga" – make of a car).

b) 'through' (by the agency of):

- – Телне белми. Яннарына телне белә торган бер карчык куйдым. Әлегә **шуның аша** аралашалар. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) "She does not know the language. I have assigned to them an old woman who knows the language. For the time being, they are conversing through her."
- Нур Ибәтуллин дигән бер авылдашым бар минем. ... Аның үзенә һәм **аның аша** мәктәп китапханәсенә үз китапларымны җибәргәләгән чакларым да булды. (Мирсәй Әмир, Күңелле сәяхәт.) I have a fellow villager called Nur Ibätullin. ... At times, I have also sent my own books to him personally (lit., himself) and, through him, to the school library.

c) 'via':

- Баграждан Чаллыга турырак юл да бар ... Шыкмай, Борды **авыллары аша,** ... (Аяз Гыйләҗев, Татарстан могҗизасы.) From Baghrazh to Chelny there is a more direct road ... via the villages of Shyqmai (Shykmamayevo), Bordy (Burdy), ...
- Казаннан Дәүләкәнгә **Бәләбәй аша** да, **Уфа аша** да кайтып була. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) From Kazan one can return (or: it is possible to return) to Däwläkän either via Bäläbey or via Ufa.

d) 'across', 'over' (a place, thing):

- – Ник соң мин сезнең белән **читән аша** сөйләшеп торам, керегез әле бакчага, ... (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) "But why am I still talking with you across the fence. Please, come into the garden, ..."
- – Сез Алафузов заводыннанмы? Фәрхетдин өчен Гафур әйтте. – Безнең Фәрхетдин **Идел аша** күпер сала. (Атилла Расих, Ямашев.) "Are you from the Alafuzov works?" Ghafur spoke for Färkhetdin: "Our Färkhetdin is building a bridge over the Volga."

- Без шул машиналар агымы уртасында **күпер аша** чыгып барабыз. (Мирсәй Әмир, Күңелле сәяхәт.) We drive over the bridge in the midst of that stream of cars.
- **Тау аша** таулар үтеп, **дәрья аша** дәрьялар кичеп, **чүл аша** чүлләр гизеп, Алып Бәргән Җамна елгасына килеп чыкты. (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) Traveling over mountain after mountain, crossing over river after river, passing through desert after desert, Alyp Bärgän came to the river Jamna.
- Теге мәлне ул миңа балалар йортын бик яманлап сөйләгән иде бит. Хәзер дә ул бу йорт **бусагасы аша** узарга бик үк адарынып тормый. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) After all, at that time he had spoken very ill to me of the children's home. At this moment (lit., Now) too, he was not particularly eager to step across the threshold of this house.

e) 'across', 'beyond' (farther down):

- Мин аңардан өч **өстәл аша** гына эшлим ... (Әмирхан Еники, Вөҗдан.) I work only three tables across from her ...
- – Ул тиз булмас. Бер **ишек аша** лейтенант Гафуров утыра. Аңа керегез. (Мәҗит Рафиков, Илһам авазы.) "He will be a while. One door beyond (farther down) sits lieutenant Ghafurov. Go in to him."
- Җәмил ашыгып өйдән чыгуга, үзләреннән биш-алты **өй аша** яшәгән Сәрвәрбикә апаны очратты. (Аяз Гыйләҗев, Әтәч менгән читәнгә.) Upon hurrying out of the house, Jämil met Särwärbikä, who lived five or six houses down.

f) 'by' (by means of):

- – Мин ... сезне истән чыгармаячакмын. **Хат аша** хәбәрләшербез. (Атилла Расих, Айлы төннәр.) "I shall not forget ... you. We shall keep in touch by letter."
- Бу көннәрдә аңа Юлдашев белән очрашырга туры килмәде. Ул үзе аның янына бармады да, **телефон аша** шалтыратуны да кирәкле санамады. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) In these days he did not happen to meet Yuldashev. He himself did not go to him, nor did he deem it necessary to call him by telephone.

g) 'through' (simultaneous action):

- Елена бик тиз үзен кулга алды һәм ... күз **яше аша** елмайды. (Барлас Камалов, Ялыкмаслар.) Yelena composed herself very quickly and ... smiled through (her) tears.

h) 'apart', 'through' (with nouns indicating time):

- Туйны да икесе бер җәйдә, **атна аша** гына уздырдылар, ... (Аяз Гыйләҗев, Әтәч менгән читәнгә.) Both (of them) also had their wedding in one (and the same) summer, (and) only a week apart.
- Табигать аңа әнисе хакында сөйли. ... Тыңлый Тәбрик. Кайдадыр якында, ... яшь бала тавышы ишетелә. Тәбрикнең үз тавышы. Тәбрик үз тавышын тыңлый, **еллар аша** тыңлап, үзен кызгана ... (Әхсән Баянов, Тау ягы повесте.) Nature tells him about his mother. ... Täbrik listens. Somewhere nearby, ... the voice of a little child is heard. Täbrik's own voice. Täbrik listens to his own voice and, listening to it through the years, feels sorry for himself ...

i) 'across', 'over' (at a time):

- [Искәндәр] ... ике-өч **баскыч аша** сикерә-сикерә урамга чыкты. (Разил Вәлиев, Иске сәгать дөрес йөри.) [Iskändär] ... jumping down the stairs two or three at a time, went out onto the street.

*Note:* **аша** is sometimes used with the possessive suffix of the 3rd person singular and the ablative case: Егет... **бакча ашасыннан** Мәрьямнәрнең йортына таба юнәлде. (Галимҗан Ибраһимов, Яшь йөрәкләр.) The youth ... made his way towards Märyäm's house through the garden.

**[471] баш** 'head'.

1. **башына** 'up to', 'to the top of', 'upon' (indicating motion):
   - ... **болдыр башына** чыгып ашчы хатын аларны чәйгә чакырды. (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында.) ... stepping out onto the porch, the cook called them (i.e., the guests) to tea.
   - Атлар хәл алганнар, ..., мендерү кыен булмады. Тауны мендерү белән, дүрт атымны бер-бер артлы тездем дә, алдагы **арба башына** сикереп мендем. (Галимҗан Ибраһимов, Карт ялчы.) The horses had rested, ..., ascending (i.e., ascending from the bottom of the ravine) was not difficult. As soon as we were at the top (lit., climbed the hill), I strung my four horses in a row and jumped on the first wagon (i.e., the wagon in front).
2. **башында** 'upon', 'on', 'on top of' (indicating position):
   - Кич саен диярлек Мансур белән очраштылар, кич саен диярлек ... текә **яр башында**, таныш урындыкта, кулларны куллардан алмыйча утырып тордылар. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Almost every evening she and Mansur met. Almost every evening they ... sat on the familiar seat on the steep bank, not letting go of each other's hands.
   - **Койма башында** канатларын җилпеп кызыл әтәч кычкыра. (ibid.) On the fence, a red cock crows, flapping his wings.
   - **Мич башындагы**[1] **эш башында** була алмый. (Шәүкәт Галиев, Хикмәтле сүзләр.) The one on top of the stove cannot be on top of the work (i.e., He who lies on top of the stove cannot keep up with his work).
3. **башыннан**

a) 'from' (the top of a place or thing):
   - Шул арада **тау башыннан** төшеп килгән атлы бер кеше күренде. (Шәриф Камал, Матур туганда.) At that moment, a rider appeared, coming down (from) the mountain.
   - **Тау башыннан** чишмә ага. Тәбрик чишмә янында туктап улак башына утырды. (Әхсән Баянов, Тау игы повесте.) A spring flowed (lit., flows) from the mountain. Täbrik stopped beside the spring and sat down on a drinking trough.

b) 'by', 'per' (indicating amount):
   - Халикъ әйтә, **гектар башыннан** түләмим, **центнер башыннан** түлим, ди. (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) Khaliq says, "I am not paying by the hectar, I am paying by the centner."
   - Печәнгә йөрүчеләргә **җан башыннан** өч йөз грам он бирелә. (Нурихан Фәттах, Кичү.) Those who are making hay get three hundred grams of flour per person.

**[472] белән** (берлә, берлән, илә(н) ); old Turkish: bir+lä < bir+i-l– 'to unite[2]. The older forms берлә and берлән still occurred in Tatar literary works written only a few decades ago; илә(н) pertains to the pre-revolutionary literary language.

The postposition **белән** expresses a rather wide range of relationships:

a) 'with' (indicating accompaniment, joint execution of, participation in, an action; comitative):
   - – Ярый, барырсың, ләкин үзең генә түгел. – **Кем белән** соң? – дидем мин. – Берәр дус **кызың белән**. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) "All right, you can go (lit., you will go), but not alone." "With whom then," I said. "With some girl friend of yours."

---

[1] Мич башы – A small place on top of a brick and clay stove on which things can be dried and on which a person can sleep.

[2] (See A. von Gabain, Alttürkische Grammatik, § 276).

- – Өч ел бит инде мин **синең белән** йөрим, сине беләм, ... (Әмирхан Еники, Рәшә.) “After all, I have been going steady with you already for three years, I know you, ...”
- Рәшидә иптәшләренең бу гөнаһсыз сөйләнүләренә бер генә **сүз белән** дә катнашмады. (ibid.) Räshidä did not participate with one single word in these innocent talks of her collegues.
- ... тора-бара мин ул **малай белән** таныштым. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) In due course I became acquainted with that boy.
- – **Сезнең белән** танышуыма мин шат ... (Атилла Расих, Айлы төннәр.) “I am glad to have made your acquaintance ...”

The comitative meaning may be emphasized by placing **бергә**, **бергәләп**, less often **берлектә** ‘together’, after the postposition **белән**:

- **Алар белән бергә** тагын Мәдинәнең туганы Хәтимә яши. (Рәмзи Максудов, Шәйморза кешеләре.) Mädinä’s sister Khätimä also lives together with them.
- Тыңлаучылар **лектор белән бергә** ерак Африка илләренә сәяхәт кылдылар. (Саҗидә Сөләйманова, Гөлбадран.) Together with the lecturer, the audience (lit., the listeners) made a trip to distant African countries.
- Шәрифулла эшкә тотынды. Ул, **улы белән бергәләп**, мичнең бер өлешен сүтте, төтен юлларын көлдән, корымнан арчыды ... (Афзал Шамов, Миңнур карт.) Shärifulla started working. Together with his son he pulled down one part of the stove, cleaned the smoke paths of ash and soot ...
- 1812 елда университетта Ибраһим Хәлфин татар теле укыта башлый ... XVIII гасырда ук эшләп килгән үзенең бабасы С. **Хәлфин белән берлектә** И. Хәлфин татар телен өйрәнүгә нигез салган. (Татарстан АССР тарихы.) In 1812, Ibrahim Khälfin began (lit., begins) to teach the Tatar language at the university (i.e., University of Kazan) ... Together with his grandfather S. Khälfin, who had worked back in the 18th century, I. Khälfin laid the foundation for the study of the Tatar language.

b) ‘with’, ‘by’ (indicating instrument, means: also in abstract relationships and idiomatic expressions):

- Болгар дәүләте яшәгән чорда сөреп чәчүгә нигезләнгән игенчелек авыл хуҗалыгының төп тармагы булып әверелгән. ... Уңышны урып-җыю **урак белән** башкарылган. (Татар АССР Тарихы – IX-XIII гасырларда Идел буендагы Болгар дәүләте.) In the period when the Bolghar State existed, farming based on ploughing and sowing turned into the main branch of agriculture. ... Harvesting the crops was carried out with the sickle.
- Шул арада Мәликә әби өстәлгә олы **табак белән** аш китереп куйды. (Әмирхан Еники, Рәшә.) At that moment, Grandmother Mälikä brought in a large tureen with soup (lit., brought in soup with a large tureen) and put it on the table.
- ... ул **автобус белән** көн саен Чаллыга йөри торган булды. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) ... she started going (i.e., she assumed the habit of going) every day by autobus to Chelny.
- Без ярга төшеп, Идел **суы белән** битләребезне юып килдек. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) We went down to the bank and washed our faces with the water of the Volga.
- Ул **йодрыгы белән** капканы төйде. (Мәдинә Маликова, Фидая.) He banged at the gate with his fist.
- Ниһаять, без үзебезне Казанга тартып китергән изге бина каршында. ... бу йорт үзенең тышкы **күренеше белән** үк аерылып тора: ... (Мирсәй Әмир, Казан.) Finally, we are standing in front of (opposite) the venerable building which has attracted us to Kazan. ... this house distinguishes itself by its very appearance: ...

- Мәдрәсәдән имам-мөгаллим **исеме белән** чыккан Идрис хәлфә заманына күрә хөр фикерле укытучы була. (Мирсәй Әмир, Казан.) Instructor Idris, who had finished the medrese with the title (lit., name) of spiritual educator-teacher, was (lit., is) for his time a freethinking teacher.
- – **Шуның белән** бүгенге утырышны ябык дип игълан итәм. (Гөлсем Мөхәммәдова, Яшьлек көннәрендә.) "With this I declare today's session closed."
- Керүченең кем икәнен шунда ук белсә дә, ул ... ни **хәрәкәте**, ни **торышы белән** берни дә сиздермәде. (Әмирхан Еники, Рәшә.) Although she immediately knew who was entering, she did not ... let her feelings show either by her behaviour or by her bearing.

c) 'because of', 'with' (indicating the cause of, reason for):

- – Соңгы елларда сиңа бигрәк күп килде инде, – диде Искәндәров. – Бәлки бөтен гомәреңә тиешле кыены шушы елларда булгандыр. Ә бит син бәхетле булырга тиеш кеше. Синең **чибәрлегең, акылың, уңганлыгың белән**, синең **сөйкемлелегең белән**! (Мәдинә Маликова, Фидая.) "True, you have gone through a lot, particularly during the last few years," Iskändärov said. "The difficulties which perhaps you were destined to experience over your entire life seem to have happened in just these years. But, after all, you are a person who ought to be happy – with your beauty, your intelligence, your abilities, with your charm!"
- ... карт гозерен /ɡ͡jøzeren/ әйтергә ашыкты: – Килен, әйдә, без өлкәннәрне борчып тормыйк инде, – диде. – Менә карчыгым **сүзе белән** йөрүебез. Шушы нигезне, коены күрәсе килде аның. (Рафис Гыйззәтуллин, Сиртмәле кое.) ... the old man hastened to state his request: "Young lady (lit., daughter-in-law), come now, let's not disturb the old folks," he said. "We have come here because of my wife's urging (lit., word, constant talk). She wanted to see this house (and grounds) and the draw-well." (Нигез – here: The house and grounds of a person's ancestor(s), the house in which a person was born and raised.) (Килен – 'daughter-in-law'; also used by a woman's parents-in-law in addressing her. Furthermore, килен may be used by an older man or woman in addressing a younger woman.) In the above example the second case applies.
- Син **килмәү белән** эш тоткарланмас. (Tatar-Russian Dictionary.) Work will not be delayed (just) because you don't come (lit., because of you not coming).

d) 'on' (indicating result):

- Исәнләштеләр. Давыт аңа өмет белән карады: бу хатын юкка гына килмәгәндер. Фидаяның **чакыруы белән** килгәндер, димәк, алар очрашырга тиеш. (Мәдинә Маликова, Фидая.) They said hello to each other. David looked at her with hope. This woman had probably not come without some reason. She had probably come on Fidaya's request. That meant that they were to meet. (David had been looking for Fidaya in vain.)

e) 'with' (indicating manner):

- Мәүлет егетләргә зур **кызыксыну белән** карап торды. Альберт Хәсәнов, Фәндәм фонды.) Mäwlet had been watching the youths with great interest (lit., was looking at the youths).
- Ул көтепханәнең һәрвакыткы кунагы. Каюм укырга тәкъдим иткән китапларны ул **комсызлык белән** укый ... (Шәриф Камал, Матур туганда.) He is a regular visitor to the library. He avidly (lit., with avidity) reads the books which Qayum suggests that he read ...
- ... Имаметдин кунакларны якты **чырай белән** каршы алды. (Атилла Расих, Айлы төннәр.) ... Imametdin received the guests cordially (lit., with a friendly face).

f) ‘along’ (indicating motion along):

- Егет, иртәгесен йокыдан торып, ашап-эчкәч, карчыкка бик күп рәхмәтләр әйтеп, ... юлга чыгып китә, теге карчык өйрәткән **юл белән** көн бара, төн бара. (Татар халык әкиятләре, Көнгә күренмәс Сылу-көмеш.) After getting up in the morning and having had something to eat and drink, the youth thanked the old woman very much, ... and set out on the road. Day and night he travels along the way which that old woman had explained to him.

*Note:* In Tatar the verbs ‘to thank’ and ‘to set out’ are in the present tense to give more vividness and effect to the narration.

g) with predicates (both verbal and nominal) requiring the postposition белән:

- – Барыбыз исеменнән Рөстәмне туган **көне белән** тәбрикләргә рөхсәт итегез. (Сафа Сабиров, Фирдәвес.) “On behalf of all of us, allow me to congratulate Röstäm on his birthday.”
- Җырлыйлар бердән болар **шатлык белән,**
  Берсе-берсен котлый **азатлык белән**.
  (Мәҗит Гафури, Хөррият иртәсе.)
  They are singing together with joy,
  They congratulate each other on their freedom.
- [Зөфәр] киенә башлады. Киенеп беткәч, әбигә рәхмәт әйтеп, акча бирде. Аннары **кызлар белән** кул биреп саубуллашты ... (Әмирхан Еники, Рәшә.) Zöfär began to dress. After he finished dressing, he thanked the old woman and gave her money. Then he said goodbye to the girls, shaking hands with them...
- ... ул баш кагып кына **Зөфәр белән** исәнләште. (ibid.) ... she greeted Zöfär, only nodding her head.
- [Зөфәр] ишек төбендә идарә **кешеләре белән** кул биреп күреште, һәркайсын бәйрәм **белән** котлады ... (ibid.) At the door [Zöfär] greeted the administration people, shaking hands with them, (and) congratulated each of them on the holiday ...
- – Менә киленегез, әти-әни. Рәйхан. **Тумышы белән** безнең як кызы. (Барлас Камалов, Урамнар киңәя.) “Here, Dad and Mom, is your daughter-in-law, Reykhan. She is from our area.” (тумышы белән – by birth).
- Йөрү юллары **студентлар, журналистлар, нәшрият хезмәткәрләре белән** тулы. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) The aisles are filled (lit., full) with students, journalists, and employees of the publishing house.

h) followed by янәшә ‘beside’; ‘alongside of’, ‘next to’ (a person, place, or thing):

- Турат хәлне аңлаган кебек, муенчагыннан җитәкләгәнгә буйсынып, **минем белән янәшә** йөгерде. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) Turat (name of his horse), as if understanding the situation, submitted to being led by the collar and ran alongside me.
- Искәндәрнең күзләре өстәл түрендә **Рүдәл белән янәшә** утырган кызда иде. (Разил Вәлиев, Иске сәгать дөрес йөри.) Iskändär’s eyes were on the girl sitting next to Rüdäl at the head of the table.

i) with verbs in the passive voice when their agent is inanimate (see also 864):

- Шәһәрнең уртасында тирә-ягы **бакчалар белән** әйләндерелгән зур бер сарайга бардык. (Галимҗан Ибраһимов, Көтүчеләр.) In the center of the town, we went to a large palace, which was surrounded on all sides by gardens.
- Күрәм, көймәбез **ай белән, йолдызлар белән** бизәлгән диңгез суын ерып бара. (Галимҗан Ибраһимов, Диңгездә.) I can see, our ship is ploughing through the waters of the sea, which is adorned by the moon, by the stars.

- Инде кыш башланса да, күлләр, елгалар **боз белән** капланса да, кар әле төшмәгән. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) Although winter has already begun, and although lakes (and) rivers are covered with ice, snow has not yet fallen.

*Note:* With verbal nouns **белән** expresses temporal relationship (1186, d).
With nouns designating time **белән** forms adverbs (607). Furthermore, **белән** functions as a conjunction (622).

**[473] борын** ‘nose’.
1. **борынча** (with the word **өй**, **йорт** ‘house’, **капка** ‘gate’)
a) ‘to each, every’, ‘per’:
- ... пычкы **өй борынча**, һәр кешедә бар ... (Аяз Гыйләҗев, Әтәч менгән читәнгә.) ... there is a saw to every house, everybody has one ...

b) ‘from ... to’ (indicating movement):
- Авыл тегүчеләренең гадәте буенча, без **өй борынча** йөреп тегә идек. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) In keeping with the habit of the village tailors, we were moving from house to house, sewing.

2. **борынына** ‘from ... to’ (indicating movement):
- – Син нигә алай **өй борынына** кереп, теләнеп йөрисең, ...? (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) “Why are you going from house to house, begging like that, ...?”

**[474] буй** ‘height’, ‘stature’, ‘length’.
1. **буе** /bujь/
a) ‘for’, ‘through’, ‘throughout’ (indicating time):
- Урманда кунып ятып, **атналар буе** кайтмыйча эшләделәр. (Мөхәммәт Мәһдиев, Торналар төшкән җирдә.) They worked, sleeping out in the woods and not returning (home) for weeks.
- Ул **көне буе** йоклады һәм бары тик караңгы төшкәндә генә уянды. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) He slept all day and awoke only when darkness just began to fall.
- Каяндыр илнең урта бер җиреннән Бөек дала башлана. Аның өстеннән **сәгатьләр буе** очарга һәм бер генә җан иясе, бер генә яшеллек тә очратмаска мөмкин. (Ислам Беляев, Солдат төймәсе.) From somewhere, from a central place of the country, the Great Plain begins. One can fly over it for hours and not come across even one living thing, even one green spot.
- Аерыла алмыйм, **көне буе, төне буе** бастым. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) I cannot tear myself away (from it); I typed day and night (lit., throughout the day and night).

b) ‘on’, ‘along’ (indicating movement):
- Һәм бер көнне Фәрхетдин ... тагын Көлемсәрне һәм балаларын алырга китте. **Юл буе** нәрсә уйлаганын сорасаң, узе дә әйтә алмас иде. (Әхсән Баянов, Тау ягы повесте.) And one day Färkhetdin ... went again to fetch Kölemsär and their children. If you asked what he was thinking on the way, he himself would not be able to tell.
- Авыл да инде күптән тынды. Тик этләрнең генә **урам буе** йөри торган яшьләргә ара-тирә өргәләп куйганнары ишетелеп китә иде. (Садри Җәләл, Югары урманга җиләккә бару.) The village too had long since become quiet. Only the dogs were heard barking from time to time at some youths walking along the street.

c) ‘as ... as’, ‘like’ (indicating length, height):
- ... күзләр кармак җебенә текәлә: ... **бот буе** җаен килеп чыксачы, дип өметләнә. Шуннан кармагыңны тартып җибәрәсең. – Һәм чәнти **бармак буе** маймыч

ялтырап килеп чыга ... (Әнисә Ибраһимова, Томан тарала.) ... the eyes are fixed on the fishing line: ... one hopes that a sheatfish as long as one's legs (lit., thigh, i.e., reaching from the ground to one's hips; waist-high) may emerge. Then you quickly pull in the hook. – And a fish as long as one's little finger comes glistening to the surface ...

(For the modal particle **-чы**, **-че** with verbs in the conditional mood see 1006, 4.).

- Башка елларда бу вакытта **кеше буе** була торган арыш быел тычкан эзләп йөргән этне дә күмә алмый ... (Кәрим Тинчурин, Кара көннәрдә.) The rye, which in other years at this time is as high as a man, cannot even cover up a dog looking for mice ...

2. **буена** /bujьna/

a) 'throughout', 'for', 'over' (indicating time):

- Бөтен **рамазан буена** Коръәнхафиз мәчеттә ... кычкырып коръән чыкты. (Әмирхан Еники, Коръәнхафиз.) All throughout the entire Ramadan Qor'änkhafiz read the Koran aloud in the mosque ...

*Note:* Ramadan – The ninth month of the Moslem year during which Moslems fast every day from sunrise to sunset.

- [Патша] биш **ай буена** улыннан хәбәр көтте. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) For five months [the king] waited for news from his son.
- Казан **гасырлар буена** төзелеп килгән. (Рәшит Мусин, Киләчәккә атлый Казан.) Kazan was built over centuries.
- Берничә **гасыр буена** бу дәүләтнең башкаласы Болгар, яки, борынгы рус елъязмалары буенча, Бөек Болгар шәһәре булган. (С.С. Айдаров, Н.Д. Аксенова, Болгар шәһәре.) For several centuries, the capital of this state was Bolghar, or, according to old Russian chronicles, the city of Great Bolghar.

b) 'to', 'on', 'all along' (indicating movement):

- **Урман буена** килеп җиткәч, чиләген агач төбенә куйды ... (Мөхәммәт Мәһдиев, Торналар төшкән җирдә.) After reaching the wood, she put her pail under a tree ...
- Икәүләп **Агыйдел буена** төшеп китәбез. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) We go down to the Belaya as a twosome.
- **Юл буена** ул караңгы чырайлы булды. **Юл буена** ул үзенең бәхетсез язмышы, билгесез киләчәге турында уйлады. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) All along the way he looked gloomy. All along the way he thought about his unhappy fate, his uncertain future.

3. **буенда** /bujьnda/ 'by', 'beside', 'along' (indicating position at, along a place):

- Өй эчендәге җиһаз-мөлкәтләр дә заманча – ... түр яктагы **тәрәзә буенда** телефон тора. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) Also the furniture and (other) belongings in the house are in keeping with the times. ... by the window in the parlor (best room) stands a telephone.
- Болгарлар IX–XIV йөзләрдә **Урта Идел буенда** һәм Каманың түбән агымында **Идел буе** Болгар дәүләте дигән илдә яшәгән. (Болгар шәһәре.) In the 9th–14th centuries, the Bolghars lived along the Middle Volga and on the lower course of the Kama, in a country called the Volga Bolghar State.

4. **буеннан** /bujьnnan/ 'along' (indicating movement along); 'from' (indicating movement from):

- Мәктәпкә юл **урман буеннан** бара. (Мөхәммәт Мәһдиев, Торналар төшкән җирдә.) The road to the school runs along a forest.
- Ындыр арты **киртәләре буеннан**, еш-еш атлап, ... карчык урманга таба чаба иде. (ibid.) Along the fences behind the kitchen garden, ... the old woman was hurrying with quick steps towards the wood.

- **Сары-су буеннан** кузгалып китүгә дүрт көн булды дигәндә алар Диңгез-күлгә якынлаштылар. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) Almost four days after they had set out from Sary-su (Yellow Water), they approached Dinggez-kül (Sea Lake).
- Әмма Тәтиш тикле Тәтиштән тәпиләп кайткач, ... Галияттәйнең[1] **капкасы буеннан** борылып китү дә егетлек түгел. (Барлас Камалов, Ялыкмаслар.) But after you return on foot from Tätish (i.e., from a place as far as Tätish), turning away from Aunt Ghaliä's gate is no act of daring.

(For **тикле** between two nouns to indicate emphasis see 537).

5. **буенча** /bujьnca/ expresses a very wide range of relationships. Compare the examples below.

a) 'for', 'throughout' (indicating time):
- Ул тоташ биш **сәгать буенча** дәресләрдә утырды. (Диләрә Зөбәерова, Кыр чәчәге.) He sat at his (lit., the) lessons for five hours without a break.
- Сөләйман, **өч көн, өч төн буенча** бүлмәсеннән һавага чыкмыйча, хикәя язды. (Кәрим Тинчурин, Тугызынчы мәрҗән.) Söleyman wrote a story, not getting out of his room into the air for three days (and) three nights.
- Ул улларына акча җибәргәндә һәрвакыт: «Менә, карчык, без азапланып **еллар буенча** җыйган малны улларың ничек җиңел бетерәләр!» ди. (Садри Җәләл, Дим буенда.) Each time he sends his sons money he says: "Here you see, Mother, how thoughtlessly your sons are wasting the fortune which we acquired over the years with (such) difficulty."

*Note:* Карчык – 'old woman'; used by an elderly husband to address his wife.

b) 'along', 'throughout' (indicating movement along, or position at, a place):
- Ямле җәйге **юл буенча** җәяүләү җиңелчә киенгән яшьләр өчен авыр булмаса да, авылга кайтып җитү белән, буыннарыбызда арыганлык сизелде. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Although walking along the pleasant summer road was not difficult for lightly dressed youths, we felt fatigue in our knees (joints) when we reached the village.
- Мин трактор **эзе буенча**, ауган читәннәр, җимерелгән киртәләр аркылы үтеп, ... яланга таба йөгерә башладым. (ibid.) Passing over knocked-down fences, through ruined hedges, I began to run ... along the tractor tracks towards the field.
- Бу шөһрәтле дин әһеленең ... **бөтен дөнья буенча** гизеп йөрүен Җәгъфәр күптән белә иде. (Атилла Расих, Ямашев.) Jäghfär had known for long that this famous clergyman ... had traveled throughout the whole world.
- ... **дивар буенча** кечкенә өстәлләр куелган. (Фәтхи Бурнаш, Адашкан кыз.) ... small tables have been placed along the wall.

c) 'in', 'of' (indicating profession, trade, skill):
- Барысы да кайчандыр Галиәкбәргә **кошчылык фәне буенча** имтихан биргән ... кешеләр. (Атилла Расих, Сынау.) All of them are persons who at some time had taken the exam in poultry raising with Ghäliäkbär...
- ... күз алдына сабан туе батырыдай, кыска җиңле аксыл күлмәген кигән Җиһангиры килеп басты. ... **Гер күтәрү буенча** авылда да, районда да беренчелекне бирми. (Нурислам Хәсәнов, Ак балык.) ... before her mind's eye stepped her Jihangir in his off-white, short-sleeved shirt which he had worn as the champion of the Festival of the Plough. ... He does not cede first place in weightlifting either in the village or in the district.

---

[1] Галиыяттәй – short for Галия түтәй.

- Узенең беренче хикәясе «Гарәфә /Ģәrәfә/ кич төшемдә»не татарлардан төрле **фәннәр буенча** профессорлар, танылган язучылар ... җыелган кичәне сурәтләүгә багышлады. (Х. Хисмәтуллин, Фатих Әмирхан иҗаты.) He devoted his first story "A Holiday Eve in My Dream" to depicting an evening at which from among Tatars professors of various sciences, well-known writers, ... had assembled.
- Профессор Әбүзәр Таһиров Казанда **йөрәк авырулары буенча** иң зур белгечләрнең берсе булып санала. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Professor Äbüzär Tahirov was regarded as one of the most renowned specialists in heart diseases in Kazan.

(For the use of the present tense instead of the past tense in Tatar see 956, 5.)

- Укучы кызларга төрле фәннәрдән белем бирү өстенә аларга чигү чигү, кием тегүише кул эшләре, аш-су **әзерли белү буенча** да махсус дәресләр оештырылган. (Миркасыйм Госманов, Чәчелгән орлыклар – Голҗа татарлары.) In addition to teaching the girl students various subjects, special classes have been arranged in needlework, such as embroidering and sewing, as well as in cooking (lit., in knowing how to prepare food, meals).
- Мәктәптә эшләвен зур сыйныфларга математика укытудан башлаган, аннары **укыту эшләре буенча** мөдир дә булып торган Әсгать абзый Исхаков аз сүзлелеге, сабырлыгы белән аерылып тора торган иде. (ibid.) Äsghät Iskhaqov, who had begun his activity in the school with teaching mathematics to the senior classes, and who then became the principal (lit., director for matters of education), distinguished himself by his taciturnity and patience.
- – Таныш бул, – диде Шәмсүн, минем **хуҗалык буенча** ярдәмчем Минәт булыр бу. (Азат Вергазов, Кайту.) "Get acquainted," Shämsün said. "This is Minät, my assistant in financial (economic) matters."

d) 'by' (by means of, with the help of):

- Табышмаклар – халык авыз иҗатының иң күп таралган төрләреннән берсе. Аның җавабы табышмакта бирелгән **сурәтләр, билгеләр буенча** табыла. (С.М., 9, 1977, б. 20.) Riddles are one of the most widespread genres of folklore. Its answers to them are found by means of (with the help of) the descriptions and intimations given in the riddle.
- – Чәчү эшен без үзебез дә булдырабыз, егетләр. Яшелчә бакчасы эше икенчерәк. Әхмәт иптәш безгә аны **китаплары буенча** эшләп күрсәтсен. (Шәриф Камал, Матур туганда.) "The sowing job we will manage ourselves, fellows. Work in the kitchen garden is something else. Have comrade Äkhmät demonstrate how from his books."
- **– Исемлек буенча** кемнең нindирәк кеше икәнлеген кыскача гына сөйләп чыксагыз иде, – дим. (Миргазиян Юныс, Юлда уйланулар.) "If, from (with help of) the list you would just tell me roughly what kind of a person each is," I say. (The speaker is new in a higher position and wants to get some information on the people he has to work with.)

e) 'for', 'on', 'to' (indicating purpose):

- Барый Сафин дигән егет белән таныштым. ... Мин әле бәлки аңа тиз генә сүз кушарга да кыймаган булыр идем. Такташ **шигырьләре буенча** ясаган рәсемнәремне күреп, үзе игътибар итте. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч.) I became acquainted with a young man called Bari Safin. ... I would perhaps not have mustered the courage to address him anytime soon. Seeing the (lit., my) pictures I had prepared for Taqtash's poems, he himself took notice of me.
- **Казан буенча** юл күрсәткеч китап. (Мирсәй Әмир.) A guide(book) to Kazan.
- **Эш буенча** аңа шәһәргә барырга туры килде. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) He had to go to town on business.

· – Кичә минем эти сезгә телефонда шалтыраткан икән. Мин шул **мәсьәлә буенча** килдем. (Габдрахман Минский, Язның беренче көне.) “Yesterday my father called you up, I understand. I have come on that matter.”

(For **икән** see 742, a.).

f) ‘by’, ‘on the basis of’:

· **Рәсемнәре буенча, ишеткәннәрем буенча,** хәтта **әсәрләре буенча** да аны таныдым: бу – Фатих Әмирхан иде. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) I recognized him by his pictures, by what I had heard, and even by his works. This was Fatikh Ämirkhan.

· – Әллә сез аны беләсезме? – Күреп тугел, газеталарда басылган **мәкаләләре буенча** гына. (Вакыйф Нуруллин, Яшьнәп үткән яшьлек.) “Then you know him?” “Not by sight, only by his articles which are printed in the newspapers.”

· Әхмәй **тәҗрибәсе буенча**, без үзебез торган йорттан ераграк, авылның икенче башынарак киткән идек. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) Based on Äkhmey’s experience, we had gone farther away from the house in which we were living more towards the other end of the village.

g) ‘from’ (on the basis of, in accordance with):

· ... аннары үзе берәр яңа көйне уйнап күрсәтә һәм шуны миңа **нота буенча** уйнарга куша. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) ... then he himself demonstrates (lit., plays and shows) some new tune and has me play it from the music (lit., by note).

h) ‘on’, ‘at’ (as a result of, because of):

· ... ул минем өчен дә бик сөенде, чөнки Салих **чакыруы буенча** баруымны белеп тора. (ibid.) ... she was also very glad for me because she knew (lit., knows) that I was going at Salikh’s invitation.

· Аның урынына Алиуллин **киңәше буенча** Иршатны куйдылар. (Рәмзи Максудов, Шәйморза кешеләре.) On Aliullin’s advice, they put Irshat in his position (i.e., in the former accountant’s position).

· Ләлә ханымның һәм Заһит Рәхмәтулловичның катгый **таләбе буенча** Альфредның этисе белән әнисенә бүләкләр дә алынды. (Фоат Садриев, Адәм әүлиясе.) At lady Lälä’s and Zahit Räkhmätullovich’s firm request (insistence), presents were bought for Alfred’s parents too.

· Фәтхинең **тәкъдиме буенча**, ... Мостафа сайланды. (Шәриф Камал, Матур туганда.) At Fätkhi’s suggestion, Mostafa was elected ...

i) ‘in’, ‘by’ (according to):

· Нәгыймнең **фикере буенча** Шихрау сайланырга тиеш иде. (ibid.) In Näghim’s opinion, Shikhraw ought to have been elected.

· Фәтхи **карашы буенча** да бу киңәш дөрес иде. Ул шулай эшләде дә. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) In Fätkhi’s view too this advice (i.e., the advice given him) was right, and he proceeded accordingly.

j) ‘after’ (indicating manner, ‘according to’):

· Мөмкин булган очракта күмәкләп «Дүртенче биеклек» **әсәре буенча** эшләнгән кинофильм карала. (С.М., 12, 1977, 6. 25.) The movie made after the work “The Fourth Height” is to be watched collectively (i.e., by the whole class), if that is possible.

k) ‘according to’ (in agreement with, in accordance with, as stated or shown by):

· Борынгыдан килә торган **гадәт буенча** кунакка барырга берничә ай элек әзерләнә башлыйлар. (Рәмзи Максудов, Шәйморза кешеләре.) According to long-standing tradition, they begin preparing themselves for visits several months in advance.

- Минем **исәп буенча** инде өч түгел, ун минут узарга тиеш иде. (Гариф Гобәй /Ǫǰøbəj/, Без үскәндә.) According to my calculation, not three but ten minutes must already have passed.
- Картларның **сүзе буенча**, элек, унтугызынчы гасырның ахырларында, бу хәрабә Исхак мирза гаиләсенең кайнап торган оясы булган. (Садри Җәләл, Дим буенда.) According to what the old folks relate, these ruins were once, around the end of the nineteenth century, the busy estate (lit., nest) of Mirza Iskhaq's family.
- Мәкальләрне урындагы **сөйләшләр буенча** язып алганда, анда кайбер урынчылык, кабиләчелек сүзләре очрый. Урындагы диалектларны өйрәнү өчен аларны шул **әйтелешләре буенча** язып алу әһәмиятле. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) As the proverbs are recorded in accordance in the local vernacular, one will come across some words there which pertain to local or tribal idioms. Recording them in accordance with those pronunciations is important for the study of local dialects.
- Әнисә. ... **Кагыйдә буенча**, тирәнлек кимендә егерме сантиметр булырга тиеш. Өрлек бу хәлендә калса, ярты елдан түшәм бөтенләй ишелеп төшәчәк. (Гамир Насрый, Кушамат.) Änisä. ... According to the rules, the depth must be at least twenty centimeters. If the girder stays in this position (i.e., with its end only six centimeters in the wall), the whole ceiling will collapse in half a year.

l) 'about' (concerning):
- – Юк, кайбер **мәсьәләләр буенча** без барыбыз да, кызганычка каршы, бертөрле уйламыйбыз әле. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) "No, about some matters all of us do, unfortunately, not yet think the same way."
- – Мин дә нәкъ шундый **мәсьәләләр буенча** килгән идем, бергә сөйләшик әле! (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) "I have come exactly about such matters; so let's talk together."
- – Миңа Шаһзаманов **эше буенча** чыгыш ясау икеләтә кыен, – диде Биккинин авыр сулап. (Фоат Садриев, Шаһзаманов эше.) "To make a speech about (concerning) Shahzamanov's case is for me difficult in two ways (or: doubly difficult)," Bikkinin said, taking a deep breath.
- Очрашкан саен ул мине **эшем буенча** югары оешмаларга ник язмыйсың дип тинтерәтә. (Гурий Тавлин, Афәт.) Each time we meet, she gets on my nerves by saying why don't I write to higher authorities (departments) about my case.

m) 'on', 'with' (about, concerning, engaged upon):
- Укучыларга түбәндәге ике сорау тәкъдим ителә: ... Беренче **сорау буенча** әңгәмә алып барганда, үсемлекләрнең кешегә туклану азыгы ..., шулай ук кием-салым ... йорт җиһазлары ... h.б. була алуы аңлатыла. (С.М., 8, 1977, б. 41.) The following two questions (lit., The two questions which are below) are put to the pupils: ... During the discussion held on the first question it will be explained (i.e., the teacher explains) that plants can be food for man ..., as well as clothing, ... furniture, ..., etc.
- Хаби миңа **тарих, география буенча** ярдәм итә, ... (Мөхәммәт Мәһдиев, Торналар төшкән җирдә.) Khabi helps me with history, geography, ...

n) 'by' (indicating origin):
- Зариф **тумышы буенча** Казан арты районнарының берсеннән икән. (Атилла Расих, Сынау.) It turned out that by birth Zarif was from one of the districts behind Kazan.

o) 'from' (indicating source):
- «Татарча Театр». «Йолдыз» газетасында ... «Г. Тукай» имзасы белән басылган. Г. Тукай кулъязмалары арасында да бар. Текст **кулъязма буенча** алынды. (Габдулла Тукай – Әсәрләр.) (The article) "Tatar Theatre" was published in the

newspaper “The Star” ... with the signature “Gh. Tuqai”. It (i.e., the article) is also among Gh. Tuqai’s manuscripts. The text has been taken from the manuscript.

p) ‘due to’ (indicating cause):

- Кемнәр аркасында, нинди **сәбәпләр буенча** булганлыгын әйтеп тормыйм, мин җиде яшемдә чагымда укырга-язарга өйрәнгән идем. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) I am not saying through whom and due to what reasons it happened, (but) I had learned to read and write at age seven.

**[475] буйлап**, **буйлый** (**буйлый** is used rarely), **буйлатып** ‘along’, ‘throughout’, ‘through’ (indicating motion, extent, **буйла** ‘go, walk along’; ‘measure’):

- ... без дә **башкалабыз буйлап** сәяхәткә чыктык. Көннең-көн буе **шәһәр буйлап** йөрдек ... (Гариф Ахунов, Марсель Зарипов, И кадерле туган як.) ... we too set out on a tour of our capital. All day long we traveled throughout the city ...
- Фәрит ишек төбендә бераз көткәннән соң, профессорны тиз генә күрә алудан өметен өзеп, **баскыч буйлап** түбән төшә башлады. (Атилла Расих, Сынау.) After waiting a little at the door, Färit gave up hope of being able to see the professor soon and began to walk down the stairs (lit., walk down by, along the stairs).
- Мин, **тәнем буйлап** йөгергән калтырауны басар өчен, беркавым сарай буенда торырга мәҗбүр булдым. (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) In order to calm the shiver which ran through (all along) my body, I was forced to pause for a while beside the shed.
- Тубәндә кечкенә елгачык, шул **елгачык буйлап** сузылып киткән Каракош авылы җәелеп ята. (Әмирхан Еники, Туган туфрак.) Below is a little river. The village of Qaraqosh lies spread out along that little river.
- Бу романнарның даны белән бергә, татар әдәбиятының да даны **ил буйлап** яңгырады. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) Together with the fame of these novels, the fame of Tatar literature too rang out throughout the country.
- Чишмәдән чыккан кебек саф, салкын су **агач улак буйлап** чиләккә агып кына төшә. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) The water, clear and cool as though coming from a spring, simply flows through a wooden trough into the pail.
- ... ул ... өч-дүрт метр киңлегендәге боздай салкын су аша чыкты да, тагын **яр буйлатып** китеп барды. (Нурихан Фәттах, Артта калган юллар.) ... she ... walked through the three or four meter wide, ice-cold water and continued again along the bank.
- ... әңгәмәләре түгәрәкләнеп тә җитмәде, ферма көтүен әйдәп, **инеш буйлатып** килгән Гайнан белән Дилбәр күренде. (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) ... Their conversation had not come to an end (when) Gheynan and Dilbär appeared, coming along the brook driving the farm herd.

**[476] буйлата**.

a) ‘along’ (indicating motion):

- Төш вакыты җитәр алдыннан **яр буйлата** шәһәр ягына ике төркем балык тотучы малайлар үтеп киттеләр. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Before midday appoached, two groups of boys, who had been fishing, were walking along the banks towards the town.
- Шәһәр һәм аның тирәсендәге **юллар буйлата** таныш машина – карасу-зәңгәр «Волга» уза. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) Through the city and along the roads around it passes a familiar car – a dark blue “Volga”.

b) ‘from’, ‘according to’ (indicating source):

- Бары тик Сәләхи генә, Шихрайдан **ишетүе буйлата**, Нәгыймнең ... фронттан ... качканлыгын белә иде. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Only Säläkhi knew, from what he had heard from Shikhrai, that Näghim ... had run away from the front.

**[477] буларак** (verbal adverb plus **+рак** of **бул** ‘be’, ‘become’).
‘as’ (‘in the capacity of’, with a connotation of ‘that being so’, ‘because of’):

- **Хуҗа буларак**, Исәнтәй бераз гына алдан барды. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) As the host, Isäntey went just a little ahead.
- ... ул үзе дә югары күтәрелде, фән, культура **эшлеклесе буларак**, бер Татарстанда гына түгел, бөтен ил күләмендә танылды. (Мансур Хәсәнов, Галимҗан Ибраһимов.) ... he himself too rose high (i.e., to a high position). As a scientist (and) cultural worker, he was known not only in Tatarstan but throughout the entire country.
- Әдәби **тәнкыйтьче буларак** Ибраһимовның исеме матбугатта 1910 елдан алып күренә башлый. (ibid.) As a literary critic, Ibrahimov’s name began (lit., begins) to appear in the press from 1910 on.
- 30 нчы елларда, төп игътибарын драматургия өлкәсенә юнәлткән хәлдә, Бурнаш **шагыйрь буларак** та шактый зур әһәмиятле әсәрләр иҗат итә. (Бәян Гыйззәт, Фәтхи Бурнаш.) Though in the 1930’s he directed his main attention to the field of dramaturgy, Burnash created (lit., creates) works of rather great importance also as a poet.
- Университет бетергәннән соң биш ел бue кеше өстендә яшәү, язып утырырга ныклы бер урын булмау, шуларның барысы өстенә Матбугат йорты белән Казан урамнарыннан башканы күрмәү мине ялыктыра башлаган иде. Гел шулай барса, минем, **язучы буларак**, төпсез көймәгә утырып калуым да бик мөмкин иде. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) Living as a roomer for five years after finishing the university, having no set (permanent) place to write and, in addition to all that, not seeing anything else besides the House of the Press and the streets of Kazan had begun to vex me. If things continued like that, it might be very possible that, as a writer, I’d be in a hopeless situation (lit., be getting in a boat without a bottom).

**[478] булып** (verbal adverb of **бул** ‘be’, ‘become’).
a) ‘as’ (in the function, condition, sense of):

- Ул 1947 елдан **ташчы булып** эшли башлады ... (Кызыл таң.) From 1947 on he began to work as a bricklayer ....
- Сәлих ... Нукай сигезьеллык мәктәбендә **укытучы булып** эшләгән. (ibid.) Sälikh ... worked as a teacher in the eight-grade (lit., eight-year) school of Nuqai.
- Революциядән соң Галимҗан Ибраһимов **язучы булып** кына түгел, тел-әдәбият **белгече, тарихчы** һәм тырыш җәмәгать **эшлеклесе булып** та танылды. (Г. Халит, Галимҗан Ибраһимов.) After the revolution, Ghalimjan Ibrahimov was known not only as a writer but also as a scholar of language and literature, as a historian, and as a zealous social worker.
- Аның ... «Татар телен ничек укытырга?», «Тел сабаклары» исемле хезмәтләре кат-кат басылып чыктылар, озак еллар мәктәпләрдә **дәреслек-кулланма булып** хезмәт иттеләр. (Мансур Хәсәнов, Галимҗан Ибраһимов.) His works ... “How to Teach the Tatar Language?”, “Language Lessons” were published many times over and for many years served as textbooks and manuals in schools.

b) *'as'* (role, character of):

- Гаяз кыза төште: – Сиңа килешүдә эш түгел. Авыл **кызы булып** киен! (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Ghayaz got excited: "The thing is not whether it suits you. Get dressed as a country girl!"
- ... яныбызга ашыга-ашыга Гаяз килеп җитте. Ул **Хәлил булып** киенеп, бизәнеп өлгергән иде инде. (ibid.) ... Ghayaz came hurriedly to us. He had already managed to dress as (i.e., as the character of) Khälil and to put on makeup.

c) 'like' (similar to):

- Күзләре **ут булып** яна башлады. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Her eyes began to burn like fire.
- Йолдызлар нуры, Киек каз юлы яктысы күктән серле **көч булып** агыла иде. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) The sparkle of the stars, the light of the Milky Way flowed from the sky like a mysterious power.

*Note 1.:* Preceded and followed by the same noun, **булып** has the meaning of **хәтта** 'even' (see 1263).

*Note 2.:* For reasons of style (for example, to avoid repeating the same postposition in short succession in a sentence), **буларак** and **булып** may be used in parallel construction. But note that they are not fundamentally sunonymic. They are 'synonyms' in 'such constructions' however.
For example: Мин сезгә бу сүзләрне рәсми кеше **булып** түгел, ә сезне якын күрүче кеше **буларак** әйтәм. (Атилла Расих, Ике буйдак.) I am not telling you this as an official person, but as a person who regards you as one close.

**[479] бәрабәр** 'equal'; 'corresponding'.
**бәрабәренә** 'at the price of', 'for'; 'instead'; 'in return for':

- Бу җиңү күп **корбан бәрабәренә** яулана. (Нияз Хәкимуллин, Арктика киңлекләрендә.) This victory was (lit., is) won at the price of much sacrifice.
- – Бөтенесен бәхетсез иттем, үземнең сафлыгымны югалттым, ә **шулар бәрабәренә** ни таптым, ни алдым? (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) "I made all of them unhappy. I lost my purity, and what did I gain, what did I get in return for (all) that?"
- Эш хәзер аерата авыр, ләкин **шуның бәрабәренә** күнелле дә. (Атилла Расих, Бәхет орлыклары.) The work is especially heavy now, but for (all) that, cheering.
- – Ихтимал булган **җәнҗаллар бәрабәренә** минем белән килешергә тырышуың күңелне йомшарта төште. (Әхсән Баянов, Аргы яр.) "Your endeavor to become reconciled with me, instead of quarelling (as you might have done), somewhat softened my heart."
- – Кадерле кунаклар, – диде конферансье егет. – Безнең атаклы җырчыбыз Сабир әфәнде Шәрипов бүген сырхаулап тора, сезне җыры белән бүләкләүдән гаҗиз ʤəçiz/. Әмма, **аның бәрабәренә** Сабир әфәнде безгә ... – скрипкада милли көйләребезне башкарачак! (Ибраһим Салахов, Имәннәр тамыр җәйгәндә.) "Dear guests," the young master of ceremonies said. "Our illustrious singer, Mister Sabir Shäripov is ill today and incapable of presenting you with his songs. But instead, Mister Sabir will perform (some) national melodies for us on the violin ...!"

**[480] вакыт** 'time'.
**вакытында**, **вакытта** 'during', 'for', 'as' (indicating time):

- Өч сәгатькә сузылган **сөйләшү вакытында** ул бик нык арыды ... (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) During the conversation, which stretched out three hours, he became very tired ...
- – Сабыр итегез, ... әйтәсе сүзегезне **фикер алышу вакытында** әйтерсез. (Мөхәммәт Шәйми, Сынау.) "Be patient, ... what you have to say you will say during the discussion period."

- Икенче **тәнәфес вакытында** алар янына доцент Янгура килде ... (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) During the second recess, assistant professor Yangghura came to them ...
- Монда бытбылдык, тургай тавышлары, аның **кыз вакытта**, үзенең тиңдәшләре белән урак урып, печән җыйнап йөргән заманнарын искәртә иделәр. (Шәриф Камал, Козгыннар оясында.) Here, the voices of the quail and the lark reminded her of her years (lit., times) when, as a girl, she reaped (and) gathered hay with her equals (i.e., girls her age).
- Ул һәр ике-өч көндә бер тапкыр керләр алып, тыныч вакытта гына елгага төшә һәм берәр **сәгать чамасы вакытта** керләр чайкап, юып, рәхәтләнеп кайта иде. (ibid.) Once every two or three days, at a quiet time, she would take the linen and go down to the river, and, for about an hour, she would rinse and wash linen and return contented.

**[481] итеп** (verbal adverb of **итү** 'to do', 'to make').
'as' (in the role, function, capacity, form, or sense of):

*Note:* With certain verbs (usually verbs of choosing, calling, naming, and making) a noun with **итеп** may correspond to a predicate objective (complementary object), or to a predicate nominative (subject complement) in English. It corresponds to the former when the verb is in the active, to the latter when it is in the passive voice.

- – Мин бит сезне аның белән чибәр **түташ итеп** кенә түгел, ә бигрәк тә булачак **музыкант итеп** таныштырдым. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) "After all, I did not introduce you to him just as a pretty young lady, but above all, as a future musician. "
- Ул үзен Җагпар Солтанбековның **агасы итеп** танытты. He introduced himself as the older brother of Jaghpar Soltanbekov.
- Ул бу кульъязманы **китап итеп** бастырырга бик хыяллана иде. He was dreaming very much of having this manuscript published as a book.
- ... Фәрит бу эшне кемгәдер башка кешегә йөкләргә җөрьәт итмәде, аны өстәмә бер **эш итеп** үз кулына алды. (Атилла Расих, Сынау.) ... Färit did not dare to charge some other person with this work, (but) took it on himself as an additional task.
- Ул 1928 елда Дәүләт сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый **әгъзасы итеп** сайланды. (Мансур Хәсәнов, Галимҗан Ибраһимов.) In 1928 he (i.e., Ghalimjan Ibrahimov) was elected a full member of the State Academy of Arts and Sciences.
- ... Ибраһимов аның ярдәмчеләреннән **берсе итеп** билгеләнә ... (Г. Халит, Галимҗан Ибраһимов.) Ibrahimov was (lit., is) appointed one of his (i.e., Wakhitov's) assistants ...
- Алар (яшьләр) ... халыкка хезмәт итүне үзләренә **бурыч итеп** куялар. (Бәян Гыйззәт, Кәрим Тинчурин /1887-1947/.) They (the youths) made (lit., make) it a duty to serve ... the people (or: made serving ... the people a duty).

*Note:* Kərim Tincurin (1887-1947). Writer, playright, actor and stage director. Author of numerous stage plays (dramas, comedies, etc.) and novellas.

**[482] иш** 'a pair'; 'an equal', 'kind'.
**ише** 'like', 'such as' (compares two or more of a class):

- Ул бит **минем ише** теләсә кемнән сорый ала һәм беркем дә аның үтенечен кире какмаячак. (Вакыйф Нуруллин, Һәлакәт.) After all, she can ask anybody like me (i.e., any of the executives) and no one will refuse her request.

- – Ә эш ничек соң? ... – Утын ваклау, утын кертү, ишек алдын, капка алдыларын себерү һәм башка **шуның ише** вак-төяк эшләр. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) “And what work is it then?” ... “Chopping wood, carrying in wood, sweeping the yard, the front of the gate and other minor jobs like these.”
- ... хәзрәткә сәдака итеп **сарык, сыер, ат, дөя ише** мал-туар тагып килүчеләр җәен дә, кышын да тукталмый. (Атилла Расих, Ямашев.) ... those coming to His Excellency (His Holiness), driving lifestock, such as sheep, cattle, horses and camels as a gift (i.e., as alms, charity), do not stop summer and winter.
- – **Синең ише** яшьрәк кешеләр өчен бер урында озак утыру файдалы түгел. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) “Remaining (lit., sitting) for a long time in one position (i.e., job) is not good for young people like you.”

*Note:* Final **+е** of **ише** can have two functions.

1. It may function as the possessive suffix third person singular of the noun **иш**. In that case, **ише** takes the case endings ordinarily joined to such possessive stems: ишенең, ишенә, ишен, ишендә, ишеннән.
2. Final **+е** may form an integral part of **ише**, making it a simple noun. **Ише** is then treated as any other noun. For example:

- ... бу кабиләләрнең бер **ишесе** көнбатышка таба юл тота. (Гариф Ахунов, Марсель Зарипов, И кадерле туган як.) ... one part of these tribes moved towards the west.
- – ... Мин аның **ишегә** сүз югалтасым да килми. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) “ ... I do not wish to waste any words on something like that.”
- Үзе инде югары белемле һөнәр иясе. Минем **ишеләрне** укытачак. (Вакыйф Нуруллин, Ике урам арасы.) She is already a specialist (expert, master) with a higher education. She will teach the likes of me.
- ... көчлеләр кирәк, ... – Хәсәннәр кебек, Морат **ишеләрдәй.** (Хәниф Хәйруллин, Картлык кемгә шатлык?) ... we need strong men, ... – like Khäsän, such ones as Morat.

**[483] йөз** ‘face’, ‘surface’.

1. **йөзенә** (most frequently with the words күк ‘sky’, җир ‘earth’, дөнья ‘world’) ‘on’, ‘upon’, ‘in’ (indicating movement to the face, surface of):
   - Бара торгач, кояш җиңеп чыкты,<br>**Җир йөзенә** карап көлде ул.<br>(Мәҗит Гафури, Кояш җиңде.)<br>Little by little the sun gained the upper hand,<br>It laughed down upon the earth.
2. **йөзендә**

a) (in this function mostly with the words күк, җир, дөнья) ‘on’, ‘upon’ (position on the face, surface):
   - Зәңгәр **күк йөзендә** алама бер болыт кисәгеннән гайре /ʤәjre/ берни күзгә чалынмый. (Рөстәм Кутуй, Сөенче.) Except for a thin shred of clouds, nothing catches the eye in the blue sky.
   - Ул минутта **дөнья йөзендә** миннән дә бәхетсезрәк беркем дә булмагандыр. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) That minute there was probably no one on the face of the earth more unhappy than I.

b) ‘in’ (people, things):
   - **Альфред йөзендә** ул гөнаһсыз, тәҗрибәсез авылны таныды, әнә шул җене котырган нәрсәләрдән вакытлыча булса да күз күрмәслек еракка алып китүче затны күрде. (Фоат Садриев, Адәм әүлиясе.) In Alfred she (Rufina) discerned the

simple, crude (lit., inexperienced) village, saw the person who would, if only temporarily, take her far away from those things (i.e., the din, street noise, the crowded streetcars, etc.) which angered her.

3. **йөзеннән**

a) (in this function mostly with the words күк, җир, дөнья) ‘from’ (indicating direction, from the face, surface of):
   - Караңгы **күк йөзеннән** вак-вак күбәләкләр шикелле карлар очып кешеләр өстенә сырыша ... (Шәриф Камал, Таң атканда.) From the dark sky snow is flying down like tiny butterflies and clinging to the people ...

b) (in this function mostly with the words күк, җир, дөнья) ‘in’, ‘over’ (indicating movement along):
   - **Күк йөзеннән** бер-бер артлы ак болытлар йөзәләр. (Әбрар Шәмин, Камай күпере.) In the sky white clouds are drifting by, one after the other.

c) ‘out of’ (for the sake of, for the purpose of), ‘in order to’:
   - Кунакчыл хуҗасына **ихтирам йөзеннән** Тома бу үтенечкә риза да була. (Иршат Вергасов, Кырым партизаннары.) Toma agrees to this request out of esteem for the hospitable hostess.
   - – **Мактау йөзеннән** түгел, ә чын дөресен әйтәм. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) “I don’t say it in order to praise, but I am speaking the real truth.”
   - Шул бурычны **үтәү йөзеннән**, амбарларга тутырылган орлыкларны тикшереп йөргәндә, бер амбарда чистартылмаган бодай очратты ул. (Мирсәй Әмир, Безнең авыл кешесе.) While, in order to carry out that duty, he was inspecting the seeds which had been stored (lit., filled) in granaries, he came, in one granary, upon wheat which had not been cleaned.
   - Белорус кызы Таня миңа үз өйләреннән укырга китаплар ташый иде. **Рәхмәт йөзеннән** мин аңа китапларын төпләп бирә идем. (Ибраһим Гази, Малайлыкта кунакта.) The Belorussian girl Tanya was bringing (lit., was carrying) me books to read from their home (lit. their own home). As a way of saying thank you, I was making (paper) covers for her books.

d) ‘as’ (indicating capacity, example):
   - Җәза **бирү йөзеннән**. As punishment.
   - **Мисал йөзеннән** әйтү. To say as an example.
   - Мондый мәкальләрнең кайберләре ... **киңәш йөзеннән** ... әйтеләләр. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) Some such proverbs ... are used (lit., said) ... as advice.

**[484] кат** ‘place beside, close to a person, place, or thing’.

1. **катына** ‘to’, ‘before’, ‘at’ (indicating motion towards):
   - **Мәгъсүмә катына** йөреп ияләшкән бия юл аерылышында кинәт кенә сулга каерды. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) The mare, which had got used to going to Mäghsümä, suddenly turned to the left at the fork of the road.
   - Якуп ... **Хәлим катына** килеп, малайның башына кулын салды. (ibid.) Jacob ... came over to Khälim and put his hand on the boy’s head.
   - – Кыбырсынма инде! Утыр әле **минем катка**. (Рөстәм Кутуй, Бер дә бер көзне.) “Now, don’t fuss about! Sit down beside me, please.”
   - – **Синең катыңа**, улым, зарланырга дип кермәдем. (Марсель Галиев, Ерак урман авазы.) “I did not come (in) to you, my son, in order to complain.”
   - Мин кичен азан әйткәнне тыңларга **мәчет катына** барам. (Ибраһим Гази, Малайлыкта кунакта.) In the evening I go to the mosque to hear the call to prayer.

- Авылдан авылга йөрибез. Басу капкасыннан килеп керүгә Җәмил абый: – Алма сатам, алма! – дип кычкырып җибәрә ... олылар ашыкмый гына ... алмалы **арба катына** якынаялар. (ibid.) We are moving from village to village. As soon as we enter through the village gate (i.e., the gate at the outskirts of a village on the road to the fields), uncle Jämil cries out: “I’m selling apples, apples!” ... unhurriedly ... the adults come up to the apple cart.

2. **катында** ‘beside’, ‘at’ (location):
   - – Ни булды? Син бит үзем киләм димәгән идең? – дип килүчене өйгә чакырырга да онытып, **ишек катында** терәлеп калды ул. (Ринат Мөхәммәдиев, Сират күпере.) “What happened? You hadn’t said that you would come yourself, had you?” he said, and remained standing (motionless) at the door, even forgetting to invite his (lit., the) visitor into the house.
   - – Үз гаебеңне кешегә аударма, – диде шул ара Шәмсүн Хәдискә һәм **күз катында** яткан кәгазьгә ишарәләп өстәп куйды ... (Азат Вергазов, Кайту.) Meanwhile, Shämsün said to Khädis: “Don’t shift the (lit., your) blame onto somebody else, and, motioning to the paper which lay there open to view (lit., before the eye), he added ...”
3. **катыннан** ‘from’ the direction of a place or thing):
   - – Башка вакытта сөйләрсең йомышыңны, – диде ул шактый коры итеп, – хәзер вакытым юк. – Ул картны бер селтәү белән **күз катыннан** юкка чыгарган кыяфәт белән өстәл өстендәге кәгазьләрен актарырга тотынды. (Азат Вергазов, Кайту.) “You’ll submit (lit., say) your request at another time,” he said rather severely. “I have no time now.” With an expression as if, with one motion, he had made the old man disappear from his sight, he began to go through his papers on the desk.
   - **Мич катыннан** өйне икегә бүлеп сузылган бүлмә тактасы буенда ... иске генә тимер карават. (Әмирхан Еники, Туган туфрак.) Along the room divider which, extending from the stove, divided the room in half (lit., two), is a ... rather old iron bed.

**[485] катнаш** ‘mixed’. As a postposition it indicates

a) simultaneous actions:
   - ... Артыкбикә тагын да ныграк борчылды. **Елау катнаш** ялыну тавышы белән Гаязны кире кайтырга өнди башлады. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) ... Artyqbikä started to worry (lit., worried) still more. With an imploring and crying voice she began to call upon Ghayaz to turn back.
   - Аның карт кипкән йөзенә, тирән, эчкә баткан күзләренә **рәнҗү катнаш ачу** ялкыны чыкты. (Галимҗан Ибраһимов, Тирән тамырлар.) There appeared in his old, shriveled face, in his deep-set eyes, a glint of anger (mixed with) resentment.

b) ‘side by side’, ‘together’:

   **Каен катнаш** нарат урманы. (T.T.A.C.) A pine forest mixed (interspersed) with birches (i.e., a forest in which pines are standing side by side with birches).
   - Болгар дәүләтендә, бигрәк тә далалы һәм урман **катнаш** далалы урыннарда, терлекчелек тә хуҗалыкның мөстәкыйль тармагы булып киткән. (Татарстан АССР тарихы, XI–XIII гасырларда Идел буендагы Болгар дәүләте.) In the Bolghar State, particularly in the steppe and forest-steppe areas, stockraising too was carried on as an independent branch of the economy.

c) inseparably mixed:
   - ... иртә белән күбәләк кар ява, җирнең өстен агартып ташлый, төш җиткәч, ул **кар катнаш яңгырга** әйләнә. (Давыт Юлты Кан.) ... in the morning, flakes of snow fall (and) quickly turn the ground (lit., surface of the earth) white. At midday (lit., when, after midday arrived), it turned (lit., turns) into rain mixed with snow.

**[486] катыш** 'mixed'. As a postposition it indicates

a) simultaneous actions:

- Йөзендә **аптырау катыш** каушау сизелә, ... (Мөхәммәт Шәйми, Сынау.) On his face one senses confusion together with embarrassment, ...
- Кучәрбай **елау катыш** калтыравыклы тавыш белән үзенең гаепсез икәнлеген аңлатырга теләде. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) In a trembling and crying voice, Quchärbai tried to explain that he was innocent.
- Ул **үпкә катыш** ачу белән Аязгуловның күзләренә карады. (ibid.) He looked into Ayazghulov's eyes with anger and resentment (lit., anger mixed with resentment).
- Әни, **шаяру катыш** шелтә белән каршы алып, үзенең көтә-көтә арып беткәнлеген аңлатты. (ibid.) Receiving us with mock reproach, Mother explained that she had become tired waiting (for us).

b) inseparably mixed:

- Сөякләргә үтеп исә торган ачы җил ярма сыман каты **кар катыш** ком бөртекләре алып килде. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) A penetrating wind, which cut right through to the bone, carried along grains of sand mixed with hard, granular snow.
- Караңгы. **Кар катыш** яңгыр ява. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) It is dark. Rain is falling mixed with snow.
- ... бүлмәдә тәмәке **төтене катыш** көнбагыш мае, төтәсләнгән балык һәм кер сабыны исләре аңкый. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) ... in the room there was a smell of sunflower oil, smoked fish, and laundry soap mixed with that of tobacco smoke.

c) 'side by side', 'together':

- Юл янәшәсендә, сул яклап, **каен катыш имән** урманы башланды. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) Beside the road, on the left, a forest of birches and oaks (i.e., birches and oaks standing beside each other) began.
- ... мәйданда **гаскәр** /ɢjəskər/ белән **эшчеләр катыш** митинг булды. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) ... at the square there was a meeting of workers side by side with soldiers. (митинг – зур җыелыш).

**[487] кебек (күк, кеби)** – (кеб 'model', 'form').
'as ... as', 'like' (similar to', in comparisons).

*Note:* **Кебек** is commonly used in today's Tatar language. **Күк** belongs to the spoken language but is also used in poetry and prose. The form **кеби** pertains to the older Tatar literary language.

1.
- – Мин дә өйләнәм! **Синеке кебек** матур хатын алам! (Ибраһим Гази, Канатланыр чак.) "I too shall get married! I shall take a woman who is as pretty as yours!"
- Бүре әйтә: – Син, нәкъ **минем кебек** үк, бүтән җан ияләре исәбенә яшисең. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) The wolf says, "You are just like me; you live at the expense of other creatures."
- Шәүрә егетне кулыннан алды. Алар шундук берсен-берсе әллә кайчангы **белешләр, дуслар кебек** хис итә башладылар. (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) Shäwrä took the young man by the hand. They instantly began to feel like acquaintances, friends who had known each other a long time.
- Биш **бармак кебек** яхшы белә ул Уфаны. (Атилла Расих, Айлы төннәр.) He knows Ufa well, like the back of his hand (lit., like his five fingers).
- Көн салкынча, мамык **кисәкләре кебек** эре-эре кар ява. (Рәфкать Кәрами, Сагышлы кояш.) The day is chilly; snow is falling in large flakes like shreds of cotton.
- Көтүчеләр тапкан **чишмә кебек**,
  Җырым минем, син дә улаксыз.

Шул **чишмә күк** син дә тыныч актың,
Шул **чишмә күк** син дә гөнаһсыз.
(Сибгать Хәким.)
Like the spring the shepherds come upon,
You too, my song, have no (confining) channel
(i.e., you are completely free, unbound).
You too have run quietly like that spring,
You too are without sin like that spring.

- Ул чыдый алмады. Гайникамал абыстайга да, ..., **бүгенге кеби** шәриф кичне гыйбадәт беләнрәк уздырырга тырышырга кирәк дип уйлаганын белдертте, ... (Фатих Әмирхан, Бәйрәмнәр, 1908.) He could not bear it. He let Lady Gheynikamal know that he thought she too should, ..., (like he himself) endeavor to spend a holy evening like today's more with prayer, ... (Rather than praying, Gh. was making preparations for the guests they expected the next day.)

2. A noun combined with **кебек** and repeated after the postposition in its required case form expresses emphasis (in English mostly rendered by 'even'):
   - Мондый энҗе гасырга бер генә мәртәбә табыла. Мондый байлыкны еш тудырырга **диңгез кебек диңгезнең** дә көче җитми. (Миргазиян Юныс, Энҗе эзләүчеләр.) Such a pearl is found only once in a century. Even the power of the sea is not sufficient to produce such richness often.
3. Used in enumerations of objects of similar kind, **кебек** means 'such as' (for example):
   - Рифгатьнең алдында төрле зурлыктагы тәлинкәләрдә **тозлы кәбестә, кыяр, помидор, тозлы балык кебек** сыйлар тезелеп тора, ... (Мирсәй Әмир, Саф күңел.) Before Rifghät, on plates of various sizes, are placed refreshments, such as salted cabbage, cucumbers, tomatoes, and salted fish, ...
4. **Кебек** with possessive suffixes and **бар** expresses politeness, often with a shade of humility or respectfulness:
   - – Төп теләгем күрешеп, хәлегезне белеп чыгу иде, Сания апа, – диде Рифгать һәм бераз уңайсызланыбрак өстәп куйды: – Кечкенә йомыш **кебегем** дә **бар**. (Мирсәй Әмир, Саф күңел.) "I mainly wanted to say hello and to inquire after your health, Mrs. Saniä," Rifghät said, and, somewhat uncomfortably, he added, "I would also have a small request."

**[488] килеш** 'appearance', 'semblance', 'look', 'state', 'way', 'manner', 'order'.

- Used as a postposition, **килеш** means 'as' (in the capacity, function, or sense of): ... Йосыф гомеренең ахырынача аңа тугры кала ... Зөләйха үлгәннән соң да яңадан өйләнми, бәлки, **тол килеш** кала биреп, балаларын тәрбияләү белән шөгельләнә. (Миркасыйм Госманов, Кол Гали – халык хәтерендә сигез гасыр.) ... Joseph remained faithful to her right to the end of his life ... Also after Zöleykha's death, he did not remarry, but lived on (lit., stays on) as a widower, busying himself with bringing up his children.

(For the use of the present tense instead of the past tense see 956, 5.)

- Әмма, гадәтенчә, бу эшне дә тагын кичектерде Чыңгыз. Ә үзе көтте, һаман көтте, һаман ялгыз килеш, **буйдак килеш** йөри бирде. (Заһир Садыйков, Ясалма чәчәкләр.) But, as was his habit, Chynggyz put this matter (i.e., proposing to a girl) off again. And he waited, and waited, continuing to live alone as a bachelor.
- ... хыялым – **хыял килеш** калды. (Гариф Гобәй, Без үскәндә.) ... my dream remained a dream.

**[489] кырый** (in the vernacular also **кыр**) 'edge', 'border'.

1. **кырыена** /qьrъjьna/ 'to' (the edge of), 'beside', 'next to' (indicating movement very close to):
   - Сәмигулла ... печән белән бүрәнәләрне каплый калды ... **Абзар кырыена** сөйрәлеп килгән бүрәнә эзләрен югалту нияте белән йорт тирәсен дә себергәләп алды. (Мәсгут Шәрифуллин, Еллар үткәч.) Sämighulla ... covered the logs with hay ... To cover up the tracks of the logs (left) by dragging them right up to the (cow) barn, he also swept here and there around the house.
   - Барысыннан да алдан килгән Фаягөл белән Миңлеҗамал кичәге урыннарына урнаштылар ... **Болар кырыена** Фәгыйлә, Нәсимә, тагын берничә хатын килеп утырды. (Нәзифә Кәримова, Карурманнан чыккан юлчылар.) Fayagöl and Minglejamal, who arrived before everybody else, took the seats they had the day before ... Fäghilä, Näsimä, and several other women came and sat down next to them.
2. **кырыенда** /qьrъjьnda/ 'beside', 'next to' (position very close to):
   - Зәйнәп, **гармончы кырыенда** утырган егет янына барып, нәрсәдер әйтте. (Мәсгут Шәрифуллин, Еллар үткәч.) Zeynäp walked over to the youth sitting right next to the accordion player and said something to him.
   - Мин белә башлаганнан бирле, безнең өебезгә генә орынып, юан кәүсәле шомырт агачы үсә ... Ә заманында шул **шомырт агачы кырыенда** калай түбәле, әйбәт каралты-куралы бай гына йорт та булган. (Нәзифә Кәримова, Карурманнан чыккан юлчылар.) As long as I can remember (lit., Since the time I began to think), a bird-cherry tree with a thick trunk has been growing (lit., is growing) quite close to our house ... And at one time, next to that bird-cherry tree, there were also a rather stately home with a metal roof, as well as (various) nice service buildings (work quarters).
3. **кырыеннан** /qьrъjьnnan/, **кырыннан** (vernacular) 'beside' (movement very close past):
   - **Йорт кырыеннан** гына аккан ... чишмәнең чылтыраганы таң атканда ишетелә торган ... тавышларга кушыла иде. (Мәсгут Шәрифуллин, Еллар үткәч.) The murmur of the ... spring, which flowed right by the house, mingled with the ... sounds heard at dawn.
   - Наиләнең тагын бер җитди шиге бар иде ... хәзер ... анысын да ачып салды. «Иртән, хуҗалар йоклаган **бүлмә кырыннан** үтеп барам, ишек ярым ачык, эчтә сөйләшәләр ...» (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында.) Nailä had still another serious doubt (suspicion) ... now ... she came out with that too: "In the morning when I was passing by the room in which the hosts sleep, the door was half-open and inside they were talking ..." (N. tells this to her husband. Both are guests in the home of her husband's rich brother, where they experience some very strange things.)

**[490] көй** 'shape', 'form', 'appearance'; 'way', 'manner', 'order'.
Used postpositionally, **көе**, **көенчә**, **көенә** express
a) 'as' (in the capacity, function, role, or sense of):
   - Соңгы вакытларда да Мәдинәнең кияүгә чыкмыйча **тол көе** яшәвен авыл кешеләреннән ишетеп белгәч, аның Мәдинә турындагы элекке уе /ujь/ тагын да ныгый төште. (Шәриф Камал, Матур туганда.) And after he learned from the village folks that Mädinä, not having remarried, was living in recent years as a widow, his earlier opinion of Mädinä became even more definite (stronger).
   - [Тәбәнәкев] әллә кайчан инде, **малай көенчә** үк ... Ялантаудан чыгып киткән булган. (Мирсәй Әмир, Саф күңел.) [Täbänäkev] (so they say) had already left Yalantaw a long time ago, when he was still a boy ...

b) manner, way:

- – Нишләп монда төшеп калдың? – диде хатыны, үпкәләгән сыман ... – **Үз көемә** җәяүлеп кенә кайтасым килгән иде, – дип акланды Җиһангир. (Нурислам Хәсәнов, Ак балык.) "Why did you get out (of the car) here?" his wife asked as though (a bit) angry ... "I had just wanted to walk home by myself, on foot," Jihangir said, apologizing. (J. is ill and walks with a cane. The car could have brought him right to his house. His wife, seeing her husband from the window, had hurried to meet him).

**[491] нам** (P.) 'name'.
**намына**
a) 'to' (in toasts):

- Тостлар башланды – кунаклар исәнлегенә, алдагы **уңышлар ... намына**. (Әхсән Баянов, Таш китап.) The toasts began – to the guests' health, to future successes, ...

b) 'for the sake of':

- **Җиңү намына** 'for the sake of victory'.

**[492] нигез** 'basis', 'foundation'.
**нигезендә** 'on the basis of', 'based on':

- Ул **карар нигезендә** губернада җыелышлар уздыру рөхсәт ителмәячәк, ... (Атилла Расих, Ямашев.) On the basis of that decree, holding meetings will not be permitted in the province, ...
- Билгеле инде, дәресләр барысы да мәгариф бүлегеннән бирелгән төп **программа нигезендә** алып барыла. (Ибраһим Салахов, Томаннарга төренгән яшьлек турында.) Of course, all classes (lit., lessons) are conducted on the basis of the original program issued by the Department of Education.
- **Шулар нигезендә** мәктәпнең бер бүлмәсендә язучы музеен оештырырга ниятлиләр. (Мәктәпкә – язучы исеме, К.У. 10, 1991.) On the basis of those (i.e., books, documents, pictures, etc. mentioned before), it is intended to organize, in one room of the school, a museum dedicated to the writer (i.e., to Afzal Shamov).

**[493] нәзед** (P.) 'nearness', 'closeness'.
**нәзедендә** (obs.) 'near', 'close', 'beside', 'at':

- Аңладыңмы, и гүзәл! Бәс җаным ул я /jә/ җаным ал,
  Ит бәни **нәздәңдә** үлмәклә сәгадәт наиле.
  (Габдулла Тукай, Мәхү идәрмисән? 1906.)
  In contemporary Tatar: Аңладыңмы, и гүзәл! Я /Jә/ җаным бул, я /jә/ җанымны ал, – Мине яныңда үлү белән бәхетле ит. (Юк итәрсеңме?) Did you understand, O beautiful one! Either be my sweetheart – or take my soul. Make me happy with death at your side.

*Note:* Җан 'soul' – also used as a term of endearment.

**[494] нәтиҗә** 'result'.
**нәтиҗәсендә** 'as a result of', 'resulting from', 'in consequence of', 'owing to', 'due to', 'because of', 'through':

- Бу чорда телләрнең әле язма формалары булмаган. Шуңа күрә төрле тарихи **сәбәпләр нәтиҗәсендә** бу телләр төрле үзгәрешләргә бик тиз бирелгәннәр. (М.З. Зәкиев, Татар халкы теленең барлыкка килүе.) In this period, languages did not yet have a written form. Therefore, as a result of various historical causes, these languages very quickly yielded to various changes.

- Ел коры килсә дә, **сугару нәтиҗәсендә** уңыш әйбәт көтелә. (Социалистик Татарстан.) Although the year is coming on dry, the harvest is expected to be good, owing to (due to) irrigation.
- **Шулар нәтиҗәсендә** безне бөтен авыл бик тиз белеп алды. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) In consequence of those (works), the whole village very quickly got to know us.

**[495] рәвеш** 'shape', 'form', 'appearance'.

1. **рәвешендә** 'like' (similar to; in comparisons); 'as' (in the capacity of), by way of:
   - Юлыбыз тыныч булмады, көймәбез куәтле дулкыннар арасына ташланган кечек бер **йомычка рәвешендә** әйләнгән чаклар күп булды. (Галимҗан Ибраһимов, Диңгездә.) Our voyage (lit., way) was not calm. There were many moments when our ship gyrated like a small chip thrown into the midst of powerful waves.
   - ... су астында тоташ мәрҗән урманы башланды. Мәрҗәннең күбесе урман **абагасы рәвешендә** үсә. (Миргазиян Юныс, Бездән яшерен зәңгәр дөнья.) ... under water a continuous coral forest began. Most corals were (lit., are) growing like forest fern.
   - ... [көймә] бераздан бер батып, бер калкып уйнаган кармак **калкавычы рәвешендә** генә күренә башлады. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) ... soon, [the boat] began to look only like the bobbing (lit., playing) float of a fishing rod, now going down, now rising.
   - – ... **киңәш рәвешендә**, бер-ике сүз әйтәсем килә сезгә. (Риза Ишморат, Шайтан таягы.) "... I wish to say to you a few words by way of advice."
2. **рәвештә** 'like' (similar to), 'as' (in the capacity of), 'by way of', 'in' (the form of):
   - ... хезмәт халыкларының тормыш, социаль-тарихи тәҗрибәләрен мәкальләрнең үзенчәлекле чагылдыруларын да (яки **үрнәк рәвештә** калыпка салуларын) бу китапта җитәрлек табачакбыз. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) In this book, we shall also find in abundance that proverbs reflect characteristically (or put into a mould by way of example) the social-historical (and) life experience of the working people. (социаль – иҗтимагый).
   - ... **башлангыч рәвештә** бу турыда кайбер фикерләремне әйтеп үтмәкче булам. (ibid.) ... as a beginning, I wish to mention some thoughts of mine about this.

   (For үтмәкче булу see 1223 a, 1224 b, 1225, 1228, 1230.)
   - Теләгән кеше соравын **язма рәвештә** дә бирә ала ... (Габдрахман Минский, Язның беренче көне.) Any person who wants to can submit his question in writing as well ...
3. **рәвешле**, **рәвешчә** 'like' (similar to):
   - ... Ильяс эчкә узды һәм ишекне сак кына япты. Бүлмә караңгы булганлыктан башта Рәгыйдә күзгә күренмичә, аның караватта ятып торганын чамаларга гына мөмкин иде. Шулай да бераздан бүлмә ярыклары аша төшкән зәгыйфь яктылык күзгә чалына башлап, аннары **шәүлә рәвешле** генә гәүдә барлыкка килде. (Әхсән Баянов, Җәй белән җәй арасы.) ... Ilyas entered and cautiously closed the door. As the room was dark, he could not see Rägidä at first. He could only guess that she was lying in bed. However, after a little while, the scant light falling through the cracks of the room began to strike the eye, and then (her) body emerged as a silhouette.
   - Мәкальләрне җыю бер эш, әмма аларны нинди тәртиптә бирергә? ... Эшнең **бу рәвешле** торуы җыелган мәкальләрнең дә матбугатка чыкмый ятуына төп сәбәпләрнең берсе булып тора дияргә мөмкин. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) Collecting proverbs is one thing, but in what order do you present (lit.,

give) them? ... That (lit., That the matter stands like this) is, one can say, one of the principal reasons why collected proverbs are also not being published.
- [Бизгәк] бераздан **Казандагы рәвешчә** бөтен тамырларны дерелдәтә башлады. (Габдулла Тукай, Т.Т.А.С.) [The fever], like that (a short time ago) in Kazan, soon began to make all my (lit., the) veins tremble.

**[496] саен** /sajьn/ (сан 'number', 'figure').

a) 'every', 'each' (indicating recurrence):
- Эштән соң алар һәр **көн саен** икәүләп велосипедта күнегүләр ясыйлар. (Мәгъсүм Гәрәев, Җиңелмәс капитан.) Every day after work, they both train together on bicycles.
- **Бәйрәм саен** я /jə/ үзе кунак чакыра, я /jə/ ... дусларына бара. (Рәфкать Кәрами, Сагышлы кояш.) Each holiday, either he himself invites guests, or he goes to ... his friends.
- Журнал **ай саен** татар телендә чыга. The journal appears monthly in the Tatar language.
- Җиргәндә яши торган татарларның үз араларында да **урам** яки **тыкрык саен** диярлек бер шивә. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) Also among the Tatars themselves who live in Jirgän a different dialect is spoken in almost every street or lane.
- Элеккеләрне сагынып утырырмын. **Җыелыш саен** сөйли идем бит, ... (Габдрахман Әпсәләмов, Идел хикәяте.) I shall be sitting, longing for what was in former times. After all, I was speaking at every meeting, ...
- Нәнәү дә **хат саен** диярлек чакырып яза. (Сәрвәр Әдһәмова, Нәфисә апа.) Nänäw too invites her almost with every letter.

b) 'each', 'per', 'to' (indicating equality, uniformity on the basis of a unit):
- ... **бүлмә саен** өчәр-дүртәр кеше утыра, ... (Фатих Хөсни, Алтын эзләүчеләр.) ... in each room there are sitting three to four people, ...
- Капка **төбе саен** диярлек, икешәр-өчәре бергә җыелган кешеләр ... безне күзәтәләр. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Almost at every gate people ... gathered together in groups of two or three (each), are watching us.
- ... әйләнә-тирәбездә алты-җиделәп көймә. **Көймә саен** өч-дүрт кеше. (Мирсәй Әмир, Балыкчы ялганнары.) ... there are about six or seven boats around us. In each boat there are three or four men.
- Ашханә залы гаҗәп зур, матур. Ап-ак ашъяулык җәелгән өстәлләр ... **кеше саен** кашыгы, чәнечкесе, пычагы куелган. (Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр, Исмәгыйль Рәмиев.) The restaurant room is amazingly large (and) beautiful. The tables are covered with snow-white table cloths (lit., There are tables covered ...) ... For each person a spoon, a fork, (and) a knife have been laid out.

*Note:* The expression **аның саен** means: 'all the' (with the comparative of adjectives), 'in spite of'; 'still', 'constantly':
- Тавышы гел бер көе, битараф, хиссез. Ә хаттагы сүзләрнең тәэсире **аның саен** көчлерәк ... иде. (Әхәт Гаффар, Бишек.) His voice was (lit., is) completely even, neutral, unemotional. But the effect of the words in the letter was all that much stronger ...
- Зәйтүнә ... урыныннан торып, бүлмәгә чыкты, җәелмәле ятакка урын әзерләргә кереште. Ә кухняда Лариса **аның саен** җанланып сөйли иде. (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) Zeytünä ... got up, went into the room and began to prepare a place on the folding bed. But in the kitchen Larisa was talking all the livelier.

· Нинди кеше мин? Нигә кирәк миңа ул Мәдинә? Ләкин Мәдинә **аның саен** күз алдыннан китми ... иде. (Атилла Расих, Ике буйдак.) What kind of a man am I? What do I need that Mädinä for? But Mädinä still did not disappear from his mind's eye ...
· «Ай-һай бай яши хәзерге балалар» – дип сокланып куйды ул. Тик соклануның чиге булмады: малайлар **аның саен** акча санадылар: йөз, биш йөз, мең. (Камил Кәримов, Алдавыч көз.) "Oh, do today's children live affluently," she said to herself in wonder. But the wonder did not end there. The boys still kept on counting out money – one hundred, five hundred, a thousand.

**[497] сая** /sajə/ (P. saya) 'shade', 'shadow'; 'protection'.
**саясендә** /sajəsendə/ (obs.), corresponds to **аркасында**, **сәбәпле**:
· Шәриф һаман сүз башламый, бүген мәшәкать белән үзенең **уңганлыгы саясендә** генә акча тапканлыгын белдерер бер сурәттә тора иде. (Мәҗит Гафури, Ярлылар, 1907.) Shärif was standing (there), still without speaking, and in a manner which let it be known that today he had earned money only with difficulty and through his dexterity.
· Мин хәзер инде Думага сайландым, ... Мин бу дәрәҗәгә алланың миңа **ярдәме саясендә** генә ирештем. (Галиәсгар /Ɑ̃əliəsɑ̃ər/ Камал, Депутатлар озату, 1907.) Now I have already been elected to the Duma[1] ... I have reached this rank only through God's help to me.
· ... Габбас яшь пишкадәмнәрдән улса (булса) да, **зәкавәте саясендә** (сәләтлелеге аркасында) карт хәлфәләрдән дә гыйльме артык иде. (Закир Һади, Бәхетле кыз, 1904.) ... although Ghabbas was a young pishqädäm[2], through (due to) his giftedness his knowledge was superior to that of the old teachers.

**[498] сурәт** 'picture', 'appearance', 'shape', 'form'.
**сурәтендә** 'as' (similar to):
· Син **тәрбияче** һәм **ана сурәтендә** итә башлаган бу яңа гомереңнән тагы үзенә башка бер кызык табарсың. (Габдулла Тукай, Икенче мәктүп, Фатыйма Гайшәгә.) You will find again some new (special, particular) interest in your new life which you have begun as an educator and a mother. (мәктүп – хат).
· **Җен җегетләре сурәтендә** кырык кыз юлбасарлык кыла икән, дигән хәбәрләр күптән йөри. (Батулла, Сөембикә кыйссасы.) Reports have been circulating for a long time claiming that forty girls, appearing (i.e., clad and behaving) as men possessed by evil spirits, are waylaying travelers.
· Тәбәнәк буйлы булса да, утырган чагында ул ничектер көчле бер **кеше сурәтендә** иде. (Рөстәм Кутуй, Бер дә бер көзне.) Although he was rather short, when he was sitting, he somehow looked (lit., was) like a strong man.

**[499] сыйфат** 'quality', 'character', 'capacity'.
a) **сыйфатында**, **сыйфаты белән** 'as' (in the capacity, quality of):
· ... мин аны һаман көлеп, шаярып, гел кызык сүзләр генә сөйләп утыручы бер **кеше сыйфатында** күрергә әзерләнгән идем. (Мирсәй Әмир, Казан.) ... I had been prepared to see him as a man who always laughs, jokes, always says only interesting things.

---

[1] Parliament in Czarist Russia.
[2] A person who has finished the complete course of the old medrese.

- Сәлим бу ачы сүзләрен эчке тантана белән, **җиңүче сыйфатында** әйтте. (Рәфкать Кәрами, Сагышлы кояш.) Sälim said these (his) bitter words with an inner triumph, as the victor.
- – ... **тәрҗемәчегез сыйфатында** мин сезне озатып йөриячәкмен, – диде ... (Ислам Беляев, Солдат төймәсе.) "... I shall accompany you as your interpreter; he said ..."
- Ильяс, ике көтүченең **берсе сыйфатында**, шул авыр эшне һич җиксенмичә үз өстенә алды. (Әхсән Баянов, Җәй белән җәй арасы.) ... as one of two shepherds, Ilyas took that heavy work upon himself without any reluctance.

b) 'like' (similar to):

- Ильяс бирге ярның актык чигенәчә килде дә, шунда үзе кагарга җыенган казыкларның **берсе сыйфатында** катты да калды. (ibid.) Ilyas advanced to the very edge of his side of the (river) bank and suddenly stood there as if rooted to the spot like one of the stakes he was about to drive into the ground.

**[500] сыман**, **сымак** 'like' (somewhat similar to), 'as' (in the capacity of).
**Сыман** and **сымак** are synonymous. They are used to make comparisons indicating qualified similarity, resemblance. For example: ук сыман 'arrow-shaped', кеше сыман 'resembling a man', кеше сыман маймыл 'anthropoid ape'.

Compare the examples below:

- Болыт дысәң болыт түгел, күктә әллә ниткән **төтен сыман** дымлы бөркүлек тора һәм аның аркылы бер генә йолдыз да күренми иде. (Рафаэль Мостафин, «Оҗмах»ка сәяхәт.) There was not a cloud. In the air (lit., sky) there was a damp, oppressive heat like some sort of smoke, and through it not one star was visible.

(For дисәң as intensifier see 1017 d.)

- Бу ике нарат безгә чыннан да картаеп бөкрәйгән **карт** белән **карчык сыман** күренә башлыйлар. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) These two pines begin to look to us really like (somewhat similar to) an old man and an old woman who, growing old, have become stooped.
- **Бәрхәт сыман** яшел үсентеләр белән капланган, өстенә су җибәрелгән дөге басулары кояшта ялтырый. (Рафаэль Мостафин, «Оҗмах»ка сәяхәт.) The irrigated rice fields covered with velvety green shoots, glisten in the sun.
- Ташлары әнә бүген дә, җимерелгән хыял **хәрабәләре сыман**, җирдә аунап ята. (Фаил Шәфигуллин, Өй салуның ние бар.) Even today its stones lie on the ground like the ruins of a shattered dream.
- Ниһаять, беркөнне шушы хакта **хикәя сымак** бер нәрсә яздым. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) At last, one day I wrote something like a story about this.
- Һади абый бит ул миңа **этием сымак** кеше! (Кояш Тимбикова, Агым уртасында.) Uncle Hadi is, after all, like a father to me (lit., a person like, similar to, a father)!
- ... ул Рушадка авыру **кеше**, ә икенче төрле әйтсәң, **бала сымак** итеп карый. (Габдрахман Әпсәләмов, Идел хикәяте.) ... she regards Rushad as a sick man, in other words, as a child.

*Note:* **Сыман** and **сымак** may serve as word forming elements. For example: күбәләк 'butterfly' – күбәләксыманнар 'papilionaseous plants'; олы 'older', 'elderly', 'adult', 'venerable' – олысымаклану 'to put on airs', 'to give oneself airs'.

**[501] сын** 'figure', 'picture', 'image', 'sculpture', 'portrayal'.
**сынлы** 'like', 'as', 'similar to':

- Ул үзен һавалы тота; кызыл өйгә еш-еш /jьş-jьş/ кереп китә дә, аннан моңа бик мөһим эш , вазыйфа тапшырылган **адәм сынлы** чыгып һәм халыкка эре вә югарыдан карап: ... Таралмагыз, китмәгез! – дип кычкыра. (Галимҗан Ибраһимов, Яшь йөрәкләр.) He behaves arrogantly. He frequently goes into the red house and, emerging from it like a man charged with a very important task and great responsibility, haughtily looking down upon the people, he cries: ... "Don't go away, don't leave!"
- Аля авылында да бу **Казантау сынлы** тау бар. (Ибраһим Салахов, Имәннәр тамыр җәйгәндә.) In the village of Alya there is also a mountain like this Qazantaw here.
- Менә хәзер тишек **капчык сынлы**, сөйләгәндә берәү бүлдерсә, уем төшә дә кала. (ibid.) Now it's like a bag with holes. If somebody interrupts me while I'm speaking, I immediately lose my thoughts (train of thought) (lit., my thoughts get lost immediately).

(For төшә дә кала see 1377.)

- – ... Мачы Гыйлаҗ кызын әйтәм, урам аша гына тора. Менә дигән, кура **җиләк сынлы**. (ibid.) " ... I mean Machy Ghilaj's daughter who lives just across the street. She is really something – like a raspberry."

**[502] сәбәп** 'cause', 'reason', 'ground'.
**сәбәпле** 'because of', 'due to', 'on account of', 'since':

- Ай чамасы вакыт үткәч, бүтән эшкә **күчерелүе сәбәпле** ул автобус белән көн саен Чаллыга йөри торган булды. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) After about a month had passed, (and) because of (due to) her having been transferred to another job, she started going (i.e., she assumed the habit of going) to Chelny by autobus every day.
- Укытучыларның хезмәт хаклары **арту сәбәпле**, Солтанга бүген узган айлары өчен өстәмә түләделәр. (Гадел /Ɑ̃ədel/ Кутуй, Солтанның бер көне.) Due to the increase in teachers' salaries, they paid Soltan today additionally for past months.
- Залда халык артык күп булса да, урынының бик **зурлыгы сәбәпле**, тыгызлык тоелмый иде. (Фатих Әмирхан, Фәтхулла хәзрәт.) Although there were a great many people in the hall, no overcrowding was felt, due to the great magnitude of the place.

**[503] тараф** 'side', 'direction'.

1. **тарафына** 'to', 'towards' (indicating direction):
   - Ул урыныннан сикереп торды, ... Капка ягына илле адым, бинага таба кире илле адым ... Тагын **капка тарафына**, янә кирегә ... (Барлас Камалов, Ялыкмаслар.) He jumped up from his seat, ... To the gate (it is) fifty paces, back to the building fifty paces ... Again to the gate, again back ...
   - ... кешеләр **аның тарафына** борылып карамыйча үтмиләр. (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) ... people do not pass without turning round and looking at her.
   - [Мусин-Азман] ... урам чатындагы **йорт тарафына** ымлап: – Әйдә, шунда барып килик әле, – диде. (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем элмәге.) ... motioning towards the house on the street corner, [Musin-Azman] said: "Come on, let's go there now."
2. **тарафында** 'about' (concerning), (used rarely in this function):
   - **Кем тарафында** сүз бара? (Татарча-русча сүзлек.) About whom is the conversation?

3. **тарафыннан**

a) 'from', 'for one's part', 'in' (indicating starting point, source):

- Талипов. ... мин **үз тарафыннан** мөмкин булган бөтен чараларны эшләдем, иптәшләр. (Шәриф Камал, Габбас Галин.) Talipov. ... for my part, I have taken (lit., done) all actions which were possible, comrades.
- Кызның ... моңа кадәр **һичкем тарафыннан** бу кадәр ягымлы сүзләрне ишеткәне юк иде. (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) Up to now, the girl ... had not heard such endearing words from anybody.
- **Җәнүп тарафыннан** болытлар төн ягына таба агылалар. (Садри Җәләл, Дим буенда.) Clouds are drifting from the south towards the north. (җәнүп – көньяк 'south').

b) 'by' (indicating an animate agent with verbs in the passive voice; see also 861, 862):

- Җыентыкка кергән күпчелек мәкаләләр, истәлекләр, белешмәләр төрле урыннарда театр төзүдә турыдан-туры үзләре катнашкан, йә булмаса шул вакыйгаларның җанлы шаһите[1)] булган **кешеләр тарафыннан** язылган һәм боларның һәммәсен яхшы **белүчеләр тарафыннан** бастырып чыгарылган. (Татар совет театры.) The majority of the articles, recollections, communications included in the collection have been written by persons who themselves have directly participated in establishing theatres in various places, or who have at least been living witnesses of those events, and they have been published by persons who knew all of these well.
- Пахом, бу икмәк кисәгенең **дусты тарафыннан** соңгы кабат бүләк төсле итеп бирелгәнлеген сизә. Бу – аерылышу минутлары иде. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) Pakhom realized (lit., realizes, feels) that this piece of bread was (lit., is) being given to him by his friend as a final gift. These were the moments of their final parting.
- Ногман үз **баласы тарафыннан** әйтелгән бу сүзне әз генә дә авырга алмады, ... (Мирсәй Әмир, Карамалы егете.) Noghman did not resent these words spoken by his own son even a bit, ...

**[504] тирә** 'surroundings', 'environment', 'environs'.

1. **тирәсенә** 'around' (movement to and around):

- Кергәч, чәй табыны әзерләнгән **өстәл тирәсенә** утырыштык. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) After entering, we sat down (together) around the table, which was set for tea.
- Башкалар да **минем тирәгә** тупландылар. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) The others too gathered around me.
- Мостафа, Каюм һәм башкалар **Һидият** /Hidiət/ **тирәсенә** җыйналдылар. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Mostafa, Qayum and the others gathered around Hidiät.

2. **тирәсендә**

a) 'around' (movement about the central point of):

- Җир **Кояш тирәсендә** ... әйләнә, Ай исә **Җир тирәсендә** әйләнеп йөри. (Гөлсем Мөхәммәдова, Яшьлек көннәре.) The Earth revolves around the Sun ... as for the Moon, it revolves around the Earth.
- Урам **утлары тирәсендә** кар бөртекләре ак күбәләкләр кебек бөтереләләр. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Snowflakes are whirling around the street lights like white butterflies.

b) 'around' (movement, position in the vicinity of, about, near, at):

- Хафиз. **Синең тирәңдә** башка егетләр буталуын яратмыйм. (Риза Ишморат, Гөлзадә.) Khafiz. I do not like other (young) men hanging about you.

---

[1)] Also used with back vowel suffixes: шаһиты.

- Нәсимә белән Хәмидә **казаннар тирәсендә** мавыгалар. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Näsimä and Khämidä are busy around the kettles.
- Бу **сукмаклар тирәсендә** кош оялары бар иде. (Социалистик Татарстан.) Around these paths there were (i.e., there used to be) bird's nests.
- Гөлнур. Мин дә **шул тирәдә** торам, Җәгъфәр картта. (Фәтхи Бурнаш, Камали карт.) Gölnur. I too live around there, with old (man) Jäghfär.
- И, матур йорт ул! Яшелгә буялган калай түбәле. **Тирәсендә** алма, чия бакчасы. Ә **бакча тирәсендә** биек коймалар. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) Oh, how beautiful that house is! It has a (sheet) iron roof painted green. Around it is a garden with apple and cherry trees. And around the garden are high fences.

c) 'around' (approximately – with time of day, date, age, weight, price, etc.):
- Буген сәгать **унберләр тирәсендә** офыкта төтенләп баручы морҗалар сафы күренде. (Рафаэль Мостафин, «Оҗмах»ка сәяхәт.) Today, around eleven o'clock, a row of smokestacks, which were emitting smoke, appeared at the horizon.
- Төхфәттән башка монда тагын өч татар бар иде. Аларның икәвесе егерме биш **яшьләр тирәсендә**, берсе шактый өлкән ... кеше иде. (Шәриф Камал, Таң атканда.) Besides Tökhfät, there were still three Tatars here. Two of them were around twenty-five years old, one was an elderly man ...
- Шәфи Шамилнең улы Заһид 1870-71 **еллар тирәсендә** Калугада дөньяга килгән. (Ибраһим Нуруллин, Фатих Әмирхан.) Shäfi Shamil's son Zahid was born in Kaluga around the years of 1870-71.
- Капал – бик кечкенә бер шәһәр. Анда яшәүче халыкның да саны унбер-унике **мең тирәсендә** генә. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) Qapal is a very small town. Also the number of people living in it is only around eleven or twelve thousand.

d) 'about' (concerning):
- ... Мохтар ул **мәсьәлә тирәсендә** байтак уйлады. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) ... Mokhtar thought much about that matter.
- Чынлап та, сүз **Гариф тирәсендә** барган чагында, Газизәнең /Ǫəzizənen/ күз алдына Гарифның кыяфәте /qiafəte/ килеп баскан. (ibid.) Indeed, while the conversation went on about Gharif, Gharif's figure appeared before Ghäzizä's (inner) eye.

3. **тирәсеннән**

a) 'around' (movement around and along a surface):
- Алар **чыршы тирәсеннән** бергәләп әйләнделәр дә ... тар юлдан клубка кереп киттеләр. They walked together around the New Year's tree (lit., fir-tree) and entered the club by the narrow path ...
- Печән базары **тирәсеннән** узышлый мондагы үзгәрешләргә хәйран калдым. (Гомәр Бәширов, И язмыш, язмыш.) ... when passing Haymarket, I was amazed at the changes (which had taken place) here.
- Сорауларым күп иде. Тик иркенләп сөйләшеп булмый. ... аркылы чыгучы көймәләрне урап узарга кирәк. Сөйләшүгә мавыгып китеп, **кораб тирәсеннән** үтеп торган көймәләрне батырып ташлавың бар. (Миргазиян Юныс, Юлда уйланулар.) I had many questions. But it was (lit., is) impossible to talk freely (i.e., without interference). We had (lit., have) to ... navigate around the boats which were (lit., are) going across (i.e., across the Bosporus). If we (i.e., the speaker and the ship's pilot) were to become engrossed in conversation, we might sink the boats which pass by the ship.

b) ‘from around’:

- Кан басымы ике йөз утыз-ике йөз **кырык тирәсеннән** төшми, ... (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) His blood pressure does not fall from around two hundred thirty, two hundred forty, ...

**[505] тирәли** (verbal adverb of тирәләү ‘to fence in’, ‘to border, edge with; тирәләп йөрү (очу) ‘to walk (fly) around something’).
‘around’ (both position and movement):

- Ул, ..., **өстәл тирәли** утырган Сабиров, һәм Фирсовларга сөзеп карап алды, ... (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) ..., he glanced intently at Sabirov and Firsov, who were sitting around the table, ...
- Әбүзәр күзлеген киде дә, **өстәл тирәли** йөреп, чәчәкләрнең һәрберсен аерым-аерым карый башлады. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Äbüzär put on his glasses and, walking around the table, began to look at each of the flowers separately.

**[506] тиң** ‘equal’ (in height, depth, width, length, etc.).
**тиңентен**, **тиңеннән** ‘up to’ (equal to ... in height, depth, etc.):

- Аларга көлке, ә мин **тубык тиңентен** суда. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) To them it is funny, but I am up to the ankles in water.
- Александр. ... иелде һәм ... идәннән зур йомры таш алды. Хасил булган тишеккә **терсәк тиңентен** кулын тыкты да ... металл таяк тартып чыгарды, ... (Зөфәр Фәтхетдинов, Ачылган серләр.) Alexander. ... bent down and ... lifted a large, round stone from the floor. He put his arm up to the elbow into the hole which had appeared, and pulled out a metal rod, ...
- **Бил тиңентен** булып үскән куе кычытканлыклар арасыннан сержант: – Москвыч! Автомашина!! – дип кычкырып җибәрде. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) From dense thickets of waist-high stinging nettles (lit., growing waist-high) the sergeant cried out: “A Moskvich! A car!!”
- Авылга кергәнче Абу бабага **тез тиңеннән** кар ерып барырга туры килде. (Булат Сөләйман, Абу баба.) Until he entered the village, Abu Baba had to struggle on, breaking a way through the knee-deep snow.

**[507] туры** ‘straight’, ‘direct’.

1. **турысына**, **турына** ‘about’, ‘around’, ‘near’, ‘opposite’ (indicating movement to the vicinity of a place or thing):
   - Тагы бераз сөйләшеп йөргәч, **Мәдинәләр турына** килеп җиттеләр. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) After they had walked and talked still a little more, they arrived near Mädinä’s place.
   - Без Хәбирә әбиләр **тыкрыгы турысына** җиткәч тә тыкрыкта ниндидер карачкылар күрдек һәм шунда ташландык. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Upon arriving near Grandma Khäbirä’s lane, we saw in the lane some dark silhouettes, and rushed there.
   - Күргәзмә **парк турысына** урнашкан. (Татарча-русча сүзлек.) The exhibition is located opposite the park.
2. **турында**, **турыда**, **турысында**

a) ‘about’ (concerning):

*Note:* The form **турыда** is used with demonstrative pronouns in the *nominative* (бу, ул, шул, etc.) and with personal pronouns (except that of the 3rd person singular and plural) in the possessive case. However, with the latter **турыда** may also take the possessive suffixes. For example: синең турыда, or: синең турыңда ‘about you’.

· Үз-үзен миннән зуррак, өстенрәк итеп тотты. Ничәнче елгысың, диде; кайдан килдең, кайда укыдың, диде; әтиең-әниең бармы, ... диде. Шуннан соң **Уфа турында, шәһәр тормышы турында** сораштыра башлады. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) He comported himself as though he were older than I, as though he were superior. He asked (lit., said) how old I was; he asked (said) where I came from, where I studied; he asked (said) whether I had parents, ... Then he began to inquire about Ufa, about city life.

(For indirect discourse see 432, analytical, 1265, c-e.).

· Мин Гаязга Имәлинең кем **булуы турында** сөйли башладым. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) I began to tell Ghayaz about who Imäli was.

· Мин **бу турыда** уйламый булдыра алмадым. (Мәгъсүм Насыйбуллин, Телсез шаһитләр.) I could not help thinking about this.

· – ... сез, Елена ... **үзегез турында** сөйләгез ... (Барлас Камалов, Ялыкмаслар.) .".. you, Yelena. ... talk about yourself."

· Кичә Мәдинәдән алган **хат турысында** уйланулар ... аның йокысын качырганнар иде, ... (Шәриф Камал, Матур туганда.) The thoughts about Mädinä's letter, which he had received yesterday, ... had prevented him from sleeping, ...

· Кызчыкның безнең белән озак сөйләшәсе килмәде, бик зур **эш турысында** сөйләгән кыяфәт алып, Низаминың колагына нәрсәдер пышылдады. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) The little girl did not wish to talk with us for long. Assuming an air as if speaking about a very important matter, she whispered something into Nizami's ear.

(For the future participle in **-асы** etc. plus **килү** see 1143.)

b) **турысында**, **турыда** 'opposite', 'around', 'near' (ind. position):

· ... менә, инде кыш кергәч, чатлама суык төннәрнең берсендә Нигъмәтулла узып баручы эшелоннан **авыл турысында** сикереп төшеп кала. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) ... there, on one freezing cold night, after winter had already arrived (lit., entered), Nighmätulla jumped (lit., jumps) down from a passing troop train, near the village.

· **Бу турыда** тирән ярлары астына яшеренгән Тын елга борылмалы тугайлы урыннарда ара-тирә күзгә чагылгалап китә. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) Around here (lit., Around this (i.e., this spot, place here), the river Tyn, hidden under its steep (lit., deep) banks, now and then catches one's eye at curvy, grassy spots.

3. **турысыннан**, **турыннан**

a) 'by' (indicating movement past a place or thing):

· Ул **мәчет турысыннан** үткәч тә, атны урам юлыннан Хөснулла капкасына таба борды. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Right after passing by the mosque, he turned the horse along the street towards Khösnulla's gate.

· Авылда бер нәрсә дә яшерә алмыйсың: ... кич саен синең **Борһаннар турыннан** үтеп киткәнеңне күреп торалар. (Аяз Гыйләҗев, Җомга көн, кич белән.) In the village you can't hide anything: ... they see that every evening you walk past the Borhans' (house).

b) 'from around' (indicating movement from around):

· Моратбакыйның тәрәзәсеннән караганда, иртәнге кояш гел шушы **өянке турысыннан** күтәрелә иде. (Марсель Галиев, Ерак урман авазы.) When looking out from Moratbaqi's window, (one always sees) the morning sun rising from around this willow tree (i.e., from this same willow tree mentioned just before).

· Борылып караса – өлкән яшьтәге таза гына милиционер. – Егет, **бу турыдан** юлны аркылы чыгарга ярамый, – диде ул. (Фоат Садриев, Адәм әүлиясе.) When he turned around and looked, there was an elderly, strapping policeman. "Young man," he said, "it is not permitted to cross the road at this spot."

*Note 1:* The case endings used with possessive stems of the 3rd person singular may be joined to **туры** either directly (турына, турында, турыннан) or to its expanded possessive stem турысы (турысына, турысында, турысыннан). When joined directly, final -ы of **туры** functions like a possessive suffix.
*Note 2:* турыда, турында, турысында, etc. have the archaic forms тугрыда, тугрында, тугрысында, etc.

**[508] тәртип** 'order', 'discipline'.
**тәртибендә** 'as' (in the capacity of), 'by way of':

- **Сорау-җавап тәртибендә** без чибәр егетнең кем булуы һәм ничек итеп аның мондый авыр хәлгә төшүе тарихын бик тиз белеп алдык. (Мирсәй Әмир, Балыкчы ялганнары.) By way of question and answer, we learned very quickly who the handsome young man was and the history of how he got into such a difficult situation.

**[509] төп** 'bottom', 'base'.

1. **төбенә** 'under', 'at', 'to' (indicating direction):
   - Урман буена килеп җиткәч, чиләген **агач төбенә** куйды ... (Мөхәммәт Мәһдиев, Торналар төшкән җирдә.) When she reached the forest, she put her pail under a tree ...
   - Ул арада **капка төбенә** җиңел машина килеп туктады. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) At that moment, an automobile pulled up and stopped at the gate.
   - Искәндәр ... әле **тәрәзә төбенә**, әле ишек катына килде. (Разил Вәлиев, Иске сәгать дөрес йөри.) ... Iskändär moved now to the window, now to the door.
2. **төбендә** 'under', 'at', 'beside', 'at the base of', 'in' (position):
   - Юл буенда бер биек, зур **агач төбендә** утырган карчыкка очраган. (Татар халык экиятләре, Чакма ташы.) Along the way he met an old woman, who was sitting under a big, tall tree.
   - Урамда, **ишек төбендә**, машина көтеп тора иде. (Габдрахман Әпсәләмов, Агыла болыт.) In the street, a car was waiting before (at) the door.
   - Гәрәй белән Нәсимә иртәгесен әнә шул текә **кыяташ төбендә** очраштылар. (Сафа Сабиров, Гәрәйнең бер җәе.) In the morning Gärey and Näsimä met at (the base of) that (same) steep rock there.
   - Гөлбиби аны **баскыч төбендә** көтеп тора иде. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Gölbibi was awaiting him at the staircase.
   - **Телефон төбендә** бер ярты сәгатьләр чамасы азаплангач, ул аны тапты, хәлне аңлатып бирде. (Гариф Ахунов, Хәзинә.) After wearing himself out at the telephone for about half an hour, he reached (lit., found) him (and) explained the situation.
   - Чыннан да, бу көннәрдә Бибисаның **колак төбендә** таныш исем яңгырап торды ... (Саҗидә Сөләйманова, Гөлбадран.) Indeed, in these days a familiar name kept ringing in Bibisa's ears ...
3. **төбеннән** 'from under', 'from', 'past' (a place, point):
   - – Әйдә безгә, ди, чәй эчәрсең, ди ... Мин **алмагач төбеннән** көчкә кузгалам. (Ибраһим Гази, Малайлыкта кунакта.) "Come on, to us," she says. "Have tea," she says ... I move with difficulty from under the apple tree.
   - Утырышып кына бетүгә, **капка төбеннән** сәлам биргән тавыш ишетелде. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) They had just sat down when from the gate a voice was heard saying hello.
   - Ул арада кояш та чыгарга җыенды. **Капка төбеннән** дөбер-дөбер базарчылар уза башлады. (ibid.) Meanwhile, the sun too was about to rise (was preparing to rise). The market men were beginning to rumble past the gate.

**[510] төс** 'color'; 'air', 'appearance', 'aspect', 'look'.

1. **төсле** 'as', 'like', 'similar to' (in making comparisons):
   - Аның чалара башлаган озын чәче якасын каплап тора, бөтен битен **чәче төсле** үк соры сакал-мыек баскан, ... (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) His long hair, which has begun to turn grey, covers his collar. A beard and moustache, which are just as grey as his hair, cover his whole face, ...
   - Тәлгать /Təlɕət/ исемле иде ул, Кәшшаф җизнинең **үзе төсле** тыныч кына, сабыр гына бер малай иде. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) His name was Tälghät. He was a rather quiet, rather patient boy, like brother-in-law Käshshaf himself.
   - Иртыш безнең Иделгә дә, Чулманга да охшамаган иде. Аның суы **Иделнеке төсле** каралҗым да, **Чулманныкы төсле** кызгылт-комлы да түгел иде. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) The Irtysh resembled neither our Volga nor our Kama. Its water was not darkish like that of the Volga, nor was it reddish-sandy like that of the Kama.
   - – ... **синең төсле** сеңелем булса, мин нинди бәхетле булыр идем ... (Кәрим Тинчурин, Утыз өч көн.) "... if I had a (younger) sister like you, how happy I would be ..."
   - **Бу төсле** матур чәчәкләрне күргәнем юк иде. I had not seen such beautiful flowers.

   *Note:* Before **төсле**, the demonstrative pronouns may stand in the nominative.

2. **төсендә** 'as' (in the capacity of); 'by way of':
   - Кинаяле /kinajəle/ мәкальләр чынбарлыктан алынган берәр шигъри **мисал төсендә** читләтеп әйтеләләр. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) Allegorical proverbs are used (lit., said) metaphorically as some poetic example taken from reality.
   - Мәкальләрнең күпчелеген **киная, ишарә, читләтем төсендә** карап була. (ibid.) The majority of proverbs can be regarded as allegory, allusion, metaphor.
   - ... яшь балыкчыларга **киңәш төсендә** кайбер тәҗрибәләремне уртаклашасым килә. (Мирсәй Әмир, Балыкчы ялганнары.) ... I wish to share some of my experiences by way of advice to young fishermen.

**[511] угрында** (arch.) 'by way of', 'for':
   - Укымак – хәзерге көннәрне киләсе көннәр өчен, бу көнге мәсьәләләрне киләчәктәге мәсьәләләрне **чишү угрында** ташламак димәктер. (Габдулла Тукай, Хиссияте миллия, 1906.) To study means to give up the present days for future days, [to leave] today's matters (problems) for solving the matters (problems) of the future. (укымак – уку, ташламак – ташлау).
   - Хатыннар **ирке угрында** үләрмен мин. (Габдулла Тукай, Хатыннар хөррияте, 1909.) I shall die (i.e., I am ready to die) for the freedom of women.

**[512] урта** 'middle', 'center'.

1. **уртасына** 'to, into the middle, center of', 'into the midst of':
   - **Урам уртасына** чыгарып куелган кечкенә өстәл тирәсен бик күп халык сырып алган. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) A great many people are crowding the space around a small table, which has been pulled out into the middle of the street.
   - Бикбулат, мәртәбәле булырга тырышып кына, **мәҗлес уртасынарак** узды ... да вәкарь белән сүз башлады ... (Җәмит Рәхимов, Батырша.) Bikbulat, endeavoring to be authoritative, moved more to the center of the meeting and ... began to speak ceremoniously: ...

2. **уртасында** 'in the middle, center of', 'in the midst of':
   - **Урам уртасында** бер кое /qoјь/ бар. (Мирсәй Әмир, Әбелгата күпере.) In the middle of the street there is a well.

- Басуларда эш кыза барды ... **Җәй уртасында** бөгелгән билләр көзгә кадәр языла алмады. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) Work in the fields became more hectic ... The backs, which had (begun to) bend in the middle of summer, could not straighten out until autumn.
- Күрешү кичәбездә дә **игътибар уртасында** булачагымны сизенеп, кыенсынуларым юкка чыкты. (Диләрә Зөбәерова, Куш өянке шаһит.) Sensing that I will be in the center of attention also at our (school) reunion party, my timidity disappeared.

3. **уртасыннан** 'from, along the middle, center of':
   - Хәзер инде Амантай кемгә юлыгуларын төшенгән иде. Шуңа күрә, Балҗанны кулыннан җитәкләп, тизрәк шикле **төркем уртасыннан** чыгып котылырга омтылды. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) By now, Amantai had realized whom they had run into. Therefore, leading Baljan by her hand, he endeavored to get out from the midst of the suspicious crowd in a hurry and disappear (escape, get away).
   - **Үзән уртасыннан**, нәкъ электәгечә, көмеш кебек чишмә ага. (Әбрар Шәмин, Сагындырган сукмаклар.) Just as before, a spring like silver is flowing along the middle of the valley.
   - Ул **урам уртасыннан** алпан-тилпән килеп, туры Шәрифҗаннарга кайтты. (Аяз Гыйләҗев, Өч аршин җир.) Walking unsteadily along the middle of the street, he returned straight to the Shärifjans.

**[513] урын** 'place'.

1. **урынына**

a) 'instead of':
- Наил **җавап урынына** елмайгач, Фәез яне сорады ... (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) When Nail smiled instead of (giving) an answer, Fäyez asked again ...
- Тик ул вакытта залда мулла юк иде инде. **Аның урынына** зур ак сакаллы бер карт сүз алды. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) But at that time the mulla was no longer in the hall. In his place, an old man with a large, white beard began to speak.
- Түгәрәккә язылган егерме **кеше урынына** йөз кеше килгән. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Instead of the twenty people registered for the circle, a hundred people have come.

b) 'like' (similar to):
- Таҗи бер нәрсәне бик яхшы аңлап алды: бу йортта Вәсиләне **ат урынына** җиккәннәр. (Гариф Ахунов, Хуҗалар.) One thing Taji understood very well: In this house they have roped in (lit., they have harnessed) Wäsilä like a horse.
- ... илләр белән илләр, халыклар белән халыклар бәрелешкән. Кешеләр **чебен урынына** кырылган, ... (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) ... countries have clashed with countries, nations with nations. People have been crushed like flies, ...

c) 'as' (in the capacity of):
- Бу китап берәүдә дә юк. ... монда укып яткан мәрхүм Зәйнетдин шәкерттән **мирас урынына** калган китап бу. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) Nobody has this book, ... This is a book which has remained as a legacy from the deceased student Zeynetdin, who ... studied here.
- ... ул каганнар тамырының иң карт кешесе, бөтен ыруга **ата урынына** калган кеше. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) ... he is the oldest man of the khakan stock. He is a man who has remained as a father to the whole tribe.

2. **урынында** 'as' (in lieu of):
   - ... карт ... егетне күрде. Күрде, ләкин күрмәмешкә салышты. Егетнең бернинди сүз дә кушмыйча тыныч кына карап торуына **җавап урынында** карт, аңа караганда

да тынычрак итеп, бер карап алды да шунда ук күзләрен башка ноктага күчерде. (Фатих Хөсни, Идел тынычсызлана.) ... the old man saw the youth, ... He saw him, but pretended not to see him. As an answer to the youth's gazing at him silently without saying a single word, the old man, even more silently than he, took one look at him and immediately turned his eyes to another point.

(For **урында**, **урынга** with the future participle in **-асы**, **-әсе** etc. see 1150.)

**[514] уңай** 'direction'; 'favorable', 'suitable'.

1. **уңаена**

a) 'with' (indicating direction):

- ... коры яфраклар, сары күбәләкләрдәй, һавада уйнаклап алдылар да, **җил уңаена** очып, Бәдәр себергән якка төшә башладылар. (Мөхәммәт Шәйми, Сынау.) ... dry leaves fluttered up in the air like yellow butterflies and, flying with the wind, began to fall where Bädär was sweeping.
- Башка чара калмагач, мин батмас өчен **агым уңаена** акрын гына йөзә бирдем. (Сафа Сабиров, Фирдәвес.) As there was no other alternative, I kept swimming slowly with the stream so as not to drown.

b) 'in time to', 'while' (indicating simultaneous actions):

- Ул, мөгаен /møɢəjen/ ... каенга сөялеп, айга карап җырлыйдыр. **Көе** /køje/ **уңаена** акрын гына башын боргалыйдыр. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) He probably is singing, leaning against a birch ... and looking at the moon. He probably is moving his head slowly in time to his song. (Expresses supposition.)

2. **уңае**, **уңаенда**, **уңаеннан** 'while' (with certain nouns, indicating simultaneous actions carried out by the same agent or by different agents):

- Район үзәгеннән ул **юл уңае** туры килгән, шылтырап таралыр хәлгә җитеп тузган машинага утырып кайтты. (Әхияр Хәкимов, Гомер /Ɋømer/.) He returned from the district center, sitting in a rattling, battered car which had reached the stage of falling apart, and which he happened to encounter while on the road.
- Ниһаять, менә Агыйдел дә, **юл уңаенда** үзенә килеп сыенган бик күп инешләрне эченә ала-ала ... Камага килеп җитте. Кушылды. Хәзер инде безнең алда Кама гына калды. (Мирсәй Әмир, Усә төшкәч.) Accepting on its way a great many streams which came running into it, the Byelaya too ... finally reached the Kama and joined up with it. Now only the Kama remained before us.
- Фидаяның башын кая куярга белмәгән чаклары була. Ялгыз калганда, кичләрен-төннәрен күңелгә бигрәк авыр уйлар килә. Шундый сәгатьләрнең берсе аны **юл уңаенда** чишмә буена китерде. (Мәдинә Маликова, Фидая.) There were times when Fidaya became very despondent (lit., did not know where to put her head). Especially in the evenings and at night when she was alone, gloomy thoughts came to her mind. One such time (lit., one of such hours) brought her to the spring while she was on her way (i.e., on her way to another village).
- **Юл уңаеннан** «Үзәк»кә кагылып чыгарга уйладылар. (ibid.) While on their way, they intended to (briefly) stop at the "Center". («Узәк» – "Center"; name of a collective farm.)

3. **уңаенда** following a noun denoting *time*, indicates approximateness.

- **Кич уңаенда** гына Мәрьям «Чишмә» ашханәсенә барып керде. (Мәдинә Маликова, Казан каласы – таш кала.) Towards (in the) evening Märyäm went to the "Chishmä" (Spring) restaurant.

4. **уңае белән**

a) 'while' (same as **унае**, **уңаеда**, **уңаеннан**):

- Ул ... төенчек эчендәге әйберне балаларның икесенә бүлеп бирергә уйлаган иде. Ләкин шул **уй уңае белән** төенчекне тагын бер тапкыр тотып карагач, ул уеннан ваз кичте. (Шәриф Камал, Матур туганда.) ... he had thought to divide and give the things in the little parcel to both the children. But, when with that thought (in mind), he took the little parcel once again in his hands and looked at it, he gave up that idea.
- Рузаевка станциясендә минем Байбиков дигән танышларым бар иде. **Юл уңае белән** шунда туктап, берәр көн кунак булырга уйладым. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) At the Ruzayevka station I had acquaintances called Baibikov. I thought that, while on the way, I would stop there and stay a day as (their) guest.

b) ‘in connection with’, ‘on the occasion of’:

- Шуларны уку минем күңелемдә читкә китү фикерен тудырган иде. Иптәшләрнең **соравы уңае белән**, минем шул теләгем күз алдына килеп басты ... (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) Reading those things had given rise to the thought in me (lit., in my heart) to go to foreign parts. In connection with (my) comrades’ question, that wish of mine appeared before my mind’s eye ...
- ... «Вакыт» газетасының чыга башлавына өч ел **тулу уңае белән**, кечкенә генә бер җыелыш үткәрелде. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) ... a small meeting was held on the occasion of the completion of three years since the newspaper “Waqyt” had begun to appear.

*Note:* сүз уңаенда, сүз уңаеннан means ‘by the way’.

**[515] хак** ‘right’, ‘benefit’.

1. **хакында**, **хакта** ‘about’ (concerning):

*Note:* The form **хакта** is used with demonstrative pronouns in the nominative (бу, ул, шул, etc.) and with personal pronouns (except that of the 3rd person singular and plural) in the possessive case. However, with the latter **хакта** may also take the possessive suffixes. For example: синең хакта, or синең хакыңда ‘about you’.
The latter applies also to **хак** in the dative: минем хакка, or минем хакыма ‘for my sake’.

- Авылдагы **хәлләр хакында** бераз сөйләшкәч, басуларга чыгып киттек. (Әхсән Баянов, Аязучан болытлы һава.) After we had talked a little about conditions in the village, we went out to the fields.
- **Ул хакта** мин соңыннанрак сөйләрмен, ... (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) About that I shall speak a little later, ...
- Наилә. Сөйләшмик бу хакта, син борчыласың. (Аяз Гыйләҗев, Без уникe кыз идек.) Nailä. Let’s not talk about this; you are upset (worried).
- – ... Гөлчирә миңа андагы кешеләрнең барысы турында да сөйләгән иде, никтер **сезнең хакта** гына берни дә әйтмәде. (Сафа Сабиров, Фирдәвес.) “... Gölchirä had told me about all the people who were there. Only about you she did for some reason not say anything.”
- Егетләр **аның хакында** нидер әйтмәкчеләр иде бугай – үзен шәйләгәч, тындылар. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) Apparently, the young men intended to say something about him, (but) when they noticed him, they fell silent.

2. **хакына**, **хакка** ‘for the sake of’, ‘thanks to’, ‘for’ (for the benefit of):

- – Нишлим мин, киңәш бирегез, **алла хакына.** (Атилла Расих, Ямашев.) “What am I to do; for God’s sake, give me advice.”
- – Тынычлан, кызым, тынычлан! – диде ана. – Язмыштан узмыш юк. **Әтиең хакына**... **минем хакка**... (Әбрар Шәмин, Янар тауны кичкәндә.) “Calm down,

my daughter, calm down!" the mother said. "There is no escape from fate. For your father's sake..., for my sake..."

- **Мәхәббәте хакына** ул (ягъни Галиябану) үзендә кыюлык таба, ... атасына каршы төшә. (Барлас Камалов, Мирхәйдәр Фәйзи, Галиябану.) Thanks to her love, she (i.e., Ghaliäbanu) finds the courage in herself; she ... stands up to her father. (Her father wants her to marry a man she does not love).
- – Искә алмаган көннәре юк, **синең хакка** дога кылалар. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) "There is no day when they do not remember you. They pray for you."
- ... Тукай саулыгына, татар мәдәнияте һәм әдәбиятының алга **китүе хакына** тостлар күтәрелгәннән соң, мәҗлес тынычрак рәвеш алды. (И. Нуруллин, Көзге җилләр исәр алдыннан.) After toasts had been proposed to ... Tuqai's health, for the advancement of Tatar culture and literature, the party took on a quieter character.

**[516] хосус** 'matter', 'case', 'subject'.
**хосусында**, **хосуста** (arch.) 'regarding', 'in respect of', 'in relation to', 'about':

- Сабирның остазы Габдулла хәзрәт тәкъва вә риясыз бер имам иде ... Узенең шәкерде мулла **Сабир хосусында** дәхи ул кадәр разый түгел иде. (Галиәсгар Камал, Сабир хәзрәт, 1900.) Sabir's mentor, His Excellency (His Holiness) Ghabdulla, was a pious and sincere imam ... He was also not particularly (lit., that much) pleased with regard to his (former) student, Mulla Sabir.
  (шәкерд, now spelled шәкерт, дәхи (arch.) 'also', 'still', 'again'; разый – риза 'pleased', 'agreeable').
- **Бу хосуста** һичкемгә мөшәвәрә вә киңәш итмәк лязем түгел. (ibid.) About this it is not necessary to deliberate and consult with anybody.
  (мөшәвәрә (arch.) 'consultation', 'deliberation', лязем, лазим (arch.) кирәк 'necessary'; итмәк – итү).

**[517] хәл** 'state', 'condition', 'situation', 'circumstance'.
**хәлендә** 'as', 'like' (in the capacity, role of):

- Бу эштә Хәмитов үзен нәкъ чит кешеләрчә тотты. **Күзәтүче хәлендә.** (Әхсән Баянов, Таш китап.) In this matter Khämitov conducted himself exactly like a stranger – as an observer.
- Бары тик ... унтугыз яшьлек бер **егет хәлендә** бәхет эзләргә чыгып киткәч кенә беренче мәртәбә поездга утыра алдым. (Сәйфи Кудаш, Яшьлек эзләре буйлап.) I got (had an opportunity) to board a train for the first time only when ... as a nineteen-year-old youth, I went out to seek my fortune.

**[518] чак** 'time'.
**чак**, with or without possessive suffixes in the locative, 'while', 'during'; 'when', 'as':

- Хәниф абый кесәсеннән авыз гармунын кулына алды ... – Әтием бүләк иткән иде, – диде. – Бик күптән. Әле синең кебек **малай чагымда**. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) Uncle Khänif took a mouthorgan from his pocket ... "My dad gave it to me as a present," he said. "Very long ago. When I was still a boy like you."
- Маһирә ханым чак кына кызарып куйды. **Кыз чагында** Янгура аңа игътибар итеп йөргән кешеләрнең берсе иде. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Lady Mahirä nearly blushed. Yangghura was one of the persons who had noticed her when she was a girl (i.e., unmarried).
- Ул, үсмер **егет чагында** шушы йортка кунак булып килгән вакытта, Мәдинәгә гашыйк /ʁaşiq/ булган иде. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) He had fallen in love with Mädinä when, as a teenager, he had come to this house as a guest.

· – ... минем әнкәем мин кечкенә **бала чакта** матур әкиятләр сөйлидер иде. (ibid.) "... when I was a little child, my mommy told me (lit., was telling me) beautiful stories."

*Note:* For **-дыр**, **-дер** etc. see 693, d. In the above example, **-дер** indicates emphasis. The speaker wants the woman to whom she is talking to tell, not to read, to her a story.

· **Малай чакта** куна йөргән аланнарга ... барып чыгам. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) I am going out to the glades where, as a boy, I often spent the night ...

**[519] чама** 'approximate measure, dimension'.
**чамасы**, **чама(сын)да** 'about', 'approximately' (indicating approximate quantity, distance, length, height, size, weight, depth, time, age, etc.):

· 150 ел /jьl/ элек бу урында 150 **кеше чамасы** җирле халык яши торган кечкенә генә балыкчылар авылы булган. (Рафаэль Мостафин, «Оҗмах»ка сәяхәт.) One hundred and fifty years ago, there was in this place a rather small fishing village in which about one hundred and fifty local people lived.

· Алар икәү иде. Менә алар аннан бер ун **адым чамасы** җирдә туктап калдылар. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) They were two. There, they stopped at a spot some ten paces from him.

· – Миндә **бер мең чамасы** бар, – диде ул ... – Мин сиңа биреп торырмын. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) "I have about a thousand (rubles)," he said. "I am prepared to give them to you."

· Ул әле бүген төш вакытында гына су алырга барган коены исенә төшерде. Ул коеның тирәнлеге, күп булса, ике-өч **метр чамасы** булырга тиеш иде. (ibid.) She recalled the well to which she had gone to fetch water only this noon. The depth of that well must have been approximately two or three meters at the most.

· Көрәш бер-ике **минут чамасы** гына дәвам итте. Мансур Илгизне дә күтәреп бәрде. (ibid.) The (wrestling) match lasted only about one or two minutes. Mansur lifted and threw Ilgiz too.

· Әйтүләренә караганда, беренче басуның озынлыгы сигез **чакрым чамасы** булырга тиеш иде. (ibid.) According to what they say, the length of the first field must have been about eight versts.

· Беренче караштa Галләметдин Әхмәткә кырык биш **яшьләр чамасында** урта яшьле кеше булып күренгән иде. (Шәриф Камал, Матур туганда.) At first glance, Ghällämetdin had appeared to Äkhmät to be a middle-aged man of about forty-five.

**[520] шикелле** (шәкел 'form', 'figure') 'like', 'as', 'similar to':

· **Уенчык шикелле** җыйнак өйләр тау итәгенә сыенып утырганнар. (Рөстәм Кутуй, Сөенче.) The cheerful houses were nestled like toys at the foot of the mountain.

· Мин кемнән ким? Мин дә **аның шикелле**, ул да минем кебек. (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) To whom am I inferior? I am like him, he (too) is like me.

· ... Киек каз юлы ялтыравык **бәс шикелле**, эчтән яктырып торган тузан бөртекләредей йолдызлар белән җемелди. (Рафаэль Мостафин, «Оҗмах»ка сәяхәт.) ... the Milky Way shimmers with stars like glittering hoar-frost, like specks of dust shining from within.

· Сөенеченнән аңа бөтен дөнья **үзе шикелле** бәхетледер сыман тоела ... (Рәмзи Максудов, Шәйморза кешеләре.) In her joy, it seems to her as though the whole world is as happy as she ...

(For **сыман** with relational adjectives and conjugated verbal forms see 575).

**[521] эч** ‘interior’, ‘internal part’.

1. **эченә** ‘into’:
   - Гаяз мине **бакча эченә** алып кереп ... өстәл янындагы скәмьягә (эскәмиәгә) утыртты. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Ghayaz took me into the garden and had me sit on a bench beside the ... table.
   - Егет, аларның бу сүзләрен ишетүе белән, атына менде дә ... киң даланың **караңгылыгы эченә** кереп югалды. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) Upon hearing these words (of theirs), the young man mounted his horse and ... disappeared into the darkness of the wide steppe.
   - Урманда **үз эченә** бикләнеп, гел бертөрле генә яшәргә гадәтләнгән бу күңелсез, сүрән **гаилә эченә** Йомабай үзе белән җанлылык, ягымлылык алып керде. (Гомәр Бәширов, Кунак егет.) Yomabai brought with him liveliness (and) kindness into this cheerless, listless family, which, retired into itself in the forest, had become used to living a monotonous life (lit., living always the same way).

2. **эчендә**

a) ‘in’, ‘inside’, ‘within’ (position where):
   - Ул ... чанага ничек чыгып утырганын да хәтерләмәде. Тирә-як **томан эчендә** күк тоелды аңа. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) She did not remember either how she got into the sleigh ... The surroundings appeared to her as though in a haze.
   - Тирән **тынлык эчендә** берничә секунд вакыт үтте. (Габдрахман Әпсәләмов, Зәңгәр иртә.) Several seconds passed in the deep stillness (of the forest).
   - [Ай] ... акрын гына киң **күк эчендә** йөзеп китә. (Галимҗан Ибраһимов, Диңгездә.) [The moon] ... is floating slowly in the wide sky.
   - Алар киенеп урамга чыктылар. Көне буе диярлек **бина эчендә** булганга, һава сулап туймаслык татлы тоела. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) They dressed and went out into the street. As they had been inside the building almost all day, breathing (fresh) air felt (lit., seems) infinitely good (lit., sweet).
   - Яктырганда Босфорга килеп җиттек ... Эчкә керә башлагач, чайкалу сүнде. **Бугаз эчендә** безне тынлык кочаклап алды. (Миргазиян Юныс, Юлда уйланулар.) When it was getting light, we reached the Bosphorus ... As we were getting into it, the rocking (of the ship) ceased. Inside the strait a stillness embraced us.
   - Безгә бу нәмәкәйне почта белән салганнар. Хәзер **шәһәр эчендә** дә хатлар ташбака тизлеге белән йөри. Ким дигәндә, өч көн үтә. (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем элмәге.) This was sent to us by mail. At present, letters go with the speed of a turtle even within the city. They take at least three days.
   (нәмәкәй – dialect of the Mishar Tatars – нәрсә).

b) ‘among’ (a group, people, etc.):
   - Бү җирдә торып **калганнарының эчендә** ... Шәриф дигән кеше дә бар иде. (Мәҗит Гафури, Ярлылар.) Among those (men) who remained standing in this place was also a man named Shärif ...
   - Бу **яшьләр эчендә** ирләр һәм хатын-кызлар бергә һәм бер булып эшлиләр. (Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр, Шәһит Әхмәдиев.) Among these young people men and women are working together as one (body).

c) ‘within’, ‘in’ (indicating time):
   - Монда мәктәпләр, китапханәләр ... кинотеатрлар күп, урамнар иркен ... Шуларның барысы егерме биш-утыз **ел эчендә** салынды. (Г. Ахунов, М. Зарипов, И кадерле туган як.) Here are many schools, libraries ... cinemas, the streets are wide ... All of these were built within twenty-five, thirty years.

- Йөз километрга якын араны барлы-юклы сәгать **ярым эчендә** узып, Талбазыга килеп тә җиттек. (Мирсәй Әмир, Күңелле сәяхәт.) We arrived in Talbazy, covering the distance of approximately one hundred kilometers in a mere hour and a half.

3. **эченнән**

a) 'from within', 'from among', 'out of':

- ... конвертны кулыма алдым. **Аның эченнән** дүрт хат килеп чыкты. (Газиз Мөхәммәтшин, Табылдык хатлар.) ... I took the envelope in my hand. From (within) it four letters came out.
- ... хатын, бер генә сүз дә дәшмичә ... мич алдына барды. **Учак эченнән** таш табак белән аш чыгарып, ян тәрәзә төбендә торган өстәл өстенә китереп куйды. (Мирсәй Әмир, Безнең авыл кешесе.) ... without saying a word, the woman ... went to the stove. From (within) the fireplace she took out food in a stoneware dish and put it on the table, which was standing at the side window.
- Ике кат сары төрем кәгазен сүтеп ташлаганнан соң, **кәгазьләр эченнән** фиолет төсендә ефәк баш яулыгы һәм **яулык эченнән** хат чыкты. (Шәриф Камал, Матур туганда.) After the two layers of yellow wrapping paper were undone, a violet silk headscarf came out of the paper, and from within the scarf came a letter.
(фиолет – шәмәхә).
- Әкрен генә күбәләк-күбәләк кар ява ... Шул **кар эченнән** Диләфрүз килеп чыкты. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Snow is slowly falling in dense flakes ... Out of that snow Diläfrüz emerged.
- Бик ерактан, **томан эченнән** Гөлшаһидә шәүләсе калка. (ibid.) Very far away, Gölshahidä's shadow rises out of the mist.

b) 'in' (indicating movement in, inside):

- Трамвайдан төшүчеләр ..., туфлиләрен кулларына тотып, туп-туры су эченә сикерәләр иде. Кыям белән бу кыз да, туфлиләрен салып, **су эченнән** ... ялан аяк киттеләр. (Ибраһим Гази, Гаепсез гаеплеләр.) Taking ..., their shoes in their hands, the people descending from the streetcar jumped right into the water. Qiam and this girl took off their shoes too and walked barefoot in the water, ...
- Анда яшел таллы **чокыр эченнән** матур булып елга ага. (Мирсәй Әмир, Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре.) There, in the ravine covered with green willows, a river flows beautifully.
- Җил дулый, күзләргә ком тула. Сәхип **ком эченнән** бата-чума һаман алга бара. (Шәриф Камал, Таң атканда.) The wind is raging, the eyes fill with sand. Sinking in the sand, Säkhip keeps moving on.

c) 'to', 'by' (myself, yourself, etc.):

- Алдама, мин әйтәм **эчемнән** генә. (Мирсәй Әмир, Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре.) "Don't deceive me," I say to myself.
- «Шунысы гына җитмәгән!» – дип Хөснулла **эченнән** уйлап куйды. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) "That's all I need!" Khösnulla thought to himself.

**[522] юл** 'way', 'road'.

**юлында**, **юлы белән** 'in the way of', 'by', 'through', 'by way of':

- Ул әнисе пешергән ипиләрнең тәмлелеген күрсәтер өчен, капчыгыннан бер ипине чыгарып, шәкертләргә авыз иттерә-иттерә анасының абруен **саклау юлында** бер бөтен ипинең беткәнен сизми дә калды. (Кәрим Тинчурин, Икенче мәрҗән.) In order to demonstrate the tastiness of the breads his mom had baked, he pulled a bread from his bag, and having the students taste it, he didn't even notice that through protecting his mother's reputation a whole bread was finished off.

- Шушы елларда басылган күп санлы мәкаләләрдә аның татар сәнгатен /sənɋəten/ **үстерү юлында** күрсәткән тырышлыгы ачык чагылган. (Бәян Гыйззәт, Фәтхи Бурнаш.) The zeal which he displayed in the way of developing Tatar art is clearly reflected in numerous articles printed in these (same) years.
- ... ул башка шәкертләр шикелле, мәчеткә барып коръән уку ... сәдака **алу юлы белән** түгел, бәлки үз кул көче белән эшләп яшәргә тырыша. (Татар Әдәбияты, Габдулла Тукай.) ... he (i.e., Tuqai) did (lit., does) not endeavor to make a living (lit., live) by going to the mosque and reading the Koran ... receiving alms like other students, but by working with his own hands.
- Әгәр 1905 нче елга чаклы шагыйрь тормышны, башлыча, **мәгърифәтчелек юлы белән** үзгәртергә мөмкин дип караган булса, ... (Мәҗит Гафури, Сайланма әсәрләр, Introduction.) If until 1905, the poet had the opinion that living conditions (lit., life) could be changed mainly through enlightenment, ...

**[523] як** ‘side’.

1. **ягына** ‘to’, ‘towards’ (in direction of):
   - Бүген алар Әптелбәр белән **Бакалтай ягына** ... бардылар. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) Today they went with Äptelbär to Lake Baqaltai ...
   - – Әнә алар! – Грязинюк кичке эңгергә урала башлаган алма **бакчасы ягына** кул изәде. (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем элмәге.) “There they are!” Gryazinyuk motioned with his hand towards the orchard, which was becoming enveloped in dusk.
   - Фидаяров күз кырыйлары белән генә **ир-егетләр ягына** карап алды. (Газиз Үзиле, Гыйфрит.) From the corner of his eye Fidayarov cast a glance towards the men.

2. **ягында**

a) ‘at’, ‘beside’ (position where):
   - Сеңлем Сажидә өйдә юк, **Арча ягында** тракторда эшли иде. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) My younger sister Sajidä was not at home. She was working at Arsk on a tractor.
   - ... тәрәзәсез **дивар ягында** шәһәр йортларында була торган зур шифоньер, әйбәт урындыклар ... бу йортта шактый ук мул тормышлы кешеләр яшәгәнне әйтеп тора иде. (Гариф Ахунов, Хуҗалар.) ... the large chiffonier at the windowless wall, which is usually (found) in the city homes, the fine chairs ... showed (lit., spoke) that there lived in this house rather well-to-do people.

b) ‘for’ (in favor of, in support of):
   - – Юк, Зариф Салихович, мин сез әйткән тәкъдимне кабул итә алмыйм. Мөмкин түгел. Мин яхшы башлангычны бууга юл **куйдырмау ягында**! (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) “No, Zarif Salikhovich, I cannot accept the suggestion which you have proposed. It is not possible. I am not for permitting a good beginning to be stifled.” (lit., for permitting to stifle a good beginning.)

3. **ягыннан**

a) ‘from’ (from the direction of):
   - Юлда ул **басу ягыннан** кайтып килүче яшьләрне очратты. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) On the road he met the youths who were returning from the field.
   - **Бакча ягыннан** алма исе аңкый. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) The fragrance of apples emanates from the garden.
   - ... үзем генә калгач, көтмәгәндә кайдандыр Хәйрүш килеп чыкты. Әлеге **Нөгеш ягыннан** безгә кармак чыбыклары алып кайта торган иптәшем. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) ... after I was left alone, Kheyrüsh, that same friend of mine

who used to bring us fishingrods from Nögesh, appeared unexpectedly from somewhere.

b) ‘in’, ‘by’ (indicating age, origin, background, etc.):

- Туйга без **эти-әни ягыннан** булган туганнарны, тирә-күршене чакырдык. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) To the wedding we invited the relatives on Dad’s and Mommy’s side as well as the neighbors.
- Иң күп таралган һәм фән өчен иң әһәмиятле төркемләү – телләрне **туганлыгы ягыннан**, ягъни килеп чыгышлары буенча төркемләү. (М.З. Зәкиев, Татар халкы теленең барлыкка килүе.) The most common, and for linguistics (lit., science) the most important classification, is the classification of languages by relationship; that means, according to their origin.

c) ‘as to’, ‘from the point of view of’, ‘from the standpoint of’:

- **Яшь ягыннан** ул Фәездән ундүрт яшькә зур ... (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) As regards age, he was fourteen years older than Fäyez ...
- ... **ашау-эчү ягыннан** мәҗлес матур бара. (Әбрар Шәмин, Эт белән мәче.) ... as to food, the party is going beautifully.
- ... мәкальләрне **мәгънә ягыннан** ике төркемгә бүлеп була. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) ... from the point of view of meaning, it is possible to divide proverbs into two groups.
- Дөресен генә әйткәндә, җырга-музыкага **сәләтлелегем ягыннан** мактаныр җирем юк. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) To tell the truth, regarding (as to) my talent for song (singing) and music, I have nothing to be proud of.

**[524] ян** ‘side’.

1. **янына** ‘to’, ‘up to’, ‘at’ (in the direction of, towards a person, thing, or place):

- Машина ике-өч минуттан **яшьләр янына** килеп тә туктады. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Two or three minutes later (lit., in, after two or three minutes), the car came up to the youths and stopped.
- Шәрифҗан ... яңадан **телефон янына** килеп, аның тоткасын бора башлады. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) Shärifjan ... went (lit., came) again to the telephone and began to turn its crank-handle.
- Шул ук **сабырлык янына** татарның тыйнаклыгын да кушарга кирәк. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) To that (same) patience must also be added the Tatar’s unpretentiousness.
- Урыныннан күзгалды да **минем яныма** килде. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) She (i.e., my mom) got up from her seat and came over to me.
- Мохтар ... китапны алып, **өстәл янына** утырды. (Шәриф Камал, Таң атканда.) Mokhtar took the book ... and sat down at the table.
- – Сәгать кичке җиделәргә **минем янга** керерсең. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) “You shall come to me by about seven o’clock at night.”

2. **янында**.

a) ‘at’, ‘beside’ (position where):

- Кичке сигез туларга биш минут калганда, Фәез Лазаревлар **ишеге янында** иде инде. (ibid.) At five minutes to eight in the evening Fäyez was already at the Lazarevs’ door.
- ... Гыйльмулла кереп, аш хәзер булганлыкны әйтте. Болар бүлмәдән чыкканда, Корбангали карт **өстәл янында** көтеп утыра иде инде. (Шәриф Камал, Таң атканда.) ... Ghilmulla entered and said that the meal was ready. When they came out of the room, the old man Qorbanghäli was already sitting at the table waiting.

- Һәркемдә булган кебек, безнең ындырыбыз бар иде. **Өй янында** кечкенә бәрәңге бакчабыз. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) We had our Kitchengarden, just as everybody else did. Beside the house was (lit., is) our little potato garden.
- – Син йокламыйсыңмы? – ди бер тавыш. Башымны күтәрсәм, **янымда** Миргали басып тора. (Локман Бадыйкшан, Ерак диңгездә.) "You aren't sleeping?" a voice said. When I raised my head, there was Mirghäli standing beside me (at my side). (For the use of the Tatar present tense instead of the past see 956, 5.)

b) 'at', 'with' (at house of, in company of):

- – **Атаң янында** башка кеше торыр, син көтүгә бар, диделәр. (Галимҗан Ибраһимов, Көтүчеләр.) "Someone else will stay with your father, you go to the (cattle) herd," they said.
- Иртәгесен билгеләнгән вакытта Галимҗан **Ибраһимов янында** идем инде. **Янында** кунагы булуына карамастан, мине ачык йөз белән каршы алды. (Истәлекләр, Бакый Урманчы.) Next morning, at the scheduled time, I was at Ghalimjan Ibrahim's (place). Despite his having a guest (visitor) with him, he received me in a friendly manner (lit., with an open face).

c) 'on, with' (on person):

- Яшь егет. Садрый абзый, миңа иртәгә кадәр ун тәңкә акча биреп торыгыз әле, мин сезгә иртәгә иртә үк кертеп бирермин. Садрый. **Минем янымда** ул кадәр үк акча юк. (Галиәсгар Камал, Безнең шәһәрнең серләре.) The young man. Uncle Sadri, lend (lit., give) me ten rubles until tomorrow, please, I'll give it back (lit., bring and give it) to you tomorrow morning right away. Sadri. I don't have that much money with me.

d) 'at', 'during' (meal, etc.):

- Сәгыйтҗан белән Миһри **чәй янында** шактый озак сөйләшеп, киңәшеп утырдылар. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) Säghitjan and Mihri sat at tea, talking and discussing for a rather long time.
- **Аш янында** сүз Казан хәлләре, андагы хөкүмәт мәктәпләрендә укучы татар яшьләре, матбугат ... һәм шуларга охшашлы башка мәсьәләләр турында барды. (Истәлекләр, Каюм Мостакаев.) During the meal, the conversation was about events in Kazan, about the Tatar youths studying at government schools there, the press ... and other matters similar to those.

3. **яныннан** 'from', 'by', 'past' (the side of a person, thing, or place):
   - Тәрҗимә ат җигеп кайткач, Тимершәех ... **өстәл яныннан** торды. (Хәсән Сарьян, Бер ананың улы.) After Tärjimä had harnassed the horse and returned, Timershäyekh ... got up from the table.
   - **Корбанов яныннан** мин тәмам тынычланып чыктым. (Гадел Кутуй, Тапшырылмаган хатлар.) I came away (lit., out) from Qorbanov completely calmed down.
   - Бер ярты сәгатьтән еракта Көктугай күренде. ... яшьләр шифер түбәле яңа **йортлар яныннан**, төзүчеләрнең яшел **чатырлары яныннан** ... выжлап узып киттеләр дә иске Көктугайга килеп керделәр. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) After about half an hour, Köktughai appeared in the distance. ... the youths zipped past the new slate roof houses and the green tents of the construction workers ... and entered old Köktughai.

**[525] ярдәм** 'help', 'assistance'.
**ярдәмендә** 'by means of', 'by', 'through', 'with the help of':

- Тартым төшенчәсен тартым **кушымчасы ярдәмендә** белдереп була. (С.М., но. 7, 1976.) Possession (lit., the concept of possession) can be rendered by means of possessive suffixes.

- Дәреснең темасы – «Үсемлекләрнең **бөҗәкләр ярдәмендә** читтән серкәләнүе.» (ibid.) The subject of the lesson is “Cross-pollination of Plants by (through) Insects”.
- ... аның беренче хикәяләре «М. Гали» имзасы белән «Аң» журналында басыла башлыйлар. Язучының әйтүенә караганда, алар «Хөсәения» мәдрәсәсенең әдәбият укытучысы Нәҗиб Гасрый тәэсире белән язылалар һәм шул **укытучы ярдәмендә** басылалар. (Гази Кашшаф, Мөхәммәт Гали.) ... his first stories with the signature “M. Ghäli” began to be published (printed) in the journal “Awareness”. According to the writer (lit., According to what the writer says), they were written under (lit., with) the influence of Näjib Ghasri, the teacher of literature at the “Khösäyeniye” medrese, and they were published with the help of that (same) teacher.

**[526] өс(т)** ‘top’, ‘upper part’, ‘surface’.

*Note:* Case endings, derivational suffixes with an initial *consonant*, and the plural suffix **+лар** are joined to the short form: өскә ‘up’, ‘upward’; өстә ‘above’; өстән ‘from above’, ‘from the top’; өскә алу ‘to take upon oneself’; өскә чыгу ‘to win a victory’; өске кат ‘the top floor’; өсләр ‘the upper parts’; ‘tops’, ‘surfaces’.

1. **өстенә**

a) ‘on’, ‘upon’, ‘over’ (indicating movement to):
- **Шәһәр өстенә** кара, куе болыт ябырылып килә. Тиздән яңгыр явасы. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) Dark, dense clouds are gathering over the city. Soon it will rain.
- Вакыт соң. **Идел өстенә** төн салкыны төшеп килә. (ibid.) It is late. The cold of the night is settling upon the Volga.
- Минем инде сөйләшергә хәлем юк иде ... Калтырандым. Хәниф абый мине тапчанга яткырды, **өстемә** юрган япты. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) I was no longer able to speak ... I shivered. Uncle Khänif laid me down on the tapchan and put a blanket over me. (тапчан – piece of furniture used both as a chair and a bed).
- Ул **кәгазь өстенә** иелеп, ... яза башлый, ... (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) Bending over the paper, ... he begins to write, ...

b) ‘on’, ‘upon’ (indicating a person or collective assuming, or being charged with, a task, responsibility):
- Өйдә инәсеннән кала иң өлкәне ул – Габделхәй. Бөтен җаваплылык **аның өстенә** төшә. Дөресрәге, инәсенең ул беренче ярдәмчесе, уң кулы. (Нурихан Фәттах, Кичү.) Next to his mother, he, Ghäbdelkhey, is the oldest in the house. All responsibility falls upon him. More precisely, he is his mother’s first assistant, her right hand.
- Без нишли алабыз – булган хәлне сөйләп бирүдән башка чара калмады. Төп гаепне мин **үз өстемә** алдым. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) What could we do? We had no other choice but to tell what had happened. I took the main blame upon myself.
- Көн-көннән авырая бара, ләкин әллә ни эшләр хәл юк, син яллангансың, **өстеңә** алган эшне башкарырга тиешлесең. (Галимҗан Ибраһимов, Көтүчеләр.) From day to day it becomes more difficult. But there isn’t anything you can do. You have hired yourself out and you are obliged to carry out the work which you have taken upon yourself.

c) ‘in addition to’:
- Күзәтү манарасы, чыннан да, ныклы, тотрыклы, **шуның өстенә** матур һәм күренекле дә иде. (Флүс Латыйфи, Хыянәт.) The observation tower was indeed firm, sturdy, and, what is more, it was beautiful and splendid as well.
- Гәүһәршад бикә Сөембикәгә янә сокланып бакты: бу дала кызы, **гүзәллек өстенә**, зиһен иясе дә икән, кара. (Батулла, Сөембикә кыйссасы.) Lady Gäwhärshad looked again with delight at Söyembikä. Just think (lit., look)! In addition to being beautiful,

this girl from the steppe turned out to have a mind as well. (Expresses admiration and surprise.)

- Үз туган телләрен **белү өстенә** алар гарәп һәм фарсы телләрен дә бик яхшы белгәннәр. In addition to their native language, they also knew Arabic and Persian very well.

2. **өстендә**

a) 'on', 'upon', 'over', 'above' (position where):

- Стәрлетамак-Уфа **юлы өстендә** С. дигән бер авыл бар. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч.) On the road from Sterlitamak to Ufa there is a village called S.
- **Һәркемнең өстендә** эш киеме иде, ... (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Everybody had working clothes on, ... (lit., On everybody were working clothes).
- **Су өстендә** акчарлаклар оча. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Seagulls are flying over the water.
- **Камышлар өстендә** ак томан йөзә. (ibid.) A white fog floats over the reeds.
- Без хәзер **шәһәр өстендә**. Иң югарыда. Иң биек йортларның да бирәдән түбәләре генә күренә. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) We are now above the city – at the highest point. From here one can see only the roofs of even the highest buildings.

b) 'on', 'at' (engaged upon):

- Рианның хәзергә матбугатта чыккан әйбәрләре юк. Ул көн-төн ... исемле шигъри роман өстендә утыра. (Гурий Тавлин, Афәт.) So far, Rian has nothing (i.e., no piece of writing) which has appeared in print. He works day and night at (lit., he sits day and night over) a novel in verse entitled ...
- ... моңа кадәр һәр елны ул ... Беренче май бәйрәмен ... кырда-басуда – **эш өстендә** каршылады. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) ... every year until now (lit., until this) ... he had observed (lit., received) the First of May holiday in the fields – at work ...
- ... ул һәр көн диярлек **үз өстендә** эшләргә, үзенең белемен арттыра барырга, ... вакыт таба. (Гадел Кутуй, Солтанның бер көне.) ... almost every day he finds the time to work on himself, to advance his education, ...

c) 'with' (at house of):

- ... кече баҗа хәзергә әле **кеше өстендә** бер бүлмәдә генә яши ... (Әмирхан Еники, Ике баҗа турында хикәя.) ... the younger brother-in-law has been up till now lodging with some people (i.e., in some people's house), in only one room ...

3. **өстеннән**

a) 'from upon', 'from top of':

- Җиһан әби ... кеткелдәп көлеп җибәрде. Ашыгып кына **сандык өстеннән** төшеп, кече якка, чыжлый башлаган самавары янына китте. (Марсель Галиев, Ул чакта.) ... Grandma Jihan chuckled. She hurriedly came down from the chest and went into the kitchen, to her samovar, which had begun to sizzle.
- Урамга чыккач, **Камил өстеннән** авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйды. (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) After getting out into the street, Kamil breathed a sigh of relief as though a heavy load had fallen from him.

b) 'over' (movement on, along, or over):

- Алар, сөргән **җир өстеннән** әле күптән түгел генә салынган юл буйлап, күксел тауларга таба киттеләр. (Мәдинә Маликова, Юлдашлар.) They drove towards the bluish mountains along a road which had only recently been built over ploughed land.
- Закир абый безне **инеш өстеннән** сикертеп уйнатты. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) Uncle Zakir made us play at jumping over the brook.
- Яңгура **хат өстеннән** күзләрен тиз-тиз йөртте дә, агарынып, хатны өстәлгә ташлады. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Yangghura quickly glanced over the letter and, paling, threw the letter on the table.

· Әле **Казан өстеннән** очкан чакта ук ул күзләре белән Федосеев дамбасын эзләде. (ibid.) While she was still flying over Kazan, her eyes were searching for the Fedoseyev Dam.

c) ‘over’ (garments, etc.):

· Башта энҗеле кәләпүш, өстә ак күлмәк, **күлмәк өстеннән** җиңсез камзул, **камзул өстеннән** бишмәт, **бишмәт өстеннән**, елның фасылына карап, я /jə/ җиңел җилән, я төлке толып. (ibid.) On his (lit., the) head is a skullcap embroidered with pearls. On him is a white shirt, over the shirt a sleeveless camisole, over the camisole a beshmet (a quilted jacket), over the beshmet, according to the season, either a light coat or fox coat.

d) ‘over’ (the glasses, shoulder, etc.):

· Шәүрәнең фатир карчыгы ... баскыч төбендә ... утыра иде. Егеткә **күзлек өстеннән** дә, күзлек аша да тыныч кына карап утырганнан соң: – китте, – диде. (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) Shäwrä’s old landlady ... was sitting at the staircase ... After looking calmly at the young man over her glasses as well as through her glasses, she said, “She’s left.”

e) ‘on’, ‘against’:

· – Сез нәрсә, миңа **этием-энием өстеннән** әләк сөйләргә кушасызмы? (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) What do you want, are you ordering me to inform on my parents?

· Ул теге вакытта ... Мансур **Таһиров** һәм аңа килеп кушылган Юматша **Әхмәтшин** ... **өстеннән** зур шикаять /şikəjət/ язган иде. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) At that time ... he had written a big complaint against Mansur Tahirov and (against) Yumatsha Äkhmätshin ... who had sided with him (i.e., had sided with the former).

**[527] өчен** (old Turkish: uč ‘aim’, ‘cause’, ‘end’ – uču > üčü) ‘aim at’?[1)]

a) ‘for’, ‘(in order) to’ (indicating intention, aim, purpose):

· «Москвич» килгән иде инде. Заһид ... **саубуллашу өчен** ашыгып кулын сузды. (Атилла Расих, Ике буйдак.) The “Moskvich” had already come. Zahid ... hastily stretched out his hand to say goodbye. (Moskvich – make of car.)

· Төрле яктан чолгап алган ... дошманнардан үзен-үзе **саклау өчен**, үзенең бүгенгесен, киләчәген, ... **яклау өчен** ул аларны, ... тар-мар итеп ташларга тиеш иде. Ләкин **моның өчен** әлегә тиешле сәбәбе, җитәрлек сылтавы булмады. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) To protect himself from the enemies ... who surrounded him from various sides, to safeguard his present (lit., present day), his future, ... he would have to destroy them. But for the time being, he had no good reason, no sufficient pretext for this.

· – ... эш моның белән генә бетми. Сез монда **шуның өчен** генә килмәдегез. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) “... work does not end with this alone. You did not come here just for that.”

b) ‘for’, ‘about’ (with regard to, concerning):

· **Безнең өчен** аның сүзләре яңа түгел иде. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) For us his words were not new.

· – ... синең бик әйбәт язылган озын хатыңны алу **минем өчен** зур бәйрәм булды. (Шәриф Камал, Матур туганда.) “... receiving your long, very beautifully written letter was for me a big event.”

· – Ал, – диде. – Сезгә кирәк булыр. Биредә бераз акча да бар. – Анысы да синә калсын, – диде Барлас. – **Безнең өчен** кайгырма. Без акчага аптырамабыз ... (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) “Take it,” he said. “You’ll need it. Here is also

1) See also A.v. Gabain, Alttürkische Grammatik, p. 142.

some money.” “You keep that too,” Barlas said. “Don’t worry about us. We won’t be short of money.”

- Вәдүтнең эшкә **урнашуы өчен** һич кенә дә борчылыр җир юк иде. Аны дүрт куллап кабул иткәннәр. (Барлас Камалов, Урамнар киңәя.) There wasn’t the slightest reason to worry about Wädüt’s getting placed in a job. They received him most readily.

c) ‘for’ (because of, therefore, reason):

- Зөһрәбану түти Вәдүтне ... хат-хәбәр **язмавы өчен** тиргәргә дә ниятләгән иде дә, Морзахан абзый, ..., карчыгына тел озайтырга җай калдырмады. (Барлас Камалов, Урамнар киңәя.) Aunt Zöhräbanu had intended to give Wädüt a real scolding ... for not having written any letter or news, but uncle Morzakhan, ..., did not give his wife a chance (lit., possibility) to start an argument.
- – Сез миңа ачуланмыйсызмы, Гөлшаһидә? ... **Ни өчен** мин сезгә ачуланырга тиеш. (Габдрахман Әмсәмәмов, Ак чәчәкләр.) “Aren’t you angry at me, Gөlshahidä?” ... “Why (for what) should I be angry at you?”
- Әбинең мине шәпләп сыйлыйсы килде. Ләкин каймагы кар базында икән, үзе анда төшә алмый, ..., **шуның өчен** каймак алырга мине чакырды. (Мирсәй Әмир, Әби васыяте /wasiəte/.) Grandmother wanted to feed me nicely. But it turned out that her cream was in the cold (storage) cellar. She herself could not go down there, ... Therefore (for that reason), she had me get the cream.

d) ‘for’ (for the benefit, sake of):

- Тыйнак холыклы ул безнең әни. **Әти өчен, безнең өчен** аһ итеп яши. (Барлас Камалов, Ялыкмаслар.) She is of a retiring nature, our mother. She lives, caring for Father, for us.
- Татар милләтенең **үсүе өчен** файдалы бер эш эшләү, аңар файдалы кеше булу – безнең максатның иң зурысы иде. (Мәхмүт Бөдәйли, Ул тормышны сөя иде.) Our greatest aim was to do a useful work for the development of the Tatar nation, to become men useful to it.

*Note:* Reference is to the Tatar-Bashkir poet Шәехзадә Бабич (1895-1919).

- – Мин **синең өчен** бик шатмын, Асия /Asiə/. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) “I am very glad for you, Asiä.”

e) ‘for’ (in exchange, return):

- Без, кара-каршы утырып, тамак ялгадык. Буфеттан чәй алып эчтек. **Аның өчен** түләргә дип мин никадәр генә тырышсам да, ул миннән акча түләтмәде. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) Sitting opposite to one another, we had a little to eat. From the counter we got some tea. Try as I might to pay for it, he did not let me (pay).
- – Кичерегез, бай. Мин сезгә карт **үгезегез өчен** биш мең кирпеч сугып бирдем ләбаса? Нишанбай елмаеп куйды. – ... Эш беткәч, бер пот бодайны кем бирде сиңа? Моннан тыш, **үгез өчен** тагын килеп эшләрмен димәдеңмени? (Әбрар Шәмин, Янар тауны кичкәндә.) “Pardon me, Master. I made you five thousand bricks for your old ox, didn’t I?” Nishanbai gave a smile. ... “Who gave you a pood (16.38 kg) of wheat when the work was finished? Besides, didn’t you say that you would come and work again for the ox?”
- Сүз дә юк, чибәр кыз ... Әмма бу **кыз өчен** күпме калым бирер икән ул? (ibid.) Undoubtedly, she is a pretty girl ... But how much bride-money will he possibly pay for this girl?

f) ‘for’ (representing, instead of):

- – Сайлап куйдык, сайлап! – диде Белугин, **барысы өчен** дә җавап биреп. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) “We elected him, elected him!” Belugin said, answering for all of them.

· Хәзер ул Фәридәне бөтенләй эшләтмәде, **аның өчен** сабанын да чистартты, тракторын да чистартты. (ibid.) Now he did not let Färidä work at all. He cleaned her plough and cleaned her tractor also for her.

g) 'for', 'to' (indicating suitability):

· Биргиделне үзләренә хезмәт **иттерү өчен**, табигать иҗат иткән елга тармагы белән генә канәгатьләнмичә ... Яңа ерым ачканнар. Нәтиҗәдә, Биргидел зурайган, саллар авылның янына ук килә башлаганнар ... Биргидел киң күңелле булып чыкты. Ул агач байларына хезмәт итеп кенә калмады ... Бала-чагага **су керү, балык тоту, каз көтү өчен** шуннан да кулай, шуннан да ямьле урын бар идеме икән дөньяда? – шулай тоела иде безгә. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) Not satisfied with the arm of the river just as nature had created it, they (i.e., the lumber barons) ... opened up the Yanga Yyrym (New Ravine) to make the Birgidel serviceable to them. As a result, the Birgidel became larger and (timber) rafts began to come right down to the village ... The Birgidel turned out to be kind. It didn't just serve the lumber barons ... Could there possibly be a place in the world which was more convenient, more pleasant for children to swim, fish and tend geese? To us it seemed that way (i.e., that there wasn't). (Birgidel – a small arm of the Aƣidel/Belaya.)

h) 'for' (indicating a time period for which something is due or designated):

· Мондый кадер-хөрмәткә лаек булган кеше – ... Айсылу апа иде. Май аеның беренче **яртысы өчен** ул хәзер эш хакы алып килгән иде. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) The person deserving such esteem was ... Aunt Aisylu. She had brought the wages for the first half of May.

· Укытучыларның хезмәт хаклары арту сәбәпле, Солтанга бүген узган **айлары өчен** өстәмә түләделәр. (Гадел /Ƣädel/ Кутуй, Солтанның бер көне.) Due to the increase in teachers' salaries, they paid Soltan today additionally for past months.

**[528] үтә**, **үтәли** (**үт** 'cross, go, pass through').

'beyond', 'through':

· Урамның ике як рәтендәге өйләрдән **тәрәзә үтә** лампа яктылары караңгылыкны ертып кар өстенә төштеләр. From the houses standing in a row on either side of the street, the lights of the lamps, shining through the windows, pierced the darkness and fell upon the snow.

· ... Сулар агызам тирән күлләрдән.
... **Болыт үтә** төшкән ай шәүләсен
Төшереп куям Күлнең төбенә.
(Һади Такташ, Кояш күктә шулай мәңге йөзәр.)
... I make the waters flow from deep lakes.
... The reflection of the moon which falls through the clouds
I send down to the bottom of the lake.

· Яхшыбай өйалды баскычыннан төшеп җитүгә эт ... ачык **капка үтәли** ишек алдына[1] кереп килә иде инде. (Мирсәй Әмир, Ашмасов.) Just when Yakhshybai had descended the stairs to the porch, the dog ... was already coming into the yard through the open gate.

(For җитү as auxiliary verb see 1374, a; for the verbal noun in the dative see 1177, a.)

---

1) New spelling: ишегалдына.

## Postpositions Governing the Nominative, the Genitive, or the Dative

**[529]** The postpositions **кадәр** /qədər/, **тикле** (**тиклем**), **хәтле**, **чаклы** (**чикле**).

**[530]** These postpositions govern either the nominative of nouns, the genitive of the personal pronouns (except that of the third person plural), or the dative, and their meaning changes accordingly. With the *dative*, they express *spatial*, *temporal*, and a *variety of other relationships* (for details see below). With the *nominative* (*genitive of the personal pronouns*), they express *comparison in extent, size, quantity, quality, degree, property, characteristics.* Also, when expressing comparison, they mostly emphasize the noun (pronoun) which they govern.

**[531]** **кадәр** (qadr – Arabic, meaning 'extent', 'scope', 'scale', 'quantity', 'measure', 'degree').

a) 'to', until', 'as far as' (indicating distance):

- Изге Өмет **борынына кадәр** /qədər/ ике көнлек юл калды. (Рафаэль Мостафин, «Оҗмах»ка сәяхәт.) A two days' voyage remained to the Cape of Good Hope.
- ... җырчылар, ... биючеләр, ... сәхнәдән **түшәмгә кадәр** баскычлы таган ясаучы акробатлар – һәммәсе сокланырлык матур ... (Мөхәммәт Шәйми, Сынау.) ... the singers, ... the dancers, ... the acrobats, who are building a stepped pyramid (lit., trivet) from the stage to the ceiling – all are enchantingly beautiful ...
- [Мөршидә] Зөлфәт белән Фәһимәне ишегалдына озата чыкты. Аннары урам **чатына кадәр** үк барды. (Рәисә Ишморатова, Язмышлар.) [Mörshidä] saw Zölfät and Fähimä out to the yard. Then she went with them even to (as far as) the corner of the street.
- Хәзер алар икесе дә Җиргәнгә алып бара. Турыга киткәне – Йомак авылы аша. Димәк, Йомакның үзенә барып җитәргә ике-өч чакрым чамасы да, аннан соң **Җиргәнгә кадәр** җиде чакрым исәпләнә. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) Now both of them (i.e., both roads) lead to Jirgän. The one running straight ahead goes through the village of Yomaq. That means, it is about two or three versts to Yomaq itself and then (lit., after that) seven versts to Jirgän.

b) '(up, down) to' (including):

- Алар арасында берсе, шомарып, ялтырап торган тоташ кап-кара күн киемнән иде. Аягыннан алып **башына кадәр** күн. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) One of (lit., among) them was in a polished, shining, entirely raven-black leather suit. From head to foot (lit., From his feet up to his head) it was leather.
- Һәр санын көтеп алам. Аны башыннан **ахырына кадәр** укып чыгам. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч.) I wait impatiently for each number (i.e., issue of the newspaper). I read it through from the (lit., its) beginning to the (lit., its) end.

c) 'until', 'till', 'to' (indicating time limit):

- Сәгать ике ... **Җидегә кадәр** биш сәгать бар әле. (Мирсәй Әмир, Аюханов.) It is two o'clock ... There are still five hours until seven.
- Ул көнне без эти белән иртәдән **кичкә кадәр** кырда булып, кояш баеган вакытта гына кайтып кердек. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) That day Dad and I were in the field from morning till evening, and we returned home only at sundown.
- Ул быел яздан **көзгә кадәр** Бикбулатларга хезмәтче булып ялланган. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) He has been hired to work as a farmhand with the Bikbulats this year from spring to fall.

- Унбер **яшькә кадәр** Галимҗан авыл мәктәбендә укый, ... (Татар совет әдәбияты тарихы, Галимҗан Ибраһимов.) Until the age of eleven, Ghalimjan studied (lit., studies) in a village school, ...

d) ‘before’ (indicating time, order, rank):

- Торатау түбәсендә җәй **уртасына кадәр** кар эреп бетмәгән еллар еш кына була. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) Years in which the snow on top of Torataw (mountain) does not melt completely before the middle of summer occur rather frequent.
- Болай ук та моңлы, болай ук та тирән итеп бу җырны **аңа кадәр** бер кем дә җырлый алмагандыр ... (Марсель Галиев, Ул чакта.) Before him, no one has probably been able to sing this song in such a melancholy way, in such a soul-stirring way ...
- Күңелдә тагын да тирәнрәк эз калдырган урын – Агыйделнең Камага кушылган урыны иде. Бу юлдан **безгә кадәр** узган кешеләрдән ишеткәнебез бар иде инде. Дөрес икән. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч.) A place which left a still deeper imprint in one’s heart was the place where the Belaya joins the Kama. We had already heard this from people who had passed on this way before us. It turned out to be true.

e) ‘for’ (‘up to’, indicating time period):

- Яткачтын бераз **вакытка кадәр** төрле кешеләр вә манзаралар аның күз алдына берәм-берәм генә килеп торсалар да, ахырда һәммәсе буталып китә. (Шәриф Камал, Сукбай.) Although for a little while after lying down the various people and sights come one by one to his mind’s eye, they eventually all get mixed together.

(For яткачтын see 1277 b; вә – һәм.)

- Корычагач кырык метрга буй үстерә, бер метр юанлыкка җитә, ..., өч йөз **елга кадәр** яши. (Мәрди Рафиков, Урманым – һәйкәлем.) The ash-tree grows a trunk up to forty meters tall (and) reaches a thickness of one meter. ... It lives for (up to) three hundred years.

f) ‘for’ (as long as, time period):

- Ул күзен алмыйча биш **минут кадәр** тәрәзәгә карап торды. (Шәриф Камал, Уяну.) Without taking his eyes away, he gazed at the window for (as long as) five minutes.

g) ‘as much as’, ‘as many as’ (indicating time, or quantity, amount):

- Бу вакыйгага (waqiɋəgə) инде **ел ярым кадәр** заман узып китте. (Галиәсгар Камал, Үз хәлебез.) As much as a year and a half have already passed since this event.
- ... быел әүвәлдәге дүрт-биш студент урынына, университетта **егерме кадәр** мөселман студентлары бар. (Галиәсгар Камал, Мөселман студентларыбыз.) Instead of the previous four or five students, there are this year as many as twenty Moslem students at the university.
- ... уку хакы буларак, университетка елына йөз **сум кадәр** акча түләргә кирәк. (ibid.) ... as tuition fee one must pay the university as much as one hundred rubles per year.
- Кечкенә чагында миңа бервакыт утыз **тиен кадәр**, бакыр акча бирделәр. (Габдулла Тукай, Сыбызгы.) When I was little they once gave me as much as thirty kopecks in copper coins.
- – Безнең гасыр башында, беләсезме, бу тирәдә урман күпме булган? Барлык җирнең өчтән **бере кадәр.** (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) “Do you know how much woodland there was around here at the beginning of the century? As much as one third of all the land.”

h) ‘as’, ‘as ... as’, ‘like’ (in making comparisons):

- Чыннан да, бу әтәчне минем әтием каяндыр үзе алып кайткан иде. Ул чакта Гөлдери **йодрык кадәр** генә бер йолкыш чеби иде. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) In fact, my father had brought home this cock himself from somewhere. At that time, Gölderi was a flabby chick only as big as a fist.
- Аңа төшенү өчен, **дөнья кадәр** белем өстенә, **тау кадәр** тәҗрибә кирәк. (Мөхәммәт Шәйми, Сынау.) To understand it (i.e., life), one needs, in addition to knowledge as wide as the world, experience as big as a mountain.
- Ихтимал, ул чагында миннән дә бәхетлерәк бер генә кеше дә юк идедер. Үзенең сөйгән кызын унике башлы дию пәриеннән коткарган әкият батыры да **минем кадәр** үк куанмагандыр. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) At that time there was probably no one happier than I. Even the fairy tale hero who saved his beloved girl from the twelve-headed demon was probably not as happy as I.
- – Мине **шул кадәр** беркатлы дип уйлыйсыңмы? (Габдрахман Әпсәләмов, Идел хикәяте.) “Do you think that I am that naive (as naive as that)?”

i) ‘even’ (as intensive particle):

- Укуымның өченче елында әти мине ... Каенсар авылының кадим /qədim/ мәдрәсәсенә илтеп ташлады. Моңа әни дә, бөтен өй эче дә каршы иде. **Кардәш-ыруларга** /qərdəş-ьrularoja/ **кадәр** борчылды. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) In the third year of my studies, Father ... transferred me to the old-style medrese in the village of Qayynsar. Mother, as well as everybody in the house,was against this. Even the relatives worried.
- Без, тыела алмыйча, тәгәрәшеп көләргә тотындык. Хәтта **этигә кадәр** көлмичә булдыра алмады. (ibid.) Unable to control ourselves, we began to double up with laughter. Even Father could not help laughing.

*Note:* The use of both the intensive particle **хәтта** and the postposition **кадәр** expresses strongest emphasis.

**[532]** The postposition **кадәр** has the expanded forms **кадәре** and **кадәрле**. All three forms may be regarded as parallel forms without any difference in meaning. Their use depends on euphony (for example, to achieve a greater ease of pronunciation when the following word begins with a consonant), rhythm of speech, as well as on individual preference. It seems, however, that **кадәр** conveys a certain concreteness, that it is somewhat more definite than, for example, **кадәре**.

- Бу **көнгә кадәре** Җәмилә Шәехнең үлекме, терекме икәнен, кая киткәнен белмәде. (Мәҗит Гафури, Ярлылар.) Up to this day, Jämilä did not know whether Shäyekh was dead or alive, (or) where he had gone.
- **Ул кадәре** инглизчә мин дә беләм. That much English I know too (i.e., very little).
- ... Зәйнәп егетенең башыннан **аягына кадәре** карап чыкты. (Мәсгут Шәрифуллин, Еллар үткәч.) ... Zeynäp scrutinized her boy friend (lit., her young man) from head to foot.
- ... ни **кадәре** генә тавыш чыгармаска тырышса да ... коймага бәрелеп, төнге тынлыкны бозды. (ibid.) ... however much he tried not to make any noise ... he bumped against the fence and broke the stillness of the night.
- Музыка тынып кала. Көндезге **ялга кадәрле** инде ул бүгән яңгырамаячак. (Равил Вәлиев, Көчле агым.) The music ceases. Today it will not sound again until the lunch break.
- – Абый, руль артына утырып бер генә әйләним инде, теге **башка кадәрле** генә алып барыйм әле. (Мәсгут Шәрифуллин, Еллар үткәч.) “Uncle, please, let me sit behind the wheel and do just one turn. I’ll take it (i.e., the tractor) only as far as the other end (of the village).”

- Без **тәүлек кадәрле** баргач, Казанга килеп кереп бер урында туктадык. (Габдулла Тукай, Исемдә калганнар.) After we had traveled for as long as a whole day, we entered Kazan and stopped at a certain place.

**[533] тик** (arch.) 'like' (in making comparisons):

- Дәрвиш. ... Ай **тик** йөзең, бал **тик** телең белән, алла юлында тузан булган бер дәрвишкә ни өчен ялган сөйлисең? (Нәкый Исәнбәт, Хуҗа Насретдин.) The Dervish. With your face like the moon, your tongue like honey, why do you lie to a dervish, who is dust on God's path?
- – Карап-карап торам да, аптырыйм бән сезгә, – дип башлады Абдулла, салмак кына. – **Үгез тик** егетләр үзегез, вәләкин зарланышып йөрүдән бушамыйсыз. (Җәмит Рәхимов, Батырша.) "I have been watching you, and I am puzzled at you," Abdulla began in a measured tone. "You are men strong as oxen, but you go on merely complaining." (Implies that they ought to act.) (бән – мин).

**[534] тикле**, **тиклем**.

a) 'to', 'until', 'as far as' (indicating distance):

- Көзен алсу әнисләр алмагач ботагыннан **тәрәзәгә тикле** сузылалар. (Рәмзи Максудов, Шәйморза кешеләре.) In fall the pinkish anise apples extend along the branches of the apple-tree to the window.
- – Менә **шунда тикле** укып килерсең. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) "You will read up to there. "

*Note:* монда, шушында 'here', анда, шунда 'there', тегендә 'there', indicate both position at and movement to a place. For example: Без монда. 'We are here.' Монда кил! 'Come here!' Монда хәтле (чаклы, кадәр). 'Up to here.' Алар анда утыралар. 'They are sitting there.' Анда барма! 'Don't go there!'

- Әни утырган арба артыннан барам ... Бабай атка сукты. Ат чаба, мин йөгерәм ... **Күпергә тикле** йөгердем, артык йөгерә алмадым. (Ибраһим Гази, Малайлыкта кунакта.) I walk behind the wagon on which Mother is sitting ... The old man hit out at the horse. The horse galops, I run ... I ran as far as the bridge, I could not run any further.
- Мин аны борынынннан **койрык очына тиклем** сабынлап юып чыктым. (Рөстәм Кутуй, Бер дә бер көзне.) I washed him (i.e., the dog) with soap from his nose to the tip of his tail.

b) 'up, down) to' (including):

- Бик соң инде. Инде без генә, чана шуучы малайлар гына калдык ... Киез итек белән бияләйләр дә гел боз гына. Бүтәнне әйткән дә юк, шуып төшкән саен егыла-мәтәлә торгач, **чалбарларга тикле** сыгып ташлардай булган. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) It is already very late. Only we, the boys who are tobogganing, have remained ... The felt boots and the mittens are all frozen. Not to mention everything else. Since we are falling, rolling head over heels, each time we slide down, everything down to the trousers has become wringing wet.

c) 'until', 'till', 'by', 'before' (indicating time limit):

- ... шул биш тәңкә өчен тагын ике капчык бәрәңге җыеп бирергә күңелемне беркеттем. Әмма көндәлек мәшәкатьләр миңа вәгъдәмне үтәргә ирек бирмәде, ул бурыч шушы **көнгә тикле** минем өстемдә асылынып тора. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) ... In my heart I made the firm resolution to pick another two sacks of potatoes and give them to her for the five rubles (i.e., the five rubles she had given the boy in addition to the ten rubles he had asked for two sacks of potatoes). But the daily worries did not permit me to fulfill my promise, and that debt has been hanging over me until this very day.

- Хәзергә мин әйткәннән башка берни дә билгеле түгел. Икенче **әңгәмәгә тикле**, бәлки яңа хәбәрләр алыныр. (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) Except for what I have said, nothing is known up to now. Perhaps, new information will be received by the time we have the next talk.
- Анау елны ... яңгыр яумады, күлгә әллә ничә басудан торбалар тыгып, җәй буе суын суырттылар. **Көзгә тиклем** күл төбендә ындыр табагы хәтле генә су калды дип сөйләделәр. (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында.) That year ... it did not rain. They said that from several fields they put pipes into the lake, and all summer long they drained (lit., sucked out) the water from it. By the autumn, only as much water as (the size of) a threshing floor had remained at the bottom of the lake. (анау – dial. әнә шул, әнә теге).

d) ‘before’ (indicating time, order, rank):
- Ул Таһирҗанның килгәнен **Гүзәлгә тикле** үк күргән иде. (Гариф Гобәй, Ләйсән яңгыр.) He had seen Tahirjan coming even before Güzäl (had).

e) ‘as’, ‘as ... as’ (in making comparisons):
- Йортларда **тычкан күзе тикле** ут күренми ... халык шәфәкъ сүнү белән йокларга ята. (Гомәр Бәширов, И язмыш, язмыш.) There isn’t even a tiny light (lit., a light as tiny as the eye of a mouse) visible in the houses ... people lie down to sleep as soon as the glow of the sunset is gone.
- – Кабаланма **ул тиклем**, мин киткәч чыгарырсың. (Фатих Хөсни, Җәяүле кеше сукмагы.) “Don’t hurry so much. You’ll go out after I have left.”

f) ‘even’ (as intensive particle):
- Моңарчы ... шаулашып барган малайлар берьюлы тындылар. Әхмәттән көнләшеп, юл буе үчекләп килгән **Нимҗанга тикле** телсез калды. (Гомәр Бәширов, Туган як – яшел бишек.) The boys, who until now had walked noisily, ... all of a sudden fell silent. Even Nimjan, who was jealous of Äkhmät and had teased him all along the way, stopped talking.

*Note:* Of the two forms **тикле** and **тиклем** the former is the most commonly used form.

**[535] хәтле** (hadd – Arabic, meaning ‘edge’, ‘border’, ‘limit’).

a) ‘to’, ‘until’, ‘as far as’ (indicating distance):
- Кала бит ул, Өчиле түгел. Аның бер очыннан икенче **очына хәтле** җәяү йөреп кара! (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) After all, this is a city, not (the village of) Öchile. Try to walk from one end of it to the other!
- – Әйдә мин сине **почмакка хәтле** кире озатыйм, – диде Хәлим. «Куркырсың»ны сылтау итеп, Хәлим аны башта **почмакка хәтле**, аннары **мәчеткә кадәр**, шуннан соң һичбер сылтаусыз **өйләренә тикле** озатты. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) “Come on, I’ll accompany you back as far as the corner,” Khälim said. Using the pretext: “You will be afraid”, he accompanied her first to the corner, then to the mosque, and after that, without any pretext, up to their house.
- Авылдашлары аны үсмер чакта ук чыгып киткән дә, шуннан бирле ярты дөньяны айкаган, диләр ... бөтен Себерне кыдырганнан соң, хәтта Манҗурия дигән җир белән **Кытайга хәтле** барып чыккан. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) His countrymen (fellow villagers) say that he left when he was still a young lad, and that since then he has roamed around half the world ... after wandering around all of Siberia, he even got as far as Manchuria (lit., the land called Manchuria) and China.

b) ‘(up, down) to’ (including):
- Көтмәгәндә Хәлимнең кулына клиндер тоттырдылар. Хәлим аны икегә сындырып, яртысын кесәсенә тыкты. Калган яртысын ... коелган **валчыкларына хәтле** ...

ашап бетерде. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) Suddenly (unexpectedly), someone put a small ring-shaped cracker into Khälim's hand. Khälim broke it in two and put one half into his pocket. The other (lit., remaining) half ... he ate up ... down to (i.e., including) the crumbs which had fallen down.

- ... гарьләнү тойгысы егетне тәмам биләп алды. Күзләреннән атылып чыккан яшь, юеш чәчләреннән тамган су тамчыларына кушылып, ике яңагы буйлап акты. Кинәт, бизгәк тоткан кебек, бөтен тәне дер-дер килә башлады. Шунда гына ул үзенең **җеп бөртегенә хәтле** чыланган булуын, көзге төннең салкынча җиле **җелегенә кадәр** үтеп өшүен сизде. (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем элмәге.) ... the feeling of being humiliated completely overwhelmed the young man. The tears bursting from his eyes mixed with the rain (lit., water) drops which dropped from his wet hair and ran down both his cheeks. Suddenly, as if gripped by fever, his whole body began to tremble. Only then did he feel that he had become soaked to the skin, and that the cold wind of the autumn night was penetrating to his bone marrow, making him shiver with cold.

c) 'up to' (indicating limit):

- Шулай бер дә уйламаганда, тире ташуны ташлап, җир казучыга әйләндем. Бердән, бу эш бик якын, икенчедән, чыннан да «көрәкне батырып эшләсәң», ..., – 70-80 тиен, хәтта **бер сумга хәтле** «төшереп» була икән. (Ибраһим Салахов, Томаннарга төренгән яшьлек турында.) So, without thinking twice, I quit hauling hides and turned laborer-excavator. Firstly, this work was very familiar (lit., close), and, secondly, if you really "dug in your shovel", ..., it seems you could "fetch" 70-80 kopecks, even as much as one ruble. (In his old job the speaker earned 20 kopecks.)
- Аннары, андагы эшләр кими төшкәч, хатыны белән бергә Мангышлакка күчте һәм шунда зур **идарә җитәкчесенә хәтле** үсте. (Газиз Үзиле, Гыйфрит.) Then, when the work there fell off, he moved with his wife to Manghyshlaq and there rose to the post of manager of a large department.

d) 'until', 'till', 'to' (indicating time limit):

- ... җомга көннәрдә, сәгать унбердән **икегә хәтле** ... бөтен шәкертләр эштән азат ителәләр. (Кәрим Тинчурин, Өченче мәрҗән.) ... on Fridays, from eleven to two o'clock, ... all students are excused from work.
- – Син яшь бит әле, мин кайтканда, егермең дә тулмаган була. – Мин **кырыкка хәтле** көтәргә дә риза. (Мирсәй Әмир, Карамалы егете.) "You are still young, after all. When I return, you will not even have completed your twentieth year." "I am ready to wait even till I am forty."
- Закир Һади 1904 нче елның азагыннан алып 1906 нчы елның **язына хәтле** Одесса шәһәрендә укыта. (Каюм Мостакай, Закир Һади.) From the end of 1904 until the spring of 1906 Zakir Hadi taught (lit., teaches) in the city of Odessa.[1)]

e) 'before', 'ahead of' (indicating time, order, rank):

- Мохтар, Гайфуллинның **сугышка хәтле** мөгаллим булганлыгын ишеткәне бар. (Шәриф Камал, Таң атканда.) Mokhtar has heard that before the war Ghaifullin was a teacher.
- **Исламга хәтле** борынгы заманнарда бездә ай, ел, көн исемнәре үз телебезчә булган, кайберләре әле дә әйтелгәли. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) In ancient times, before Islam, we had names of the months, years, (and) days in our own language. Some of them are still used (lit., said) from time to time.
- **Фәезгә хәтле** ул баш инженер булырга тиеш иде. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) He should have become the chief engineer ahead of Fäyez.

---

1) Zakir Hadi (1863-1933) Tatar writer.

f) ‘for’ (up to, indicating time period):

· Ул (Мохтар) бүлмәсенә кереп йокларга яткач та, бераз **вакытка хәтле**, нотариус Бродскийның ... кульяулык белән җилләнүләре аның күз алдына килеп торды. (Шәриф Камал, Таң атканда.) He (Mokhtar) entered his room, and after he had lain down for a little while, notary Brodskiy stood before his mind’s eye, fanning himself ... with a handkerchief.

g) ‘as’, ‘as ... as’, ‘like’ (in making comparisons):

· – ... мин аны үземә алып кайтам, ... – Юк, ..., диде Ибрай. – Син **минем хәтле** тәрбияли алмассың. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) “... I’ll take him to my place, ...” “No, ...,” Ibrai said. “You will not be able to take care of him as I can.”

· – Мин анысын «Разия» дип йөри башлыйм. Ләкин ул **сезнең хәтле** үк матур түгел, – дип, мин Разияны култыкладым. (Фатих Әмирхан, Кадерле минутлар.) “That one (i.e., that star) I shall from now on call (lit., I shall begin to call) Razia. But it is not as pretty as you,” I said, taking Razia’s arm.

· Узенең Аркылы тыкрыктагы тавык **кетәге хәтле** генә бүлмәсеннән соң, бу егерме метрлык бүлмә аңа искиткеч зур булып тоелды. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) After her room on Arqyly Lane, which was only as big as a hen-coop, this twenty-meter room appeared to her wonderfully large.

· – Ни өчен **бу хәтле** арттырасыз, иптәш Гыйльманов? (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) “Why are you exaggerating like this, comrade Ghilmanov?”

· Көн **ул хәтле** суык түгел, ләкин шактый кискен җил исә. (ibid.) The day is not that cold, but a rather sharp wind is blowing.

h) ‘even’ (as intensive particle):

· Аның көй ритмына куллары гына тугел, **иңбашларына хәтле** уйнаклый, ... (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) Not only her hands, even her shoulders moved to the rhythm of her song, ...

· Иртән чыккан кеше, көндез мин инде авылда идем. Шул арада авыл бик сагындырган. Үз авылыңның читәнгә кунган **чыпчыкларына**, тал ботагында тибрәнгән **каргаларына хәтле** күңелгә якын. (Ибраһим Гази, Малайлыкта кунакта.) Leaving as I did (lit., being a man who left) in the morning, I was already in the village at noontime. It was that I (had) pined (lit., the village had made me pine) very much for the village all that time. Even the sparrows of one’s own village, which sit on the fences, the ravens, which swing on the willow branches, are close to the heart.

**[536] чаклы** (in some dialects also **чикле**; **чик** ‘border’, ‘edge’, **чикле** ‘limited’, ‘having a limit, border’).

a) ‘to’, ‘until’, ‘as far as’ (indicating distance):

· Салих ... артык кыстап тормады һәм **урамга чаклы** озата да чыкты. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) Salikh ... no longer tried to persuade me and even accompanied me out to the street.

· – ... өченче автобусны эзләп тап. Аның белән Салават **тукталышына чаклы** бар да Тынычлык урамы буйлап китәрсең. (Гариф Ахунов, Хәзинә.) “... look for the number three bus. Go with it until (as far as) the Salawat stop and walk along Tynychlyq (Peace) Street.”

· Умарталыктан өч **километрга чаклы** арада юкә агачларын кисү тыела. (Мәрди Рафиков, Урманым – һәйкәлем.) Cutting down lindentrees is prohibited within a distance of (as far as) three kilometers from an apiary.

b) ‘(up, down) to’ (including):

· Кулъязманы өстәлгә салды, укырга ашыкмады, **энәсеннән җебенә чаклы** минем тормышымны, кайда укуымны, кайчаннан бирле әдәби эш белән шөгыльләнүемне,

сораштырды, ... (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) He put the manuscript on the table. He did not hurry to read it (but) questioned me about my life down to the smallest detail; where was I studying, since when had I been engaged in literary work, ...

c) ‘until’, ‘till’ (indicating time limit):
- – Мин риза. Тик вакыты кичке сәгать биштән **җидегә чаклы** булсын иде. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) “I agree. Only let the time be in the evening from five o’clock until seven.”
- – Марат өчен бер дә борчылма, **көзгә чаклы** миндә торыр. (Сафа Сабиров, Фирдәвес.) “Do not worry at all about Marat. He can (lit., will) stay with me until fall.”

d) ‘before’ (indicating time, order, rank):
- Таҗи бай хуҗалыгында бишенче ай хезмәт итә ул. Ә **моңа чаклы** – ятим балалар йорты, теләнче сабый ... (Әбрар Шәмин, Янар тауны кичкәндә.) He is working the fifth month now on Taji Bai’s estate. And before this – the orphanage, a beggar child ...
- Эчтән көләм үземнән: **Миңа чаклы** бер җүләр дә төнлә бу түбәгә менеп бөтен авыл каршында гармун тартып утырмагандыр! – дим. (Мәҗит Рафиков, Илһам авазы.) Inwardly I am laughing about myself. Before me no fool has probably climbed to this summit during the night and played the accordion, before the whole village.

e) ‘for’ (up to, indicating time period):
- Ул нихәтле арыган булса да, йокысы качкан иде. Әллә **кайвакытка чаклы** күзләрен ачып караңгылыкка карап ятты. (Шәриф Камал, Сукбай.) Tired as he was, sleep escaped him. For some time he lay with open eyes, looking into the darkness (lit., he lay, his eyes open and looking).
- Бу халәт бер **атнага чаклы** барды, аннары җиңеллек килде, ... (Гариф Ахунов, Хәзинә.) This condition lasted for (up to) a week, then relief came, ...

f) ‘as ... as’, ‘like’ (in making comparisons):
- Каршыда **капка чаклы** киң ишек, ... (Саҗидә Сөләйманова, Гөлбадран.) Opposite is a door as wide as a gate, ...
- Безнең авыл шактый зур. **Аның чаклы** башка татар авылларында өч-дүрт мәчет ... булса, безнең авылда бар булганы ике мәчет, ... (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) Our village is rather large. Whereas, ... in other Tatar villages which are as large as it there are three or four mosques; in our village there are only two mosques, ...
- – Кычкырма **ул чаклы**! – диде Җәмилә пышылдап. (Нурихан Фәттах, Кичү.) “Don’t shout like that!” Jämilä whispered.

g) ‘even’ (as intensive particle):
- – ... ул Хисами кайда соң монда? – Хисамимы? Хисами сугыш беткәч тә ... күчеп китте ... Бик әйбәт тора, диләр. **Күркәсенә чаклы** асрый икән. (Әмирхан Еники, Туган туфрак.) “... that Khisami, where (around) here is he (i.e., does he live), then?” “Khisami? Khisami moved away to ... immediately after the war ended ... He is doing very well, they say. He is even raising turkeys (so they say).”

h) Examples with **чикле**:
- Кичен без уку йортында сәгать **унга-унбергә чикле** утырабыз. (Татар теленең диалектологик сүзлеге.) In the evenings we sit in the educational institution until ten or eleven o’clock.
- ... мин язгы **сабанга чикле** ике йөз сум акча табам ... (Галимҗан Ибраһимов, Кызыл чәчәкләр.) ... by (the time of) the spring ploughing I shall make two hundred rubles ...

**[537]** Emphasis may also be expressed by combining a noun in the nominative with **кадәр**, **тикле**, **хәтле**, or **чаклы** and repeating the same noun after the postposition, putting it (the noun) in the required case form. These constructions express various emotions, such as pride, surprise, belief, trust, disappointment, doubt, conviction, etc.:

- – Ә хәзер... мин ни әйтергә дә белмим... Менә **йорт кадәр йорт** алгансың – аны миннән яшергәнсең, ... (Әмирхан Еники, Рәшә.) "And now... I don't know what to say... Look here! You have even bought a house. You have hidden that from me, ..." (Expresses disappointment.)
- Борисович безгә карап исе китеп калган. Ничек болай, **акча кадәр акчаны** алырга теләмиләр? дип гаҗәпләнә, күрәсең. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) Looking at us, Borisovich was amazed. "How is that, he seemed to wonder, "they don't even want to take the money?"
- – Туй иткәч, Чаллыга кайтабыз. Бөтенләйгә ... Рәйхан бер мәл эндәшмәде ... – Синең туганнарың безне ничек кабул күрер? ... Без алар белән бер куышка сыя алырбызмы? – Бер куышка сыеша алмасак, **шәһәр тикле шәһәр** калыккан төштә төзүче белән укытучы урамда торып калыр дисеңме? (Барлас Камалов, Урамнар киңәя.) "After getting married we go back to Chelny. For good. ..." For a while Reykhan was silent. ... "How will your relatives receive us? ... Will we be able to fit in with them in one house?" "If we can't fit in in one house, do you think that in a place where a city is rising a builder and a teacher will be left to live in the street?"
- Шигырь сөйләүгә, күрәсең, шундый да остарып киткәнбез, бер елны хәтта безне **Арча хәтле Арчага** алып барып сөйләттеләр. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) It seems that in reciting poems, we had become such masters that one year they even took us to such a city (i.e., such an important, such a large city) as Archa (Arsk) to have us recite (there). (Expresses pride.)
- Әлбәттә, шулайдыр. **Эти чаклы эти** шулай дип әйтеп торгач, шулай булмыйча соң. (Фатих Хөсни, Утызынчы ел.) Of course it is so. If even Father says so, then how can it not be so. (Expresses belief, trust, conviction.)

*Note:* **кадәр**, **тикле**, **хәтле**, **чаклы** (**чикле**) have the same meaning. Their choice depends on the personal preference of the speaker (writer), as well as on which of them appears to be more euphonic within the context.

**[538] дип** (verbal adverb of **дию** 'to say').

After nouns in the nominative, **дип** means 'for', 'for the sake of'; after nouns in the dative, it means 'for', expressing intention, aim, for the benefit of. After nouns in the dative denoting time, it expresses temporal relationship:

- Бәйрәм **көн дип** өстәлләргә яхшырак, затлырак азыклар куелды. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) For the holiday better, fancier food was put on the tables.
- Яңа докторны күрергә килүчеләр арасында Зәмзәмия дә булды. ... **Ни дип** килә ул? (Габдрахман Минский, Язның беренче көне.) Among those who were coming (lit., who are coming) to see the new doctor was also Zämzämiä ... For what is she coming?
- Бәнат ... иртәнге чәйгә **суга дип** күл буена төшеп китте. (ibid.) Bänat ... went down to the lake for water for the morning tea.
- Ул ... кайтып кергәндә, өйдә инде күптән ашаганнар иде. **Аңа дип** калдырылган карабодай боткасы ... әллә кайчан суынып беткән ... (Сафа Сабиров, Үз каным.) When he returned and entered, ... they had already eaten in the house long ago. The buckwheat porridge ... which had been left for him had got cold long ago ...
- Бер-ике генә **сәгатькә дип** кергән булсалар да, дөнья хәлләрен сөйләшеп утыра торгач, самовар артыннан самовар яңартып, төн узып китте, таң да беләнде.

(Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Мохтар Ибраһимов.) Although they had come in for only one or two hours, after discussing the world situation and heating up (lit., renewing) samovar after samovar, the night passed and it began to dawn.

**[539] каршы**. The word functions as a postposition proper and as a postpositional word of nominal origin. As the former, it remains unchanged and always governs the dative. As a postpositional word – as a noun it means 'opposite side', as an adjective 'opposite', 'adverse' – it takes the possessive suffixes, the dative, locative, or ablative case and requires the nominative of nouns, the genitive of personal and demonstrative pronouns. When preceded by the pronouns **минем**, **синең**, **безнең**, **сезнең**, the possessive suffix may be omitted.

Note also that the *case endings* used with nouns plus the possessive suffix of the 3rd person singular are joined to **каршы** either directly or with the possessive suffix **+сы**, i.e., каршына, каршысына, каршында, каршысында, каршыннан, каршысыннан. When joined directly, final **ы** of **каршы** functions as the possessive suffix.

1. **каршы** means

a) 'against' (indicating opposition, protest):

- Фәтхи **моңар каршы** ләм-мим сүз әйтмәде. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Fätkhi did not say a single word against this.
- Бу юлы аның чыгышы аерым кешеләргә, Әхмәт һәм **миңа каршы** төбәлгән. (ibid.) This time, his speech was directed against specific people, (against) Äkhmät and me.
- **Кояшка каршы** өйләрнең тәрәзә капкачлары ябык. (Г. Ибраһимов, Көтүчеләр.) The shutters of the houses are closed against the sun.
- Ул аларга су уңаена гына йөзүнең ансат булуын, әмма **суга каршы** йөзүнең башкачарак икәнен төшендерергә тырышты. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) He tried to make them understand that just swimming with the stream (lit., water) was easy, but that swimming against the stream (water) was something else.

b) 'at' (position at):

- **Өстәлгә каршы**, аңа аркасы белән, нидер язып утырган ак күлмәкле егет аның ишектән килеп керүен сизенмәде булса кирәк, ... (ibid.) The young man in a white shirt, sitting at the table with his back towards him and writing something, must not have noticed that he entered (lit., his coming through the door), ...

(For булса кирәк see 1010.)

c) 'opposite' (both position at and movement to):

- Менә шул **сазлыкка каршы** гына кечкенә вә бик иске бер өйнең бер бүлмәсендә, хатыны вә бер баласы белән, искече бер карт ... тора иделәр. (Шәриф Камал, Ата.) In one room of a small and very old house, just opposite that (same) swamp, an old junkman was living with his wife and one child ...
- Уңда һәм сулда **бер-берсенә каршы** ике ишек. (Габдрахман Минский, Язның беренче көне.) On the right and on the left there are two doors opposite each other.
- Ул арада егетләрнең **берсенә каршы** зәңгәр күлмәкле, ал яулыклы, яшел алъяпкыч япкан бер кыз чыкты. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) Meanwhile, a girl in a blue dress (and) a pink scarf, and a green apron on, stepped opposite one of the young men.
- Шәпеш хәлфә өстәл янына килеп **балаларга каршы** утырды ... (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) The teacher Shäpesh came to the table and sat down opposite the children ...

d) 'to' (indicating cause):

- Әлфиянең **гаҗәпләнүенә каршы**, бу нәрсәләр Сафура өчен яңа түгел. (Атилла Расих, Сынау.) To Älfiä's surprise, these things are nothing new for Safura.

· Compare also: үкенечкә каршы ‘to (one’s) regret’; бәхеткә каршы ‘fortunately’; бәхетсезлеккә каршы ‘unfortunately’.

e) ‘to’ (concerning, regarding):

· – Әллә сөйлисеңме? Сафинның бу **соравына каршы** Игнат бер генә сүз белән җавап бирде: – Сөйлим. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) “Shall you speak?” To this question of Safin’s Ignat replied with only one word: “Yes.” (lit., “I shall speak.”).

f) ‘towards’ (indicating time):

· Кояш түбәнәя, күк йөзе ачык, һава саф, бөтен дөньяны **кичкә каршы** гына була торган бер рәхәт тынлык чолгый. (Галимҗан Ибраһимов, Диңгездә.) The sun is going down, the sky is clear, the air clean, a serene tranquillity, which (usually) occurs only towards evening, envelops the whole world.

· **Төнгә каршы** Красноборга барып җиттем. (Мирсәй Әмир, Киңәш.) Towards night I arrived at Krasnobor.

g) ‘for’ (in return):

· Мин аңар аз-маз бурыч биргәләп торганым бар. **Шуңар каршы** ул да миңа шактый файда иткәләде. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) I have been giving him small loans from time to time. For that (in return) he too has repeatedly been rather useful to me.

h) ‘before’ (indicating time):

· Май **бәйрәменә каршы** төнне Хафизның һич онытасы юк. (Барлас Камалов, Ялыкмаслар.) Khafiz is not going to ever forget the night before the May Day celebrations.

(For the participle in **-асы**, **-әсе**, **-ыйсы**, **-исе** plus **бар** or **юк** see 1129, 1. a-d, 2.; 1130 1133.)

Note also: яңа **елга каршы** төндә ‘on New Year’s eve’.

· Августның 14 еннән 15 **енә каршы** төндә ... (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем элмәге.) During the night of August 14 to August 15 ...

i) in figurative speech:

· – Менә егет иде, мескен. Өч **кешегә каршы** эшли иде бит ул, – диде Насрый. (Шәриф Камал, Козгыннар оясында.) “He was a good fellow, the poor soul. He did the work of three men, he did,” Nasri said.

2. **каршына**, **каршысына**.

a) ‘opposite’, ‘towards’ (indicating movement to):

· Кабинетның ... зур **тәрәзәсе каршына** чүлмәкләр белән берничә гөл утыртылган ... (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) Opposite the large window ... of the office pots have been placed with a few flowers in them ...

· Сафин өстәл артына, Сабиров **аның каршысына** утырды. (ibid.) Safin sat down behind the desk, Sabirov sat down opposite him.

· ... үз урамына борылуга, **Кадыйр каршысына** килүче Зөһрәне күрде. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Хәтер ярлары.) ... the moment he turned into his own street, Qadir saw Zöhrä coming towards him.

b) ‘to’, ‘before’, ‘towards’ (indicating movement to, movement into the presence of):

· ... Мәгъсүмә яңадан бүлмәгә керде һәм бик арыган, талчыккан кыяфәт белән **өстәл каршына** килеп утырды, ... (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) Mäghsümä again entered the room and, with a very tired, weary look, came to the table and sat down, ...

· Без икенче катка күтәрелеп, бизәкле **ишек каршысына** килеп туктадык. (Миргазиян Юныс, Тозлы җил.) We walked up to the second floor and stopped (lit., came to and stopped) in front of an ornamented door.

- Мин тетрәнеп киттем. Әйтәм аны, җир астыннан чыккандай, кинәт кенә **каршыма** килеп басты. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) I began to shake. I tell you, he suddenly stepped in front of me as if by magic (lit., as if he emerged from the ground).
- ... күрше өстәлдәге бер кыз **Зөһрә** белән **Табибә каршына** уймак кадәре генә кечкенә чынаякларга салынган кофе китереп куйды. (Кояш Тимбикова, Агым уртасында.) ... a girl at the next table brought coffee in cups as small as a thimble and placed it before Zöhrä and Tabibä.

3. **каршында**, **каршысында**.

a) 'opposite', 'before', 'in front of', 'at' (indicating position at a place; in the presence of):

- Көзгегә баксам, **каршымда** ыспай гына бер егет басып тора. (Диләрә Зөбәерова, Куш өянке шаһит.) I look into the mirror; there is a rather elegant young man standing before (opposite) me.
- ... **Өстәл каршында** аңа арты белән утырганы кинәт борылды ... (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) ... the one sitting at (before) the table with his back towards him, suddenly turned around ...
- Якуп бик арып кайтты. Ул мичкә ягарга, **ут каршында** утырырга бик ярата иде. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) Jacob returned very tired. He loved very much to light the stove and sit at the fire.
- Энебездән сорау алырга тотындык. Менә ул, гаепле кыяфәттә башын иеп, **каршыбызда** басып тора. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) We began to question our little (lit., younger) brother. There he was standing before us, hanging his head in a posture of guilt.
- Гомереңне үткәрмә син юкны теләп,
  **Хак каршында** кабул булмас мондый теләк.
  (Мәҗит Гафури, Ярканат белән карлыгач.)
  Don't you spend your life wishing the impossible
  (wishing a senseless thing),
  Such a wish will not be acceptable before God
  (in the eyes of God).
- Тукта, чү! Ямьсез тавышлы Әллә нәрсә кычкыра. Сискәнеп безнең егет Катып кала аягүрә, Аңламастан, **каршысында** Әллә нинди «ят» күрә. (Габдулла Тукай, Шүрәле.) Stop, hark! Something is howling With a horrible voice. Startled, our youth Stands petrified, At a loss to understand, he sees before him, something "strange".
- Мине дүртенчедән туры алтынчыга күчерделәр. Бу хәл минем күңелемне дә, **малайлар каршында** дәрәҗәмне дә күтәреп җибәрде. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч.) They moved me from the fourth grade directly up to the sixth grade. This event raised my spirits (lit., heart) as well as my standing with the boys.

b) 'with', 'in', 'at' (an institution, etc.):

- **Бүлек каршында** оештырылган әдәбият түгәрәгенең эше торган саен җанлана бара. (Казан утлары но. 5, 1971.) The activity of the Literary Circle established with the department is getting more and more lively.
- Татар дәүләт академия **театры каршында** башта «Программа-Мәҗмуга», соңрак «Тамашачы» исемле махсус театр журналы чыга башлый. (Татар совет театры, Кереш.) At (i.e., under the direction, management of) the Tatar State Academy Theatre a special theatre journal began (lit., begins) to appear, first under the name "Program-Almanac", later "Spectator".

c) 'against' (facing, be faced, confronted with):

- Каеннар сары яфракларын җиргә түшәгәннәр, сирәк-мирәк кенә шәрә нечкә тармакларда сары, көрән яфраклар тирбәлә, алар ятим, кызганыч, ачы **җилләр**

**каршында** чарасыз булып тоелалар. (Мәдинә Маликова, Фидая.) The birch trees have spread their yellow leaves on the ground. The sparse yellow and brown leaves on the bare, thin twigs are quivering. They are orphans, pitiful. They seem forlorn, facing the piercing winds.

4. **каршыннан**, **каршысыннан** 'from (in front of)', 'past', 'by', 'opposite' (indicating movement):
   · Марина да **көзге каршыннан** борылып, Мәрвия чакырган кызны көтеп алды. (Кояш Тимбикова, Агым уртасында.) Marina too turned around from (in front of) the mirror and awaited the girl whom Märwiä had invited.
   · – Котбетдин абый, әле генә **каршыгыздан** узып барадыр идем ... (Габдрахман Әпсәләмов, Күк күкрәр.) "Qotbetdin, I was just going past your place (lit., past you) ... " (**-дыр**, **-дер**, **тыр**, **-тер**, see 980).
   · Чыннан да төш урталарында безнең **тәрәзә каршыннан** гына атка атланган берничә кеше узып китте. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) And indeed, around noon, several men on horseback passed just by our window.
   · – Әйдә, утырыгыз әле, – диде карт ... Үзе Фәрит урынына утырды, Рәмзигә **каршысыннан** урын күрсәтте. (Атилла Расих, Сынау.) "Come, sit down, please," the old man said ... he himself sat down in Färit's place, (and) to Rämzi he offered a seat opposite him.

**[540] янәшә**. This postpositional word is used in its basic form as well as with possessive suffixes plus the dative, locative, or ablative case. Used in its basic form, it governs the dative. With possessive suffixes and case endings, it requires the nominative of nouns, the genitive of personal and demonstrative pronouns.

1. **янәшә** means '(close) beside', 'side by side', 'next to':
   · Казарманың һәрбер урынында чәй эчүләр башланды. Менә Сибгать **бабайларга янәшә** генә, яшь кенә хатынлы һәм кечкенә балалы берәү кәефләнеп чәй эчә. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) At every place in the barracks tea drinking has begun. Here, just next to the old Sibghäts, someone with a rather young wife and small child is enjoying tea.
   · Дерибас урамына җиткәндә ашханәләр ачыла башлаган иде инде. Зур **универмагка янәшә** бер ашханәгә чәй эчәргә кердем. (Миргазиян Юныс, Тозлы җил.) When I reached Deribas Street, the restaurants had already begun to open. I went into a restaurant next to a large department store to have tea.
   · Порт Сәид артта калды. Инде өч сәгать каналда барабыз. ... Уңда, Африка ягында, **ярга янәшә** асфальт юл сузылган. (Миргазиян Юныс, Юлда уйланулар.) Port Said remained behind (us). We had already been traveling on the (Suez) Canal for three hours. ... On the right, the African side, an asphalt road ran beside the bank.
2. **янәшәсенә** 'beside' (indicating movement close to the side of a person or thing):
   · ... машинаның арткы урынында Михсеевның юлдашлары, мине уртада калдырып, икесе ике ягыма утырдылар. Михсеев үзе **шофер янәшәсенә** урнашты. (Гурий Тавлин, Афәт.) ... in the back of the car, Mikhseyev's two companions sat down, one on either side of me, leaving me in the middle. Mikhseyev himself took a seat beside the chauffeur.
   · З. тукталышында, ..., бер өер яшьләр керде. Урыннар буш иде, ..., **янәшәмә** дә, каршыма да утырыштылар. (Мирсәй Әмир, Балыкчы ялганнары.) At the Z. stop, ..., a crowd of youths entered (i.e., entered the railway carriage). There were seats vacant, ..., (and) they sat down together beside me and opposite me.

3. **янәшәсендә** ‘beside’ (indicating position or movement close beside):

- Иркен, бай өйдә, ялкынланып янган **учак янәшәсендә** алар икәүдән-икәү генә утырдылар. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) In the spacious, rich (i.e., richly furnished) house they both sat together alone beside the brightly burning fireplace.
- Зур зал. Без барып кергәндә, анда ... Минһаҗ Сәйфи, **аның янәшәсендә** озын кара чәчле, кыскартылган кара мыеклы, таза гәүдәле бер кеше утыра иде. (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Тимер Алюк.) A large hall. When we entered, Minhaj Seyfi, (and) beside him a strongly built man with long, black hair and short-trimmed moustache, were sitting there.
- Сөмбел каршылык күрсәтмәде, тын гына **аның янәшәсендә** атлый бирде. (Разил Вәлиев, Иске сәгать дөрес йөри.) Sömbel did not resist. She kept walking silently beside him.

4. **янәшәсеннән**

a) ‘beside’ (indicating movement beside, side by side):

- Салих минем якка чыкты, ләкин аз гына ара калдырып **янәшәмнән** атлады. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) Salikh came to my side, but he walked beside me, leaving a little bit of space (between us).
- Күзгә күренү белән ике ягыннан ике эт ташланды. Җайдакны аты белән бергә тотып ашардай булып, өрә-өрә **янәшәсеннән** чабалар, ... (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) The moment he appeared, two dogs came rushing out from two sides. As if ready to devour the rider together with his horse, they kept running beside him, barking, ...

b) ‘beside’ (indicating movement past or away from a person or thing):

- Җитәкләшкән кулларын да ычкындырмый, **янәшәмнән** узып киттеләр. (Ринат Мөхәммәдиев, Кенәри – читлек кошы.) They walked past me hand in hand, without even letting go of one another’s hands.

## Postpositions Governing the Dative

**[541] бинаән** ‘on the basis of’, ‘by virtue of’, ‘by dint of’, ‘through’ (Arabic: banā ‘to build, erect’, binā’an ‘alā ‘on the basis of’, ‘by virtue of’):

- – Менә шушы **сәбәпләргә бинаән** без сезгә: ... дибез. (Фатих Әмирхан, Мөтәгассыйп Казан татарларына ачык хат, 1907.) “It is for these reasons (by virtue of these reasons) that we say to you: ...” (мөтәгассыйп – arch. ‘fanatic’).
- ... шул шаян хат-газета, көтелмәгән берәр **могҗизага бинаән** кайдадыр сакланган булып, бүген миңа аны күрергә туры килсә? Ихтимал, хәзер тасвирланганга туры килеп бетмәгән урыннары да табылыр иде. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч, 1979.) What if by dint of some unexpected miracle that satirical newsletter ... has been preserved somewhere and I should see it today? Probably, one would find (in it) some spots which do not quite correspond to what I have described now.

*Note:* In today’s Tatar literary language бинаән is used infrequently.

**[542] гаит** /ɑaid/ (arch. ‘about’, ‘regarding’, ‘concerning’ (Arabic: ‘āda ‘to refer, relate to’):

- Җөмлә фикрем кичә-көндез **сезгә гаит**, милләтем. (Габдулла Тукай, Милләтә, 1906.) In contemporary Tatar: Барлык уем /ujьm/ кичен дә, көндезен дә сезнең турыда, милләтем. Day and night all my thoughts are about you, my nation. (милләтә-милләткә).

- «Заманымызның әдип вә **мөхәррирләренә гаит»** мәкаләсенә гаит. (ibid., heading of an article, 1906.) In contemporary Tatar: «Заманыбызның язучы һәм журналистлары турында» дигән мәкалә турында. About the article “About Writers and Journalists of Our Times”.

**[543] даир** (arch.) ‘regarding’, ‘concerning’; (Arabic, dâ‘ir ‘turning’, ‘revolving’):
- ... ул хикәятләр вә мәкальләр һәркайсы **әхлакка** вә **мәгыйшәткә даир** булган сүзләр иде. (Закир Һади, Бәхетле кыз, 1904.) ... every one of those stories and proverbs were (words) concerning ethics and everyday life (мәгыйшәт – тормыш).

**[544] караганда** (past participle in the locative of кара ‘look’).
‘judging by’, ‘according to’:
- Ул үзен шул тирәдәге бер авылның мулласы итеп танытты. **Кыяфәтенә караганда**, чыннан да мулла төсле иде ул. (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Мөхәммәт Бикбулатов.) He introduced himself as the mulla of a village in that area. Judging by his appearance, he really looked like a mulla.
- Профессорның **сөйләвенә караганда**, сынаулар әле тагын җәелергә ... тора. (Атилла Расих, Сынау.) According to what the professor says, the experiments are about to be extended still more ...
- Һава торышы турындагы соңгы **мәгълүматларга караганда**, безгә каршы көчле давыл килә. (Рафаэль Мостафин, «Оҗмах»ка сәяхәт.) According to the latest weather report (lit., report about the weather situation, state of the weather), a strong storm is coming towards us.

**[545] карамастан** (negative future participle in the ablative of кара ‘look’) ‘despite’, ‘in spite of’:
- Ул, яшь **булуына карамастан**, байтак кына нәрсәне белә ... (Фатих Хөсни, Утызынчы ел.) Despite her being young, she knows quite a lot of things ...
- Шулай **үзгәрүгә карамастан**, ул миңа борынгы вакыттан да матур һәм сөйкемле күренде. (Мәҗит Гафури, Кара йөзләр.) In spite of having so changed, she appeared to me still more beautiful and charming than in the old days.

**[546] карап** (verbal adverb of кара ‘look’).
a) ‘towards’ (indicating direction):
- Без һаман бөек диңгез өстеннән кыйбла **якка карап** барабыз. (Галимҗан Ибраһимов, Диңгездә.) We are still traveling over the great sea towards the south.
- Менә шушы юл буенча **көнчыгышка** – Иртыш **ягына карап** китсәң, Көктугайга барып чыгасың. **Көнбатышка карап** китсәң, кая барып чыгасың? (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) If you travel along this road (here) towards the east, towards the Irtysh, you get to Köktughai. If you travel towards the west, where do you get?

b) ‘according to’ (in proportion to):
- **Юрганыңа карап** аягыңны суз. (Proverb) Cut your coat according to your cloth (lit., Stretch your feet according to your blanket).
- Бер йортта эшне бетерәбез дә икенчесенә күчәбез. Кайсында бер кич кунылa, кайсында икене, өчне. Эшнең **бетүенә карап.** (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) We finish work in one house and move on to the next. In some one night is spent, in others two, three – according to when the work is finished.

c) ‘by’, ‘according to’ (as stated or shown by):

- ... күп очракта без кеше турында аның тышкы **кыяфәтенә карап** хөкем йөртәбез ... (Мәгъсүм Насыйбуллин, Телсез шаһитләр.) ... in many cases, we judge (about) people by their appearance ...
- **Хәрәкәтләренә карап**, өйгә керүченең әби икәнен чамаладык. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) By her movements (i.e., by the manner in which she moved), we guessed that the one entering the house was the grandmother.

d) ‘by’ (indicating means):

- – Ай саен төяп килмәсә ни, минем әле яңадан сукмаган бер әвен арышым бар, ... – Юк инде, абый, авылда тормаган кешегә әйт син аны, ..., син инде шул бер әвен **арышыңа карап** яңа икмәккә кадәр ачлы-туклы торасың, ... (Мөхәммәт Гали, Кала кешеләре.) “If I can’t bring a load (i.e., a load of oats to sell in the city) each month (of the year), so what. I still have one barn of rye not yet threshed ...” “No way, brother, you tell that to people who haven’t lived in the country (lit., village), ..., you really live by that one barn of rye, half-strarving until the new crop, ...” (Әвен: a structure /barn, shed, etc./ equipped for drying grain before threshing.)

e) ‘on account of’ (on the basis of):

- Менә безгә ... очраган бер кеше **сүзенә карап** теләсә нинди дуамал адымнар ясаудан сакланырга кирәк. (Шәриф Камал, Матур туганда.) There, we must ... guard against taking any hasty steps whatsoever on the basis of the word of some man we have chanced to meet.

f) (most frequently with **аңа**, **аңар**, **шуңар**) ‘in spite of (that)’, ‘all the same’, ‘for all that’:

- Рәйхтрман ... йөгереп чыгып китте һәм каядыр качты. Фәйзулла аның артыннан куа чыкканда, ул югалган иде инде. Ләкин **аңа карап** Фәйзулланың ачуы басылмады. (Фатих Хөсни, Гармоньчы.) Reykhtrman ... ran out and fled somewhere. When Feyzulla, chasing after him, came out (from the house), he had already disappeared. But in spite of that (But nevertheless), Feyzulla’s anger did not abate.
- ... Нәсимәнең әнисе Гөлсем ханым Гәрәйгә кырын карый, кызының Гәрәй белән дус булуын теләми ... Нәсимә белән Гәрәй, **аңар карап**, әлбәттә, очрашмый калмыйлар, ... (Сафа Сабиров, Гәрәйнең бер җәе.) ... Näsimä’s mother, Lady Gölsem, looks askance at Gärey. She does not wish her daughter to be friends with Gärey ... In spite of that, Näsimä and Gärey continue, of course, to meet each other, ...
- Алар озак кына, матур гына итеп уйлаштылар, ләкин **аңа карап** аларның тамаклары туймады. (Фатих Хөсни, Гармоньчы.) They discussed (lit., thought) long and nicely together (how to earn some money), but for all that, they did not have enough to eat.
- Кичәнең программасы ... шактый күп нәрсә вәгъдә итә иде. **Шуңа карап**, әлбәттә, билет бәяләре дә түбән куелмаган. (Шәриф Камал, Таң атканда.) The program of the soirėe ... promised rather much. ... Therefore (Because of that), the ticket prices have not been set low, of course.
- Мәликә ханымны мәктәпкә чакырып, баласы өчен оялтудан туктамадылар. Малайга өйдә дә эләкмәде түгел. Ләкин ничек кенә каты булмасыннар, **аңа карап**, Мәликә ханымны мәктәпкә чакыру сирәгәймәде. (Фатих Хөсни, Моң.) They did not stop calling Mrs. Mälikä to the school and make her feel ashamed for her son. It’s not that the boy didn’t get it at home too. But however severe they were, calling Mrs. Mälikä to the school did not become less frequent.

*Note:* Карап may function as a conjunction meaning ‘because’, ‘still’ (in the sense of ‘notwithstanding’).

- Доктор бераз туктап тора да, тагы сүзендә дәвам итә: – ... Хәлең авыр икәнен үзем дә күрәм. Ләкин аңар бөтенләй бирелергә, корган планнарны бер кызның

**алдавына карап** болай җимереп ташларга ярамый. (Садри Җәләл, Дим буенда.) The doctor paused a little and then continued: "... That your condition is serious I can see myself. But to abandon yourself completely to it and to throw out (destroy) the plans which you made just like that – because a girl deceived you is not proper."

**[547] карата** (verbal adverb of карат 'cause to, make look').

a) 'to' (when addressing someone):

· Мин, турыдан-туры **үземә карата** куелган бу сорауга ни дип җавап бирергә белмичә, аптырап калдым. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) I was at a loss, not knowing what answer to give to this question, which was put directly to me.

b) 'regarding', 'concerning':

· Дөрес түгел, һәрхәлдә, **миңа карата** дөрес түгел. (Габдрахман Әпсәләмов, Идел хикәяте.) It is not true. At any rate, it is not true with regard to me.

· Мин үзем **иҗатыма карата** тәнкыйть сүзе ишетмәсәм дә, мине гел мактап килсәләр дә, тәнкыйтьне кирәк дип карыйм. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) Though I myself do not hear any words of criticism with regard to my (literary) works, and although they always acclaim them (lit., praise me), I consider criticism necessary.

· Бу **мәсьәләгә карата** Хәкимовның ныклап уйланылган планы ... бар. (Мөхәммәт Шәйми, Сынау.) Regarding this matter, Khäkimov has a thoroughly thought-out plan, ...

c) 'about' (concerning), 'towards' (in relation to), 'for', 'on' (with regard to, concerning):

· Вәлишинның эзен **югалтуга карата** да Хәкимовның фикере башкачарак икән. (ibid.) Also about losing trace of Wälishin, Khäkimov's opinion appeared to be somewhat different.

· Туган **телебезгә карата** мәхәббәт тәрбияли алган укытучы бәхетле укытучы ул. Кеше рухын тәрбияли алган укытучы ул. Рәмзия апаны мин әнә шундый укытучы дип саныйм һәм шуңа күрә дә без, аның шәкертләре, **аңа карата** күңелебездә рәхмәт хисе саклап йөрибез. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) A teacher who is able to instill love for the native language certainly is a lucky teacher. He (She) is a teacher able to educate (a person's mind). I consider Aunt Rämziä to be just such a teacher, and, therefore, we, her students, carry in our hearts a feeling of thankfulness towards her.

· Сәмитов тайгак юлда түгел ... Тыңлаусыз иде, үз сүзле иде ... **Яшенә карата** буйга-сынга да зур һәм тотрыклы булгангадыр, яшьтәшләренә өстәнрәк карау гадәте дә бар иде. (Барлас Камалов, Урамнар киңәя.) Sämitov was not straying from the straight and narrow ... He was recalcitrant, he was stubborn ... Perhaps because he was physically tall and strong for his age, he also had the habit of looking somewhat down on boys of his age.

· Бу оешма авылларда мәктәпләр, китапханәләр ача, төрле фәнни китаплар, бигрәк тә авыл **хуҗалыгына карата** файдалы булган нәрсәләрне бастырып тарата, юллар, күперләр төзәтә иде. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) This organization was opening schools (and) libraries in villages. It printed and distributed various scientific books, especially books which were useful for agriculture, (and) it repaired roads, bridges.

· ... Хәмит Госманов алдынгы укучылардан иде ... Шул чорга хас булган төрле мәүзугъларга аеруча әдәбият **мәсьәләләренә карата** язган мәкаләләрен ярата идем. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч.) ... Khämit Ghosmanov was one of the foremost students ... I liked his articles on various topics pertaining to that period, particularly, literary subjects.

d) ‘towards’ (in direction of):

- Мине иялртеп алып килгән танышым көлемсерәп **миңа карата** ишарә ясады да: – Менә кунак алып килдем сиңа, – диде, ... (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) My acquaintance, who had taken me with him, smiled and, motioning towards me, said: “Here, I have brought you a guest, ...”

**[548] каратып** ‘according to’ (verbal adverb of карат ‘cause to, make look’):

- – Менә бу әлифба ысуле мәтдиянең иң асат вә яңа **кагыйдәләренә** /qaɑʤidələrenə/ **каратып** тәртип кылынган нәрсә, – диде мөгаллим. (Шәриф Камал, Чуар манзара.) “This alphabet here is something which has been arranged according to the easiest and newest rules of the phonetic method,” the teacher said. (ысуле мәтдия ‘phonetic method’ – ысулы җәдит ‘new method’, i.e., the new phonetic method used at the beginning of this century to teach reading and writing with the Arabic alphabet. – асат – (vernacular) – ансат)

**[549] килгәндә** (past participle in the locative of кил ‘come’).
‘regarding’, ‘concerning’:

- ... аңа әллә нинди озын шигыйрьләр кирәкми ... инде ... Ун-унбиш юл җитә ... Язу **хакына килгәндә**, без анысын кызганмабыз. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) “... she does not need any long poems ... Ten or fifteen lines will do ... as to the writer’s fee (lit., writing fee), we shall not be stingy.”
- – Хәзергә әйтүе кыен /qьin/. Беренчедән, ул әле китмәгән, икенчедән, кемне сайлыйлар бит. Ә **үземә килгәндә**, минем өчен барыбер. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) “For now it is difficult to say. First of all, he has not gone yet. Secondly, whom will they elect then. But as far as I am concerned, it is all the same.”

**[550] күрә** (verbal adverb of күр ‘see’).
a) ‘according to’, ‘by’ (as stated or shown by; in agreement with, in proportion to):

- Хәсәннең **ишетүенә күрә**, бу кыз егетләргә бер дә игътибар итми торган ... киберле кыз иде. (Фатих Әмирхан, Урталыкта.) According to what Khäsän heard, this girl was a presumptious girl who did not pay any attention to (young) men ... (киберле – горур, эре, тәккәббер).
- **Сәгатемә** /səɑʤətemə/ **күрә**, сәгать өч. By my watch it is three o’clock.
- **Эшенә күрә** ашы дигәндәй, айлыгы – өч йөз-өч йөз илле сум. (Рәмзи Максудов, Шәйморза кешеләре.) One says one earns (lit., one’s meal is) according to one’s work – his monthly salary is three hundred, three hundred and fifty rubles.
- ... һәркайсы, үзенең **дәрәҗәсенә күрә**, сәдака җыйныйлар. Муллага егерме биш тиен икән, мәзингә егерме, мәхдүмгә унбиш. (Шәриф Камал, Матур туганда.) ... each of them collects alms in accordance with his rank. If for the mulla it is twenty-five kopecks, for the muezzin it is twenty, for the mulla’s son fifteen.

b) ‘at’ (in consequence of):

- Марзияның **кыставына күрә** ул, скамья читенә утырып ... (ibid.) Upon Marzia’s urging, she sat down on the edge of the bench and ... (скамья – эскәмия, утыргыч).

c) ‘for’ (considering):

- ... Казанда еш-еш мәдрәсәләр алмаштырганнан соң, 14-15 яшьлек үсмер **заманына күрә** алдынгырак саналган «Мөхәммәдия»дә ятып укый башлый. (Ибраһим Нуруллин, XX йөз башы татар әдәбияты, Галиәсгар Камал.) ... after frequently changing medreses in Kazan, the 14 or 15-year-old youth begins to live and study at the “Muhammediye” (medrese) which, for its time, was regarded as more progressive.

- Инде уникедә булсам да ... **яшемә күрә** буйга кечкенә һәм бик арык идем. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) Although I was already in my twelfth year (lit., in the twelve) ... I was small for my age and very thin.

d) 'because of':

- Мөбарәкне **юашлыгына күрә**, Бүләкне чаялыгы өчен сөя бугай ул. (Батулла, Сөембикә кыйссасы.) He (i.e., Khan Safa Gärey) loved Möbaräk because of his gentleness, Büläk for his boldness, it seems.
- – Анысында сүз да юк, Халыйк абзый. Тик әле башта икеләнебрәк җавап **бирүеңә күрә** кабатлап соравым. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) "That is not the issue, brother Khaliq. I am only repeating my question because, at first, you answered ( lit., because of your answering) somewhat hesitatingly."

e) 'therefore' (with the demonstrative pronoun шул):

- Галимҗан Хәнәфи белән ачуланышмаска, сүзгә кермәскә тырыша иде. **Шуңа күрә** ул сабыр гына җавап бирде. (Аяз Гыйләҗев, Үги ана яфраклары.) Ghalimjan was trying not to get angry, not to have words with Khänäfi. Therefore he answered patiently.

**[551] муафыйк** (Arabic) 'in accordance with', 'according to', 'corresponding to':

- Гайникамал картының һәр елны, гарәфә /ɑ͡ʒərəfə/ кич, шулай күңелсез була торган гадәтен белә вә шуңар күрә **шуңар муафыйк** төскә керә вә **хәлгә муафыйк** сүзләр генә сөйли иде. (Фатих Әмирхан, Бәйрәмнәр.) Gheynikamal knew her husband's (lit., her old man's) habit of being melancholy like that every year on the eve of a religious holiday, and, therefore, she assumed a mien corresponding to that and said only things suited to the situation.
- **Максатка муафыйк**. According to the aim.

**[552] таба**, **табан**

a) 'to', 'towards' (in the direction of):

- Яшькелт-соры төстәге машина ... тимер капка аша чыгып аэродром **ягына таба** юл алды. (Разил Вәлиев, Яшисе килә.) The greenish-gray car ... left through the iron gate and took the road to the airport.
- Иделнең уң ягындагы җирләрне – **көнбатышка таба** Зөя елгасына кадәр һәм **көньякка таба** хәзерге Тәтеш шәһәренә кадәр булган җирләрне дә Казан ханлыгының төп җирләре исәбенә кертергә мөмкин. (Татарстан АССР тарихы.) The territories on the right bank of the Volga, to the west as far as the river Sviyaga, and the territories to the south as far as the present town Tetyushi can also be included in the original territories of the Khanate of Kazan.
- Ул ... **Халикъка таба** иелеп, аның белән озак кына сөйләште ... (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) He ... bent over towards Khaliq and talked with him for a rather long time.
- Без акрынлап кына **өйгә табан** атладык. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) We walked slowly towards the house.

b) 'towards' (indicating time):

- **Төшкә таба** күк йөзе ачылып, көн бөтенләй аязып китте ... (Фатих Хөсни, Авыл өстендә йолдызлар.) Towards noon the sky (lit., the face of the sky) brightened up, and the day became completely clear ...
- Урак өсте җиткәндә халык шактый иркен сулый башлаган иде инде. **Җәй азакларына, көзгә таба** авыл җанланганнан-җанлана, ямьләнгәннән-ямьләнә барды. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) When the harvesting (time) was approaching, the people had already begun to breath rather freely (i.e., because the

harvest would end the lack of grain). Towards the end of summer and the (beginning of) autumn, the village became more lively, more pleasant.

**[553] хилаф** (arch.) 'against', 'contrary to', 'despite', 'notwithstanding' (khiläf /Arabic/ 'contrast', 'contrariety'):

- ... Зина, Хәсәннең **теләвенә хилаф**, аз сөйли, ... иде. (Ф. Әмирхан, Урталыкта, 1912.) ... contrary to Khäsän's desire, Zina was saying little, ...
- Чәй куелды ... **гадәткә хилаф** уларак, минем алдыма бер шакмак шикәр дә куйдылар. (Габдулла Тукай, Исемдә калганнар, 1909.) Tea was served ... as an unusual thing, they put before me also a cube of sugar. (уларак, arch. буларак)

**[554] якын**. As an adjective, якын means 'near', 'close by'. When functioning as a postposition, it means

a) 'nearly', 'about', approximately':

- Бу – уртача тизлек сәгатенә 35 **километрга якын** дигән сүз. (Мәгъсүм Гәрәев, Җиңелмәс капитан.) This means that the average speed is approximately 35 kilometers per hour.
- Разия. Әйдә, Әнвәр, уз. Безгә инде синең ике **айга якын** килгәнең юк. (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Raziä. Come on in, Änvär. You haven't come to see us for nearly two months now.

b) '(approximately) like' (similar to):

- Халикъ **ышануга якын** мәгънә аңлата торган тавыш белән Нәгыймнең сүзен җупләде (хуплады). (Шәриф Камал, Матур туганда.) With a voice indicating something (lit., a meaning) like belief, Khaliq approved of Näghim's words.
- Бу хатның кемнән икәнлеген Мәдинәнең йөрәге шунда ук сизде. Ләкин шатланудан бигрәк аның йөрәгендә **куркуга якын** бер тойгы туды. (ibid.) In her heart Mädinä sensed (lit., Mädinä's heart sensed) right away from whom this letter was. But rather than joy, there arose in her heart a feeling like fear.

## Postpositions Governing the Nominative and the Ablative

**[555] соңра** (соң 'end'; 'late').

**Соңра** is a dialect word[1] which, as an adverb, means 'afterwards', 'then', 'later'. As a postposition meaning 'after', **соңра** was used in the older Tatar literary language. In today's Tatar literary language it is no longer used in this function, its equivalent being **соң** (see 567).

When governing the nominative, соңра indicates order, with the ablative it indicates time:

- Өч-дүрт бүре **берсе соңра** кача берсе,
  Өченчесе, **аннан соңра** дүртенчесе ...
  (Габдулла Тукай, Кәҗә белән сарык хикәясе, 1910.)
  The three or four wolves are taking flight one after the other,
  The third one, after that the fourth ...

---

1) See T.T.A.C., volume 3, p. 665.

- – Безне Орски ягына ... барырга кушалар. – Кайчан китәргә. – **Иртәдән соңра** китәргә. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында, 1929-1931.) "They are ordering us to go to Orsk ... When are we to leave?" "We are to leave after tomorrow."

*Note:* **соңра** is the only postposition governing these two cases.

## Postpositions Governing the Dative or the Ablative

**[556] кала** (verbal adverb of кал 'remain', 'stay').

1. When governing the dative, кала means

a) 'from' (indicating distance):

- Әниләре яшәгән **йортка** йөз илле-ике йөз **метрлар** чамасы **кала**, урам чатында тукталды машина. (Ринат Мөхәммәдиев, Кенәри – читлек кошы.) The car stopped at the street corner, about one hundred fifty or two hundred meters from the house in which her mother lived.
- Мин **Алмайга** биш-алты **чакрым каларак** Идел аръягына борылам. (Сает Шәкүров, Сәхнәнең кыл уртасында.) I am turning off to the other side of the Volga, about five or six versts before Almai.

(For postpositions with **+рак**, **+рәк** see 572.)

b) 'before', 'to' (indicating time before):

- Яңа ай **башына** ярты тәүлек **кала** ул да ... кузгалырга булды. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) Half a (twenty-four-hour's) day before the beginning of the new month (or: new moon), he too decided to set out.

(For **°-рга**, **°-ргә** with **булу** see 1159).

- Сәгать **алтыга** ун минут **кала**. At ten minutes to six.
- ... бәйрәмгә дүрт-биш **көн кала**, мәктәп ишегалдына аклы-каралы шакмаклар төшерелгән машина килеп туктый. (Газиз Кашапов, Җир җылысы.) ... four or five days before the holiday, a black and white checkered car pulled into the schoolyard (lit., comes into and stops).

2. When governing the ablative, **кала** means

a) 'next to' (indicating order):

- Ул чорда Кави Нәҗми минем өчен, **Такташтан кала** – бәлки аның белән бер дәрәҗәдә үктер әле – иң кызыклы язучы булгандыр. (Мирсәй Әмир, Казан.) Next to Taqtash – perhaps even in the same degree as he (lit., with him) – Qawi Näjmi was for me at that time probably the most interesting writer.

*Note 1:* Кави Нәҗми (1901-1957). Tatar novelist and poet, author of numerous literary works.

*Note 2:* Һади Такташ (1901-1931). One of the most outstanding Tatar poets, who also excelled in the fields of dramatics, prose, literary criticism and journalism. One of his most renowned works, his tragedy «Җир Уллары» ("Sons of the Earth"), is based on the biblical story of Cain and Abel. Written in a poetic form, it was first performed in 1923. Despite the comparatively short span of time of his literary activities, Taqtash had a deep influence on the subsequent development of Tatar literature.

- **Аттан кала** безнең мәкальләрдә безгә файдалы сыер, сарыклар иң күп урынны алырга тиеш кебек булса да, эт ала. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) Although it would appear that, next to the horse, cows (and) sheep, which are useful to us, should take the foremost place in our proverbs, the dog takes it.

(For **кебек** with conjugated verbal forms see 576.)

b) 'except for':

- Әйләнә-тирәдә дулаган җил-буран **тавышыннан кала**, башка тавышлар юк иде. (Гурий Тавлин, Буран.) Except for the sound of the wind and the blizzard raging all around, there were no other sounds.

- Бераздан Оля: – Ирек, нигә мине рәнҗетәсең? – диде. – Минем **синнән кала** бер якын кешем дә юк бит. (Гурий Тавлин, Афәт.) After a little while, Olya said: "Irek, why do you hurt (offend) me? After all, except for you, I have no one else who is close to me."

## Postpositions Governing the Ablative

**[557] алып** (verbal adverb of ал 'take', 'receive').

a) 'from', 'from ... on', 'since' (indicating the beginning at a specified time):

- Шул **көннән алып** без аның белән йөрешә башладык, ... (Галимҗан Ибраһимов, Табигать балалары.) From that day on he and I began to date each other, ... (lit., we, i.e., I, began to go with him).
- Икенче айның **башыннан алып** хезмәт хакымны сиксән сумга, берничә айдан соң йөз сумга кадәр җиткерделәр. (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Гыйниятулла Терегулов.) From the beginning of the second month, they raised my salary to eighty rubles and after a few months, to a hundred rubles.

b) 'from' (with a specified point or time as the first of two limits; with a specified quantity, measure, etc. the lowest of two amounts):

*Note:* **алып** is often used in conjunction with the postpositions **кадәр**, **тикле**, **хәтле**, **чаклы** to form pairs denoting 'from ... to', 'from ... till/until'.

- **Урамнан алып** инешкә төшеп җиткәнче, алабуга, кычыткан, әрекмән басып бетергән буш җир җәелеп ята. (Әмирхан Еники, Туган туфрак.) A vacant lot (parcel of land), which is completely overgrown with goosefoot, stinging nettle and burdock, stretches from the street until it reaches the brook.
- ... ул шушы тәрәзә янына бер утырып, бер торып аны көтте. **Иртәдән алып** төнгә хәтле көтте. (Шәриф Камал, Матур туганда.) ... she waited for him, now sitting down, now standing at this window. She waited for him from morning till night.

(For бер ... бер see 651).

- Һәммә кеше иртә үк торган. **Картлардан алып**, бала-чагаларга кадәр, хәлле хәленчә киенгәннәр. (Мөхәммәт Гали, Сабан туенда.) Everybody has got up early. From the old folks to the children, they have dressed according to their (financial) means.
- Бугазның ... тирәнлеге егерме җиде **метрдан алып** йөз егерме метрга кадәр. (Миргазиян Юныс, Истамбул һәм Сүәеш каналы аша Ямәнгә сәяхәт.) The strait's ... depth is from twenty-seven meters to one hundred and twenty meters.

**[558] ары**

a) 'beyond' (farther away than; on the far side):

- **Тымызыктан ары** Наҗар киңрәк сулар күрде – Кама, Бөек Идел. (Әхсән Баянов, Аргы яр.) Beyond the (river) Tymyzyq, Najar saw wider rivers (lit., waters) – the Kama, the Great Volga.
- – Миңа **моннан ары** барырга рөхсәт юк. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) "I am not allowed to go beyond this (point)."
- Алда буа, буада иске тегермән ... **тегермәннән ары** ферма каралтылары күренә. (Әмирхан Еники, Туган туфрак.) In front there is a pond (i.e., a pond created by damming a brook, etc.), on the pond there is an old mill ... beyond the mill, farm buildings are visible.

b) 'from' (indicating distance from, beyond a point):

- **Бездән** ярты гына чакрым **ары** Каенлык дигән авыл бар иде ... (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) Just half a verst from us (i.e., from our village) was the village of Qayynlyq /Qajьnlьq/ (Birch Grove) ...
- Урман **бездән** ике-өч чакрымнар **ары** иде. (ibid.) The forest was about two or three versts from us (i.e., from our village).

c) 'after', 'beyond' (in a specified time):

- – Мин үз фикеремне яклаучыларны табармын! Ә сезгә соң булыр, үкенерсез. Уйлагыз, – диде Юлдашев. **Шуннан ары** инде аларның гәпләре алга тәгәри алмады. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) "I shall find people who will support my opinion! But for you it will be too late, you will regret it – think," Yuldashev said. After that their talk could no longer move forward.
- – Унбиш-егерме **елдан ары** бармас, минемчә, – диде Гыйльманов. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) "In my opinion it will not go (i.e., last, continue) beyond fifteen or twenty years," Ghilmanov said.

d) 'beyond' (surpassing, exceeding, past the limits):

- Ул туп-туры әйтте: – Синдә өмет бар, Ахунов. Хикәя өчен кирәкле вакыйга тапкансың. Ләкин осталыгың шул вакыйга **табудан ары** узмаган. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) He put it straight to me: "You have prospects (of success), Akhunov. You have found a suitable plot for the story. But your proficiency has not gone beyond finding that plot."
- Борис белән аралар һаман ... суына бара. Рәсми **сөйләшүдән ары** китеш юк. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) (His) relations with Boris continue to ... cool. They do not go (lit., there is no going) beyond official communication.
- Белеме дүрт **сыйныфтан ары** узмаган ... (Нурихан Фәттах, Кичү.) His (formal) education did not go beyond the fourth grade (lit., beyond four classes) ...

e) 'more' (with a connotation of 'beyond'):

- Бераз вакыт сүзсез генә эшләгәч, картәтәй үз алдына зарланып куйды. – Юкагач ташуы авырайды, – диде. – Бер барганда **биш-алтыдан ары** күтәреп булмый. Бик бирештем быел, улым. (ibid.) After working silently for a little while, Grandpa, talking to himself, complained: "Fetching lindentrees has become difficult. I can't carry more than five or six at a time (i.e., each time he goes). I have grown very weak this year, my son." (Reference is to very young trees.)

*Note:* картәтәй – Минзәлә (Menzelinsk) and Оренбург (Orenburg) dialect – бабай.

- – Аңа кара ... Кем аңа кырык бишне бирер? **Утыз биштән ары** бирәү дә бирмәс. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) "Look at her ... Who would say that she is (lit., Who would give her) forty-five? Nobody would think her (lit., give her) more (i.e., older) than thirty-five."
- Хәсән. Үткән ел йомыркалардан гына егерме мең сум алдык. Гаделша. Егерме мең, ә? Менә бит ул акча кайда ята. Егерме! Моны алу өчен бит йөз **гектардан ары** иген игәргә кирәк. (Риза Ишморат, Серле моң.) Khäsän. Last year we made twenty thousand rubles on eggs alone. Ghädelsha. Twenty thousand you say? It's here where the money is! Twenty (thousand)! Why, to earn that much, you have to grow more than one hundred hectares of grain.

**[559] башка** (башка 'other'; баш 'head'); 'besides', 'except', 'without':

- Анның чыгып китүен **миннән башка** берәү дә күрмәде ... (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Nobody besides me saw him leave ...
- – **Җомгадан башка** көннәрнең кайсы да ярый миңа. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) "Any day except Fridays suits me."

- Тын урманда чаңгыларның җиңелчә **чыжлавыннан башка** һичнәрсә ишетелмәде. (Габдрахман Әпсәләмов, Зәңгәр иртә.) Except for the light swishing of the skis, one heard nothing in the quiet forest.
- – ... синең **ризалыгыңнан башка** ул дәү эшне эшләп булмый. (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) "... without your consent it is impossible to do that big thing."

(For the verbal adverb in **°-п** with **булу** see 1258.)

- – **Синнән башка** көн юк миңа, Рокыя ... (ibid.) "Without you life (lit., the day) is nothing for me, Röqiä."

**[560] башлап** (verbal adverb of башла 'begin').

a) 'from', 'from ... on', 'since' (indicating the beginning at a specified time):

- XV гасыр **азагыннан башлап** Казанда даими ике базар булган. (Татарстан АССР тарихы.) From the end of the 15th century on there were two permanent markets in Kazan.
- – Кайчан юлга чыгабыз? – Августта. Көнен бергәләп ачыкларбыз. Шул **көннән башлап** күңелем белән Казанда идем инде. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч.) "When are we going to leave?" "In August. We'll fix the day together." From that day on I was in my mind (lit., heart) already in Kazan.
- Шул **еллардан башлап**, Мәрьям апа һаман укытучы булып килде. (Мирсәй Әмир, Күңелле сәяхәт.) Since those years (my) older sister Märyäm has always been a teacher.

b) 'from' (with a specified point or time as the first of two limits).

*Note:* **башлап** is often used in conjunction with the postpositions **кадәр**, **тикле**, **хәтле**, **чаклы** to form pairs denoting 'from ... to', 'from ... until/till':

- Очраклы юлдашым ... үзенең фикерләү-саташуларын шулай **Ангарскидан башлап** Омскига кайтып җиткәнче сөйли-сөйли саруымны кайнатты. (Гурий Тавлин, Афәт.) My chance traveling companion ... annoyed me, going on and on expounding his nonsensical ideas all the way from Angarsk until we arrived back at Omsk.
- Кыпчаклар XI **йөздән башлап** XIII йөзнең яртыларына кадәр Идел һәм Дунай елгалары арасындагы далаларда, Үзәк һәм Көнбатыш Казакстанда, Кара диңгез буенда, Кырымда һәм Кавказда күчмә кабиләләр булып яшәгәннәр. (В.Х. Хаков, Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше.) From the 11th century until approximately the middle of the 13th century, the Qypchaqs lived as nomadic tribes in the steppes between the Volga and Danube rivers, in Central and Western Kazakstan, along the Black Sea, in the Crimea, and in the Caucasus.

**[561] бирле** (бире+ле, бире 'here') 'for', 'since', 'from ... on' (continuously or without exception or interruption from the time given until now; during the period between the time given and now):

- Әхмәт аны ике-өч **елдан бирле** белә. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Äkhmät has known (lit., knows) him for two or three years.
- Мин Зөләйха туташ белән бер **атнадан бирле** таныш инде. (Кәрим Тинчурин, Утыз өч көн.) I have been (lit., I am) acquainted with Miss Zöleykha for a week already.
- Ул **заманнардан бирле** инде утыз елдан артык вакыт узган. (Мөхәммәт Мәһдиев, Торналар төшкән җирдә.) Since those times more than thirty years have already passed.
- Шул **вакыттан бирле** мин аның белән бик дус яшәдем. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) From that time on I became (lit., lived) very friendly with him.
- **Иртәдән бирле** күренмәгән ... Солтан да көндезге аш вакытында башкалар белән бергә аланлыкка килде. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) Soltan, who ...

had not been seen since morning, also came at lunch time to the glade together with the others.

**[562] борын** (борын ‘ancient’; ‘nose’).
a) ‘before’ (in preference to; having precedence of):

· Ходайга дога кыйлып, бер Ярканат
Шушылайча дога кыйлды кабат-кабат ...
Теләгем күп, ләкин **һәммәсеннән борын**
Җир йөзеннән алсаң иде кояш нурын ...
(Мәҗит Гафури, Ярканат белән Карлыгач.)
Praying to the Lord, a Bat
Prayed thus again and again ...
My wishes are many, but before all,
If you would only take the sunlight
off the face of the earth ...

*Note:* кыйлып, кыйлды are now spelled кылып, кылды.

b) ‘before’ (earlier than; preceding in time):

· ... алар **аннан** да **борын** кайсы заманнарда чыккан, Болгар чорындамы, башкамы, аларын билгеләве кыен /qiɒn/. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальәре.) ... at what time before that (i.e., before the period of the Khanate of Kazan) they (i.e., ancient proverbs) originated, whether in the Bolghar period or in some other (period), (that) is difficult to determine.
· ... икесе дә намазны истән чыгармыйлар, уразаны өч ай **борын** сөйли вә көтәләр. (Шәриф Камал, Эч пошулы.) ... the two of them do not forget the prayer. They talk about and wait for the fast, three months ahead.
· (өч ай борын, i.e., **моннан (аннан, шуннан)** өч ай **борын**).

**[563] бүтән** (бүтән ‘other’, ‘different’) ‘besides’, ‘except’ ‘(nothing) but’:

· Маратның **бабасыннан бүтән** беркеме дә юк иде. (Әбрар Шәмин, Гөрләвекләр акканда.) Marat had no one besides his grandfather.
· Анда ... бала арбасы тәгәрәтүче яшь **хатыннан бүтән** кеше күренмәде. (Гурий Тавлин, Афәт.) There ... was no one to see, except a young woman pushing a baby carriage.
· Без сиңа, балам, **изгелектән бүтән** бер ни дә теләмибез. (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) We, my child, wish you nothing but good.

**[564] гайре** /ɑ̆əjre/ (Arabic – ghair ‘other than’; ghaira ‘except’, ‘save’, ‘but’) ‘besides’, ‘except’, ‘save’:

· Сыерчык оясы хәтле генә **өйләреннән**, өч-дүрт баш **сарыкларыннан** һәм бер **кәҗәләреннән гайре** телгә алып сөйләрлек маллары юк иде аларның. (Вакыйф Нуруллин, Һәлакәт.) Besides their house, which was only as large as a nesting box for starlings, three or four heads of sheep and one goat, they had no property worth mentioning.
· Зәңгәр күк йөзендә алама бер болыт **кисәгеннән гайре** берни күзгә чалынмый. (Рөстәм Кутуй, Сөенче.) Except for a thin shred of clouds, nothing catches the eye in the blue sky.
· Кулында **эшләпәсеннән**, **таягыннан гайре** бер нәрсәсе юк иде. (Ибраһим Гази, Кызыл томаннар артында.) He had nothing in his hand except his hat and his walking stick.

*Note:* гайре means also ‘other’. Furthermore – mostly in the older language, infrequently in contemporary Tatar – гайре functions as a particle corresponding to such English negative prefixes as **non+**, **un+**, **in+**, etc. For example: гайре рәсми ‘nonofficial’, ‘unofficial’, гайре табигый ‘unnatural’, гайре мөмкин ‘impossible’, гайре ихтыяри ‘involuntary’.

**[565] игътибарән** (arch.), (Arabic: i‘tibâran) ‘from’, ‘as of’, ‘beginning’ (indicating the beginning at a specified time):

- Минә шул **вакыттан игътибарән** безнең тормышыбызда бертөрле үзгәрү сизелә башлады. (Шәриф Камал, Бер картның тойгылары.) From that time on, a certain change began to be felt in our life.

**[566] мөкаддәм**, **мөкатдәм** /møqəddəm/ (Arabic: muqaddam ‘anteceding’, ‘preceding’) ‘before’, ‘ago’:

- Менә аның шәкерт вакытында, **моннан** унбиш ел **мөкаддәм** алдырган портреты. (Фатих Әмирхан, Картайдым, 1909.) Here is his portrait which he had taken fifteen years ago during his student days.
- Хәдичә – **моннан** 30-35 еллар гына **мөкатдәм**... Бәдретдин дигән кешенең бердәнбер генә сөекле кызы улып, унбиш-уналты яшьләре тулып килгәндә ... тирә-якта «Җаек Хәдичә» дип дан тоткан бер кыз иде. (Сәгыйть Рәмиев, Галәветдин хаҗи корбаны – Җаек Хәдичә, 1909.) Just about 30 or 35 years ago, ... Khädichä was born the only beloved daughter to a man called Bädretdin, and when she attained the age of fifteen or sixteen, she ... was a girl famous all around as “Khädichä from the (river) Ural”. (улып. obs. – булып).

*Note:* In today’s literary language, мөкатдәм is used infrequently.

**[567] соң** ‘end’; ‘late’.

a) ‘after’ (later in time):

- Шул **көннән соң** авыл минем күңелемне тарта башлады. (Галимҗан Ибраһимов, Көтүчеләр.) After that day, the village began to tug at my heart.
- Бер-ике **сәгатьтән соң** мин, саубуллашып, китәргә җыендым. (Афзал Шамов, Авыр көннәрдә.) After one or two hours I said goodbye and prepared to leave.
- **Чәйдән соң** мин ишек алдына чыктым. (Мирсәй Әмир, Куркыныч урыннар.) After tea I went out into the yard. (ишек алды, now spelled ишегалды).
- ... беренче исәнләшү **сүзләреннән соң**, Фәезнең карашы өстәлдәге дәфтәрләргә төште. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) ... after the first words of greeting, Fäyez’ eyes fell on the notebooks, which were on the table.
- Җаек һәм Сакмар елгалары, **ташудан соң**, әле дә ярларына кире кайтмаган. (Атилла Расих, Айлы төннәр.) After the flood, the Ural and Sakmara rivers have still not retreated to their banks.

b) ‘after’ (indicating order):

- Стәрлетамак мәктәбен тәмамлагач, 1925 елның җәендә мин Яңа Карамалы дигән авылга килдем. ... **Стәрлетамактан соң** миңа Карамалы бик фәкыйрь күренде. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч.) After finishing school in Sterlitamak I moved to the village of Yanga Qaramaly in the summer of 1925. ... After Sterlitamak Qaramaly appeared to me very poor.
- Мондый тавыш мең елга бер генә туадыр. Болай ук та моңлы, болай ук та тирән итеп бу җырны аңа кадәр бер кем дә җырлый алмагандыр, **аннан соң** да булмас... (Марсель Галиев, Ул чакта.) Such a voice is probably born only once in a thousand years. Before him no one probably had been able to sing this song in such a melancholy way, in such a soul-stirring way, and there will (perhaps) be no one after him either...

**[568] тотынып** (verbal adverb of тотын ‘begin’, ‘set about’, ‘get down to’) ‘from’ (indicating starting point):

- [Фәйзулла] иң зур **гармоньнан тотынып** иң кечкенә гармоньга чаклы, аннары киресенчә, иң **кечкенәсеннән тотынып** иң зурысына хәтле, барлык гармоньнарында да уйнады ... (Фатих Хөсни, Гармоньчы.) [Feyzulla] played on all the accordions, from the largest accordion to the smallest accordion, then, conversely, from the smallest to the largest ...

**[569] тыш** (тыш ‘exterior’, ‘outer part’) ‘besides’, ‘in addition to’:

- Гадәти **чүлмәкләрдән тыш**, биредә чит илләрдән китерелгән кыйммәтле савытлар ... табылды. (С.С. Айдаров, Н.Д. Аксенова, Болгар шәһәре.) Besides ordinary earthenware, costly vessels ... imported from abroad, were found here.
- Өстәл тирәсендә дәү апа белән **Газизәдән тыш** тагынниндидер ике яшь һәм бер картрак хатын ашап утыралар иде. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) Besides the oldest sister and Ghäzizä, there were still some other women, two of them young, one elderly, sitting around the table and eating.
- Өстәл янындагы урындыкларга утырган әлеге ике **хатыннан тыш**, аягүрә басып торучы без биш кеше белән бүлмәнең эче бөтенләйгә тулып киткән иде. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) With us five men standing, in addition to the same two women, who were seated on chairs beside (at) the table, the room (lit., the interior of the room) had become completely crowded (lit., full).

**[570] элек** (элек, adverb, ‘first’, ‘at first’).

a) ‘before’ (earlier than, preceding in time):

- **Керүеңнән элек** чыгуыңны уйла. (Proverb.) Before you enter think of your way out.
- Бу **хәлләрдән** бер ай **элек** ... тымызык күл буенда Хәйри кармак салып утыра иде. (Әбрар Шәмин, Камай күпере.) A month before these events ... Kheyri was sitting by the quiet lake ... casting his fishhook (lit., fishing rod).

b) ‘ago’:

- Мин сиңа **моннан** ике атна **элек** ике хат язган идем. Ләкин җибәрмичә калдым. (Гадел Кутуй, Тапшырылмаган хатлар.) Two weeks ago I wrote (lit., had written) you two letters. But I did not send them off.
- [Фирдия] /Firdiə/ ... **моннан** сигез ел **элек** ... булган вакыйгаларны исенә төшерде. (Рәфкать Кәрами, Сагышлы кояш.) [Firdiä] ... recalled the events which took place eight years before ...

c) ‘before’, ‘above’ (ahead in order, rank, or importance):

- Ләкин ул, **барыннан да элек**, хезмәт ияләренә яшәү өчен уңайлы шартлар тудыруны күздә тотып төзелгән. (Мирсәй Әмир, Күңелле сәяхәт.) But it (i.e., the city) was built above all with a view to creating favorable living conditions for the employees.

**[571] әүвәл**

This postposition is the Arabic equivalent of **элек**. As a postposition it is used rarely in today’s Tatar literary language:

- **Моннан** биш ел **әүвәл**, мин бу шәһәрдә торган елны, бу йорт ... бөтенләй болай түгел иде. (Фатих Әмирхан, Бер хәрабәдә, 1912.) Five years ago, the year I lived in this town, this house ... was not at all like this (i.e., in this dilapidated state).

- Майның бер якшәмбесе, көндезге сәгать өчләр иде. Бер сәгать кенә **моннан әүвәл** явып киткән җиңел яңгыр шәһәр урамнарының тузанын баскан ... иде. (Фатих Әмирхан, Хәят.) It was a Sunday in May, about three o'clock in the afternoon. The light rain which had fallen just an hour ago had settled away (lit., covered) the dust of the city streets ...
- Исламов, **барыннан** да **әүвәл**, эшчеләр өчен пешерелгән ашны татып карады. (Фатих Хөсни, Зәңгәр җыр, 1935.) Before anything else, Islamov tasted the food cooked for the workers.

## Postpositions with +рак, +рәк

**[572]** The suffix **+рак**, **+рәк** is joined to postpositions used in their basic form as well as to nouns and adjectives functioning as postpositions. To the former it is joined directly, with the latter it is attached to the case endings.

A postposition with the suffix **+рак**, **+рәк** indicates relationship in an incomplete degree. Бу мәсьәләдә үзе **кебегрәк** уйлаган башка бер кыз белән дуслашып алды. She made friends with another girl who thought more like herself in this matter.

- – Кәефем минем начар түгел. Сәламәтлек яхшыра, ... Әмма рухым минем бүтәнчәрәк. Төшенке димәс идем мин аны. Юк, төшенке түгел! Ләкин ничегрәк дип аңлатырга? Тын кырлар өстенә яткан кичке шәфәкъ вакыты **кебегрәк** димме, – үзем дә белмим. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) "I am not in a bad mood (lit., My mood is not bad). (My) health is improving, ... But my state of mind is somewhat different. I would not call it depressed. No, it is not depressed! But, how is it ever to be explained? Should I say that it is somewhat like the time when the evening glow settles (lit., lies) over the quiet fields? I don't know myself."
- Халикъ ... Ничек инде ... затлы әйберләр бар микән соң анда? Галләм. Нәрсәләр барын яхшылап белмим белүен. Әмма шулай да көмеш әйбер, кашык-аяк кебек нәрсәләр дигән иде. **Иллә мәгәр** алтыннар да булырга кирәк. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Khaliq. ... How is it now ... are there perhaps any valuables there? Ghälläm. True, I do not know precisely what there is. But, nevertheless, he (i.e., the owner of the objects burried in his garden) had said that there are things like silver objects, silverware. However, there ought to be gold coins too. (The speaker believes this). (For белмим белүен see 1206, a-b, 1).

## Disjunctive Conjunctions

**[646] яки** /jaki/ 'or'.

- Кем белә, бәлки Рухия дә хыялына ирешкәндер, бәлки ул да Ташкент университетын тәмамлап, берәр газетада **яки** журналда эшлидер. (Вакыйф Нуруллин, Әгәр син булмасаң.) Who knows, perhaps Rukhiä too has realized her dream, perhaps she too has finished Tashkent University and is working with some newspaper or journal.

(For the particle **±дыр**, **± д̊ер**, **±тыр**, **±тер**, see 693, a).

- Бу бакча бүген генә шулай искитмәле матур һәм купшы булмаган бит. Нигә ул моңа кичә **яки** аннан элегрәк көннәрдә игътибар итмәде икән? (Табдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) After all, this park has not become so amazingly beautiful and luxuriant just today. Why had she not noticed this yesterday or in former times?

**[647] я** /jә/ 'or' (also spelled йә).

a) · Монда халык күп. Кайберәүләр ... бакча һавасын суларга, иптәшләре, **я** бала-чагалары белән ... әйләнгәләп керергә дип чыккан ... Кайберәүләр эшкә барышлый, **я** эштән кайтышлый гына узалар. (Гомәр Бәширов, Көннәрнең берендә.) There were a lot of people here. Some had come to take the air of the park, to ... walk around a few times with their friends or children. ... Some are only passing through on their way to or from work.

*Note:* In the vernacular ипгәш means also 'husband' or 'wife'.

- Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? **Я** өрәкме, нәрсә бу? (Габдулла Тукай, Шүрәле.) What is this? Is it a fugitive, a demon? Or is it a ghost? What is it?

b) The conjunction **я (йә)**, immediately preceded and followed by the same verb, first in the affirmative and then in the negative form, or the same conjunction preceding each of the latter, indicates an action reaching its end. The observer is unable to determine with certainty the moment of its completion, the reason(s) for this being stated in the following or preceding sentence (context).

- Газизә байтак вакыт, ишек яңагына сөялгән көе, китеп баручылар артыннан карап торды. Кояш та **иңгән, я иңмәгән**! Ул якны болыт каплаган иде. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) Leaning against the doorpost, Ghäzizä gazed for quite some time after the departing men (lit., those departing). It seemed the sun had departed (lit., set) too; clouds had covered that part (of the sky).
- Һава шактый салкын һәм болытлы. Кояш әле **я калыккан, я калыкмаган иде**. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) It (i.e., The weather) was rather cold and cloudy. Whether the sun had already risen or not yet risen was not clearly discernible.

**[648] яисә** /jəisə/ 'or'.

- Давыл ике көнгә барды. Бу чакта эшчеләр күбрәк вакытларын карта һәм шашка уйнап, **яисә** йоклап үткәрделәр. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) The storm continued for two days. During this time, the workers spent most of their time playing cards and checkers or sleeping.
- Анасы ... – Аңсыздан дию кайтып керсә, **яисә** туганнарыннан берсе килсә, харап булырбыз, – диде. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) ... his mother said, "If the demon returns unexpectedly, or if one of its relatives comes, we shall perish."
- Табигать терелеп бетмәгән. Кошлардан чыпчык, **яисә** сыерчыклар гына чырылдашкалап үтәләр, **яисә** ала карга ачы тавышы белән каркылдап уза. (Шәриф Камал, Курай тавышы.) Nature has not yet completely awakened (lit., revived). Of the birds only sparrows or starlings go by, twittering, or a common crow passes by, croaking loudly.

*Note:* The conjunctions **яки** and **я** are commonly used to join words, groups of words, which denote persons, things, actions, or occurrences which are *enumerated.* The conjunction **яисә** is primarily used to join words, groups of words, etc. which denote persons, things, actions, or occurences which *alternate.* But often all three may be used interchangeably, with **яисә** expressing a shade of contrast.

**[649] яки** ... **яки**, **я (йә)** ... **яки**, **я (йә)** ... **я (йә)**, **я (йә)** ... **яисә** 'either ... or'.
Used as disjunctive correlatives, the above conjunctions indicate a *choice of alternatives:*

- Таһир. Шуны бел, әгәр дә хәзер аерылабыз икән, гомергә аерылабыз ... Сине гомеремдә дә онытасым юк ... Ләкин белеп тор, быел ук өйләнергә мәҗбүр булачакмын. **Яки** хәзер, **яки** бер вакытта да! (Хәй Вахит, Мәхәббәтең чын булса.) Tahir. Know this, if we do part now, we part forever ... I shall never forget you ... But understand (lit., know, realize) that I must marry (you) now, this year; it is either now or never!
- Ул беркайчан да җикеренми. Гаебең бар икән, бюрога чакырта да, **я** шелтә бирдереп җибәрә, **яки** эшеңнән азат иттерә. (Вакыйф Нуруллин, Аккан су юлны табар.) He never shouts. If you are at fault, he has you called into the office and either has you given a dressing-down and sends you back, or he has you relieved from your work.
- Сатылачак нәрсәне үз күзең белән күрмәс борын бәясен сорау күп вакытта саташтыра гына; **йә** гайрәтне чигерә, **йә**, киресенчә, ашыгырга мәҗбүр итә. (Әмирхан Еники, Рәшә.) To ask its price before you have seen the object which is up for sale (lit., to be sold) often just confuses you; it either turns you off (damps your ardor) or, on the contrary, forces you to hurry.

- ... кайсы берләре **я** артык киң, **я** кыскарак, **я** озынрак иделәр. (Фатих Әмирхан, Урталыкта.) ... some of them (i.e., some of the shirts) were either too wide or somewhat short or somewhat long.
- Һәр көн ... эш эзләп тә карыйбыз ... ләкин һаман рәт чыкмый: **я** бөтен җәй буена егерме тәңкә генә бирәләр, **яисә** вакытлы эшләр генә күрсәтәләр. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) Every day ... we try to find work ... but always nothing comes of it. Either they give only twenty rubles for the whole summer or they offer only temporary work.
- Ул ... кичке чәйдән соң гына азгамы, күпкәме чыгып китә, **я** күрше бүлмәдә генә торган Мәһди янына кереп утыра, **яисә** барактагы егетләр янына керә. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) ... he goes out only after evening tea for a shorter or longer while; he either drops in on Mähdi who lives in the room just next (to his) or he goes to see the young men in the barracks.

**[650] әллә** ‘or’; **әллә** ... **әллә** ‘either ... or’.
**Әллә** and the correlative **әллә** ... **әллә** present the action, state, etc. as *doubtful, uncertain, unclear:*

- Өнме бу, **әллә** чынлап та төш кенәме? (Ринат Мөхәммәдиев, Беренче умырзая.) Is this reality, or is it really only a dream?
- Ни көтә аны алда? Мәхәббәтме, **әллә** мавыгу гынамы? Бәхетме, **әллә** сагышмы? (Рәфкать Кәрами, Йөрәгемне ут алган.) What is waiting for her in the future? Love or only passion? Happiness, or anguish?
- Бу сүзләрдән соң егетнең **әллә** ачудан, **әллә** куркудан тетрәп киткәнлеге Ризванга ачык сизелде. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) Rizwan felt distinctly that after these words the youth (suddenly) began to tremble either from anger or from fear.
- ... ул урамда улаган җилгә колак салды. Тәрәзә пыялалары юеш, **әллә** кар, **әллә** яңгыр ява. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) ... she listened to the wind howling in the street. The window panes are wet. It must be either snowing or raining.
- – Белмим, диде ул, – **әллә** син гаепле, **әллә** мин. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) “I don’t know,” he said, “either you are guilty or I am.”

**[651] бер** ... **бер** ‘now ... now’.

- Күк йөзеннән, айны **бер** каплап, **бер** ачып, болытлар йөзә. (Зөфәр Фәтхетдинов, Ачылган серләр.) Clouds are drifting over the sky, now covering, now revealing the moon.
- Яңгыр **бер** көчәеп, **бер** иләктән иләнгәндәй вак тамчылар булып ява бирде. (Газиз Кашапов, Җир җылысы.) The rain continued, now becoming more intense, now falling in fine drops as though passed through a sieve.
- Әсма ... **бер** аңа, **бер** ишек янындагы гармоньга карап, күзләре белән ымлый башлаган иде. (Мөхәммәт Гали, Аулак өйдә.) Äsma had started to give signs with her eyes, now looking at him, now at the accordion, (which stood) near the door.

**[652] әле** ... **әле** ‘now ... now’.

- Хәмдия ... елмаеп **әле** балага, **әле** әнисенә карады. (Нурихан Фәттах, Артта калган юллар.) ... smiling, Khämdiä now looked at the child, now at her mother.
- Актырнак телен салындырган килеш **әле** анда, **әле** монда сугыла, үләннәрне, агач төпләрен исни. (Садри Җәләл, Аучы карт.) With his tongue hanging out, Aqtyrnaq runs now here, now there and smells the grass and the tree bases. (Aqtyrnaq – name of a dog; he is tracking a deer.)

- Аккош канатларын җәеп каршы тора. Сурка да **әле** бер яктан, **әле** икенче яктан аңар һөҗүм итәргә тырыша. (Садри Җәләл, Аккош.) Spreading its wings, the swan stands its ground. Surka tries to attack it now from one side, now from the other. (The dog Surka plays with a pet swan.)

**[653] кирәк** ... **кирәк** ‘whether ... or’; **кирәк** ... **вә кирәк** ‘both ... and’.

- **Кирәк** Себердән булсын, **кирәк** Грузиядән, я Латвиядән бер генә галим дә аның соравын җавапсыз калдырмаган. (Атилла Расих, Ике буйдак.) Whether it be from Siberia or from Georgia or from Latvia, not one scientist has left his inquiry unanswered.
- – Анасы, әле безнең шикәр күптер? – дип сорый иде, һәм Маһитап абыстай **кирәк** күп дип җавап бирсен, **кирәк** аз дип җавап бирсен, Сәмигулла абзый мотлак ... дип куя иде. (Фатих Әмирхан, Сәмигулла абзый.) He would ask, “Mother, do we still have plenty of sugar?” And whether Lady Mahitap would answer that there was plenty or that there was little, Sämighulla would undoubtedly say...
- Кунаклар киткәч, **кирәк** Маһитап абыстай **вә кирәк** кызы Сәмигулла абзыйны бик орыштылар. (ibid.) After the guests had left, both Lady Mahitap and her daughter severely reproached Sämighulla.

**[654] булсын** ... **булсын** ‘be it ... be it’, ‘both ... and’.

The third person singular imperative of **булу** ‘to be’ is used as a correlative conjunction. It is placed *after* each homogeneous part of speech:

- Бу турыда вакытлы матбугатта **булсын**, әдәби әсәрләрдә **булсын** бик күп язылды. (Гомәр Бәширов, Гореф-гадәт /Ƣөref-ƣədət/ законнан өлкәнрәк.) Much has been written about this both in periodicals and in literary works. (закон R. – канун /qanun/).
- Өйдә **булсын**, эштә **булсын**, ул бөтенләй сөйләшмәс, аралашмас булып калды. (Ринат Мөхәммәдиев, Ачык тәрәзә.) Be it at home or at work, he completely ceased to speak, to associate.

(For **-мас**, **-мәс булу** see 992, 2.-5.)

- Җыелышларда **булсын**, үзара сөйләшкәндә **булсын**, баш кешеләр әйтә килделәр: язгы кыр эшләрен мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә тәмамларга кирәк ... (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Whether at meetings or when they talked among themselves, the leaders (leading people) kept saying: “We’re going to have to accomplish the spring field work in the shortest possible time ...”
(For килү as auxiliary verb see 1347.)

**[655] теләсә** ... **теләсә** ‘be it ... be it’, ‘whether ... or’.

The third person singular conditional of the verb **теләү** ‘to wish’, ‘to want’ is used as a correlative conjunction. Placed *before* each member of a homogeneous word combination, it indicates equal stress and importance.

- **Теләсә**, язгы чаптыруларда, **теләсә**, базарларда, **теләсә**, башка уеннарда без һаман үзебез теләгәнчә алып барабыз. (Галимҗан Ибраһимов, Кызыл чәчәкләр.) Whether it is at the spring horse races or at the bazaars or at other games, we always carry on as we wish (i.e., we always have it our way).
- Ул **теләсә** яхшылап, **теләсә** ачуланып әйтсен, Шәрәфи агайның җавабы һаман бер. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) Whether she speaks nicely or angrily, Uncle Shäräfi’s answer is always the same.

**[656] дими ... дими**, etc. 'whether ... or whether', 'be it ... be it'.
The negative form (for negative verbs see 906, 911, 953 g, 954 a, 957, 966, 969, 971) of the verb **дию** 'to say' in any person present tense, past tense I, and future tense I indicative can function as a correlative conjunction. It is placed *after* each member of a homogeneous word combination, the person depending on the subject of the sentence.

Furthermore, in addition to functioning as a correlative conjunction, **дими ... дими**, etc. indicates that the subject pays no attention to, disregards all circumstances or conditions – favorable or unfavorable – in carrying out the action.

- Көн **дими**, төн **дими**, җәй, кыш **дими**, туктаусыз эшләп яталар. (Галимҗан Ибраһимов, Тирән тамырлар.) Whether it is day or night, summer or winter, they work constantly.
- Ильяс. ... Яз **димисең**, көз **димисең,** эзләнүдән өзелмисең. (Хәй Вахит, Карлыгач канат кага.) Ilyas. ... Whether it is spring or whether it is autumn, you do not stop searching.
- Кыш буе атлар карады Рәхимҗан. Салкын **димәде**, буран **димәде**, иртә таңнан кичкә кадәр атлары янында булды. (Ринат Мөхәммәдиев, Беренче умырзая.) Throughout the winter Räkhimjan took care of the horses. Whether it was cold or whether there was a snowstorm, he was with his horses from the first light of dawn until evening.
- Әсма. Аның шул инде, көн **димәс,** төн **димәс.** Яза да сыза, сыза да боза. (Хәй Вахит, Күк капусы ачылса.) Äsma. That's the way he is. Whether it is day or night, he writes and draws, he draws and erases (deletes, crosses out).
- Икесе дә күз карашларын дәшми-тынмый гына еракка, караңгы басу уңаена төбәделәр ... Әле һаман туфракны каезлый бирәләр, өя бирәләр. – Икенче җәен бит инде. ... Яңгыр **димәсләр**, ачы җил, зәһәр челлә **димәсләр**. ...! – дип пышылдады Ризван. (Эдуард Касыймов, Җир балкышы.) Both of them gazed silently into the distance, in the direction of the dark fields. ... They (i.e., the construction workers) still continue to peel away the soil and keep piling it up. "It is the second summer now ... in spite of rain, piercing wind, or scorching heat," whispered Rizwan.
- Ә Хәнәфи исә, ..., өйалдында үзенә ятак хәстәрләргә кереште. Яңгыр тамчыларының сихерле тамуын мыштым гына тыңлап ятарга. ... Ә «Кара тау»ны тегендә, инде төн уртасы **димиләр**, җирне изрәтте **димиләр**, өя бирәләр. (ibid.) As for Khänäfi, he ... began to ready the bed for himself on the porch, to lie down and quietly listen to the magic dripping of the rain drops. ... But even though it is midnight and (the rain) has made the ground sodden, they continue piling up the "Black Mountain" there.

**[657]** (**+мы**) **+ме** ... **+ме**, (**+ме**) **+мы** ... **+мы** 'either ... or'.
Joined to each member of a homogeneous word combination, the particle **+мы**, **+ме** (see also 672) functions as a correlative conjunction indicating equal stress and importance.

- Зурларга 25-30 тиен түлиләр иде, безнең ише малайларга 15 **ме**, 20 **тиенме** эләкте. (Гомәр Бәширов, Тормыш сукмаклары.) They were paying the grown-ups 25 or 30 kopecks; boys like us got either 15 or 20 kopecks.
- ... урыны белән алар, кибеп җитмәгән сыек сазлыкка һәм суларга очрап, киселеп калалар. Андый урыннарга үтеп йөрүчеләр **тактамы, ташмы** ыргыткан булалар ... (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) ... in some places, they (i.e., the trails) run into and cut through occasional boggy spots and puddles which have not dried out. At such places, people passing through have thrown down either boards or stones.

- Без һәммәсенә капка ачабыз, күбесе безгә ярты **конфетмы, прәннекме**, каткан клиндер **кисәгеме** ташлап китә. (Галимҗан Ибраһимов, Кызыл чәчәкләр.) We open the gate to all of them. Most of them throw us either half a candy or a cookie or a piece of a stale (small ring-shaped) cracker.
- Сал инде аңа йөгеңне: **көлтәме** ул, **ашлыкмы, бәрәңгеме, кирпечме** яисә **утынмы** – барыбер ... тартачак ... (Барлас Камалов, Өметең өзелмәсен.) Just put your load on it; whether it is sheaves (of corn) or grain, potatoes or bricks, or firewood – it makes no difference ... he (i.e., the ox) will pull it...

**[658]** **кая** ... **кая** 'either ... or', 'now ... now', 'sometimes ... sometimes'.

- – Миңа бернинди партнерның да кирәге юк – дип кырт кисте Нурия ... **Кая** – кинодан, **кая** телевизордан күреп калам да шуларны кабатлыйм. Көй генә булсын! Ритм! (Кояш Тимбикова, Ярлар биек.) "I don't need any (dancing) partner," Nuriä cut her short ... "I see them (i.e., the dances) either in the cinema or on television, and I practice them (repeat the dances). All I need is a tune! Rhythm!"
- [Фирүзә] түбән карады. Кыялар, уентыклар аша, **кая** сикереп, **кая** ташлар арасына керә-югала чишмә ага, ... (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Туй балдагы.) [Firüzä] looked down. Over rocks (and) ledges a spring was flowing, now jumping (over), now entering and disappearing between the rocks, ...

## Subordinating Conjunctions

**[659]** **ягъни** /jəɠni/.

a) 'that is' (id est):

- Равил иртәгәсен, **ягъни** шимбә көнне Агачбашка үзе килергә, Булат белән сөйләшеп карарга булды. (Барлас Камалов, Өметең өзелмәсен.) Rawil decided to go to Aghachbash the next day himself (i.e., Saturday) to try to talk with Bulat.

(For **-рга булу** see 1159, for **-п карау** 1345, a.)

- ... әнисе бер бәләкәй шәһәрдәге кызында, **ягъни** Флүр Сәхбиевичның бертуган апасы тәрбиясендә. (Рәфкать Кәрами, Йөрәгемне ут алган.) ... his mother is with her daughter, that is, in the care of Flür Säkhbievich's older sister, (who lives) in a small town.

b) 'as if asking', 'as if inquiring' (expressing undecidedness, hesitation):

- Габдулла иптәшенә карап алды, **ягъни**: нишлибез? (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) Ghabdulla glanced at his friend as if inquiring what to do (lit., as if inquiring, what should we do?).
- Габдулла белән Әһли бер-берсенә карашып куйдылар, **ягъни**: бу кешегә без нинди мөнәсәбәттә булырга тиеш? (ibid.) Ghabdulla and Ähli glanced at each other as if inquiring on what terms they should be with this man (lit., as if inquiring, what terms should we be on with this man.)

**[660]** **димәк** 'that means'.

- Сәмигулла шушы уйлар белән каравыл өенә килеп җитте. Анда ут яна: **димәк**, эчендә кем булса да бар. (Нәзифә Кәримова, Карурманнан чыккан юлчылар.) With these thoughts (i.e., thoughts about his future) Sämighulla arrived at the watchman's house. There was a light burning, which meant that there was someone inside.

- Хатыннар кер юа, **димәк** якын-тирәдә генә җәйләү, я торак өйләр. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кубрат хан.) Women are washing clothes – that means, there is either a summer pasture or dwellings near by!

**[661] бигрәк тә**, **аннан да бигрәк** 'particularly'.

- Язның салкынчарак, хуш исле төннәре, **бигрәк тә**, ул төннәрнең шундый хуш исле булучылыгы Хәятның йөрәгендә үзенә белемсез бер тойгы уята иде. (Фатих Әмирхан, Хәят.) The somewhat chilly, fragrant spring nights, particularly those nights being so fragrant aroused in Khäyat's heart a feeling unknown to her.
- Болгар дәүләтендә, **бигрәк тә** далалы һәм урман катнаш далалы урыннарда, терлекчелек тә хуҗалыкның мөстәкыйль тармагы булып киткән. (Татарстан АССР тарихы, IX-XIII гасырларда Идел буендагы Болгар дәүләте.) In the Bolghar State, particularly in the steppe and forest-steppe areas, stock-raising too was carried on as an independent branch of the economy.
- Гәүһәр кинәт бәйләнә башлагач, үзен тыя алмады. Булатны яклап, **аннан да бигрәк**, ямьсез, ләкин гаҗәп яхшы күңелле, гаҗәп сөйкемле Нинаны да аклап, сүз әйтми калырга көче җитмәде. (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) When Gäwhär suddenly started an argument (with Bulat), she (i.e., the girl student Shirinskaya) could not hold back. She did not have the strength not to speak out, supporting Bulat, and particularly, exonerating also Nina who was uncomely but amazingly kind-hearted, amazingly likable.

**[662] һәрхәлдә** 'at any rate'.

- Мансур Гөлшаһидәне күрми идеме, әллә күреп тә күрмәмешкә салына идеме, **һәрхәлдә** Гөлшаһидә ягына бер генә тапкыр да күтәрелеп карамады ... (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) Whether Mansur did not see Gölshahidä or whether he was pretending not to see her, at any rate, he did not even once raise his eyes to look in Gölshahidä's direction.
- Зәкиевләрнең уртанчы энеләре Таҗи белән мин моннан бик күп еллар элек очрашкан идем. Ае-елы /Ајь-јьlь/ хәтердә калмаган, **һәрхәлдә** сугыштан соңгы авыр заманда. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) Taji, the second oldest of the Zäkiev brothers, I had met very many years ago. The month and year I do not remember; at any rate, it was during the difficult post-war time.

**[663] чөнки** 'because'.

The conjunction **чөнки** introduces subordinate clauses expressing *cause*. It is one of the most active conjunctions and is used in both the literary language and the vernacular.

- Күбрәк Яңгура сөйләде, **чөнки** аның белмәгән һәм ишетмәгән нәрсәсе юк иде. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) It was mostly Yangghura who talked, because there was nothing that he did not know, that he had not heard.
- – Мин ул көнне бик яхшы хәтерлим, **чөнки** иртәгесен Кларaның туган көне уздырылачак иде. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "I remember that day very well, because on the next day Klara's birthday was to be celebrated."
- Галия. Кичә мин ул турыда аның белән сөйләшә алмадым. **Чөнки** кич сездән кайтып килгәндә, ул инде йокларга яткан иде. (Шәриф Камал, Ут.) Ghaliä. Last night I was unable to talk with him (i.e., with her husband) about that (i.e., getting her brother another job) because, when I got home late from your place (house), he had already gone (lit. lain down) to sleep.

**[664] шунлыктан**, **шуңа(р) күрә**, **шуның өчен**, **шуның аркасында**, **шул сәбәпле**, **шул сәбәптән** 'therefore', 'for that reason', 'because of that', 'consequently', 'hence'.

Being derived from the demonstrative pronoun **шул** (**шун-лык-тан**), or consisting of the same pronoun and postpositions, the above function as conjunctions connecting subordinate clauses expressing *cause, reason.*

- Без ул көнне кырда эшли идек, **шунлыктан** мин Габдулланы озата да алмый калдым. (Зәкия Рәсулева, Тукай эзләреннән.) That day we were working in the field, so I could not even see Ghabdulla off.
- Аңардан (Әсгатьтән) аталарына да, миңа да һичбер хәбәр юк, **шуңа күрә** аның кая икәнен беркем дә белми иде. (Садри Җәләл, Инде мин аңа рәнҗемим.) Neither his father and family nor I had any news from him (i.e., Äsghät). Therefore, nobody knew where he was.
- Бу аланнан без күп җыя алмадык: тиз бетте. **Шуңар күрә** икенче баерак алан эзләргә киттек. (Садри Җәләл, Югары урманга җиләккә бару.) On this glade we could not gather many (i.e., berries). They were gone fast. Therefore, we went to look for another, richer glade.
- Әбинең мине шәпләп сыйлыйсы килде. Ләкин каймагы кар базында икән, үзе анда төшә алмый ... **шуның өчен** каймак алырга мине чакырды. (Мирсәй Әмир, Әби васыяте.) Grandmother wanted to feed me nicely. But it turned out that her cream was in the cold (storage) cellar. She herself could not go down there ... therefore, she called me to get the cream.
- Бүген мәктәптә мин дә фалчы булдым. Тәнәфес вакытында ... барысына да фал ачтым! **Шуның аркасында** эләкте дә соң үземә. (Нәзифә Кәримова, Карурманнан чыккан юлчылар.) Today I too became a fortuneteller at school. During the recess I ... predicted the future to all of them (i.e., to all his classmates). Did I ever get into trouble for that! (A fortuneteller had come to their village and the boy was imitating him.)
- Без авылда алар белән күрше генә торабыз. **Шул сәбәпле** Гыйлемдар белән мине алырга бер язын безнең ат килсә, икенче язда алар аты килә торган иде. (Әмирхан Еники, Матурлык.) We lived in the village right next door to them. Therefore, Ghilemdar would come to pick me up one spring with our horse, the next spring with their horse. (I.e., Pick me up from the district medrese at the end of a school term.)

**[665] ни өчен** (**ник**, **нигә**) **дисәң** (**дисәгез**, etc.[1]), **ни өчен** (**ник**) **дигәндә** 'because'. The conditional (see 1020) and the past participle in the locative (see 1101, a-g) of the verb **дию** 'to say' used with the interrogative words **ни өчен**?, **ник**?, **нигә**? 'why?', form a parenthetical interrogative clause which corresponds to the subordinating conjunction 'because':

- – Мин, Әхмәт Шәрипович, кырт кисеп кенә җавап бирергә кыенсынам, әлегә ... **Нигә дисәң**, Бердников бу эшне тикшергән чагында имтиханнар тапшырырга киткән идем. (Фәнил Галиев, Командировка.) "I, Äkhmät Shäripovich, dare not answer yet categorically ... because I was away to take examinations when B. investigated this case."
- Аның әле тора-бара тагын да катлаулана төшүе бик ихтимал. **Нигә дисәгез**, менә болай ... (Вакыйф Нуруллин, Аккан су юлны табар.) It is very possible that that (i.e., the lack of farm machinery and farm hands) will gradually become still more complex because this, now, is the situation...

---

[1] The second person singular and plural and **дигәндә** are the most frequently used forms, but it is also possible to use the first person singular and plural and the third person plural without changing the structure of the sentence.

- – ... Бу хәл минем җаваплылыкны тагын да арттыра иде. **Ни өчен дисәң**, «Уңыш» исемен йөрткән колхозның уңышы түбән булырга тиеш түгел. (ibid.) "... This situation increased my responsibility still more because the harvest (yield, success) of a collective farm named 'Success' must not be low."
- – ... Һәрхәлдә, шахтада күмер чабу тимерлектә эшләүдән дә авыр тоелмады миңа. ... **Ник дисәң**, тимерлектә без бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшлибез, ә монда сигез сәгатьтән ары теләсәң дә эшли алмыйсың. (ibid.) At any rate, to hack coal in a mine did not appear to me harder than working in a forge. ... because in a forge we work from dawn to dusk, whereas here, even if you wish to, you cannot work longer than eight hours.
- Институтта уку мәктәптә укудан кыен /qьin/ түгел икән. Һәрхәлдә, минем өчен шулай булды. **Ни өчен дигәндә**, анда укыганда, кичке мәктәптәге шикелле, атнага дүрт тапкыр дәрескә барып йөрисе түгел. (ibid.) It turned out that studying at the institute was no more difficult than studying at school. At any rate, for me it was (not more difficult) because, when studying there, one does not have to attend classes four times a week as at nightschool.
- Уйландыра торган, хәл итүне сорый торган факт бу. Борчый торган факт. **Ник дигәндә**, алга таба авыл җирендә эшләү өчен механизаторлар тагын да күбрәк кирәк булачак. (ibid.) This is a fact (i.e., the tendency of young people to move from the villages to the cities) which causes one to think, which requires a solution. It is a fact which worries one because in future still more machine-operators will be needed for work in the countryside.
- Менә монысына түзә алмадым инде, гафу итсеннәр. **Ник дисәк**, мин, беренчедән, урынбасар Галибәкнең үземнекен бер селтәнүдә бәреп еккан режиссерлык сәләтеннән көнләштем. (Әхсән Баянов, Аязучан болытлы һава.) Now, with this I could not put up. They were going to have to apologize because, firstly, I envied assitant director Ghälibäk his talent (ability) as a producer which had shattered my own with one blow.
- – ... утырышны бу якын көннәрдә генә үткәрә алмаслардыр әле. **Ни өчен дисәк**, бердән бюро әгъзаларыннан берсе һаман авырып ята. Икенчедән, ... (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) "... they will probably not be able to hold the meeting in these next few days, you know, because, firstly, one of the bureau members is still lying ill. Secondly, ..."

**[666] ки** 'that'.

The conjunction **ки** is used in the literary language and in the vernacular. It is positioned at the very end of the *main* clause, *immediately before* the beginning of the subordinate clause, and in writing, it is always followed by a comma.

However, the use of **ки** is not obligatory and it may be omitted. For, although it indicates the connection of subordinate clauses with their main clause, **ки** does not – in contrast to other conjunctions – establish a specific relationship between them. Hence, **ки** is more a stylistic rather than grammatical means.[1]

---

[1] See e.g. М. З. Зәкиев, Хәзерге татар әдәби теле, Казан, 1974, p. 209, and М.З. Зәкиев, Х.Р. Курбатов, Современный татарский литературный язык – Синтаксис, Moscow, 1971, pp. 190 and 206.

**Ки** is used with:

a) Clauses of *result;* the main clause often contains such adverbs as **шулкадәр**, **шулхәтле**, etc.

- Ул (Сәми карт) **шулхәтле** сусаган **ки**, аңа бер күл суы да аз булыр төсле иде. (Давыт Юлтый, Тимеркәй фәлсәфәсе.) He (i.e., the old man Sämi) was so thirsty that even a lake(-full) of water seemed likely to be too little for him.
- Бу уйлар мине **шулкадәр** ваттылар **ки**, мин таң аткач кына йокыга китә алдым. (Фатих Әмирхан, Нәҗип.) These thoughts tormented me so much that I was able to fall asleep only when day was breaking.
- Озак та үтми, ул үзенең өстенлеген күрсәтүдә **шул дәрәҗәгә** барып җитте **ки**, миңа хәтта әти-әнием алдында шелтә ясый торган булды. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) In showing his superiority, he soon went so far as to reproaching (lit., assumed the habit of reproaching) me even in front of my parents.

(For ясый торган булды see 991, 1. a.)

b) Clauses *corresponding* to English *noun* clauses used as the *direct object* of a transitive verb.

- – Әгәр дә инде карар чыгару безнең ихтиярда булса, **ышанам ки**, без аларны аерыр идек. (Әмирхан Еники, Яшьлек хатасы.) “Now, if making a (court) decision were left to our discretion, I believe that we would grant them a divorce.”

c) Clauses *corresponding* to English *noun* clauses used as *subject.*

- Билгеле **ки**, авыл хуҗалыгында машиналаштыру зур әһәмияткә ия. (М.З. Зәкиев, Хәзерге татар әдәби теле, p. 206.) That mechanization in agriculture is of great importance is well known.

d) **Ки** may be used together with other conjunctions.

- Картның карашы шундый иде **ки**, **гүя** ул сине үтәли күрә. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кубрат хан.) The old man’s look was such that it seemed he looked right through you.
- (Сурәттән) аңа ханша Аппак карап тора. Ул шулхәтле чын һәм ихлас итеп ясалган **ки, гүя** авызын ачып ханына дәшер кебек иде. (ibid.) The Khan’s wife Appaq looked at him (i.e., at the Khan from the picture). It (the picture) was done so real and lively, it was as though she would open her mouth and speak to the Khan.

**[667] гүя** /gyjə/, **гүяки** ‘as though’, ‘as if’.

The conjunction **гүя** (**гүяки**) is primarily used in the literary language. Introducing the subordinate clause, it compares its action or state with that expressed by the predicate of the main clause.

*Note:* There is no difference between **гүя** and **гүяки**, **ки** having only stylistic significance.

- Су өсте көзге кебек шоп-шома, тып-тыныч, **гүя** ул юаш, күндәм. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) The water surface is completely smooth like a mirror, completely calm – as though it were gentle, obedient.
- Илхан туктарга тырыша, ә кул-аяклары **гүя** аныкы да түгел, **гүя** башка бер кеше аның аякларын хәрәкәтләндерә иде. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кубрат хан.) The Ilkhan (here: son of the Khan) tried to stop, but it was as if his arms and legs were not his own, as if some other person caused his legs to move.
- Табигатьнең хәзерге хәле хәятлы түгел; **гүя**, ул бу минутларда үз алдына, үз башына тора, **гүя**, ул үзенең башка вакыттагы колларына киберле бер салкынлык саклый; **гүя**, аның һичкемгә илтифаты юк, **гүя** ул хәзер үзен ялгыз вә ерак тота, – шуның өчен, **гүя**, җаны да беленми ... (Галимҗан Ибраһимов, Яшь йөрәкләр.) Now nature does not have a living aspect; (it is) as if in these moments it stands by itself, isolated, as if it preserves a proud coldness for its slaves of other times, as if it

has no consideration for anybody, as if now it keeps aloof (lit., alone) and remote, as if, because of that, its soul does not manifest itself... (хәятлы – тере; киберле – горур, эре, тәкәббер).

- ... Фәйзинең мандолинасы өстәлдә ята. Мохтар ... кылларына чиерткәләп карады. Кыллар, **гүяки** эч пошканнан кәефсезләнеп, «кирәкмәс, кирәкмәс!» дигән төсле күңелсез тавыш чыгара иделәр. (Шәриф Камал, Таң атканда.) ... Feyzi's mandolin was lying on the table ... Mokhtar tried to pluck its strings a few times. The strings, as if in low spirits from being bored, gave out a cheerless sound as though saying, "That will do, that will do!"

(For the verbal adverb in **-п** with **карау** see 1345, a; for the iterative in **-гала**, **-кала**, **-гәлә**, **-кәлә** see 1310, 2; 1311, a-c.)

**[668] әйтерсең**, **әйтерсең лә** 'as if', 'as though'.
The conjunctional word **әйтерсең (лә)** is the second person singular future tense I of the verb **әйтү** 'to say'. Like **гүя**, it introduces a subordinate clause, comparing its action or state with that expressed by the predicate of the main clause.

- ... Матусов ... уң кулын Камалиевка сузды. **Әйтерсең,** боларның берсе – җинаятьче, икенчесе – тикшерүче түгел, **гүя** озак еллар буе бер-берсен күрергә зарыккан туганнар гына. (Мәгъсүм Насыйбуллин, Ярканат.) ... Matusov ... stretched out his right hand to Kamaliev as though one of them was not the criminal and the other the investigator, (but) as though they were just brothers who had pined for years to see one another.
- Бу чокырлар үзләре зур гына, **әйтерсең лә**, монда кайчандыр күлләр булган да, хәзер аларның суы кипкән, **әйтерсең лә**, ул вакытларга инде чиксез күп еллар узган, чөнки шул корыган күлләрнең төпләрендә дә ... каеннар, усаклар үсеп утыра. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) These ravines themselves are rather large, as though at some time there were lakes here, and now their water has dried up, as though since those times a great many years have passed. Because at the bottoms of those dried-up lakes ... birches and asps are growing.
- Шулкадәр дәртләнеп, шулкадәр бирелеп җырлый иде Артыкбикә, **әйтерсең лә**, ул чын-чынлап Галиябану кичергәннәрне үз йөрәгендә кичерә. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Agtyqbikä sang with such feeling, such abandon, as though in her own heart she was really going through what Ghaliäbanu[1] had gone through.

**[669] диярсең** 'as if', 'as though'.
The conjunctional word **диярсең** is the second person singular future tense I of the verb **дию** 'to say'. It always *follows* the predicate of the subordinate clause.

- Кинәт, болыттан тамып төште **диярсең**, – ак койма башында кечкенә генә кара шәүлә пәйда булды. (Гариф Гобәй /Ɠʉbəj/, Лэйсән яңгыр.) Suddenly, as if it had dropped out of the clouds, a rather small, dark shadow appeared on top of the white fence.
- Йорт хуҗасы Шәйхулла абзый, акылын талап киткәннәр **диярсең**, гел бер сүзне тәкрарлый. (Барлас Камалов, Өметең өзелмәсен.) The owner of the house, Sheykhulla, keeps repeating the same words as if he had been robbed of his mind.
- Фәхри карт ... бары тик узып кына китә, шуны гына сагалап торалар **диярсең**, ферма каралтылары ышыгыннан, берсе артыннан икенчесе тезелеп, унике каз

[1] Галиябану /Ɠaliəbanu/ – drama by Мирхәйдәр Фәйзи (1891-1928).

килеп чыга. (Фатих Хөсни, Ата каз.) As soon as old Fäkhri ... has passed by (lit., passes by), twelve geese, as if they are only waiting for that, file out from the shelter of the farm buildings.

*Note:* In syntactical constructions with **диярсең** the subordinate clause *precedes* the main clause.

**[670] ±мыни**, **±мени** 'as if', 'as though'.

The interrogative (modal) particle ±**мыни**, ±**мени** (see 710, a-d) is joined to the predicate of the subordinate clause. It compares its action or state with that of the main clause.

- Фәридәнең яңагына чалтыратып **суктылармыни**, ике бите, колак яфраклары, ут булып яна башлады. (Ләбибә Ихсанова, Сәгать.) Both Färidä's cheeks and ear lobes began to burn like fire as if someone had given her a resounding slap on the face.
- Офык читләре аксыл мамык шәлгә **уранганмыни** – шундый куе томан. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) The fog is so dense – it seems as if the edges of the horizon have been wrapped in a whitish cotton shawl.
- Күбәләк-күбәләк йомшак кар ява, әйтерсең күктән чәчәк коела. Бөтен дөнья ап-ак, җиңел, ак мамыкка **төренгәнмени**. (Габдрахман Әпсәләмов, Күк күкрәр.) Soft snow is falling in large flakes as if flowers are raining down from the sky. The whole environment (lit., world) is all white as if wrapped in light, white cotton.
- ... ял итәргә ташка утырдым. Авыл – уч **төбендәмени**! (Таһир Таһиров, Галия.) ... I sat down on a rock to take a rest. The village lay (lit., lies) there as if in the palm of one's hand.
- Шул тиклем куе томан төшүен күрү түгел, хәтта ишеткәнем дә юк иде. Көзге караңгы төндә, бөтен дөньяны баскан су эченнән **барабызмыни**! (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) Not only had I not seen such dense fog (fall), I had not even heard (tell) of such. We are walking as though in a dark autumn night, as though through water which had flooded the whole area.

**[671] -мы**, **-ме** 'as soon as', 'when'.

The particle **-мы**, **-ме** is joined to predicate verbs in the *past tense I indicative.* It introduces subordinate clauses expressing *time*. The subordinate clause commonly precedes the main clause.

*Note:* This syntactical construction is used widely in the literary language.

- ... ул **кайттымы**, бөтен халык аңа җыела. (Давыт Юлтый, Төн.) ... as soon as he returns, all the people gather around him.
- – Сөйкигә **кердеңме**, инде кайтып җиттем дип сана, дигән иде Гыйльметдин абыйсы ... (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) "As soon as you enter Söyki, consider you have already arrived," his uncle Ghilmetdin had said ... (i.e., once he has entered the village of Söyki, it is just a stone's throw to his own village).
- Үзе җыр яратучан. Атна кич **килдеме**, кадер, мәүлид бәйрәме **булдымы**, шәкерт мәҗлесләре **башландымы**, – Баязит анда беренче каһарман. (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) He loves songs (i.e., he loves to sing). As soon as Thursday comes, when it is qadr[1)] or Mohammed's birthday, and as soon as the students' gatherings start, Bayazit is the foremost hero there (i.e., he is the foremost hero because he has a wonderful voice, and people love to listen to him singing, especially when chanting the Koran in the mosque).

*Note:* Thursday – the last day of the Moslem week, the day before Friday, the Moslem holiday.

---

1) qadr (lailat alqadr) – the night in which the Koran was revealed; celebrated during the night between the 26th and 27th of Ramadan.

- Афишада «Шүрәле» исемен **укыдыммы**, бар эшемне ташлап театрга ашыгам. (Рашат Низамиев, Матурлыкның яшәр урыны.) As soon as I read the name "Shuräle" on the playbill (poster), I drop everything and hurry to the theatre.

*Note:* (Шүрәле 'Forest Demon'; story-poem by Ghabdulla Tuqai. Arranged for ballet and put to music by Färit Yarullin, 1914-1943.)

**-мы**, **-ме**, joined to verbs in the *past tense I indicative* may also express *condition:*

- Кулаев. Син дә, шулай минем кебек үк ачулымыни...? Локман. У-у-у ... Хода күрсәтмәсен! Бер тапкыр ачуым **кузгалдымы**, һич тотар хәл булмый. (Шәриф Камал, Габбас Галин.) Qulayev. Then you too are just as bilious (ill-tempered) as I am...? Loqman. U-u-u ... God forbid! Once I get angry, there is no way of controlling me.
- Артист – балга кунган чебен шикелле ул. Театрның, сәхнәнең тәмен белеп **алдымы**, аннан мәңге аерыла алмый. (Сәет Шәкүров, Сәхнәнең кыл уртасында.) An actor is like a fly sitting on honey. Once he has got a taste of the theatre, the stage – he can never leave it.

**[672]** ±**мы** ... ±**мы** (±**ме**), ±**ме** ... ±**ме** (±**мы**) 'whether ... or (whether)', with negative verbs (or other parts of speech in the negative, or words of negation) 'whether or not'.

Functioning as a correlative conjunction, the particle ±**мы**, ±**ме** (see 657) is joined to each part of speech to which it refers.

- Урманга **чыгабызмы**, шәһәргә **барабызмы**, ул безне беркайчан да ялгыз җибәрми. (Гомәр Бәширов, Бибек нигә елгый.) Whether we go out to the woods or whether we go to town, he never lets us go alone.
- Эштән кайтып **керәме** ул, **җыелыштанмы, киноданмы**, яки **мунчаданмы** – балалар аны һәрвакыт: – Әти, нәрсә алып кайттың? – дип каршы алалар. (Мирсәй Әмир, Казан урамнарында.) Whether he comes home from work or from a meeting, whether from the cinema or from the bath, his children always meet him, asking, "Daddy, what did you bring?"
- Ул (Искәндәрев) итекләрен дә киеп өлгерми, Хәбибуллин кайтып керә. Төнлә чыгып китүеннән яңа кайтып **кердеме** ул, әллә бераз йоклап, яңадан чыгып йөрүе **булганмы** аның – әйтүе читен ... (Әмирхан Еники, Егет кунакка кайтты.) He (Iskändärev) did (lit., does) not even manage to put on his boots when Khäbibullin returned (lit., returns and enters). Whether he just returned after having been away during the night or whether he was out again after sleeping a little, that is difficult to tell...

*Note again* that the conjunction **яки** in the second example presents the action as a real possibility, whereas **әллә** in example 3 presents it as doubtful, uncertain, unclear.

- **Тыңлыймы, тыңламыймы** – ул кадәресе аның эше. (Әмирхан Еники, Саз чәчәге.) Whether he listens or not is up to him (is his business).
- Либерия корабына төяләсе машиналар тимер юл белән килә. Ә вагоннарның вакытында килеп **җитәме-җитмиме** икәнен тимер юлчылар үзләре дә белми иде. (Миргазиян Юныс, Юлда уйланулар.) The machines which are to be loaded on the Liberian ship arrive by railway. But even the railwaymen do not know whether or not the freight cars will arrive in time.
- – Мин бернинди дә ярамаган эш эшләмәдем. – **Яраганмы, ярамаганмы**, анысы турында сүз бармый. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "I have not done anything improper." "Whether proper or whether improper, that is not what we are talking about."

**[673] әгәр**, **әгәр дә**, **әгәренки** ‘if’, ‘in case’.
These conjunctions connect subordinate clauses expressing condition. However, their use depends more on stylistic rather than grammatical considerations, as the suffix **-са**, **-сә** (see 996), which is joined to the predicate verb to express condition, also connects the subordinate clause with the main clause. **Әгәр** and **әгәр дә** intensify somewhat the condition, while **әгәренки** (see also 996) expresses emotion, as for example: strong desire, apprehension, anxiety.

- – ... Аннары, **әгәр** мин дөрес аңлаган булсам, сезне авылга бәйләп тота торган нәрсә дә юк шикелле. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) “... Then, if I have understood correctly, there does not seem to be anything which keeps you tied to the village.”
- Табигать кешене, **әгәр** ул аны аңласа, яратса, яхшырта, чистарта, матурландыра. (ibid.) Nature, if man understands and loves it, improves, cleanses, enriches him (spiritually).
- – Монысы, әлбәттә, җитди мәсьәлә, – диде Башкирцев ... Ләкин, **әгәр дә** бик теләсәгез, сезне мәктәптән бөтенләй аермаска мөмкин. (Мирсәй Әмир, Саф күңел.) “This is, of course, a serious matter, Bashkirtsev said ... But if you want it very much, it is possible not to completely detach you from the school.”
- **Әгәр дә** Нина әйбәт кенә урнаша алса, сеңлесенең дә кубып килергә исәбе бар, имеш. (Мәгъсүм Насыйбуллин, Ярканат.) If Nina can establish herself nicely, her younger sister too apparently plans to move here. (For **имеш** see 743, a-f; 975.)
- Әй бу оят дип әйткән нәрсә булмаса иде, ... Әй **әгәренки** шулай булса ... Сәүбанны иң алдан барып кочучы мин булыр идем. (Мирсәй Әмир, Карамалы егете.) Oh, if there were not this thing called shame, ... Oh, if it were only like that ... I would be the very first to go and embrace Säwban.

**[674] әгәр дә мәгәр** ‘if then’, ‘in case’, ‘provided’.
**Әгәр дә мәгәр** emphasizes conditions.

- **... әгәр дә мәгәр** бөтен уңышның терлекләрне туендыруга китәчәген белсәң, 80 миллион гектарлы иген кырына ниләр чәчәр идең. (Марсель Зарипов, Отышлы әйләнеш.) If you did know that the entire crop will go to feeding the livestock, what would you sow on an 80 million hectare cornfield.
- – Минем ирем бар, балам ... – Мин Сезне яратам. – Ха-ха-ха, их-ма, егеткәй, бу бит тиле яшьлек хыялы ... **Әгәр дә мәгәр** ирегездән бүген китәм дисез икән, ике дә уйламый мин Сезгә өйләнәчәкмен. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) “I have a husband, a child” ... “I love you.” “Ha, ha, ha, come now, young man, this is just a crazy youthful dream **...**” “If you were to say that you are leaving your husband today, I would marry you without thinking twice.”

**[675] гәрчә** ‘although’, ‘though’.
The conjunction **гәрчә** connects concessive clauses (see 1001, a-b). Like **әгәр**, **гәрчә** *intensifies* but is not essential for the *connection* of such clauses, as they are already joined to the main clause by the particle **да**, **дә** which immediately follows the conditional suffix **са**, **сә** to express concession.

- **Гәрчә** анда тумасам да, Мин бераз торган идем. (Габдулла Тукай, Шүрәле.) Although I was not born there, I lived there for a little while.
- Боерык тоны белән диярлек әйтелгән бу сүзгә Мокатдәс карт, **гәрчә** үзенең хуҗа икәнен онытмаса да, буйсынмыйча булдыра алмады. (Фатих Хөсни, Алтын эзләүчеләр.) Although he did not forget that he was the host, old Möqätdäs could not but bow to these words which were spoken in an almost commanding tone.

**[676] дип**.

The conjunctional word **дип** is the verbal adverb of the verb **дию** 'to say'. Originally used (and still being used) in direct and indirect discourse (for details see 1265, a-b; 1265, c-e), **дип** has developed into a conjunctional word which, depending on the type and form of the predicate of the subordinate clause, establishes various kinds of grammatical and syntactical relationships. In constructions with **дип**, the subordinate clause precedes (except in inversions) the main clause.

**Дип** connects:

1. *Causal clauses.* Cause is expressed by **дип** after a predicate consisting of:

a) A verb in the *indicative mood.*

- – Укырга алмасагыз, акча әрәм итү генә **булыр дип**, китап-дәфтәрсез генә килгән идем бүген. (Вакыйф Нуруллин, Әгәр син булмасаң.) "Today I have come without books and exercise books because, should you not accept me for study, it would only be wasting money."
- Сез мине дөрес **аңламассыз дип** уңайсызландым ... (Сафа Сабиров, Хатлар язам сагынып.) I was embarrassed that (because) you might not understand me correctly ...

b) A future participle in **-асы**, **-әсе**, **-ыйсы**, **-исе** (see 1122).

- – ... кичә мин Дербышкада үземнең туганнарда кунакта булдым. Соң булса да, иртәгә эшкә **барасы дип**, кайтып киттем. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "... yesterday I visited with my relatives in Derbyshka. Although it was late, I returned (home) since (because) I had to go to work the next day."

c) A noun with **бар** or **юк** expressing possession.

- Вакытыбыз юк **дип** юлда туктап тормадык. As we had no time, we did not stop on the road.

2. *Clauses of purpose.* Purpose is expressed by **дип** after a predicate consisting of:

a) A verb in the *imperative mood* 3rd person singular and plural.

- Мин һәр вакыт эшемне кешеләргә **охшасын дип**, кешеләргә файдалы **булсын дип** эшләргә тырышам. (Вакыйф Нуруллин, Аккан су юлны табар.) I always do my work so that it will please the people, so that it will be advantageous for the people.
- Сөтне күбрәк **бирсеннәр дип**, ферма сыерларын ... тәүлек буена көтүдә йөртүне оештырдым. (ibid.) In order that they might give more milk, I arranged to let the farm cows graze (lit., go) on the pasture ... day and night (lit., throughout the 24 hour day).
- ... берәр аңсызы ... килеп үлән **таптамасын**, суны **пычратмасын дип** ... сакчылар көненә бер мәртәбә булса да, үзләренә билгеләнгән җирне караштырып әйләнгәлиләр иде. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) ... so that some blockhead ... would not come and trample the grass (and) pollute the water, the ... guards made their rounds at least once a day, inspecting the area assigned to them.

b) A verb in tie *optative mood.*

- ... күптән уйлап йөргән бер теләгемне **үтим дип**, төшке аштан соң шәһәр музеена киттем. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) ... in order that I might carry out a long held wish, I went to the city museum after lunch.
- Шәйхинең ... уңышны **арттырыйм дип** алай баш ватып азапланмаганын әйткән идем шикелле. (Вакыйф Нуруллин, Аккан су юлны табар.) I have said, I think, that Sheykhi ... did not worry and bother that much to increase (lit., in order that I may increase) the yield (i.e., the yield of the land).

c) A future participle in **-р** in the *dative* (also called infinitive).
- – Сездән бер-бер эш **сорарга дип** төшкән идем. (Ринат Мөхәммәдиев, Беренче умырзая.) "I came down to ask you for some work." (For the pluperfect expressing attenuation see 983.)
- – Рәхмәт, мәшәкатьләнмәгез, – диде. – Мин Зөһрәне киногa **чакырырга дип** кенә кергән идем. (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) "Thank you, don't go to any bother," he said. "I only dropped in to invite Zöhrä to the cinema."
- Ул елларда ... бик күп татар яшьләре, **укырга дип**, Казанга киләләр иде. (Мирсәй Әмир, Казан.) In those years, a great many Tatar youths ... were coming to Kazan to study.
- Мохтар бүген Төхфәтнең хәле ничек икәнлекне **белергә дип** кич белән Шәрәфи картларга барып чыгарга уйлаган иде. (Шәриф Камал, Таң атканда.) Mokhtar had thought to go to the old Shäräfis tonight to inquire how Tökhfät was doing today.

d) A verb in the *future tense I.*
   - Зәйтүнә. ... Инде син миңа әкият сөйлә. Бибинур. Әкият сөйләргә, син бала түгел **лә**. (Риза Ишморат, Давылга табан.) Zeytünä. ... Now, you tell me a story. Bibinur. Tell you a story? After all, you are not a child." (Mild reproach.)
   - Миңлекамал. Ә сез миңа нинди зур эш тапшырмакчы идегез соң? Гыйльманов. Нәкъ шул үзегез сораган эшне: ... Миңлекамал. **Булмас ла**, шаяртасыздыр?

(Мирсәй Әмир, Миңлекамал.) Minglekamal. But what kind of an important job did you want to entrust me with then? Ghilmanov. With the very job which you yourself asked for: ... Minglekamal. Impossible, you are joking, aren't you? (Doubt.)

- – Әллә бер-бер хәл булдымы соң, Сәҗидә? – **Юк ла**, берни булмады ... (Мәдинә Маликова, Казан каласы – таш кала.) "Has perhaps something happened, Sajidä?" "Not really, nothing happened ..." (Sajidä is evasive.)
- Рәмзи ... ничегрәк җавап бирергә белмичә уйланып торды. Аннан: – Ә, дип кул селтәде. – Андыйлар кайда да табыла **ла** ул! (Атилла Расих, Сынау.) ... not knowing really how to answer, Rämzi thought for a while. Then, waving his hand as a sign that he did not care, he said, "Oh, after all, one finds such things everywhere." (Indifference.)
- Гафур. Әллә Фатыймага күзең төштеме? Садыйк. Әй, **юк ла**, Гафур абый. Гафур. Кара, кара, нинди кызарды егет. Әллә кыек атып туры тидердемме? Садыйк. Эш турында иде **лә**. (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Ghafur. Have you perhaps taken a liking to Fatima? Sadiq. Oh, no, Uncle Ghafur (pronounced with embarrassment). Ghafur. Look, look, how crimson the young man has turned. Did I perhaps unwittingly hit upon the truth? Sadiq. But it was about work (i.e., about work that Sadiq had seen Fatima).
- Шамил. ... Паспортым бар. Теләгән җирдә яши алам. Эшләрмен дә, укырмын да. **Бала түгел лә**! Хурлык! (Рәисә Ишморатова, Яшьлек канат җәйгәндә.) Shamil. ... I have my passport. I can live any place I wish. I shall work and study. After all, I am not a child (any more). It is a disgrace! (Offense.)
- – Ә Мәхмүт?! Ул томана түгел **лә**! Мин ул бүтәкәгә баштук әйттем – тыңламады. (Фоат Садриев, Авыш басу икмәге.) "But Mäkhmüt! He is no blockhead after all! I told that midget right at the beginning – he would not listen." (Anger.)
- – Мин Мөнир түгел **лә**! – диде Марс авызын ерып. (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында.) "After all, I am not Mönir! Mars said, grinning." (Pronounced sarcastically. Mars thinks that he is smarter than Mönir.)

d) In poems andsongs, especially in longer songs, **ла**, **лә** is used to adjust the words to the rhythm (see 705 and Note).
e) The particle **ла**, **лә** is used with verbs in the imperative mood (see 929).
f) The particle **ла**, **лә** is used with verbs in the conditional mood (see 1006, 2).

**[704] лабаса**, **ләбаса**.

This particle is used postpositionally. Its first syllable is subject to vowel harmony.

a) It serves to sharpen (stronger than бит) a *statement*, an *opinion, assertion,* a *confirmation, supposition, denial,* or *question.*
   - – Бик кызулыйсыз, Ибраһим абзый. Чак кына утырып тын алырга ирек бирегез, ичмасам, әле яңа гына кереп җиттек **ләбаса.** (Шәриф Камал, Сафура.) "You are rushing too much, Uncle Ibrahim. At least allow us to sit down a little and to get our breath back. After all, we have just come in."
   - – Бу мәсьәлә сезгә дә кагыла **лабаса**, Хатип әфәнде, – диде Хәбир. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) "After all, this matter concerns you too, Mr. Khatip," Khäbir said.
   - – Файдасы юк кына түгел, зарары куп, хәтта куркынычлы да булыр иде. – Мин дә шуны әйтәм **ләбаса**! (ibid.) "Not only doesn't it do any good, it does much harm, it would even be dangerous." "That's what I say too!"
   - Талиянең кардәше булгач, ул Акназарга яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш **ләбаса**! (Габдрахман Әпсәләмов, Яшел Яр.) Since she is Taliä's relative, she must, after all, be on good terms with Aqnazar!

- Садыйк. Нигә Зөбәйдә Сөләйманны ярата да, нигә Зарифны яратмый? Зариф бай баласы **лабаса**? (Сәгыйть Рәмиев, Яшә Зөбәйдә, яшим мин!) Sadiq. Why does Zöbeydä love Söleyman, and why does she not love Zarif? After all, he is the son of a wealthy man, isn't he?
- Хәдичә. Ай алла, белмәдем **лəбаса**. (Гариф Ахунов, Утлар яна учакта.) Khädichä: Oh God, I just did not know that.
- Гәрәй. Ай алла, бүре түгел – ашамам **лабаса**. (Шәриф Камал, Козгыннар оясында.) Gärey. Oh God, I'm no wolf. I'm not going to eat you.

b) The particle **лабаса**, **лəбаса** intensifies various emotions or feelings such as: *amazement, surprise, grief, distress, annoyance, offense, disapproval, warning, disagreement, upset, regret, reproof, reprimand, irony, rudeness, anger.*

- Сәфәр. Яшә, Фатыйма! Син матур итеп җырлый да беләсең икән **лəбаса**. (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Säfär. Excellent, Fatima! As I see now, you also sing beautifully. (Amazement, surprise.)
- Мулла. ... Катнашмагыз ... Афәт килә. Гарасат килә! ... Тыңла сүземне! ... Шуннан арысын сорама! Әйткәнемә ышан! ... Зөлфәт. Яшермә, хәзрәт! ... Өстеңә тау кадәр гөнаһ алма. Мулла. Я ходай! Шуңа әйтәм **лəбаса** инде. (Габделхәй Сабитов, Чулпан таңны уята.) Mulla. ... Don't join (participate) in ...! A disaster is coming. The Last Judgment is coming! ... Listen to my words! ... Don't ask me more about it. Just believe what I have said! ... Zölfät. Don't keep it all to yourself (Don't hide it), your Excellency! ... Don't take a mountain of sin upon yourself. Mulla. Oh Lord! After all, that is the very reason that I speak.
- – Кара, нигә тотасыз мине? Мин үзем дә йөри алам **лабаса**! (Шәриф Хөсәенов, Әниемнең ак күлмәге.) "Look, why are you holding me? After all, I can walk alone." (Annoyance and offense.)
- Сәлим. Шыпыртрак мөмкин түгелме? Тавышың бөтен йортка яңгырый **лабаса**. (Хәй Вахит, Беренче мәхәббәт.) Sälim. Can't you lower your voice? After all, your voice is sounding through the whole house! (Disapproval.)
- Үз балам ла инде **лəбаса**! (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) "After all, he is still my child, isn't he!" (Disagreement with the interlocutor.)
- Фазыл. ... Акылдан шашкан! Өч ел торабыз **лабаса** без, шундый хат язарга тиеш идемени ул?! (Сәет Шәкүров, Мәхәббәт газабы.) Fazyl. ... She is out of her mind! After all, we have been living together three years now; was it really necessary to write such a letter? (The speaker is upset.)
- Ай алла, нинди начар сүз әйттем әле мин сиңа? ... Ай алла, белмәдем **лəбаса**. ... Ай алла, ялгыштым **лабаса**. (Гариф Ахунов, Утлар яна учакта.) Oh God, how on earth could I say such bad words to you? ... Oh God, I did not know that at all. ... Oh God, I was all wrong. (Regret.)
- Зөбәйдә. Ал яңа күлмәк – барам! Габдрахман. Кияүгә чыгам дисең **лəбаса**. Киявең алыр. (Шәриф Хөсәенов, Зөбәйдә – адәм баласы.) Zöbeydä. Buy me a new dress and I will go! Ghabdrakhman. Well, you say that you are going to marry, don't you. Your husbvand will buy you one." (Irony.)
- Әхсәт. Исәнмесез! Зөбәйдә кайтмадымы әле? Җәүһәрия. Күрмәдем. (Әхсәтнең чыкмый торуын күреп, тупас итеп.) Әйтәм **лəбаса** сиңа, күренмәде! Кайтканы юк Зөбәйдәнең. (ibid.) Äkhsät. How are you! Hasn't Zöbeydä returned yet? Jäwhäriä. I didn't see her. (Seeing that Äkhsät is not leaving she puts in bluntly.) I told you, didn't I, she did not show. Zöbeydä has not returned.

**[705] ±лай, ±ләй (лай, ләй).**

This is a poetic form consisting of **ла**, **лә** plus **й**. It is subject to vowel harmony. It is joined to both nominal and verbal forms, but may also be written separately. It expresses *regret,*

*sorrow, endearment, love for one's native country* or *region*, etc. Furthermore, it is used to harmonize the text of a song, especially a longer song, to its rhythm.

- **Калдылай** калды туган илем. Өскә салдым соры шинелем. (Фәтхи Бурнаш, Тагы да сәлам хатлар җибәрәм.) It is left behind, (oh, how sad), it is left behind, my (beloved) native land. I put on my grey uniform.
- Ай-һай ла гына дигән ай тавышка кыр **казларылай** кача камышка. Идел буенда шаулый камышлар, сулышларым чыга сөрем булып **эчемдәгеләй** кайгы-сагышка. (Гомәр Бәширов, Урман шаулый.) At the sound of my calling out "ai-hai" and "ai" the (dear) wild geese flee into the reeds. Along the Volga rustle the reeds, my breath comes heavy, because of the grief and sorrow which is in my (poor) heart.
- Шул кара урман аша; Кара урман аша лай, кошлар сайраша лай, башлар адаша. (Мирхәйдәр Файзи, Асылъяр – Song.) Passing through that dense forest; through the dense forest, birds sing, people (lit., heads) lose their way.

*Note:* Besides **лай**, **ләй**, the particles **гына**, **генә** (**кына**, **кенә**), **да**, **дә** (**та**, **тә**) and **ла**, **лә** are also used in poetry and songs, especially in longer songs, to harmonize their texts to their rhythms. Furthermore, they serve to increase poetic expressiveness:
Кара **да гынай** урман, караңгы төн, Яхшы атлар кирәк **лә** үтәргә ... (From the old Tatar-Bashkir folk song "Qara urman".) Oh, how very dense this forest is, and pitch-black the night. Oh, how very necessary are good horses to get through it ...

**[706] ласа**, **ләса**.

This particle is identical with **лабаса**, **ләбаса**. However, it is used more in the vernacular rather than in the literary language. Its first syllable is subject to vowel harmony.

- Денисның күзләре шар булды: ул уен күңеленнән генә әйткән иде **ләса**, ә философ аның ни уйлаганын әйтте дә бирде! (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кубрат хан.) Denis opened his eyes wide. After tall, he had thought this only to himself, but the philosopher said right out what he had been thinking. (For әйтте дә бирде see 1377, 1378.)
- Егорыч. Каян алдың ул акчаларны? Хәйдәр. Таптым. Егорыч. Алдама, Хәйдәр! Урладың? Хәйдәр. Урламадым. ... Зәйтүнә. Дөрес түгел! Бибинур. Гөнаһ **ласа** бу, энем. (Риза Ишморат, Давылга табан.) Yegorych. From where did you get that money? Kheydär. I found it. Yegorych. Don't deceive us, Kheydär! Did you steal it? Kheydär. I did not steal it. ... Zeytünä. That is not true! Bibinur. It is a sin, you know, my brother.
- – Бу мин, Шәмсинур әби, Әхмәтвәли булам. – Кем? – Әхмәтвәли, дим. ... – Ай аллам! – ди карчык, җанланып китеп. – Карасана, танымыйда торам **ласа**. Әхмәтвәли бәбкәм, син икәнсең. Исән,сау гына кайттыңмы соң? (Әмирхан Еники, Тауларга карап.) "It is I, Grandma Shämsinur, I am Äkhmätwäli." "Who?" "Äkhmätwäli, I say." ... "O my God!" the old woman says, brightening up. "Just look at that – me not even recognizing you. ..."

**[707] мазар**.

This particle, which is not subject to vowel harmony, is connected to nouns (seldom to verbs) to form word pairs. It expresses *uncertainty*, supposition.

- Керәләр, барысы да сиңа карап сөенәләр. Минем хәлемне сорашалар. ... **Кибет-мазардан** күчтәнәч-фәләннең агылып торган чагы. (Әсрар Галиев, Асыл кошым минем.) They come in, all of them look at you and are happy (i.e., they share my happiness). They inquire about my health. ... This was the time when presents, etc., were coming (lit., flowing) from I don't know what shops.
- Ул заманда гади солдат белән командирны аеруы ансат түгел, бу егет тә гади солдат кынамы, әллә берәр **командир-мазар** идеме, ачык кына белмәдек. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) At that time telling an ordinary soldier from a

commanding officer was not easy. Whether this young man too was only an ordinary soldier, or whether he was some kind of a commanding officer we did not learn (fully) precisely.

**[708] -малы, -мәле.**

This particle is joined to affirmative verb stems. Depending on the context, it indicates *possibility, permissibility, necessity.* The negative is formed with **түгел**.

*Note 1:* When expressing *possibility*, it is synonymous with the verbal adjective in **-рлык**, **-рлек** (see 1233-1235). When expressing *permissibility*, it has the meaning of **ярый** (see 770, b). When expressing *necessity*, it corresponds to **тиеш** (see 761).

*Note 2:* Tatar verbal stems with **-малы**, **-мәле** correspond to the respective modal auxiliaries in English.

- Шунда аның күзләре Кубрат хан каршындагы рәсемгә төште. Таң **калмалы** иде. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кубрат хан.) Then his eye fell on the picture which was in front of Khan Qubrat. It was amazing.
- Ул арада кызлар килделәр, алар бик матур киенгәннәр, үзләреннән күз **алмалы** да түгел иде. (ibid.) At that time the girls arrived. They were dressed beautifully, (so that) one could not take one's eye off them.
- – Кызым, булыш әле, торып булмый. Аяк каймыкты, күрәсең, **басмалы** түгел. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) "My dear (lit., My daughter), help me, please, I cannot get up. I sprained my foot, it seems. It's impossible to stand (on it)."
- Сөйләп тә **бетермәле** түгел. (Фатих Хөсни, Бәдретдин.) This cannot be expressed in words.
- Таныш, иялэнгән әйберләр булмагач, кайчандыр монда тулы бер гаилә көн иткәнлегенә **ышанмалы** да түгел. (Марсель Галиев, Ерак урман авазы.) As there are no things which are familiar, to which one is accustomed, one cannot believe that at some time a whole family lived here.
- Кызларга чынлап та сүз **әйтмәле** түгел. Бер минут та вакыт әрәм итмиләр. (Әхсән Баянов, Таш китап.) One really cannot (may not) say anything to (i.e., criticize, chide) the girls. They do not waste even one minute (i.e., they work constantly).
- – Син тыгылма, ... – дип кычкырды Әминә. – Безнең Айзат, аллага шөкер, кайберәүләр шикелле акыл сорап күршегә **кермәле** түгел. (Газиз Мөхәммәтшин, Йөрәктәге эзләр.) "Don't you interfere, ..." Äminä cried. "Thank God, unlike some, our Aizat need not go to the neighbor and ask advice."

Verb stems with **-малы**, **-мәле** may be used attributively.

- Аста – ... төзелеш кыры. Салынган һәм салынырга чират көтеп яткан, атлы арба **сыймалы** торбалар ... (Әхсән Баянов, Таш китап.) Below there is ... the construction site. There are pipes which have been laid down, and (such) which are awaiting their turn to be laid down, pipes which can hold a horse and cart (i.e., they are so big in diameter).
- Күк йөзе аксыл-зәңгәр, ... ай **үтә күренмәле** кәгазьдән ясалган кебек. (Мәдинә Маликова, Казан каласы – таш кала.) The sky is whitish-blue, ... the moon as if made from transparent paper (paper which one can see through).
- Тышта буран тагын да котырган, аяктан **екмалы** җил дулап, бөтерелеп, карны өеме-өеме белән һавага күтәрә, әйләндерә, болгата да әллә кайларга алып китә. (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) Outside, the blizzard has become still more intense. Raging and whirling, the wind, strong enough to (which can) knock a person off his feet, lifts the snow up in the air in piles, swirls it around, stirs it up and carries it off.

**[709] ±мы**, **±ме**.

The particle **±мы**, **±ме** is the interrogative particle in Tatar. When used with verbs, it is attached to the personal endings. In questions in which the copula is not expressed after a predicate adjective or noun, **±мы**, **±ме** is joined directly to the latter.

For example:

- Сез Казанда беренче **тапкырмы**? (Русско-татарский разговорник, p. 13.) Are you in Kazan for the first time? Сез театрга еш **йөрисезме**? (ibid.) Do you often go to the theatre? Сораулар **бармы**? (ibid. p. 7.) Are there any questions? Бу рәсем сиңа **ошыймы**? (ibid. p. 34.) Do you like this picture?
- Фәрхиназ. Бу кем? **Өнемме** бу, **төшемме**? Я булмаса **өрәкме**? (Таҗи Гыйззәт, Фәрхиназ.) Färkhinaz. Who is this? Is this reality, or a dream? Or is it perhaps a ghost? (For more details see 954, a-j.)

Furthermore, **±мы**, **±ме** functions:

a) As an *intensive particle*. In this function, **±мы**, **±ме** is joined to the first component of a reduplication consisting of the same noun or verbal form (in writing mostly connected by a hyphen).

- Өйдәге күрешү шатлыклары нәкъ менә **шатлыкмы-шатлык** булып истә калган. (Рафаил Төхфәтуллин, Агымсу.) The joys of reunion at home have remained in my memory as a real joy.
- ... ул аны кулында чак кына уйнаткалап та ала иде булса кирәк, **ялтырыймы-ялтырый** Казан кояшында. (Фатих Хөсни, Алтын эзләүчеләр.) ... he probably was making it (i.e., the walkingstick) play just a little in his hand, (for) it just glistened in the Kazan sun. (For булса кирәк see 1010.)
- Фәез ике сүзнең берендә: «Без җитәкчеләр алдан күреп эш итәргә тиешбез», дип кабатларга **яратамы-ярата**. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) Fäyez just loves to repeat with every other word that: “We leaders must work with foresight”.

b) To indicate *approximateness*.

- Сәгыйдә ... Хафизовның **дүртме, бишме** тапкыр өйләнгәнен сөйләп куйды. (Гөлшат Зәйнашева, Бүләк.) ... Säghidä remarked that Khafizov had been married about four or five times.
- Ике **көнме** баргач, поезд мине Өфегә китереп җиткезде. (Нәкый Исәнбәт, Унсигезенче елдан бер сәхифә.) After traveling for about two days, the train brought me to Ufa.
- ... бармакларында **дүртме** йөзек балкый, ... (Гөлчәчәк Әдһәмова, Үкенечкә калмасын.) ... maybe four rings sparkle on her fingers...

*Approximateness* is also expressed by the construction **-мы/-ме-юкмы**, or **-мы/-ме, юкмы**. Joined to the personal endings of verbs in the past tense I indicative, this construction indicates that the action expressed by the verb has ‘just about’, ‘very nearly’, ‘more or less’ been completed when a second action begins.

- Алар киенеп, ... чыгып киттеләр. Ләкин, бер ярты сәгать **үттеме-юкмы**, әйләнеп тә кайттылар. (Хәсән Сарьян, Паку!) They got dressed ... and went out. But they returned after about half an hour.
- Шул көннән соң ай **үттеме-юкмы**, этисеннән хат килде. (Мөхәммәт Мәһдиев, Мәңгелек яз.) After that day about a month passed  and a letter from his father arrived.
- Ярты чакрым китәргә **өлгердекме-юкмы**, артта каты шартлау тавышы ишетелде ... (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) We had just gone about half a verst when there was the sound of a sharp explosion behind us.

- Бер стакан чәйне эчеп бетерергә **өлгердемме, юкмы** – ... Зәбир килеп керде. (Марсель Галиев, Нигез.) I had just about finished drinking one glass of tea ... when Zäbir came in. (стакан: тустаган).

c) To express 'perhaps'.
- Галим абый һәрвакыт тирән уйда була. **Шуңа күрәме**, ул һәрвакыт башын ия биреп алдан атлый. (Давыт Юлтый, Төн.) Uncle Ghälim is always in deep thought. Perhaps because of that, he always strides ahead with his head bent.

d) The particle **±мы**, **±ме** may form emphatic questions indicating that the speaker expects or prefers, desires a reply expressing the opposite of what is said in the question. The speaker resorts to this form of question to convince the audience (the interlocutor) that his (her) opinion, thoughts, ideas, etc., are the correct ones. To give a greater persuasive strength to his question, the speaker may furnish the reply himself (herself). In the latter case, he may or may not be motivated by doubt or fear that the audience (the interlocutor) might not agree with him (her).
- ... халык ... күңелендәгесен бушатып бетерергә тырышты. Колхоз рәисе Әмирханга нык эләкте: тегермәннең эшләгәне юк, ипине район үзәгеннән ташыйсы – юньле җитәкче шундый эшне **сузып торамы**? (Нияз Акмал, Күгәрчен сөте.) ... the people ... endeavored to pour out all they had on their minds (lit., in their hearts). They came down hard on Ämirkhan, the chairman of the collective farm: the mill isn't working, bread must be brought in from the district center. Is a good executive (lit., leader) then supposed to drag out such things (i.e., delay rectifying the situation)? (Implied answer: Of course, he is not supposed to delay things but to take swift remedial action.)
- Хатынының күңел күтәрелгәнен сизми калган ир **буламы**? (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында.) Is there then a man who does not feel when his wife is in a good mood (in good spirits)?
- – Мәскәүдә укыганда Нәҗип чирләп егылган икән! Чирле кешене эштә **яраталармы**? Мин ... беләм, яратмыйлар.) (ibid.) "While studying in Moscow, Näjip fell ill! (So the speaker has now learned.) Do you think they like sick people at work? I ... know that they don't." (The speaker says this in her capacity as a physician.)
- – Эзләгән егет кулына мал **төшмиме**, Нәҗип туганым? (ibid.) "Doesn't wealth fall into the hands of the man who seeks it, my brother Näjip?"
- – Эш кешесенә кадер **юкмы** бездә? Көчеңне кызганмыйча, ялкаулыкка бирелмичә генә эшлә – барысы да була. ... (Нияз Акмал, Күгәрчен сөте.) "Is it really so that we don't have any esteem for the working man? Just work, sparing no effort and without loafing about – and you'll have everything. ..." (In the speaker's mind, paying decent wages, adding bonuses and supplying adequate housing indicates esteem for the working people. His interlocutor disagrees.)

e) The particle **±мы**, **±ме** is joined to the personal endings of verbs in the *conditional mood* (see 1006, 3), to the verbal adverb in **-п**, (see 1256), to certain forms of the verb **дию** (see 1036, c-d).

f) For **±мы**, **±ме** as a disjunctive and subordinating conjunction compare 657; 671, 672.

**[710] ±мыни, ±мени.**

Consisting of the interrogative particle **±мы**, **±ме**, and the pronoun **ни** **±мыни**, **±мени** is likewise an interrogative particle. It is used:

a) To somewhat attenuate a question. Also, the person asking the question usually expects a confirming answer. However, note that that answer may not always be affirmative. sometimes the question may not require an answer at all.
- – **Китәсеңмени**? – Китәм шул. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең /Şaɑjirnen/ алтын приискасында.) "You are leaving, aren't you?" "Yes, I am."

- – Хәзер сез шул бер эш белән генә **шөгыльләнәсезмени**? – дип сорады Латиф. – Юк, андый эш мөмкин түгел ... диде профессор. (Атилла Расих, Каһарманнар юлы.) "Then you are now occupied with this one assignment only?" Latif asked. "No, such a thing is not possible," ... the professor said. (i.e., he has still other duties.)
- Госман. Эх, киявем итәр идем мин сине. Берсеннән-берсе чибәр ике кызым бар, әйдә, теләгәнеңне сайлап ал. Гайфи. Сеңелесен. Госман. Апасы **ошамыймыни**? Менә дигән ич. Эшчән, ... тәҗрибәсе бар. Әйдә, ике куллап бирәм. Гайфи. Рәмзияне. (Хәй Вахит, Күк капусы ачылса.) Ghosman. Ah, I would make you my son-in-law. I have two daughters, one prettier than the other. Come on, choose and take the one you like. Gheyfi. The younger sister. Ghosman. Then you don't like the older sister? She is really something (really nice), you know. She is hard-working ..., and she has experience. Come, I'll give her (to you) with pleasure. Gheyfi. Rämziä.

b) To ask questions expressing *surprise, joy, indignation, protest, doubt, regret, sorrow, reproach.*

- Хәйдәр елмаеп куйды һәм: – Әни! Син дә **биредәмени**? – диде, гаҗәпләнеп. (Әбрар Шәмин, Сагындырган сукмаклар.) Surprised, Kheydär gave a smile and said: "Mother! You're here too?"
- Ъинъямин. Борындык, син **бездәмени**? Хуш килдең! (Сәгыйт Сүнчәләй, Сәнгатьчеләр.) Benjamin. Is that you, Boryndyq (who is with us)? Welcome!
- Рәшит. ... Ничә рәт рәсемеңне яздым, әмма буяулар алырга да акча бирмисең. Әлфия. Каян алыйм? ... Барлык әйберләремне сатып акчасын ашадыгыз да – **җитмимени**? (ibid.) Räshit. ... How many times have I painted your portrait, and you do not even give me money to buy paints. Älfiä. Where am I going to get it from? ... You have sold all my things and consumed the money from that too – isn't that enough? (Indignation.)
- Әнә әнисе Сәүбанны кочаклый, ә минем кочаклыйсым **килмимени**? Әнә әнисе елый, ул Сәүбанны ярата. Ә мин аны **яратмыйммыни**? Әнисенең аны җибәрәсе килми. Ә минем **киләмени**? (Миреәй Әмир, Карамалы егете.) There, his mother is embracing Säwban, don't I want to too? There, his mother is crying. She loves Säwban. Don't I too? His mother does not want to let him go. Do I? (Expresses protest.)
- – Әнкәй, әйдә икәүләп барабыз тагын? Ындыр табаклары бардыр әле бүтән җирдә. – Әйбәт булырые /bulьrъjь/ да соң – диде әнисе, теләмичә генә. – Нәрсә, рөхсәт **итмиләрмени**? **Тоталармыни**? – диде Хәмдия сагаеп. (Нурихан **Фәттах,** Артта калган юллар.) "Mother, come, shall the two of us go again? Surely, there are still threshingfloors (i.e., threshingfloors where they might find some grain to eat) in other places." "It sure would be good..." her mother said rather reluctantly. "What, do they (i.e., the authorities) not allow it then? Do they detain (people) then?" Khämdiä said guardedly. (Implies doubt.)

(булырые – булыр иде. For the contraction see 988.)

- Фазыл. Өч ел торабыз лабаса без, шундый хат язарга тиеш **идемени** ул?! (Сәет Шәкүров, Мәхәббәт газабы.) Fazyl. After all, we have been living together three years now. Was it really necessary to write such a letter? (Regret and sorrow.)
- – Нигә ул кадәр куасың, экренрәк **булмыймыни**? Арттан куып килмиләр лә. (Сөббух Рафиков, Авыл иртәсе.) "Why are you racing that much, can't you go slower (lit., can it not be slower)? After all, nobody is chasing us." (Reproach.)

c) ±**мыни**, ±**мени** is used to make a comparison (see 670).

d) Just like the particle ±**мы**, ±**ме** (see 709 d), ±**мыни**, ±**мени** may be used in *emphatic* (*exclamatory*) *questions*:

- Бану. Хатын-кыз йөрәген аңлый торган **егетмени** ул! (Риза Ишморат, Гөлзадә.) Banu. But is he then a man who understands a woman's heart? (The expected answer is: No, he is not.)

*Note:* The particle ±**мени**, may be contracted with the modal word **икән**(742, a-e); ±**мени** is then separated. The first component, ±**ме** drops the vowel and is prefixed to **икән**, the second component, **ни**, is joined to **микән** to form **микәнни**.

- Хәсән. Уйнап кына әйтсәң дә телемне бәйләдең... Эх, Фәйрүзә ... Шулай ук сине югалтырбыз **микәнни**? (Риза Ишморат, Серле моң.) Khäsän. Although you said it playfully, you left me speechless. ... Oh, Feyrüzä, will we lose you as well?
- Садрый. Әти, Ногман абый анда юк. Калага киткән дигән булалар. Бәдри. Ә, **шулай микәнни**? Кем әйтте алай дип? (Мирхәйдәр Фәйзи, Галиябану.) Sadri. Dad, Uncle Noghman isn't there. They say he went to the city. Bädri. Oh, is that so? Who told you so?

**[711] менә, әнә.**

Besides functioning as demonstratives and intensifiers of demonstrative pronouns (see 424, a-b), **менә** and **әнә** are used:

a) To place logical emphasis on parts of speech *immediately following them.*

- Гомәр. Мөмкинме? Рәүф. Бик мөмкин. **Менә** танышыгыз: Галия туташ Туйбикова, Гомәр Саттаров. (Шәриф Камал, Ут.) Ghömär. May I (i.e., enter)? Räüf. You are very welcome. Let's get aquainted: Miss Ghaliä Tuybikova, Ghömär Sattarov.
- Илгизәр. **Менә** кем белән киңәшергә кирәк. Нишләп мин аны бөтенләй онытканмын әле. (Әнисә Ибраһимова, Томан тарала.) Ilgizär. He is the one I need to consult. Why then had I completely forgotten about him.
- – Мин аларның ай буена ... тапкан акчасын кайчак бер көн эчендә эшлим! ... **Менә** бүген мин, таң белән торып, Биектау районын урап кайттым. Татар авылларын. (Нияз Акмал, Күгәрчен сөте.) "Sometimes I make the money they make in a month ... in one day. Today I got up at dawn and toured the district of Biektaw, (visiting) the Tatar villages." (The speaker talks about his work as a merchant.)
- – Син, Ахо, чит ил дә чит ил, дисең, – Хәбир елмаеп җибәрде. – Ә үзең **менә** яшәр өчен бер дә чит илне сайламагансың, шушы илдә тукталгансың. (ibid.) "You, Akho, are constantly talking about (i.e., praising) foreign countries," Khäbir interjected, smiling. "But you did not choose any foreign country to live in, you have settled (lit., stopped) in this country here."
- Ишек төбендә безне ябык кына, чандыр гына гәүдәле, ... бер апа инде көтеп тора иде. Барласны күрүе булды, кинәт кенә – Бәй! – дип кычкырып җибәрде. – **Әнә** кем безгә килгән! Таныш егет, бик таныш. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) A rather skinny woman (lit., aunt) ... was already waiting for us at the door. Upon seeing Barlas, she suddenly cried out, "Well! Look who has come to us! A familiar young man, very familiar."
- – Ягез, юк-барны сөйләшеп вакыт уздырмагыз инде, – диде Мансура, ... **әнә** Сәхил вальс уйный ... (Әнисә Ибраһимова, Томан тарала.) "Well now, don't spend the time talking trivialities," Mansura said, "... Säkhil there is playing a waltz, ..."
- Ул нәрсәләр сөйли, әллә киләчәкне юрыймы? Бәхет телиме, ачынып елыймы? Нигә еласын ди – көлә... Шатлана ул. **Әнә** ничек шаулый... У-у-у... (ibid.) What is it (i.e., the wind) saying, is it perhaps foretelling my (lit., the) future? Is it wishing me luck, or is it weeping in grief? Why should it be weeping – it is laughing... It is glad. Hear how it howls... U-u-u...

b) To intensify emotional nuances in speech.

Галия. **Менә** көтмәгәндә нинди шатлык! (Шәриф Камал, Ут.) Ghaliä. What an unexpected pleasure!

- – Теләсәм, шул мактаулы егетләрегезнең башын шундый итеп әйләндерермен ... – Тырышып кара. – Мин тырышмам. Үзләре йөгерерләр, **менә** күрерсең. (Әнисә Ибраһимова, Томан тарала.) "If I wish, I can (lit., I will) turn the heads of those

much-praised young men just like that ...” “Try it.” “I shall not try. They themselves will come running (lit., will run), you will see.” (The speaker is conceited and boastful.)

- – Нигә килдең? Хәлемне белергәме? **Менә** исән-саумын. (ibid.) “Why did you come? To inquire about my health? Here, I am alive and healthy.”
- «Илгизәр минем белән **менә** нәрсә өчен сөйләшми йөргән. **Менә** безнең ара нәрсә өчен бозылган. Ниһаять томан тарала башлады. Тик бик соң... бик соң... Их, вакытында аңлаган булсамчы...» (ibid.) That’s why Ilgizär hasn’t been speaking with me. That’s why our relationship has been spoiled. Finally the fog has begun to lift. But very late... very late... Oh, if only I had understood in time... (The subject is thinking the above /in Tatar indicated by quotation marks/. She has come to realize her mistakes and is despondent.)
- «Мин уку турында бөтенләй оныттым, ә Илгизәр **менә** онытмаган, укыган, хәтта институтка керү дәрәҗәсенә барып җиткән. **Әнә** бит ул нинди,» дип уйлап алдым. (ibid.) “I completely forgot about studying, but Ilgizär, he did not forget, he studied. He even reached the level of entering the Institute. There that’s what he is like,” I thought. (The subject is admiring Ilgizär.)
- – Абый, әллә ни бар! – Кайда? – **Әнә, әнә**, кыштырдый. (Аяз Гыйләҗев, Урамнар артында яшел болын.) “Uncle, there is something there!” “Where?” “There, there – that rustling sound!” (Expresses fear.)

c) Placed at the end of a sentence, **менә** and **әнә** emphasize the part of speech *preceding* them.

- Ризван. Баскан урынымда җир упсын **менә**, әгәр дә мин мин булмасам. (Хәй Вахит, Күк капусы ачылса.) Rizwan. May the earth at the spot where I am standing swallow me, if I am not I.
- – Син, Зәбирә түти, бик тә тормыш җанлы кеше икәнсең, мин сиңа карыйм да исем китә. Чын **менә.** (Габдрахман Әпсәләмов, Яшел Яр.) “You, Aunt Zäbirä, seem to be a person who has a very positive approach to life. I look at you and I am amazed. Really.”
- Батырҗан. Әй, Гайшә, әллә ни үтә матур да түгелсең дә, зәрә яратам инде үзеңне, билләһи **менә**. Гайшә. Ә! Шул-шул **менә**. Матурлык туйда кирәк, ә мәхәббәт көн дә кирәк ди. (Фәтхи Бурнаш, Ялгыз Ярулла.) Batirjän. Oh, Gheyshä, it’s not that you are so very beautiful, but I love you very much – by God, I do! Gheyshä. Why, that’s just it! They say that beauty is needed at the wedding, but love is needed every day.
- Балкыш сул күзен учы белән каплады да эчкә атлады. ... – Ни булды? – Чүп керде **менә**. ... – Өскә таба кара, – диде Зиләйлә. – Уңга, хәзер сулга. ... – Әйберкара күренми. Күз яше белән юылып чыккандыр, бәлки. ... Күзегез әйбәт карый әнә. (Мәдинә Маликова, Фидая.) Balqysh covered his left eye with the palm of his hand and walked in (i.e., walked into the first aid post) ... “What happened?” “Some dust has got right in my eye.” ... “Look upwards,” Zileylä said. “Look to the right, now to the left.” ... “I can’t see any foreign matter. Perhaps it was washed out by tears.” ... “Your eye looks just fine.”
- – Әле генә шалтыраттың лабаса, монда ята дип! Карале, алдашып торуын! – Мин бит сезнең бозауны әйттем. Теге якта күләгәдә ята **әнә**. (Фоат Садриев, Адәм әүлиясе.) “After all, you just called me and said that he is lying here! Now look how you are deceiving me!” “But I was talking about your calf. It’s lying over there in the shade, you see.” (The first speaker, a woman, has misunderstood her interlocutor, thinking that the latter had been talking about her drunk husband lying there.)

d) With such particles as **бит**, **инде**, **ич**, **менә** and **әнә** form compound particles indicating a *higher degree* of emotion.

- Гомәр. Эш турында сүзне ике минутка гына калдырып тор әле. Бу нинди туташ соң? Мин моны һич күргәнем юк бугай. Рәүф. **Менә бит**, мин әйткән эш турындагы сүз дә шушы туташка кагыла. (Шәриф Камал, Ут.) Ghömär. Please, forget about work for just a minute (lit., two minutes). Who is that young lady? I don't seem to recall ever seeing her before. Räüf. Well, you see, what I said about work concerns this same young lady.
- Соңыннан барысы да үзгәрде, утыз алты баланың холкы утыз алты төрле булып чыкты. **Менә инде** син аларның җаннарына ачкыч тап! (Габдрахман Әпсәләмов, Яшел Яр.) After that, everything changed. It turned out that the thirty-six children had thirty-six different characters. Now, to find the key to their hearts and minds.

*Note:* When *following* **менә**, **инде** forms a compound particle. When *preceding* **менә**, it is an adverb of time meaning 'now':
Г. Ай, шушы көй, өзә бит минем үзәгемне. ... **Инде менә** үз исемемне кушып җырлый башладылар. (Мирхәйдәр Фәйзи, Галиябану.) Gh. Oh! That song goes right through me (lit., cuts right to my core). ... Now they have begun singing it, adding my name.

*Note:* The above example is part of a monologue.

- Хуҗа кеше буларак, әтисе озата чыкты Нуриәхмәт хәзрәтне. – Бәрәкалла, бәрәкалла. **Менә ич**, безнең егетебез эшкә дә бик әвәс икән, – дип, чыга-чыгышка Мирсәетнең тырышлыгын игътибарга алды ул. (Ринат Мөхәммәдиев, Сират күпере.) Being the host, his father saw His Holiness Nuriäkhmät out. "Well, will you just look here, your youngster really seems to love work very much," he (i.e., Nuriäkhmät) said, upon leaving taking notice of Mirsäyet's industriousness.

*Note 1:* The boy Mirsäyet had not just shoveled away the snow in the yard and doorways but had even swept them clean too.

*Note 2:* Бәрәкалла – Arabic: baraka 'to bless', allah 'God'. Used as an interjection expressing admiration, delight, amazement, praise.

- Мирсәетнең исә кәефе күтәренке. **Әнә ич**, әтисе сөйләшә башлады аның белән. Шул гына кирәк тә. – Ярар, әти, укырга ярамаса, укымам ул гәҗитне. (ibid.) As for Mirsäyet, he was in a good mood. There, after all, his father had begun to speak with him. That was exactly what he needed. "All right, Dad, if it's not appropriate, I won't read that newspaper."
- **Әнә бит**, әйләнә-тирә дөм караңгыга күмелде. Димәк, таңга ерак түгел. Таң белән кем дә булса чыкмый калмас, чыгар. Кем дә булса шушы ... юлдан узмый калмас, узар. (Сәет Шәкүров, Сәхнәнең кыл уртасында.) There you see, the vicinity is shrouded in pitch-black darkness. That means, dawn is not far. With dawn someone is bound to go outside for sure, someone is bound to pass by on this ... road for sure.

*Note:* The person referred to had been lost in a severe blizzard, but, completely exhausted, finally stumbled upon a road.

- Галимә. Монда бер «әлеп» бар, атасы. Бәдри. Ә-ә-ә, таяк кебекме? **Әнә инде** шуның янында бер тырма теше кебеге дә юкмы? (Мирхәйдәр Фәйзи, Галиябану.) Ghalimә. There is an "alif" here, Father. Bädri. A-a-ah, something like a stick? Now then, next to this, isn't there something like the teeth of a rake?

*Note:* 'Stick': In Tatar, the Arabic letter 'alif' is often referred to as a 'stick' because it resembles a stick. 'Teeth of a rake' refers to the Arabic 'sin' (s) connected with the letter following it. Talking with his illiterate wife, the speaker compares it with the teeth of a rake. Both are trying to decipher the signature on a letter they found among their daughter's things.

e) In conjunction with the particle тагы(н) (717), менә – менә тагы(н) – expresses *astonishment* and *disagreement* with the interlocutor's words.
   - Мөгълифә. ... **менә тагы** иске авыздан яңа сүз, мин ни эшләп сине харап итим? (Галиәсгар Камал, Уйнаш.) Möghlifä. ... What do you know, that's news to me. Why should I do you harm?

f) **Менә** immediately followed by **дигән** (past participle of **дию** 'to say') indicates such qualities as *excellence, cleverness, capability, wonderfulness*.

- **Менә дигән** кешеләр арасында күп нәрсәне аңладым, укыдым, күзләрем ачылды дип уйлыйм. (Атилла Расих, Ямашев.) I think that among (those) wonderful (capable, clever) people my eyes opened, that I perceived, learned many things.
- Ринат бакчада үзенә **менә дигән** дуслар да тапты. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) Rinat found wonderful friends in the kindergarten.
- Моның белән килешергә була. **Менә дигән** кеше, **менә дигән** җитәкче. (ibid.) With him one can communicate. He is a very good man, an excellent (a capable) leader (boss).

**[712] ни**.

The particle **ни** is used postpositionally. Following a noun or pronoun *in the dative*, or used with a verb, it indicates *indifference* towards the thing, idea, etc., of the person(s) denoted by the noun, pronoun, or verb.

- Дөрес, ... аларның күңелле шау-гөре түбәндә ишетелә әле, алар анда Гәүһәрне рәсемгә төшәргә көтәләр. **Балаларга ни**, аларга шул рәсемгә төшү шатлыгы да җиткән, ә Гәүһәрнең күңеле ташына, күзеннән яшь тә бәреп чыга. (Габдрахман Әпсәләмов, Яшел Яр.) True, ... their happy din can still be heard below. They are waiting there for Gäwhär (their teacher) to be photographed (with them on their graduation day). To the children it's all the same. For them the joy of that picture-taking is sufficient, it seems. But Gäwhär is deeply moved, tears even burst from her eyes.
- Имеш, Брагин түрә, ... Тимәш, Күян, Анык вә башка авылларның күп кенә җирләрен үзләштергән. **Әмингә ни**, аның җире юк – хәбәрләрнең болары бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты. (Җәмит Рәхимов, Батырша.) Allegedly, the official Bragin ... had seized a lot of land from Timäsh, Quyan, Anyq and from other villages. To Ämin it is all the same – he has no land, and this news went in one ear and out the other.
- – Ярар, Сәлимҗан энекәш. **Безгә ни**, ни кушсалар, шул булыр, Сәлимҗан энекәш. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) "All right, brother Sälimjan. To us it's all the same. Whatever they order that will be (done), brother Sälimjan."

For **ни** used with verbs to express indifference see 962 and 1005, 4.

A verb in the *negative* form of the *third person singular* followed by the particle **ни** indicates *categorical negation*.

- – Иреккә ирештем дигәч тә, үз-үзеңне белми кыйланып җөрсәң, шулай **булмый ни**! (Эдуард Касыймов, Җир балкышы.) "You may think you have your freedom now (i.e., freedom by studying in another city, away from the parental home), but if you forget yourself and act up, it just won't do!" (җөрсәң – йөрсәң; кыйланып – кыланып).
- Нияз. Ихтыярыгыз. Мең сум өчен атып куйсалар... Мисбах. Өркетмә, егет, өркетмә... Асрау өчен аталар ди, **атмый ни**... (Кәрим Тинчурин, Җилкәнсезләр.) Niaz. Suit yourself. If they shoot you because of a thousand rubles... Misbakh. Don't frighten me, young man, don't frighten me... Shoot a person because of a servant girl ... Surely, they don't shoot one (a person)... (Pronounced emphatically.)

*Note:* Niaz, an officer and secretary of the Moslem Committee, has come to get the thousand rubles Misbakh's former maid claims he owes her. Misbakh is bargaining for a lesser amount.

For **ни** with verbs in the past tense I see 962; with verbs in the conditional mood, 1005, 4; with verbs in **-рга**, **-ргә**, 1155, a-b; with the negative verbal adverb in **-мый**, **-ми** and **-мыйча**, **-мичә**, 1298, 1299, 1300.

**[713] нибары**.

Consisting of the particles **ни** and **бары**, **нибары** is used prepositionally. It refers to numerical figures. It emphasizes that a quantity does not exceed the limit indicated by that figure. Furthermore, it may imply that the limit is lower than that normally needed or expected for the performance of a certain action or the achievement of a certain result.

- Хәсән. Фермада **нибары** өч кеше эшли. (Риза Ишморат, Серле моң.) Khäsän. Only three people work on the farm. (But the farm has a very high income.)
- Разия. Соң, бу сиңа **нибары** ике сәгатьлек эш ич. (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Razia. After all, for you this (i.e., writing a report) is just a two-hour job, isn't it! (Others may need more time.)
- Володя. ... Миңа ошый ул кыз. Сертей. Чыннанмы? Володя. Әйе. Сертей. Син әле аны **нибары** бер генә күрдең... (Риза Ишморат, Давылга табан.) Volodya. ... I like that girl. Sergey. Really? Volodya. Yes. Sergey. But you have seen her just once, ...
- Абдулов. Күрдегезме? Үзем тотынсам, бик тиз тәрбия итәм мин. Миңа аны юлга салу өчен **нибары** ун минут вакыт җитә. (Риза Ишморат, Шайтан таягы.) Abdulov. Did you see? When I make up my mind to it, I teach him very quickly. It takes me just ten minutes to straighten him out.
- Абдулов. ... Бала бит әле ул. **Нибары** ундүрт яшь. (ibid.) Abdulov. ... After all, he is still a child. He is just fourteen years old.

**[714] нәкъ** 'exactly', 'just'.

- **Нәкъ** Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр. (Габдулла Тукай, Шүрәле.) Just behind Kazan there is a village. They call it Qyrlai.
- – Әйе, **нәкъ** менә шул көнне абый янына бер кеше керде. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "Yes, exactly on that same day a person came to see my (older) brother."
- Г. Мин **нәкъ** сез әйткәнчә эшләдем. (Мирхәйдәр Фәйзи, Асылъяр.) Gh. I did exactly as you said.

**[715] -сана, -сәнә**.

This particle, which is subject to vowel harmony, is joined only to verbs in the imperative and optative moods (see 930, a-c; 948).

**[716] соң**.

a) The particle **соң** is used to put special emphasis on a question.
- Шуннан соң Садыйк карт җитди чырай белән: – Инде син миңа шунысын әйт: бу яңа икътисади сәясәт дигән әйбер, **нәрсә соң** ул үзе? – диде. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) After that, old Sadiq said with a serious face: "Now, you tell me this: what is this then, this thing called the new economic policy?"
- Әхмәт. ... Я, мин юкта монда **ниләр булды соң**? ... Я, **ниләр эшләдең соң**? (Мирсәй Әмир, Гөлшаян.) Äkhmät. ... Well, what happened here then while I was away? ... Well, what did you do, then?

b) In *interrogative* sentences, **соң** intensifies various shades of emotions such as *doubt, embarrassment, regrett, worry, amazement, disbelief*.
- Зәйнәп. Искәндәр, син ничек уйлыйсың? Искәндәр. Нурия әйткән материаллар чынлап та бармы икән **соң**? (Кәрим Тинчурин, Американ.) Zeynäp. Iskändär, what do you think? Iskändär. Does the material of which Nuriä is speaking really exist, then? (Doubt.)
- Инзарский. Гафу итегез туташлар. (Гөлҗамалга.) Сез Гөлҗамал туташ буласыз бит? Гөлҗамал (аптырабрак). Сез кем буласыз **соң**? (Нәкый Исәнбәт, Гөлҗамал.) Inzarski. Pardon, young ladies. (To Göljamal.) You are Miss Göljamal, aren't you? Göljamal (somewhat embarrassed). Who are you, then?

- Максудов. Бүген киногa бара алмыйбыз, Разия. Разия. Ничек инде бара алмыйбыз? Билетлар юкмы әллә? Максудов. Билетлар бар. Менә алар. Разия. **Соң**, шулай булгач? ... Максудов. Хәкимов абый бик ашыгыч эш тапшырды ... Разия. Нинди эш **соң** ул? (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Maqsudov. We can't go to the movies today, Razia. Razia. Why can't we go, then? Because there are no tickets, is that it? Maqsudov. There are tickets. Here they are. Razia. Well then, in that case... Maqsudov. Khäkimov has charged me with a very urgent assignment. ... Razia. What kind of assignment is it, then? (Regret and worry.)
- Теге егетләр моңа бик гаҗәпләнәләр: – Бабай, аны кеше итеп **буламы соң**? – диешәләр. (Татар халык әкиятләре, Тылсымлы чыбык.) Those youths are very amazed at this. "Grandfather," they say, "is it possible, then, to turn it (i.e., the sparrow) into a man?" (Amazement.)
- Миләүшә. Гөлшаян, җаным. Арслан белән сөйләштек. Никах укытыр кеше таба алсак, ... Гөлшаян. Табарбыз. Миләүшә. Кемне табарбыз икән? Кайсы авылдан? Гөлшаян. Үзебезнең мулла укыр. Миләүшә. Булмас, ул **укыймы соң**? (Мирсәй Әмир, Гөлшаян.) Miläwshä. Gölshayan, my dear. Arslan and I have agreed. If we can find someone who will perform the wedding ceremony, ... Gölshayan. We will find someone. Miläwshä. Who will we find, then? From which village? Gölshayan. Our own mulla will perform it. Miläwshä. Impossible – he will do it? (Disbelief.)

c) In a dialogue consisting of a question and an answer to it, **соң** conveys *emphatic confirmation* or *consent.* The predicate verb in the answer is in its *negative interrogative* form, *indicative mood*, immediately followed by **соң**. It may or may not be the same verb used in the question.

- Әсма. ... ошадымы консирт? Фәйрүзә. Бик ошады, ... Әсма. ... Сәүбәннең җырлавы да ошадымы? Фәйрүзә. **Ошамыймы соң**! ... Сандугач диярсең. (Риза Ишморат, Серле моң.) Äsmä. ... did you like the concert? Feyrüzä. I liked it very much ... Äsma. ... Did you also like Säwbän's singing? Feyrüzä. Did I like it? You bet! Like a nightingale (i.e., he sings like a nightingale).
- Фәйзелкәбир. ... Ничек тиз риза булды? Әзрәк аңладымы **соң** ул мине? Хәер, нигә гаҗәп калырга? Хатын-кыз **аңламыймы соң**? Минем кебек егет шулай дип торгач, гади авыл хатыны ничек каршы тора алсын! (Мирсәй Әмир, Гөлшаян.) Feyzelkäbir. ... Do you see how quickly she agreed? So she did understand me a little? Why be amazed, anyway? Women certainly do understand. How can a simple village woman resist when a young man like me talks like that!
- Телефон шалтырый. Разия. Тыңлыйм. Әйе. Синме бу, Гөлсинә? ... Ничек? Берсекөнгә? Шулай ук тизмени? ... Озатырга? **Бармыйммы соң**? Барам, ... (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) The telephone is ringing. Razia. Hello (lit., I am listening). Yes. Is this you, Gölsinä? ... How's that? For the day after tomorrow? So soon? ... To see you off? Am I going? Of course! I'm going.

d) If the Tatar predicate verb in the answer is in its *affirmative interrogative* form, **соң** conveys *emphatic disagreement.*

- – Сиңайтәм, Гыйсмәтнең кәләше маржа-мазар түгелдер бит? – **Буламы соң**. Өммегөлсем атлы бала, – дип куйды Банат ... (Җәмит Рәхимов, Бурыч.) "I ask you, isn't Ghismät's bride perhaps a Russian girl?" "But how can she be. She is a girl (lit., child) with the name Ömmegölsem," Banat put in (interjected) quickly. (Сиңайтәм – vernacular, contraction of Сиңа әйтәм.)

e) In *exclamatory* sentences **соң** is used to intensify various emotions and feelings.

- – Нишләп **соң** әле без монда басып торабыз, – диде Сафиуллин, – әйдә киттек, кайтабыз. Әнә минем машина. (Туфан Миңнуллин, Хәсән Вәгыйзович.) "Why then are we still standing here," Safiullin said. "Come on, let's go, we're going home. Here is my car." (Embarrassment.)

- Айсылу. Эштән соң Яшәр тагын өйгә кайтмады. Акбүләк. Сәбәбе нәрсәдә соң? Сөйләшеп караганың бармы? Айсылу. Бар да **соң**, әйтәмени ул. (Риза Ишморат, Шаулыйлар дулкыннар.) Aisylu. Yäshär did not come home after work again. Aqbüläk. What is the reason then? Have you tried to talk to him? Aisylu. I surely have, but will he tell you anything? (Strong confirmation.)
- Кемгә генә охшап шундый булдың **соң** син, балам. (ibid.) Who on earth have you taken after that you have become such a man (i.e., such an evil, heartless man), my son. (Strong rebuke with a connotation of incomprehensibility.)
- – Кызым, мин үзем рәсем ясый белмәдем, сиңа **соң** кемнән күчкән бу! – диде Габбани. (Әсрар Галиев, Асыл кошым минем.) "My dear, (lit., daughter), I myself could not paint (i.e., did not know how to paint). From whom has this been passed on to you, then!" Ghabbani said. (Amazement.)
- Рәкыйп. ... Тотынма, тотынма керләргә. Шулкадәр нәрсәне күтәрергә, җаный, йөрәгең **соң**! (Сәет Шәкүров, Мәхәббәт газабы.) Räqip. ... Don't touch it, don't touch the laundry. To lift something that heavy (lit., that much), my dear, – your heart, you know!" (Cautioning.)

f) The particle **соң** is used with verbs in the *imperative* and *conditional* moods (see 931; 1005, 4-5).

**[717] тагы(н)**.

The particle **тагы(н)** serves:

a) To *convey* or to *intensify* various emotions.

- Хәзрәт. Кем соң ул Таждар хаҗи? Садыйк. Сөләйманның атасы. Хәзрәт. Сөләйманның атасы? Ул нинди Сөләйман **тагы**? (Сәгыйт Рәмиев, Яшә, Зөбәйдә, яшим мин.) His Excellency (Holiness). Who is that hadji Tajdar, then? Sadiq. Söleyman's father? His Excellency (Holiness). And what Söleyman is that then? (Conveys embarrassment.)
- Нәсимә. Киенеп чыксам, аптырадым да калдым: яшүсмер кыяфәтле бер адәм! Ябык, алҗыган. **Багажы тагы**! Гади кәрзин. (Ибраһим Нуруллин, Тукай Петербургта.) Näsimä. When I got dressed and went out (to the station), I was simply stunned. A man with the looks of a teenager! Thin, worn out. And his luggage! A simple basket. (For аптырадым да калдым see 1377, 1378.)

*Note 1:* Näsimä had not expected the great Tatar classical poet to look as described in the example.
*Note 2:* Ghabdulla Tuqai (1886-1913) died young of tuberculosis.

- Газиз. ... Минемчә, аның тәкъдиме ... ничек дип әйтим ... әлегә өлгермәгән. Шакир. Син ни сөйлисең, нәрсә уйлап чыгарасың **тагын**? (Хәй Вахит, Күк капусы ачылса.) Ghäziz. ... In my opinion, his presentation (i.e., project) has ... how shall I put it ... not yet matured. Shakir. What are you saying, what are you cooking up there! (Disapproval, with a shade of anger.)
- Хәмидә. Тик тор син, атаң алдында әдәпсезләнеп сорап торма! Синең шикелле юләргә ярамаган **тагын**. (Галиәсгар Камал, Бүләк өчен.) Khämidä. Be quiet, you. Don't be insolent, asking questions in front of your father! For a fool like you it just isn't proper. (Anger and warning.)
· Җирнеӊ уртасында суы кипкән күл **бар**. (Галимҗан Ибраһимов, Табигать балалары.) In the middle of the field there is a lake whose water has dried out.
· Җәмилә. Камилә, кайда син? Бар, әнә ишектә кеше **бар**, ... (Галиәсгар Камал, Бәхетсез егет.) Jämilä. Kamilä, where are you? Go, there is somebody there at the door, ...
· Наилә. ... Дөнья шул кадәр кызык ич! Сәнгать, музыка, спорт, театрлар, эш-хезмәт **бар**. (Аяз Гыйләҗев, Без унике кыз идек.) Nailä. ... The world is so interesting, you know! There is art, music, sport, theatres, (one’s) work.
· Шәрәфи карт тыныч кына: – Әле вакыт **бар**, – диде. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) Old Shäräfi said calmly, “There is still time.”
· Зөбәйдә. Нихәл. Ни хәлләр **бар** сездә? (Сәгыйть Рәмиев, Яшә, Зөбәйдә, яшим мин.) Zöbeydä. How are you. How are things with you?
· – ... сездән китүчеләр **бармы** соӊ? – Бик **юк** шул, яшьләрдән генә бераз **бар**, – диде Хәкимулла. (Хәниф Хәйруллин, Канатлар талмасын.) “... are there any leaving you (lit., going away from you then?” “There are very few, only a few of the young people,” Khäkimulla said.
· Утызлап кына кеше **бар иде**. (Сәгыйть Сүнчәләй, Сәнгатьчеләр.) There were only some thirty people.
· ... шуннан соӊ аларныӊ дуслыклары тагын да артты. Бу дуслыкны арттыра торган башка сәбәпләр дә **бар иде**. (Кәрим Тинчурин, Икенче мәрҗән.) ... after that, their friendship grew still more. There were also other reasons which caused this friendship to grow.
· Анда син дә **бар идеӊ**? (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күӊел.) You too were (present) there?
· ... күк йөзендә бер генә болыт кисәге дә **юк**. (Кәрим Әмири, Югалган малай.) ... there is not even a small cloud in the sky.
· ... урманда аныӊ йөрмәгән һәм белмәгән җире **юк**. (Садри Җәләл, Аккош.) ... in the woods there is no place where he has not walked, which he does not know.
· Җаныӊ ни тели, барысы да **бар**. ... Тик зур шәһәргә бәхет эзләп килгән Сөләйманга эш кенә **юк**. (Кәрим Тинчурин, Беренче мәрҗән.) What (ever) your heart desires, it is all there. ... Only there is no work for Söleyman, who had come to the big city to seek his fortune.

- – Китик, миңа башка юл **юк**! (Атилла Расих, Сынау.) "Let's go away. There is no other way for me!"
- Сәлимә. Әйдәгез, йөреп сөйләшик? Безгә утырырга урын **юк** бит бире. (Фатих Әмирхан, Тигезсезләр.) Sälimä. Come on, shall we talk as we walk? After all, there is no room here for us to sit down.
- Аз гына яктылык биреп торган лампадан башка өстәл өстендә бернәрсә дә **юк иде**. (Шәриф Камал, Уяну.) There was nothing on the table except a lamp, which gave rather little light.
- Һава кичәгегә караганда шәп иде. Җил **юк иде**, ... (Ш. Камал, Акчарлаклар.) The weather was nicer than yesterday's. There was no wind, ...
- Хәзер аңа бер кем дә **юк иде**. (Атилла Расих, Сынау.) Now she had nobody.
- Киләчәк турында уйларлык көч тә, ихтыяр да **юк иде** анда. (Кәрим Әмири, Завод мәктәбендә.) He had in him neither the strength nor the will (to enable him) to think about the future.

(For the verbal adjective in **-р+лык**, **-р+лек** see 1233-1235.)

- Исхакка хат та, хәбәр дә **юк иде**. (Аяз Гыйләҗев, Берәү.) For Iskhaq there was neither a letter nor a message.

**[733]** The form **бар иде.**

This form is also used to express *politeness, modesty, respectfulness.*

- – Газиз абый, – диде ул, ..., – минем сезгә бер бик кирәкле соравым **бар иде**. (Мирсәй Әмир, Ялантау кешеләре.) "Uncle Ghäziz," she said, "I would like to ask you a very important question."
- – Минем сезгә әйтәсе сүзем **бар иде**, Җәгъфәр. (Габдрахман Әпсәләмов, Яшел Яр.) "I would have a word to say to you, Jäghfär."
- Карт ... : – Я, нишлибез, анасы? Узеңме чәй ясыйсың? – диде. – Минем әле азрак эшләрем **бар иде**, үзең генә башкара тор әле, – диде карчык. (Ш. Камал, Акчарлаклар.) The old man ... said, "Now, how do we do it, Mother? Will you be making the tea?" ... "I thought I would still get to do a few things. You go ahead with it, please," the old woman said.

**[734] бар** and **юк**

may be the predicate of *synthetic subordinate clauses.* (For the latter see Index.)

- ... акчасы **бар** кешегә кибет тулы товар. (Ибраһим Гази, Канатланыр чак.) ... for people who have money the store is full of goods.
- **Бар** нәрсәнең кадере юк. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) A thing which one has is not appreciated (has no value).
- Ил **бар** җирдә ир бар, ир **бар** җирдә ил бар. (ibid.) Where there is a country, there is a man. Where there is a man, there is a country.
- Комы **юк** су булмас. (ibid.) There cannot be any water which does not have sand.
- Сандугач **юк** елны карга дан тотар. (ibid.) The year when there are no nightingales, the crows will win (lit., seize, catch, hold) fame.
- Ул (Лиана) өйдә **юк** чакны Сафурага җиңелрәк иде. (Атилла Расих, Сынау.) For Safura it was easier at the time when she (Liana) was not in the house.

**[735] бар** and **юк** may be used *attributively.*

- – Нигә аңа исең китте, ул **бар эш**. "Why are you amazed at that; it is a fact (lit., it is an existing thing, matter)."
- Габделкәрим. Нинди **юк сүз** бу! Бәдигыльҗамал. Бер дә **юк сүз** түгел. (Галиәсгар Камал, Кайниш.) Ghäbdelkärim. What empty talk this is! Bädigheljamal. It is not empty talk at all.

- **Юк кешедән юк сүз** чыгар. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) From a shallow person a shallow word will come forth.
- «Балалар кала, – диде ул һәм тамак төбе белән: – Бәдәр!» – дип кычкырды. Баягы хатын **юк җирдән** бар булды, ... (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында.) "The children stay here," he said and (then) shouted at the top of his lungs: "Bädär!" The same woman appeared from nowhere, ...

**[736] бар** and **юк** used in the *dative* or *ablative case*, indicate *cause, reason.*

- Наилә. Матур яшисез, Наҗия. Ирең дә менә дигән уңган кеше. ... Мактар җире **барга** мактыйм. (Аяз Гыйләҗев, Без унике кыз идек.) Nailä. You live beautifully, Najiä. Your husband too is an extremely clever man. ... I am praising him because he has a laudable trait.
- ... заманы шул. Ирек булса, берегез дә оялаcы түгел, тик ирек **юктан** гына аптыраш. (Фатих Әмирхан, Рәхәт көн.) ... times are like that. If there were freedom (i.e., freedom from narrow customs), not one of you would have to be ashamed; only because there is no freedom is there embarrassment. (For -асы түгел see 1125, a-c.)
- Ул алай күп уйланып, **юкка-барга** йөрәк бозып яшәргә күнекмәгән иде. (Нурихан Фәттах, Кичү.) He was not used to living that way, thinking a lot and worrying (losing his spirits) because of a petty little matter.

**[737]** Used in the *locative case* (with or without the possessive suffix of the third person singular), **бар** and **юк** indicate *time.*

- Акчаң **барда** юк чагын истә тот. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) When you have money, remember the time when you had none.
- – И дусым, син мин **барында** курыкма. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) "Oh my friend, don't be afraid, I am here."
- Гайшә. Кеше **юкта**, тыныч чакта рәхәтләнеп утырыйк әле. (Таҗи Гыйззәт, Кыю кызлар.) Gheyshä. While there is no one (around), while it is quiet, let's sit and enjoy ourselves.
- Алчын. Ярар, ул **юкта** син бире нишлисең? (Нәкый Исәнбәт, Хуҗа Насретдин.) Alchyn. All right, what are you doing here in his absence?
- Хатыны Хәдичә әйтә: – Алайса, мин дә туганнарымны күреп кайтыйм, барыбер монда миңа якты көн булмас син **югында**, – ди. (Татар халык әкиятләре, Чибәр кыз Хәдичә.) His wife Khädichä says, "If that is so, I too will go away to visit my relatives, for I shall not have a happy day here with you away."

**[738] бар** and **юк** may function as nouns.

- **Бар** – бакыр, **юк** – алтын. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) What you possess is copper, what you do not possess is gold (i.e., things which one has are not appreciated).
- Аты **барның** канаты бар, сыеры **барның** сые /sыjь/ бар. (Proverb.) He who has a horse has wings, he who has a cow has fare (has something to offer his guests).
- – Анда син дә бар идеңме? Мин синең **барыңны** белмәдем. (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күңел.) "You too were there? I did not note your presence."
- Ярулла. Эше **юкның** ашы да булмас, ... (Фәтхи Бурнаш, Ялгыз Ярулла.) Yarulla. He who has no work won't have any food either, ...
- Эше **юкка** көн дә бәйрәм. (Нәкый Исәнбәт, Татар халык мәкальләре.) For him who has no work every day is a holiday.
- **Юкны бар** итеп сөйләү. To speak, making something out of nothing (i.e., To make a mountain out of a mole-hill).
- **Юктан бар** булу. To arise (spring up) from nothing.

**[739]** Furthermore, **бар** and **юк** are used:
a) To render 'to have', 'to possess'; 'not to have', 'not to possess' (see 206, 207).
b) With the past participle in **-ган**, **-гән**, **-кан**, **-кән** (see 1076, a-f).
c) With future participles (see 1118; 1129, 1. a-d, 2; 1130; 1132; 1133).
d) With the verbal noun in **-у**, **-ү** (see 1193, 1194).
e) **Юк** is used in denying, corresponding to English 'no'.

**[740] бугай**.
This modal word expresses *supposition* (probably, must, as it appears/seems, it seems, I(we) believe).

- – Башлыйбыз, иптәшләр! ... Барыбыз да җыелып беттек **бугай**. (Барлас Камалов, Өметең өзелмәсен.) "Let's begin, colleagues! ... All of us are here (assembled), I believe."
- Бу очрашуга алар икесе дә шат **бугай**. (Ринат Мөхәммәдиев, Беренче умырзая.) It seems that they are both happy about their running into each other like this.
- – Вакытсызрак килеп төштек **бугай**, гафу итегез, – диде Тәүзих. (Мәдинә Маликова, Фидая.) "It seems we have come at a somewhat inconvenient time. We beg your pardon," Täwzikh said.
- Нәҗип сүз кыстырырга тырышмады, сүзе дә юк иде **бугай**. (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында.) Näjip did not attempt to throw in any remark. It seemed he had nothing to say.

**[741] бәлки**.
This modal word attenuates a *request* or *demand,* i.e., it indicates the speaker's *polite restraint* in making his (her) request or demand. The attenuated verb is in the future tense I.

- – Мин менә, гадәтемчә, йолдызларымны барларга чыктым. ... – Мөмкин булса, иренмәсәгез, **бәлки** Җидегән турында сөйләрсез миңа. (Гурий Тавлин, Афәт.) "Well, I came out to scan my stars, as is my habit." ... "If possible and if you don't mind, perhaps you could talk to me about the Great Bear?"
- – Миңа ут комачаулый бит, **бәлки** сүндерерсез? (ibid.) "The light disturbs me, you know, would you put it out?"
- – Башта **бәлки** сез сөйләрсез, аннары – мин. (ibid.) "Perhaps you will talk first – then I will."
- – Теге көнне мин үзем турында сөйләгән идем, бүген **бәлки** сез үзегез турында сөйләрсез? – диде Оля, мине күлтыклап. (ibid.) "The other day I talked about myself, perhaps you'll talk today about yourself?" Olya said, putting her arm through mine.
- Потопов, Хөрмәтле әфәнделәр! Кекин. Әгәр хәзер үк моннан китмәсәгез, ул чагында мин... Потопов. Хөрмәтле әфәнделәр! Кекин. Мин үзем китәм! Әйе, әйе! Әйе! Потопов. Сез **бәлки** бераз тынып торырсыз, Кекин әфәнде? (Риза Ишморат, Давылга табан.) Potopov. Esteemed gentlemen! Kekin. If you don't leave here immediately I'll... Potopov. Esteemed gentlemen! Kekin. I am leaving! Yes, yes! Yes! Potopov. Perhaps you'll calm down a bit, Mr. Kekin? (Potopov is having a meeting with university students to hear their complaints. Some students think that Potopov is biased and Kekin keeps interrupting him.)

**[742] икән**.
**Икән** is a participle (see 975) of the defective auxiliary verb **и-** (see 974, a-d).
As a modal word it is used:
a) To indicate *assumption* or *knowledge based on hearsay.*

- – Син мине дөрес аңламагансың **икән**, ... (Газиз Мөхәммәтшин, Йөрәктәге эзләр.) "You didn't understand me correctly, it seems, ..."

- Өзелеп-өзелеп сайрыйлар, көнозын сайрыйлар. Туймаслар **икән**. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) They (i.e., the skylarks) are warbling at the top of their voices. They warble all day long. They can't get enough of it, it seems.
- Минем ул озын көйне кайчандыр ишеткәнем бар иде. Фәтхи миңа аның тарихын сөйләргә кереште: – Шушы Идел буендагы авылларның берсендә, бик күп еллар моннан элгәре, ярлы гына бер кеше яшәгән, ди. ... Бар **икән** ди, моның Сәфәр исемле бердәнбер улы. Егет матур да, җитез дә **икән**. Ул җыралаганда шул, аны ишеткәннәр эшен ташлап ... хәйран калып тыңлыйлар **икән**. Шулай тыңлыйлар **икән** дә: «Әй, Сәфәр, ... Син туганда, баш очында былбыл сайрап тордымы **икән** эллә, югыйсә?» – дип әйтәләр **икән**.

  Менә шул җырчы егет өстенә, бер заман, урман кискәндә, агач ауган да, ул шунда ук үлгән. ... Атасы тамагына ашамый, йокысын йокламый, әйткәнне аңламый башлаган. ... Аны юатырга авылның иң оста гармоньчылары, скрипкачылары, җырчылары киләләр, уйныйлар, җырлыйлар **икән**. Тик берсе дә атаның күңелен таба алмый, ди. Ул әйтә **икән**: «Юк, дусларым, күңелем тынычланмый, ...» ди **икән**. Тагын уйныйлар **икән**, ул тагын шулай дип әйтә **икән.** ... (Гомәр Бәширов, Урман шаулый.) I had heard this long song at one time. Fätkhi set about telling me its history: –They say that a great many years ago there lived in one of these villages along the Volga a rather poor man. ... He had, they say, only one son, called Säfär. The young man is said to have been both handsome and clever. – And when he sang, the people who heard him would stop their work ... and listen in amazement, they say. They would listen (like that) and say: "Oh, Säfär, ... When you were born, must there not have been a nightingale singing at the head of your bed?"

  Now, once, when that young singer was felling trees, a tree fell upon him, and he died instantly. ... His father, they say, began not taking food, sleeping, or understanding what was said to him. ... To console him, the most skilfull accordionists, violinists and singers of the village came and played and sang, they say. But none of them could cheer the father up. He is said to have told them: "No, my friends, my heart cannot be soothed, ..." They would play again, but he would say the same again, they say.

b) To relate an actual event or state which has become clear, obvious, or manifest to the apprehension of the narrator's mind through *his own observation* or *experience.*

- Фәез инде кайтыр якка борылды. Күпмедер баргач, күзгә таныш шәүлә чалынды. Борис **икән**. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) Fäyez was already turning back. After he had walked a short distance, a familiar silhouette struck his eye. It turned out to be Boris.
- Янбулат бик киң күңелле, табигате белән тыйнак бер кеше **икән**. (Габдрахман Минский, Язгы ояну.) Yanbulat turned out to be a very broad-minded and, by nature, modest man.
- Карагыз әле, аның бит иртәдән бирле ашаганы да юк **икән**, бу турыда тик менә хәзер генә исенә төште. (Фатих Хөсни, Утызынчы ел.) Look here, obviously, he has not had a bite to eat since morning. He has become aware of this only just now.
- – Мин – Уфа ягы, ә бу иптәш Златоуст ягыннан була, ... хатын, безнең бу сүзебезне ишеткәч, тагын да кызыксына биреп: – Уфа ягыннан **икән**! Алай булгач, безгә якташ буласыз бит. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) "I am from Ufa, and my friend here is from Zlatoust." ... hearing these words of ours, the woman became still more interested: "From Ufa you say! Then you are a countryman of ours."
- – Тавышың бик матур **икән**, Зөһрә, – дидем. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) "Your voice is very beautiful (I hear), Zöhrä," I said.

- Келәтнең үз йозагы бар **икән**, өйне бикләргә дә бер иске богау йозагы бар **икән** әле, ... (Әмирхан Еники, Әйтелмәгән васыять.) It turned out that the storeroom had its own lock, and that there was also still an old chain lock to lock the house, ...
- Без малай чакта Сәгъди абзый Өчиле авылыннан Кырлайга асрамага дип бер малай алып кайтты. Малай Габдулла исемле иде. (Ул вакытта аны инде Казаннан Өчилегә китергән булганнар **икән**.) (Зәкия Рәсулева, Тукай эзләреннән.) When I was a boy, Uncle Säghdi returned to Qyrlai from the village of Öchile, bringing with him a boy as a foster child. The boy's name was Ghabdulla. (At that time they had already brought him from Kazan to Öchile.) (The writer relates some recollections of a contemporary of Tuqai's and adds a remark emphasizing an actual event which she has a good knowledge of, but has not witnessed herself.)
- Камил Миләүшәнең үзе, аның уку эшләре турында сорашырга күчте. Миләүшә университетка имтихан бирү өчен Казанга килгән булган **икән**. (Мирсәй Әмир, Ялантау кешеләре.) Kamil switched to inquiring about Miläwshä herself, her studies. It turned out that (as she told Kamil) Miläwshä had come to Kazan to take the (entrance) exam for the university.

c) Depending on the context, **икән** serves to express, or intensify various modalities, such as *surprise, amazement, supposition, apprehensiveness, regret, uncertainty, doubt, disbelief, hesitation, wondering, unfulfilled desire* (with the conditional in **-са**, **-сә**), *reflectiveness, pensiveness.*

These modalities arise from a context of emotionality, i.e., the subject's becoming affected by the event or state as described under a) and b).

*Note:* The examples listed below will naturally also fall under categories a) and b).

- Ә офыкларда болытлар, болытлар. Без шул якка таба барабыз. Анда тагын нәрсәләр бар **икән**? Еракмы **икән**, якынмы **икән** ул алма, чия, хөрмә җирләре? (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) And on the horizon there are clouds and clouds. We travel in that direction. I wonder, what else might there be? Were those places where apples, cherries and dates grow, far or near?
- ... минем турыда уйлыйлар **микән**? Кайларда гына яши, дип әйтәләр **микән**? ... Are they (the boys back home) thinking of me, I wonder. Do they talk about where I (lit., he) might be living?

*Note:* **Икән** may be contracted with the interrogative particles ±**ме** and ±**мени**.

- Хәсән белән Хәлимә һаман кайтып җитә алмыйлар әле. Кайтмаска булдылар **микәнни**? (Вакыйф Нуруллин, Җавап бир, кеше.) Khäsän and Khälimä are still unable to return. Have they perhaps decided not to return then?
- – Ни кирәклеген үзегез белмәгәч, мин каян белермен **икән**? – диде ул. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) "If you yourself don't know what you need, how, then, can I know?" she said.
- Булышырга теләсәм дә, ул риза булыр иде **микән**. (Фәнил Галиев, Командировка.) Although I want to help him, still, I wonder if he would agree (to it). (The speaker has doubts, is uncertain.)
- – Син **икәнсең**! – Бик вакытсыз йөрисең! – диде [карт]. (Галимҗан Ибраһимов, Татар хатыны ниләр күрми.) "It is you! You are coming at a very inconvenient time!" said [the old man].
- Әй, Хәдичә апа, син **икәнсең**! Әйдә кер. (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) Oh, Khädichä, it is you! Come on in. (The speaker is surprised.)
- Дәшми торуы яхшырак булган **икән**. (Мирсәй Әмир, Мәхәббәт хаты.) It would (obviously, evidently, plainly) have been better if he had kept silent. (Pronounced with regret.)

- Туганын, яисә бүтән бер якын кешесен эзләп килгән ят кеше кирәк йортны ничек таба **икән**? (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) How, then, is a stranger, looking for his relatives or for another close person, going to find the right house? (The speaker wonders.)
- Гөлбану. Нәрсә генә әйтим **икән** сезгә, нинди генә теләкләр телим **икән**? (Газиз Мөхәммәтшин, Тынгысыз төн.) Gölbanu. What shall I say to you then, what shall I wish you, then? (The speaker wonders. She is at a (momentary) loss as to what to say, what kind of wishes to express.)
- Әгәр минем мәхәббәтем сүнгән булса, ... Мәликәне хәтеремдә саклый идемме **икән**? (Габдрахман Минский, Язгы уяну.) If my love had died, ... would I then really have been able to preserve Mälikä in my memory? (Obviously not, I doubt it very much.)
- Заркай. Сиңа теге вакытта ук ... егетнең үзе белән сөйләшергә генә кирәк булган **икән**. (Нәкый Исәнбәт, Миркәй белән Айсылу.) Zarkai. Obviously, you should have talked with the young man himself right at that time (you really should have...).
- Ләйли. Монда да күренми, кайда **икән** соң бу? (ibid.) Leyli. I don't see her here either; wherever can she be, then?
- – Борчылырлык бер нәрсә дә юк, әнкәй. ... – Аллага шөкер **икән**! – диде Мәликә ... (Барлас Камалов, Ялыкмаслар.) "There is nothing to worry about, Mummy." ... "Thank God!" Mälikä said ... (Emphasis, Mälikä is relieved that there is nothing to worry about.)
- – Елена кирәк иде, өйдә юкмыни? – Юк иде шул, бик хаҗәтмени соң? – Күрәсе бар иде. Тиз кайтырмы **икән**? (ibid.) "I am looking for Yelena; is she perhaps at home?" "No, she wouldn't be, do you need to see her very urgently?" "I really would like to. Will she perhaps return soon?" (The speaker wonders.)
- Әйшә. И, болар тәрәзәләренә яңа тюль алганнар **икән**, карачы. (Нәкый Исәнбәт, Зифа.) Eyshä. Oh! It seems they have bought new curtain lace for their windows, – just look! (Surprise, amazement.)
- Эсмеральда. Ләкин мин уйлыйм, ул эшегез үтмәс. Иван. Aha! Ни өчен үтмәс **икән**? (ibid.) Esmeralda. But I think that work of yours will not pass. Ivan: Oho! Why shouldn't it pass? (Disbelief, doubt.)
- Эсмеральда. Кара, бүген төнлә төш күргәмен **икән**, шулай көзгегә карыйм да чәч тарыйм **икән**. (ibid.) Esmeralda. You know, last night I had a dream; it seems I was (lit.: am) looking into the mirror like this and combing my hair. (The narrator relates an actual event in a pensive way, telling what she remembers.)
- – Ах, шул кошларның берсе **булсаң икән**. (Әхсән Баянов, Декабрьның унөченче көне.) "Oh, if one could only be one of those birds." (Strong wish with connotation of regret.)
- – ... Ул мине үзе белән чакырган иде бит, ... Их, шунда ник кенә бармадым **икән** соң мин? Бәхетеңне кайчан табасыңны **белсәң икән**! Белмәдем шул мин, белмәдем. (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) "... She had invited me to go with her, after all, ... Alas, why on earth didn't I go, then? If one only knew when one will (is to) find one's happiness! That's what I didn't know, I didn't know!" (Deep regret, unfulfilled desire.)

*Note:* If several homogeneous predicates refer to the same subject, **икән** may be used only once, after the last one:

- Димәк, авылдан килгән кичне Шәүкәт Мәрьям белән юри ызгышырга теләгән **икән**. Ул Мәрьямнең аңа үпкәләп китүен **теләгән**, аерылышуда аны гаеплисе **килгән**, яңа танышыннан Мәрьямнең начаррак икәненә үзен-үзе ышандырырга **тырышкан икән**. (Мәдинә Маликова, Казан каласы – таш кала.) That means (as

Märyäm now realizes), on that evening, when Shäwkät returned from the village, he had intentionally quarreled with her. He wanted Märyäm to leave angry at him, wanted to accuse her of breaking with him and tried to convince himself that Märyäm was inferior to his new acquaintance.

d) **Икэн** placed between a *repeated* verb in the **-рга**, **-ргэ** form (compare also its use with the *unrepeated* **-рга**, **-ргэ** form, 1169), indicates the *firm determination* or *decision* of the agent(s) to carry out the action.

- – Юк ла, җыелыш та, утырыш та түгел, без менә Хәнәфи Бариевич белән сезнең янга бераз гәпләшеп алыр өчен ... килгән идек. ... – **Гәпләшергә икән гәпләшергә**. Без әзер! дип елмайды нәкъ Акбашев каршында, өстәлнең икенче ягында урнашып алган ярыйсы ук өлкән яшьләрдәге хатын. (Эдуард Касыймов, Җир балкышы.) “No, it’s not a meeting or session. Khänäfi Barievich and I thought we would come and have a little talk with you ...” “Talk! We are ready!” a woman of rather advanced age, who was seated on the other side of the table, exactly opposite Aqbashev, said smiling. (гәпләшү – vern. сөйләшү).
- – Барырга кирәк дисеңме? – ... Күзгә-күз карап, ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк. – Ярый алайса, **барырга икән, барырга**, – диде Илһам, ныклы карарга килеп. (Фоат Садриев, Шаһзаманов эше.) “You mean it’s necessary to go (i.e., that I go)?” ... “You must face them and talk to them openly (frankly).” “All right then, I’ll go,” Ilham said, coming to a firm decision.

e) **Икән**, placed between a repeated *noun*, indicates *concession* or *resoluteness.*

- Беренче кызына исемне Гөлбикә куштырган иде, икенчесенә исемне Якуб үзе сайлады. Гөлбикә каршы төшмәде. Әйдә, **Кәримә икән Кәримә** булсын, исемне ата кушса кыз бала бәхетле була, диләр. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) Gölbikä had given the name to their first daughter. Yaqub chose the name for the second one himself. Gölbikä did not object. So let it be Kärimä. If the father gives the name, the daughter will be happy (lucky), they say.

**[743] имеш**.

**Имеш** is an old participle of the auxiliary verb **и-**. Functioning as a modal word, it is used:

a) To indicate that the information, news, etc., related by the speaker (writer) is based on what he (she) has heard or been told.

- Нурия. Тегүчегә барып кайтам да, аннан клубка китәм. Буген зур җыелыш була, **имеш**. (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Nuriä. I’m going to the tailor, and after I come back I’ll go to the club. They say there is a big meeting today.
- – Ә сез Тукайның үзен күрдегезме? – Күрдем, бәгырь, күрдем! ... – **Имеш**, ул буйга кечкенә, арык кына бер кеше булган диләр, дөресме шул? (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) “And did you see Tuqai himself?” “(Yes) my dear, I did see him!”... “They say he was a short, rather lean man. Is that true?”
- Институтка керергә дип Әгерже районыннан килгән дә, теләге насыйп булмагач, **имеш,** вакытлыча гына ашханәдә эшләп калган. (Вахит Имамов, Күке.) She has come from the district of Agryz to enter (attend) the institute, and, since her wish was not granted, she has, as she says, stayed on only temporarily, working in the dininghall.

b) To emphasize the *predicate.*

- Хәниф абый бераз тынып торды. Беләм, аның да күңелендә хәсрәт тыпырчына. Сиздерми генә. Ир кеше **имеш**. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) Uncle Khänif remained silent for a little while. I know (I realize) that grief is gnawing at his heart too. He just doesn’t show it. He is a man, after all (i.e., a man is not supposed to show that he grieves).

c) To indicate *uncertainty, doubt, suspicion.*

- Аларга өр-яңа квартирны ... йортның бишенче катыннан бирделәр. Өлкәнрәк яшьтәгеләр өчен бераз югарырак инде югарылыкка, әмма артык зыяны булмастыр, шәт: лифт дигәннәре өзелми эшләп торачак, **имеш**. (Эдуард Касыймов, Җир балкышы.) They gave them a brand-new apartment on the fifth floor of the ... house. True, for people of advanced age it is a bit high, but, perhaps, it won't be too much trouble. They say the elevator will work (function) at all times. (The speaker has doubts about that.)

(For the form югарырак югарылыкка see 1238, b.)

- – Таһир белән башта киңәшим әле. Нигез урыны билгеләмәс микән? Йөрәгем дерт итеп куйды. Моңарчы үз акылы белән генә яшәгән кеше Таһир абыйның киңәшенә мохтаҗ, **имеш**! (Нәбирә Гыйматдинова, Ханым-солтаным.) "I still want to consult Tahir first. Perhaps he can determine the site for the foundation?" My heart began to throb. As if a person, who up to now has gotten along using her own judgment (mind), needed Tahir's advice! (The speaker is suspicious of the woman's motive.)

d) To relate the contents of a *dream*, or things existing only in one's *imagination.*

- [Әгъзәм] төш күрә. ... Гәүһәр бик матур бакчада утыра, **имеш**. Тыңлый. Сандугач сайрый. Әгъзәм дә шунда, **имеш**. ... Зәбирә түти дә чыккан икән. Ул, кулын изәп, Әгъзәмне янына чакыра, **имеш**. Әгъзәм аңа таба бара, ләкин алда ниндидер зәңгәр урман. Шунда балалар уйнап йөриләр, **имеш**. (Габдрахман Әпсәләмов, Яшел Яр.) [Äghzäm] has a dream. ... It is as though Gäwhär is sitting in a very beautiful garden. She is listening. A nightingale is singing. It is as though Äghzäm is also there ... Aunt Zäbirä has gone there too, it seems. She is waving her hand as though calling Äghzäm to her side. Äghzäm walks towards her, but there is some kind of blue forest. Children seem to be playing there.

e) To express various modal nuances such as *dissatisfaction, disagreement, dislike, hesitation, irony, contempt, disgust, anger.* The speaker (writer) repeats his (her) interlocutor's words either verbatim or with slight changes and adds **имеш**.

*Note:* **Имеш** also converts a direct quotation into an indirect quotation.

- Разия. Син инде гафу ит, Барый. Мин бара алмыйм. Үзең генә бар. Барый. Үзем генә?! Башлап үзең шалтыраттың. Киев профессорын каршы алырга мине дә алып бар, аның белән таныштыр дидең. Хәзер инде бармыйм, **имеш**. (Рәисә Ишморатова, Яшьлек канат җәйгәндә.) Razia. You must forgive me, Bari. I can't go. Just go alone. Bari. Alone? At first you yourself called me and asked me to take you along to meet the professor from Kiev and to introduce you to him. And now you say that you are not going. (Expresses dissatisfaction.)
- Гариф. Эх, Дилбәр. Белмисең, Дилбәр. Аңламыйсың, Дилбәр. Күрмисең, Дилбәр. Дилбәр. Дилбәр, Дилбәр! Аңламыйсың да белмисең, **имеш**. Ык-мык итеп сөйләмичә генә әйт инде ичмасам, ... (Риза Ишморат, Серле моң.) Gharif. Oh, Dilbär. You don't know, Dilbär. You don't understand, Dilbär. You don't see, Dilbär. Dilbär. Dilbär, Dilbär! You don't understand and don't know (what it is all about)! At least, say it straight out (lit., without talking incoherently), ... (Pronounced with slight irony.)
- [Наилнең укытучысы] ... көлемсереп беравык карап торды да өстәде: – Сез, Хәдичә ханым, хафаланмагыз, ирегез чакыра икән – җыеныгыз да китегез, ... Җыеныгыз да китегез, **имеш**. Әйтергә генә ансат. ... (Фатих Хөсни, Мәйдан.) ... Smiling, [Nail's teacher] looked at her for a while and added, "And you, Lady Khädichä, don't worry. If your husband calls you, get ready (for the journey) and leave, ..." Just get ready and leave. Well, that's easy to say. (Considering the circumstances, Khädichä is hesitant to accept the teacher's advice.)

(For **икән** expressing condition see 1000, 1. a-b.)

- Зәкия. Халыкны җыймакчы булдым. Юк, зинһар, **имеш**, эш бүлдереп йөрми торыгыз. Миңа сүз кирәкми, **имеш**, эш кирәк. Зиннәт үзе шулай диде. (Мирсәй Әмир, Наилә.) Zäkiä. I wanted to call the people together. But no, please, don't keep interrupting the work! I don't need talk, I need work! Zinnät himself said that. (Pronounced with frustration and irony.)
- Сәфәр. ... 12 не сукмый таралмаслар дип уйлаган идем. Офицер. Уйлаган идем, **имеш**. Бу – уй белән эшләнә торган эш түгел. (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Säfär. ... I thought they would not disperse before the stroke of twelve. The officer. I thought, he says. This is no matter for thinking. (Expresses anger and contempt.)
- Үзе һаман сөйли: ул шагыйрь **имеш**, ул газаплана, аңар матурлык кирәк, **имеш**. Ул йолдызлар белән сөйләшә, ... аларга гашыйк, **имеш**, аларның берсен тапмыйча адашып йөргән, **имеш**, ул аны хәзер генә тапкан, ул йолдыз гүя мин, **имеш**. ... Ул шуннан тагын үзенең шагыйрьлеген сөйләп китте. Аның күңеле бик саф, **имеш**, күңелендә тузан хәтле дә усаллык юк, **имеш**, ... Ул дөнья тормышында шул хәтле фәкыйрь, хатын тәрбия кылырлыгы да юк, **имеш**, ... әмма мәгънәвияте шул хәтле олуг, шул хәтле югары, ... ул өйләнү кебек вак эшләрдән өстен тора, **имеш**. ... Кичә генә Нәфига апай килгән иде. ... аңардан бу кешене сорадым. Ул әйтте: «Хәлфә икәнлеген беләм – **имеш** – шагыйрьлеген белмим» ... «Хатыны һәм дә дүрт баласы белән бергә ... мәчет йортында ук торалар» ди! Кара инде! Оятыңнан җир ярыгына чәнчелеп кит бит. ... Шагыйрь **имеш**, мәшһүр **имеш**, өйләнми **имеш**: бер-ике атна башымны әйләндереп чыгарды бит, каһәр! (Шәриф Камал, Сердәш.) He went on about being a poet, about being tormented and needing beauty. He conversed with the stars, ... was fascinated by them. He had wandered all over, never finding one, and only now had he found one – me. I was just that star, he said. After that, he kept on about his being a poet. His heart was so pure, there was not a speck of evil in it ... He claimed to be so poor in this worldly life, that he couldn't support a wife ..., but his spirituality – that was so great, exalted ... he was above such petty things as marriage. ... Yesterday, Näfighä came. ... I asked her about this man. She said, "I know he is a teacher at a medrese, but I don't know how much of a poet he is." She said that he lives together with his wife and four children ... in the mosque building! Just imagine! I was so ashamed, I could have gone through the floor. A poet! Famous! And not married! And he turned my head for a week or two, the scoundrel.

  *Note:* The above example is an excerpt from a letter in which the writer gives her (girl) friend an account of her experience with that man.

f) In a monologue, to indicate the subject's *mental relation to an event or state affecting him.*

- Менә тиздән ул пенсиягә чыгар. ... Шулай да кыендыр /qiьndьr/ ул җан сөйгән эшеңнән, ... иптәшләреңнән аерылу. Үзең турында гына уйлап, үз мәнфәгатеңне генә кайгыртып гомер сөр, **имеш**. (Җәмит Рәхимов, Кыядагы чәчәкләр.) There, soon he will retire. ... Yet, parting from one's beloved work, ... from one's colleagues ... will probably be difficult. Just imagine, leading a life thinking only about yourself, caring only about your own interests.

**[744] ихтимал**.

An Arabic loanword (verbal noun), **ихтимал** denotes *probability, possibility.* In Tatar it is used both as an *adjective* and as a *noun.*

- Кондрат. ... анда булулары бик **ихтимал**. (Давыт Юлтый, Карагол.) Kondrat. ... it is very probable that they are there.

- Садыйк. Бер дә **ихтималы** юк. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Sadiq. There is no possibility of that at all.
- Нәгыйм. **Ихтималы** юк түгел. (ibid.) Näghim. It is not impossible.

**[745] кирәк**.

a) The modal word **кирәк** expresses *necessity, compulsion* or *obligation, duty, need, requirement, probability, supposition*, or *expectation*. With the first person it may also express *insistence* or *fixed resolve*. Except when indicating probability, supposition, **кирәк** requires the *dative* of the acting person or thing and the participle in **-р**, **-мас/-мәс** in the *dative* of verbs.[1]
   - Морат. ... **миңа** хәзер **китәргә кирәк**. (Нәкый Исәнбәт, Рәйхан.) Morat. ... I have to leave now.
   - ... **миңа** иртә **торырга кирәк**. (Шәриф Камал, Сукбай.) ... I have to get up early.
   - Хәким. Син борчылма, Шәмсия апа. **Хафизга** бераз хәл **җыярга,** йоклап **алырга кирәк.** (Риза Ишморат, Гөлзадә.) Khäkim. Don't you worry, Shämsiä. Xhafiz must rest a little (and) sleep for a while.
   - Нәҗип. **Нишләргә кирәк** инде, Хак абзый? (Газиз Мөхәммәтшин, Тынгысыз төн.) Näjip. What are we to do now, Uncle Khaq? (нишләргә – contraction of ни эшләргә).
   - Исән. Зинһар китеп тор, Хисам дус. **Миңа** аның үзе белән генә **сөйләшергә кирәк**. (Мирсәй Әмир, Наилә.) Isän. Please, leave (for a while), friend Khisam. I must speak with her alone.

b) When indicating *probability, supposition* (expressed by **булырга кирәк**), the acting person or thing (the subject of the sentence) is in the *nominative.*
   - **Иркәбай карт** балык ауларга киткән **булырга кирәк**, аның алачагында кем дә юк иде. (Садри Җәләл, Аккош.) The old man Irkäbai must have gone fishing, (for) there was nobody in his cabin.

   *Note:* Probability, supposition may also be expressed by **булса кирәк** (see 1010).

c) When indicating *probability, supposition* plus *possession*, the person or thing possessing something is in the *genitive*, the thing possessed takes the possessive suffix of the third person.
   - Әхмәт. ... зинһар миңа бер ун-унбиш сум гына акча биреп тор. Мин тиздән бирермен. Исмәгыйль. ... Миндә юк, әнә син Ногманнан сора, **аның** акчасы күп **булырга кирәк**. (Галиәсгар Камал, Өйләнәм... ник өйләндем.) Äkhmät. ... please, give me (for a limited time) just some ten or fifteen rubles. I shall repay them quickly. Ismäghil. ... I don't have it. There, ask Noghman, he must have a lot of money.

d) The action may also be expressed by a *verbal noun* in **-у**, **-ү** (see 1195). In this case, the verbal noun becomes the logical subject of the Tatar sentence and, consequently, stands in the *nominative.* When indicated, the acting person or thing is in the *dative.*
   - Гариф хәлфә дә өстәп куйды: – **Укырга**, һөнәрле **булырга кирәк**! ... Истәй карт үзе җавап бирергә тотынды: – **Уку**, һөнәрле **булу кирәк**, әлбәттә, – диде ул, ... (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) The teacher Gharif too added, "One must study, one must acquire a trade." ... The old man Istey set about answering, "Studying, acquiring a trade is, of course, necessary." (хәлфә: teacher in a medrese).
   - Әхметова. Утырыгыз Сәрби апа. Сезне **күрү миңа** бик **кирәк иде**. (Мирсәй Әмир, Минем хатын.) Äkhmetova. Sit down, Särbi. I need very much to speak with you (lit., I needed very much to see you).

---

[1] This form designates the infinitive in some grammars. For its functions see Index I under 'Infinitive'.

e) **Кирәк**, used with a personal form of the verbal noun in **-у**, **-ү**, indicates the subject's *inner compulsion* to carry out the action regardless of possible obstacles, or it indicates the subject's *absolute obligation* to perform the action expressed by the verbal noun. When indicated, the subject appears in the *genitive.*

- ... үзе борын эченнән генә нәрсәдер җырлый, чит җирләрдә торуның кыенлыгыннан зарлана, туган иленә кайтасы килгәнне сөйли: – Кайтыр идем – илем ерак, кайтмасам – яна йөрәк, – ди, тагы шуның артыннан ук кемгәдер ачуланган сыман: – Карлар түгел, боз яуса да, илгә **кайтуым кирәк**! – ди. (Садри Җәләл, Дим буенда.) ... he is humming some song, complaining about the hardship of living away from the homeland, and says that he desires to return to his homeland: "I would return, but my country is far away – still, if I don't return – o, my heart aches." Then, right after that and, as if angry at someone, he continues, saying: "Even if it doesn't just snow but hails, I *must* return to my country!"
- Һидият кичә шәһәргә киткән иде, бүген кичкырын ул кайтырга тиеш. Киңәшмәдә әлбәттә **аның** да **булуы кирәк**. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) Hidiät traveled to the city yesterday. He is due to return this evening. He too *must*, of course, be at the meeting. (Hidiät is one of the important personalities.)

f) A noun or pronoun denoting the person or thing *needed* stands in the *nominative.* The person or thing *needing* someone or something is in the *dative.*

- Рәшидә. Гафу итегез, **сезгә кем кирәк**? (Мирсәй Әмир, Мәхәббәт бүлмәсе.) Räshidä. Pardon me, who do you want?
- – **Сиңа** миннән **ни кирәк**? (Габдулла Тукай, Шүрәле.) "What do you want from me?"
- Официант. **Сәзгә нәрсә кирәк**? (Кәрим Әмири, Печән базары.) The waiter. What will you have?
- Сәйфуллин. Әйдә, бергә китәбез, Муса. Муса. Юк, Шәрәф, Мөмкин түгел бу. **Мин** монда **кирәк** хәзер. (Риза Ишморат, Улмәс җыр.) Seyfullin. Come, let's leave together, Musa. Musa. No, Shäräf, this is not possible. I am needed here now.

g) **Кирәк** may express a need in the sense of 'having use for', 'being desirable, wanted'.

- – Куян табып бирә алам. Ун тәңкә. **Кирәкме**? – **Кирәк**, – дидем мин. ... Алма ал. Күпме **кирәк.** ... яхшыларын сайлап ал. (Рөстәм Кутуй, Бер дә бер көзне.) "I can get you a hare. Ten rubles. Do you want it?" (Do you have use for it?) "I do (want it)," I said. ... "Take some apples. As many as you want (have use for) ... pick good ones."

**[746]** *Tenses* and *moods* are formed by placing the defective auxiliary **-и** (974, a, c; 975) or the auxiliary **булу** (974, b; 976) after кирәк.

- **Миңа** Казанга **кайтырга кирәк иде.** (Мирсәй Әмир, Сәдака.) I had to return to Kazan.
- ... Артыкбикәнең безнең янда каласы килмәдеме, әллә чынлап та **аңа китү кирәк идеме**, ул безне калдырды. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) ... whether it was that Artyqbikä did not wish to remain with us or that she really had to leave, she left us alone.
- ... мин ... гади бер кеше булып калырга теләдем, шунлыктан **миңа** яңа баштан укырга **тотынырга кирәк булды**. (Фатих Әмирхан, Минем тәрҗемәи хәлем.) ... I ... wanted to be an ordinary man. Therefore, I had to (it became necessary for me to) start studying all over again. (Up to then he had studied in a religious school.) (For the difference between **булды** and **иде** see 977, 3, and Note; 975.)
- Аларның **икесенә**, йөреп туңгач, җылынып чыгарга **урын кирәк булган**, ... менә ни өчен алар кергәннәр. (Фатих Әмирхан, Сүнгәч.) After walking and feeling cold, both of them must have needed a place to warm up, ... This is (probably) why

they dropped in. (The acting person is thinking, supposing this.) (For the past tense II see 966.)

- Күчәрбай ... җавап бирде: – **Миңа** бу авылдан **китәргә кирәк булыр**, иркәм. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Küchärbai ... answered, “I will have to leave this village, my dear.”
- – Ә бәлки **аңа** ... берәр **ярдәмче кирәк булыр**, ... (Атилла Расих, Сынау.) But perhaps she will ... need some assistant, ...
- Кәлимуллин. Аларны **өйрәтү өчен**, кимендә бер ел **вакыт кирәк булачак**. (Гамир Насрый, Кадерле минутлар.) Kälimullin. To teach them will require at least a year’s time.
- Хөсәен. Егетләр, кызлар, берегез дә китмәгез, **сез миңа кирәк булырсыз**. (Фәтхи Бурнаш, Хөсәен мирза.) Khösäyen. Men, girls, don’t leave – not one of you. I shall need you.
- – Әле тикшерү бара. **Кирәк булсаң**, үзебез чакырырбыз, – диделәр. (Эдуард Касыймов, Гомер ике килми.) “The investigation is still continuing. If we need you, we will call you ourselves,” they said.
- Рөкыя. ... **Кирәк булса**, мин сиңа аның хатын бирим, апа. (Фатих Әмирхан, Тигезсезләр.) Röqiä. If necessary (needed), I will give you his letter, sister.

**[747] кирәк**. Formation of the negative.

a) The *negative* of **кирәк** is formed by placing **түгел** (түгел иде) or a negative form of **булу** after **кирәк**.
   - Мөгълифә. Синең миңа **ышануың** һич **кирәк түгел**. (Галиәсгар Камал, Уйнаш.) Möghlifä. You don’t have to believe me at all.
   - Фәнүсә. Безгә **синең бер тиен** акчаң **да** кирәк **түгел** һәм шулай ук ... **Үзең** дә **кирәк түгел**. Хуш, Әбелгаяз. (Газиз Мөхәммәтшин, Тынгысыз төн.) Fänüsä. We don’t need even one penny of your money, and ... we don’t need you either. Goodbye Äbelghayaz!
   - Ничә көн, ничә атналар буе, караңгы төшсә дә, Сөембикә ут кабызырга, чырак яндырырга кушмады. Хәтта көндезләрен дә ул тәрәзәләрдәге кояш каплавычларын ачтырмады. Яктылык та, җылылык та, һава да аңа **кирәк түгел иде.** (Батулла, Сөембикә кыйссасы.) For how many days and how many weeks, even when darkness fell, Söyembikä did not permit (or: order) a light to be made, a torch to be lighted (i.e., a torch to light the room). During the day, she did not even have the (window) shutters opened to let in the sun. She needed neither light nor warmth nor air.
   - **Аңа** эшне сәгатькә карап эшләүнең ни дәрәҗәдә файдалы икәнлеген белү өчен артык зур тәҗрибә **кирәк булмады**. (Атилла Расих, Ике буйдак.) He did not need too great experience to realize how advantageous it was to perform his duties by the clock (i.e., strictly schedule his time, dividing it between taking care of his children and doing his job).
   - – Чоланнарыннан үткәндә әзрәк бәхетеңне сынарга туры килер. Шулай булмаса, **батырлык** та **кирәк булмас иде**. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) “When passing the storerooms, you will have to try your luck a little. If that were not so, courage would not be necessary.”
   - Илдерхан. Кирәкле кәгазьләр ... алдыңмы инде? Инде артык **кирәк булмаммы**? Хәерле юл үзеңә. (Нәкый Исәнбәт, Зифа.) Ilderkhan. Have you already received the necessary papers, ...? Then I shall not be needed any more? Have a good trip.

b) The modal word **кирәк** may be used with negative future participles in **-мас/-мәс** in the dative, or with *negative verbal nouns* in **-мау**, **-мәү**. This construction expresses a *suggestion* or *command* not to perform the action.

· Мортаза. Минемчә ... Эшне ул дәрәҗәгә **җиткермәскә кирәк**. (Риза Ишморат, Якын дус.) Mortaza. In my opinion ... one must not carry the matter to that extent (lit., degree).
· Ярулла. **Бирешмәскә кирәк**, күрше, нык булырга кирәк. (Фәтхи Бурнаш, Ялгыз Ярулла.) Yarulla. You must not give in, neighbor, you must be firm.

**[748] кирәк иде** and **кирәк булган.**

a) **кирәк иде** may correspond to the modal auxiliaries 'should', 'ought to' in English, referring to *present* or *past*. **Кирәк булган** may correspond to 'should have', 'ought to have'.
· Хөсәен. Оятсыз. Ходайдан курыкмасаң, бераз карт-корыдан **оялырга кирәк иде**. (Фатих Әмирхан, Яшьләр.) Khösäyen. Shameless (boy). If you don't fear the Lord, you should (ought to) (at least) be ashamed a little in front of the old folks.
· Хөсәен. Миңнулла, син бик борчылгансың бит. Сиңа азрак хәл **алырга кирәк иде.** (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Khösäyen. Mingnulla, you have had a lot of troubles (worries). You ought to take a rest.
· Абдулов. ... Бармадым. Нигә барыйм? Марго ханым. **Барырга, аңлашырга кирәк иде**. Абдулов, Юк, бармыйм. (Риза Ишморат, Шайтан таягы.) Abdulov. ... I did not go. Why should I go? Lady Margo. You should go, have a talk (with her). Abdulov. No, I am not going.
· Әнвәр. Менә килдем бит. Нурия. Күптән **килергә кирәк иде**. (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Änwär. Here, I have come, haven't I. Nuriä. You ought to have come long ago.
· – Күптән шулай дип **әйтү кирәк иде**, – диде Галләм ... (Әмирхан Еники, Рәхмәт, иптәшләр.) "You should have said that long ago," Ghälläm said ...
· Хәмит. Ул сезне машинага утыртып җибәргән, үзе торып калган. Искәндәр. Әйе шул. ... Искәндәр. Шунда миңа, сикереп төшәргә дә, үз урыныма аны утыртып **җибәрергә кирәк булган**. (Мирсәй Әмир, Минем хатын.) Khämit. (As I was told) she (i.e., the interlocutor's teacher) put you on the bus and sent you off, while she herself remained standing outside. Iskändär. Yes, that's right. ... Iskändär. I should have jumped off (i.e., jumped off the bus) and had her sit in my seat right there.
· Мәдинә. Бәлки **миңа** барысы турында Вилгә **сөйләргә кирәк булгандыр**. (Риза Ишморат, Мәдинә.) Mädinä. Perhaps I should have spoken to Vil about all that.
· Гөлсинә. Бүген мин Сәлим абый белән кычкырыштым, әбкәй. Аңа бик каты сүзләр әйттем. Фәрхия. Я алла! Ник алай эшләдең инде, балам? ... Ни генә булса да, авыр сүзләр **әйтмәскә кирәк иде**. (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Gölsinä. Today I quarreled with uncle Salim, dear Grandma. I said very harsh words to him. Färkhiä. Oh God! Why did you do so, my child? ... Whatever it was, you should not have said hard words.

b) **Кирәк иде** may express *politeness, respectfulness, modesty.*
· – Миңа бер мәсьәлә хакында сөйләшеп алырга **кирәк иде**. (Фәнил Галиев, Командировка.) "I'd have some matter to talk over briefly."
· – Миңа бәлки сез дә ярдәм итә алырсыз? – дидем мин. – Рәхим итегез! – диде ханым. – Миңа Һәдия Вафинаны күрергә **кирәк иде**. (Мәхмүт Хәсәнов, Кама таңнары.) "Perhaps you could help me?" I said. "Please," the lady said. "I'd have to see Hädiä Wafina."
· Рәхим ... – Сезгә берәр кеше **кирәк идеме**? – дип сорады. – Миңа Заһид Сафич **кирәк иде**, – диде хатын. (Атилла Расих, Ике буйдак.) Räkhim ... asked. "Are you perhaps looking for someone?" "I'd like to see Zahid Safich," the woman said.

**[749]** The modal word **кирәк** may express an *order.*

- ... иртүк аларны быргы, барабан тавышы уята: – Торыгы-ыз! дип Аблак остаз кычкыра. – Калкыны-гы-ыз! Таң салкынында эшләп калыш **кирәк**! (Батулла, Сөембикә кыссасы.) ... early in the morning they are awakened by the sounds of trumpets and drums, "Get up!" instructor Ablaq cries. "Ri-i-se! Work must be done in the cool of the dawn!"
- ... ишегалдында һәм ындыр тирәсендә аның боерулы авазы яңгырар: – Яхъя олан, тимерче Ычтапанга барып кайтырга **кирәк**! (Җәмит Рәхимов, Батырша.) ... in the yard and around the barn her commanding voice would ring out: "Yakhya (John), my boy, you must go to Stephan the blacksmith!"

**[750]** **Кирәк** preceded by **ничек** and followed by **алай** expresses the performance of an action to the extent possible under existing conditions or circumstances.

- Мин аңа ничек **кирәк** алай кереп урнашкач, сержант тартма ишеген тыш яктан ябып шалтыратып бикләп куйды. (Гурий Тавлин, Афәт.) After I had gotten inside (i.e., inside the box-like narrow room) and accommodated myself as well as I could, the sergeant closed the door from the outside and noisily locked it.
- – Әнә киемнәрең, киен. ... Ничек **кирәк** алай киендем. (ibid.) "There are your clothes, get dressed." I put them on as well as I could. (They have searched his clothes, ripping up seams, tearing out the lining, cutting off all buttons.)

**[751]** **Кирәк** may assume verbal qualities and function as a verb. In that case, **кирәк** becomes a verb stem i.e., suffixes forming tenses or moods, the negative suffix **-мә** as well as suffixes forming various other verb forms (verbal nouns, participles, etc.), are joined *directly* to **кирәк** in its basic form. For example: **киркми** 'it is not necessary, needed', **кирәкмәс** 'it will not be necessary, needed', **кирәгер** 'it will be necessary, needed', **кирәксә** 'if necessary, needed'.

*Note:* In its function as a verb, **кирәк** is used mainly in the negative.

The difference between the verbal forms of кирәк and кирәк plus түгел, or кирәк and a conjugated form of булу, is one of emphasis, the former being more emphatic than the latter.

- Сәрвәрев. Минемчә, бу турыда баш **ватарга кирәкми** ... (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Särwärev. In my opinion, we need not rack our brains over this, ...
- Сәхәп. Морат иптәш, **сиңа** хәзер алар авылына **барырга кирәкми** бит. (Нәкый Исәнбәт, Рәйхан.) Säkhäp. But Morat, my friend, you must not go to their village now.
- Наилә. **Миңа** кеше **әйтүе кирәкми**. (Мирсәй Әмир, Наилә.) Nailä. The last thing I need is people telling me what to do.
   - Утырыштылар да капкадан чыгып киттеләр. Мин дә урамга йөгереп чыктым. Әни утырган арба артыннан **барам**. ... Бабай атка сукты. Ат **чаба**, мин **йөгерәм**. Күпергә тикле йөгердем, артык йөгерә алмадым. Туктадым. Китеп барган арба артыннан шашып карап **торам**. (Ибраһим Гази, Малайлыкта кунакта.) They got on (the wagon) and left through the gate. I too ran into the street. I walked (walk) behind the wagon on which Mother was sitting. ... The old man whipped (whips) the horse. The horse galloped off (gallops off). ... I run, I ran as far as the bridge. I could not run any further. I stopped. Being beside myself, I stood (stand) and gazed (gaze) in a frenzy after the wagon as it moved (moves) away.
   - **Була** әүвәл заманда бер ярлы кеше. ... Моның **була** ике улы. Улларын теләнеп кенә **туйдыра**. Карт белән карчык бер көнне үлеп **китәләр.** Болардан малайларга һичбер нәрсә **калмый**. (Татар халык әкиятләре, Эшлексез кеше.) Once upon a time there lived a poor man. ... He had two sons. He fed his sons only by begging. One day the old man and woman passed away. They did not leave the boys anything.

6. The present tense is used to actualize, to give mor vividness and effect to, *biographies* and *recollections.*
   - Мирхәйдәр Фәйзи – бик үзенчәлекле драматург, ... Аның иҗат гомере нибары егерме ел дәвам **итә**, әмма ул бай мирас калдырырга **өлгерә**. Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзуллин 1891 елның 1 ноябрендә элекке Оренбург губернасы Орск өязенең Күкшел авылында туган. Башта ул кызлар укытучы абыстайга йөреп укырга **өйрәнә**, аннары Орск һәм «Хөсәения» мәдрәсәләрендә **укый**. Әдәби әсәрләр язу

дәрте аңарда 1905 елларда ук **уяна**, ... Мирхәйдәр Фәйзинең беренче драма әсәрләре 1912 елда дөньяга **чыгалар**. (Барлас Камалов, Мирхәйдәр Фәйзи.) Mirkheydär Feyzi was a very original playwright, ... His creative life lasted only twenty years, but he succeeded in leaving behind a rich heritage. Mirkheydär, son of Mostafa Feyzullin, was born on the first of November, 1891, in the village of Kükshel, district of Orsk, in the former province of Orenburg. First, he learned to read with the wife of a mulla, who taught girls. After that, he studied at the medrese at Orsk and at the "Khösäyeniä" medrese[1]. The urge to write literary works awakened in him around 1905, ... Mirkheydär Feyzi's first dramas appeared in the year of 1912.[2]

- Әле дә хәтердә. Бервакыт без кечкенә арба ясау белән мавыгып киттек. Безгә аны зурлар да ясап бирергә әзер **торалар**, тик үзебезнең ясыйсыбыз **килә**. Без әле рәтләп пычкы да тота **белмибез**, шулай да үзебез **ясыйбыз**, үзебез **эшлибез**. Ниһаять, арбабыз эшләнеп бетте. Ул арба исемә төшсә, хәзер дә әле елмаймыйча булдыра алмыйм. ... Көпчәкләре юан колгалардан киселеп ясалган. Дүртесе дүрт эздән **бара**. Шулай да ул безнең өчен авылдагы иң матур, иң җыйнак арбалардан. (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, Мохтар Ибраһимов.) I still remember it. Once we went crazy about building (lit., making) a small cart. The grown-ups were also ready to build it for us, but we wished to build it ourselves. We could not even hold a saw properly yet. Nevertheless, we built it ourselves, we did the work ourselves. Finally, our cart was finished. When I remember that cart, I still cannot (do so) but smile even now. ... Its wheels were cut from thick poles. The four of them ran in four (different) tracks. However, for us it was one of the most beautiful, one of the neatest carts in the village.

7. The present tense is used in reviews of *literary works* and in *stage directions*.
   - «Галиябану» /Ǥaliəbanu/ драмасында инде без гадәттән тыш шәхесләр һәм гадәттән тыш хисләр белән **очрашмыйбыз**. Галиябану – гади /ǥadi/ авыл кызы. Аның иң зур идеалы, сөйгән егетенә кияүгә чыгып, бәхәтле булу. Бүтән кызлар кебек үк **киенә**, эшен **эшли**, чигү **чигә**, шулай ук **шатлана**, шулай ук **кайгыра**. Хәлилнең сүзләре, үз-үзен тотышы, гадәт-холкы да яучы карчык сүзләрен раслап **тора**. Авылда ул беренче гармончы. ... «Сөйгәне өчен корбан булудан яшь егет баш тартырмы» дип **җырлый**, соңыннан исә моны эш белән **раслый.** (XX йөз башы татар әдәбияты, Мирхәйдәр Фәйзи.) In his drama "Ghaliäbanu", we no longer encounter extraordinary personages and extreme emotions. Ghaliäbanu is an ordinary village girl. Her greatest ideal is to get married to the man she loves, to be happy. She dresses, works and embroiders just like the other girls, rejoices just as they do and grieves the way they do. Khälil's words, the way he conducts himself, his habits and character confirm the words of the old match-maker woman. He is the best accordionist in the village. ... "Would a young man ever refuse to sacrifice himself for his beloved," he sings. And later on, he proves this (i.e., that no young man would refuse) by his deeds.
   - Сибгать **җырлый**. Хәлил «Җәмилә» көен уйный **башлый**. Бер кабат уйнаганнан соң Галиябану белән Сәгыйдә **кушылалар**. (ibid.) Sibghät sings. Khälil begins to play the tune "Jämilä". After he has played it once, Ghaliäbanu and Säghidä join in.
   - Газиз агачлар арасына **китә**. Сәхнәдәге кешеләр акрын гына бер-берсе белән **сөйләшәләр**, **йөреналәр**, Зәкәрия, Зыя, Әхмәт **керәләр**. (Фатих Әмирхан, Яшьләр.) Ghäziz steps between the trees. The people on stage are conversing in a low voice. They walk around. Zäkäriä, Zia, Äkhmät enter.

---

[1] Khösäyeniä medrese – Located in Kazan.
[2] Мирхәйдәр Фәйзи (1891-1928).

8. The present tense is used to inform (in a known context) of an action which will definitely take place *in the future*. The subject performs the action out of his own free will or as a result of some outside compulsion.
   · – Ярты сәгатьтән мин өйдә **булам**. (Шәриф Хөсәенов, Зөбәйдә – адәм баласы.) “I shall be home in half an hour.”
   · Заһид ... кыю адымнар белән аудиториягә керәчәк һәм ... лекциясен башлап җибәрәчәк. Һәм менә әле генә авыр, газаплы булып күренгән эш шунда дәртләндерә, илһамландыра торган күңелле бер нәрсәгә әвереләчәк. Ул белә: башта сүлпәнрәк тыңлаган аудитория әкренләп игътибарын **көчәйтә**, ә бераздан ул Заһиднең лекциясе белән, ... бөтенләй мавыгып **китә**, әсир **ителә**. Шулай тыңлаучылар белән лектор арасында җепләр **ныгыганнан-ныгый**, ... Әле шундый бер минут **була**: барлык күзләр аңа гына **текәлә** ... Әйе, ул вакыт барлык әйткәннәре бөтен төгәллеге белән тыңлаучыларга барып **җитә**, алар сөйләүче белән бергә тирән рәхәтлек **кичерәләр**. Юк, алай гына да түгел, алар үзләренең остазлары белән **горурланалар**, аны эчкерсез ярату белән **ярата башлыйлар**, Заһид боларның барын да тоеп, кичереп белә. Тик шулай да һәр лекциясе алдыннан каушый. (Атилла Расих, Ике буйдак.) ... Zahid will enter the lecture hall with firm steps and ... he will begin his lecture. And the matter which just a minute ago had looked difficult and painful (distressing) will at once turn into something stimulating (encouraging), inspiring and cheerful. He knows that the audience, listening at first somewhat languidly, will gradually increase its attention and, after a little while, will ... become completely enraptured and captivated by Zahid’s lecture. In this way, the bonds between the listeners and the lecturer will grow firmer and firmer, ... Now there will come a moment such that all eyes will be fixed only on him ... Yes, at that time everything that he says will reach the listeners with all its subtlety (scope, exactitude). Together with the lecturer (lit., speaker), they will experience a profound satisfaction. No, not only that, they will be proud of their teacher, they will begin to love him sincerely. Zahid knows all this, having felt and experienced it. But, nevertheless, he becomes embarrassed before every lecture. (For the forms ныгыганнан-ныгый see 1056, c.)
   · ... ак бүре ... әйтте: – ... Монда минем рөхсәтемнән башка үләннәрне таптату җитмәгән, тагы урмандагы кошларны атарга барасың, – диде. Егет бүрегә: – Бик арыдым, талдым. Бик ерак җирдән килдем. Инде алай булса, синең рөхсәтеңнән башка мин монда бер эш тә **эшләмимен**, кошыңны да **атмыйм**, атымны да **ашатмыйм**. ... **Чыгам** да **китәм**, – диде. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) ... the White Wolf said, “... it’s not enough that you trample on the grass here without my permission, you also go and shoot the birds (which are) in the forest.” The young man said to the wolf, “I am very tired and exhausted. I have come from a very distant place. Well, if that’s how it is, I shall not do anything here without your permission. I shall neither shoot your birds nor shall I feed my horse. ... I shall get out (of the forest) right away.”
9. When referring to the future, the *second person singular* and *plural* of a verb in the present tense may express various nuances of an *order, instruction,* a *demand* or *recommendation* to perform an action.
   · – Дөресен генә, бернәрсәне дә яшермичә генә сөйләп **бирәсез**, – диде ул (Ризван), сүз башлап. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) He (Rizwan) began, saying to him, “Just you tell us the truth, without hiding anything.”
   · – Сөйләштек алайса, – диде Ризван. – Минем белән һәрвакыт бәйләнештә **буласыз**. (ibid.) “Then we are agreed,” Rizwan said. “You stay in contact with me at all times.”

- Ләкин улының үзе каршында кулын кесәсенә тыгып, салынкы гына карап торуына йөрәге түзмәде – ачуы өскә бәреп чыкты. Ул ... яңадан улына борылып: – Хәзергә шул: өйдә **утырасың.** Беркая да **чыкмыйсың**! – диде. (Рәисә Ишморатова, Милиция лейтенанты.) But his son, standing (there) before him with his hands in his pockets and looking at him apathetically – his heart could not bear (that). His anger burst to the surface ... he turned again to his son and said, "For now, this: You will stay at home. You won't go anywhere!"

# Past Tense I

## Formation

**[957]** The basic form – identical with the third person singular – of the past tense I is obtained by joining **-ды-**, **-де-** to stems ending in a vowel or in a voiced consonant, **-ты-**, **-те-** to stems ending in a voiceless consonant. The other persons are formed by adding the personal endings of the *possessive type* to the basic form.

| | **укы** read | **эшлә** work | **яз** write | **кил** come | **укыт** teach | **төш** fall |
|---|---|---|---|---|---|---|
| мин | укыдым | эшләдем | яздым | килдем | укыттым | төштем |
| син | укыдың | эшләдең | яздың | килдең | укыттың | төштең |
| ул | укыды | эшләде | язды | килде | укытты | төште |
| без | укыдык | эшләдек | яздык | килдек | укыттык | төштек |
| сез | укыдыгыз | эшләдегез | яздыгыз | килдегез | укыттыгыз | төштегез |
| алар | укыдылар | эшләделәр | яздылар | килделәр | укыттылар | төштеләр |

| | Negative Form | | | Interrogative Form | |
|---|---|---|---|---|---|
| мин | укымадым | килмәдем | мин | укыдыммы? | килдемме? |
| син | укымадың | килмәдең | син | укыдыңмы? | килдеңме? |
| ул | укымады | килмәде | ул | укыдымы? | килдеме? |
| без | укымадык | килмәдек | без | укыдыкмы? | килдекме? |
| сез | укымадыгыз | килмәдегез | сез | укыдыгызмы? | килдегезме? |
| алар | укымадылар | килмәделәр | алар | укыдылармы? | килделәрме? |

## Use of the Past Tense I

**[958]**

1. The past tense I expresses actions in which the speaker (or writer) has *participated*, which he has *personally witnessed*, or which he *remembers* and *knows well.*. The actions are viewed as completed.
   - Моннан бер ел чамасы элек булган иде ул вакыйга. Көз ахыры **иде**, көннәр шактый **суытты**, тугай өстенә ак бәс **кунды**, ниһаять, менә Дим култыгы, Комач өсте дә күксел боз белән тигез генә **капланды**. ... Бер-ике-өч көн узуга Комач бозы безнең ише малайларны күтәрерлек ныгып та **өлгерде**. Әнә шундый көннәрнең берсендә өч кыз Арыслангәрәй тыкрыгыннан су буена **төштеләр**. Болар безнең каршыдагы Таифә апа һәм Гайшә апа белән Һаҗәр **иде**. Мин аларны яр башында **очраттым** һәм нишләптер үзем дә аларга ияреп **төштем**. ...

Һаҗәр күргәч, иярмичә булдыра **алмадым** инде. **Төштек** шулай, мин шунда ук боз өстенә кереп **киттем**– ул тәмам ныгыган, зурларны да күтәрерлек **иде**. Кызлар да әзрәк таптанып **тордылар** да сакланып кына бозга **бастылар**. Шуа-шуа гына **киттек**. ... Шулай бара торгач, шактый киң Комачның аръягына да чыгып **җиттек**. ... Без, бераз тын алгач, кире үзебезнең якка чыга **башладык**. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) That event happened about one year before this (i.e., before a certain point of time in the past). It was the end of autumn. The days got rather cold. White hoarfrost settled on the meadow, and, finally, the bay of the (river) Dim, and also the surface of the Qomach, got covered evenly with bluish ice. ... After one, two or three days passed, the ice on the Qomach became strong enough to carry boys like us. On one of those days, three girls from the Aryslangärey Lane went down to the river (lit., water). They were Taifä, Gheyshä and Hajär, who lived across from us. I encountered them at the top of the (river) bank and, somehow, accompanied them. ... after seeing Hajär, I just couldn't but follow them. Thus, we walked down, and I immediately went out upon the ice. It had become completely firm and could carry adult persons also. The girls too stomped around a little and cautiously stepped on the ice. We moved along, sliding. ... Walking like that, we crossed to the other side of the rather wide Qomach. ... After a little rest we began to move back to our side.

· ... капитан башта Фәрхәткә мөрәҗәгать **итте**: – Әйтче, Фадик, синең абыең янына килеп йөргән кеше шушы **идеме**? Үсмер, мәктәбендәгечә, аягүрә басып җавап **бирде**: – Шушы үзе, мин аны яхшы таныйм. ... – Ул абыеңа моннан ике ай чамасы элек Казанга этисенең кайтуын **әйттеме**? – **Әйтте**. Минем бик ачык хәтеремдә калган ... – Менә тагын бер сорау. Унтугызынчы октябрьда төнлә абыең нинди кешегә ... кечкенә капчык белән әйбер алып **бирде**? Фадик көлемсереп Маһинурга **текәлде**: – Менә шул апа **иде** ул капчыкны алып китүче. – Ничек **таныдың**? – Исемә **төште**. Алкасын, менә шушы зур алтын алкасын **хәтерләдем**. Аннан буен, аннан тагы йөзен дә. Шул инде, шул. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) ... first, the captain addressed Färkhät: "Tell me, Fadik, was this the man who (repeatedly) dropped in on your (older) brother?" The youth, standing up the way they did at school, answered, "This is he, I know him well." ... "Did he tell your brother approximately two months ago that his father was returning to Kazan?" "He did, I remember very clearly ..." "One more question. During the night of October 19, to what person did your brother give an object in a small bag ...?" Fadik smiled and fixed his eyes on Mahinur, "There, that woman (lit., sister) was the one who took away the bag." "How did you recognize her?" "It came to my mind. I remembered her earrings, those large golden earrings of hers. Then her figure and then also her face. It is she all right."

2. The past tense I relates the *process* of actions which took place in the past (mostly in narratives).

· Кама суының да рәхимле кояш нурларына җаны эреп **китте** ахрысы: йөзе **яктырды**, көзге кебек **булды**. Ул **тынычланды** – **мөлаемләнде**, үзенең җылы, йомшак кочагына кешеләрне чакырып тора **башлады**. Ә Ялантау кешеләренә шул гына кирәк **иде**. Җәйнең ямьле көннәренең берсе **иде.** Хәтта алай гына да түгел, озак көттереп килгән җәйдә булган ямьле көннәрнең дә иң шәбе **иде**. Өстәвенә шундый матур көн якшәмбегә туры **килде**. Ялантау кешеләре Кама буена **ябырылдылар**. Кояш офыктан аерылып нарат биеклеге күтәрелгән вакытта, Кама өсте чуп-чуар **иде** инде. Хисапсыз күп сандагы ап-ак каеклар, эреле-ваклы моторкалар, ... балыкчы көймәләре – өзлексез аргы як ярга таба агылып **тордылар**. (Мирсәй Әмир, Ялантау кешеләре.) Apparently under the beneficial rays of the sun, the Kama too relented (lit., the heart of the waters of the Kama

melted). It's face brightened, became like a mirror. It calmed down, became gentle and began to invite the people into its warm, soft embrace. And that was just what the people of Yalantaw needed. It was one of the pleasant days of summer. And what was more, it was the best of the pleasant days which happened in a summer which had been a long time in coming. In addition, that (lit., such a) beautiful day fell on a Sunday. The people of Yalantaw rushed to the Kama. By the time the sun separated from the horizon and rose to the height of the pines, there was already a motley crowd on the Kama. A great many snow-white (row) boats, large and small motor boats, ... and fishing boats were constantly going towards the opposite bank. (Моторка – vernacular, моторлы көймә.)

3. The past tense I expresses actions which took place *once* in the *recent* past. (For example: In every-day conversation, in communications, reports, news, etc., worded in concrete form.)
   - Разия. Әни, Марат **шалтыратмадымы**? Нурия. Юк. Разия. Без аның белән кинога бармакчы **идек**. Нурия. Кинога? Үткән атнаны театрга **бардыгыз**, бүген кинога. ... (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Razia. Mother, hasn't Marat called? Nuriä, No. Razia. He and I had meant (intended) to go to the movies. Nuriä. To the movies? Last week you went to the theatre, today to the movies. ...
   - Йолдыз. Саумы, әткәй! Күр әле кабинетың матурланып киткән. Госман. Бик озак **йөрдең**, кызым. Бер атна дигәнең ике атнага **сузылды**. Йолдыз. Киңәшмәдән соң, семинар **үткәрделәр**. Мин бит сезгә хат язган идем. Госман. Хатыңны **алдык**. Я, исән-сау йөреп **кайттыңмы**, кызым. Йолдыз. Кайтып **кердем** дә. Өйдә беркем дә юк. Әнкәй дә эштә икән. Сине эзләп **килдем**. (Гамир Насрый, Кушнарат.) Yoldyz. How are you, Father dear! Just look, your office has been brightened up. Ghosman. You were away for a very long time, my dear (lit., my daughter). What you said would take one week lasted two weeks. Yoldyz. They held a seminar after the conference. I did write you a letter. Ghosman. We received your letter. Well, did you get home safe and sound, dear (lit., my daughter)? Yoldyz. I did. There was nobody in the house. Mother was at work, it seems. (So) I came to (find) you.
   - ... Сентябрь аенда Татарстан Фәннәр Академиясендә энциклопедияне төзүче өлкән мөхәррирләрнең утырышы **булды**. Анда шәһәребез югары уку йортлары, фәнни тикшеренү институтлары галимнәре, Фәннәр Академиясе әгъзалары **катнашты**. Утырышны Татарстан Фәннәр Академиясе президенты, академик М. Хәсәнова **алып барды**. (Галимнәр киңәшә, Казан утлары, 10, 1992, б. 191.) ... In September, the senior authors (editors) who are working on the preparation of an encyclopedia at the Academy of Sciences of Tatarstan held a conference. Participating in it were scholars from our city's (i.e., Kazan) establishments of higher education, from scientific research institutions and members of the Academy of Sciences. The conference was conducted by the president of the Academy of Sciences of Tatarstan, academician M. Khäsänova.
4. The past tense I expresses actions performed *repeatedly* in the past.
   - Казанның югары уку йортлары ел саен илгә халык хуҗалыгының төрле тармакларында эшләү өчен кирәк булган йөзләрчә ... белгечләр **бирделәр**. (Татарстан АССР тарихы, 2. т.) The higher educational institutions in Kazan have given the country each year hundreds of ... experts needed for work in various branches of the national economy.
5. The past tense I may be used stylistically, in order to give greater *authority* and *credibility* to the narrator's, or writer's, words as well as to the *events* and *conditions* related but

*not* witnessed by him and which, consequently, would ordinarily be conveyed in past tense II (966; 967, 1-8). Such use of the past tense I occurs mainly:

a) In *history* books and texts.

- Беренче рус революциясе татар культурасы үсешендә куәтле этәреш **ясады**. ... Революция алдыннан үзгәртелгән (җәдит) мәктәпләр саны шактый **артты**. ... Вакытлы матбугат барлыкка **килде**. 1906-1907 нче елларда татар телендә 19 газета һәм 12 журнал **басылды**. ... Алдынгы татар яшьләре 90 нчы елларда театр оештырырга омтылып **карадылар**. ... Беренче рус революциясе татар театрын оештыруны **тизләтте**. (Татарстан АССР тарихы.) The first Russian Revolution produced a strong upswing in the development of Tatar culture. ... The number of schools which had been changed (reformed) before the revolution increased considerably. ... A contemporary press came into existence. During the years 1906-1907, 19 newspapers and 12 journals appeared in the Tatar language. ... In the 1890's, forward-looking young Tatars attempted to organize a Tatar theatre. ... The first Russian Revolution accelerated the founding of the Tatar theatre. (Культура – мәдәният.)
- Аның хакында ... Уйгырстан тарихчылары болай язалар: «Төрле фәннәрне яңача укыткан ... бу мәктәп, Эле өлкәсендә генә түгел, бәлки бөтен төньяк Шенҗаң буенча да бердәнбер атаклы мәктәп **иде**. Бу мәктәптә бер татар балалары гына түгел, бәлки кардәш милләтләрдән уйгыр, үзбәк, казакъ, кыргызларның да балалары **укыдылар**. ... дөңгәннәрнең дә уллары, кызлары **укый иделәр**. ...» (Миркасыйм Госманов, Чәчелгән орлыклар – Голҗа татарлары.) About it (i.e., about the new school) historians in Uigurstan ... write as follows: "This school, which taught the various subjects in a modern way, ... was the only famous school, not just in the district of Ili, but throughout all of Northern Sinkiang. Not only Tatar children but also children from kindred nations, Uigurs, Uzbeks, Kazaks and Kyrgyz studied in this school ... even the sons and daughters of Dzungans were attending it. ..." (lit., were learning/studying in it).

*Note:* Tatar history books published during the Soviet period are commonly written in past tense II up to the beginning of the 20th century and in past tense I after that.

b) In religious texts, including translations from the Koran, Bible, etc.

- Мөддәте тулгач, Муса, хатын вә бала-чагаларын ияртеп, юлга **чыкты**. Тау янында ул ниндидер ут күреп, үзенең гаиләсенә **әйтте**: ... (Коръән, «Касас» сүрәсе, 29-30 аятьләр. Quoted from: Гариф Гобәй, Коръән серләре.) When the (alotted) time had passed, Moses took his wife and children and set out on the way. Near a mountain he saw a fire of some sort and said to his family: ...
- 41. Аның ата-анасы ел саен Иерусалимга Пасха бәйрәменә бара торган **иделәр**. 42. Аңа унике яшь тулгач, алар гадәттәгечә тагын Иерусалимга бәйрәмгә **бардылар**. 43. Бәйрәм көннәре үткәч өйгә кайтырга дип юлга **чыктылар**, яшүсмер Гайсә /ɑ̈jəjsə/ Иерусалимда **калды**; әмма ата-анасы моны **белмәде**. (Luke 2.) 41. Now his parents went to Jerusalem every year at the feast of the Passover. 42. And when he was twelve years old they went up (again) according to custom; 43. and when the feast was ended, as they were returning, the boy Jesus stayed behind in Jerusalem. His parents did not know it. (Tatar text quoted from a publication by the Institute for Bible Translation, Stockholm.)

6. The past tense I is used instead of the past tense II (966) to express humor.

- Мин 188* ел гыйнварның таңында **тудым**. ... һәрбер татар шикелле, мин дә тугач та: «Нәрсәгә дип **тудым** мин?» дип уйлап **мәшәкатьләнмәдем**, ата-баба эшләгәнне эшләргә кирәк дип, акырып елый **башладым**, ... (Фатих Әмирхан, Минем тәрҗемәи хәлем.) I was born in January of 188* at dawn. ... Like every

Tatar, I too, right after being born, did not bother to think why I was born, but (saying) that I must do what my forefathers did, I began to cry at the top of my voice, ...

7. The past tense I may indicate an action or state which began at some unspecified point in the past and continues at the time of speaking. In this sense, the past tense I often occurs in exclamations.
   - Сания кулындагы киез итекләрне урындык өстенә куйды да ишеккә таба кузгалды. Гашия берни аңламаган кеше кыяфәтендә аның артыннан ташланды. – Кая **киттең**, Сания җаным, тукта, берәр чынаяк чәй эчеп чыгарсың! диде. (Мирсәй Әмир, Ялантау кешеләре.) Saniä put the felt boots which she had in her hands on a chair and moved towards the door. Ghashiä, like a person who does not understand, ran after her. “Where are you off to, Saniä, my dear, wait, have a cup of tea before leaving!” she said.
   - Самат. Уф, башым **әйләнде**. (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күңел.) Samat. Oh, my head is in a spin!
   - Гөлйөзем. Ах, харап **булдык**, ...! (Фәтхи Бурнаш, Яшь йөрәкләр.) Gölyözem. Oh, are we in trouble, ...
   - Егет бүрегә: – ... Бик **арыдым, талдым**. Бик ерак җирдән килдем, ... – диде. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) The young man said to the wolf, “... I am tired out, completely exhausted. I have come from a very distant place ...”
   - – Нинди машина булыр бу? – Ибраһим булырга тиеш. – Мин аның белән кайтып китәм. Егет үз колакларына үзе ышанмады. – Син миңа **үпкәләдеңме**? (Аяз Гыйләҗев, Үги ана яфраклары.) “What car would that be?” “It must be Ibrahim. I’ll go back with him.” The young man did not believe his ears. “Are you angry with me?”
   - Сәйдәр аны шундук танып алды, ул теге юлы танышкан ханым иде. – Миңа Наташа Жеребцова кирәк иде. – Мин булам – кем син? – Без сезнең белән... – А-а-а, керегез, кер... мин **хәтерләдем** сезне. Сез... (Газиз Үзиле, Гыйфрит.) Seydär recognized her immediately. She was the lady he had got acquainted with at that time (i.e., the time mentioned before). “I would like to see Natasha Zherebtsova.” “I am she, who are you?” “You and I...” “Oh yes, do come in... I remember you. You...”
8. The past tense I may express an action which will definitely take place if a certain condition is fulfilled.
   - Бер капчык он. Әгәр барып ала башлагач кына, су анасы якаңнан эләктереп алса? **Киттең** аннары су төбенә. Яңасалага гомердә әйләнеп кайта алмассың. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) A bag of flour (i.e., a bag of flour floating in the water). What if you go and the waterspirit seizes you by the collar just when you reach for it? You’ll go down to the bottom of the lake (lit., water) then. You will never be able to return to Yangasala.

**[959]** The first person singular of the past tense I, used in exclamations, indicates that the speaker is going to *immediately* carry out the action.

- Ганбәр. Мин аңа, сөенче, дип тә әйтә аламмы әллә? Мавия. Аңа катгый вәгъдә бирәм. ... Ганбәр (куанып сикерә). Менә шатлык! ... Менә рәхмәт! ... Мин **киттем**, китү генә түгел, **очтым**. (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күңел.) Ghänbär. Can I perhaps give him some good news too? Mawiä. I give him a firm promise. ... Ghänbär (jumps up joyfully). What joy! ... What bliss! ... I’m off. I’m not just going off, I’m flying off!

- Телефонда Гөлүсә тавышы. ... – Гази, ишетәсеңме? Хәзер янына барам. ... Көт, Гази, синең янга **йөгердем**. Көт яме! (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы ажаган.) On the telephone is Gölüsä's voice. "... Ghazi, do you hear me? I am coming (lit., going) to you now. ... Wait, Ghazi, I am running to you. Wait, will you?"

**[960]** The first person plural of the past tense I is used:

a) Instead of the optative to indicate an *invitation* to others to *immediately* carry out a *joint* action.
   - Вәли. Ягез, **киттек**, егетләр. Хуш әби! (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күңел.) Wäli. Well, let's go now, (young) men. Goodbye, Grandma!
   - Әнвәр. Әйдә, Гөлсинә, **киттекме**? (Риза Ишморат, Бистә кызы Гөлсинә.) Änwär. Come on, Gölsinä, shall we go now?
   - – **Башладык**, иптәшләр. ... сезгә беренче сүз. (Аяз Гыйләҗев, Шамил Усманов.) "Let's begin now, comrades. ... you speak first."
   - – Ишетәсеңме, Галимҗан абый? – Ишетәм, Сөмәя. Зәй ягыннан берсе кайта. – **Йөгердекме**, Галимҗан абый? Сөрелгән җир өсләп кенә юлга йөгерделәр. (Аяз Гыйләҗев, Үги ана яфраклары.) "Do you hear, Uncle Ghalimjan?" "I hear, Sömäyä. Someone is returning from the (river) Zey." "Shall we run, Uncle Ghalimjan?" They ran right over ploughed land to the road.

b) The first person plural of the past tense I is used in forms of salutation. It then refers to the first person singular or plural.
   - Галимә. **Хуш иттек**, балакайлар! (Фәтхи Бурнаш, Яшь йөрәкләр.) Ghalimä. Goodbye now, dears (lit., dear children)!
   - Ильяс керә. **Сәлам бирдек**. Низами. Исәнмесез, Ильяс. (Хәй Вахит, Карлыгач канат кага.) Ilyas enters. Greetings! Nizami. How are you, Ilyas?

**[961]** A verb in the *affirmative* past tense I immediately followed by the *negative modal word* **юк** *emphatically* denotes that the subject will *definitely not perform* the action expressed by the verb. The non-performance of the action may depend on the subject's *own determination,* or it may be *involuntary*, due to some outside circumstances leaving him (her) no other choice.

In such construction, the past tense I expresses *future* time. When referring to the *first person,* the verb is often in the *third* person singular.

- Илфат. Юк инде, агай-эне, моннан **кузгалдым юк**. Миңа табигатьне сакла диделәр, менә саклыйм. (Туфан Миңнуллин, Монда тудык монда үстек.) Ilfat. No, friends, I will definitely not move from here (not leave here). They told me to guard the nature here (i.e., trees and plants in the park), and, here, I am guarding it.
- Чүлдәге афган җилен хәтерләткән җилләр исә, кар бөтереп буран уйный. Әмма берсеннән дә **курыктым юк**! (Зәки Нури, Батырлар һәм матурлар поэмасы.) Winds are blowing which remind one of the Afghan desert winds. Blizzards are raging with driving (whirling) snow. But I will not fear either one!
- Гази да шунда. Аяктан егылыр хәлгә җитеп арыса да, сер **бирде юк**: әнә, печән кабартучы кызлар арасында аның йөрәк парәсе Гөлүсә дә бар. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы ажаган.) Ghazi is also there. Although he is tired to the point of falling off his feet, he will positively not show it (lit., he will positively not give away the secret): there, among the girls tedding the hay, is his sweetheart (lit., part of his heart), Gölüsä.

- Мәскәүгә килүемнең сәбәбен **әйтте юк** хәзер. Нәфисә ападан бик шәп сабак алдым. (Атилла Расих, Ишан оныгы.) This time I am definitely not going to tell the reason for my coming to Moscow. I was taught quite a lesson by Aunt Näfisä.
- Кичә генә шунда уйнап йөрдек. Тик бу турыда әнигә **әйтте юк**. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) We were playing there (i.e., on thin ice) yesterday. But I definitely won't tell Mother about it.
- Җитмәсә тагын, шул барлы-юклы өч бәбкәне сакларга әни мине китереп такты. Бер адым **китте юк**, тагылып йөрим шулар артыннан, кулда озын чыбык. (Фатих Хөсни, Кыр казлары.) On top of it all, Mother has saddled me with watching those unimportant three goslings. I won't take one step away (from them). I'll walk closely behind them, a long switch in my hand.
- – Иптәшләр! ... Акттан күренгәнчә, тирә-юньне нефть баскан, янәшәдәге иген басуына агып кергән ... Нишләмәк кирәк, тиешле җәзадан **котылды юк**. Киләчәктә ачы сабак булыр. (Мәхмүт Хәсәнов, Шөгеровлар.) Fellow workers! ... As can be seen from the report, oil has flooded the surrounding area and has flowed into the adjoining grain field ... What shall we do now; we will surely not escape our deserved punishment. It will be a bitter lesson for the future.

**[962]** A verb in the *affirmative* past tense I, repeated in the *affirmative* or *negative* form – but not necessarily in the same person – and each followed by **ни**, expresses *indifference* of the speaker towards the action, or it denotes that carrying out the action is *useless, futile, of no avail.* The past tense I refers to the present or future.

- – ... Ул **алды ни**, мин **алдым ни**, ике исәп – бер хисап. (Мирсәй Әмир, Саф күңел.) "... Whether he buys it or I buy it; whichever way you figure it, it amounts to the same thing (i.e., it makes no difference)."
- – ... Тукта әле, нигә миңа сөйлисең аны? Миңа **сөйләдең ни**, шушы таякка **сөйләдең ни**. (Хәй Вахит, Карлыгач канат кага.) "... Wait, please, why are you telling me that? Whether you tell me or whether you tell it to this (walking)stick here, it's all the same (i.e., telling him is useless because he is in no position to do anything about it)."
- ... Мәүлиханы да кушып санасак, тугыз. Ә Мәүлиханы исәпкә **керттеләр ни, кертмәделәр ни**, ул барыбер утыра. (Фатих Хөсни, Утызынчы ел.) ... if we add Mäwlikha also, there are nine. But whether or not they include Mäwlikha, she sits (in) anyway.
- – Сөмбелгә сөйләгәнең бармы соң? – Аңа **сөйләдең ни** дә **сөйләмәдең ни**. (Разил Вәлиев, Иске сәгать дөрес йөри.) "Have you told Sömbel then?" "Whether you tell her or not, it's all the same (i.e., it is useless)."

**[963]** A verb in the past tense I plus the particle **-мы**, **-ме** may express *time* or *condition* (compare also 1000, 5).

- Кәт елгасы буенда, нәкъ безнең яклардагы кебек, шомырт, миләш, тал, зирек, зелпе кебек агачлар үсә. Көзләр **җиттеме**, нәкъ безнең яклардагы кебек саргаялар. Күңелдә билгесез моң кузгату өчен шул бик җитә иде. Соңрак ул якларга карый алмас булдым. Су буйларына күз **салдыммы** – сары сагыш, тайга ягына баксам – кара кайгы. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) Along the river Kät trees, such as bird berry, mountain ash, willow, alder and honeysuckle, were growing; just like in our homeland. When autumn comes, they turn yellow; just as in our homeland. That was

plenty to become despondent about. Later on I could not (bear to) look any more in that direction. If I looked at the river banks, I felt very depressed, if I looked at the taiga, I felt intense grief.

(For the form карый булмас булдым see 992, 3.)

**[964]** A verb in the *negative* past tense I, used with an *interrogative pronoun* or with certain *adverbs,* indicates strong emphasis. Though negative in form, such constructions have an affirmative meaning. (Compare also 686, f.)

- Шәһәр уртасындагы бу бакчада **нинди** генә агачлар да **нинди** генә үсемлекләр **юк иде**. (Гөлсем Мөхәммәдова, Сикәлтәле туры юл.) What trees, what plants weren't there in this park (which was) in the center of town.
- Ул **чак** кына **егылмады**. (Ибраһим Салахов, Имәннәр тамыр җәйгәндә.) He almost fell.
- Госман **чак** кына көлеп **җибәрмәде**. (ibid.) Ghosman almost burst out laughing.

**[965]** In the vernacular, the past tense I is sometimes used in consequence clauses of conditional sentences.

- Әх, артист булсаң! Чыгып бер җырлаган **булдың**, я **биедең**, һәм – эшең **бетте**! (Шәйхи Маннур, Муса.) Oh, if one were only an artist! One would make an appearance and sing a song, or one would dance, and – one's work would be finished! (Pronounced with irony.)

(For җырлаган булдың see also 995,3.)

*Note:* In Tatar dialects the past tense I in *all persons* may be followed by **иде**: Мин әйттем иде, син әйттең иде, ул әйтте иде, etc. Though infrequently, these forms are used also in literary works to lend greater authenticity, realism to the speech of certain characters.

The past tense I followed by **иде** denotes:

a) The *result* of an action performed in past time.

b) An action performed shortly or just before the moment of speaking. The speaker has witnessed the action or knows it well.

- Галимә. Ни **әйттең иде** дә бит, балам, белмим шул. Сугыш яман ... (Фәтхи Бурнаш, Яшь йөрәкләр.) Ghalimä. What have you said there, my son. I don't know about that. War is bad ...

c) It may be used in consequence clauses of conditional sentences (corresponding to 'would' and 'should' in English.[1])

# Past Tense II

## Formation

**[966]** The past tense II is formed by joining **-ган**, **-гән** /-ɢan, -gən/ to stems ending in a vowel or a voiced consonant, **-кан**, **-кән** /-qan, -kən/ to stems ending in a voiceless consonant. This form, which is actually a past participle (see 1047, 1048), is identical with the third person singular. The other persons are formed by adding the *pronominal* personal endings.

---

[1] See also Ф.Ю. Юсупов, Изучение татарского глагола, Казан, 1986, pp. 178-180.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | язган | таныган | күргән | эшләгән |
| | wrote | knew | saw | worked |
| мин | язганмын | таныганмын | күргәнмен | эшләгәнмен |
| син | язгансың | таныгансың | күргәнсең | эшләгәнсең |
| ул | язган | таныган | күргән | эшләгән |
| без | язганбыз | таныганбыз | күргәнбез | эшләгәнбез |
| сез | язгансыз | таныгансыз | күргәнсез | эшләгәнсез |
| алар | язганнар | таныганнар | күргәннәр | эшләгәннәр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тоткан | киткән | | |
| | held | left | Negative Forms | |
| мин | тотканмын | киткәнмен | язмаганмын | эшләмәгәнмен |
| син | тоткансың | киткәнсең | язмагансың | эшләмәгәнсең |
| ул | тоткан | киткән | язмаган | эшләмәгән |
| без | тотканбыз | киткәнбез | язмаганбыз | эшләмәгәнбез |
| сез | тоткансыз | киткәнсез | язмагансыз | эшләмәгәнсез |
| алар | тотканнар | киткәннәр | язмаганнар | эшләмәгәннәр |

## Use of the Past Tense II

**[967]** The past tense II has a wide range of application. It may, for example, function as an imperfect, present perfect, present perfect of result, past perfect (past perfect of result), be timeless, denote both non-witnessed and witnessed actions and conditions. It often occurs together with verbs in the present tense when the latter are used stylistically to actualize, to give more vividness and effect to the speech (or narration).
Following is a detailed review of its functions and meanings.

1. The past tense II denotes an action or the resultant state of an action which the speaker (or writer) has *not personally witnessed,* which he relates on the basis of information received. The action was completed or its resultant state realized at some point in the past.
   - Аннары үзе турында сөйләргә кереште. Район мәгариф бүлегенең мөдире булып эшли икән. Педагогия институтын тәмамлагач, без укыган мәктәптә тарих **укыткан.** Аннан директор **иткәннәр**. Аннан районга **алганнар**. Мәктәптән китәсе **килмәгән**, аяк терәп каршы **торган**. **Күндергәннәр**. Ләкин һаман да мәктәпне, укытучы булган чакларын сагына икән. (Туфан Миңнуллин, Хәсән Вәгыйзович.) Then he began to talk about himself. It turned out that he was working as the director of the Education Department of the district. After graduating from the Pedagogical Institute, he had taught history at the school which we had attended. Later he had been made its principal. After that he had been transferred (lit., they took him) to the district (administration). He had not wanted to leave the school and had steadfastly resisted. But he had been persuaded to do so. He still yearned for the school though, for the time he had been a teacher.
   - Йормаш карт Алып Бәргәнгә барын да сөйләп бирде. Яхур патша яшь чакта бик тәртипле, итагатьле бер бала булып **үскән икән**. Йормаш карт аның остазы **булган**. Шулай бик матур **яшәгәннәр** алар. Егет булып җиткәч, шаһзадә дөнья гүзәле Җәмлиягә **өйләнгән**. Ипле, сабыр бу кызны Йормаш-вәзир үзе табып **димләгән**. Өйләнгән көнне үк Яхур патша үзгәрә **башлаган**. **Кырысланган**, ... (Батулла, Алып Батыр маҗаралары.) The old man Yormash told Alyp Bärgän everything. As it turned out, King Yakhur had in his young years grown up as a very

courteous, obedient child. The old man Yormash had been his tutor. They had lived very nicely in this way. When he reached manhood, the prince married Jämliä, a world-famous beauty. Vizir Yormash himself had found and induced this well-mannered and patient girl (to marry the prince). The very day King Yakhur got married, he began to change. He became severe, ...

2. The past tense II indicates an action or state which the speaker (writer) has completely forgotten or which he remembers only vaguely.
   - Мин үзем, билгеле, бу чәйни заманын бөтенләй диярлек хәтерләмим, бик кечкенә **булганмын** әле, – әйтик, ике белән биш арасында гына. Аннары без чәйнинең үзендә түгел, ә күршедәге икенче бер йортта **торганбыз**. ... мин, әйтүләренә караганда ... бик тере бер малай **булганмын**. Бер генә минут та бер урында тик кенә утыра **белмәгәнмен**, ... (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) I myself, of course, have almost no remembrance at all of the time of the teahouse. I was very little – let's say, only between two and five years old. Then, we lived not in the teahouse itself, but in another house in the neighborhood. ... according to what they (people) say, I was a very lively boy. I couldn't sit still in the same place for even one minute ...

   *Note:* Чәйни – vernacular, чәйханә.

   - Әтине мин бик начар хәтерлим. ... Фотосы юк. Әнинең әйтүенчә, фотога төшәргә **яратмаган**. ... Ул кырык биш яшендә һәлак **булган**. ... Ул ... көчле **булган**. Үзенә юл ярып максатына **омтылган, үскән, күтәрелгән**. Бүтәннәр шикелле бүрәнә өстендә акыл сатып утыруга вакытын әрәм **итмәгән**. (Туфан Миңнуллин, Хәсән Вәгыйзович.) I remember Father very vaguely. ... There is no photograph of him. As Mother said, he did not like to be photographed. ... He was killed (i.e., was killed during the war) when he was forty-five years old. ... He was a strong man ... He endeavoured to attain the goal which he had set for himself. He developed and rose in life. Unlike others, he did not waste his time sitting on a tree trunk and talking big.

3. The past tense II is used to indicate one's date and place of birth.
   - Мин ... 1901 нче елның 7 нче гыйнварында **туганмын**. ... Мин Яңасала авылында **туганмын**. (Гомәр Бәширов, Тормыш сукмаклары.) I was born on January 7, 1901. ... I was born in the village of Yangasala.

4. The past tense II expresses actions which took place over a period of time in the *distant* past (for example, in the narration of historical events and in fairy tales).
   - Урта гасырларда шәһәрләр, бигрәк тә башкала ролен үтәгәннәре, гадәттә икегә **бүленгәннәр**. Беренче өлеше кальга /qəlʤə/ дип **аталган** һәм анда дәүләт башлыгы, хөкүмәт әгъзалары, югары дәрәҗәле руханилар **урнашкан**. Бистә яки шәһәр дип йөртелгән икенче өлешендә һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һәм шуның ише «кара халык» **яшәгән**. XVI гасырда Казан шәһәрендә дә шундый бүләнеш **булган**. ... Хан сараена якында гына кальганең һәм бөтен ханлыкның баш мәчете калкып **торган**. Сигез манаралы шушы мәчет янәшәсендә зур мәдрәсә, китапханә, Казан дәүләтендә ислам дине башлыгы булып саналган сәетнең йорты урнашкан **булган**. ... Хан мәчете янындагы зур мәдрәсә һәм китапханәдән тыш Казанда башка мәктәп һәм мәдрәсәләр дә **булган**. ... 1523 елга кадәр Казаннан җиде чакрым читтә, Казан елгасы Иделгә койган урында каршы утрауда һәр ел саен июнь аенда ярминкә **уздырылган**. Казанның үзенә һәм шул ярминкәгә килеп, бик күп илләрнең сәүдәгәрләре үзара алыш-биреш **иткәннәр**. Казан халыкара сәүдәнең зур үзәгенә **әверелгән**. Европа һәм Азия илләрен бер-берләре белән бәйләнешкә **кертешкән**. Шәһәрдә рус һәм әрмән бистәләре барлыкка **килгән**. ... Казан татарлары үзләре дә чит шәһәрләр, илләр белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә **торганнар**. ... Казанның үзәгендә ике базар булып, аларның берсе хәзерге Беренче

Май мәйданын **биләгән**. Икенчесе аннан аста Болак буенда **булган**. (Сәлам Алишев, Казанның 800 еллыгына – тарихтан бер сәхифә.) In the middle ages, cities, especially those functioning as capitals, were usually divided in two parts. The first part was called the fortress, and the head of state, members of the government and the high-ranking clergymen lived there. In the second part, called the suburb or city, lived the craftsmen, merchants and similar "common people". In the 16th century such a division existed also in the city of Kazan. ... Close to the Khan's palace rose the main mosque of the fortress and of the whole Khanate. Beside this mosque, which had eight minarets, were a large medrese, a library and the house of the sayid, who was regarded as the head of the Islamic religion in the Kazan state. ... in addition to the large medrese and the library, there were also other schools and medreses in Kazan. ... Until 1523, a fair was held each year in June on an island situated at a spot seven versts from Kazan where the Kazanka flows into the Volga. Merchants from a great many countries, who came to Kazan itself and to that fair, traded among themselves. Kazan became an important international trading center and brought European and Asian countries into contact with each other. In the city, Russian and Armenian quarters came into existence ... The Kazan Tatars themselves too had trade relations with foreign cities and countries ... In the center of Kazan were two markets. One of them occupied the present First of May Square. The other was farther down on the Bulak.

- Борын-борын заманда бер кешенең ике кызы, бер улы **булган**. Кызларның берсе үги булганга, аны бер дә **яратмаганнар**. Беркөн киңәш **иткәннәр** дә үги кызны урманга илтеп адаштырмакчы **булганнар**. Бу үги кызга агасы **әйткән**: ... (Татар халык әкиятләре, Үги кыз.) Once upon a time there was a man who had two daughters and a son. Because one of the daughters was a stepchild, they did not like her at all. One day, they consulted with each other and decided (lit., intended) to take the stepdaughter into the forest and have her lose her way. Her brother said to the stepdaughter: ...

5. The past tense II indicates *indefinite manner of speech*, often with a tinge of *modesty, supposition, doubt, uncertainty,* frequently in conjunction with parenthetical expressions or particles expressing these nuances.
   - Әсхәт. Мин Бүрекле белән Күреклегә яңа оя ясадым. Күрдеңме? Зөбәйдә. Әһе. Әсхәт. Матур **булган** бит? (Шәриф Хөсәенов, Зөбәйдә – адәм баласы.) Äskhät. I made a new dovecot (lit., nest) for Bürekle and Kürekle. Have you seen it? Zöbeydä. Ehe (yes). Äskhät. It turned out beautiful, didn't it? (Äskhät is not sure that Zöbeydä shares his opinion.) (Bürekle, Kürekle – names of pigeons.)
   - Рафаэль. Беләсеңме, алар электән танышлар, алар дуслар. Зөһрә. Булмас. Ышанмыйм. Мөмкин эш түгел. Ялгыш **күргәнсең**. (Хәй Вахит, Соңгы хат.) Rafael. Do you know, they have known each other for a long time, they are friends. Zöhrä. It cannot be. I don't believe it. It's (something) impossible. You must have got it wrong.
   - Матурлыкның гадилектә икәнлеген мин чын-чыннан, ихтимал, әнә шунда аңлый **башлаганмын**. (Гомәр Бәширов, Тормыш сукмаклары.) It probably was then that I really began to understand that beauty lies in simplicity.
   - Күрәсең, бу бөек серне, ..., без һаман да ачып **җиткермәгәнбез** әле. (ibid.) Apparently, we still have not completely uncovered this great secret, ...

   *Note:* I.e., the secret why Ghabdulla Tuqai's poetry had, and still has, such a strong emotional effect on the reader. (Gh. Tuqai, 1886-1913.)

   - – Исәнме бабай, – диде Гөлшаһидә. – Иске йортлардан бу урамда синеке генә **калган**, ахрысы. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) "How are you, Grandpa,"

Gölshahidä said ... "Of (all) the old houses in this street yours alone seems to have remained."

6. The past tense II describes or presents as a *fact* the *result, state, condition* or *situation* produced or created by an action and still existing at the *moment of speaking* or having existed in the *past.* In the latter event, it links the result, etc., up with the moment of speaking. The result, state, or condition has been witnessed by the speaker. The action which produced the result, etc., may or may not have been witnessed or carried out by the speaker.
   - Пар нарат бөтенләй корып бетә **язган**, алардан инде көзләрен мул булып күркә дә коелмый, баш түбәләрендә бүрек тикле генә булып эленеп торган сирәк ылысларыннан күләгә дә төшми, кабыклары да кубып, карт тәннәре шәрәләнеп **калган**. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) The pair of pine-trees have withered almost completely. In autumn there are also not many cones falling from them, and their thinly growing needles, which sit (lit., hang) like a cap only on their tops, do not give any shade either. Their bark too has peeled off and their old trunks have become bare.
   - Тышка күз салсам, безнең тирәдә яңгыр **туктаган**, авыл өстенә утлы-яшелле, сарылы-зәңгәрле булып, бик биек, бик матур салават күпере **күтәрелгән**. (ibid.) I threw a look outside. Around us the rain had stopped, a fiery-greenish, yellowish-bluish, very high, very beautiful rainbow had risen over the village.
   - Без Тимерҗаннарга барып җиткәндә, аның әнисен инде өйгә алып кергәннәр иде. Ул инде һушына **килгән**. Караватта чалкан сузылып ята. Шунда ук ике-өч хатын кайнаша. Алар аңа су **бөркегәннәр**, киемнәрен чылатып **бетергәннәр**. Кемдер башына юеш сөлге бәйләп **куйган**, кемдер аягы астына мендәр **кыстырган**. – Аягы **тайган**, аягы – диештеләр хатыннар мин килеп кергәч тә. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) When we arrived at the Timerjans', they had already brought his mother into the house. She had already regained consciousness. She lay stretched out on her back. Two or three women were busying themselves there. They had sprinkled water on her, and they had wetted and rolled up her clothes. Someone had put a wet towel on her head, and someone had tucked a pillow under her foot. "She has dislocated her foot, her foot!" the women said when I entered.
   - Әкрен генә борылдым. Каршымда Әминә басып тора. Бераз гына да **үзгәрмәгән**. (Туфан Миңнуллин, Хәсән Вәгыйзович.) Slowly I turned around. Before me stood Äminä. She had not changed a bit.
   - ... көз үзен сиздерә. Сукмак кырыйларындагы өрәңгеләрнең яфраклары яшел әле, ләкин ныклабрак карасаң, алар да төс сала **башлаганнар, коңгыртланганнар, катыланганнар**, ... (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) ... autumn makes itself felt. The leaves of the maples beside the pathway are still green, but if you look closely, they too have begun to take on color. They have turned brownish, have hardened (have become inelastic) ...
- Зөфәр. Бүген көне матур. Җил дә басылган. Зөбәйдә. **Басылса ни**! Зөфәр. Көймәдә йөрергә әйбәт. Зөбәйдә. **Булса ни**! Зөфәр. Кабан күленә ике аккош җибәргәннәр. Зөбәйдә. **Җибәрсәләр ни**! (ibid.) Zöfär. Today is a beautiful day. The wind has also calmed down. Zöbeydä. If it has calmed down, so what! Zöfär. It's fine for a boat ride. Zöbeydä. What if it is! Zöfär. They have sent (they say) two swans to Qaban Lake. Zöbeydä. So what if they have sent them!
- – Калыйк, – дидем мин. Минем өчен барыбер – **кайтсак ни дә, кайтмасак ни**. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) "Let's stay," I said. For me it was the same – whether we returned (home) or not.
- Сәетҗан. Әгәр аны тотсалар, беләсеңме, әни, нәрсә булачак? Файзә. **Булса соң**, анда синең ни эшең бар? (Таҗи Гыйззәт, Фәрхиназ.) Säyetjan. Do you know, Mother, what will happen (to him) if they catch him? Faizä. So what. What business is it of yours?
- Рәхим. ... Минем белән сөйләшү өчен дию сылтау гына аның. Наилә янына килгән ул. Фәридә. Наилә янына **килсә соң**? Ул бала түгел ич инде. (Риза Ишморат, Якын дус.) Räkhim. ... That he says he wants to talk with me is only an excuse of his. He has come to (see) Nailä. Färidä. What if he has come to (see) Nailä? She isn't a child anymore, you know.
- Мәрфуга. Кычкырмый гына сөйләш дим, абыең ишетмәсен. Рәшидә. **Ишетсә соң**! (Гамир Насрый, Кадерле минутлар.) Märfugha. Talk quietly I say, don't let your brother hear. Räshidä. If he hears, so what?
- Бибкәй. ... Сәхәп, юньсез, аны Гәрәй абый өстенә алып килгән. Гөлбикә. **Килсә тагы**. Яшь вакытта булган эшләр инде. (Нәкый Исәнбәт, Рәйхан.) Bibkey. ... that blockhead Säkhäp has taken him to Gärey, it seems. Gölbikä. What if he has. Those are things which happened when they were young.
- Кызбикә. Кайтып киткәндер, ... я берәр җирдә ятадыр. Мәрьям. Егетләр беләнме? Хи-хи-хи. Кызбикә. **Булса тагы**. Минем кулыма тапшырылган кыз түгел. (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күңел.) Qyzbikä. She may have gone back (home), ... Or she is perhaps resting some place. Märyäm. With the boys? Ha-ha-ha. Qyzbikä. If she is, so what. She is not a girl who has been put under my care.

5. The particles **бит** and **соң** following a verb in the *conditional* may emphasize also other emotions.
   - Нәкыя. Ай ... нишлим соң? Минем өчен харап **булса бит**, алла сакласын. (Мирсәй Әмир, Миңлекамал.) Näqiä. Oh ... what am I to do then? God forbid that she should ruin herself for my sake.
   - Ильяс. Болай вакытсыз нишләп йөрисең, әни? Мәрфуга (ачу белән.) **Йөрсә соң**! Минем килүемне әллә гаепкә санар идеңме? (Гамир Насрый, Кадерле минутлар.) Ilyas. What are you coming here for at such an inopportune moment, Mother? Märfugha (with anger). What if I do come here. Would you fault me for coming?
   - – Ә бит синең, мөгаен, көчле, батыр буласың киләдер. – **Килсә соң**! (Фәнис Яруллин, Кыйгак, кыйгак каз кычкыра.) "But, after all, you probably want to be strong, brave." "And what if I want to!" (Pronounced with anger and a tinge of aloofness.)

# The Conditional with Other Particles

**[1006]**

1. **гына**, **генә**.
   The particle **гына**, **генә**, following a verb in the conditional, both *emphasizes* and *limits* the condition.
   - – Мин менә әнигә боларны кайтарып куям әле. Көт мине. – Тиз **чыксаң гына**. – Хәзер. (Рәисә Ишморатова, Язмышлар.) “Here, I just bring these (i.e., milk and bread) in to Mother. Wait for me.” “Only if you come out quickly.” “I’ll be right back.”
   - Җәй җиттеме, соңгы көзгәчә тормыш бакчага күчә. Кунак-төшем **килсә генә** өйгә керәбез. (Әсрар Галиев, Асыл кошым минем.) As soon as summer comes, life shifts to the garden right up to late autumn. We go into the house only if guests come.
2. **ла**, **лә**.
   The particle **ла**, **лә** emphasizes a *wish, request,* etc., while adding a shade of *familiarity, unceremoniousness.*
   - Шакир. Алай бик ашыккач, чыгып йөрмә. Үзем машина җибәрермен. Ризван. **Борчылмасагыз ла**. (Хәй Вахит, Күк капусы ачылса.) Shakir. Don’t leave in such a great hurry. I’ll send you a car. Rizwan. Oh, please, don’t bother.
   - Сөләйман. Бәдрелхәят абыстай, зинһар, сез шушыны Зөбәйдәгә **бирсәгез лә**? (Сәгыйть Рәмиев, Яшә, Зөбәйдә, яшим мин.) Söleyman. Lady Bädrelkhäyat, would you please give this (i.e., this letter here) to Zöbeydä?
   - Дирижер. Әфәнделәр, шауламый гына **утырсагыз ла**, ... (Галиәсгар Камал, Безнең шәһәрнең серләре.) The bandleader. Gentlemen, if you would please remain seated and not make any noise, ...
3. **-мы**, **-ме**.
   The particle **-мы**, **-ме**, joined to the personal endings of a verb in the conditional, emphasizes such emotions as *longing, regret, anger, disagreement, threat, admonition.*
   - Син исән **булсаңмы**, әни, бәгырем! Нинди бәхетле кеше булыр идем мин ... (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Унсигезенче яз.) If only you were alive, Mother dear! What a happy man I would be, ...
   - – **Әгәр** иртәгә шушы билгеләрне яттан **белмәсәңме**, – диде аңа апасы, – эткәйгә әйтеп, сыртыңны каезлатам мин синең! (Барлас Камалов, Ялыкмаслар.) “If by tomorrow you don’t know these (mathematical) symbols by heart, I shall tell Daddy and have him whip your back,” his (older) sister said to him. (The speaker admonishes and threatens her younger brother.)
   - Мин шул чорда **яшәсәмме**, күрсәтер идем мин аңа. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) If only I had lived in that epoch, I would have shown him. (Expresses disagreement and anger.)
   - Миркәй. Мин моны болай **калдырсаммы**? ... Судка **бирмәсәмме** мин аларны? (Нәкый Исәнбәт, Миркәй белән Айсылу.) Mirkey. Surely, you do not think that I am going to leave it like this? That I’m not taking them to court? (Mirkey is extremely incensed and threatens to carry out the actions.)
4. **-чы**, **-че**.
   The particle **-чы**, **-че**, joined to the personal endings of a verb in the conditional, emphasizes such emotions as: *regret, repentance, despair, reproach,* a *plea, wish*, or a *polite request, suggestion, inducement.*
   - Рабига. Бармаган **булсамчы**! Күрмәгән **булсамчы**! Ул сүзне башламаган **булсамчы**! Хәзер бәлки барыбызга да җиңелрәк булыр иде. (Аяз Гыйләҗев, Без

унике кыз идек.) Rabighä. If only I hadn't gone! If only I hadn't seen her! If only I hadn't started that conversation! Perhaps it would now be easier for all of us. (Expresses regret.)

- Мөршидә риза булды. Ләкин ай, риза булмаган **булсачы**! (Гариф Гобәй, Ләйсән яңгыр.) Mörshidä agreed. But, oh, if only she hadn't agreed. (Expresses regret.)
- – Гази! Аерылабыз да микәнни! Яа-а, йөрәккәем, ярылмыйча **түзсәңче**. Мәңгегә хушлашабыз бит. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) "Ghazi! We are parting from each other then! Oh, my poor heart, if only you will bear it without breaking. We are saying farewell to each other for ever." (Expresses despair.)
- Йөрәк леп-леп тибә башлый, күзләр кармак җебенә текәлә, чуртан каптымы, әллә чабакмы дисең, ә күңелнең бер почмагы, һәй, бот буе җаен килеп **чыксачы**, дип өметләнә. (Әнисә Ибраһимова, Томан тарала.) Your heart begins to throb, your eyes are fixed on the fishing line: You wonder (lit., say) whether a pike or perhaps a roach bit, but deep inside you hope (lit., a corner of the heart hopes) ardently that a sheatfish as long as your legs (lit., thigh, i.e., reaching from the ground to one's hips; waist-high) may emerge.
- Мавия. Әй ходаем, Маһитап апа ничек тә бер ярдәм итә **алсачы**. (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күңел.) Mawiä. O my Lord, if only Mahitap could somehow help me. (Expresses a plea with a tinge of despair.)
- Фәйрүзә. Ачык кына **әйтсәңче**, ... нәрсә бар? (Риза Ишморат, Серле моң.) Feyrüzä. If only you would make yourself clear, ... what is it? (Expresses a wish.)
- – Их, вакытында аңлаган **булсамчы**. (Әнисә Ибраһимова, Томан тарала.) "Alas, if only I had understood this in time." (Expresses a strong wish with a connotation of regret.)
- Нәгыймә. Әй, зинһар, үзеңне **кыстырмасаңчы**! (Шәриф Камал, Габбас Галин.) Näghimä. Oh, please, don't interfere! (Expresses a mild reproach.)
- – Алайса, бик күңелле яшисез? – Аның әле бөтенләй күңеллесе атна азагында була. Шимбә белән якшәмбе кичләрендә. ... Безнең клубка бер кичне килеп **карасагызчы**! (Эдуард Касыймов, Җир балкышы.) "In that case, you are living very happily?" "The happiest part of it is the weekends. Saturday and Sunday nights. ... You should try to come to our club one evening!"

**[1007]** Used without its conclusion (apodosis), a conditional clause (the protasis) may serve to express a rather wide range of modalities.

For example, depending on intonation, it may express:

a) A *mild inducement, polite request, stipulation,* or *suggestion.*

- ... Бузбала ...: – **Тыңлар булсагыз**, бөек каган – дип сүз башлады. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) ... Buzbala ... began to speak, "If you would kindly listen, great Khakan."
- – ... Син инде кешеләрне үзеңә тупларга туры килер. ... – Менә бүген минем белән шәп егетләр килде, әгәр дә аларны миңа **бирсәгез**... (Газиз Үзиле, Гыйфрит.) "... As it is, you'll have to assemble the men yourself. ..." "Well, there are some nice young men who came together with me today (i.e., to apply for work). If you'd assign (lit., give) them to me..."
- – Атны сугарып килик мәллә, улым? – Юк, Усылыны кичкәндә суны мул гына чөмерде. – Шулай ук мул гына чөмердеме? – Бабасы хәйләкәр елмаеп тагын сорап куйды. – Бүтән эчмәсме? – Эчмәс. – Малай хуҗаларча кырт кисте. – Дымлы үлән белән аркасындагы тозын **сыдырсак** кына ... (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) "How about watering the horse, my son?" "No, it slurped plenty of water when we passed through (the village of) Usyly." "So it slurped plenty?" His grandfather asked

again, smiling cunningly: “It won’t drink more?” “It will not drink,” the boy said categorically with an air of a proprietor. “If we just rubbed off the salt from his back with some damp grass...”

- Яңгура. Ах, качкын! Әйтәм бит, бу шул Җирән чичән. Тоткавыл. Сез аны башта ук кулга алырга **кушкан булсагыз**... (Нәкый Исәнбәт, Җирән чичән белән Карачәч сылу.) Yangghura. Ah, the fugitive! I’m telling you, this is that Jirän Chichän. Totqawyl. If you had ordered his arrest right at the beginning...

*Note:* җирән – red-haired; чичән – in ancient times a poet of the people. Җирән чичән – here used as the name of such a poet.

b) A *strong wish* or *yearning* for someone or something.

In this case, the conditional clause is usually used as an exclamation.

- Хак. Их, үземнең унҗиде яшьлек чагым **булса**! (Газиз Мөхәммәтшин, Тынгысыз төн.) Khaq. Oh, if it were only the time when I was seventeen!
- – Гәүһәр апа, көрсенмәгез, зинһар. Бар да яхшы булыр. Яшел Яр ул йөрәк яраларын төзәтә. – Яшел Яр шундый сихәтле **булса**! (Габдрахман Әпсәләмов, Яшел Яр.) “Gäwhär, don’t sigh like that, please. Everything will turn out well. Yäshel Yar heals aching hearts.” “If only Yäshel Yar were so beneficial!” (Yäshel Yar – Name of a small town.)

c) Used by itself, as an interrogative clause, the conditional clause may express a *suggestion, stipulation,* or *apprehensiveness, uncertainty, doubt, hesitation, offense, anger.*

In this function, the conditional clause does *not* take the interrogative particle **-мы**, **-ме**, the question being expressed by intonation only.

*Note:* This use of the conditional with the conclusion omitted occurs rather frequently in Tatar, especially in dialogue.

- Бәдри. Көндез булса сиңа әйтеп тә тормас идем. Беләсең бит кич күземнең язу укый алмаганын. Галимә. Ут янынарак барып **карасаң**? (Мирхәйдәр Фәйзи, Галиябану.) Bädri. If there were daylight, I wouldn’t even ask you (i.e., ask you to read the letter). But you know that I can’t read any writing when it is dark (lit., evening). Ghalimä. If you tried to, stepping closer to the light?
- Гөлниса. Кара әле, ялгызыбыз гына булганда, мин сезгә, якын итеп, син дип, Рәҗәп дип кенә **эндәшсәм**? (Риза Ишморат, Мәдинә.) Gölnisa. Look, please, what if I addressed you with the familiar “thou” and (your first name) Räjäp when we are alone?
- Гөләндәм. ... Туташ, егетләрнең берсе үз атыңа көй чыгарып җырласа, аны ни белән куендырыр идең? Хәмдия. Ул минем киявем булыр иде. ... Гафия. Туташ, әгәр ул көй чыгарган кеше Солтангәрәй мирза кебек карт бераү **булса**? ... Ерактан җырланган тавыш килә: Хәмдиянең ак калфагы. ... Хәмдия. Уз көем! Хәмдия көе! ... Рушан, нинди матур көй! ... Әйдә, ул якын бугай. Аңа гына яр булып ярылганымны белдерим ... Рушан. Шаһиттимер **булмаса**? Хәмдия. Нигә ул булмасын? ... Чынлап та, ул Шаһиттимер **булмаса**? Шаһиттимерем, син бит бу? Син бит? ... Рушан. Аңа **җитә алмасаң**? Усаллар кулына **төшсәң**? Бакыйны гына җибәрик, туташ ... Хәмдия (куркып.) Ул **югалса**? (Мирхәйдәр Фәйзи, Ак калфак.) Göländäm. ... Miss, if one of the (young) men composes a song on your name, with what would you reward him? Khämdiä. He would become my companion for life (fiancé, bridgegroom) ... Ghafiä. Miss, what if that person composing the song turns out to be someone as old as Mirza Soltangärey? ... From the distance comes the voice of someone singing: Khämdiä’s white qalfaq. ... Khämdiä. My song! Khämdiä’s song! ... Rushan, what a beautiful song! ... Come, let’s go, he seems to be nearby. I’ll tell him that I was born for him alone, to be his sweetheart. ... Rushan. What if he isn’t

Shahittimer? Khämdiä. Why shouldn't it be he? ... (But) indeed, if he isn't Shahittimer? My Shahittimer, it is you, isn't it? It is you? ... Rushan. What if you can't get to him? What if you fall into the hands of evil men? Let's send Baqi, Miss. ... Khämdiä (frightened). But if he disappears (i.e., the person singing)?

*Note 1:* Khämdiä is the daughter of a Mirza, Rushan is one of her servants. Baqi is the Mirza's shepherd.

*Note 2:* Qalfaq – National headgear for women. Embroidered with beads or pearls.

· – Туктале! Әнә, күрдеңме? Бер капчык он! Әнә, әнә агып бара! Ул зур булып ачылган кара күзләре белән бер миңа, бер су өстенә карый. – Карале, **әгәренки** аны су анасы юри **чыгарган булса**? Безне кызыктырыр өчен! (Гомәр Бәширов, Туган ягым, – яшел бишек.) "Just wait! There, did you see it? A bag of flour. There, it's floating there!" Her black eyes wide open, she now looked at me, now on the water (of the lake). "What if the water-sprite has put it out intentionally? To entice us!"

· Рабига. ... Акланма, сиңа килешми. Наилә. Акланмыйм. Рабига. Нигә көлеп торасың алайса? Наилә. Сорама, Рабига. Рабига. **Сорасам**? Бәлки сорарга дип килгәнмендер. (Аяз Гыйләҗев, Без унике кыз идек.) Rabighä. ... Don't justify yourself, it isn't proper for you. Nailä. I'm not justifying myself. Rabighä. Why are you laughing then? Nailä. Don't ask me, Rabighä. Rabighä. And if I ask? Perhaps (the reason) I have come (is) to ask? (Pronounced with a tinge of anger and offense.)

d) In a *dialogue* consisting of a *question* in the *conditional* and an answer to it, the verb in the answer may – just like in the conclusion of conditional sentences – appear in the *continuous past.*

· Хәдичәнең башы аска иелгәннән иелә барды. Ниһаять, ул ниндидер бөтенләй үзенекенә охшамаган ят, арыган тавыш белән:
– Моны күтәреп син ничек яши алдың? – дип сорады.
– Үзең әйткәнне көттем... Менә бит – әйттең. Мин дә әйттем...
– Әгәр **әйтмәгән булсам**?
– Мин дә **әйтми идем**. Син минем бөтенесен дә белгәнемне уйлап та карамаячак идең. Ялгыш уй белән **китә идең** дөньядан... бу берни дә сизмәде дип. (Фоат Садриев, Таң җиле.)
Khädichä's head bent lower and lower. Finally, she asked in some strange, tired voice, which did not resemble her own at all:
"How could you live, bearing this?" (i.e., knowing that Khädichä had an affair with her interlocutor's husband.)
"I waited for you to tell me yourself. Now, there, you have told me. (And) I have told you too..."
"What if I hadn't told you?
"I wouldn't have said anything either. You wouldn't have had the slightest idea that I knew everything... You would have left the world with the false assumption that she didn't sense anything."

**[1008]** Used *by itself, without* a consequence clause, the conditional followed by **иде** indicates the speaker's *desire* or *wish* for the execution of the action expressed by the conditional, or it denotes a *polite request, stipulation, repentance* or *regret.*

· Заһирны уйлап утырам. Ул да уйлый микән? **Уйласа иде**! (Таһир Таһиров, Галия.) I am sitting, thinking of Zahir. I wonder if he too is thinking (of me). If only he would!

· – Син, Якубҗан, күзгә ташлана торган кеше бит, гади кеше түгелсең. Иң әүвәл шул турыда **онытмасаң иде**. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) "You,

Yaqubjan, are, after all, a man who attracts attention (he is a militia captain), you are no ordinary man. Above all, you should not forget that." (Expresses a strong wish with a tinge of reproach.)

- Тәлгать. Камилә апа! Тик минем өчен **борчылмасагыз иде**. (Хәй Вахит, Беренче мәхәббәт.) Tälghät. Auntie Kamilä! If only you would not worry about me.
- Сәлим. ... Ах, кичерә **алсаң иде** син мине. Беләм, мин гаепле ... (ibid.) Sälim. ... Oh, if you could forgive me. I know, I am guilty, ...
- – Синең шалтыратуыңны нинди түземсезлек белән көткәнемне **белсәң иде**. (Рәфкать Кәрами, Йөрәгемне ут алган.) "If you had known with what impatience I waited for your (telephone) call." (Expresses regret.)
- – Әнә минем баштагы сорауга кыска гына җавап **бирсәгез иде** ... (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) "If you would just give a short answer to my initial question ..."
- Сара. Күземнән **юк булсаң иде**, ярабби! (Әхәт Гаффар, Ярлар моңы.) Sara. O God, if you would only get out of my sight.
- Мавия. Нәкыя ханым, Ганбәр, сез мине Бәкер абзый белән генә **калдырсагыз иде**. (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күңел.) Mawiä. Lady Näqiä, Ghänbär, would you please leave me alone with Bäker.

**[1009]** The conditional followed by the modal word **икән** emphasizes to varying degrees the speaker's *wish, desire, request, invitation* to *fulfill* (or *not fulfill*) the action. Furthermore, it may indicate strong *apprehensiveness, repentance,* or *regret* of having (or not having) performed the action.

- – Монда шәп шул, экияттәге өйдә кебек миңа. Һавасын сулап туймаслык. Син берәр җәй көне **килсәң икән**! (Фәнил Галиев, Командировка.) "Here it's really nice. For me it's like living in a fairy-tale house. One can't get enough of breathing the air here. You should come over some summer day!"
- Балта остасы ... тукучы янына барды: – Агачтан бер нәрсә ясадым, һичкемнең андыйны күргәне юк. Миңа ярдәм **итсәң** һәм минем белән сахрага **барсаң икән**. ... Бу тылсымны кулланып, сынап карыйк ... – диде. (Мәҗмугы-л-хикәят, Патша кияве «Җәбраил» маҗаралары.) The carpenter ... went to the weaver and said. "I have made some thing of wood. No one has ever seen such a thing. If you would only help me and come along (go) with me into the desert. ... Let's try to use and test this magic thing, ..."
- Шаһзадә ...: – Солтанның шахматка оста кызы бар икән, аның белән **күрешсәм икән**, – диде. (Мәҗмугы-л-хикәят, Җәйсур хикәяте.) The prince ... said. "The Sultan has a daughter who is a master at playing chess, it seems (as they told me). I would very much like to meet with her."
- Нинди әйбәт кешеләр икәнлеген **белсәгез икән**! Аларда ике елга якын яшәдем. (Фәнил Галиев, Командировка.) If you knew what good people they were! I lived with them for nearly two years.
- – Мин дә синә охшый **алсам икән**. (Барлас Камалов, Өметең өзелмәсен.) "If only I could be like you."
- – Ах, шул кошларның берсе **булсаң икән**! Әкиятләр илен барып күрер идем мин! (Әхсән Баянов, Декабрьның унөченче көне.) "Oh, if one were only one of those birds! I would go and see the land of fairy tales!"
- Бәхетеңне кайчан табасыңны **белсәң икән**! Белмәдем шул мин, белмәдем! (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) If one only knew when to find one's luck (happiness)! I surely didn't know, I didn't!

- [Кыз] күңелендә әйтте: «Бармаган гына **булсам икән**, бу егетне күрмәгән генә **булсам икән**!» (Мәҗмугы-л-хикәят, Таз бакчасы турында хикәят.) [The girl] said to herself (lit., in her heart), “If only I hadn’t gone, if only I hadn’t seen this young man!” (Expresses extremely strong regret and apprehensiveness.)
- ... Фидаяров ... юлдан читкәрәк төште һәм үзенә ошаган урынны табып, машинасын туктатты да ял итеп алырга булды. Әгәр дә ул үз юлыннан икенче тапкыр читкә борылмаган **булса икән**! (Газиз Үзиле, Гыйфрит.) ... Fidayarov ... departed somewhat from the road and, finding a place he liked, stopped his car (intending) to take a rest. If only he hadn’t turned off his road for the second time! (He would have avoided getting into a situation which changed his life in an extremely unpleasant and harmful way.)

**[1010]** A verb in the *conditional* followed by **кирәк**, or a verb in the *indicative* followed by **булса кирәк**, expresses a *supposition, probability.*

- Телдән әйтелмәгән бу үпкәне этисе үзе дә **сизсә кирәк**, өйдә вакытта гел улы белән була, уенчыклар алып кайта, ... (Сафа Сабиров, Үз каным.) Father himself too must feel this unspoken resentment. When he is at home, he is always with his son, brings home toys for him, ...
- Рәхим сорарга мәҗбүр булды. – Сез музыкант **булсагыз кирәк**? (Атилла Расих, Ике буйдак.) Räkhim was forced to ask, “Would you be a musician?”
- ... ул яхшы күңелле, намуслы кеше булган булырга тиеш ... Заһидә апаны бәхетсезлектән йолып, ничәмә йөз чакрым җирдән атасы йортына китерүе шуны **расласа кирәк**. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) ... he must have been a good-hearted, honest man. ... That he rescued Zahidä from her troubles and brought her to her father’s home from a place hundreds of versts away would confirm that.
- – Кичә генә миндә Бәшири булды. – Бүген сиңа килерме ул? – **Килсә кирәк иде**. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) “Yesterday Bäshiri was with me.” “Will he come today to you?” “He ought to (should) come.”
- 1966 нчы елның җәй башында **булса кирәк**, сабан туйларында катнашу өчен, без – дүрт татар язучысы – Мамадыш районына киттек. (Фатих Хөсни, Кичке дога.) It must have been at the beginning of the summer in the year 1966, when we – four Tatar writers – traveled to the district of Mamadysh to participate in the festivities of the plough.
- ... ул хәзер Алтынчәчтән читләшә, аның белән араны бөтенләй өзәргә **ниятли булса кирәк**. (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) ... he now avoids (keeps away from) Altynchäch. He probably intends to break completely with her.
- Ул мине аяк тавышларымнан ук **таныды булса кирәк** ... (Атилла Расих, Хәвефле сынау.) He must have recognized me right away by my footsteps ...
- Сөләйманның соңгы сүзләре кызны уңайсыз хәлгә **калдырды булса кирәк**. (Кәрим Тинчурин, Тугызынчы мәрҗән.) Söleyman’s last words must have left the girl in an awkward position.
- Сөләйманның керсез, ... бу сүзләре өстәл артында утырган кешегә **ошады булса кирәк**. Ул елмаеп: – Ярый, барыгыз, уйлагыз. ... (ibid.) The man sitting behind the desk must have liked these sincere, ... words of Söleyman’s. Smiling, (he said), “All right, go, think about it.”
- – Сезнең шикләнүегезнең серенә төшенәм бераз, – диде ул. – Сез минем эшемнең методик алымнары белән **танышкан булсагыз кирәк**, ... (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) “I understand a bit why you are having doubts,” he said. “You probably have made yourself familiar with the methodical ways of my work, ...”

**[1011]** A verb in the conditional followed by:

1. **да**, **дә**, **та**, **тә** and the modal word **ярый**, **ярар** expresses

   a) the *possibility, permissibility* to carry out, or not to carry out, the action; b) a *reproach* or *friendly advice.*

   · – Һаман ышанып бетмим әле. ... Такси белән килдек. Әйберләрне иртәгә **алып килсәк тә ярар**. (Мәдинә Маликова, Казан каласы – таш кала.) "I still don't fully believe it (i.e., that they got their own apartment) ... We came by taxi. We can bring our things here tomorrow. ..."

   · Ул минем дустым. Авылдаш **дисәң дә ярый**. (Кәрим Тинчурин, Өченче мәрҗән.) He is my friend. You can (may) also call him a fellow villager.

   · Хәйдәр. Бер вакыт табып, шул хатны аңа тапшыра алмассыңмы? Хәмит. Мөмкин булыр, дип уйлыйм. Хәйдәр. Хат ашыгыч түгел. Кайчан **тапшырсаң да ярый**. (Кәрим Тинчурин, Беренче чәчәкләр.) Kheydär. If you find the time, couldn't you deliver that letter to him? Khämit. I think it will be possible. Kheydär. The letter is not urgent. You can (may) deliver it at any time.

   · – ... рәхим итегез, җавапны хәзер үк **бирмәсәгез дә ярый**. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) "... please, you need not (don't have to) give the answer right now." (Or: "... please, it's all right if you don't give the answer right now.")

   · Арслан. Ай-һай, Гөлшаян, эреләнгәнсең, исәнләшмисең дә. Гөлшаян. Башлап үзең **исәнләшсәң дә ярар**. Әзме-күпме мин сиңа апа кеше. (Мирсәй Әмир, Гөлшаян.) Arslan. I must say, Gölshayan, it seems you have become quite proud. You don't even greet people. Gölshayan. It would be proper if you greeted me first. I am somewhat older than you. (Expresses a mild reproach.)

   · Сания. ... үзеңне кунак итеп **санамасаң да ярар**. Миңа булышыр идең. (Мирсәй Әмир, Җыр дәвам итә.) Saniä. ... If only you wouldn't regard yourself as a guest. If you would only help me. (Expresses a reproach.)

   · Өмми. Миңлекамал бередәме, Хәерниса? Хәерниса. Биредәсен биредә дә, эше бик тыгыз әле аның. Тиз генә бушый алмас. **Кайтып торсаң да ярар**. (Мирсәй Әмир, Миңлекамал.) Ömmi. Is Minglekamal here, Khäyernisa? Khäyernisa. She is here, but her affairs are still very strained. She won't be free soon. You had better return (home). (Expresses a friendly advice.) (For биредәсен биредә see 1238, c.)

   · Бәдри. Бүген бик суык бит, инде **чыкмасаң да ярар**. (Мәҗит Гафури, Ярлылар.) Bädri. It is very cold today, after all. It would be better if you didn't go out anymore.

2. A verb in the conditional followed by **ярар иде** or **гына**, **генә**, **кына**, **кенә ярар иде** expresses a *wish, polite request, apprehensiveness, fear.*

   · Зәкия. ... «Һай илгәзәк тә инде бу Бибинур! Кичкә безгә ашка керәсе бар, тагын каядыр чыгып китте әле. Кайтып җитәр җитүен, бик озак юанып **көттермәсә генә ярар иде**!» дип уйлады. (Аяз Гыйләҗев, Җомга көн, кич белән.) Zäkiä ... thought, "Oh, is this Bibinur ever smooth-spoken! She is (supposed) to come to us for dinner and she has gone off somewhere (else) again. She'll manage to get here (sometime). If only she doesn't tarry too long and make us wait."

   (For җитәр җитүен see 1206 a, b 1.)

   · Вафа. ... Мәшәкать булмаса, минә шушы мәкаләне карап **чыксагыз ярар иде**. (Ибраһим Нуруллин, Тукай Петербургта.) Wafa. ... If it isn't inconvenient, I would like you to look over (review) this article here.

   · Шапырдап су чәчрәгән тавышка әйләнеп караса, Шәфика инде суның тирән җиренә үк кереп җиткән иде. Йә ходаем, **батмаса гына ярар иде**. (Гариф Ахунов, Идел кызы.) When, upon the sound of the splashing water, she turned

around and looked, (she saw) Shäfiqa had already reached the spot where the water was deep. O my God, if only she won't drown.

- Сәрби. Минә рәхмәт сиңа Мәфтуха бәгърем. **Калдырмасаң ярар иде** дип котым очып торды. (Фәтхи Бурнаш, Яшь йөрәкләр.) Särbi. Thank you, Mäftukha, my dear. I was terrified that you would leave me.

**[1012]** The conditional followed by **да**, **дә**, **та**, **тә** and the *third person singular* of **булу** – mostly in the *present tense indicative,* less often in other tenses – expresses the *possibility, admissibility* to carry out, or not to carry out, the action denoted by the verb in the conditional. Furthermore, it indicates an invitation to carry out (not to carry out) the action.

- Инде **кузгалсак та була,** ... (Гөлсем Мөхәммәдова, Яшьлек көннәре.) "We can get going now ..."
- – Минә хәзер **уйнасаң да була**. ... Искәндәр ... пианино каршына килеп утырды. (Разил Вәлиев, Иске сәгать дөрес йөри.) "Now you can play." ... Iskändär ... stepped to the piano and sat down.
- – Шушында **туктатсагыз да була**, юкса сезгә борылуы читен булыр, – диде Рәхим. (Атилла Расих, Ике буйдак.) "You can stop right here; otherwise it will be difficult for you to turn around (with the car)," Räkhim said.
- – Торуын үзебездә генә торырлар, анысы өчен баш **ватмасагыз да була**. (Альберт Хәсәнов, Әбием ядкаре /jədkəre/.) "They will, of course, stay with us. You need not rack your brain over that."
- Райман. Алар алдында үзеңнән гафу үтенермен. Гөлия. Миннән **гафу үтенмәсәң дә була**. (Рөстәм Мингалим, Өченче бүлмәдә эт яши.) Raiman. I shall apologize to you in front of them. Göliä. You need not apologize to me. (It's all right if you don't apologize to me.)
- Димәк, бу тарафтан Туры карт үз максатына иреште **дисәң дә була иде**. (Эдуард Касыймов, Җир балкышы.) That means, one could say that from this point of view, old Tury had achieved what he had intended.
- – Ә бит ул дөрес эшләмәде! Без аңа ярдәмгә килдек. Без монда чит кешеләр. Безгә **килмәсәк тә булыр иде**. Шулай булгач, ул безгә алай ук караңгы чырай күрсәтергә тиеш түгел. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) "But he didn't act right after all! We came here to help him. We are strangers here. We could also not have come here. Considering that, he ought not behave in so unfriendly a manner (show us a somber face)."
- [Валия] ... Хәзер **борылсаң да була**, – диде. (Батулла, Юл буенда зәңгәр чәчәк.) "... Now you may turn around," [Wäliä] said.

**[1013]** A verb in the *affirmative* conditional, immediately followed by the *same* verb in its *respective negative* conjugated form of the *past tense I indicative*, expresses *impatience.*

- **Башласалар башламадылар**, парга әйләнеп, морҗадан очар вакыт җитте монда. (Фатих Хөсни, Утызынчы ел.) When are they going to start – if they are ever going to. People in here are ready to turn into steam and fly through the chimney.
- Бер якта тышкы баскычка чыгып баскан хатын, икенче якта – ... ир, өченче якта «**җиксәләр җикмәделәр**, болар нишләр минем белән?» дигәндәй, әллә нидә бер калын иреннәрен шапылдатып куйгалаучы алаша – торалар да торалар басып. (ibid.) They remain standing there; on one side, the woman, who has stepped out on the outer staircase, across from her (on the other side) – the husband ..., and beside him, (on the third side) the horse, now and again champing his thick lips as if saying, "What are they going to do with me, are they ever going to harness me?"

**[1014]** A verb in the *affirmative* or *negative conditional* followed by the *same* verb in its *respective affirmative* or *negative* conjugated form in the *present, past,* or *future* tense *indicative,* or by a verb in the *imperative* or *optative* expresses:

a) varying degrees of *concession*, with or without a tinge of *indifference, unconcern, possibility, resignation;* b) *indifference, unconcern;* c) *agreement, consent;* d) *possibility, probability;* e) *reproach;* f) *determination, courage, resolution;* g) *emphasis, intensiveness;* h) an action the *reason(s)* for which is (are) given in *concrete terms* by successive words (statements, etc.).

The two verbal forms may be separated by the particle **да**, **дә**; the conditional clause and the conclusion may be contrastive.

*Note:* When expressing concession it may sometimes have the meaning of such concessive expressions as 'true', 'I admit', 'to be sure', 'certainly', 'indeed'.

Examples of a):

- Мин, әлбәттә, аның иртәгә чаклы хикәяне укып чыгарына ышанмадым. ... **ышанмасам, ышанмадым**, ... төп-төгәл унга ... килеп кердем. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) I did not, of course, believe that he would read through (review) the story until the next morning. ... though I did not really believe it, I entered (the room of the Writers' Union), ... precisely at ten o'clock.
- Узгандагыларны искә **төшерсә төшерә**, ә менә «хәзергеләрдән» аерылып китә алмый, ... (Фатих Хөсни, Яз галәмәте.) He does recall what is past, but he cannot part "from what is now", ...
- Урман юлы белән бара торгач, бу юл тар гына бер сукмакка әйләнә. «**Адашсам адаштым** инде, барыйм әле мин шул сукмак беткәнче», дип уйлый бу. (Татар халык әкиятләре, Өч күгәрчен.) After he walked for some time along the forest road, this road turned into a rather narrow path. "Even if I lose my way, I'll follow this path until it ends," he thought. (Connotes possibility.)
- ... карчык чыдамады: – Ходайның язмышы булыр! Ни **күрсәм, күрермен**, ... – дип, авылга китәргә риза булды. (Галимҗан Ибраһимов, Тирән тамырлар.) ... the old woman did not resist. Saying: "What God wills will be! Whatever I am to face, I shall face, ...," she agreed to travel to the village.
- **Ашамасам ашамыйм, йокламасам йокламыйм**, әмма ызбаны менә дигән итеп салдырам. (Фатих Хөсни, Куркыныч йорт.) Even if I don't eat, even if I don't sleep, I'll still have the house built in the grand style. (Ызба – dialect: өй.)
- Камилә. **Әйтсәм әйтим** инде, Мәхупҗамал, мин сиңа яучы булып килгән идем. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Kamilä. Let me tell you then, Mäkhupjamal, I have come to you as a match-maker.

Examples of b):

- – Бу минем сыер, ... – Үземә кайтарыгыз, юкса казыйга барам, – ди бай. – **Барсаң барырсың**, сыерны сиңа кайтарыр өчен асрамадык, – ди бабай. (Татар халык әкиятләре, Мактанчык бай.) "This is my cow, ... Return it to me, otherwise I go to the judge," the rich man said. "If you go, so what, we didn't rear the cow to return it to you," the old man said.
- «**Барса да барыр** шул», диештеләр авылдашлар, «җылап калыр кешесе юк, ...» (Аяз Гыйләҗев, Әтәч менгән читәнгә.) "If he goes, so what," the fellow villagers said, "he has no one who will remain (behind) and cry, ..."
- Алмагач әйтә: – **Киссәләр кисәрләр**, беренче чәчрәгән йомычкамны артыгыздагы күлгә илтеп ташласана, – ди. (Татар халык әкиятләре, Аучы белән асрау кыз.) The apple tree says to her, "If they cut me down, let them. Please, throw the first of my chips which fly into the lake behind you."

Examples of c):

- Камилә. Сәлим, Тәлгатьне укырга урнаштыру чарасын күрәбезме әллә? Бәлки, Госман ярдәм итәр, ... Әллә соң Госман белән сөйләшеп карыйммы, дим. ... Сәлим. Әйдә, **сөйләшсәң сөйләш** инде. (Хәй Вахит, Беренче мәхәббәт.) Kamilä. Sälim, shouldn't we see about some way of getting Tälghät placed for (higher) education? Perhaps, Ghosman would help, ... I mean, perhaps I should try talking to Ghosman then. ... Sälim. Right, go ahead and talk with him.
- Мулла ... миңа әйтте: – Әйдә, кайтыйк инде, Гыймадетдин, ди. Бу бик хозур булды, ди. – Ярый, мин әйтәм, **кайтсак-кайтыйк**, дим. (Галимҗан Ибраhимов, Тирән тамырлар.) The mulla ... said to me, "Come on, let's return now, Ghimadetdin. It was very enjoyable." "All right," I said, "if you say so, then let's return."

Examples of d):

- – Ирегез үлгән икән, ә? ... Бу әнә маңгайга бәреп сорады. **Чыдасаң, чыда**, авыр булса, ела да җибәр. (Кояш Тимбикова, Тын бакчада.) "Your husband died, right?" ... He put the question right to her. "Bear it, if you can. If it is too difficult, cry out."
- Шуннан соң бу егеткә карчык: – Улым, ... син сораган нәрсәне мин белмим, аны минем тутам **белсә белер**, иртәгә шуның янына барырсың, ..., – ди. (Татар халык әкиятләре, Көнгә күренмәс Сылу-көмеш.) After that the old woman says to the young man, "My son, ... the thing you asked I don't know, my (older) sister probably knows it. You'll go to her tomorrow ..." (Тута – dialect: апа.)
- Әй, ходаем, әй, раббым, хуҗам! Адәм бу чаклы да **үзгәрсә үзгәрер** икән. (Галимҗан Ибраhимов, Яшь йөрәкләр.) O, my God, o, my Lord, my Master! That a man can change so much!

Examples of e):

- Тик әллә нинди шатлык вә дуслык минутларында гына, ярым шелтә вә ярым иркәләү катыштырып: – Куйчы, балам! Кайдан тапкансың шул җыен койрыксыз киемнәреңне! – дип **куйса куя**. (Галимҗан Ибраhимов, Яшь йөрәкләр.) Only at certain moments of gladness and friendliness would she put it directly to him, half reproachfully and half caressingly, "Come on now, my child! Where did you get all these funny-looking clothes of yours!"

Examples of f):

- Бара, бара, барып керә бер кара урманга. Моңарга шул кара урманның эчендә бер сарай күренә башлый. «Ни **булса да булыр**, шул сарайга барып керим әле» – ди егет. (Татар халык әкиятләре, Аучы белән асрау кыз.) Walking for some time, he comes into a dense forest. In that dense forest he catches sight of a palace. The young man thinks (lit., says), "Whatever happens, I'll go to that palace and enter it."
- Егет әйтә: – Әй хатын, **әйтсәм әйтеп бирим**. Минем кешегә күрендерми торган бүрегем бар. (ibid.) The young man says, "Oh, woman, let me tell you straight out. I have a cap that makes me invisible to man."
- Ире әйтә: – Әй, нәрсәгә безгә ул алмагач, **киссәк кисәрбез**, – ди. (ibid.) Her husband says: "Oh, why do we keep that apple tree, what if we just cut it down?"

Examples of g):

- – Без бит барыбер бергә булачак. Безне хәзер инде кабер генә **аерса аера алыр**. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы ажаган.) "After all, we will be together anyway. Now nothing but the grave can separate us."
- ... Рөстәме дә итәкләре бозга катып кайтып керә иде бит. Итек эчләренә ... кар тулган булыр иде. Соңыннан радиаторга әле аркасын, әле аякларын терәп бик озак җылыныр иде. Суык **тимәсә дә тими** икән бу бала-чагага. (Ләбибә Ихсанова, Ана көндәлеге.) ... after all, her Röstäm too used to come home with the lower part

of his coat frozen stiff. His boots would be filled with ... snow. Then he would warm himself for a very long time, now leaning his back onto the radiator, now holding his feet, against it. These children never seem to catch cold.

Examples of h):

- – Тулаем алганда, кешеләр яхшы сезнең совхозда. ... **Йокламасалар йокламадылар**, игеннәрне вакытында җыеп бетерделәр. (Фатих Хөсни, Зәңгәр җыр.) "Taken as a whole, the people on your State farm are good ... They certainly did not sleep. They brought in (lit., gathered) the corn on time."
- Ул (Галимҗан) кул-аякларын гына өшетеп калмаган, бик каты салкын да тидергән иде. Шулай да Хөсәен бирешмәде, җитәрлек **ял итмәсә итмәде**, тик газетаны вакытында әзерләп барды. (Атилла Расих, Айлы төннәр.) Not only had his (i.e., Ghalimjan's) hands and feet become frostbitten, he had also gotten a very severe cold. Still, Khösäyen did not give in. True, he didn't get sufficient rest, but he continued to get the newspaper ready on time. (The newspaper which the two men were publishing.)
- ... Ситдыйк каты итеп санап әйтте: **Гаепләсәң, гаепләрсең** инде, Миңзифа тутай! Сине сыйларлык хәлебез юк. (Галимҗан Ибраһимов, Тирән Тамырлар.) ... Enumerating (the reasons), Sitdiq said bluntly, "You may blame us for it, Aunt Mingzifa! But we are in no position to offer you anything (i.e., food)."
- Варшаваларны, Берлиннарны узып киттем. **Китсәм киттем**, ә күкне җиргә тоташтырган әлеге серле сызыкны барыбер куып җитә алмадым. (Ибраһим Гази, Малайлыкта кунакта.) I had passed through such cities as Warsaw and Berlin. True, I had traveled that far (i.e., I had had the possibility of passing through), but still, I was unable to catch that mysterious line which joins the sky to the earth.

**[1015]** A verb in the *affirmative conditional* and repeated in the *negative conditional*, and each of them followed by the particle **да, дә** and the *same* verb in its *respective affirmative* conjugated form of the *indicative* or in the *imperative*, indicates that the subject performs the action *reluctantly*, that existing circumstances or moral considerations *force, compel* the agent, leave the agent no choice to carry out the action.

The two pairs of such constructions may be separated from each other by other parts of speech. The last component of the second pair is sometimes omitted.

- Кинотеатр ишек төбенә җиткәч, Тәнзилә Мәхмүткә акча сузды: – Мә, билет ал. **Алса да алды** Мәхмүт акчаны Тәнзилә кулыннан, **алмаса да алды**. Аның башка чарасы юк иде. (Сәет Шәкүров, Сәхнәнең кыл уртасында.) When they came to the doors of the cinema, Tänzilä held out the money to Mäkhmüt, "Here, get the tickets." Reluctantly, Mäkhmüt took the money from Tänzilä's hand. He had no other choice. (He himself had no money to pay for the tickets.)
- Хатыннар дәшми генә чәй эчә башладылар. Дүрт стаканга чәй ясап куелган иде. Сәгадәт **утырса да утырды, утырмаса да утырды**. (Саҗидә Сөләйманова, Йолдызларга йодрык.) The women began to drink tea without saying anything. Tea had been poured into the four glasses. Säghadät sat down reluctantly.
- Айсылу (авыр сулап.) Мең чуалчык ... мең бәла ... Барысы да бер башыңа синең, Айсылу. **Чишәлсәң чиш, чишәлмәсәң дә чиш**. (Риза Ишморат, Шаулыйлар дулкыннар.) Aisylu (breathing heavily): A thousand dilemmas, a thousand troubles. All of them fall on your head alone, Aisylu. Solve them however you can (i.e., you have no choice). (чишәлсәң, чишәлмәсәң – contractions of чишә алсаң, чишә алмасаң, 1245, 1, 2 a-b).
- Мондый хәлләрдә әнисе нишләсен, **күнсә дә күнде**, **күнмәсә дә күнде** Рәмиләнең китүенә. (Эдуард Касыймов, Җир балкышы.) Under such circumstances what should

her mother do. Reluctantly she agreed to Rämilä's departure. (The mother had no choice, she was helpless.)

- Бу атасына көн-төн ирек бирмичә сорый торгач, атасы инде моңа рөхсәтне **бирсә дә бирде, бирмәсә дә бирде**. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) When he kept asking his father, not giving him peace day and night, his father reluctantly gave him permission.
- – Актык йөз тәңкә, ди, **алсаң да ал, алмасаң да ал**, моннан соң миннән акча кайтып сорама. (Татар халык әкиятләре, Һөнәрле югалмас.) "These are the last hundred rubles," he says. "You take them (since you are broke you have no choice), (but) after this don't ask me again for money."
- Ниһаять, Илгәзәк канәгатьләнде. Дөресен әйткәндә, **канәгатьләнсә дә канәгатьләнде, канәгатьләнмәсә дә**, чөнки аның вакыты беткән иде инде. (Мирсәй Әмир, Егет шә-ә-әп.) Finally, Ilgäzäk was satisfied. To tell the truth, he had to (was obliged to) be satisfied because he had no more time.

**[1016]** A verb in the *affirmative conditional*, followed by the *same* verb in its *respective affirmative* conjugated form of the *indicative* or *imperative* and repeated in the *negative conditional* followed by **юк**, expresses the speaker's *indifference* towards, or *resignation* to, the action.

- – Ул әнә өенә кайтып **керсә керә, кермәсә юк**. Хәер, аның кайтып кермәве яхшырак та. (Нурихан Фәттах, Кол Гали.) "If he doesn't come home, so what. Anyway, it's even better if he doesn't."
- Сүзне Мансурның авызыннан келәшчә белән тартып алырга кирәк. ... тәртибе белән бервакытта да сөйләп бирми. ... **Аңласаң аңла, аңламасаң юк**. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) The words have to be pulled from Mansur's mouth as if with pincers. ... he never tells things in an orderly fashion and (all) at the same time. ... If you don't understand it, so what.
- Малайлар белән дә бик җиңел түгел дөнья. ... кайтканчы җиңгәгез алардан тәмаммы туя, минем ... кайтып керүем була, өчесен берьюлы минем өскә өсләтеп җибәрә. **Чыдасаң, чыда, чыдамасаң – юк**. (Гариф Ахунов, Хуҗалар.) With boys it isn't all very easy either. By the time I return (home) ... your sister-in-law is thoroughly fed up with them and, as soon as I come home, ..., she sets the three of them on me together. What can you do, you just bear it. (For керүем була see 1201, b.)
- ... ишек янында торган хатын: – Ашыга халык, ..., – дип үзалдына сөйләнеп калды. ... Якуб бу сүзләрне **ишетсә ишетте, ишетмәсә юк**. Ул шат иде. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) ... talking to herself, the woman standing at the door said, "People are in a hurry ..." ... Yaqub paid no attention to these words. He was happy.

## The conditional of the verb дию

**[1017]**

a) The conditional of the verb **дию** 'to say' in the *second person singular* – **дисәң** – placed between the reduplication of a noun word – mostly substantive – *emphasizes* the *positive* or *negative* qualities expressed by the reduplicated word. **Дисәң** may or may not be followed by the particle **дә**.

- – Менә **егет дисәң дә егет** бу Кәрим! (Ибраһим Салахов, Имәннәр тамыр җәйгәндә.) "Indeed, he is a real man, this Kärim!"

- Менә ичмаса сөенеч! **Сөенеч дисәң дә сөенеч**. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) Here at least was good news! Real good news, indeed.
- Сәйфи. **Юләр дисәң дә юләр** инде мин. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Seyfi. Well, I am really a fool.
- Матур Зартугай яклары. **Урманы дисәң – урманы, даласы дисәң – даласы.** (Гариф Ахунов, Идел кызы.) The area of Zartughai is beautiful. What forests, what a steppe it has.

b) Placed between the reduplication of an *adverb of time,* **дисәң** emphasizes the *time* denoted by the adverb.
   - Хәзер, сүз дә юк, тормыш әйбәт. Җитешмәгән нәрсәбез юк. Минем **бүген дисәң бүген** «Жигули» алырлык рәтем бар. (Вакыйф Нуруллин, Аккан су юлын табар.) There is no question about it, life is good now. There is nothing missing. I have the means to buy myself a "Zhiguli" right now, today. (Zhiguli – make of an automobile.)

c) The modal word **түгел**, the modal word **юк**, or a *verb* in its *negative form,* following the *second component* of the reduplication, negates the meaning of the construction, or it indicates *uncertainty.* When followed by a verb, the second component appears in the case governed by the verb.
   - Нәрсә ул техникум бетергән кеше? **Надан дисәң, надан түгел, белемле дисәң белемле түгел**. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) What is a person who has finished the technical school. He (she) isn't really uneducated nor is he (she) really educated.
   - Көн болытлы, күңелсез иде. Өстәп, **яңгыр дисәң яңгыр түгел, кар дисәң кар түгел**, салкын дым ява. (Мәдинә Маликова, Казан каласы – таш кала.) The day was cloudy and dull. In addition, no real rain, no real snow, but a cold dampness came down.
   - Сәет моңарчы бер дә татымаган тирән һәм татлы йокыга талды. Ул, имеш, ниндидер сихерле бер дөньяда йөзә, **су дисәң, су түгел, күк дисәң, күк түгел**. Идел өстендәге вак томандай сыек та, үтә күренмәле дә бер җисем. (Флүс Латыйфи, Хыянәт.) Säyet sank into a deep and pleasant sleep such as he had never experienced before. It was as though he was floating in some mysterious world. It wasn't really water nor was it really the sky. It was some matter, thin and transparent, like a fine mist over the Volga.
   - Гайни. ... Миңа бар, сине хатынлыкка алам, ди. Биби. Соң ник бармыйсың? Алай бик яраткач, бару кирәк иде! Гайни. Барам менә! Мин аның нәрсәсенә кызыгып барыйм? **Акчасы дисәң, акчасы юк, кыяфәте дисәң, кыяфәте юк**. Бигрәк сөйкемсез нәрсә. Мин аның белән йөрсәм дә, акчасы өчен генә йөрдем. (Галиәсгар Камал, Бәхетсез егет.) Gheyni. ... Marry me, I'll take you as my wife, he says. Bibi. So, why don't you marry him? Since you love him so very much, you ought to marry him! Gheyni. Me, marry him! What does he have that I should care for him and marry him? As for money, he has no money, and as for looks, he is not good looking. He is a very unpleasant fellow. If I was going with him, it was only for his money. (The young man used to have plenty of money, taking it from his father's cash register. But his father had put a stop to that.)
   - Акрынлап атлыйбыз, кара күләгәләр дә якынлаша. **Ат дисәң, атлы түгел, кеше дисәң, кешегә дә охшамаган**. (Аяз Гыйләҗев, Язгы кәрваннар.) We march slowly. The dark shadows too come nearer. They aren't horses and riders nor do they resemble people.

d) Used like a particle, **дисәң** emphasizes the words preceding it, while contrasting them with the words following it.

- Егет әзрәк уйланып торды. – Хәзер апаңнарга бергә барсак та була! Әлфия утырган урынында сикереп алды. «Нинди кеше бу, ә? Ябышкак сагыз, **дисәң**, йөзе ягымлы!» (Әнәс Галиев, Авылдашлар.) The young man thought for a little while. “Now (i.e., Now that we have introduced ourselves to one another) we can go together to your (older) sister (and family)!” Älfiä jumped up at the place where she was sitting. “Just what kind of a person was this? He sticks to one like sticky pitch, but his face is likable (attractive)!” (Älfiä thought).

*Note:* Älfiä is on her way from a village to her older sister in Kazan. The young man has attached himself to her even before boarding the train and stays with her also after their arrival in Kazan.

**[1018]** The *negative* of дисәң – димәсәң – may be used in an emphatic answer to express the speaker’s rebuke, rejection of, disagreement with his (her) interlocutor’s statement, remark, assumption, etc.

Though used in its negative form, димәсәң has then an affirmative meaning.

- – Әгәр дә мәгәр ирегездән бүген китәм дисез икән, ике дә уйламый мин Сезгә өйләнәчәкмен. ... Егетнең сүзләрендә шулкадәр ихласлык ята сыман тоелды аңа, туктап ук калды. – – Менә **тиле димәсәң тиле** инде. Беткәнме сиңа кызлар, балалы хатынга яратам **димәсәң**! (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) “If you say that you will leave your husband today, I’ll marry you without thinking twice.” ... To her it seemed that there was such a sincerity in the young man’s words that she even stopped (walking). “Now, aren’t you crazy. Don’t you have enough girls that you say to a woman who has a child that you love her!”

*Note:* A similar construction is possible also with other verbs in the conditional mood. For example: – Инде хәзинә артыннан йөрмиләр дисәң, бу сазлы урманнарда аларга ни калган? – Бәлки дару үләннәре җыялардыр? – дип карады Сорокин. Рәхмәтулла кулын гына селкеде. – Бу җәһәннәм сазлыгына **кермәсәләр**, бүтән урын беткәнме аларга? (Якуб Зәнкиев, Иртеш таңнары.) “Now, if you think (say) that they aren’t after the treasure, what else remains there for them (to do) in this swampy forest?” “Perhaps they are gathering medicinal herbs?” Sorokin ventured. “Aren’t there enough other places for them that they have to go into this infernal swamp?”

**[1019]** a) The conditional of **дию** in the *first person* can express various emotions such as an *unrealizable desire, grief.*

   · – Апагыз кайсы урамда тора? – Әй, беренче тапкыр баруым, кайсы урамда **икәннәрен** белеп тә бетермим. (Әнәс Галиев, Авылдашлар.) "On which street does your (older) sister live?" "Oh, this is the first time I'm going (to see her). I don't know exactly on which street they are."
   · Жуков. Сез, әлбәттә, өстегезгә зур җаваплы эш **алганыгызны** ачык аңлыйсыз булыр. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Zhukov. Of course, you probably realize that you have taken upon yourselves a big, responsible task.

d) The agent is in the *nominative;* the participle takes the *respective possessive suffix.*
   Хөсәен **ишек ачылганын** көтте. (Атилла Расих, Ямашев.) Khösäyen waited for the door to open (the opening of the door).
   · – Шифоньер ишекләрен соңгы мәртәбә **кем ачканын**, **кем япканын** әйтегез. (Мәгъсүм Насыйбуллин, Ярканат.) "Tell us who last opened and who last closed the doors of the chiffonier."
   · – Нәрсә турында **сүз барганын** аңламыйм! (Зөфәр Фәтхетдинов, Ачылган серләр.) "I don't understand what you are talking about (lit., about what the word is going)."

e) The agent is in the *nominative;* the participle does *not* take a possessive suffix.
   · Бәдрелхәят. Хәзер барып әйт **мин кайтканны**, бүген безгә килсен, ди. (Сәгыйть Рәмиев, Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!) Bädrelkhäyat. "Go now and tell him that I have returned, that he shall come to us today," she says.
   · Шамил. Нәрсә сөйләдең? Әкълимә. Барын да. ... **Ләйсән кергәнне, сөйләгәннәрне**, барын да. (Рәисә Ишморатова, Яшьлек канат җәйгәндә.) Shamil. What did you tell? Äqlimä. Everything. ... That Leysän came in, what she said, everything.
   · Сәфәргали боларның барысы турында да бик ныгытып уйлады. Аннары **үзе уйлаганнарны** өйгә – эти-әнисенә хат итеп язды. (Фатих Хөсни, Җәяүле кеше сукмагы.) Säfärghäli thought about all that very thoroughly. Then he wrote (down) what he thought in a letter to his parents back home.

f) The participle does *not* take a possessive suffix; the agent is *not* expressed but is known from the context. In this case, the participle always refers to the agent, who can appear in any person.

- – Кара аны! Әгәр яхшылык белән **әйткәнне** тыңламасаң, бу эшләр синең үзең өчен яхшы булмас! (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) “Look here! If you don’t heed (lit., listen) what I am telling you in kindness, these things will not turn out well (lit., be good) for you!”
- Тәрәзә алдына яткан сары эт, зур һәм кара күзләрен сөзеп, **килгәнне** каршы ала, **киткәнне** моңлы күзләре белән озата иде. (Шәриф Камал, Буранда.) The yellow dog, which had lain down before the window, fixing its big, black eyes upon them, received those who came in and followed those who left with his doleful eyes.

**[1055]** The participle is in the *locative.*
The past participle in the locative indicates:

a) *Time.* The action expressed by it takes place *at the same time as,* or *follows,* that of the *principal verb.* The participle does *not* take possessive suffixes.
   - **Узганда-барганда** алар бер-берсенә бүрекләрен салып сәлам бирешәләр. (Фатих Хөсни, Шәһәр читендә.) When they pass by each other, they greet each other, doffing their caps ...
   - Алар урта мәктәптә **укыганда** ук танышлар иде. (Кояш Тимбикова, Ярлар биек.) They had already been friends (lit., acquaintances) when they studied at the middle school.
   - Базарлыга җитәргә бер километр җир чамасы **калганда**, безгә Низамый очрады. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) When there was about one kilometer left to (the village of) Bazarly, we met Nizami.
   - Без авылга **кергәндә** кояш баткан иде инде. (ibid.) When we entered the village, the sun had already set.
   - Йөрәгең үзеңә дә сиздермәстән аның йөрәге белән кушыла. Ул **куанганда** куанасы, ул **көлгәндә** көләсе килә. Ул **боекканда** боегасы, ул **елаганда** аның белән бергә елыйсы килә. (ibid.) Without noticing it, your heart unites with her (i.e., the actress’) heart. When she rejoices, you want to rejoice, when she laughs, you want to laugh. When she is despondent, you want to be despondent, when she cries, you want to cry with her. (For the form -асы килә see 1143.)

b) A *condition.* (See 1000, 2.)

c) The past participle is in the locative when governed by a verb requiring this case.
   - Хәзер мин яшь **татарның** берәр интеллигент **икәнендә** бер дә **шөбһә итмим**. (Фатих Әмирхан, Танымаганлыктан таныштык.) Now I have no doubt at all (I do not doubt at all) that the young Tatar is some intellectual or other.

d) Some past participles in the locative have become fixed phrases, others are used as adverbs.
   - **Дөресен әйткәндә**, Хәдичәне аптыратып калдырганы Котбыйның өйләнүе түгел ... (Фатих Хөсни, Шәһәр читендә.) To tell the truth, what leaves Khädichä embarrassed is not Qotbi’s getting married ...
   - Бер **караганда** язгы боз кисәкләренә, бер **караганда** тауларга яки дулкыннарга охшыйлар иде ул бизәкләр. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) Looking at them one way, those (ice) patterns (on the window) resembled pieces of ice in spring, looking at them another way, they resembled mountains or waves.
   - Мин дә, Гаязның бу фикеренә нидер өстәргә дип авызымны ачкан идем, **көтелмәгәндә** яныбызга килеп чыккан Имәли бүлдерде. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) I was just about (lit., I had just opened my mouth) to add something to this thought of Ghayaz’, when Imäli, who had unexpectedly (suddenly) sidled up to us, interrupted me.

· Сүз шушы җирдә тукталып калды: аларны **көтмәгәндә** йөк машинасы куып җитте. (Әбрар Шәмин, Күңел күзе.) The conversation stopped here because a truck suddenly (unexpectedly) caught up with them.

**[1056]** The participle is in the *ablative.*
The ablative of the past participle indicates:

a) *Cause, reason.*

· – Бер көн **эшләмәгәннән** без дә үлмәбез, ... (Фатих Хөсни, Җәяүле кеше сукмагы.) "We won't die because we don't work (from not working) one day, ..."

· Зөбәйдә ни әйтергә **белмәгәннән** кесәсеннән чыгарып бер кәгазь карый. (Сәгыйть Рәмиев, Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!) Not knowing (As she doesn't know) what to say, Zöbeydä looks at some paper she pulls from her pocket.

b) *Comparison of action.* To express comparison of action, the following constructions are used: 1) The ablative of the *affirmative* past participle is followed by the *negative possessive form* of the same participle (килгәннән килмәгәне); 2) The ablative of the *negative* past participle is followed by the *affirmative possessive form* of the same participle (әйтмәгәннән әйткәне). The agent may be expressed by a noun or pronoun, or by the possessive form of the participle alone.

· – Солтан, тыңла мине. ... Хатын-кыз алдында әйтеп тормадым, **аларның белгәннән белмәгәне** әйбәтрәк. (Гариф Ахунов, Идел кызы.) "Soltan, listen to me. ... I didn't say it in front of the women; for them it's better not to know."

· – Күрдеңме соң, бездә кунак бар. – Күрдем, – диде Габделхәй, ... Күңеленнән уйлап куйды: «Андый кунакны **күргәнеңнән күрмәгәнең** артык.» (Нурихан Фәттах, Кичү.) "Did you see, we have a guest." "I saw her," Gäbdelkhey said. To himself he thought: "It's better not to see such guests."

– **Әйтмәгәннән әйткәне** яхшырак, хәзер кем белән эш иткәнебезне яхшы беләбез. "It is better that he said it; now we know very well with whom we are dealing."

*Comparison of action* is also expressed by the past participle plus **+дагы**, **+дәге** and the ablative case.

· Шуның өчен дә иң элек күрүдә ул Мохтарга **көткәндәгедән** бик күп түбән тәэсир бирде. (Шәриф Камал, Таң атканда.) Therefore, at first sight, he made a much worse (lit., lower) impression on Mokhtar than (he had) expected.

c) The *ablative* of the past participle followed by a *conjugated form of the same verb,* or by the *verbal adverb* in **-а**, **-ә**, etc. of the *same verb* and the auxiliary verb **бару** (1328 a), indicates that the action *continues to intensify.* The time is determined by the conjugated verb or by **бару**, respectively. In writing, the participle is connected with the conjugated verb or with the verbal adverb, by a hyphen.

· Мәҗлес **җанланганнан-җанланды**. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) The party became more and more animated.

· Ул чын-чынлап хәзер Гаязның язмышы өчен куркына, һәм аның өмете **кимегәннән-кими иде**. (Атилла Расих, Бәхет орлыклары.) Now she was really fearing for Ghayaz's life (lit., fate), and she lost hope more and more.

· Кыз **ачылганнан-ачыла**, үзенең иптәш кызлары турында сөйли. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) The girl opens up more and more; she talks about her girl friends.

· Кичтән сибәләп кенә ява башлаган яңгыр **көчәйгәннән-көчәйде** һәм иртәнгә кадәр туктамады. (Таһир Таһиров, Галия.) The rain, which had begun to fall in a drizzle in the evening, grew gradually stronger and did not stop until the morning.

· Ике гаилә дуслыгы **якынайганнан-якыная барды**. (Рафаил Төхфәтуллин, Чатта тукталу.) The friendship between the two families grew closer and closer (grew constantly closer).

- Яшен **ешайганнан-ешая барып**, тышта яңгыр **көчәйгәннән-көчәя** иде. (Мирсәй Әмир, Безнең авыл кешесе.) The lightning became more and more frequent, and outside the rain grew constantly stronger.

d) The past participle in the *ablative*, following the verbal adverb in **-а**, **-ә**, etc. *of the same verb* (in writing connected by a hyphen), indicates that the action of the principal verb begins *immediately after the completion* of the action expressed by the participle and verbal adverb. The construction may or may not be followed by the postposition **бирле**.
- **Килә-килгәннән**, буякларны **күрә-күргәннән** аның күңелендә бер хыял баш калкытып тора иде. (Фатих Хөсни, Мәйдан.) From the very moment he had come here, and from the very moment he had seen these grounds, a dream had been taking shape in his heart.
- Кәүсәрия. **Килә-килгәннән бирле** миңа бәйләнәсез. (Сәет Шәкүров, Мәхәббәт газабы.) Käwsäriä. Ever since you arrived, you have been (lit., are) picking on me.
- Рәфкать – үзебезне **белә-белгәннән бирле** минем дус. (Аяз Гыйләҗев, Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәя.) Räfqät has been my friend (lit., is my friend) ever since we have known each other.

e) The past participle in the *ablative* forms adverbs.
- Бу кадәрле тынлык **уйламаганнан** гына ишек янында ишетелгән тупас тавышлар тарафыннан җимерелде. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) This deep (lit.: precious) silence was unexpectedly broken by harsh voices heard at the door.

## The Past Participle in -тан, -тән, -кан, -кән with Postpositions

A past participle in -тан, -тән, -кан, -кән governed by a postposition appears in the *case required by the latter.*

**[1057]** A participle followed by the postposition **кебек**, **шикелле**, **сыман**, **сымак**, **төсле**, or **караганда** expresses *comparison* of the action expressed by the participle with that denoted by the predicate verb.
- Ул минем белән олы кешеләр белән **сөйләшкән кебек** сөйләшә. (Давыт Юлтый, Төн.) He talks with me as he does with adults (as if talking with adults).
- Рәхимов. Биш ел бергә эшлибез. ... Сезгә үземә **ышанган кебек** ышанам. (Риза Ишморат, Ватан.) Räkhimov. We have worked together for five years. ... I have faith in you as I have in myself.
- Нурия аның, беренче лекциясен **аңламаган кебек**, бүгенге лекциясен дә аңламады, ... (Гариф Ахунов, Идел кызы.) Just as she hadn't understood his first lecture, Nuriä didn't understand his lecture today either.
- Ул безнең белән **исәнләшмәгән кебек**, без дә аның белән исәнләшергә кыймадык. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) As she had not said hello to us, we too did not dare to say hello to her.
- Бу дөньядагы бернәрсә дә озакка **сузылмаган шикелле**, Зәйнуллинның да тормышындагы зур шатлык көннәре озакка бармады, әлбәттә. (Садри Җәләл, Журналист.) Just as there is nothing in this world that lasts long, the days of great joy in Zeynullin's life too did not continue for long, of course.
- Калмурзин, «Син ничек карыйсың моңа?» **дигән шикелле**, Хәкимовка текәлде. (Мөхәммәт Шәйми, Сынау.) Qalmurzin looked straight at Khäkimov as if saying: "How do you regard this?"

- Хәкимов аңа сынаулы караш ташлап, «Икеләнерме, әллә тәвәккәллек күрсәтерме» **дигән сыман**, Калмурзинга текәлде. (ibid.) Throwing him a searching glance, Khäkimov looked straight at Qalmurzin as if saying: "Will he hesitate, or will he show courage?"
- Сания ... Үзалдына **сөйләнгән сыман**, акрын гына тавыш белән сорау бирде: ... (Мирсәй Әмир, Саф Күңел.) Saniä ... as if talking to herself, asked in a low voice: ...
- Рахманов безнең сүзләргә артык әһәмият **бирмәгән сыман** тыңлый иде. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Räkhmanov was listening as if he did not attach too much importance to our words.

*Note:* The suffix **+дай**, joined to the postposition **сыман**, indicates that the action expressed by the participle is carried out in a hardly noticeable degree. For example: Мин дә **елмайган сымандай** итеп куйдым. (Шәйхи Маннур, Чын сөю бармы?) I too gave a faint smile.

- Ул минем уйларымны **аңлаган төсле** шаян караш ташлап алды. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) As if she had understood my thoughts, she threw me a mischievous glance.
- Ай һаман да миңа нәрсә булса **уйлаган**, нәрсә турындадыр **кайгырган төсле**, күңелсез, салкын карый. (Садри Җәләл, Инде мин аңа рәнҗемим.) The moon still looks at me sadly, coldly, as if thinking something, as if worrying about something.
- Ул көнне таң без **көткәнгә караганда** тизрәк атты. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) That day it dawned earlier than we had expected.

**[1058]** A past participle, followed by the postposition **кебек**, **шикелле**, **сыман**, **сымак**, or **төсле** and **булу**, expresses *assumption, imagination*, with a connotation of *comparing* the *result* of an action.

- Зәйтүнәнең өстеннән тау **төшкән кебек булды**, Гөлсем апасы яныннан җиңеләеп чыгып китте, ... (Әнәс Галиев, Авылдашлар.) It was as if a heavy load (lit., a mountain) had been taken off Zeytünä, and she came away from her sister Gölsem much relieved, ...
- Йөрәгем бөтенләй тибүдән **туктаган кебек булды**. (Мирсәй Әмир, Кысыр хәсрәт.) It was as if my heart had completely stopped beating.
- Биредән караганда, бу ниндидер шаулап торган базар шикелле иде. Тик алар арасында бу юлы минем әнием, үги әтием генә юк. Әйе, алар юк. Ә күңелемдә кичә генә **күргән шикелле булып торалар**. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) Looking at it from here, this was like some kind of a bustling (lit., buzzing) marketplace. Only this time, my mom and my stepfather were not among them (i.e., among the people). Yes, they were not there (i.e., they were no longer with me). But they dwelled in my heart as if I had seen them only yesterday.

**[1059]** The past participle with **кебек**, **сыман**, **сымак**, **төсле** or **шикелле** and followed by **итү** expresses *assumption, surmise, imagination, comparison.* Furthermore, it may indicate *pretense.*

The construction with **итү** is a narrative form (i.e., it indicates the process, course of an action.)

- Без **ышанган сыман кебек иттек**, әмма Габдерәкыйб монда бер алдау сизде. (Мөхәммәт Мәһдиев, Торналар төшкән җирдә.) We acted as if we really did believe him, but Ghabderäqib sensed here some deceit (lie).
- Әмирҗан, «эш барып чыга, дускай» **дигән төсле итеп**, Чуркинга күз кысып елмаеп куйды. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) Ämirjan winked at Churkin and gave a smile as if saying: "Things are going to work out, my friend."

- – Качмас, качмас. Акыллы малай ул. Тагын биредән элдерсә, үзенә үпкәләсен. Андыйларга бездә башка урыннар да бар, – дип Дуняша апа Барласка **ачуланган төсле итте**, ә үзе елмая иде. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) “He won’t run away, he won’t run away. He’s a smart boy. If he takes off from here again, he will have himself to blame. For such (boys) we have other places too,” Dunyasha said (acting) as though she were angry at Barlas, but she was smiling.

*Note.* Barlas, who had been living on the city streets, has been caught by the police and is about to be sent to an orphanage, the same orphanage from which he had escaped.

- ... андый нечкә, ябык хатыннар бик җитез булалар. Йөргәндә дә **очкан шикелле итәләр**. (ibid.) ... such frail, slim women are (can be) very agile. Even when walking they seem to fly.

**[1060]** The past participle in its *affirmative form* followed by **кебек тә** and repeated in its *negative form* likewise followed by **кебек тә**, expresses the idea that the subject does not perform the action *fully* or *completely*, implying lack of *attention, interest* on his part, varying with the context.

For example: Ул **эшләгән кебек тә, эшләмәгән кебек тә**, күренә. He seems to work only half-heartedly.

In some instances another verb which is lexically synonymous may substitute for repetition.

- Галимә апа, боларның сүзләрен **тыңлаган кебек тә**, бер дә **колак та салмаган кебек тә**, тик утыра ... (Мәҗит Гафури, Кара йөзләр.) (My) sister Ghalimä is sitting motionless, (seemingly) listening only with half an ear to their talk, ...

**[1061]** The past participle with **вакытта** (**вакытында**), **чакта** (**чагында**), **арада**, or **аралаш** indicates the *time* when the action denoted by the principal verb is carried out.

- **Кайткан вакытта** без, бөтенләй диярлек, сөйләшмәдек. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) When we returned we almost didn’t talk at all.
- Узе турында, үзенең үткәне турында сөйлисе килми иде аның. **Укыган вакытында** күргән кечкенә вакыйгалар ... турында күбрәк сөйли иде ул. (ibid.) She didn’t want to talk about herself, about her past. She talked more about some little events ... she had experienced when she was studying.
- Фәтхи кич белән, утлар **алындырган чакта** Кигәвенледә узенең абзасы Ишмай картка килеп төште. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) Fätkhi arrived at her uncle’s, the old Ishmai ... in Kigänwenle in the evening when the lights had been put on.
- Юлда **барган чагында** Гарәпша үзенең монда алган тәэсирләрен эткәсенә әйтеп бирде. (ibid.) While they were walking along the road, Ghäräpsha described to his father the impressions he had received here.
- Ул Чаллыда ... барасы җирләренә барып **йөргән арада** торактагы иптәшләре дә эштән кайтыр, ... (Атилла Расих, Сынау.) While he is ... going to the places he has to go to in Chelny, his roommates will return from work, ...
- Ныгытып **ашаган аралаш** Нәгыйм дә сүзгә катнашырга тиеш тапты. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) While having a good meal, Näghim too deemed it necessary to join in the conversation.

**[1062]** The past participle with **саен** indicates *repetition* or *degree* of action.

- **Килгән саен**, безне бу өйдә бик теләп, куанып каршы алалар. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) Each time we come, they receive us in this house with great pleasure and joy.

- Әйе, мин **кайткан саен**, Хәмит белән очрашмыйча китми идем. (ibid.) Yes, each time I came back, I did not leave without meeting Khämit.
- Көннәр **узган саен**, ул миңа дошман була бара. Инде аның миннән качып китүендә әз генә дә шөбһә итмим. (Садри Җәләл, Инде мин аңа рәнҗемим.) As the days passed by, he gradually became an enemy to me. I no longer doubted even a bit that he left to escape from me.
- Эчкәрәк **кергән саен** урман куера, юл караңгылана барды. (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) The deeper he went into the forest the denser it became, and the darker the path became.
- Алар чыннан да бик матур. **Караган саен** карыйсы килә ул кечкенә чәчәкләргә. (Батулла, Юл буенда зәңгәр чәчәк.) They are really very beautiful. The more you look at those little flowers the more you want to look at them.
- Ару-талуның нәрсә икәнен тәмам онытты ул. **Эшләгән саен** эшлисе килә иде. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) He completely forgot what weariness was. The more he worked the more he wanted to work.

**[1063]** *Degree* of action is also expressed by **торган саен**.

- Ә Мөршидә апаның җырлары **торган саен** ешрак ишетелә башлады. (Нәбирә Гыйматдинова, Ханым-солтаным.) And Mörshidä's songs were heard more and more often.

*Note:* The use of the word **апа** indicates here that the speaker is younger than the person referred to.

- Фәез аларны **торган саен** ныграк кызгана барды һәм, ничектер, ярдәм итәсе килде. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) Fäyez pitied them more and more and wanted to help them in some way.

**[1064]** The past participle with **соң** indicates that the action expressed by the principal verb takes place after the completion of the action denoted by the participle.

- Бераз коры җир белән **барганнан соң**, бер бик куе урманга барып җиттеләр. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) After walking a little while over arid (dry) land, they came to a very dense forest.
- Атна чамасы икеләнеп **йөргәннән соң**, Фәез Борисның эшләгән җиренә шалтыраткан иде, һаман авырый диделәр. (Әхсән Баянов, Ут һәм су.) After hesitating for about a week, Fäyez called the place where Boris worked. They said that he was still ill.

**[1065]** The past participle with **күрә** or **өчен** indicates the *reason for*, the *cause of*, the action expressed by the principal verb.

- Разия үзе аз сүзле **булганга күрә**, күбрәк миңа сөйләп йөрергә туры килә иде. (Фатих Әмирхан, Танымаганлыктан таныштык.) Because Razia herself was taciturn, I had to talk more.
- Авыл төрле ягыннан эре-эре усак, өянке агачлары белән уратылып **алынганга күрә**, аның мәчете дә ерактан күренә алмый икән. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) As the village was surrounded on several sides by very big aspens and willows, we found that its mosque could not be seen from afar.
- – Каршы алырга **килгәнең өчен** рәхмәт, ... (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) "Thanks for having come to meet me, ..."

**[1066]** The past participle with **бирле** indicates that the action expressed by the principal verb continues from the time when the action of the participle was completed.

- Афзал **киткәннән бирле** авылында бернәрсә дә үзгәрмәгән булып чыкты. It turned out that nothing had changed in his village since Afzal had departed.
- Кыш **башланганнан бирле** мондый буран булганы юк иде әле. (Мөхәммәт Шәйми, Сынау.) Since the winter began, there hadn't yet been (hadn't yet taken place, happened) such a snowstorm.
- Сабан ашлыгы чәчелгәнчегә хәтле дә рәтле яңгыр булмады. **Чәчелгәннән бирле** дә булганы юк. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Before the spring crops were sown, there wasn't a good rain either. Nor was there any from (the time) the sowing had been done.

**[1067]** The past participle in the *nominative* followed by **кадәр**, **хәтле**, **чаклы** or **тикле** indicates the *degree* to which the action of the principal verb is carried out. The past participle in the *dative* with the same postpositions denotes the *time up to which* the action of the principal verb continues.

- Ничек газап чигеп килгәнебезне үзегез белеп торасыз. Булдыра **алган хәтле** эшләдем, ... (Фатих Хөсни, Мәшәкатьле озын сәфәр.) You yourself know what we have endured. I have worked as much as I could, ...
- **Тырышкан чаклы** тырыштым. (Мирсәй Әмир, Кысыр хәсрәт.) I tried as much as I could.
- – ... әгәр минем кирәгем чыкса, тартынмагыз, чакырыгыз, көчемнән **килгән кадәр** булышырмын. (Гариф Ахунов, Хуҗалар.) "... if you need me, don't hesitate, call me. I'll help you to the best of my ability."
- Капитан ... күперчек өстендә әрле-бирле йөри. ... Ул томан **таралганга кадәр** шушында булачак. (Рафаэль Мостафин, «Оҗмах»ка сәяхәт.) The captain ... walks to and fro on the bridge. ... That's where he will be until the fog lifts.

**[1068]** The past participle with the suffix **+дагы**, **+дәге** and the postposition **кебек**, **шикелле**, **сыман**, **сымак**, **төсле**, or **караганда** indicates *comparison* of the action denoted by the principal verb with the action expressed by the participle as it took or takes place once or habitually at some point in past or present (extended present) time.

- Барыннан да элек өс-башы күзгә ташланды. Клубка **баргандагы кебек** киенгән! Мин беренче мәртәбә **күргәндәге кебек**. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) First of all, her clothes struck the eye. She was dressed like the time she went to the club! Like I had seen her the first time.
- Зәки. Әни, син инде яхшырак, матуррак итеп киен. Кунакка **баргандагы кебек**. (Риза Ишморат, Ил өчен.) Zäki. Mother, come on, dress better, prettier. Like you do when you go visiting someone.
- ... ишек ачылып китте. Кабинетка **кергәндәге шикелле** үк, башын югары тотып, Бабайкин килеп чыкты. (Мирсәй Әмир, Ялантау кешеләре.) ... the door suddenly opened. Out came Babaikin, carrying his head high, just as he had when he entered the office.
- Нурия Свияжскига барырга чыкты. Беренче **баргандагы төсле** алтын-сары көз түгел иде. Агачлар ялангач иде. (Гариф Ахунов, Идел кызы.) Nuriä set out to go to Sviyazhski. It was not a golden-yellow autumn as it had been when she went the first time. The trees were bare.
- Карт, идарәгә **кергәндәгегә караганда**, гәүдәсен турайтыбрак чыгып китте. (Мөхәммәт Мәһдиев, Мәңгелек яз.) The old man left the administration (office), holding himself up a bit straighter than (at the time) when he had entered it.

## The past participle with хәлдә (дә), уңайга (уңаеннан, уңайда), килеш, көйгә, көе, көенә, көенчә, рәвештә, рәвешле, тәкъдирдә (дә), сурәттә, дәрәҗәдә

**[1069]** The past participle with **хәлдә** expresses:

a) The *manner* in which the action expressed by the principal verb is performed.

- Габдулла туктады һәм, баскычның тоткасына **тотынган хәлдә**, артына борылып карады. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) Ghabdulla stopped and, holding on to the banister, turned around and looked.
- Газдал күзен Руфинәгә **төбәгән хәлдә** аңа гына мөрәҗәгать итте, әйтерсең, хатыны белән малае юк иде. (Фоат Садриев, Адәм әүлиясе.) Looking intently at Rufinä, Ghazdal addressed only her, as though his wife and boy were not present.

**Хәл** or the past participle may take a possessive suffix:

- Мин бераз **тынычланган хәлемдә** урамга чыгам ... (Габдрахман Минский, Язгы уяну.) Somewhat calmed down, I go out into the street.
- Нигә, нигә килмәде соң Мәликә?! Шул турыда уйлап, никадәр генә уйласам да, уйларыма җавап таба алмыйча, ачуымнан караватыма **сузылганым хәлдә**, күзләремне түшәмгә төбәп, уйлап ятам. (ibid.) Why, just why did Mälikä not come? I am thinking about that, but, no matter how hard (lit., much) I think, I am unable to find an answer to my thoughts. Stretched out on my bed in anger and fixing my eyes at the ceiling, I keep thinking.

b) A *condition.*

- Багатырны бер нәрсә борчый иде: «сәүдәгәрләр» кирмәнгә керә алдылар микән? **Кергән хәлдә** Чалбай хан ничегрәк каршы алды икән үзләрен? (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кубрат хан.) One thing bothered the Bagatyr (Bahadur): had the "merchants" been able to enter the fortress? If they had entered, how might Khan Chalbai have received them? (Багатыр 'a hero', 'a warrior'; here: title of a high-ranking military leader.)

c) A *concession.* **Хәлдә** is mostly followed by **дә** – **хәлдә дә**.

- Ул сәүдәгәр, укый-яза белмәүче надан кеше **булганы хәлдә**, кемнән күпме аласы барлыгын энәсеннән-җебенә, тиененнән-тиененә кадәр белеп торган, ди. (Мирсәй Әмир, Ялантау кешеләре.) They say that, although he was an illiterate man, that merchant knew in detail and down to a penny (kopeck) who owed him how much.
- – Мин аңлыйм, – диде профессор. – Лекин **аңлаган хәлдә дә** сезгә шуны әйтергә тиеш булам. (Атилла Расих, Ике буйдак.) "I understand," the professor said. "But although I understand, I must tell you this."

**[1070]** The participle with **уңайга** indicates:

a) The simultaneous execution of the actions expressed by the participle and the principal verb.

- ... чаттан борылуга, Бакый ерактан ук Зариманы искәреп алды. Озын күлмәк итәге **атлаган уңайга** җилферди. (Марсель Галиев, Ерак урман авазы.) ... upon turning around the corner, Baqi, even at a distance, (could) make Zarima out. Her long dress fluttered (lit., flutters) as she walked (walks).
- ... арыштан **барган уңайга** Кәбир башак сындырып алды да, шунда ук авызына кабып, чәйни башлады. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) ... while walking through the rye, Käbir tore off an ear and, immediately putting it into his mouth, began to chew.

- Тирә-юньне күзәтеп, үз алдына уйланып **барган уңайга** йокыга киткәнен сизми дә калган ул. (ibid.) While watching the environs and thinking to himself, he had fallen asleep without noticing it.

b) In most cases with verbs of motion, the *simultaneous execution* of the action of the participle and the principal verb, *both actions* expressing movement *in the same direction.*
   - Ул инде аякларында тора алмый, боз **аккан уңайга** колачлап йөзә, ... (Кояш Тимбикова, Тәңкәле тау.) She can no longer stand on her feet. In crawl style she swims in the direction in which the ice is floating ...
   - ... арттан йөгергәләгән Кәбир, аруын арымаса да, инәсенең тәкъдименә каршы килмәде – башын **барган уңайга** куеп, печәнгә сузылып ятты һәм ... бер-бер артлы ачылган манзараларны күзәтеп бара башлады. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) ... although Käbir, who from time to time ran behind (i.e., behind the horse-drawn wagon to get some exercise), was by no means tired, he did not resist his mother's suggestion (i.e., to get on the wagon). Putting his head in the direction in which they were traveling, he stretched out on the hay and began to watch the views which offered themselves (lit., opened up) one after the other, ... (инә – dialect: әни).

c) The beginning of the action expressed by the principal verb *immediately* after the action of the participle has been completed.
   - Бүген дә килеп **кергән уңайга** пальтосын салып атты, ... чалбар кесәсеннән зур яулык өстерәп чыгарып, итләч битләрен сөртте ... (Мөхәммәт Шәйми, Сынау.) Today too, as soon as he arrived (at the office), he threw off his overcoat, pulled a large handkerchief from his trouser pocket and wiped his fleshy cheeks ...
   - Староста **әйткән уңайга** ук, без унлап малай чабышып чыктык та, батырлар шикелле, кулларны тезгә куеп, чүгәләшеп утырдык. (Мөхәммәт Гали, Сабан туенда.) The moment the village elder told us, we, about ten boys, ran out and, like wrestlers (lit., braves, fighting men), squatted down, our hands on our knees. (Староста – R.; a village elder in Czarist Russia.)

*Note:* Actions performed or taking place as discussed under a) and c) may also be expressed by **-ган**, **-гән**, etc. + **уңаеннан** and **-ган**, **-гән**, etc. + **уңайда**, respectively.

For example:

- Юл читендәге ат күмелерлек юан сабаклы һәм эре яфраклы үләннәрне Бамбук **барган уңаеннан** умырып алырга өлгерә. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) As she walks, Bambuk manages to tear off the thick, broad blades of grass growing at the edges of the road to a height as to cover a horse. (Bambuk – name of a mare.)
- Уң якта һич **көтелмәгән уңайда**, нидер дөпелдәп китте. (Гомәр Бәширов, Сиваш.) All of a sudden (lit., completely unexpected), on the right hand side, something made a muffled sound.

**[1071]** The past participle with **көйгә**, **көе**, **көенә**, **көенчә** forms:

a) *Concessive* clauses.
   - Язу-сызу **белмәгән көенә**, Сәфәргалиләренең шул дәрәҗәгә менүенә карт та, карчык та бик шатланалар. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) The old man and his wife are very glad that their (son) Säfärghäli, although illiterate, has risen to such a rank.

b) *Participial phrases;* both the action expressed by the participle and that of the principal verb take place *at the sime time.*
   - Дамир унынчыны **эшләгән көйгә** кичке мәктәптә тәмамлады. (Эдуард Касыймов, Гомер ике килми.) Damir finished the tenth grade in an evening school while working.

- Керсәм, Лиза песиен **кочаклаган көйгә** минем каршыма килеп баса, ... (Фатих Хөсни, Солдат хикәясе.) When I enter, Liza, cuddling her cat, steps up to me, ...
- Газизә байтак вакыт, ишек яңагына **сөялгән көе**, китеп баручылар артыннан карап торды. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) For a long time, Ghäzizä, leaning against the doorpost, gazed after the departing men.

c) *Adverbial phrases.*

- Вера Александровна алмаларны иң элек Нәсимәдән пешертте, шуннан соң гына ашарга рөхсәт бирде. Ә Мәдинә аларны **пешмәгән көенчә** ашарга бик теләгән иде. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) Vera Aleksandrovna had Näsimä cook the apples first and only then gave permission to eat them. But Mädinä had wanted very much to eat them uncooked (i.e., in an uncooked state).

**[1072]** The past participle with **килеш** or **рәвештә**, **рәвешле** expresses *manner.*

- ... [мин] бер прелюдияне ашыкмыйча гына уйный башладым. Ул башын **игән килеш** кенә тыңлап утырды. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) ... unhurriedly, [I] began to play a prelude. He sat and listened with his head bent.
- Малай, дилбегәне **тоткан килеш**, атны юлның икенче ягына борды. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) Holding the reins, the boy turned the horse to the other side of the road.
- Иптәше аның сүзләрен **дөресләгән рәвештә** баш ишарәсе генә ясаштырып утыра иде. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) His companion sat there, nodding his head from time to time in confirmation of his (i.e., the speaker's) words.
- – Сез үзегез монда күптән эшлисезме? Ул сүзне озынга җибәрергә **теләмәгән рәвештә** генә: – Күптән түгел, мин бүген монда, иртәгә анда! (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) "Have you been working here for a long time?" In a way indicating that he didn't want to engage in lengthy conversation, he only (said): "Not for long, today I'm here, tomorrow there."
- Хафизов, исе **китмәгән рәвешле**, кәгазьне учына йомарлады да сиздерми генә кесәсенә шудырды. (Газиз Камалов, Җир җылысы.) Unperturbed, Khafizov crumpled the paper up in the palm of his hand and slipped it into his pocket without letting it be noticed.

**[1073]** The past participle with **тәкъдирдә** expresses a *condition*, with **тәкъдирдә дә** a *concession.*

- ... алмагачка үрмәләдем, **түзмәгән тәкъдирдә** сикереп төшәргә чамалап, ботакка бастым. (Гариф Гобәй, Без үскәндә.) ... I climbed up on the apple tree and, intending to jump down in case it wouldn't bear (my weight), I stepped out onto the branch.
- Балалар йортына үзе генә **алынган тәкъдирдә**, нихәтле авыр булса да, Бобиктан бөтенләй аерылып торырга риза булган иде ул. ... **Калдырган тәкъдирдә дә** кемгә һәм нинди шартлар белән калдыру мәсьәләсе ачык хәл кылынырга тиеш иде. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) If they accepted only him alone in the children's home, no matter how hard that would be, he would agree to part with Bobik for good. ... Even if they (i.e., Ghäräpsha's parents who are moving too) were to leave him behind, the question of leaving him with whom and on what condition would have to be clearly resolved. (Bobik – name of a dog.)
- Юк бит, балык **булмаган тәкъдирдә дә** алар һичнәрсә югалтмыйлар. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) Not at all, even if there are no fish (i.e., no fish to catch), they don't lose anything (i.e., they still get paid).

**[1074]** The past participle with **сурәттә** indicates the *manner* in which the action of the principal verb is carried out, or it may express a *condition.* With the particle **дә** – **сурәттә дә** – it denotes a *concession.*

· Мин ата-анамны белмим. Аларны бик шәп **киенгән сурәттә** фараз кыла идем. (Шәриф Камал, Курай тавышы.) I did not know my parents. I would imaging them as being dressed very nicely.

· – **Теләгән сурәттә** сез әле япь-яшь кызга да өйләнә аласыз. (Мәхмүт Хәсәнов, Кама таңнары.) "If you wish, you can still even marry a very young girl."

· ... Галинур бер генә кешегә дә кычкырмас ... Хәтта берәрсе ялгыш **эшләгән сурәттә дә**, ул әйтер: ... (Гариф Ахунов, Гомер юлы.) ... Ghälinur would not shout at anybody ... even if someone had acted wrongly (made a mistake), he would say: ... (He would ask the person in a polite, nice way, to check again whether he (she) hadn't made a mistake and then correct it.)

· ... ятьмәсе эләкмәгәч, ул имтиханга кереп өлгерә иде, әгәр керсә, имтиханын тапшыра **алмаган сурәттә дә** Руфинә белән танышмый иде, ... (Фоат Садриев, Адәм әүлиясе.) If her net bag had not got caught (i.e., got caught on a pocket clasp of his jeans while standing in a crowded streetcar), he would have managed to take (lit., enter) the exam, and if he had taken it and had even not been able to pass it, he would not have become acquainted with Rufinä, ... (His having become acquainted with Rufinä did not only result in his missing the Students' entrance examinations but later caused him also various other difficulties.)

**[1075]** The past participle with **дәрәҗәдә** indicates the *degree, extent* to which the action of the principal verb is carried out.

· Читкә китеп, ялгыз, үз көнемне үзем күреп, яши башладым. Һәм, әйтергә кирәк, бу ялгыз яши башлау минем өчен **көтелмәгән дәрәҗәдә** катлаулы, авыр булып чыкты. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) I went away and began to live alone, earning my living by myself. And I must say that starting a life alone turned out for me to be complicated and difficult to an unexpected degree.

## The Past Participle in -тан, -тән, -кан, -кән with бар or юк

**[1076]** The past participle in -тан, -тән, -кан, -кән with **бар** or **юк** refers to some *unspecified* time in the past. It indicates that the subject *had,* or *did not have, occasion* to perform the action expressed by the participle, and it *emphasizes, singles out* this fact. Furthermore, it indicates a witnessed action performed once or repeatedly.

Taking the auxiliary **иде** the construction forms a *pluperfect.*

*Note:* In English the form with **бар** or **юк** is most often rendered by the present perfect, that with **бар иде** or **юк иде** by the pluperfect. However, depending on the situation and context, the former may also correspond to the pluperfect and the latter to the present perfect.

The subject and the relation between it and the participle are expressed in the same way as in the form with the participle in the accusative (1054, a-f).

a) The word (noun, pronoun) denoting the agent appears in the *genitive case*; the participle takes the *respective possessive suffix.*

· Гафур. Сез мине ничек беләсез? Гариф. Беләм, хәтта бик нык беләм, Гафур абый. Сезнең мәктәптә **минем** бик күп мәртәбәләр **булганым бар**. (Кәрим Әмири, Таң

вакыты.) Ghafur. How come you know me? Gharif. I know you, I even know you very well, Uncle Ghafur. I have been in your school many times.

- Агайның тавышы миңа ничектер таныш тоелды. Бу авазларны **минем** кайдадыр **ишеткәнем бар**. Тик кайда. (Венера Касыймова, Ачы Умач.) The gentleman's voice seemed somehow familiar to me. I heard a voice with those tones somewhere (before). But where.
- Әйе, **безнең** бу агай белән кайдадыр **очрашканыбыз бар**! Бу шөбһәсез. Тик кайда һәм кайчан икәне генә хәтеремә төшми. (ibid.) Yes, this gentleman and I have met somewhere! There is no doubt about this. But I can't recall just where and when it was.
- Гөлсем. Әй, миңа нәрсәгә инде уку? Кияүгә чыккач, **кемнең укыганы бар**? (Кәрим Әмири, Печән базары.) Gölsem. Well, what need is there for me to study now? Who has (ever) studied after getting married?
- – ... **сезнең** казакъ даласында **йөргәнегез бармы**? – Юк, Салих Әфәнде, туры килгәне юк. – **Минем** дә әле **күргәнем юк**. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) "... have you traveled (have you had occasion to travel; or: have you ever traveled) in the Kazak steppe?" "No, Mister Salikh, I have not (lit., it has not occurred/happened)." "I too have not yet seen it (have not yet had occasion to see it)."
- Нәфисә. **Минем** анда беркайчан да **булганым юк**. (Риза Ишморат, Гөлзадә.) Näfisä. I have never been there (I have never had occasion to be there).
- ... **аның** бу турыда беркемгә дә **әйткәне юк**, әйтмәс тә. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) ... she hasn't (ever) told anybody about this, and she will not do so.
- Бу җырны **минем** моңа кадәр дә күп **ишеткәнем бар иде**. I had heard (had had occasion to hear) this song often before.
- «Чегәннәр табыры», – дип уйлап алды малай. Авылларыннан үтешли, йорттан-йортка кереп, фал ачкан ... чегәннәрне **күргәне бар иде аның**. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) "A Gypsy camp," the boy thought. He had seen (he had had occasion to see) gypsies moving from house to house, telling people's fortune ... while passing through their villages (i.e., his village and other villages in his area).
- Соңгы бер атна эчендә нәрсәләр генә күрмәгән-кичермәгән **малайның** бу кадәре **аптыраганы юк иде** әле. Кайдан белә Нәби абзыйсы Бамбукның исемен? (ibid.) Whatever he had seen and gone through within that last single week, the boy had never up to then been so confused. How (lit., From where) did uncle Näbi know Bambuk's name? (Бамбук – name of a horse.)
- **Аларның** елдан артык **күрешкәннәре юк иде** инде. (Барлас Камалов, Өметең өзелмәсен.) It was now already more than a year since they had seen (had had any occasion to see) each other.

b) The agent is *not* indicated by a separate word (noun, pronoun) but is expressed by the *possessive form* of the participle.

- Галия. Хәер, бәлки, әле китмичә дә калырмын. Бөтенләйгә мәсьәләне өзеп **куйганым юк** әле. (Шәриф Камал, Ут.) Ghaliä. By the way, perhaps I won't go away yet. I haven't yet dropped (given up) the matter completely.
- Рәшит. Акча бирмисеңмени? Хуҗа хатын. Биргәннәремне дә әле **кайтарганыгыз юк**. (Сәгыйть Сүнчәләй, Сәнгатьчеләр.) Räshit. You're not giving us any money, then? The landlady. You haven't even returned what (i.e., the money) I gave you yet.
- Габбас. Институтта бергә укыган егетне очраттым. Өч ел **күрешкәнебез юк иде.** Өч ел! (Аяз Гыйләҗев, Без унике кыз идек.) Ghabbas. I met a fellow with

whom I studied at the institute. We hadn't seen (hadn't had occasion to see) each other for three years. Three years!

- Сөләйман. Шулай шул, Зөбәйдә туташ. Аны мин дә беләм. Башыма **төшкәне бар**. (Сәгыйть Рәмиев, Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!) Söleyman. Yes, Miss Zöbeydä. I know that too. I have experienced it (lit., it has fallen on my head).
- Малай аны таныган иде инде. Авылда **күргәне бар иде**. (Фәүзия Бәйрәмова, Кыңгырау.) The boy had already recognized him. He had seen him in the village.

c) The agent is in the *nominative;* the participle takes the *respective possessive suffix.*

- – **Мин** аңар аз-маз бурыч биргәләп **торганым бар**. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) "I have given him small loans now and then."
- Галия. ... Рәүф белән сөйләшәсе бар. Бүген **мин** аны иртәдән бирле **күргәнем юк**. (Шәриф Камал, Ут.) Ghaliä. ... I must talk with Räüf. I haven't seen (haven't had occasion to see) him since this morning.
- Гомәр. ... **эш** аңа барып **җиткәне юк** әле, Галия ханым, ... Рәүф белән дә күрешкән юк әле. Чыгып киткән. Галия. **Ул** иртәдән бирле **кайтканы юк**. (ibid.) Ghömär. ... things haven't come to that yet, lady Ghaliä, ... I haven't seen Räüf yet either. He has gone out, it seems. Ghaliä. He hasn't come back since this morning.
- Гөлбану. **Сез** монда күптәннән **кайтканыгыз юктыр**, ахрысы. (ibid.) Gölbanu. You didn't come back here for a long time, it seems.
- **Гыйльманов** хәзергә хәтле Нәгыймәне **күргәне юк**, ләкин аның үзе һәм эшләре турында байтак нәрсәләр ишеткән иде. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) Up to now, Ghilmanov had not seen (had not had occasion to see/meet) Näghimä, but he had heard a great deal about her herself and her works (affairs, businesses).
- **Мохтар** күптән инде ... театрга **барганы юк иде**. Mokhtar had already long since ... not been (lit., gone) to the theatre.

d) The agent is denoted by a *pronoun* in the *possessive case;* the participle appears in its *basic form*, i.e., *without* a possessive suffix.

*Note:* The participle being a noun, this construction is formed along the pattern of минем өй, синең китап, etc.

- Рәшит. Алай булса, бир әле – барып аны-моны китерим. Бүген **безнең ашаган юк** әле. (Сәгыйть Сүнчәләй, Сәнгатьчеләр.) Räshit. If that's the way it is, please give (us some money) then. I'll fetch something. We haven't eaten today yet.
- Бераз сүзсез торгач, ул, миңа күтәрелеп карамыйча гына, тагын болай дип куйды: – Сугышта **булган юк**, ахры, әле **синең**? (Мирсәй Әмир, Якташ.) After being silent for a little while, and without raising his head and looking at me, he added, "You haven't seen battle yet, have you?"

e) The agent is in the *nominative;* the participle does *not* take a possessive suffix.

- Әле менә Әдирнә хакында яңа хәбәрләр дә бар. Ләкин **без** аның белән бу арада **күрешкән юк**. (Шәриф Камал, Минем таныш.) Now, there is also up-to-date news about Edirne. But during this time we haven't been seeing one another. (They used to discuss the Balkan War, especially the fight for Edirne /formerly Adrianople/. But now that there is up-to-date news about that city they cannot discuss it because they have lost contact with each other.)
- Дөньяда ләззәт була, ди, **мин** аны **күргән** дә **юк**. Хәсрәт белән үтте гомерем, **уйнаган, көлгән** дә **юк**. (Мәҗит Гафури, «Юк».) There is bliss (pleasure) in the world, they say. I haven't seen it at all. My life has passed with sorrow. I have not played, not laughed at all.
- Беләм бит, матур иттереп, килештереп язасың, язганнарыңны **без** монда, терлекчеләр йортында, кычкырып та **укыган бар**. (Кояш Тимбикова, Табылдык

хатлар сере.) I do know, you write beautifully, masterfully. We have even here, in the cattlebreeders' house (building), read your writings aloud.

f) The agent is *not* expressed; the participle does *not* take a possessive suffix. Though impersonal in form, it always refers to the acting person, who is known from the context. Furthermore, this construction may indicate an involuntary action. The participle followed by **бар** or **юк**, respectively, may refer to *present time, extended present time* (future) as well as to *past time*. Followed by **бар иде** or **юк иде**, it always refers to *past time*.

*Note:* This construction is used rather frequently, and it is most common in the *negative*.

- – Авыл кызы мин, эшне **күргән бар**! – диде. (Әнәс Галиев, Авылдашлар.) "I am a country girl, I have seen (i.e., experienced) work!" she said.
- Искәндәр. Акчага **аптыраган юк**, аллага шөкер. Менә бүген почтадан алдым. (Шәриф Камал, Ут.) Iskändär. Thank God! There is no worry about money (I don't worry about money). Here (it is) I received it today by mail.
- – Ә нигә дип син миңа тәкъдим ясамыйсың? – Ясасам да чыкмыйсың ич. – Иң элек ясап кара. Ничек җавап бирү – минем эш. ... егет уйга калып торды шунда. – Юк, – диде ул, кызның күзләренә бертын текәлеп торганнан соң. Ул хакта **уйлаган юк** әле. (Ринат Мөхәммәдиев, Кенәри – читлек кошы.) "And why then don't you propose to me?" "Even if I proposed to you, you wouldn't marry me anyway." "First try proposing. How I answer is my concern." ... the young man stood there, pondering. "No," he said, after looking straight into the girl's eyes for a little while. "I'm not thinking about that yet."
- Иптәшем дә бик сагынган (без икебез бер авылдан), үземнең дә туган-үскән җирләрне бер кайтып күрәсем килә иде. Балаларны **әйткән дә юк**. (Мирсәй Әмир, Күңелле сәяхәт.) My wife too (both of us are from the same village) was longing very much for it (i.e., to see her village). I myself too wanted to return once and see the place where I was born and raised. Not to mention the children (i.e., their children who were also eager to go).
- – Гафу ит, сине таный алмыйм, – диде. Үги әти ни әйтергә дә белми торганда әни: – Минем ирем – Хәйрулла, – диде. – Авылдашың. Үги әти сүзне үзе алып китте: – Танымассың да энем, авылда рәтләп **торган юк**. Гел читтә яшәргә туры килде. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) "Pardon me, I can't place you," he said. When (my) stepfather stood there, not knowing what to say, Mother said: "He is my husband, Kheyrulla. Your fellow villager." Then, my stepfather began to speak: "You won't know me, brother (i.e., younger brother of the mother), I have never lived regularly in the village. I always had to live in places away from it."
- Ял көннәремнең берсендә әтиләргә бардым. Себергә килгәннән бирле аларда **булган юк иде** әле. (Шәйхи Маннур, Агымсуларга карап.) On one of my vacation (rest) days, I went to (see) my parents (lit., father's). Since I came to Siberia I had not yet been (had not yet had occasion to be) with (visit, see) them.
- Җиһандар. Мин сезне бик сагындым. Рәшит. Күптән **күрешкән юк иде**. (Сәгыйть Сүнчәләй, Сәнгатьчеләр.) Jihandar. I missed you very much. Räshit. We haven't seen each other a long time.

# The Possessive Form of the Past Participle with the Third Person Singular of булу

**[1077]** The form **-ган** + *possessive suffix* and the *third person singular* of **булу** in the *past tense* I (mostly in the *negative* form) is more or less synonymous with **-ган** + *possessive suffix* and **бар** or **юк** (**иде**.) However, since **булу** may also mean 'to occur', 'to happen', 'to take place', 'to come to pass' (suggesting direct cause), the construction with **булу** often reflects these meanings, whereas the construction with **бар** or **юк** (**иде**) denotes that the subject had, or did not have, *occasion* to perform the action.

The possessive form of the past participle with **булу** in its third person singular, *past tense* II designates actions *not witnessed* by the narrator.

*Note:* Depending on the situation and context, the construction with **булу** may correspond to the past, present perfect, or pluperfect tenses in English.

- – Ходай белә, мин гаепсез. Гомеремдә кеше өлешенә кул **сузганым булмады**. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) "God knows, I am innocent. I have never ever (lit., never in my life) reached (It has never ever occurred to me to reach; I have never ever happened to reach) for someone else's property."
- – Яза алсаң дисеңме? Әдәби әсәрме? Ха-ха-ха! Шунысы кызык, бу хәл һич кенә дә минем кәефемне кырмады. ... Чөнки, төпкәрәк караганда, һич язучы булырга теләүдән әйтелмәгән иде бит ул. Һич юк! **Минем** андый ихтимал турында хәтта уйлап та **караганым булмады**. (Гомәр Бәширов, Күзге ачы җилләрдә.) "If only you could write, you say? Literary works? Ha-ha-ha!" Interesting, this situation did not at all put me in a bad mood. ... Because, looking at it more seriously, this had never been said (I had never said this) with the desire of becoming a writer. Not at all! I never had even considered (lit., It hadn't even /ever/ occurred to me to attempt to think of such a possibility.
- – Рәсиха ханым, – диде ул, яфракны сабагыннан тотып бармаклары арасында бөтереп торгач, – бүләгем булсын сезгә. ... – Моңарчы миңа **бирәүнең** дә чәчәк бүләк **иткәне булмады**. (Мәгъсүм Хуҗин, Урак өсте болытлар.) Holding the leaf by its stem and, after twirling it in his fingers, he said: "Lady Räsikha, a present to you from me." ... "Up to now, no one has (ever) given (it has never happened that anyone /ever/ gave) me flowers."
- **Кәримәнең** элек бу егетне **күргәне булмады**. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) Kärimä had not seen (had not happened to see) this young man before.
- Тугызынчыда укыганда, ял көненә дип, **Илфатның** Гамилларга Тоныксу авылына **кайтканы** еш **булды**. (Барлас Камалов, Өметең өзелмәсен.) When he was (lit., studied) in the ninth grade, Ilfat often returned (it often happened that Ilfat returned) for vacation to the Ghamil family, to the village of Tonyqsu.
- – Бу ишек күперчеккә чыгарамыни? – дип сорады Мәскәүдән килгән тикшерүче. Сорау аның кем икәнлеген ачыклады. Диңгезче түгел иде бу түрә. **Аның** моңа кадәр кораб **күргәне булмаган**, күрәсең. (Миргазиян Юныс, Европа ат сагына.) "Is this then the door to the bridge?" the inspector from Moscow asked. The question revealed who he was. This official was no seaman. Up to now, he hadn't ever seen (had never chanced to see) a ship, it seemed.
- Бу карт **бинаның** үзе салынганнан бирле ... мондый ялкынлы сузләрне **ишеткәне булмагандыр**. (Гомәр Бәширов, Күтелмәгән очрашу.) Since the time it was built this old building had probably not heard ... such fiery speeches (lit., words).

**[1078]** The possessive form of the past participle may be used with the third person singular of **булу** in the *conditional* and *imperative moods* as well as with its verbal adverb in **-гач** (1270-1281).

- Аның белән **танышканым булмаса** да, мин аңа биредәге гадәт буенча, күптәнге танышыма мөрәҗәгать иткән шикелле, иркенлек белән сүз куштым. (Мирсәй Әмир, Якташ.) Although I was not (did not happen to be) acquainted with him, I addressed him, as it was the custom here, in the familiar way (i.e., using "thou"), like addressing an old acquaintance.
- Бүген, **әйтмәгәнем булсын**, йөрәгем тынычланды. Кан басымым да рәтләнеп килә. (Афзал Шамов, Якташым.) Today, and maybe, it's bad luck to say this, my heart(beat) is regular (lit., calmed down). My blood pressure too is returning to normal.
- Сизенәм, әлеге фельетон турында сүз бара кебек. Ләкин аның газетада басылып чыкканын, чынлап та, **күргәнем булмагач**, ни дияргә белмим. (Мирсәй Әмир, Үсә төшкәч.) I sense it. The talk seems to be about the feature (article) mentioned earlier. But since I have really not seen (not had the chance to see) it published in the newspaper, I don't know what to say.

## The past participle in its basic or possessive form augmented by the suffix +ча, +чә

**[1079]** The past participle in its *basic* or *possessive form* augmented by the suffix **+ча**, **+чә** expresses *manner*. The subject is most commonly expressed by a *noun* or *pronoun.*

- Көзге **көн**, үзенә хас **булмаганча**, коры, аяз иде. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) The autumn day was uncharacteristically (unusually) dry and clear.
- Шулай да, эшләр **мин ниятләгәнчә** барып чыкмады. (Мирсәй Әмир, Күңелле сәяхәт.) However, things did not turn out the way I had intended.
- Миңнулла. ... Бар да булыр, **син дигәнчә** булыр. (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Mingnulla. ... Everything will come to pass in the way that you say.
- Сафаров. Бөтенләй **без уйлаганча** булып чыкмады бит бу. (Шәриф Камал, Габбас Галин.) Safarov. After all, this didn't turn out at all as we thought.
- – Дөрес, авылда **мин** әле генә **сөйләгәнемчә**, актыккы урында тормыйм. (Шәриф Камал, Ныклы адымнар.) "True, as I have just said, I am not the most insignificant person (lit., I am not taking the last place) in the village."
- Мостафинның, мәгълүм **булганча**, йорты бар, ... (Әмирхан Еники, Саз чәчәге.) As is known, Mostafin has a house, ...

## The past participle with the Suffix +дай, +дәй

**[1080]** The past participle with **+дай**, **+дәй**, with **+дай**, **+дәй булу** and with **+дай**, **+дәй итү**.

This form expresses *comparison.* The action indicated by the past participle (i.e., the action compared) and the action of the principal verb may be performed by the same agent or by different agents.

Depending on the tense of the principal verb, the participle with **+дай**, **+дәй** may refer to the present or the past. But if followed by **иде** as the predicate, it always refers to the past.

*Note 1:* The above form corresponds to English clauses of comparison introduced by 'as if', 'as though'.

*Note 2:* The form with **+дай**, **+дәй**, as well as the constructions **-ган+дай**, **-гән+дәй** + **булу** (see 1081) and **-ган+дай**, **-гән+дәй** plus **итү** (see 1082), are frequently used by authors of literary works to convey the actions, reactions, thoughts, feelings, modds, emotions, etc. of their literary characters.

*Note 3:* The above forms are synonymous with those of the past participle and the postpositions кебек, сыман, сымак, төсле, шикелле. (See also: З.Ф. Ураксин, Башкорт теленең синонимдәр һүзлеге, Өфө, 1966, б. 109.)

- Күп эшли Гыйниятулла Зәйнуллин һәм күп кенә таба да. Ләкин тапканы аның комга **сипкәндәй** юкка чыга бара. (Садри Җәләл, Журналист.) Ghiniätulla Zeynullin works a lot and he earns quite a lot too. But whatever he earns keeps disappearing as if poured on sand.
- Озакламый, уң ягына пәке белән **уелгандай** тигез таулар тезмәсен култыклап, Кәбирне ... Сабыр елгасы каршылаячак. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) In a little while, the river Sabyr, which ... accompanies (lit., travels hand in hand with) the mountain range to the right, which is even (straight, regular) as if carved out with a knife, will greet (meet) Käbir.
- ... әби, үз күзләренә үзе **ышанмагандай**, уң кулын каш өстенә куеп текәлде дә, аннан, инде күпер аша чыгып өлгергән Кәбирне танып, кычкырып җибәрде: – И-и балакаем! (ibid.) ... Grandmother, as if not believing her own eyes, put her right hand over her eyebrows and looked intently. Then, recognizing Käbir, who had already managed to cross the bridge, she cried out, "Oh, my dear child!"
- Абзарның ачык капкасы аша үтеп, ул шым гына Бамбук аранына якынлашты. Туктап, тыңлый башлады. ... Эчтә кемдер **мыгырдангандай** тоелды. (ibid.) Passing through the open gate of the stable, he stealthily approached Bambuk's booth. He stopped and listened (lit., began to listen) ... It seemed to him as if someone was mumbling on the inside. (Бамбук – name of a horse.)
- Кәбирнең уйларын **сизенгәндәй**, байтал утлыктан үлән чемчүеннән туктады һәм аңа таба борылды. (ibid.) As if sensing Käbir's intention (lit., thoughts), the mare stopped nibbling the grass in the manger and turned towards him.
- ... эт шунда ук кырт борылып, хуҗабикәсе каршына килеп чыкты. Ни боерасың **дигәндәй**, аның күзләренә карап койрыгын болгады. (Нурислам Хәсәнов, Ак балык.) ... the dog immediately turned back on the spot and came up to his mistress. He looked into her eyes and wagged his tail, as though saying, "What do you command?"
- Тавышы берни **булмагандай иде**. (Әхәт Мушинский, Кайту.) His voice sounded (lit., was) as if nothing had happened.
- Галиәкбәргә монда бөтенләй җиңел булып китте. Ничектер аяклар да тизрәк **йөргәндәй иде**, гәүдә дә җиңеләеп **киткәндәй**. (Атилла Расих, Сынау.) Ghäliäkbär began to feel completely at ease here. Somehow, his feet seemed (lit., were as if) to go faster, his body too seemed to become lighter (lit., was as if it became lighter).

## The past participle with +дай, дәй and булу

**[1081]** The past participle with **+дай**, **дәй** and **булу**.

This construction is most often used with **булу** in the *third person singular, past tense I.* It indicates *assumption.*[1)]

---

1) See also: Хәзерге Башкорт Теле, Өфө, Башкортостан Китап Нәшриәте, 1986, page 229, б. 4.)

The observer, speaker/writer assumes, surmises, imagines that, in a given situation, the agent acts, reacts, thinks, feels, etc., the way as expressed by the participle, or the agent himself (herself) assumes, surmises, imagines that the action to which the construction refers takes (took) place. Furthermore, the form may connote *comparison.*

The past participle with **+дай**, **дәй** and **булу** is resultative (i.e., it indicates (stresses) the *result* of an action, event, etc. rather than its course, process.)

*Note:* In English this form corresponds to such expressions as, for example, 'giving the appearance of', 'he (she, it) appears (appeared) to', 'he (she, it) seems (seemed) as if/as though', 'he (she, it) thinks (thought), (thinks/thought expressing assumption)'.

· Мондый минутларда аның күзләре ачылып алардан нур **сибелгәндәй була.** (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) At such moments her eyes open, and it seems as if light emanates from them.

· Кунакханә бүлмәсендә тыныч кына телевизор карап утырганда, Илфат Маннуров кинәт тонык гөрелте **ишеткәндәй булды**. (Барлас Камалов, Өметең өзелмәсен.) While sitting quietly in his room at the guest house and watching television, it suddenly seemed to Ilfat Mannurov as though he heard a low roar.

· Шулчак әтисенең калын тавышы туктатты аны, – Качма, улым, кил әле монда, кер, – диде ул. Күрәсең, улының такта артында торуын сизенгән булып чыга. – Яшен **суккандай булды** малайга, әмма буйсынмый чарасы юк. (Ринат Мөхәммәдиев, Сират күпере.) At that moment his father's deep voice stopped him. "Don't run away, my son, just come here, come in here," he said. It turned out that, seemingly, he had been aware that his son had been standing behind the wooden wall (lit., board). The boy appeared to be thunderstruck (lit., was as if struck by lightning). But he had no other way out, he had to obey. (Standing behind a thin wooden wall, the boy had been listening in on the conversation his father had with a visitor.)

· Кояш офыктан аерылып шактый күтәрелде, көн әз генә **җылынгандай булды**, ... (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында.) Parting with the horizon, the sun rose rather high. It (lit., The day) seemed to get just a little warmer, ...

· Анда – таулар, чиксез офык артта – дала һәм әрем исе! ... Әрем исенең бу кадәр җанга кадерле һәм ләззәтле икәнлеген гомерендә беренче тапкыр **тойгандай булды**. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) There are the mountains, and beyond the boundless horizon is the steppe and the fragrance of wormwood! ... it seemed as if for the first time in his life he had become aware (of the fact) that the wormwood's fragrance was so dear to the heart.

· Кырыкмыш тайлар муенына тагыла торган кыңгыраулар тавышы **ишетелгәндәй булды**. Малай сагайды. Юк ла, тоелган гынадыр. (ibid.) It seemed there was the sound of bells, which are (usually) attached to the neck of yearlings (foals). The boy pricked up his ears (became watchful). But no, it had only seemed like that.

· Төн урталары җитеп бара иде. Кошлар да күптән тынды. Бик еракта күк күкрәгән тавыш **ишетелгәндәй булды**. (ibid.) The time was approaching midnight. The birds had long since become quiet. There seemed to be the sound of thunder coming from the far distance.

· Дала тын вә хәвефсез иде. Тирә-юньдәге иминлек шөбһәле уйларын куып **тараткандай булды**. (Җәмит Рәхимов, Батырша.) The steppe was quiet and safe. The peace (which prevailed) in the surrounding seemed to allay his suspicion (lit., disperse his suspicious thoughts).

· Икенче көнне ул шәкертләрен иртәрәк таратты. Үзе исә өйлә намазыннан соң юкка чыкты. Аның кая китеп олагуын авыл халкы түгел, остазбикә дә белмәде. Кара бияне юлга әзерләшеп йөргән Яхъя гына остазының ниятен бераз **чамалагандай булды**. (ibid.) The next day he dismissed his students earlier. He

himself disappeared after the noon prayer. Neither the villagers nor even his wife knew where he had gone off to. Only Yakhya (John), who had helped to get the black mare ready for the road, seemed to have some idea of his teacher's intention.

- Дәмәлла, бөтен дөньяны онытып, мөдәррислек шөгеленә чумды. Тышта инде тәмам кыш булып, барча җирнең ак япан ябынуын да **сизмәгәндәй булды**. (ibid.) The damella, forgetting about all else, became completely absorbed in his job as a teacher. He didn't even seem to notice that outside winter had already fully arrived, and that the whole land was putting on a white garment. (Damella – a highly educated teacher at a medrese.)
- Муллага сабырлыгын саклавы кыен иде. Алай да кызып китмәде. Мәгәр тавышы ныгыды, анда тимер чыңы **яңгырап киткәндәй булды**. (ibid.) The mulla had difficulty keeping his patience. Yet, he did not get excited. But his voice hardened, and there seemed to be a ring of steel (lit., iron) in it.

## The past participle with +дай, +дәй and итү

**[1082]** The past participle with +**дай**, +**дәй** and **итү**.
This form expresses *assumption, surmise, imagination, hesitation, doubt, uncertainty, comparison,* as well as a *momentary* (short), *quick* or *sudden, unexpected action.* Furthermore, it may express *pretense* (see the first and second example).

In contrast to the form with **булу**, this construction indicates the *process, course* of an action, i.e., it is a narrative form. Being a transitive verb, **итү** may govern a direct object.

- Каганга сөйлисе сүзен ул алдан ук өйрәнеп ятлап килгән иде. Шуңа күрә аңа каян да булса икенче төштән башлап китүе кыенрак хәзер. Ул, беравык уйланып **торгандай итте** дә өзелгән сүзен шул ук төштән ялгап алып китте. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) He had already in advance prepared and memorized what he was to report to the Khakan. Therefore, it was now somewhat difficult for him to begin suddenly from some other spot. For a brief moment he acted as if thinking and then went on from the same spot at which he had broken off.
- Фирәзә, нәрсәдер эшләргә, термосларны җыярга **керешкәндәй итте**. (Газиз Үзиле, Гыйфрит.) (Just) to do something, Firäzä acted as if beginning to collect the thermos containers (i.e., gather them together to be brought out).
- Кәбир **өшегәндәй итеп** калтыранып куйды. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) Käbir shivered as though he felt cold.
- Арттан ыргылып чапкан тояк тавышлары **ишетелгәндәй итте**. (ibid.) He thought that, from behind, he heard the sound of hoofbeats (of a horse) running at a fast pace.
- Ул мәсьәләнең шулай гади хәл ителүеннән еларга да, көләргә дә белмичә, офыкка күз салды. Сүзләрендә нииндидер рәнҗү дә **чагылып куйгандай итте**: ... (ibid.) Not knowing whether to cry or to laugh at the matter being resolved in so simple a way, he gazed at the horizon. In his words ... there appeared to be the slightest indication that he felt some offense: ...
- Алар елга ярына килделәр. Малай чишенергә дә, кеше киемен кияргә дә **уңайсызлангандай итте**. (ibid.) They went to the river bank. The boy appeared to be uncomfortable undressing and putting on other people's clothes. (The boy had just been pulled out from a swamp, and his rescuers had given him clean clothes.)
- ... Кәбир, ыңгырашып, авырткан ягын алыштырып, икенче ягына әйләнде. Күзләрен ачып, тирә-ягына колак салды. ... Тагын да күк **күкрәгәндәй итте**. (ibid.) Groaning, Käbir turned over from the side which hurt to his other side. He opened his eyes

and listened to (sounds in) the surrounding. ... Again it seemed as though there was thunder.

- Бөкебашны яшен **суккандай итте**. (ibid.) It was as though Bökebash was suddenly struck by lightning (at this news).
- Кулларыбелән сыйпый-сыйпый ул байталның арт санына таба китте, янбашка җиткәч, анда өтергә охшап төзәлгән яраны **тикшергәндәй итте**. (ibid.) Stroking her with his hands, he moved towards the mare's rear. Reaching her flanks, he seemed to examine the wound there, which had healed resembling a comma. (So it seemed to the observer.)
- – Язгы уянуның табигатьтә бу тикле нәфис чагылышын нәрсәгә тиңләштерер идең? – дип сорадым. Дустым бераз уйлап барды да: – Мәхәббәт сафлыгына, – диде. Мондый җавап беркадәр китапчарак яңгыраса да, асылда исә миңа бик ошады, тик мин бу чагыштыруның төбендә яткан мәгънәне берьюлы тотып ала алмадым. Бу хәл мине табышмак алдында **калдыргандай итте**. (Габдрахман Минский,Язгы уяну.) "With what would you equate this so delicate expression of the awakening of spring in Nature?" I asked. My friend walked on a little, thinking and then said, "With the purity of love." Although such an answer sounded somewhat bookish, basically, I liked it very much. But I could not immediately grasp the meaning which lay at the basis of this comparison. This circumstance left me facing something of a riddle. (Expresses comparison with a connotation of hesitation, doubt, uncertainty.)
- ... Кәбир атны янбашыннан этә башлады. **Кузгалгандай итте** теге. Аркасындагы капчыгын агач төбенә ыргытып, икеләтә көч белән этә башлады. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) ... Käbir began to push the horse by its flank. It seemed to make an effort (attempt) to move. He threw the (traveling) bag, which he had on his back, under a tree and began to push with redoubled force. (To hide from his pursuers who are trying to take the horse away from him, the boy Käbir tries to push the completely exhausted horse behind some bushes in the woods.)

## The past participle with дагы, +дәге, дагыча, дәгечә, or дагыдай, дәгедәй

**[1083]** The past participle augmented by the suffix +**дагы**, +**дәге** indicates *time.*

- Ләкин бер ел диярлек читтә йөреп, Казан чаклы Казан каласында булып, авылдан **киткәндәге** киемнәрем белән генә кайтып керәсе килми иде. (Мирсәй Әмир, Казан.) But having been away for almost a year, and having been even in the city of Kazan, I did not wish to return in the (same) clothes I wore when I departed from the village.
- Без кайтырга чыктык. ... Без **килгәндәге** тар сукмакка кердек. (Фатих Әмирхан, Кадерле минутлар.) We set out to return. ... We entered (turned into) the narrow path by which we had come.
- Җаекка **килгәндәге** өметләр һәм хыяллар берәм-берәм юкка чыгалар. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) The hopes and dreams (he had) when he came to Uralsk are disappearing one by one.

**[1084]** The past participle augmented by +**дагыча**, +**дәгечә**, or +**дагыдай**, +**дәгедәй** indicates *continuity in manner* with a connotation of comparison*.*

- Ул яшьләрнең **кергәндәгечә** бер-бер артлы чыгып китүләрен ... дәшмичә генә күзәтеп калды. (Атилла Расих, Сынау.) Keeping silent ... he watched the youths leaving one after the other, just as they had come in.

- [Петров] бәләкәй балалар белән **сөйләшкәндәгечә**, сабыр һәм түземле булырга тырышып, җитди генә җавап бирде. (Мирсәй Әмир, Якташ.) Trying to be patient and forbearing, as when speaking with little shildren, [Petrov] answered rather seriously.
- Сакаллы кеше ... бик сөеп эшли торган эшенә керешергә **җыенгандагыча**, үзенә бер тәм, бер хозурлык белән, мыек чылгыйларын бөтереп җибәрде. (Гомәр Бәширов, Сиваш.) The bearded man ... as if being about to start on a task he loved very much to perform, twirled the ends of his mustache with special relish and zest.
- Әкиятләрдә **сөйләнгәндәгедәй**, зур карурман эчендә сары нараттан салган дәү бер йорт. (Гомәр Бәширов, Карурманда бер йорт.) As told in fairy tales, there stands in the great, dense forest a large house built of yellow fir.
- Шуны әйтеп кенә торганда, ут **капкандагыдай** кабаланып, бик күп савыт-сабалар күтәреп апай килеп керде. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) Just when she (Mother) was saying that, (my) older sister, hurrying like mad, came in, carrying a big load of plates and dishes.
- Стеклов аның сүзен бүлдерде һәм өйдә сөйләшеп **утыргандагыдай** йомшак тавыш белән әкрен өстәп куйды: ... (Зөфәр Фәтхетдинов, Ачылган серләр.) Steklov interrupted him and, just as he would do, sitting and talking at home, added quietly in a soft voice: ...

## The past participle with +ныкы, +неке and +мы, +ме

**[1085]** The past participle with **+ныкы**, **+неке** plus the interrogative particle **+мы**, **+ме** indicates *cause* with a connotation of *supposition.* This form is used in the vernacular, but, though infrequently, it does occur also in the literary language.

- Өенә кайтып **җиткәннекеме**, аның тавышы шактый күңелле яңгырады бу юлы. (Фатих Хөсни, Минем тәрәзәләр.) Possibly because he had arrived home, his voice this time sounded rather cheerful.
- Кичә кичтән бирле ризык валчыгы **капмаганныкымы**, әллә өсте бик җиңелгә, ... хәзер суык аның ... арык тәне аша үтеп йөри, ... (Фатих Хөсни, Утызынчы ел.) Possibly because he had not eaten a crumb since yesterday evening, or because he was very lightly clad, ... the cold was now, ... cutting through his emaciated body ...

## The past participle with +ны, +не

**[1086]** The *negative* past participle – mostly of **булу**, less often of other verbs – augmented by the suffix **+ны**, **+не** forms an (exclamatory) negative response to the interlocutor's words.

- – Сиңа Ишәй абзый үз квартирасын бирә. ... – Үзем әлегә вагонда йоклап торырмын, миңа кайда да бер ди. – Ничек инде кайда да бер? **Килешмәгәнне**! Юк, юк, мин аның квартирасына кермим! (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) "Ishey is giving you his apartment (i.e., the apartment assigned to Ishey). ... He says that for now he will continue to sleep in the carriage, that for him it's all the same where (he lives)." "How is it the same where (he lives)? It just isn't proper! No, no, I'm not going to move into his apartment!"
- – Китсәнә, Сәгадәт. **Булмаганны**. Безнең Минай абзый әйбәт кеше ул. (Азат Вергазов, Нәзер.) "Come on, Säghädät. It's just impossible. Our uncle Minai is a good man, indeed." (The speaker is firmly convinced that he is right.)

**[1087]** The same form can also have various modal qualities. For example, using it, the speaker expresses disbelief with regard to the interlocutor's words, while in his heart he wishes that they will come true, or, on the contrary, he hopes that they will turn out not to be true.

- – Син дә булырсың язучы. – **Булмаганны**. – Нигә **булмаганны**, бер язучы да күктән төшми. Гәзит-журналларда эшләп өйрәнә. (Гариф Ахунов, Йолдызлар калка.) "You too will be a writer." "I think that's impossible." "Why impossible, – a writer doesn't fall out of the blue (lit., from the sky). He learns by working for newspapers and magazines."
- – ... Бетештек, ... . Таладылар, ... Кемнәр соң алар? ... Сәгадәтме? – Шул иманы качкан нәрсә. – **Булмаганны**. (Хәй Вахит, Нәзер.) "... I'm finished, ... . They robbed me, ..." "Who are they then? ... Saghädät?" "Exactly, that thing who has lost her faith." "But that's impossible."

Compare also:

- – Я, нишлибез, Мәгъмүрәҗан? – диде Галиәкбәр. ... Ю-ук, болай барып чыкмый. **Булмаганны**. Юк, юк, инде бирешә үк башладыңмыни ...? Барып чыкмый, бу сиңа килешми, әфәндем. (Атилла Расих, Сынау.) "Oh, what shall we do, Mäghmüräjan?" Ghäliäkbär said. ... "No, this way it won't do. It's simply impossible. No, no, you are not going to give up, are you, ...? It won't do, it won't be proper for you, sir."
- Рәхилә Нурсәнәне читкә алып, аңа кечкенә бала күлмәге суза. Рәхилә. Бүләгем булсын. Нурсәнә. Кит, кит, **булмаганны**. Әбсәләм. Нишләп булмасын, болай булгач, була инде. Нурсәнә. Һай, матур да икән. Рәхмәт инде. (Хәй Вахит, Беренче мәхәббәт.) Taking Nursänä to the side, Räkhilä hands her a little children's dress. Räkhilä. Let this be my present. Nursänä. Go on now, that's really impossible. Äbsäläm. Why should it be impossible. Since it is this way, it is possible. Nursänä. Oh, isn't this beautiful. Thank you then! (Nursänä responds initially in the negative, but she does so out of modesty.)

**[1088]** The form is also used in monologues.

- Ничек кенә булмасын, Хафиз күзенә чалынудан мөмкин чаклы качыбрак йөри иде ул. Әмма бу курку, бу уңайсызлану үзе үк аның элекке тынычлыгын югалтканлыгы турында сөйли иде. ... Шул ук вакытта: «**Булмаганны. Ошамаганны** ... күңелгә нәрсә килмәс ул!» дип, үзен тынычландырырга да тырыша иде. (Фатих Хөсни, Гыйльмениса һәм аның күршеләре.) However it may be, she endeavored to keep out of Khafiz' sight as much as possible. But this fear, this being embarrassed attested by itself to the fact that she had lost her previous peace (of mind). ... At the same time she tried to calm herself, saying (by herself): "It can't be. I really don't like him; what thoughts come into one's mind!" (The speaker rejects her own thoughts but wishes that they would come true.)

**[1089]** The past participle with **+ны**, **+не** followed either by the same or by another verb in a conjugated form indicates the subject's *ability* or *determination* to perform, or not to perform, the action.

- Моңа чаклы **эчмәгәнне** хәзер генә **эчмәс**. Since he has not been drinking up to now, he is (definitely) not going to drink now.
- Моңа чаклы анда **бармаганны** бүген генә анда **бармаячакмын** инде. Since I have not gone there up to now, I shall (definitely) not go there today either.
- Каты бәрелгән булса, минем энинең дә авызында теле бар, бер тавыктан сигез аш пешерә **белгәнне** Хабул Ярулласына гына җавапны **тапкан булыр иде**.

(Фатих Хөсни, Без яшь идек ....) If he had been rude, my mother too has a ready tongue, (and) someone able to prepare eight meals from one chicken would certainly have answered that Khabul Yarulla back (lit., found the answer).

## Other constructions with the past participle

**[1090]** The past participle of a verb followed by the *imperative* or *optative of the same verb* expresses the subject's *reluctant, unenthusiastic consent* or *agreement* to the action, sometimes with a tinge of *indifference.* Or it may indicate involuntary rejection of the action due to existing circumstances (see the first example).

- – Утыр, минем дә үз атым түгел. ... – Юк инде, Хафиз абый, рәхмәт, – диде ул ... кеше күрсә, әллә ни уйлый башлар. **Кайткан кайтыйм** инде. (Фатих Хөсни, Гыйльмениса һәм аның күршеләре.) "Get on (the wagon), the horse isn't mine, anyhow. ..." "No, Uncle Khafiz, thank you," she said. ... "If people see, they will start thinking things. I'd better walk home." (The speaker would rather have sat on the wagon.)
- – Мине дә алып барыгыз. – Ах, **барган бар** инде. "Take me along too," "All right, come then"
- – Аны да алып барыйк! – Нәрсәгә кирәк ул. – Бергә булсак, күңеллерәк булыр. – Әйдә, **барган барсын** инде. "Let's take him too!" "What do we need him for?" "It will be more fun if we are (all) together." "So let him come along then."

**[1091]** A *reduplicated* past participle (in writing connected by a hyphen) forms *causal clauses.* It indicates that, once the agent has performed the action expressed by the participle, he (she) – for one reason or other – *is determined, decides, intends, considers*, or is *induced, persuaded, asked*, etc. *to perform also the action denoted by the principal verb.*

- **Килгән-килгән**, барысын да күреп китәргә кирәк. (Атилла Расих, Сынау.) Once he had come here, he had to see all (of them).
- Кат-кат йөрмәскә, **килгән-килгән** Юнысны күреп, эшен бетереп китәргә уйлады. Шул исәп белән ... буш урындыкларның берсенә барып утырды да Юнысның килгәнен каравылларга булды. (Әнәс Галиев, Авылдашлар.) He had thought not to run there (i.e., to the District Revenue Department) several times, but, once he had come, to see Yunys, settle his business and leave. With that in mind ... he walked over to one of the vacant chairs and sat down with the intention to watch for Yunys to arrive (at his office). (Yunys is a revenue inspector.)
- Зәйтүнәнең аягы җиңел, чабып чыгып та китте. Бер минутка: «Әллә **чыккан-чыккан** бу гаугалы кибеттән бөтенләй ычкыныргамы? Рәт чыкмас монда, барыбер эшләп булмас!» – дип уйлады. Zeytünä was light-footed and she quickly ran outside. For a moment the thought occurred to her that, once she had gotten out, shouldn't she perhaps leave this noisy (scandalous) store for good? Things won't work out, it's impossible to work here anyway. (The store had been selling women's jackets. But when the store manager announced that all of them were gone, the many customers who remained in the store did not believe him and began to riot. Zeytünä, who had just started to work in the store, was sent out to get the police.)
- Юныс ... китәргә кузгалды. ... Мандрус, ... Юнысның юлына аркылы төште. – **Килгән-килгән**, безнең өйне дә күреп китегез инде, Юныс Гыйльметдинович, – дип, сул як ишеккә күрсәтте. (ibid.) Yunys ... moved to leave. ... Mandrus ... blocked Yunys' way. "Since you have come here, why don't you have a look at our house too, Yunys Ghilmetdinovitch," he said and pointed at a door to the left.

**[1092]** In a sentence whose *logical subject* is in the *plural*, the *negative* possessive form of a past participle plus **юк** folowing *the same verb* in an *affirmative* conjugated form, and preceded in turn by the *affirmative* possessive form of the participle, indicates that the action is carried out by only part of a group of agents.

- Тагын шунысы да мәгълүм булды: кичке ашка **артистларның кергәне** кергән, **кермәгәне юк**. Махсус чакыручы булмаган. (Ибраһим Нуруллин, Хәсрәт бакчасы.) Furthermore, this too became known: Only some of the artists had come in for dinner. There had been no one inviting them specially.
- Моны **ишеткәннәре** – ишетте, **ишетмәгәннәре** – **юк**. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кубрат хан.) Only some of them (i.e., some of those assembled) heard this.

**[1093]** The past participle followed by a conjugated form of the *same verb*, both in the *affirmative* and repeated in their corresponding *negative* form indicates that the action is carried out with *great intensity*.

- Һәм без киттек. Атның тояклары **тигән** җиргә **тия, тимәгән** җиргә **тими**. (Фатих Хөсни, Солдат хикәясе.) And off we went. The hoofs of the horse seemed to hardly touch the ground.
- – Бар, Биктимер, хәзер үк Җамалиларга йөгер, әни таба сораган иде ... диген. ... Биктимер ... чыга башлый. Ләкин ... Маһруй ... аны туктатып, тагы бер кат бик ныклап тукый: – Аягың **тигән** җиргә **тисен, тимәгән** җиргә **тимәсен**, югыйсә камырым ташый, хәзер үк кайт. Ишеттең? (Фатих Хөсни, Сөйләнмәгән хикәя.) “Go, Biktimer, run right now to the Jamalis’ and say that Mother is asking for (their) pan, ...” Biktimer is leaving. But ... Mahruy ... stops him and once more impresses upon him very firmly: “Hurry quickly (Run as fast as you can), for my dough will rise over the brim (of the bowl). Come back immediately. Do you hear?”

**[1094]** The *affirmative* past participle following the *negative* verbal adverb in **-мый**, **-ми** of the same verb presents the action expressed by this construction as performed rarely and as the probable cause of the action of the principal verb.

- **Эчми эчкәнгәме**, Гапсамат кызган иде. (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) Possibly because he (usually) did not drink, Ghapsamat was excited.
- ... **күрми күргән** шул плакат тәэсирендәме дип әйтим әллә олылардан ишетеп, ... дип такмаклап йөргәнебезне мин әле бик ачык истә саклый идем. (Фатих Хөсни, Минем тәрәзәләр.) Was it under the influence of that (same) poster (the kind of) which we had never seen before – or had we heard it from grown-ups – in any case, I could still recall very clearly that we would walk around, singing the verse ...

## The Past Participle in -тан, -тән, -кан, -кән with +лык, +лек

**[1095]** When it takes the suffix **+лык**, **+лек**, the past participle in -тан, -тән, -кан, -кән forms a verbal noun which may refer to the past or present.

Referring to the *past*, it indicates that the action expressed by it was completed *somewhat further back in the past* than actions expressed by the simple past participle.

Furthermore, it denotes an action or a state taking place or prevailing *prior to* or *simultaneously with* the action expressed by the principal verb.

Also, it often tends to describe conditions of a *more permanent nature.*

For example: Анның ул кичәдә яңа җыр **җырлаганлыгын** беләм. I know that on that evening he had sung a new song. (The action had become a fact long ago.)

*But:* Анның ул кичәдә яңа җыр **җырлаганын** беләм. I know that on that evening he sang a new song (I heard about it recently).

Compare also:

- Сафураның җен ачулары чыкты, тик хәзер моны һич сиздерергә **ярамаганлыгын** ул яхшы аңлый. (Атилла Расих, Сынау.) Safura began to seeth with rage, but she knew very well that she must not let it show now.
- – Сез **Әлфиянең** минем сеңел **икәнлеген** кайдан беләсез? "How (lit., From where) do you know that Älfiä is my younger sister?"
- Сәлим бабай **безнең уңайсызланганлыкларыбызны** сизеп, шуны бетерергә теләгән кебек ... әйтте дә бирде. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) Sensing our feeling uncomfortable and, as if wanting to put us at ease, old Sälim stated ...
- Мәдинә һәркайсы белән кул биреп исәнләште һәм, бераз икеләнеп торганнан соң, **үзенең** Казанга эш эзләп **килгәнлеген** әйтте. (Атилла Расих, Ике буйдак.) Mädinä said hello, shaking hands with every one of them and, after hesitating a little, told them that she had come to Kazan to look for work.
- Мин **аның** кайсыбыз Ильяс **икәнлекне** таный **алмаганлыгын** сизеп, ярдәмгә килдем. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Realizing that she could not know which one of us was Ilyas, I came to her assistance.
- **Үземнең** моңа кадәр бер вакытта да **эчмәгәнлегемне** һәм бүген дә эчәргә риза **түгеллегемне** белдердем. (ibid.) I declared that up to now I had never had any (alcoholic) drinks and that I was not agreeable to drinking today either.
- – ... мин **сезнең** бу кадәр җитди кеше **икәнлегегезне** белмәдем. (ibid.) "I didn't know that you are a person who is so serious."
- – Курыкма, Гаяз, мин **үземнең** кайда **икәнлегемне** онытмыйм, кайда **икәнлегемне** бик яхшы беләм. (ibid.) "Don't be afraid, Ghayaz, I don't forget where I am, I know very well where I am."
- **Аларның** ни өчен кәефсез **икәнлекләрен** Фәридә, әлбәттә, бик яхшы белде, ... (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Färidä knew, of course, very well why they were in a bad mood.

*Note:* In the older (mostly pre-revolutionary) literary language, the verbal noun **икән** had also the expanded form **икәнчелек**.
For example: Газизә абыстай бу егетнең Г. шәһәрендәге Салих Фатихов исемле яшь бай, бик тәүфикълы ... кеше **икәнчелеген** сөйләде ... (Фатих Әмирхан, Хәят 1911.) Lady Ghäzizä told her that the young man's name was Salikh Fatikhov, that he was a young, wealthy, very pious ... man (who lived) in the town of G ...

**[1096]** The verbal noun with **+лык**, **+лек** in the *ablative* indicates *cause.*

- Утлар **булмаганлыктан**, мин аның йөзен бик үк яхшылап күрә алмадым. (Фатих Әмирхан, Танымаганлыктан таныштык.) ... As there were no lights, I couldn't see her face too well.
- Ул, үткән көз Казан университетына кабул **ителгәнлектән**, бу кышны Казанда уздырып, кичә генә Н. шәһәренә кайткан иде. (Фатих Әмирхан, Хәят.) Because he had been admitted to the University of Kazan last autumn, he had spent this winter in Kazan and returned to the city of N. only yesterday.
- – Сез мине үз итәсез, сезнең игелегегезне кайтарырга кулымнан **килмәгәнлектән** мин оялам. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) "You regard me as close to you (i.e., to your family). I am ashamed because I am not in a position to reciprocate your kindness."

**[1097]** The suffix **+лык**, **+лек** may be joined directly to the modal words **бар**, **юк**, **түгел**, **кирәк**, **тиеш** and to *interrogative pronouns.* The suffix then stands for **икән/икәнлек** or for **булган/булганлык**, whichever applies in a given context. With **+лык**, **+лек** assuming a verbal character – mostly expressing the copula 'to be' – the forms **барлык**, **юклык**, **түгеллек**, etc. function like verbal nouns, i.e., they may take possessive suffixes, can be put into the plural and can be declined, the most frequently occurring case being the accusative.

The suffix **+лык**, **+лек** is often used with the above parts of speech for stylistic reasons, to avoid a repetition of **икән/икәнлек**, etc.

a) Examples of the suffix **+лык**, **+лек** with the above five modal words:

- Өй эче ярым караңгы, шулай да монда кемнәрдер **барлыгын** шәйләп була. (Нурихан Фәттах, Сызгыра торган уклар.) The interior of the house is half-dark; one can, however, discern that there are some people here.
- [Профессор] инде бу урынга берничә кешенең кандидатурасы **барлыгын** һәм вакыты җитсә, шулар арасыннан иң яраклысы сайланачагын әйтте. (Атилла Расих, Ике буйдак.) [The professor] said that there were already several candidates for this position and that, when the time came, the most suitable one would be chosen from among those.
- Аларга безнең **барлыгыбыз-юклыгыбыз** барыбер кебек булып күренгән булса кирәк. (Мәҗит Гафури, Шагыйрьнең алтын приискасында.) It appeared as though it made no difference to them whether we were there or not.

(For булса кирәк see 1010.)

- Фәрит әтисенең өйдә **юклыгын** абайлады. (Атилла Расих, Сынау.) Färit noticed that her father was not at home.
- Яраткан кешең сиңа нинди генә якын һәм кадерле булса да, әгәр аның инде дөньяда **юклыгын**, аның белән күрешү мөмкин **түгеллеген** яхшы белсәң, ... (Шәйхи Маннур, Муса.) No matter how close and how dear your beloved is to you, if you know that he is no longer in this world, that meeting with him is (no longer) possible, ...
- Заһид барлык көчен җыеп, эшнең яшь аермасында гына **түгеллеген**, ә тагы нindiдер билгесез бер нәрсәдә **икәнлеген** әйтергә тырышты. (Атилла Расих, Ике буйдак.) Gathering all his strength, Zahid tried to tell (himself) that the matter wasn't just one of difference in age, but that it was also one of something undefined (unknown).
- ... минем риза **түгеллегем** белән берәү дә хисаплашырга уйламады. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) ... no one thought of respecting my not being agreeable.
- ... Җәүдәтләр югарыдагы фәрман белән генә яшәргә өйрәнеп киттеләр бит. ... Шуны эшләсә, җаны тынычлана андыйларның. Ә ул фәрманның дөресме, дөрес **түгелмелеге** (түгелме икәнлеге) турында күп уйлап тормый. (Хәниф Хәйруллин, Картлык кемгә шатлык.) ... after all, people like Jäwdät have learned to live only with orders from above (i.e., from higher authorities). ... If they do that, the minds of such people are calm. But they don't think much about whether they are right or not.

*Note:* The contracted form **тугелмелеге** pertains to the vernacular but is also used in the literary language.

- Сафура Эльвирага картның ни өчен **кирәклеген** сорады. (Атилла Расих, Сынау.) Safura asked Elvira why she needed the old man.
- – Ярый ла, Басыйров – тәҗрибәле, эшне ничек йөртергә **кирәклеген** белә торган кеше. (ibid.) "All right, Basirov is an experienced man who knows how the work must be conducted."
- – Нишләргә **кирәклеген** сездән башка да белерләр. (ibid.) "They know without you what has to be done."

- Рәис боларга ... тик дөресне генә сөйләргә **тиешлекләрен**, юкса, җавапка тартылачакларын аңлата барды. (Галимҗан Ибраһимов, Тирән тамырлар.) The judge (lit., chairman) ... continued to explain to them that they must only speak the truth, that otherwise they will be held responsible.
- Сөмбел. Башта Әсма апага әйтергә **тиешлегебезне** онытттыңмыни? (Шамил Рәкыйпов, Ике килен-килендәш.) Sömbel. Have you forgotten that we must first tell (my older) sister Äsma?
- Барый балыкларның ничә кило булуын, күпме акча **тиешлеген** сорады ... (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Bari asked how many kilos the fish weighed and how much money he needed (to buy them) ...

b) Examples of the suffix +**лык**, +**лек** with interrogative pronouns:

- – Сез миннән нәрсә үтенәсез, Мәдинә? Сез үзегез мәсьәләнең **ничеклеген** беләсезме соң? – диде Заһид. (Атилла Расих, Ике буйдак.) “What are you asking of me, Mädinä? After all, you know yourself how the matter stands (lit., is), don’t you?” Zahid said.
- Миңа да кирәкле белешмәне бирерләр, мөгаен: нәрсәнең **ничеклеген**, **кайдалыгын**, ни өчен алай **икәнен** аңлатырлар. (Марсель Зарипов, Отышлы әйләнеш.) They will give the needed information to me too, probably. They will explain how, where, and why things are the way they are (lit., so, that way).
- – Син бу кеше турында ни әйтерсең? – Шамаевмы? Шәп эшли. Үзен жәлләми. Акыллы. ... Ә менә күңеленең **ничеклегенә** килгәндә, төрле кеше төрлечә фикер йөртә. (Фәнил Галиев, Командировка.) “What can you say about this man?” “Shamayev? He works well. He doesn’t go easy on himself. He is intelligent. ... But as to his true personality (nature), different people have different opinions.”
- Дөньяга яралганнан бирле кеше үзенең **кемлеген** һәм **нindилеген** белергә тырыша. (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөртеге.) Since he was put (lit., created) into the world, man has been trying to find out who and what he is.
- Минем **кемлегемне** монда беркем белми. (Нурихан Фәттах, Кол Гали.) Here nobody knows who I am.
- Минем **мондалыгым** чын түгелдер, боларны нindидер бер рәсемдә яки театрда гына күрәмендер шикелле. (Әхәт Гаффар, Бодай бөртеге һәм тегермән ташы.) It is as though I am not really here, as though I am seeing these things only in some picture or in the theatre.
- Мин ул моңның, шаян яктылыкның **каянлыгын** сизәм, тоям, аңлыйм. (Роберт Миңнуллин, Туган якка кайткач.) I sense, I feel, I understand where that tune, that playful light are from.
- Мин шатлыгымнан ... үземнең **кайдалыгымны** оныттым. (Фатих Әмирхан, Кадерле минутлар.) Out of joy I forgot ... where I was.

c) Though infrequently, +**лык**, +**лек** is even joined to adjectives, adverbs and nouns in the locative. For example:

- Гөлбикә. Әгәр дә Караголның **исәнлеген** (исән икәнлеген) кайдалыгын белсәк, үзебез дә бу кадәр күз яше түкмәгән булыр идек! (Давыт Юлтый, Карагол.) Gölbikä. If we had known that Qaraghol was alive and where he was, we wouldn’t have shed so many tears!
- Зиннәт кияүнең **андыйлыгына** ышанмыйм да әле мин. (Кояш Тимбикова, Ярлар биек.) I still don’t believe that my son-in-law Zinnät is such (a man).
- Табибәләр ишеген шакыганда, Зөһрә аның өйдәлегенә өмет тә итмәгән иде. (Кояш Тимбикова, Агым уртасында). When Zöhrä knocked at Tabibä’s door she had not even hoped that she (i.e., Tabibä) would be at home.

# The Past Participle of the Verb дию

**[1098] дигән**
functions to connect subordinate clauses with their main clause (677, 1-2 and 3 a-c). Furthermore, **дигән** may be used:

a) Instead of the *possessive case.*

- ... минем әни **Зәңгәр күл дигән авылда** туып үскән. (Вакыйф Нуруллин, Аккан су юлын табар.) ... my mother was born and grew up in the village of (in the village called) Blue Lake.
- Or (compare): Г. Ибраһимов 1887 елның 12 мартында ... **Солтанморат авылында** туган. (Мансур Хәсәнов, Галимҗан Ибраһимов.) Gh. Ibrahimov was born on the 12th of March, 1887 ... in the village of Soltanmorat.
- Г. Камал үзенең беренче әсәре булган «**Бәхетсез егет**» **драмасын** 1898 елда яза, соңыннан бу драма һәм аның «**Өч бәдбәхет**» **дигән әсәре** 1900 елны басылып чыгалар. (М. Гайнуллин, Галиәсгар Камалның шигырьләре, публицистик һәм прозаик әсәләре.) Gh. Kamal wrote his drama “The Unhappy Young Man”, which was his first work, in 1898. Later, this drama and his work (called) “The Three Scoundrels” were published in 1900.
- Сәрби. Бану Ахметова **дигән** укытучы кирәк иде миңа. (Мирсәй Әмир, Минем хатын.) Särbi. I would have to see the teacher (called) Banu Akhmetova. (Emphasis is on the name.)

b) Instead of the genitive to express the *possessive relation* between nouns when the object designated by the *governing* noun is destined *for the person or thing* denoted by the *governed* noun. The governed noun is in the *dative.*

- – Эшкә институт бетергән яшь белгеч җибәрделәр. Хатыны, баласы бар. Хәзергә **Ризатдиновага дигән** бүлмәне биреп тор, ... (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) “They’ve sent us a young expert to work with us who has finished the institute. He has a wife and one child. For now, give him the room which was intended for Rizatdinova, ...”
- – Син ничек алай **безгә дигән** машина белән шулай үзең теләгәнчә эш итмәкче булдың әле? (Вакыйф Нуруллин, Аккан су юлын табар.) “How come you decided to act just as you wished in the matter of the car which was (intended, destined) for us?”
- Башын кая куярга белмәде егет. Ул бүтән нәрсә уйлап чыгара алмады, – **алмашка дигән** күлмәк-ыштанын куенына тыкты да ... бер самогончыга элдертте. (Гариф Гобәй, Ләйсән яңгыр.) The young man was completely upset. He was unable to think of anything else – he took his extra shirt and pants into his arms and brought them to a still. (Having no money, the young man takes the clothes to a still to get some liquor for them.)

**[1099]** Together with **менә** or **бер**, **дигән** indicates that the quality of a person or thing expressed by the noun immediately following it is present in a *superior degree*, or, if followed by a verb, that the action is carried out in a *superior manner.*

- – Ул яктан тыныч бул, Булат Вәлиевич, **менә дигән галим** чыгачак синең Шамилеңнән. (Вакыйф Нуруллин, Аккан су юлын табар.) “As far as that is concerned, set your mind at rest, Bulat Wälievich. Your Shamil will make a real good scientist.”
- Эчке кичерешләре нинди генә авыр булмасын, ул имтиханнарын **менә дигән** итеп биреп чыкты. (Сәет Шәкүров, Сәхнәнең кыл уртасында.) However severe the inner experience he was undergoing, he passed his exams with flying colors.

· Өсте-башы да **менә дигән**! (Сафа Сабиров, Улым кайткач.) His clothes too were first-class.
· – Тыңла сүземне, тор Фәритең белән, **бер дигән егет** бит. (Нурия Измайлова, Яшьлек шаярулары.) “Listen to me, move in together with your Färit. He is a unique (unequaled) young man, indeed.”

**Дигән** can be the predicate of a sentence. In this case, it may be used in the plural.
· Мәдинә. **Я**, я, анаң унбер бала үстергән әле. Барыгыз да **менә дигәннәр**. (Мирсәй Әмир, Минем хатын.) Mädinä. Well, well, your mother has raised eleven children. All of you have turned out really very well.

**[1100]** a) Taking the possessive suffix *of any person,* **дигән** in the singular or plural, used postpositionally with a noun, serves to refer back to the subject matter (persons, things, ideas, etc.) mentioned or discussed earlier. The noun it follows is the same (has the same meaning) as that used previously.

*Note:* The most frequently used form is that with the possessive suffix of the *second person singular.*

· **Кеше дигәнең** бөтен тарихы буенча яшәү өчен көрәшкән. (Гомәр Бәширов, Тылсымнар дөньясында.) Man has struggled for his living throughout his entire history.
· – Һай, бу **бала дигәннәрең**! (Шәриф Хөсәенов, Мәхәббәт сагышы.) “Oh, these children!” (Children in general. The speaker, is indignant with her son, reflects on the ingratitude and indifference some children show with regard to their parents.)
· – Ул **Хәлимә дигәнең** кичә бик күңелсез иде, ник икән? (ibid.) “That Khälimä (of yours) was very unhappy yesterday. I wonder why?”
· Госман. Бик озак йөрдең, кызым. Бер **атна дигәнең** ике атнага сузылды. (Гамир Насрый, Кушнарат.) Ghosman. You were away a very long time, my daughter. Your one week (i.e., the one week you said you would be away) has become two weeks.
· **Миколай дигәннәре** татарча яхшы белә иде. (Шәриф Камал, Акчарлаклар.) Mikolai (the man they called Mikolai) knew Tatar well.
· Мәдинә. Галиябануның әнисе мин. Сәрби. **Бану апа дигәннәре** шулмы инде? (Мирсәй Әмир, Минем хатын.) Mädinä. I am Ghaliäbanu’s mother. Särbi. Is she then (the same person called) Banu?

b) The possessive forms of **дигән(нәр)** may take case endings.
· – Алып кил әле шул **Мәдинә дигәнеңне**. (Шәриф Хөсәенов, Мәхәббәт сагышы.) “Please, bring that Mädinä of yours here.”
· – Син, малай, ул **Садыйк мулла дигәннәренә** барып, белешеп кайт. (Фатих Хөсни, Җәяүле кеше сукмагы.) “You, boy, go to that mulla Sadiq (that mulla Sadiq mentioned before) and inquire.”
· Боларның нинди галәмәтләр булуын, авылда ике кешедән башка, берәү дә белми һәм игътибар итеп торучы кеше дә юк иде. Ә бу ике **кеше дигәнебезнең** берсе Зәйтүнә, икенчесе Сәфәргали иде. Except for two people, there was nobody in the village who knew what signs these were, and there was also no one who paid any attention (to them). And one of these two people of ours was Zeytünä, the other Säfärghäli. (Reference is to the two principal characters in the novel.)

**[1101]** **Дигән** in the *locative* may serve:

a) To ask an *emphatic question.*
· Кыш көне Мотаһирга тагын бер вазифа йөкләнде: ул көн саен ... егерме литр сөт алып кайтырга тиеш иде. Ни өчен **Мотаһир дигәндә**, элек бу эшкә билгеләнгән

тоткын беркөнне гөнаһлы булды. (Рәфкать Кәрами, Каргышлы юллар.) One winter day Motahir was charged with still another duty. Every day he had to ... get twenty liters of milk (i.e., from the neighboring village). Why Motahir of all people? The (prison) inmate who had been assigned to this job had transgressed one day (i.e., he had broken the lead seal and drunk some of the milk).

b) The subject's *displeasure* with, *disapproval* of, another person's intended but not yet realized action.
  - Җәүһәрия. Шул гына җитмәгән иде, унҗиде яшьтән рестораннарга сөйрәлеп **йөрисең** генә **калган**! (Шәриф Хөсәенов, Зөбәйдә – адәм баласы.) Jäwhäriä. That's all we would need – seventeen years old and hanging about in restaurants!

**[1146]** With the corresponding *negative* form – **калмаган** – the construction expresses the subject's *regret* over having performed the action.

- Болай **йөрисе калмаган**, дип уйлады ул, Лариса белән башка урында очрашасы калган. (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) He should not have gone about it like this, he thought. He should have arranged to meet Larisa at another place.

**[1147]** The participle in **-асы**, **-әсе**, etc. followed by **калу** in its *third person singular* of other tenses (mostly past tense I), indicates that the subject has no choice, that there remains nothing else for him but to carry out the action expressed by the participle, or, with **калу** in the *negative*, that there is no *need* for him to perform the action. If expressed, the subject is in the *dative*, or it is indicated by the respective possessive suffix on the participle.

- Сүз шуның белән бетте шикелле. ... **Аңа** бездән инде чыгып **китәсе** генә **калды**. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) With that the talk ended, it seemed. ... For him there was nothing left but to leave us.
- – Кара, бетеп килә бит инде. Тагын бераз гына **эшлисе калды**. (Габдрахман Әпсәләмов, Идел хикәяте.) "Look, it's almost finished already. There remains just a little bit yet to do."
- – Ятим бала, күрәсең. Кая белеп алды. **Миңа сөйлисе** дә **калмады**. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) "He is an orphan, you see. (It's obvious, he is an orphan.)" How did he discern that? There was no need for me to say anything.
- Тагын ничә балык тотуыбыз турында язып тору инде үзем өчен дә кызык түгел. Гомумән, шушында нокта да куйган булыр идем. Фәнил турында тагын бер-ике сүз **әйтәсем калды**. (Мирсәй Әмир, Балыкчы ялганнары.) To go on writing about how many fish we caught isn't even of any interest to me. In general, I would have ended (lit., put a period) right here. (But) there remained still a few words for me to say about Fänil.

**[1148]** The future participle in **-асы**, **-әсе**, etc. followed by the verb **итү** in *any person, mood* and *tense* indicates the subject's *decision* to carry out the action.

- Идел ягында урман өстен тоташ болытлар каплаган. Шулардан чамалап, өстемә пинҗәк кидем, зонтик та **аласы иттем**. (Гомәр Бәширов, Бибек нигә елый.) A cloud cover lay over the woods in the Volga area. Judging by those (clouds), I put on a coat and decided to take an umbrella too.
- Ял көне дип, Кыям кинога **барасы итте**. (Ибраһим Гази, Гаепсез гаеплеләр.) Since it was a holiday, Qiam decided to go to the cinema.
- – Нишләп сез укырга соң кердегез, ничек яшь чактарак берәр институтка **кереп карыйсы итмәдегез**? (Гомәр Бәширов, Көзге ачы җилләрдә.) "Why did you begin to study (so) late? Why didn't you decide to try to attend (to get into) some institute when you were younger?"
- Инде соң булганга күрә, бүгенгә **таралышасы иттеләр**. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) As it was already late, they decided to part for the day.
- – Урман буеннан йөрү бик сирәк эләгә миңа, шуңа күрә табигатькә хозурланып **җәяүлисе иткән идем**, – диде. (Мәгъсүм Хуҗин, Урак өсте болытлары.) "I very seldom get to walk in the woods. Therefore, I had decided to go on foot, enjoying nature," he said.
- «... Таипов хаклы: безгә дә **кертәсе итсәләр**, юньлерәк адәмнәрне сайлап алмыйча һич ярамас.» (Эдуард Касыймов, Җир балкышы.) "... Taipov is right. If they decide to put (some people) with us (in our house) too, it won't do (won't be right) if they don't select people who are orderly."

**[1149]** The future participle in **-асы**, **-әсе**, etc. followed by **икән** with or without personal endings indicates:

a) *Regret* that the action was or was not performed in the past.

- – Биш-алты сәгатькә иртәрәк килеп өлгергән булсам, тәгаен күрешәчәкбез, вокзалга хәтле сине озата **барасы икәнмен**. (Сафа Сабиров, Хатлар язам сагынып.) "If I

had managed to come five or six hours earlier, we would definitely have met (seen each other), and I would have accompanied you to the station."

- Сорамаган булсам яхшырак **буласы икән**, ... (Фатих Хөсни, Ике агроном, бер овчарка.) It would have been better if I hadn't asked, ...
- ... тәнәфестә театрдан бөтенләй китеп үк бармакчы да булып утырган иде Фәләх. Шулай иткән булса, әлбәттә, бик акыллы эшләгән **буласы икән**. (Вакыйф Нуруллин, Һәлакәт.) ... Fäläkh had sat there even wanting to get out and away from the theatre during the intermission. If he had done that, he would, of course, have acted very wisely.

b) A *suppositional possibility.*

- «Ярый әле, шул нарат төбенә ышыкланмадык, югыйсә һәлак **буласы икәнбез**», – дип шомланып һәм сөенеп уйлады Гәрәй. (Сафа Сабиров, Гәрәйнең бер җәе.) "Good that we did not take shelter under that pine, otherwise we could have perished," Gärey thought, frightened and glad (at the same time).

c) *Embarrassment, confusion,* the subject's *being at a loss.*

- Камәр түти өнсез калды. Йортта мондый шатлыкның бу йортка нигез салынганнан бирле бөтенләй булганы юк иде. Андый вакытта **нишлисе икән**? Шатланасымы? Елыйсымы? Самовар куеп җибәрәсеме? Күрешәсеме? (Мөхәммәт Мәһдиев, Каз канатлары.) Aunt Qämär was speechless. There had never been such joy in this house since its foundation was laid. At such time what should she do? Be happy? Cry? Put the samovar on the table? Greet him (i.e., her son)?

d) An action which – as the narrator has learned – *must* be performed by its agent at some point in the future. The word denoting the *agent* appears in the *dative case.*

- **Зарифка** иртүк эшкә **барасы икән**, миңа да таңнан ук унбиш чакрымдагы өйгә чабарга кирәк. (Шәйхи Маннур, Чын сөю бармы?) It turned out that Zarif had to go to work early in the morning, (and) I too would have to race the fifteen versts home right after dawn.

**[1150]** The future participle in **-асы**, **-әсе**, etc. followed by the word **урын** 'place' in the *dative* or *locative case,* indicates an action performed *instead* of that expressed by the participle.

- **Мин һөҗүм итәсе урынга** мине кысрыклыйлар. (Туфан Миңнуллин, Хәсән Вәгыйзович.) Instead of me attacking them, they are pressing me.
- – Әйтәм, миңа да Шәрифә **диясе урынга** еш кына Шәфика дип җибәрә идең. (Габдрахман Әпсәләмов, Идел хикәяте.) "I say, you would often call me Shäfiqa too instead of Shärifä."
- **Гаяз** миңа җавап **бирәсе урында** Кучәрбайга борылды. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) Instead of giving me an answer, Ghayaz turned to Quchärbai.
- ... ярдәм **күрсәтәсе урында**, вакытында акча түләмичә, труппаны кыен хәлгә төшерәләр. (М. Шакирҗанов, Көрәшнең алгы сафында.) ... instead of helping, they put the (theatre) company into a difficult situation by not paying the money on time.

# CHAPTER XXII – INFINITIVE[1)]

## The Infinitive in -рга, -ргә, -ᵒрга, -ᵒргә (-маска, -мәскә)

**[1151]** Taking the *dative case ending,* the *participle* in **-р**, **-ар**, **-әр**, **-ыр**, **-ер**, **-мас**, **-мәс** forms an *infinitive*. This infinitive can be the subject of a sentence, but it cannot be declined, cannot take possessive suffixes and cannot be used with postpositions. In a sentence, it functions as a *complementary infinitive* or as an *infinitive of purpose,* i.e., it modifies a verb a) by *completing* its meaning, b) by expressing the *purpose* of the action.

· Әйтелгән көнне, билгеләнгән сәгатьтә Салих әфәнде миңа беренче дәресен **бирергә килде**. ... Салих әфәнде, әдәп саклап булса кирәк, минем яныма **килергә ашыкмады**, тик бераздан гына этиемнән дәресне **башларга рөхсәт сорады**. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) On the day agreed upon, at the fixed hour, Mister Salikh came to give me the first lesson. ... Probably in order to observe (good) manners, Mister Salikh did not hurry to come over to me. Only after a little while did he ask my father for permission to begin the lesson.

· – Ник алай дисең, Фазыл, **кайтмаска китмисең** бит. (Әхмәт Фәйзи, Тукай.) “Why do you say that, Fazyl? After all, you are not leaving for good (lit., you are not leaving in order not to return).”

· – Менә монда бераз ак май белән ит кисәге. Бала-чагаларыгызга күчтәнәч булыр. Мин **алырга** да **алмаска** да **белмәдем**. (Афзал Шамов, Авыр көннәрдә.) “Here is a little butter and a piece of meat. It will be a present for your children.” I did not know whether to accept it or not.

· Зоя. Мин синең белән бүтән **сөйләшергә теләмим**. (Диас Вәлиев, Кеше эзлим.) Zoya. I don’t wish to talk with you anymore.

· Сәйфи. Ә, әйе, анысын **әйтергә оныткамын**. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Seyfi. Oh, yes, this is something I forgot to say to you ...

**[1152]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. (-маска, -мәскә) modifies *nouns, adjectives* or *modal words* used attributively or predicatively.

· ... мондый вак-төякләр турында озак сөйләшеп **торырга вакыты** юк иде. (Фатих Хөсни, Малай, чиләк, әби.) ... he had no time to talk for long about such trifles.

· Кояш **чыгарга байтак ара** бар әле. (Әхәт Гаффар, Бодай бөртеге һәм тегермән ташы.) There is still plenty of time until the sun rises.

· – Амбар алдында таудай бодай өелеп ята. Кыза. **Әйләндерергә, җилләтергә кеше** кирәк. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) “In front of the granary there lies wheat piled up like a mountain. It is heating up. Someone is needed to turn it over, to air it.”

· Мавия. Мин, ул юлга кергәнче, хәзер сезнең йортыгызны ташлап чыгып **китәргә риза**. (Мирхәйдәр Фәйзи, Адашкан күңел.) Mawiä. Before I go down that road I am willing to leave your house immediately.

· Сәйфи. Сиңа хат язмаганмын. Менә анысы өчен мең тапкыр гафу **үтенергә әзер**. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Seyfi. I haven’t written you a letter. Now, I’m ready to apologize a thousand times for that.

· Хәким. Син борчылма, Шәмсия апа. Хафизга бераз хәл **җыярга**, йоклап **алырга кирәк**. (Риза Ишморат, Гөлзадә.) Khäkim. Don’t worry, Shämsiä. Khafiz must rest a little (and) sleep for a while.

---

[1)] See also 1171.

- Мортаза. Минемчә ... эшне ул дәрәҗәгә **җиткермәскә кирәк**. (Риза Ишморат, Якын дус.) Mortaza. In my opinion ... one ought not carry the matter to that extent (lit., degree).
- Батыршин. Сезне озата **барырга ярыймы**? (Риза Ишморат, Үлмәс җыр.) Batyrshin. Is it all right to accompany you?
- – Син дә **укырга тиеш**, институтка **керергә тиеш**! (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) "You too must study. You too must enter the institute."
- Мин ... кешеләр белән күп **аралашмаска**, тел йотып **утырырга мәҗбүр идем**. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) I was forced to keep silent ... not to associate much with people.
- ... аларның хаклы икәнлеген **күрмәскә**, дөреслекнең алар ягында булуына **ышанмаска мөмкин** түгел иде. (Мирсәй Әмир, Зур гәүдәле, кечкенә башлы.) ... it was impossible not to see that they were right, not to believe that the truth was on their side.

**[1153]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. in its *affirmative* form and repeated in its *negative* form and both followed by **да**, **дә** corresponds to clauses connected by the subordinating conjunction 'whether ... or not'.

- Башта мин аны өемә **чакырырга да, чакырмаска да** белмәдем, **...** (Гадел Кутуй, Тапшырылмаган хатлар.) At first I did not know whether to invite him to my house or not, ...
- – Ә нигә, анда егетләр беткән идемени? – дип сорау бирә Курамшин **көләргә дә, көлмәскә дә** белмичә. (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) "But why, aren't there any young men left there then?" Quramshin asks, not knowing whether to laugh or not.

**[1154]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. (**-маска**, **-мәскә**) can be used as an *independent predicate.* In this function it may express:

a) A *categorical command, prohibition* (negative command) or *order* given to *unspecified* persons, or to one or several *specific* persons.
   - Кубрат хан беренче булып аваз салды: – **Кузгалырга**! (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кубрат хан.) Khan Qubrat was the first to cry: "Forward march!"
   - – Минем арттан йөгерегез, **туктамаска**, артка **калмаска**! (Гомәр Бәширов, Сиваш.) "Charge (forward) after me, no stopping, no falling behind!"
   - Офицер. Табарга кирәк, иртәгә кичкә **хәбәр итәргә**! Аннан соң бу исемлектәге кешеләр артыннан ныклы күзәтү алып **барырга**. Җинаять эшләнәчәк урынны алдан белеп, ... аннан бирегә килеп **әйтергә** һәм үзеңә ярдәмгә тагын бер кеше **табарга**! (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) The Officer. He must be found. Report by tomorrow evening! Then keep the persons in this list here under close observation. Find out the place where the crime is to be committed, ... then come here and report, and find another person to help you.

b) A *decision*, often with a tinge of inner compulsion.
   - Юк, юк! Бу мөмкин түгел. Мондый куркыныч уйларны **куарга**! Хәзер үк баштан чыгарып **ташларга**. **Йокларга**. Бераз гына йоклап **алырга** да, аннан репетициягә **тотынырга**. (Сәет Шәкүров, Сәхнәнең кыл уртасында.) No, no! This is not possible. Such dangerous thoughts must be chased away! They must be gotten out of one's head immediately. Sleep. Sleep a little and then begin with the rehearsal. (The speaker is talking to himself.)
   - Альфред үз-үзен тыя алмыйча аның артыннан ашыкты. **Танышырга**, ничек кенә булса да **танышырга**. (Фоат Садриев, Адәм әүлиясе.) Unable to control (restrain)

himself, Alfred hurried after her. He must make her acquaintance. No matter how, he must get to know her.

c) An *emphatic advice, suggestion, instruction* given orally or in writing by a person or some other source, or displayed or published in the form of a *slogan.*

- ... Нәҗипне чыгарып җибәрделәр. «Йөрәк шаяргнны яратмый. ... йөрәгегез нык ук зәгыйфьләнгән. ... Бераз аруланауга Кавказга. ... тау һавасына барасыз. Даими һәйбәт **тукланырга**, болын һавасы **суларга**, чишмә суы **эчәргә**, **борчылмаска**, **кайгырмаска**, **кабаланмаска**, **ярсымаска**, үз вакытында шау-шусыз урында **йокларга**, вакытында **торырга**, ... Сезгә, авыру иптәш, хәерле юл телибез!» (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында?) ... they released Näjip (i.e., released Näjip from the hospital). ... "A heart condition is no joking matter (lit., The heart does not like to joke). ... your heart has been weakened quite considerably. ... Upon recovering a little you go to the Caucasus, ... where there is mountain air. Keep eating well, breathe meadow air, drink spring water, don't worry, don't grieve, don't do things in haste, don't get excited, sleep at the right time in a quiet place, rise in time ... We wish you, sick comrade, a happy journey!"
- ... шәкертенең тәмам сәламәтләнеп җиткән булуына ышангач, [профессор] үгет-нәсихәтен әйтте: бүтән **чирләмәскә**, аяктан егылганчы **чапмаска**, китаплар укуны, чит тел өйрәнүне **онытмаска**, ... (Гариф Ахунов, Идел кызы.) ... after being convinced that his student had completely recovered, [the professor] gave (lit., said) his advice: not to become ill again, not to run around until completely exhausted, not to forget to read books, to learn foreign languages, ...
- Нурсәнә. Рәхилә, теләсәң ни әйт, миңа синең ялтыравыклы түфлиең бер дә ошамый. Олтаны тотрыксыз. **Чыгарырга** да **ташларга** гына. (Хәй Вахит, Беренче мәхәббәт.) Nursänä. Räkhilä, say what you like, but I don't like your patent leather shoes. Their soles are weak. One just ought to throw them out.
- Үстерелгән уңышны, иң яхшы тәҗрибәне кулланып, ничек тиз һәм югалтусыз **җыеп алырга**. (Кызыл Таң, Но. 183, 1973.) How to gather (reap, harvest) the planted (grown) crop fast and without waste (loss), using the best experience.
- Йортларны тизрәк **төзергә**! (Кызыл Таң, Но. 165, 1973.) Build houses faster!
- Бүген – кичәгедән, иртәгә бүгенгедән яхшырак **эшләргә**. (Кызыл Таң, Но. 175, 1973.) Work (We must work) today better than (we did) yesterday, tomorrow better than (we did) today.

d) *Instructions, orders, conditions, rules,* set forth in (government) *decrees, resolutions, ordinances,* in *court orders,* in *contracts, agreements,* etc.

- ... гомуми белем бирү мәктәпләренең, ... урта махсус һәм югары уку йортларының эшчәнлеген тагын да яхшырту өчен чаралар **күрергә**. Биредә түбәндәгеләрне эшләүне кирәкле дип **табарга**: ... Мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында укыту-тәрбия процессын даими **камилләштерергә**, ... яшьләрне урта белем алуга тулырак җәлеп итүне **тәэмин итәргә**, кичке һәм читтән торып гомуми белем алу мәктәпләренең эшен **яхшыртырга**; ... (Кызыл Таң, Но. 169, 1973.) ... to take measures in order to improve still more the activities of schools providing general education, ..., specialized middle schools and establishments of higher learning. To regard here (lit., find) as necessary to carry out the following: ... constantly better the teaching and educational process in schools and in other educational establishments, ... ensure that the young be drawn more to getting secondary school education, improve the work of evening schools and of schools of general education offering correspondence courses, ...

*Note:* The above are excerpts from a government decree.

· – Ә хәзер, әйдәгез, әмерегезне болай төзәтик: «... шикаятьче Әбдиевнең дәгъвасын кире **кагарга**. Чалабай кызы Балҗанның Амантай Туктаров белән никахка керүе шәригатькә туры килүен **танырга**.» Шиһабетдинов ... аны рәсмиләштерүен көтеп торды да, шул кәгазьне тотып тышка чыкты. Амантай белән Балҗанга карап: – Менә сезгә никах таныклыгы! – диде. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) And now come on, let's correct your order this way: "... the claim of the plaintiff Äbdiev is to be rejected. The marriage of Baljan, daughter of Chalabai, and Amantai Tuqtarov is to be recognized as satisfying (the requirements of) the Shariat (i.e., the divine laws of Islam)." Shihabetdinov ..., waited for his (i.e., the official's) legalizing it and, seizing the document, stepped out of the room. Looking at Amantai and Baljan, he said, "Here is your Certificate of Marriage!"

*Note:* Collaborating with the plaintiff, the official had planned to declare the marriage illegal. But Shihabetdinov foiled their plan.

e) The infinitive in -рга, -ргә, etc. is used *in making inquiries, asking a question,* with or without the connotation of *possibility, obligation,* asking *advice, instructions,* in confirming *emphatically* one's own *statement.* In this function the infinitive may refer to a *specific person* denoted by a noun or pronoun in the *dative.*

Depending on intonation and context, the infinitive in -рга, -ргә, etc. may express various *emotions* such as a *strong desire, wish, embarrassment, apprehensiveness, desperation, fear, impatience, doubt.*

· Муса (әкрен генә бүлмәгә керә, Янгузовны күреп.) Исәнмесез? Җыентык турында **сөйләшергәме**? (Риза Ишморат, Үлмәс җыр.) Musa (slowly entering the room, he sees Yanghuzov). How are you? Is it about the collection of poems (i.e., are you here to talk)?

· Хәсәнов. Исәнмесез, әфәнделәр! Алиш. Газета **алыргамы**? Хәсәнов. Әйе. Яңаларын. (ibid.) Khäsänov. How are you, gentlemen! Alish. Getting the newspapers? Khäsänov. Yes. The new ones. (Alish asks the purpose of Khäsänovs' visit.)

· Алиш. Хәзер ничек инде, **сөенергәме** әллә **кайгырыргамы**? (ibid.) Alish. How is it now, can we rejoice or do we have to worry?

· – Бу эш белән **миңа шөгыльләнергәме**? – дип сорады Зөфәр. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "Shall I go to work on this matter?" Zöfär asked.

· Миңнулла. Садыйк, әйт әле, кая **барырга, нишләргә**? Кемнән ярдәм **сорарга** соң? ... Киңәш бир! **Нишләргә**, **миңа** кая **барырга**? (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Mingnulla. Sadiq, tell me, please, where to go, what to do? Whom to ask for help after all? ... Give me advice! What shall I do, where shall I go?

· – Бу эшкә хәзердән үк нигез салырга уйлыйм. Акча бар, дәрт бар, ник **эшләмәскә**? (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) "I am thinking of laying the foundation for this task right away. The money is there, the energy is there, (so) why not do it?"

· Шушы басу исләрен бер **иснәргә**. Үз чишмәбезнең суын бер **эчәргә**. Шушы агачларның яфрак кыштырдавын бер **тыңларга** ... әллә ниләр бирерлек булам. (Мөхәммәт Мәһдиев, Торналар төшкән җирдә.) Only once to smell the fragrance of that field. Only once to drink the water of our own spring. Only once to hear the rustle of the leaves of those trees ... I would be capable of giving anything.

· Фәрит сүз табалмый аптырап кала. Ни **диярга**? (Рашат Низамиев, Язмыштан көчлерәк.) Embarrassed, Färit is unable to find words. What to say?

· – ... сезгә куркырлык урын юк. – Ходаем, ... ничек **курыкмаска**! – диде Асия, ... (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "... you have no reason to be afraid." "My God,, ... how should one not be afraid!" Asiä said. (For the form куркырлык see 1233.)

- Хупҗамал. Әйтәсе сүзең бар икән, нигә инде аны тарткалап-сузгалап **торырга**? (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Khupjamal. If you have something to say, then why drag it out? (Khupjamal is impatient.)
- – Әйе. Гаебеңне танымау ул бит үзеңне төзәтергә теләмәү дигән сүз! Шуның өстенә тагын, шундый ук эшнең киләчәктә дә кабатланмавына ничек **ышанырга**?! (Гомәр Бәширов, Көннәрнең берендә.) "Yes. Not to admit your guilt means, after all, that you don't want to correct yourself! In addition to that, how can one believe that the same thing will not be repeated in the future?"

**[1155]** In a *dialogue* consisting of an *interrogative* or an *interrogative-exclamatory* sentence and an answer to it, the interrogative predicate verb may be repeated in the answer in the form of an *infinitive* in **-рга**, **-ргә**, etc. a) to *confirm* the action expressed by it, b) to *assure* the interlocutor that the action will not be carried out or that it will be carried out only as suggested or requested in the question. In the first case, the predicate verb in the question is in the *affirmative* or *negative*, the infinitive is in its *negative* form but has an *affirmative* meaning. In the second case, the predicate verb is in the *negative*, the infinitive is in its *affirmative* form but has a *negative* meaning.

Depending on the structure of the answer, the infinitive may or may not be preceded by the interrogative pronoun **ник** or **нигә**. Furthermore, an increased emphasis may be put on the answer by adding **ни** after the infinitive. Also, the answer may be preceded or followed by an explanation or a statement motivating or elucidating the confirmation or assurance.

a)
- – Ә син, Рәхимҗан, **бәхетлеме** соң үзең? ... – **Бәхетле булмаска**, мин үз авылымда ич, авылдашларым арасында. (Ринат Мөхәммәдиев, Беренче умырзая.) "And you, Räkhimjan, you are happy, aren't you?" "Of course I am happy. I am in my native (lit., own) village after all, among my fellow villagers."
- Әхтәм. Син әтиеңне **яратасыңмы**? Сайра. **Ник яратмаска**? Әти ич ул. (Туфан Миңнуллин, Ир егетләр.) Äkhtäm. Do you love your dad? Saira. Why shouldn't I? He is my dad after all.
- Укып чыккач, бездән: – Я ничек соң, **ошадымы**? – дип сорады. – Фатих абзыйга ошаган нәрсә безгә **ошамаска**?! (Зариф Бәшири, эамандашларым белән очрашулар.) After he finished reading it he asked us, "Well, how is it, did you like it (i.e., the story)?" "Of course, how can we not like something that uncle Fatikh likes!"
- Камилә (сискәнеп.) Әстәгъфирулла, кем бу? Сәйфи. Мин бу! Әллә **танымыйсыңмы**? Камилә. **Танымаска ни**. Фәхри малае Сәйфелмөлек бит. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Kamilä (started). God forgive, who is that? Seyfi. It's me! You mean you don't recognize me? Kamilä. Of course, I recognize you. You are Seyfelmölek, Fäkhri's son.
- Рафинад. Әби, ә син җырлый **беләсеңме**? Фәхрия. **Белмәскә ни**. Без җырлап үстек. (Туфан Миңнуллин, Яшьлегем – юләрлегем.) Rafinad. Grandma, can you sing? Fäkhriä. Of course I can. We grew up singing.

b)
- Айсылу. Анда бик озак **утырмассызмы** соң? Мин куркам. Горфай. Озаклап **утырырга ни**! Бер-ике чынаяк кына чәйләрен эчәрбез дә кайтырбыз. (Нәкый Исәнбәт, Миркәй белән Айсылу.) Aisylu. You won't stay (lit., sit) there for very long, will you? I'm afraid. Ghorfai. Of course, we won't stay long! We'll just have one or two cups of tea and then come back.

## The Infinitive in -рга, -ргә, -$^{о}$рга, -$^{о}$рга with «иде»

**[1156]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, **-$^{о}$рга**, **-$^{о}$ргә**, followed by **иде** (third person singular of the defective auxiliary verb **и-**) expresses a *strong wish* or *desire,* a *suggestion,* an *advice with a tinge of reproach, regret* or *repentance,* a *duty, obligation, necessity, need,* or *irony.* If indicated, the subject (the agent) is in the *dative.*

Depending on the context, the construction may refer to the past or present (moment of speaking).

- **Кычкырмаска, тавышланмаска иде миңа**, ә милициягә **хәбәр итәргә иде**. (Афзал Шамов, Якташым.) I should not have screamed and made a row, but I should have notified the police. (The speaker wishes that he hadn't acted the way he did and regrets it.)
- Ләрия. **Нишләргә иде миңа**?!! Нажия. Габбаска **ышанмаска** гына **иде**! (Аяз Гыйләҗев, Без унике кыз идек.) Läriä. What could (should) I have done? Najiä. You ought not to have believed Ghabbas.
- Гадилә. **Китмәскә иде сиңа**, балакай. Берәр ел читтән торып укып **карарга иде**. (Сәет Шәкүров, Мәхәббәт газабы.) Ghädilä. You should not go away, dear child. For one year you should try taking a correspondence course.
- Сүрия. Тыңлап бетер, бүлмә. **Безгә** күптән **аңлашырга вакыт иде** инде. **Сиңа** да миннән качып **йөрмәскә иде, миңа** да бу очрашуны **сузмаска иде**. (ibid.) Süriä. Hear me out, don't interrupt. We ought to have come to an agreement long ago. You shouldn't have kept running away from me, and I too shouldn't have delayed (postponed) this meeting.
- Ник соң әле мин ул йорттан алай ансат кына борылып чыгасы иттем? **Утырырга иде**, хәлләренә кереп бераз **сөйләшергә, сорашкаларга иде.** (Фатих Хөсни, Язмыш шуклыгы.) Why then did I decide to turn back so easily from that house? I ought to have sat (with them) and, showing (some) sympathy, ought to have talked, inquired a bit.
- **Миңа** беренче белән өченче сыйныфларны **укытырга иде**. (Эдуард Касыймов, Гомер ике килми.) I was to teach the first and third grades (lit., classes).
- Менә кемнәр белән **дуслашырга иде Фарукҗанга**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) Here are the men Faruqjan ought to make friends with.
- – Әһә, син әле лирик та икән, ... – **Сиңа** шигырьләр **язарга иде**, Ризван Актуганович. (Җәмит Рәхимов, Кыядагы чәчәкләр.) "Aha, it seems you are also a lyric poet, ... You ought to write poems, Rizwan Aqtughanovich." (Pronounced with irony.)

**[1157]** A *suggestion,* or an *advice* with the connotation of *reproach* may also be expressed by the infinitive in **-рга**, **-ргә** etc. followed by the *second* person *singular* or *plural* of the auxiliary verb **и-**. If indicated, the agent appears in the *nominative case.*

- – Бер-ике көн кунак **булырга идең**. (Азат Ганиев, Габделхак.) "You ought to stay as a guest for one or two days."
- Әхтәм ... – Аларны да **чакырырга идең**, бигрәк тулы мәҗлес булыр иде, – дип әрләде. (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) "You ought to have invited them too. It would have been a really complete party," Äkhtäm ... said, reproaching him.
- – Останы зинданга ябыгыз! – Әмирем, мин сездән моны көтмәгән идем, – диде Әхмәт ... –**Көтәргә идең, көтәргә идең**. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Илчегә үлем юк.) "Put the master in jail!" "My Emir (Amir), I hadn't expected that from you," Äkhmät said ... "You ought to have expected it, you ought to have expected it."

**[1158]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. with the *interrogative particle* **+мы**, **+ме**, first used in its *affirmative* form and immediately repeated in its *negative* form, indicates the agent's *undecidedness, hesitation* or *doubt* whether to carry out the action denoted by the infinitive.

In writing, both forms may be separated by a comma or be connected by a hyphen.

- [Кара киемле] кырыс кына берничә сүз әйтте: – Исмәгыль бай кәрван-сараенда! Унҗиденче бүлмә. Көтәм. – Һәм күтәрелеп тә карамыйча ашыгып китеп барды. «**Барыргамы, бармаскамы**?» Сәет икеләнеп калды. (Флүс Латыйфи, Хыянәт.) [The man in the black suit] said a few words in a rather severe voice: "In Ismäghil Bai's caravanserai! Room number seventeen. I'll be awaiting you." And without even raising his head and looking at him, he hurried away. Should he go or shouldn't he? Säyet was hesitant (undecided, doubtful).
- Мәдинә, төенчекне **чишәргәме-чишмәскәме** дип бераз икеләнеп торгач, чишәргә булды. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Mädinä hesitated a little whether to open the package or not and then decided to open it.

## The Infinitive in -рга, -ргә, -$^{o}$рга, -$^{o}$ргә, -маска/-мәскә with булу

**[1159]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. followed by **булу** in *any person,* most frequently in the *indicative past tense* I, less often in other tenses and moods or as a verbal adverb, mostly expresses the agent's *decision, intention* to carry out or not to carry out, the action denoted by the infinitive. However, depending on the context, the construction can also indicate a *promise,* or *consent.*

- – ... ул бик әйбәт кеше, әни, каршы килмә, мин аңарга кияүгә **чыгарга булдым**. (Фатих Хөсни, Гыйльмениса.) "... he is a very nice man, Mother, don't oppose it, I have decided to marry him."
- Йолдыз. Хатыңны укыдым, Харис. Ләкин җавап **язмаска булдым**. (Гамир Насрый, Кушнарат.) Yoldyz. I read your letter, Kharis. But I decided not to answer it.
- Сәфәр. Син беркая да **бармаска булдыңмыни**, Фатыйма? (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Säfär. Then you decided not to go anywhere, Fatima?
- Аның соравы буенча Гарифә карчыкның кәҗәсе белән тавыкларын карап **торырга булды**. (Әмирхан Еники, Әйтелмәгән васыять.) Upon her request, Gharifä consented (promised) to look after the old woman's goat and chicken.
- Шунда ук ашау-эчү дә тәкъдим ителде. Ләкин без башта чыгып, йөреп **кайтырга булдык**. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) We were at once offered food and drink. But we decided to first go outside and take a walk.
- Вакытны **сузмаска**, шунда ук эшкә **тотынырга булдылар**. (Җәмит Рәхимов, Кыядагы чәчәкләр.) They decided not to delay but to begin work immediately.
- Артык чыдап тора алмый, Гыймран яшеренгән җиреннән **чыгарга була**. (Хәй Вахит, Ике килен-килендәш.) Unable to bear it any longer, Ghimran decides to come out of his hiding place.
- Тоташ бер саташу кебек иде ич болар. Әйтерсең берсе дә аның кызы авызыннан чыккан сүзләр түгел. Әйтерсең дә аның бердәнбер кызын җен алыштырып куйган да, шул – ананың түземлеген сынап **карарга булган**. (Ринат Мөхәммәдиев, Кенәри – читлек кошы.) These (words) were really like a constant delirium. It was as though not one of them were words coming from her daughter's mouth, as though a demon had substituted for her only daughter and wanted to test the mother's patience.

- Кайберәүләр: – Закир адәм күзенә күренергә оялганлыгыннан әллә кайсы якка эшкә чыгып киткән икән, ул инде тиз генә **кайтмаска булган** ... диләр. (Мәҗит Гафури, Кара йөзләр.) Some people say: "Because he is ashamed to show himself to people, Zakir, it seems, went away to some place to work. He has decided (they say) not to return anytime soon."
- Фазыл. Ул килер микән соң? Гөлзадә. **Килергә булган иде**. (Риза Ишморат, Гөлзадә.) Fazyl. Then she will come? Gölzadä. She had intended (promised) to come.
- – Сезнең ачык фикерегез юк иде бит әле башта сөйләшкәндә. **Киңәшергә**, кемнәр беләндер **сөйләшергә булган идегез**. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) "When talking first (i.e., When we first talked) (about it), you did not yet have a clear opinion after all. You (had) wanted to consult, talk with some people."
- – Булмас, булмастыр синеңчә, Туйбикә. Сине яраткан идем, яраткан идем. Ә углыңны барыбер Бөек Калага **озатырга булыр**. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Илчегә үлем юк.) "It will be impossible, it will be impossible as you would have it (happen), Tuybikä. I really did love you. But nonetheless, I'm going to have your son sent off to the Great City." (With the intention to have him killed on the way in an 'accident'.)
- Кичкә **килергә булып** китте. (Барлас Камалов, Узган гомер бигрәк жәл.) He left, intending to come again in the evening.
- Алар икәве дә шуннан тәмам акылга утырып, моннан соң тату **торырга, кычкырышмаска булып** кайтканнар. (Мөхәммәт Гали, Хатын җиңде.) Both of them returned from there (as they say) completely sobered, and promising that, after this, they would be peaceable and not quarrel again with each other.
- – **Эшләргә булгач**, эшләргә кирәк, эшлисегез килмәсә, кичә үк баш тартасыгыз бар иде, – диде Әхмәтнуров, (Мәдинә Маликова, Басып сайрар талы бар.) "Since you have decided to do it, you must do it. If you don't want to do it, you should have declined yesterday," Äkhmätnurov said.
- Гөлбану. Каза **килергә булса**, аяк астыннан гына килеп чыга бит, ул. (Шәриф Камал, Ут.) Gölbanu. If a misfortune (disaster) is bent on happening, it's going to happen quite unexpectedly.

**[1160]** The *affirmative* infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. followed by **булу** in the *third person singular* of the *present* (була), the *continuous past* (була иде), the future I (булыр), and the future I with **иде** (булыр иде), expresses the *possibility* to perform the action denoted by the infinitive. The construction can be *impersonal-indefinite,* or it can refer to a *specific agent.* If indicated, the latter is in the *dative case.*

- Күрәм, башкортлар. Димәк, татарча **сөйләшергә була**. (Мирсәй Әмир, Без бәләкәй чакларда.) They are Bashkirs, I see. That means, one can speak to them in Tatar.
- Тәлгать. Әбсәләм, сезнең белән кайчан **сөйләшергә була**? (Хәй Вахит, Беренче мәхәббәт.) Tälghät. Äbsäläm, when will it be possible to talk with you?
- – Ишеткән идем, Салихтан күп нәрсәгә **өйрәнергә була**, – диде ул ... (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) "I have heard that one can learn many things from Salikh," he said.
- ... бирედә Хәзәр диңгезе ягыннан килгән, озын юл узган Багдад сәүдәгәрләренең дә, Кара диңгез аша килгән Рум сәүдәгәрләре корабларын да **күрергә була иде**. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Илчегә үлем юк.) ... here one could (usually) see ships of Baghdad merchants which had come a long way from the Caspian Sea, as well as ships of Greek merchants which came via the Black Sea.
- ... почмакта тезелеп торган кечкенә-кечкенә агач хәрчәүнәләрнең кайсысына керсәң дә ун тиенгә туйганчы шулпа **эчәргә**, туйганчы ботка **бүсәргә була иде**. (Мирсәй Әмир, Казан.) ... if you went (one went) into any of the tiny wooden eating houses

which stood in a row at the corner ... you (one) could, for ten kopecks, eat your (one's) fill of soup (or) gorge on porridge.

- Димәк, кыз кичә сөйләшкән сүзне бүген онытa торганнардан түгел икән, «**эшләргә булыр** ул кыз белән» дип, күңеленнән уйлап куйды Айдар. (Фатих Хөсни, Авыл өстендә йолдызлар.) That means, it turned out that the girl was not one of those who forget today what they have said yesterday. "It will be possible to work with that girl," Aidar thought by himself.
- Әбсәләм. Ул урман буйлап китте. ... Ай, алданрак килгән булсагыз! Әле генә китте. Йөгергәндә артыннан куып **җитәргә** дә **булыр**. (Хәй Вахит, Беренче мәхәббәт.) Äbsäläm. She left by way of the woods. ... Oh, if you had come earlier! She left just a little while ago. If you run, it will be possible (you will be able) to catch up with her.
- Билгеле, ул әсәрне Казанда басыла торган берәр журналга, я газетага **җибәрергә** дә **булыр иде**. ... Әмма мине ул ягы һич кызыксындырмады. (Гомәр Бәширов, Тормыш сукмаклары.) Of course, it would also have been possible to send that (literary) work to some magazine or newspaper issued in Kazan. ... But that aspect of it did not interest me at all.
- – **Миңа** берәр атнадан тәҗрибәләр **башларга булыр иде**. (Атилла Расих, Ике буйдак.) "I would be able to begin the tests in about one week."
- **Миңа** ул квартирдан **котылырга**, бер бүлмәлене генә сорап **алырга**, һич югы, **алышырга булыр иде**. (Мәхмүт Хәсәнов, Кама таңнары.) It would be possible for me (I would be able) to get rid of that apartment and to request one with only one room (or) at the worst (at least) to exchange it.

**[1161]** The *negative* infinitive in **-маска**, **-мәскә**, followed by **булу** in the *third person singular* indicates that the action *need not be carried out.* The acting person or thing is in the *dative case* but may also not be indicated. In the latter case the context determines the person referred to.

- Хәер, **аңа** бүген эшкә **бармаска** да **була**, ... (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) By the way, there was no need for her to go to work today, ...
- – Юк, иптәш ..., **хафаланмаска була**. Эшләр тәгәрәп кенә бара! – диде. (Гомәр Бәширов, «Иске будильник» көйсезләнә.) "No, comrade ..., you need not worry. Things are going just fine," she said.
- – Монысына **шикләнмәскә була**. (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем элмәге.) "About that one can have no doubt."

## The Infinitive in -рга, -ргә, -ырга, -ергә with the Verbs калу, итү, тору, йөрү, тотыну, the Verbal Adverb дип, the Verbal Noun икән(лек), and the Modal Words бар, юк, түгел

**[1162]** The infinitive in **-рга**, **-ргә** etc. with **калу** 'to stay, remain' in the *third person singular* indicates that the subject has no choice but to carry out the action expressed by the infinitive. If indicated, the agent appears in the *dative case.*

- Фатыйма. Озакламый барысы да әзер була. Аннан соң кунакларны **көтәргә** генә **кала**. (Кәрим Әмири, Таң вакыты.) Fatima. Soon everything will be ready. And then all that remains for us to do is to wait for the guests.

- Садыйк. Биредә артык сөйләп **торырга** да **калмады**. Хат бөтен нәрсәне ачып салды. (ibid.) Sadiq. There remains nothing more to say here. The letter has stated everything clearly.
- Хәкимҗан. ... синең яшьлегең узмаган әле, ... Күңелеңә ошаган ирнең башын-күзен әйләндерә аласың. Минем хәлләр башкачарак бит, Хупҗамал. **Миңа** шул эчтән генә ут йотып **йөрергә кала**. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Khäkimjan. ... your youth is not past yet, ... you can turn the head of any man your heart desires. My situation is somewhat different after all, Khupjamal. I have no choice but to keep suffering within myself.

**[1163]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. with the verbal adverb in -a of **калу** – **кала** – or with a conjugated form of **калу** indicates the *time* remaining until the action expressed by the infinitive takes place.

- Бәйрәм **башланырга** ике-өч көн **кала** Идел буе кибетләр белән тулды. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Илчегә үлем юк.) Two or three days before the start of the holiday the banks of the Volga filled with shops.
- Озын тәнәфестән соң дәрес **бетәргә** ун-унбиш минут **кала**, ... (Газиз Кашапов, Җир җылысы.) After the long recess, ten or fifteen minutes before the end of the lesson, ...
- Мәҗлес **башланырга** бер сәгать **каларак**, ... (Изаил Зарипов, Туган көн.) Approximately one hour before the beginning of the party, ...
- Ниһаять, кайтыр көннәрне зарыгып көтәр чаклар җитте. Хезмәте **бетәргә** өч ай **калды** ... (Фоат Садриев, Таң җиле.) Finally, the time drew near when he would long for the days he could return home. Three months remained until the end of his (military) service ...

**[1164]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. with **итү** ‘to do, make’ in *any person* and mood indicates that the agent *intends, endeavours, attempts* to carry out the action. The construction is often used in situations in which the agent wants, intends or attempts to perform the action, but due to some outside obstacles or adverse circumstances or conditions, does not succeed or succeeds only partially in doing so.

- Егетләрнең берсе аны куып **тотарга итте**, ләкин Котбый аны туктатты. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) One of the young men wanted to chase after her and catch her, but Qotbi stopped him.
- Кәримәгә өч яшь тулгач, әтисе кызны балалар бакчасына **илтергә иткән иде**. Юлия Борисовна бирмәде. (ibid.) When Kärimä completed the third year of her life, her father had wanted to take her away to the kindergarten. Yulia Borisovna didn’t let him.
- Мин **торырга итеп** ике терсәгемне дә түшәккә кададым. Тик – башны ничек мендәрдән аерырга? (Хәсән Сарьян, Җәза.) Wanting (trying) to get up, I propped both my elbows on the bed. But how to raise (lit., separate) my head from the pillow?
- Мәҗлесләргә йөртәләр үземне. Гозерләп /ʤөzerləp/ – ялварып чакыралар. **Бармаска итсәм**, үпкәлиләр, ... (Барлас Камалов, Узган гомер бигрәк җәл.) They make me go to parties (to play the accordion). They invite me, beseeching and imploring me. If I try to get out of going (If I try not to go), they get angry, ...
- Галиәкбәр ни әйтергә белмәстән, өнсез калды. Ул **елмаерга итте**, ләкин анысы да барып чыкмады. (Атилла Расих, Сынау.) Ghäliäkbär was dumbfounded, not knowing what to say. He tried to smile, but that too didn’t succeed.
- Икенче берәү минем чалбар кесәләремне актара иде. Мин **торырга иттем**, тар маңгай хәнҗәрен бугазыма терәде: – Селкенәсе булма, ... (Гурий Тавлин, Афәт.) A

second one was searching my trouser pockets. I tried to get up, but the fellow with the narrow forehead put his dagger against my throat, "Don't move, ..."

- Хушлашканда, Тәлгать аны **үбәргә иткән иде**, Сания башын читкә борды, һәм Тәлгатьнең ирене аның салкынча бит алмасына тиде. (Әхәт Мушинский, Кайту.) When they parted, Tälghät had wanted to kiss her, but Saniä turned her head to the side, and Tälghät's lips touched her cool cheek.
- Тынгысыз һәм ыгы-зыгылы фани бу дөньяга мин шушы гасырның нәкъ башында **килергә иткәнмен**, нибары бер генә атнага соңга калынган, ягъни 1901 нче елниң 7 нче гыйнварында туганмын. (Гомәр Бәширов, Тормыш сукмаклары.) I had intended to come into this restless, bustling, perishable world exactly at the start of the century. I came just one single week too late, i.e., I was born on the 7th of January, 1901.

**[1165]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, **-$^{o}$рга**, **-$^{o}$ргә** with **тору** 'to stand, live, dwell' in *any person* indicates that the subject *is about* to carry out the action expressed by the infinitive.

- Исхак. – Нигә аны үземнән генә сорамадың, әнкәй? – дип үпкәләде. Үзеңнән дә **сорарга торам**, нигә өйләнмисең? (Аяз Гыйләҗев, Берәү.) Offended, Iskhaq asked, "Why didn't you just ask me about that, Mommy?" "Well, here I am asking you now, why don't you get married?"
- Яңгыр **яварга тора**. It is about to rain.
- Алар өчен барыбер – кем нинди эшкә чакырса – шунда **китәргә торалар**. (Шамил Бикчурин, Тирән катлам.) To them it's all the same. To whatever work anyone calls them, they are ready to go.
- – Ярый, әни, **үпкәләргә торма**. (Әмирхан Еники, Рәшә.) "All right, Mother, don't be offended."
- – Ярый әле кердең, чакырып **сөйләшергә дип тора идем**. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) "Good that you came in. I was just about to call you and have you over for a talk."
- Абдулла инде бүгенге дәресләрен бетереп, өенә **кайтырга дип торганда**, мәдрәсәгә башында Яхъя торган бер төркем шәкерт килеп керде. (Җәмит Рәхимов, Батырша.) Having already finished his classes (lit., lessons) for the day, Abdulla was just about to return home when a group of students led by Yakhya (John) entered the medrese.

**[1166]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, **-$^{o}$рга**, **-$^{o}$ргә** with **йөрү** 'to walk' indicates that the agent *is about, is preparing, getting ready,* or *wants, intends* to carry out the action expressed by the infinitive.

- Мин үзебезнең Шөмбеттә техникумны тәмамлап, укытучы **булырга йөрим**. (Эдуард Касыймов, Гомер /Ojөmer/ ике килми.) Having finished the technical school in our (village of) Shömbet, I am preparing to become a teacher.
- Шәриф. Кая барасың? Тимергали. Тагын бәхет эзләргә читкә **китәргә йөрим**. (Таҗи Гыйззәт, Чаткылар.) Shärif. Where are you going? Timerghäli. I am preparing (getting ready) to leave for other places to try my luck again.
- – Мин әллә кайчаннан инде сезгә рәхмәт **әйтергә йөрим**. (Аяз Гыйләҗев, Зәй энҗеләре.) "I have been meaning to thank you for a long time now."

**[1167]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, **-$^{o}$рта**, **-$^{o}$ртә** followed by **тотыну** 'to hold to', 'to undertake', 'to set about' in *any person* indicates the beginning of an action.

- Халык гөрләп кул **чабарга тотынды**. (Атилла Расих, Ямашев.) The people began to clap their hands loudly.

- Балалар ... китапны кулдан кулга йөртеп **карарга тотындылар**. (Сафа Сабиров, Улым кайткач.) The children ... began to look at the book, passing it from hand to hand.

**[1168]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. followed by the verbal adverb **дип** expresses *purpose.*

- Юк, бүген ул алар янына бөтенләй башка нәрсәләр турында **сөйләшергә дип** килгән иде бит. (Ләбибә Ихсанова, Юл кешесе.) No, today she had come to them to talk about completely different things.
- Әнинең кулыннан самавыр капкачы төшеп китте. Яңа хәбәрне **әйтергә дип**, ул әти янына сарайга йөгерде. (Гариф Ахунов, Чикләвек төше.) The samovar lid fell from Mother's hand. She ran to Father, to the shed, to tell him the news.
- Сәйфи. Синең белән **саубуллашырга дип** килдем. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Seyfi. I have come to say goodbye to you.
- – Мин сезне **өйрәтергә дип** түгел, мин сездән **өйрәнергә дип килдем**. (Фатих Хөсни, Мәйдан.) "I came here not to teach you but to learn from you."

**[1169]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, **-$^{о}$рга**, **-$^{о}$ргә** followed by the verbal noun **икән**(**лек**) indicates a *necessity, duty.*

- – Миңа **нишләргә**? – **Нишләргә икәнен** чыккач әйтермен, Мансур. Көтеп тор! (Мәгъсүм Насыйбуллин, Ярканат.) "What am I to do? (What do you want me to do?)" "I'll tell you what to do after I come back (lit., out) (i.e., out of the building), Mansur. Just wait."
- «Көтү башы» дип атап йөртә торган берничә сыер бар – ... эти, шул сыерларга, исемнәре белән кычкырып, кая **барырга икәнен** әйтә, ... (Галимҗан Ибраһимов, Көтүчеләр.) There are several cows called "leaders of the herd" – ... calling them by name, Father tells those cows where to go (where they must go), ...
- – Ашыгам мин. Әйдә, кузгалыйк тизрәк?! ... – ... – Сәер кеше син, ... Кая **барырга икәнне** әйт! – Ә-ә, – диде Фидаил уңайсызланып, үзе гаепле икән ич. – Аккош күленә! (Ринат Мөхәммәдиев, Кенәри – читлек кошы.) "I am in a hurry. Come on, let's go quickly!" ... "You are a strange fellow ... Tell me, where you have to go!" "O-o-h," Fidail said, embarrassed. He himself was at fault after all. "To Aqqosh Lake (Swan Lake)!"
- – Капкаев та телен тыйсын! Юкса минем белән ничек **сөйләшергә икәнлекне** күрсәтермен үзенә. (ibid.) "Kapkayev too shall (must) restrain his tongue! Otherwise I am going to show him how to talk (how one must talk) with me." (The speaker is settling a quarrel between Kapkayev and another person.)

**[1170]** The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. followed by one of the *modal words* **бар**, **юк**, **түгел**.

1. Followed by **бар** or **юк**, this construction:

a) Expresses *possession* of, or *lack of,* things needed or commonly used to carry out the action denoted by the infinitive.

- Мөршидә. Син нигә ындырда түгел, Мәхмүзә? Мәхмүзә. Өстемә **киярга юк**, җаным. Мөршидә. Базарга ... **йөрергә бар**? Мәхмүзә. Кеше сүзе ул, җаным, кеше сүзе. (Риза Ишморат, Кайту.) Mörshidä. Why are you not in the barn, Mäkhmüzä? Mäkhmüzä. I have nothing to wear, my dear. Mörshidä. (But) you have something to wear to go to the market ... Mäkhmüzä. That's just talk, my dear, just talk.

- Кучкарда янып утырган лампа төти башлады. – Кадалгыры, керосины бетә. **Барырга вакыт юк**. (Әнәс Галиев, Авылдашлар.) The lamp which was burning on the stove ledge began to give off smoke. “The deuce take it, it’s running out of oil. I have no time to go (and buy oil).”

b) Indicates that it is *necessary* or *unnecessary, needless* to carry out the action.

- Юлларның начарлыгын **әйтергә** дә **юк**. It is needless to say that the roads are bad.

*Note:* In the literary language, the more common form is ... әйтеп тә торасы юк.

c) Indicates *permission* or *denial of permission* to carry out the action.

- Мәрьям. Аһ, алай икән. Менә, Мәрьям, ишетмәсәң ишет, тыгылма, хакың юк. Аш пешерергә, кер уарга, идән юарга хакың бар синең. Ә совхоз эшләре турында сузеңне **әйтергә юк**. (Хәй Вахит, Карлыгач канат кага.) Märyäm. Ah, that’s how it is. Here, Märyäm, just listen, don’t interfere, you have no right (permission). You may (have the right/permission to) cook the meals, do the washing (laundry), scrub the floor. But you can have nothing to say about matters concerning the state farm. (Expresses a connotation of disagreement, dissatisfaction.)

d) The infinitive in **-рга**, **-ргә**, etc. followed by **бар** may indicate the *amount of time* remaining until the action expressed by the infinitive will take place.

- Зәйтүнә **кайтырга** әле шактый вакыт **бар иде**. (Әнәс Галиев, Авылдашлар.) There was still plenty of time until Zeytünä’s return (i.e., return from work).

2. Followed by **түгел**, the construction emphasizes the action, condition or state denoted by the infinitive, both in the affirmative or negative sense.

- Сәгъдетдин белән Гыйззәтбану чоланда йоклыйлар. Өйләре тәбәнәк, кысан, эссе көннәрдә өй эче ут булып кыза, тәмам **керерлек** түгел. (Якуб Зәнкиев, Иртеш таңнары.) Säghdetdin and Ghizzätbanu sleep in the storeroom. Their house is low and small. On hot days the inside of the house heats up like fire. It is practically impossible to enter it.
- Хәйдәр Кушкүпергә кергәндә, караңгы төшкән иде инде. Ләкин хәтердә сакланган таныш йортларны **танымаслык** ук караңгы да түгел иде әле. (Әбрар Шәмин, Сагындырган сукмаклар.) When Kheydär entered Qushküper, darkness had already fallen. But it was not yet so dark that he could not recognize the familiar, well-remembered houses.
- Вәзир. ... – Бу теләктән кире чиген, бу – башкарып **чыгарлык** эш түгел, – диде. (Мәҗмугы-л-хикәят, Җәйсур хикәяте.) The visir said, “Give up this wish. This is a thing that cannot (i.e., is not feasible to) be realized.”
- Эссе, яфрак **селкетерлек** тә җил юк. (Зөфәр Фәтхетдинов, Ачылган серләр.) It is hot and there is not wind enough to stir (i.e., no wind which could stir) a leaf.
- Шәһәрдә **торырлык** акча да, эш тә юк. (Кәрим Тинчурин, Бишенче мәрҗән.) He has neither money nor work which would (could) enable him to live in the city.
- Юлга чыгуның икенче көнендә, ... Хәсән адәм уза **алмаслык** сазлыкларга килеп җиткән иде инде. ... Хәсән **үтәрлек** юл эзләп сак кына эчкә дә кереп карады. (Атилла Расих, Бәхет орлыклары.) On the second day after setting out on his way, Khäsän had already come to some swamps which it was not humanly possible to cross. ... Searching for a way to get through, Khäsän tried stepping in cautiously.
- – **Киярлеге** калмаган, – диде кыз, ... – **Киярлек**, – диде Җәмил, ... (Аяз Гыйләҗев, Әтәч менгән читәнгә.) “You can’t wear it (It isn’t suitable for wearing) anymore,” the girl said, ... “You can wear it (It is suitable for wearing),” Jämil said, ...
- **Киңәшләшерлек** бүтән бер кеше юк. Димәк, минем үземә уйларга кирәк, бик нык уйларга. (Әхсән Баянов, Яшьлегемне эзлим.) There is no other person with whom I can consult. That means, I must think for myself, think very hard.

- Ишегалдына машина **керерлек** түгел иде – капка төбенә бушаттылар. (Фәнис Яруллин, Кыйгак, кыйгак, каз кычкыра.) It wasn't possible for the truck to enter the yard, so they unloaded it at the gate.
- Нәрсә генә юк бирәдә! Кием-салым, йорт кирәк-яраклары, төрле-төрле эш кораллары, сабын, ислемай – барысын да әйтеп **бетерерлек**, санап **чыгарлык** та түгел. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) What isn't there here! Clothing, household goods, various tools, soap, perfume; it is practically impossible to mention or to count all of them.
- Икесе дә кызгылт чырайлы, җитен чәчле, җитмәсә тагы, зәп-зәңгәр күзләләр – тәмам абыйлы-сеңелле **диярлегең** бар. (Эдуард Касыймов, Җир балкышы.) Both have a reddish (or: pinkish) face, flaxen hair, and what's more, very blue eyes. You might well have said that they were brother and sister. (They are not.)
- Ләкин җавабы ике ай үткәч – апрель урталарында гына килде. Хат **язарлыгы** булмаган күрәсең. (Хәсән Сарьян, Бер ананың биш улы.) But her answer came only after two months, around the middle of April. She had been unable to write (a letter), it seems.
- – Нинди дәлилләрең бар? – Әле хәзергә зурлары, кире **кагылмаслыклары** юк. Ләкин шулай да **уйландырмаслык** ук түгел. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "What evidence do you have?" "Up to now no important evidence, none which cannot be refuted. But still, it (i.e., the opinion the speaker has given before) isn't so unthinkable."
- Көлтә бирүче Учавыл картның күзе шешеп, ... килә алмаган бичара. Алыштырырга башка ир-ат юк, **алмаштырырлыклары** да каядыр киткән булып чыкты. (Батулла, Юл буенда зәңгәр чәчәк.) The eyes of the old man Uchawyl, who fed the sheaves (into the threshing machine), were swollen, ... the poor man couldn't come. There was no other man to replace him, (and) those who could (would be able to) replace him turned out to have gone off somewhere.
- Исламның **танырлыгы** калмаган. Ләйләне күргәннән бирле әллә нәрсә булды егеткә. (Мәхмүт Хәсәнов, Инженерлар.) You could hardly recognize Islam. Since he had seen Leylä something had happened to the young man.
- Штумпф. Я, тиз бул! Бушат урынны! Алексеев. Кемнәр өчен? Нинди кадерле кешеләр килә ул кадәр мин урын **бирерлек**? (Риза Ишморат, Үлмәс җыр.) Shtumpf. Now, quick! Vacate the place (bed)! Alekseyev. For whom? What exalted people are coming that I even have to give up (my) place (bed)?
- **Уйланырлык** иде Иоанн Фасианга. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кубрат хан.) Yoann Fasian had to do some thinking.

**[1234]** The verbal adjective in **-рлык/-маслык**, etc. followed by **булу** in the *indicative, imperative,* or as a *verbal adverb,* indicates that the action or state expressed by the *verbal adjective is* or *becomes possible* or *impossible* due to the action or state denoted by the *principal verb* or as *elucidated in the context.* With **булу** in the *conditional*, the construction expresses a *condition* with the connotation of *possibility* or *impossibility.*

- Тиздән караңгылык тагын куера төште һәм тире-юньдә берни дә **күренмәслек булды**. (Сафа Сабиров, Гәрәйнең бер җәе.) The darkness quickly intensified still more, and all around everything became indiscernible (everything became impossible to discern).
- – Менә болай, кем, Рәхим, соңыннан әйтмәдең **диярлек булмасын**, сиңа сүзем шул, – диде Габдуллаҗан бүлмәгә кереп. – Сезне кышка бүлмәбездә калдыра алмыйбыз. (Атилла Расих, Ике буйдак.) "Look here ... er ... Räkhim, I don't want

you to be able to say afterwards that I didn't tell you. Here is what I have to tell you," Ghabdullajan said, entering the room, "We cannot let you (i.e., Räkhim and his two children) stay in our room until winter."

*Note:* The verbal adjective of **дию** – **диярлек** – 'one can say', 'it is possible to say' is also used as a particle (see 692), meaning 'almost', 'nearly'. For example:
Зилә. Менә бу турыда мин берни дә белмим **диярлек**. (Аяз Гыйләҗев, Без унике кыз идек.) Zilä. Now, about that I know almost nothing.

- Ык суы **коенырлык булып** җылынып җитмәгән әле. (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) The water of the (river) Ik had not yet warmed up sufficiently to permit bathing (to make bathing possible).
- Рузанов. Туктатырга кирәк аларны бу хәвефле юлдан. Зөлфәт. Булмый. ... Аларны туктатырлык көч миндә юк. Сүзең **үтәрлек булса**, сөйләшеп кара. (Габделхәй Сабитов, Чулпан таңны уята.) Ruzanov. We must stop them on this dangerous road. Zölfät. Impossible. ... I don't have the strength (power, authority) to stop them. If your word can get through (to them), try to talk to them.
- Хупҗамал. ... кайтышлый безгә кереп чык әле, яме? Гөлбикәне ничек итеп озатканнарын сөйләрсең. **Керерлек булсаң**, самовар куеп торам. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Khupjamal. ... please, drop in on us on your way back, will you. You'll tell me then how they saw Gölbikä off. If you find it possible to drop in, I'll put up the samovar.
- Ильяс. ... Сез тагы бу эшне үз файдам өчен эшли дип уйлый күрмәгез, бәлки, сезгә шулай дип әйтүчеләр дә булыр. Әгәр дә алай **уйларлык булсагыз**, бер тиенегез дә кирәкми. (Кәрим Тинчурин, Назлы кияү.) Ilyas. ... Now, please, don't think that I am doing this thing for my own advantage. Perhaps there will be people who will tell you that. If you come to think like that, I don't want (need) one kopeck from you.

**[1235]** The verbal adjective in **-рлык**, etc. followed by **итү** expresses the *manner* in which the performance of the action is made possible or impossible, or, simply, that it is made possible or impossible.

- Язасы иде. ... **соklандырлык итеп** язасы, кешеләрнең йөрәкләренә үтеп **керерлек**, күз яшьләрен **чыгарырлык**, шатланып **елмаерлык, көләрлек итеп**, (кыскасы), укучы чын мәгънәсе белән **ләззәтләнерлек итеп** язасы иде. (Гомәр Бәширов, Көзге ачы җилләрдә.) One ought to write. ... one ought to write so that it can give delight, can penetrate the hearts of people, can draw tears, can make people glad, make them smile, laugh, (in brief), one should write so that the reader can truly experience pleasure.
- Хупҗамал. ... Илләмәгәр үзенә дә бирдем инде кирәгеннән! Гөлбикә. Кемгә? Хупҗамал. Кемгә булсын, Шалапаевка. Безнең авылга аяк **басмаслык иттем** үзен. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Khupjamal. ... However, I have already given him what he deserves! Gölbikä. Who? Khupjamal. Who do you think, Shalapayev. I made it impossible for him to (ever) set foot in our village (again).

*Note:* The verbal noun/infinitive in **-у**, **-ү** (**-ю**) may be augmented by the suffix **+лык**, **+лек**. This form, which is used rather infrequently, has a meaning similar to that of the verbal adjective in **-рлык**, **-рлек**, etc. For example:
**Сатулык** та, **ашарлык** та балык эләгә башлагач, бабайның көн күреше яхшырып китә. (Татар халык әкиятләре, Тире Такыя.) Since enough fish to sell as well as to eat have begun to be caught, the old man's life is getting better.

## The Verbal Adjective in -гыч, -геч, -кыч, -кеч

**[1236]** The verbal adjective in **-гыч**, **-геч**, **-кыч**, **-кеч** is formed by joining the above suffix to the verb stem. It conveys the notion that the action or state expressed by the verb stem to which it is attached can be carried out.

- Күзне **чагылдыргыч** кояшлы көн иде. (Әхәт Гаффар, Яшиселәр алда иде әле.) It was a day so sunny as to irritate the eyes.
- Без бу кайгылы кешегә нинди генә киңәш бирә алабыз соң? Йөрәк **өзгеч** әче хәбәрне матур итеп әйтеп буламы? (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) What kind of advice can we give then to this despondent person? Is it possible to convey (lit., tell) heartbreakingly bitter news (bitter news which can break a heart) in a pretty way?
- Тышта **искиткеч** матур көн. (Мәхмүт Хәсәнов, Инженерлар.) It is an amazingly beautiful day out (outdoors).
- Казакъ сахраларында **эчпошыргыч** бертөрлелектән узган көннәре аңарда мондый матурлыкка карата чиксез сагыну хисләре уяткан иде ... (Атилла Расих, Ямашев.) The days he passed in boring monotony (monotony which can bore) in the Kazak steppes had awakened in him a boundless yearning for such beauty (i.e., the beauty he was now seeing).

**[1237]** The verbal adjective in **-гысыз**, **-гесез**, **-кысыз**, **-кесез**.
This verbal adjective is formed in the same manner as that in **-гыч**, **-геч**, **-кыч**, **-кеч**. It indicates *impossibility.*

- Урам – киң, ап-ак ком белән түшәлгән. Җәйләрен биредә хәтәр өермәләр уйный, күз **ачкысыз** ком бураны була иде. (Атилла Расих, Ямашев.) The street is broad; it is covered (lit., paved) with sand white as snow. In summer dangerous eddies play here, blinding sand storms occur (sand storms which make it impossible to open the eyes).
- Ярый әле җил төньяктан исә. Юкса Бакалтай ягыннан иссә, Яңа бистәдә һаваның тын **алгысыз** булганлыгын Хөсәен бик яхшы белә. (ibid.) It's a good thing that the wind is blowing from the north. But Khösäyen knows very well that when it blows from the direction of Baqaltai, the air in the New Suburb is (almost) impossible to breathe.
- Ул әйтеп **бетергесез** шат иде. (Атилла Расих, Ике буйдак.) He was indescribably happy.
- Кеше – табигать баласы һәм ул табигать белән **аерылгысыз** бәйләнгән. (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) Man is a child of Nature, and he is inseparably tied to nature.
- Төнлә аз гына яңгыр явып үзган иде, ә монда, Акмула урамнарында, аяк **атлагысыз** саз, ... (Ибраһим Салахов, Тайгак кичү.) During the night it had rained just a little, but here, in the streets of Aqmula, there is mud, making it practically impossible to walk, ...
- Хәзер түзеп **булгысыз** эссе, бөркү. (Миргазиян Юныс, Юлда уйланулар.) Now it is unbearably hot and sultry.

# CHAPTER XXV – REDUPLICATIONS

## Reduplications of Parts of Speech other than the Verbal Noun in -у, -ү (-ю)

**[1238]** Like the reduplicated verbal noun in **-у**, **-ү** (**-ю**) discussed in 1206, other parts of speech may be reduplicated in a similar manner. They are most frequently used in dialogue or monologue. In dialogue, the reduplication in the reply is usually based on the same word used by the interlocutor, and the meanings of such constructions are about the same as those with the verbal noun (i.e., they indicate emphasis and concession.)

Parts of speech other than the verbal noun in **-у**, **-ү** (**-ю**) are reduplicated as follows:

a) One of the two components is in its basic form, and the other takes the possessive suffix of the third person singular and the accusative case ending.

- – Әй! Алар борыңгы әкиятләр ич. – **Әкиятен әкият**, ләкин хикмәтле әкият ул, Хөснулла абый. (Шәриф Камал, Матур туганда.) “Oh! They are just old stories after all!” “Granted, it’s a story but a story with a profound meaning, Uncle Khösnulla.”
- – Әнәс абыең бит бу! – диде этиең рәсемне күреп. – **Әнәсен Әнәс** тә, бөдрә чәче кая? (Әсрар Галиев, Асыл кошым минем.) “But this is your (older) brother Änäs!” your father said when he saw the picture. “Surely, it is Änäs, but where is his curly hair?”
- – Бу **хыял** гына әле **хыялын**. Әмма вакыт җитәр, бу көй ... бөтен туган ил өстендә яңгырый башлар. Минем шуңа ышанасым килә. (Гомәр Бәширов, Урман шаулый.) “I admit, this is still only a dream. But the time will come when this song will ... begin to be heard all over our native land. I want to believe that.”
- – ... моның этисе Шакир... ә? Әнисе, чынлапмы? – **Чынын чын** да бит... – диде Кәримә, гаепле тавыш белән. (Мирсәй Әмир, Саф күңел.) “... his father is Shakir? Really, Mother?” “Yes, really – he is...” Kärimä said in a voice reflecting a feeling of guilt.
- – Кара, монда нинди җылы икән. Бераз **караңгырак** кына **караңгысын**. Ә барыбер рәхәт. (Фәүсия Бәйрәмова, Болын.) “Look, how warm it is in here. Only it’s a bit dark. But it’s pleasant all the same.”
- – Карале, ал әле мине үзеңә? – диде кинәт Мансур. – Мин каршы **түгел дә түгелен** – диде ул көттеребрәк. – Ләкин минем бит Фәридә бар! (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) “I say, please, take me on (i.e., as a co-driver, mate),” Mansur said suddenly. “Basically, I would have nothing against it,” he said somewhat hesitantly. “But I do have Färidä!”
- Кара көнгә дип, бишмәт чабуына тегелгән бер червонецем **бар барын**. Ләкин мин аны барга санамыйм. (Мирсәй Әмир, Казан.) True, I do have a ten ruble bill sewn in the skirt of my coat for a rainy day. But I consider it as not being there.
- – Кая барасың? – Сезнең өчен барыбер түгелме? – дидем мин. – **Барыберен барыбер** дә, минем ат бар бит! – диде бу, минем әйберләрне караштырып. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) “Where are you going?” “It doesn’t make any difference to you, does it?” I said. “That’s right, it makes no difference, but I do have a horse,” he said, glancing (repeatedly) at my things (luggage).

b) One component is in its bacis form, the other takes the suffix **+лык**, **-лек** and the *dative* case ending. This construction weakens the statement, concession, etc.

- Кирамов. Әйтәләр иде шул, «Нур»чылар «Сәйяр»га каршы. Арская да Кирамовка каршы дип. Дөрес, ахрысы. Сабинский. **Каршылыкка** алар **каршы** инде, билгеле. Ләкин сез уйлаганча микән әле ул? (Нәкый Исәнбәт, Гөлҗамал.) Kiramov. They said that those belonging to (the theatre group) "Nur" are against (the theatre group) "Seyyar". Arskaya is against Kiramov. This seems to be a fact. Sabinskiy. Yes, of course, they (i.e., the "Nur" group) are against them all right. But is it for the reasons that you think?
- – Әллә үзегезнең дә күгәрченнәрегез бармы? – диде. – Үзебездә **юк юклыкка**! Латифа түтиләрдә бар. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) "Do you perhaps also have pigeons?" she said. "We ourselves don't have any! (But) Aunt Latifa has."
- ... аның иреннәре арасында әйтелмәгән сүзе **бар барлыкка** да, ләкин ул кызы башлаганны көтә иде. (Фатих Хөсни, Өзелгән җыр.) ... it is true, she did have unspoken words on her lips, but she was waiting for her daughter to begin.

c) Both components are repetitions of the interlocutor's word in the *same case form* as used by him, which may be the *dative* or *locative case.* One of the two components takes the possessive suffix and the accusative case.
   - – Кая җыендың болай? Балыккамы? ... – **Балыккасын балыкка**, ничек барырга икәнен генә белгән юк, – диде ул. (Аяз Гыйләҗев, Зәй энҗеләре.) "Where are you setting out for like that? Fishing?" "Fishing, yes! But how do you get there (Only I don't know how to get there)," he said (i.e., transportation is utterly inadequate).
   - Рәйхан. Өйдәме Сәхәп? Бибкәй. **Өйдә өйдәсен** дә... Кеше бар әле анда, Рәйхан апа. (Нәкый Исәнбәт, Рәйхан.) Reykhan. Is Säkhäp at home? Bibkey. He is at home but... There is still someone with him, sister Reykhan.
   - Өмми. Миңлекамал бирелдәме, Хәерниса? Хәерниса. **Бирелдәсен бирелдә** дә, эше бик тыгыз әле аның. Тиз генә бушый алмас. (Мирсәй Әмир, Миңлекамал.) Ömmi. Is Minglekamal here, Khäyernisa? Khäyernisa. She is here, but she has still a lot of work to do. She won't be able to make herself free anytime soon.
   - – Абыстай, Гариф әфәнде монда торамы? – **Мондасын монда**. Ләкин хәзер әле ул үзе өйдә юк. (Фатих Әмирхан, Кадерле минутлар.) "Lady, does Mister Gharif live here?" "Yes, he does (live) here, but right now he isn't at home."
   - Зөбәйдә. Акыл чәчтә түгел бит, бабай, башта. Сәмигулла. **Баштасын башта** ул. Әмма ләкин менә шулай пумала баш булып йөрү акыл зәгыйфлек галәмәте. (Шәриф Хөсәенов, Зөбәйдә – адәм баласы.) Zöbeydä. After all, the intellect is not in the hair, Grandpa ... It's in the head. Samighulla. True, it's in the head. But, to walk around like that with tousled hair is a sign of weak intellect.
   - – Алар бергә тормыйлар. – Соң, шәһәрдәдер бит ул? – **Шәһәрдәсен шәһәрдә**... (Ләбибә Ихсанова, Ана көнделеге.) "They don't live together." "But he does live in town, doesn't he?" "It is true, he does live in town, but..."

# CHAPTER XXVI – VERBAL ADVERBS

**[1239]** There are four verbal adverbs in Tatar. Having both the nature of an adverb and that of a verb, verbal adverbs fulfill a great variety of functions in the Tatar language. They do not take personal endings but can refer to any person. In most cases the subject of the verbal adverb is the same as that of the principal verb, but with the exception of the verbal adverb in **-а**, **-э**, **-ый**, **-и** (1240), verbal adverbs can also have their own subject. In the latter case, the verbal adverbs in **-ганчы**, **-гэнче**, **-канчы**, **-кэнче** (1266) and **-гач**, **-гэч**, **-кач**, **-кэч** (1270) can be the predicate of a subordinate clause. Depending on the context and on the tense of the principal verb, the verbal adverbs can refer to the present, past or future. Furthermore, the verbal adverbs in **-а**, **-э**, **-ый**, **-и** and in **-п**, **-ып**, **-еп** (1247) may be combined with auxiliary verbs to express various modalities and modes of action (1322-1378).

## A. Affirmative Forms

## The Verbal Adverb in -а, -э, -ый, -и

**[1240]** The verbal adverb in **-а**, **-э**, **-ый**, **-и** corresponds in form to the third person singular, present tense, indicative.

In its *simple affirmative* form (яза, сорый, килэ, эшли), it is almost always used with auxiliary verbs (see 1322-1378). When used with other verbs (non-auxiliary), it is usually reduplicated (яза-яза, сорый-сорый, etc.). In this form it indicates:

a) The *manner* in which a *continuous* or *intensive* action is performed. The action expressed by the verbal adverb occurs *simultaneously* with that of the principal verb.

- Күктэ, ..., кара-соры болытлар бер-берсен **куа-куа** ашыгып агалар. (Эмирхан Еники, Икенче көнне.) Dark gray clouds move fast ... in the sky, chasing each other.
- «Инде нишлэргэ?» – дип, үги кыз **елый-елый** урман буйлап киткэн. (Татар халык экиятлэре, Үги кыз.) Being at a loss what to do, the stepdaughter wandered through the forest, crying.
- Фэридэ ... тыелгысыз бер көлү белэн көлергэ керешеп китте. **Көлэ-көлэ** ул Исламга чэй агызды, ... (Нурихан Фэттах, Бала күңеле далада.) Färidä suddenly broke out into an unrestrained laughter. Laughing all the time, she poured tea for Islam, ...
- – Белэсең килсэ, – диде ул, – кызларга я өч, я биш чэчэк бүлэк итэлэр. Чэчэк һэрчак так санда булырга тиеш. ... Мэ, монысы сиңа булсын, – **дия-дия** теге ак розаны җэһэт кенэ егетнең үзенэ тоттырды. (Ринат Мөхэммэдиев, Беренче умырзая.) "If you want to know," she said, "one gives a girl either three or five flowers. The flowers must always be in an uneven number." ... Saying, "Here, let this one be for you," she quickly handed that white rose (i.e., that same white rose mentioned before) to the young man himself. (He had given her four roses.)
- ... эт рэхэтлэнеп сөяк кимерэ, үгез **мышный-мышный** печэн ашый, ... (Татар халык экиятлэре, Көнгэ күренмэс Сылу-көмеш.) ... the dog is happily gnawing (lit., reducing) a bone, the bull is eating hay, breathing noisily ...

b) An action *resulting* in, or *causing,* the action expressed by the principal verb.

- **Йөри-йөри** тэмам арыган иде, ... (Марсель Галиев, Ерак урман авазы.) Walking for a long time, he had become completely exhausted, ...

· Гомәр. Галия ханым, сезне **көтә-көтә** алҗып беттек. (Шәриф Камал, Ут.) Ghömär. Lady Ghaliä, we got tired waiting for you (for such a long time).

c) The *repetition* of the action expressed by the verbal adverb.

· Ул сүзләрен **бүлә-бүлә**, аптыраган тавыш белән ... диде. (Садри Җәләл, Инде мин аңа рәнҗемим.) Interrupting his words again and again, he said in an embarrassed tone: "..."

· Әнисе балык шулпасы пешерер, барысы да Әминне **мактый-мактый** тәмле шулпа ашарлар, ... (Кәрим Әмири, Югалган малай.) His mother will cook a fish soup, and all will eat the tasty soup, praising Ämin again and again (for having caught the fish), ...

· Менә зур, чуар этәч өстәлгә сикереп менде. Аның артыннан тавыклар да иярде. Өстәл өстендә калган икмәкнең йомшак җиреннән **чукый-чукый** куышлап ашый башладылар. (ibid.) There, the big, multicolored cock jumped on the table. The hens followed suit (after him). Pecking the soft part of the bread, which had remained on the table, they began to eat, hollowing it out.

**[1241]** The reduplicated form may consist of two verbal adverbs of *different* verbs of *similar* or *different* meaning. They indicate the *manner* in which the action of the principal verb is performed.

· Тугызы берьюлы килеп, **этешә-төртешә** су чөмерергә керештеләр. (Әхсән Баянов, Мәңгелек бәхәс.) The nine of them (i.e., animals) came at the same time and, pushing each other, began to drink water.

· Аларның бәрелешүе Хаковның хатыны аркасында да булырга мөмкин, – дип башлады Солтанов караңгыда **абына-сөртенә** барган кеше сыман. (Фоат Садриев, Шаһзаманов эше.) "It is also possible that they clashed because of Khaqov's wife," Soltanov began like a man stumbling about in the dark.

· Мәдинә **йөгерә-атлый** керә. (Мирсәй Әмир, Минем хатын.) Mädinä enters, now running, now walking (alternately running and walking).

· Дүрт аждаһа дүртесе тиң берьюлы сукыраеп, җиргә ятып **ауный-үкерә** башладылар. (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) All four dragons were blinded at the same time and, falling (lit., lying down) to the ground, began to writhe and roar.

**[1242]** A limited number of verbal adverbs in **-а**, -**ә**, **-ый**, **-и** may take the suffix **+рак**, **+рәк** to form adverbial clauses indicating the *time limit* of the action expressed by it. The action of the principal verb takes place *immediately* after that of the verbal adverb has come to an end or at a point of time when it is nearing its end.

Furthermore, this form may imply that the action expressed by it is performed incompletely, partially, to an approximate degree or in an indefinite manner.

*Note:* The suffix **+рак** is frequently used with булу – буларак. However, this form has different functions (see 477).

· Базарга **җитәрәк** Барлас туктады. – Ашыкма, энем, – диде. ... Син кала тор, башта үзем базарга кереп чыгыйм әле. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) When we just about reached the market, Barlas stopped ... "Don't hurry, my friend," he said. ... "You stay here! First, I'll just go briefly into the market (to take a brief look around."

· Алар көн уртасы **җитәрәк** кенә Аккош күле буена киттеләр. (Зөфәр Фәтхетдинов, Ачылган серләр.) They left for Aqqosh (Swan) Lake only when midday was coming on.

· Тамара Әхмәтне өстәл янына чакырды һәм ... кызы, эше, тормышы турында сораша башлады. Аннан киносеанс **бетәрәк**, китәргә киңәш бирде. (Ләлә

Хәйдәрова, Кырым хикәясе.) Tamara invited Äkhmät to the table and ... began to ask questions about his daughter, his work and his life. Then, when it was near the end of the movie, she advised him to leave. (Tamara's husband had gone to the cinema, and she did not want the two men to meet.)

· Ярты сәгать чамасы бардык. Шәһәрдән **чыгарак**, бер кечкенә таш кибеткә кердек. (Миргазиян Юныс, Юлда уйланулар.) We walked for approximately half an hour. When we were almost out of the city, we went into a small shop built of stone.

**[1243]** The verbal adverb in **-а**, **-ә**, **-ый**, **-и** may be used with the verbs **алу** 'to take', 'to receive' and **белү** 'to know'. In such constructions, these verbs lose their original meanings and become *modal auxiliary verbs.*

**[1244]** The construction with **алу** indicates that the action of the verbal adverb can, or cannot, be carried out.

· – Хезмәт хакы дигәндә ... Сез анда күпме аласыз әле? – Ике йөз җитмеш. – Монда да шуны ук **бирә алабыз**. (Әхсән Баянов, Мәңгелек бәхәс.) "Talking about the salary – How much are you getting there?" "Two hundred and seventy." "We can give you the same here too."

· Хәмит. Без синең белән бер фәкыйрь авылның мәзине, аша барса, мулласы гына **була алабыз** бит. Шәп булып чыксак, мөгаллим **була алырбыз**. (Кәрим Тинчурин, Беренче чәчәкләр.) Khämit. You and I can become muezzins, or, if it comes to that, mullas of some poor village.And, with luck (lit., If it turns out well for us), we'll be able to become teachers.

· Бәлки, чыннан да, нидер эшләп булыр? Барысын да **аңлата алмаса** да, нәрсәдер **әйтә ала** бит ул. (Фоат Садриев, Шаһзаманов эше.) Perhaps it would really be possible to do something. Even though he could not explain everything, there was, after all, something he could say.

· Әтисе белән сөйләшүдән **кача алса** да, үз күңеленнән **кача алмады** Булат. (Гариф Ахунов, Хуҗалар.) Though Bulat could avoid talking with his father, he could not escape from his own feelings (lit., heart).

· Вәлиев Хәят янына керде. Ләкин озакламыйча кире чыкты һәм: – Хәят ханым хәзер берәүне дә **кабул итә алмый**, – диде. (Гадел Кутуй, Илһам.) Wäliev went in to Khäyat. But he came out again at once and said, "Lady Khäyat cannot see (receive) anybody now."

· Мин бу йорт яныннан узып кына **китә алмый** идем, мин туктап, аңа карап торырга ярата идем, ... (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) I just couldn't pass by this house. I loved to stop and look at it, ...

· – Сез миңа аның турында кайбер мәгълүматлар **бирә алмассызмы**? – диде Ризван. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "Couldn't you give me some information about him?" Rizwan said.

· Алып Бәргән үзенең **кала алмаячагын** әйтте. (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) Alyp Bärgän said that he would be unable to stay.

**[1245] Алу** in its *negative* (**алмау**) is – especially in the vernacular – sometimes contracted with verbal adverbs in **-а**, **-ә** (not with verbal adverbs in **-ый**, **-и**).

When contracted with a verbal adverb of the *back vowel group,* the final 'a' of the verbal adverb and the initial 'a' of **алмау** merge into one.

· – Юк, мин **калалмыймын**! – диде Алып Бәргән. (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) "No, I cannot stay (here)!" Alyp Bärgän said.

With verbal adverbs of the *front* vowel group, **алмау** is contracted as follows:

1. The verbal adverb drops its final 'ә' and **алмау** is joined to it. Both components remain subject to their own original vowel harmony (the verbal adverb remains a *front* vowel word, **алмау** a *back* vowel word.)
   - Таһир. **Күралмыйм**! Бу минутта **күралмыйм** мин сезне, ... (Хәй Вахит, Мәхәббәтең чын булса.) Tahir. I hate you! At this moment I hate you, ...
   - Кайвакыт берәүне ник бер күрүдә үк якын итүеңне, икенче берәүне **күралмавыңны** үзең дә аңламыйсың бит. (Шәмсия Җиһангирова, Мәхәббәт бизмәне.) Sometimes you really don't understand why, at first sight, you are sympathetic to one person and cannot stand another.
2. The initial 'a' of **алмау** is dropped and the remainder is joined to the verbal adverb. In this case the two components may a) remain subject to their own original vowel harmony, or b) the remainder of **алмау** may become subject to the vowel harmony governing the verbal adverb and change its *back* vowels to the corresponding *front* vowels.
   - Нияз. ... **Күрәлмыйм** мин сине! ... Туйдым! Гарык булдым! **Күрәлмыйм**! (Хәй Вахит, Соңгы хат.) Niaz. I hate you! ... I'm tired of you! I have had enough! I hate you!
   - Ә менә нишләтәсең, үзебезнең бүлек башлыгыбызны мин яратмыйм. ... Бәлки, бу минем көнчелегемнән, үземнән өстәрәк утыручы кешеләрне **курәлмәвемнәндер**. (Фатих Хөсни, Күңел – берәүнең дә буш түгел.) But what can you do. I don't like our department head. ... Perhaps, it's because I am jealous, because I dislike people placed higher than myself.
   - – Аны куып **җитәлмәссең**, балам! диде әлеге карт. (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) "You won't be able to catch up with him, my son!" that same old man said.
   - Сандугач. Шулай икәнен дә беләм... **җиңәлмим** үземне. (Илдар Юзеев, Сөйгәнемнең туган көне.) Sandughach. I do know that it is that way, (but) I can't overcome my feelings (i.e., being jealous) (lit., myself).

   *Note:* The official spelling of the contraction of **алу** with the verb **күрү** is **күрәлмау** 'to hate', 'dislike'. See: Татар теленең орфографик сүзлеге, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1983.

**[1246]** The construction with **белү** indicates that the agent has the *knowledge*, the *skill, ability* to carry out the action expressed by the verbal adverb (French: savoir).

- Мин бу вакытта ... яшь ярымлык сабый гына булганмын. ... мин әле һич нәрсә белмим – мин бары **ашый беләм, йоклый беләм, көлә беләм, елый беләм**. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) At this time ... I was only a baby of a year and a half (so they told me). ... I don't yet know anything; I know only how to eat, sleep, laugh and cry.
- – Ашыкмагыз, без **түзә беләбез**, көтәрбез. (Әхсән Баянов, Мәңгелек бәхәс.) "Don't rush, we can be patient, we'll wait."
- Мин күп сөйләргә яратмыйм, ләкин кешене **сөйләндерә беләм**. (Галимҗан Ибраһимов, Диңгездә.) I don't like to talk a great deal myself, but I know (how) to make (other) people talk.
- – **Сорый белсәң**, табалар, ... (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) "If you know (how) to ask, they will find (things to give), ..."
- – Кучәрбай да **укый-яза белмиме**? – диде Гаяз, белмәгән булып. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) "Küchärbai cannot read and write either?" Ghayaz said, pretending not to know this.

- Диләрә. Ләрия, без синең сыман оста **сөйләшә белмибез**. (Аяз Гыйләҗев, Без унике кыз идек.) Dilärä. Läriä, we can't speak skillfully like you.
- Һарун Исламның ничек итеп кузгалып китүен күзәтеп торды да үз алдына: «Шофер имеш! Трактор да **йөртә белми**!» – дип уйлап алды. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Harun watched how Islam moved off and thought to himself: "A chauffeur, he says! He can't even drive a tractor."

*Note:* The difference between the functions of **алу** and **белү** is not always observed, **алу** being sometimes also used to express knowledge, skill. For example:
Чувашларның күбесе кебек ул да ... татарча **сөйли ала** иде. (Г. Ибраһимов, Тирән тамырлар.) Like many Chuvash, he too ... could speak Tatar.

## The Verbal Adverb in -п, -ып, -еп

**[1247]** This verbal adverb is formed by adding **-п** to verb stems ending in a vowel except **-у**, **-и**, and **-ып**, **-еп** to verb stems ending in a consonant or in **-у**, **-и**. For example: кара – карап, эшлә – эшләп, яз – язып, кил – килеп, ки – киеп, ю – юып.

In writing, verb stems ending in the diphthongs **-ай**, **-ой**, **-өй**, **-уй** **-ый** drop the **й** and add **-еп**: елмай – елмаеп /jьlmajьp/, кой – коеп /qojьp/, сөй – сөеп /səjep/, куй – куеп /qujьp/, җый – җыеп /çiьp/.

## Use and Functions of the Verbal Adverb in -п, -ып, -еп

**[1248]**

a) The verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** may be used for *stylistic reasons* to express, in one sentence, two or more independent actions immediately succeeding each other. In such syntactical constructions, the form in **-п**, **-ып**, **-еп** stands for the same grammatical form as that of the principal (final) verb and serves to avoid the monotonous repetition of identical verb endings.
   - Кыз, сандыкны **алып**, атына **атланып**, сыерны **җитәкләп**, сарыкларын, кәҗәләрен **иялтеп**, әбигә рәхмәт әйтә-әйтә, юлга чыгып китә. (Татар халык әкиятләре, Үги кыз.) The girl takes the box, mounts her horse and, leading the cow and making her sheep and goats follow her and, thanking the old woman again and again, sets out on her journey.
   - Турай батыр әбигә бик күп рәхмәтләр **укып**, билен **буып**, инештә битен **юып**, карчык күрсәткән сукмактан киткән. (Татар халык әкиятләре, Турай батыр.) Bogatyr Turai thanked the old woman very much, girded himself, washed his face in the little river and left along the path which the old woman had shown him.

b) Some verbs expressing actions which are usually associated with each other may be used in pairs, with the first component being a verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** but standing for the grammatical form of the second component. In writing both are connected by a hyphen.
   - – Әй улым, – ди карчык, – бер дә кайгырма син, ди. Бүген син минем кунагым. **Ашап-эчкәч** тә ятып йокла, ял ит. ... Шуннан соң бу егет әйбәтләп **ашап-эчә** дә ятып йоклый, ди. Иртә белән торып, **ашап-эчкәч**, егет юлга әзерләнә. (Татар халык әкиятләре, Көнгә күренмәс Сылу-көмеш.) "Oh, my son," says the old woman, "don't worry. Today you are my guest. Right after you have had something to eat and

drink lie down and rest." ... After that, the young man has a good meal (eats and drinks well) and then lies down to sleep (so they say). In the morning he gets up, and after taking food and drink, the young man prepares for the road.

- **Ашап-эчкәннән** соң бар да тамаша залына китте. (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) After eating and drinking, all went into the auditorium.

**[1249]** The verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** indicates:

1. *Simultaneity* of its action with that of the principal verb.
   - Мин барып кергәндә, Галимҗан ... тәрәзә янында, ниндидер китап **укып утыра иде**. (Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр, Әхәт Сөләйманов.) When I arrived at his house and went in, Ghalimjan, ..., was sitting ... beside the window, reading some book.
   - Шугалакта бала-чагалар **шау-гөр килеп** чана **шуып уйныйлар**. (Фатих Хөсни, Сөйләнмәгән хикәя.) Children are playing on the toboggan slide, noisily sledding.
   - Бу сөйләшү ни белән бетәр икән **дип**, әле әнисенә, әле Шакирына, әле әтисенә сабырсызланып **карап утырган** Наҗия, кинәт кулларын **чабып, кычкырып ук җибәрде**: – Их, үзебезнең йорт булса, мин аны курчак өе кебек итеп тотар идем! Бар да аңа **елмаеп карадылар**. (Әмирхан Еники, Саз чәчәге.) Najiä, who was sitting there impatiently looking now at her mother, now at her Shakir, now at her father, wondering how (lit., with what) this conversation would end, suddenly, clapping her hands, cried out, "Oh, if we had our own house, I would keep it like a dollhouse." All looked at her smiling.
2. It indicates that its action *precedes* that of the principal verb.
   - Көтүче әйтә: – Миңа бер көн көтү көтсәң, сиңа бер ат бирермен, – ди. Бу кыз ярар **дип**, бер көн көтү **көтеп**, аннан бер ат **алып**, көтүче өйрәткән юл белән тагын китә. (Татар халык әкиятләре, Үги кыз.) The shepherd says: "If you tend the herd for me for a day, I'll give you a horse." Saying, "All right," this girl tends the herd for a day, gets a horse from him and starts out again on the way the shepherd had told her about.
   - Үзе кала утын кисәргә, ә кыз, чиләген **алып**, җиләк җыярга китә. (ibid.) He (i.e., the brother) stays to cut wood while the girl (his sister) takes her pail and goes to gather berries.
   - – Татарстаннан килүчеләр юкмы? – диде ул. – Бар, менә мин Татарстаннан! – **дип**, аның каршына **килеп** бастым. (Мирсәй Әмир, Якташ.) "Aren't there any who come from Tatarstan?" he said. "There are. Here, I am from Tatarstan!" I said and, stepping forward, I stood in front of him.
3. It indicates that its action *follows* that of the principal verb.
   - Беренче булып тракторын Һарун кабызды. Вагон тәрәзәләрен **калтыратып**, колакларны **тондырып**, каты чиста тавыш белән мотор чытырдарга тотынды. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) The first to start his tractor was Harun. The motor began to roar with a loud, clear sound, causing the carriage windows to rattle and deafening their ears.
   - Көн туганын **хәбәр итеп**, яшел үлән керфекләрен **тирбәлдереп**, җир өстеннән йомшак кына, көчсез генә җил йөгереп үтте. (ibid.) A soft, gentle wind swept over the ground, heralding the birth of the (new) day and causing the green grass blades to quiver.

**[1250]** Its action taking place *simultaneously* with, or *preceding* or *following* that of the principal verb, the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** forms adverbial clauses expressing:

a) The *manner* in which the action of the principal verb is performed.

- [Зөннүн] Яр читенә җиткәч, туктап, бер тын диңгезгә карап торды да **сакланып** кына суга керде. (Миргазиян Юныс, Энҗе эзләүчеләр.) Upon coming to the edge of the shore, [Zönnün] stopped, gazed for a little while at the sea and cautiously went into the water.
- Ул һәр төрле киемне тегә. Шулай да аның иң **яратып** эшләгән нәрсәсе каеры тун тегү иде. (Мөхәммәт Гали, Рәхмәтулла тегүче.) He sews all kinds of clothes. However, the thing he did with the greatest pleasure was sewing sheepskin coats.
- Егет шулкадәр **тырышып** өйрәнә боларның һөнәрләрен, өч ай дигәндә, үзләреннән артык белә иде бу. (Татар халык әкиятләре, Өч күгәрчен.) The young man learned their trade with such fervor that, within three months, he knew more than they.

b) An action serving as the *means* of accomplishing the action indicated by the principal verb.

- Мин башта, ул бу телләрне берәр югары мәктәптә **укып өйрәнгәндер**, дип уйладым. Ләкин ул минем соравыма каршы: – Юк, **укып** түгел, – диде – энә шул халыклар арасында ике ел **йөреп өйрәндем**. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) At first, I thought that he had probably learned these languages (i.e., Chuvash, Tatar and Bashkir) by studying at some school of higher learning. But in reply to my question he said: "No, I learned them not by studying, but by living for two years among those peoples."

c) The *cause* leading to the action or state expressed by the principal verb.

- Узенә кычкыруларын **ишетеп** ул атын кызулатырга тотынды. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Hearing them shout to him, he began to urge his horse on.
- Шулай ята торгач аны йокы баса башлагандай булды. Ләкин көне буе **эшләп** никадәр арыган булмасын, ... шулай да аның чын-чынлап йоклыйсы да килмәде. (ibid.) After lying there like that, he felt he was getting sleepy. But, however tired he was, having worked all day long, ... he still didn't really want to sleep.
- Һарунның чакыруын **күреп**, ул, ... кабина янына килде ... (ibid.) Seeing Harun motioning to (lit., inviting) her, she, ... walked over to the cabin (of the tractor) ...
- Чынлап та, нигә дип әле кайтып барам? Шәлперәйгән картның туган авылына ашкынуы аңлашыла – сагынган. Мин **сагынып** түгел бит. Мин бары тик үземне рәнҗеткәннәрне, мыскыл иткәннәрне күрергә, алардан үч алырга гына кайтам. (Туфан Миңнуллин, Хәсән Вәгыйзович.) Why, really, (do you think) I am returning? The feeble old man's hurrying (back) to his native village is understandable – he has missed it (pined for it). I, after all, (am returning) not because I miss it (pine for it). I am only returning to see those people who have offended and humiliated me, to take revenge on them.

d) The *purpose* of the action expressed by the principal verb.

- ... аның сүзләрен ныграк ишетергә **теләп**, [Фәридә] бияләен колак турысына күтәрде. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) ... wishing to hear his words more clearly (lit., stronger), [Färidä] raised her gloves to her ears.
- Ателье мөдире, кызның күңелен **күреп**, рәхәтләнеп кычкырып көлде. (Ринат Мөхәммәдиев, Кенәри – читлек кошы.) To lift the girl's mood, the atelier director laughed loudly with delight.

**[1251]** The verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** can express a *condition.*

- Әби кинәт кенә учы белән авызын каплады. Тагын әллә нинди килешмәгән сүзләр **әйтеп**, көлкегә калуым бар дип курыкты шикелле. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) The old woman suddenly covered her mouth with the palm of her hand. She

seemed to be afraid that, if she said some inappropriate things (lit., words) again, she might (could) become a laughingstock.

**[1252]** The verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** may be used with the suffix **+рак**, **+рәк**. This form expresses *incomplete* or *approximate* execution of the action, or it denotes that its agent performs the action expressed by the verbal adverb in a *higher degree* than another agent.

- – Кадак табыла ла инде, Корбангали абзый, син **арттырыбрак** җибәрәсең бугай. (Шәриф Камал, Таң атканда.) "Come on, nails can be found, Uncle Qorbanghäli. I think you are exaggerating somewhat."
- – Равил ошадымы соң? ... – Ул да ошады, – диде, **көттеребрәк**. (Нурихан Фәттах, Мөдир Сажидә.) "Then you liked Rawil?" ... "I liked him too," she said somewhat hesitatingly.
- Хәер, кызлары да үпкәләп тормыйлар. Киресенчә, егет шул тирәдә чуала башлаганнан бирле ул халык кибеткә ешрак һәм **киенебрәк** йөрергә тотынды. (Фатих Хөсни, Җәяүле кеше сукмагы.) However, the girls are not annoyed at all. On the contrary, since the young man had begun to frequent that neighborhood, they (lit., those folks) began to go to the shop more often and dressed better.
- Харис. **Аңлатыбрак** сөйлә. (Гамир Насрый, Кушнарат.) Kharis. Speak more clearly.
- Йорт һәм хуҗалык эшләрен ирләргә караганда да **белебрәк** һәм урынына **җиткәребрәк** үтиләр. (Зариф Бәшири, Замандашларым белән очрашулар.) They (i.e., the women) also perform the housework and manage the household more knowledgeably and more effectively than the men.

**[1253]** The verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** may be reduplicated to express *intensiveness, repetition, continuance* of the action denoted by it, or to *give emphasis* to the action. The reduplicated form may consist of 1) two verbal adverbs of the *same verb*, 2) two verbal adverbs of *different verbs* which are *similar* (synonymous) in meaning, 3) two verbal adverbs of verbs of *different meanings.* The reduplicated form often expresses the *manner* in which the action of the principal verb is performed.

- [Хәбип] үз тирәсенә җыелган яшьләргә **тәмләп-тәмләп** шул вакыйгаларны тасвирлады. (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) [Khäbip] related those events with great relish to the youths gathered around him.
- Гыймран, аякларын көймә төбендәге тактага терәп, **каерып-каерып** ишә иде. (Миргазиян Юныс, Энҗе эзләүчеләр.) Bracing his feet against the board (which was) at the bottom of the boat, Ghimran rowed with long (powerful) strokes.
- Мин **борылып-борылып** артка таба карыйм. Безнең хутор инде күренми дә. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) I keep turning around and looking back. Our farm is not even visible now.
- Яңадан киттеләр болар юл белән. **Барып-барып**, бер көмеш күпер янына барып җиттеләр. (Татар халык әкиятләре, Тимеркендек.) They continued on their way. They walked on and on and came to a silver bridge.
- Шуннан йокысы качты Гафурның. Яңадан оеп китмәмме дип, **әйләнеп-тулганып** карады, мендәрен дә әйләндереп салды. (Җәмит Рәхимов, Бурыч.) After that (i.e., after having been awakened by noise) sleep eluded Ghafur. Thinking that he could perhaps doze off again, he tried turning around and even turned over his cushion.
- Шамил, табышмак әйтешкәндәге кебек, **ашыгып-кабаланып** җавап бирде. (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем элмәге.) Shamil answered quickly, the way you do when asking a riddle.

- Сабадырев колак торгызып бераз **тыңланып-каранып** торды. Тирә-юньдә шылт иткән тавыш та юк. (ibid.) For a little while Sabadyrev listened intently (lit., pricking up his ears) and looked to all sides. All around him there was an absolute silence.
- Бүтән көннәрне иртүк кереп идәнне, өстәл өстен **себереп-җыештырып** чыга торган Фәрхәнә апа да бүген нишләптер соңгарак калган иде. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) Färkhänä too, who on other days came in very early to sweep the floor and tidy up the table, had for some reason, been late today.
- Ә залда мәҗлес матур гына дәвам итә. **Сөйләшеп-көлешеп** арыгач, берәрсе пианинода уйный башлый, ... (Әмирхан Еники, Әйтелмәгән васыять.) And in the saloon the party continues just beautifully. After getting tired talking and laughing, someone begins to play on the upright piano, ...
- Корангыш **ярсып-кешнәп**, арткы аякларына басты. (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) Becoming furious and neighing, Qorangghysh reared up on his hind legs.

**[1254]** Followed by the particle **та**, **-тә**, the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, both in its simple form and reduplicated, expresses *concession*, the reduplicated form indicating *emphasis, repetition,* continuance.

- Берничә мөәссәсәдә хезмәт **итеп-итеп тә**, газеталарга һаман ара-тирә мәкаләләр **язып торып та**, Зәйнуллин юньле-башлы көн итә алмый ... (Садри Җәләл, Журналист.) Although he does work at several institutions and although, from time to time, he still writes articles for newspapers, Zeynullin is unable to make a passable living ... (мөәссәсә – оешма /ɕʝьşmal/).

*Note:* The reduplication or the use in pairs, not only of verbal adverbs but of practically any part of speech, to indicate emphasis, intensity, repetition, or, if synonymous or near-synonymous, to express the same idea, is a characteristic of the Tatar language.

- Газиз. Унсигез ел бергә **яшәп тә,** көн саен **очрашып та** мин сине күрмәгәнмен. (Хәй Вахит, Күк капусы ачылса.) Ghäziz. Although we have lived together (i.e., in adjoining apartments) for eighteen years, and although we have met every day, it seems I have not noticed you.

**[1255]** The verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** of a verb followed by a personal form of the *same verb* expresses *emphatic repetition* or *just emphasis.*

- – Ни булса, шул булыр, кеше ни эшләсә, мин дә шуны эшләрмен, барыйм әле, дип **әйтеп әйттем**. (Галимҗан Ибраһимов, Кызыл чәчәкләр.) "Whatever will be will be. Whatever people do, I shall do too. So, I'll go," I kept saying.
- – Гөлшаһидәнең, дип **әйтеп әйттеләр**, бездән башка якыннары юк. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) "... Gölshahidä," they kept insisting, "has no close people besides us."
- Бостан. ... менә монда безнең көтепханә булыр! Галимҗан. Әйдәгез, **карап карыйк** әле, нәрсәләр бар икән. (Фәтхи Бурнаш, Камали карт.) Bostan. ... here, this is our library! Ghalimjan. Come, let's just see what books (lit., things) there are, then.
- – Инде Хәйретдиновны гына көтәсе калды. **Карап карыйк** нинди хәбәр алып кайтыр. (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем элмәге.) "All we have to do now is wait for Kheyretdinov. Let's see what kind of news he'll bring."

**[1256]** The same construction, but with the suffix **+мы**, **+ме** joined to the verbal adverb, denotes *intensity, repetition, continuance* of the action, the subject's *absorption* in it. The action may be sudden, unforseen by the speaker.

- Тургайлар **чырылдапмы чырылдый**. (Аяз Гыйләҗев, Урамнар артында яшел болын.) The larks are singing away (heartily).
- Ул арада көчәйгәннән-көчәя барган дулкыннар, ак тешләрен ыржайтып, яртылаш су тулган көймәне йомычка урынына **биетепме-биетә**. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) Showing their white teeth, the waves which in the meantime have grown stronger and stronger, keep the boat, which is half full of water, dancing like a chip (of wood).
- Беркөнне Мотаһир. ... печән чабарга кереште ... ул аякларын шуыштырып кына атлап, **чабыпмы чаба**. (Рәфкать Кәрами, Каргышлы юллар.) One day, Motahir. ... began to make hay. ... Advancing with a (slow) shuffle, he kept cutting and cutting.
- Урман ... Әкият дөньясын хәтерләткән төрле-төрле рәвештәге агачлар ... беркадәр баргач, юлның бер читендәге агачта тукран күрделәр. ... Кош ... кәүсәгә тырнакларын батырган да тук-тук итеп **чукыпмы-чукый**. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) The forest ... There are all kinds of trees, reminding one of fairyland. ... after walking a little, they saw a woodpecker on a tree at one side of the path (way). The bird had sunk its claws into the trunk ... and was pecking away, making a knocking sound.
- – Бу бит урман, нинди шәп агачларны әрәм итәләр. ... Әйдәгез әле, шунда барыйк. ... Киң алымлы, куәтле бульдозер агачларны **кырыпмы-кыра иде**. "But this is a forest. What fine trees they are wasting. ... Just come on, let's go there." ... A powerful, wide-track bulldozer (lit., a bulldozer with a wide reach, grasp) was working away, toppling the trees.

**[1257]** The verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** may take the plural suffix **+лар**, **+ләр**. In this case, **+лар**, **+ләр** loses its original meaning and functions like a particle *expressing intensive action,* the highest degree of *various emotions* (amazement, delight, etc.), often with a tinge of *humour* or *irony; real* or *playful exaggeration* of one's feeling, *indignation.*

The form pertains to the vernacular but occurs not infrequently also in literary works. It is in most cases used by women.

*Note:* Some Tatar scholars tend to regard this form as a specific characteristic of the general vernacular (see Ф.С. Сафиуллина, Синтаксис татарской разговорной речи, Издательство Казанского Университета, 1978, p. 179.) Others maintain that it is characteristic of certain dialects only (see Ф.Ю. Юсупов, Неличные формы глагола в диалектах татарского языка, Издательство Казанского Университета, 1985, pp. 130/131.)

- Бер-беренә ачу килү, әйтешү гаиләдә булгалый торган хәл, кич якта ире эштән кайткач, һәм дустанә матур итеп дәшкәч, ... **эреплэр** киткән иде тагын. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) Getting angry at each other, quarrelling (with each other) is something which occurs from time to time in a family. After her husband returned from work in the evening and talked in a nice, friendly way, ... she had completely mellowed again.
- – Беләсезме, Хикмәтулла абый, мин дә шул турыда сезгә кергән идем. Инәки **үтенепләр** сорады. Башта ризалык бирмәдем, ачуланып чыгып киттем, соңыннан... (ibid.) "You know, Uncle Khikmätulla, I too thought I would come in to you (and talk to you) about that. Mommy implored me. At first, I didn't agree, I left angrily, (but) later..."
- [Рәмзия] гармун сайратуын онытылып **китепләр** тыңлый. (Барлас Камалов, Өметең өзелмәсен.) [Rämziä] listens with rapture to his masterful playing of the accordion.
- Ул арада Зәйтүнә ... зур агач табак белән аш алып чыкты. Үзе һаман кунагына юату сүзләре тезде. – Зарар юк, Рәхимҗан, җанашым, бар да һәйбәт булыр. ... Яле, бары белән **ашаплар** гына утырыгыз әле. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.)

Meanwhile, Zeytünä brought out the food in a big wooden pan ... She still continued to say her words of consolation to her guest, "It doesn't matter, Räkhimjan, my dear, everything will be fine ... Come now, please, sit down and eat with all (of us)."

- Сүзләренә кирәксә-кирәкмәсә дә «лар», «ләр» кушып күплектә сөйләргә ярата ул. Хатларында да «... ачларга **тилмерепләр** йөрмисеңме икән дип, **кайгырыплар** ятам», «**Өзелепләр** сагындым үзеңне», «Кайтасы юлларыңа **караплар** торам», дип язар иде. Ә инде кайтып күзенә күренгәч: «**Калтыраныплар** торасың, улым, әллә **кереплләр** ятып торасыңмы?» – дип борчылыпмы борчылыр иде. (ibid.) She (i.e., his mother) likes to speak in the plural, adding, whether necessary or not, "-lar", "-lər" to her words. In her letters too she would write "... I am worrying that you might go hungry", "I am longing for you (I miss you) very much", "I keep looking at the road on which you will (have to) return". And after he has returned and appeared before her eyes, she would worry, saying: "You are shivering, perhaps you will come in and lie down?"
- – И-и, балакайларым ла! **Туңыплар** үлә язгансың ич. ... Менә монда мич тирәсенәрәк елыш. ... Ничек соң, улым, укуларың ару гына барамы? ... Бик **ачыгыплар** яшәмисеңдер бит, улым? (ibid.) "O-oh, my dear child! You look almost frozen to death. ... Here, get closer to the stove." ... "How is it now, my son, are your studies going well? ... You aren't living (there), going hungry, are you, my son?"
- – ... Илзирәк исемле? – дип сорады Зәйтүнә кинәт. – Кызы туган иде бит аның. Ничегрәк үсә икән? – Терекөмеш кебек кызы, **тәгәрәпләр** үсеп килә! (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) "Wasn't her name Ilziräk?" Zeytünä said suddenly. "She had given birth to a daughter, hadn't she? I wonder, how is she growing up?" "Her daughter is mercurial. She is growing up dandily."

**[1258]** The verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** in its *affirmative* form, followed by **булу** in its third person singular, *affirmative* or *negative,* and in any *mood* and *tense*, expresses *impersonal possibility* or *impossibility* of performing the action denoted by the verbal adverb.

*Note:* The construction **-п** + **булу** expressing *impersonal* possibility (impossibility) is used rather frequently in Tatar. Though impersonal in form, the action denoted by it often refers to an agent known from the context.

- Рәкыйпов ... илле биш яшьләрдәге кеше иде. Аның белән ачыктан-ачык **сөйләшеп**, бик авыр хәлләрдә дә уртак тел **табып була**. (Фоат Садриев, Шаһзаманов эше.) Räqipov was a man ... about fifty-five years old. You could talk with him frankly and come to terms with him even in very difficult situations.
- Аңа теләсә кайчан **таянып** та, **ышанып** та **була**. (ibid.) One can rely on him and believe him at any time.
- – Сәер кеше син, Рәхимҗан, – диде ул ... **Аңлап булмый** сине. (Ринат Мөхәммәдиев, Беренче умырзая.) "You are a strange person, Räkhimjan," he said, ... "It is impossible to understand you."
- Дөрес, ул бер генә сүз белән дә безгә каршылык күрсәтмәде. Әмма үзен тотуыннан, күңелсез йөрүеннән безнең кушылуыбызга каршы килүен **белеп була иде**. (Гадел Кутуй, Нишләргә.) True, he didn't even say one word to show us (his) opposition (disagreement). But the way he behaved, by his walking around unhappily, one could tell that he was against our getting married (lit., going together).
- «Әйдәгез, керегез» – диде. Үзе шунда ук ишекне бикләп тә куйды. ... Кердек керүен, **чыгып булырмы**? (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) "Come on, go in," she said. Then she immediately locked the door. Well, we did enter, (but) would it be possible to get out?

- Болай булгач, инде хәзер буш вәгъдә белән генә **котылып булмаячак иде**. (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) In that case, he would now no longer be able to get away with just an empty promise.
- Байтирәк. Соң ничек, мәдрәсә тәртибенә ияләшәсезме? Бибкәй. Әкренләп **ияләшеп булыр иде** дә, бик кимсетәләр. (Таҗи Гыйззәт, Кыю кызлар.) Baitiräk. So, how is it going? Are you getting used to the discipline at the medrese? Bibkey. One could gradually get used to it, but they (i.e., some nasty students) do humiliate us (i.e., the speaker and two other girls) very much.
- Зөләйхә. Минем сөйгән егетем юк. Шамил. Төтен, Зөләйхә апа, ышанмыйм. Ничек инде ул япь-яшь башыңа яр сөйми **яшәп булсын** ди. (Риза Ишморат, Шайтан таягы.) Zöleykhä. I don't have a sweetheart. Shamil. Baloney (lit., Smoke), Zöleykhä, I don't believe it. Being young, as you are, how can you live without a sweetheart.
- Хәмит. Бигрәк кызык син, иптәш, ни **эшләп булмасын**. (Кәрим Тинчурин, Беренче чәчәкләр.) Khämit. You are really funny, my friend, why shouldn't it be possible to do it.
- Сәлим. Мин, ата, үз баламны үзем танымыйм! Мин аның ничек үскән, яшәгәнен дә белмәдем. Бу бит – гафу итмәслек эш. Камилә. Бар, аягына егыл, тезлән. Сәлим. Шуның белән генә **төзәтеп булса иде**! (Хәй Вахит, Беренче мәхәббәт.) Sälim. I, the father, do not know my own child myself! I didn't know how he grew up and lived. This is, after all, an unforgivable thing. Kamilä. So go, go down on your knees before him. Sälim. If it could be redressed just with that!

**[1259]** The same construction is also possible with impersonal forms of **булу** (verbal noun, participle, verbal adjective, etc.). Together with expressing possibility or impossibility, such constructions denote in most cases subordination or form adverbial clauses.

- Миңа бик уңайсыз: ничек булышырга белми аптырап йөрим. ... Талонга килгән ярма-токмач ише әйберне дә биргәләгән булам, тик андый вак-төяк белән генә берни дә **үзгәртеп булмавы** көн күк ачык. (Шәйхи Маннур, Агымсуларга карап.) For me it is very embarrassing. I am at a loss, not knowing how to help. ... Every now and then I did give her such things as groats and vermicelli which came on coupons, but it was clear as day that with such little things alone nothing could be changed (one could not change anything).
- Апукаев җавап бирмәде. Шушындый хәлдә барысын да **әйтеп бетереп булмаганын** Мөхәммәтов ник аңларга теләми? (Фоат Садриев, Шаһзаманов эше.) Apuqayev did not answer. Why didn't Mökhämmätov want to understand that in such a situation as this it was impossible to tell (that one could not tell; that he could not tell) all of it fully?
- Искәндәр сүзсез генә аның янына килеп утырды, малайдан барыбер **котылып булмаячагына** үртәлеп, чишенергә кереште, ... (Флүс Латыйф, Аяклы каза.) Without saying anything, Iskändär went over to him and sat down. Irritated that in any case it wasn't possible to get away (he could not get away) from (get rid of) the boy, he began to undress, ... (A woman he didn't know had asked him to take her boy with him into the bathhouse, and he regretted having done so.)
- Шамил (кул селти.) Калсын! Менә бит хәзер дә күпме эш кушасың. **Булдырып булмаслык** эш. Булмаслыгын син аның үзең дә яхшы беләсең, ә кушасың. (Хәй Вахит, Карлыгач канат кага.) Shamil (waving his hand). Leave that be (i.e., let's not discuss that any more)! Now, here, too, how much work you demand. It is work (which is) impossible to accomplish. You know yourself very well that it is impossible, and you demand it.

- Тышта **чыдап булмастай** эссе. (Әхәт Гаффар, Олы юлның тузаны.) It is unbearably hot outside.

**[1260]** The verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** followed by **булу** in the third person singular of the conditional and the particle **да** forms adverbial clauses expressing varying degrees of *emphatic concession.*

- «Укытучы»сын **бүлдереп булса да**, Шамил бу урында үз белгәнен кыстырды: ... (Зөфәр Фәтхетдинов, Үлем әлмәге.) Even though it meant interrupting his "mentor", at this point Shamil threw in what he himself knew: ...
- Зөфәр. Ярый әле үзем килеп төштем. Бу баткаклыктан, бәлки, колагыңнан **тартып булса да**, чыгарып булыр (Хәй Вахит, Соңгы хат.) Zöfär. Good that I have come here. Perhaps it will be possible to pull you out of this mess even if it be by your ears. (The person addressed has become involved in a serious office quarrel and needs help.)
- Чананы Ильяс үзе **тартып булса да** калган ярты чакрымны узачак һәм йөкне тиешле урынга илтеп җиткерәчәк. (Әхсән Баянов, Җәй белән җәй арасы.) Even if it means pulling the sleigh himself, Ilyas will do the remaining half verst and deliver the load to the place it is to go. (The sleigh had been pulled by a bull, which had caused the sleigh to capsize.)
- – Ә, исәнме, җылы язгы җил! Сине, синең белән бергә уздырган бәхетле яшьлек елларын оныту мөмкинме соң? – дияр ... Кайсыбер дусларын табу язгы җилгә, бәлки, болай ук ансат булмас. Ләкин җил аларны да, зур шәһәрләргә **барып булса да**, табар. (Садри Җәләл, Яз.) "Ah, how are you, warm spring breeze! Is it possible then to forget you, the happy years of (my) youth which I have spent together with you?" he (i.e., the now adult working man) will say, ... Finding some of its friends will perhaps not be that easy for the spring breeze. But even if that requires traveling to the big cities, the breeze will find them.

*Note:* The same construction may connote possibility or impossibility. For example:
Иртәгә кузгалырга туры килә, сәгать сукты, алда ни көткәнен **әйтеп булмаса да**, монда ни калачагы сукыр күзгә дә күренеп тора. (Аяз Гыйләҗев, Балта кем кулында.) Tomorrow they have to leave. Their hour has come (lit., the clock has struck). Though it is impossible to tell what lies (is waiting) ahead, what remains here for them is obvious even to the blind (lit., the blind eye).

**[1261]** The verbal adverb in **-ып** of **булу**, used postpositionally after a noun, expresses a comparison (see also 478, c).

- Әхмәт ... шундый да ышандырып сөйли, әйтерсең экияттәге шул тамашаларны күптән түгел генә үзе күреп кайткан! ... Койманың баганасы саен әдәм башы. Ул башларның күзләре зәңгәр **ут булып** яна. ... кошлар, җәнлекләр **кеше булып** сөйләшә, ... (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) Äkhmät ... is narrating so convincingly as though he himself has just recently seen those scenes in the story! ... Every pole of the fence has a human head. The eyes of those heads burn like blue fire ... birds, wild animals talk like people ...

**[1262]** Together with an ordinal number, **булып** indicates the order of the agent's position (see 599).

**[1263]** Placed between a repeated noun or pronoun, **булып** has the meaning of **хәтта** 'even'.

- **Шамин булып Шамин** мактады аны бүген. (Аяз Гыйләҗев, Зәй энҗеләре.) Even Shamin praised him today.
- **Закир булып Закир** моның ишене уйлап чыгармады. (Ибраһим Гази, Онытылмас еллар.) Even Zakir did not think up anything like this.

- Шуның өстенә ике ел рәттән корылык. **Идел булып Идел** кипте, җәяүләп аркылы чык, шундый сай урыннары бар. (Ибраһим Гази, Малайлыкта кунакта.) In addition to that (i.e., the civil war), there was a two years' drought. Even the Volga dried out. There were such shallow spots that you could just walk across.
- Нигә Шиһаповка барам? Ул бит үзе дә шик астында, инде **мине булып мине** алырга килгәч, аны алып ук киткән булулары мөмкин бит ... (Ибраһим Гази, Гаепсез гаепләүләр.) Why am I going to Shihapov (then)? After all, he is under suspicion himself. If they come to take even someone like me, then it is quite possible that they have already taken him away (i.e., arrested) ...

**[1264]** The construction of **булып** and the third person singular of the verb **чыгу** in its *affirmative* or *negative* form, placed after the predicate of a sentence, indicates that the narrator (speaker) *learns of, becomes aware of, finds out about* an action, event or state through his *own* observation or experience. The action or state may turn out just *as a fact,* as *expected* by the narrator, or *contrary* to his (her) expectation. In the latter event, **булып чыгу** may imply some emotion, such as *surprise, gladness, dismay.*

- Чирмешәннең бу төшендә су шактый тирән һәм саф **булып чыкты**, ... (Кояш Тимбикова, Тәңкәле тау.) At this spot (place) of the Chirmeshän the water turned out to be rather deep and clean, ...
- Сыер савучылар, терлек караучылар, эшләрен бетереп, өйләренә кайтып киткән **булып чыкты**. (Булат Сөләйман, Абу баба.) It turned out that the milkmaids and the cattle farm workers had finished their work and returned home. (The action has been anticipated.)
- Өй ишеге эчтән бикле **булып чыкты**. (ibid.) The front door (of the house) turned out to be locked from the inside. (The narrator has expected the action and is glad about it, for his little grandson is alone in the house.)
- – Ничек? – диде Рәхим тетренеп. – Сез үзегез күргәнгә ышанмыйсыз **булып чыгамы**? (Атилла Расих, Ике буйдак.) "What?" Räkhim said, trembling. "So it turns out that you don't believe what you have seen for yourself?" (The action turns out contrary to the speaker's expectation.)
- Абдулов. Ә? Зөләйхә Мәрдәнова? Соң алайса ул минем малайны укыта торган кыз **булып чыга** ич! (Риза Ишморат, Шайтан таягы.) Abdulov. What? Zöleykhä Märdänova? If that is so, then it turns out that she is the girl who teaches my boy, you know!
- Кичен хәл белергә кергән Әхсәнгә чәчәкләр өчен рәхмәт әйтә башлаган идем, аптырап китте. Бернинди дә чәчәкләр кертергә кушмаган **булып чыкты** ул. (Шәмсия Җиһангирова, Мәхәббәт бизмәне.) When I thanked Äkhsän, who had dropped in in the evening to inquire about my health, for the flowers, he became suddenly embarrassed. It turned out that he had not requested (the speaker's husband) to bring in any flowers. (The action turned out contrary to what the speaker had been told by her husbund. The flowers were from him, and she is both surprised and glad about it.)
- – Әйе, – дип дәвам итте Мөхәммәтов, – мәсьәлә без уйлаганча гади /ɑadi/ **булып чыкмады**. (Фоат Садриев, Шаһзаманов эше.) "Yes," Mökhämmätov continued, "the matter didn't turn out as simple as we thought."
- Хәсәннең бу сүзләре дөрес иде. Ул минем танышым да, кайчандыр күргән кешем дә **булып чыкмады**. (Мирсәй Әмир, Якташ.) What Khäsän said was true. He turned out to be neither my acquaintance nor the person I had seen some time (ago).

# The Verbal Adverb in -п of дию

**[1265]** This verbal adverb is used:

a) In *direct discourse* of the *analytical* kind in which the quotation precedes or fragments the author's (speaker's) words or is fragmented by them, and in which the predicate of the author's (speaker's) words is not a form of **дию** or a compound consisting of **дип** and an auxiliary verb. In such syntactical constructions **дип** serves to connect the quotation with the author's words.

*Note:* In writing, a direct quotation of the above kind *preceding* the author's (speaker's) words is preceded by a long dash and followed by a comma, exclamation or question mark. The author's (speaker's) words are connected by **дип** with a long dash preceding it. When fragmented by the quotation, the first part of the author's (speaker's) words is followed by a colon. The punctuation of the second part and of the quotation remains the same as explained above. When the direct quotation is fragmented by the author's (speaker's) words, the first part of the quotation is followed by a comma, and the author's (speaker's) words are set off by a long dash at the beginning and a comma at the end; the second part of the quotation is preceded by another long dash.

· – Кер әйдә, кер, Равил! – **дип кычкырдым** мин, куанып. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) "Come in, come on in, Rawil!" I cried out, rejoicing.

· – Әй, нинди матур кошларың бар икән, Сания апа! Сайраулары нинди матур. – Кенәриләр, – **дип ачыклык кертте** хуҗа хатын. ... – Кенәриләр... – **дип, кабатлады** ул үзалдына. (Ринат Мөхәммәдиев, Кенәри – читлек кошы.) "Oh, what beautiful birds you have, Aunt Saniä! How beautiful they sing." "They are canaries," the hostess explained. ... "Canaries..." she (Asiä) repeated to herself.

· – Сине дә беләм мин, кызый, Артыкбикәме син? – диде ул. – Әйе, мин Артыкбикә, – **дип, дөресләп куйды** кыз. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) "Why, I know you, little girl, aren't you Artyqbikä?" he said. "Yes, I am Artyqbikä," the girl confirmed.

· Әхмәт үзе дә абыйларын табу шатлыгыннан ни эшләргә белмичә: – И, абыйларны таптым, – **дип кычкырып җибәрә**. (Татар халык әкиятләре, Унберенче Әхмәт.) Not knowing what to do out of joy of having found his (older) brothers, Äkhmät himself too cries out, "Oh, I have found my brothers."

· Хуҗа бу кешедән: Кая барасың болай? – **дип сораган**. (Татар халык әкиятләре, Комагай.) The host asked (so they say) this man, "Where are you headed (going) like this?"

· – Әйе, иптәшләр, – **дип дәвам итте** Имәли, – мин бүген тәмле телле. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) "Yes, colleagues," Imäli continued, "today I am sweet-tongued." (I.e., he is not speaking with his usual sharpness.)

b) In *direct discourse* (monologue) of the *analytical* kind the contents of which the agent only *thinks* or says to himself (herself).

*Note:* In writing, the direct quotation is enclosed in quotation marks.

· Урман юлы белән бара торгач, бу юл тар гына бер сукмакка әйләнә. «Адашсам адаштым инде, барыйм әле мин шул сукмак беткәнче», – **дип уйлый** бу. (Татар халык әкиятләре, Өч күгәрчен.) After he walked for some time along the forest road, this road turned into a rather narrow path. "Even if I lose my way, I'll follow this path until it ends," he thought.

· Шомбай моны тыңлап торган да: «Тукта әле, боларны кызык итим әле», – **дип уйлаган**. (Татар халык әкиятләре, Шомбай.) Shombai (they say) overheard this and thought: "Just wait, I'll play a trick on them."

· Тәрәзә турысыннан әнисенең узып киткәне күренде. «Хәзер керәчәк тә ашарга кыстый башлаячак», – **дип уйлады** Илһам. (Фоат Садриев, Шаһзаманов эше.) He saw his mother passing by the window (lit., his mother's passing by the window

became visible to him). "Now she will come in and start entreating me to eat," he thought.

- Эт тавышы миңа Күчәрбайны хәтерләтте: «Нишләп шушы вакытка кадәр бер дә эт өргән тавыш ишетелмәде, Күчәрбай аны шулай озак йөрттеме икәнни?» **дип уйлап куйдым**. (Мирсәй Әмир, Агыйдел.) The sound of the dog barking brought Küchärbai to my mind. "Why had one never heard the dog bark before this? Had Küchärbai perhaps taken him for such a long walk?" I surmised.
- Марзия карчык үзалдына сөйләнә-сөйләнә: «Чәйнең тәмен җибәрде, нәгъләт, коймагым суынып беткәндер инде», – **дип зарлана-зарлана**, кире өенә кайтты. (Мирсәй Әмир, Мөстәкыйм карт йокысы.) The old women Marzia went back into the house, grumbling and talking to herself: "It (i.e., the hog she had just chased out of her potato garden) spoiled my tea (lit., the taste of the tea), that wicked thing. My fritters (pancakes) have probably gotten cold already."

c) In *direct discourse* in which the interlocutor's words are repeated in part or in full to lead in the reply, **дип** serves to connect the repeated part with that of the actual reply.

- Валентина. Бал сорадымы? Ибәт. **Сорадымы дип** ... мин үзем киңәш иттем. (Габдрахман Минский, Синең җырың.) Valentina. Did he ask for honey? Ibät. Did he ask! I myself advised him (to ask).
- Сәфәргали. Илле тәңкә түләгәннән бөлмәссең әле. Фаизә. **Бөлмәссең дип**, синең бурычларыңны түләргә миндә Әндри казнасы юк. (Кәрим Тинчурин, Йосыф белән Зөләйха.) Säfärghäli. You are not going to go bankrupt because you pay out fifty rubles, you know. Faizä. You won't go bankrupt! I don't have an inexhaustible purse to pay your debts.
- Мансур. ... (Ачу белән.) Я, ни әйтерең бар? Фәгыйлә. **Ни әйтерең бар**, дип, җикеренүен күр әле ... Әйтәсе сүзләрем бик күп минем. (Гамир Насрый, Кушамат.) Mansur. ... (Angrily.) Well, what do you have to say? Fäghilä. Have to say. Just look at him screaming. I have a great deal (I want) to say.

d) In *indirect discourse* of the *analytical* kind, to connect the indirect quotation with the author's words.

*Note 1:* The syntactical structure of clauses in *indirect discourse* of the *analytical* kind is very similar to that of clauses in direct discourse. In some instances, it may even be the same, the difference being expressed by intonation. Furthermore, *in writing*, the long dash is *not* used in indirect discourse.

*Note 2:* For a very detailed treatment of both *direct* and *indirect discourse* see: Х. Курбатов, Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре, Казан, 1956, 173 pages, all of them dealing with the above subject.

- Борчулы көннәр күптән онытылды, барысы да мин дигәнчә хәл ителде, **дип санап йөргән** ана телсез-өнсез калды. (Ринат Мөхәммәдиев, Кенәри – читлек кошы.) The mother, who had believed that the worrisome days had long been forgotten, that all had been solved as she had said, was speechless.
- Әле генә ... куерып, ..., менә-менә салкын тамчылар белән коендырам, **дип куркыткан**, көзге шыксыз кара болытлар кинәт таралды. (Ибраһим Салахов, Тайгак кичү.) The ugly, dark autumn clouds, which had just now accumulated ... and threatened to drench us any moment with cold rain (lit., drops), suddenly dispersed.
- Ул тагын аларның капка төбенә килде. Чыкмасмы, берәр җиргә киткән булып, кайтып килмәсме, **дип өметләнде**. (Шәриф Хөсәенов, Мәхәббәт сагышы.) She (Mädinä) went again to their gate. She hoped that he might come out (or), if he had gone somewhere, that he might return.
- Үз сүзләремә үзем нык ышанганга күрә, Тимерҗан да ышаныр **дип уйладым**. (Нурихан Фәттах, Мөдир Саҗидә.) Because I myself believed firmly in what I had said, I thought that Timerjan too would believe it.

e) In *indirect discourse* constructed in the following manner: The predicate verb of the main clause is a verb of knowing, telling, thinking, believing, naming, calling, choosing or the like. The logical subject of the *subordinate* clause appears in the accusative case (less often in the dative).

- Башта ул **кызны** шаярта **дип уйлады,** ... (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) At first he (Yaqub) thought that the girl was joking, ...
- Элек мин **үземне** институт өчен кирәкле **дип исәпли идем**. Алай түгел икән. (Кави Латыйп, Төньякта да күбәләкләр яши.) Before, I used to think that I was necessary to the institute. It turned out not to be so.
- Ул **мине** бар **дип** тә **белми**. (Вакыйф Нуруллин, Әгәр син булмасаң.) He does not even know that I exist.
- – Мин **сине** бүген килерсең **дип уйламадым**, ... (Нурихан Фәттах, Әтил суы ака торур.) "I did not think that you would come today ..."
- – Мин **сине** бу кадәр юмарт, **дип уйламаган идем**, Зөлфия. (ibid.) "I hadn't thought that you were so generous, Zölfiä."

This syntactical construction may also be used in direct address of the analytical kind (see the last two examples).

f) The same construction is also possible with two objects referring to the same person or thing, the first being the direct object, the second the complementary object. The latter may be a noun or an adjective. If both the direct object and the complementary object are nouns, only the first takes the accusative **+ны**, **+не**.

- ... мин кызыл балчыктан төрле нәрсәләр әвәләргә тотындым: күмәч булды, ... ат булды. Хәер, бу соңгы **нәрсәмне ат дип** тә, мөгезсез **сыер дип** тә, хәтта **сарык дип** тә **уйларга** мөмкин иде. (Фатих Әмирхан, Нәҗип.) ... I began to fashion various things from red clay. A roll emerged, ... a horse. By the way, it was possible to think this last thing of mine (to be) a horse as well as a hornless cow and even a sheep (lit., ... to think that this last thing of mine was a horse ...).
- Хәбир берничә романс язды. **Аларны әйбәт дип таптылар**, ... (Шәриф Хөсәенов, Мәхәббәт сагышы.) Khäbir wrote several romances. They found them to be good, ...
- ... тормышымда ... миңа ... яхшы күңелле һәйбәт кешеләр күп очрады. Бу яктан мин **үземне бәхетле дип** әйтә алам. (Гөмәр Бәширов, Көзге ачы җилләрдә.) ... in my life ... I have met many ... good-hearted, wonderful people. In this respect I can call myself lucky.

*Note:* This construction is also possible in *direct* discourse of the analytical kind. For example: – Әйдә танышыйк, – дип, дустанә төстә әйтте Әхмеров, – **Мине Әхмәт Шәрипович дип** йөртәләр. (Фәнил Галиев, Командировка.) "Come, let's get acquainted," Äkhmerov said in a friendly manner. "They call me Äkhmät Shäripovich."

g) If the predicate of the main clause is the verb **дию** in a personal form, **дип** is not used. For example:

- – Мин бит **Нәҗипне** начар **кеше димим.** ... (Әмирхан Еники, Йөрәк сере.) "After all, I do not say that Näjip is an evil man, ..."
- **Димне** хәзерге көндә Башкортстанның иң чиста **елгасы диләр**. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) Today they call the Dim (they say that the Dim is ...) the cleanest river in Bashkiria.
- – **Сезне** татар теле һәм әдәбияты **белгече дигәннәр иде**. Дөресме? – дип сорады. (Газиз Мөхәмммәтшин, Йөрәктәге эзләр.) "I've been told that you are an expert on Tatar language and literature. Is that true?" she asked.
- Маhи. Кирәкми, әни. **Рамазанны ярлы дисәгез дә**, кеше ярдәменә мөхтаҗ түгел ул. (Таҗи Гыйззәт, Чаткылар.) Mahi. It's not necessary, Mother. Though you say that Ramazan is poor (though you call Ramazan poor), he certainly does not need anybody's help.

## The Verbal Adverb in -ганчы, -гәнче, -канчы, -кәнче

**[1266]** This verbal adverb is formed by joining **-ганчы**, **-гәнче** to verb stems ending in a vowel or a voiced consonant; **-канчы**, **-кәнче** to verb stems with a final voiceless consonant: кара – караганчы, эшлә – эшләгәнче, яз – язганчы, бир – биргәнче, кайт – кайтканчы, кит – киткәнче.

**[1267]** The verbal adverb in **-ганчы**, **-гәнче**, **-канчы**, **-кәнче** indicates:

a) That the action of the principal verb is completed *before,* or continues *up to* the beginning of the action of the verbal adverb.
- – Урман чәе менә шундый була ул! – диде, Алия белән Хәмдүнәне кыстарга тотынды. – Әйдә, **суынганчы**, эчегез, ... (Кояш Тимбикова, Тын бакчада.) "This is what forest tea (i.e., tea made with herbs found in the forest) is like!" he said, and began to entreat Aliä and Khämdünä, "Come, drink before it gets cold, ..."
- – Мин әйләнеп **кайтканчы** китмә! (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) "Don't go away before I come back!"
- – ... иртә үк юлга чыкмасаң, шәһәргә **җиткәнче караңгы төшүе** бар. (Шәриф Камал, Матур туганда.) "... if you don't set out on your way early in the morning, darkness may fall before you reach the city."
- Әтисе капкага барып **җиткәнче**, Якуп күрше өйнең койма буенда торды. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сулар үргә акса да.) Yaqub stood at the fence of the neighboring house until his father reached the gate.
- Ул инде авылын, андагы **арыганчы эшләгән** көннәрен ... сагына, мондагы эшсезлегеннән зарлана башлады. (Садри Җәләл, Юләр.) He was already beginning to yearn for his village, ... for his days there when he would work to exhaustion, and he began to complain of his being without work here (i.e., in the city).
- Баймурзин белән малае, чәй эчеп **беткәнче**, бер сүз эндәшмәделәр. (Булат Сөләйман, Абу баба.) Baimurzin and his son kept silent until they finished their tea.

b) It indicates the *spacial limit* of the action expressed by the principal verb.
- Урамнан алып, инешкә төшеп **җиткәнче** алабута, кычыткан, әрекмән басып бетергән буш җир җәелеп ята. (Әмирхан Еники, Туган туфрак.) A vacant lot (parcel of land), which is completely overgrown with goosefoot, stinging nettle, and burdock, stretches from the street until it reaches the brook.
- [Алия]: – Урманны **чыкканчы** үзең генә озатып куй! – диде. (Кояш Тимбикова, Тын бакчада.) [Aliä] said, "Accompany us alone (i.e., not with horse and wagon) until we get through the forest!"

c) It expresses *manner* or *degree* and *intensive action.*
- Ул куа, мин качам, тыннарым **кысканчы** йөгерәм. (Әхсән Баянов, Аргы яр.) He chases me, I run away. I run until I pant for breath.
- Каешыннан ычкындырмый идек ычкындыруын, әмма аның өчен бу чыгулар барыбер гаять зур хөрлек иде. Хәлдән **тайганчы** безне сөйрәп чаба иде, бөтен җирне иснп-тырный иде, ... (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) True, we did not let him (i.e., the dog) off his leash; still these walks were a great measure of freedom for him anyway. He would pull us and run until he tired out, (and) he would sniff and paw the whole place ...
- Иртәгәсен аркаларына үзләре **күтәрә алганчы** бәрәңге, он һәм юл азыгы **йөкләп**, юлга чыктылар. (Айдар Хәлим, Өч аяклы ат.) In the morning, they loaded on their backs as much as they could carry of potatoes, flour and dry food for the journey and set out on their way.

d) It expresses *comparison* with a connotation of *contrast* of actions, *preference* being given to the action of the principal verb.

- Шәфика. Очу – кызлар һөнәре түгел. ... Егылып төшеп харап буласың киләме? Тәнзилә. Яратмаган эштә озак еллар **саргаеп сулганчы**, зәңгәр күктә бер сәгать очып, егылып төшүең **артыграк**. (Илдар Юзеев, Сөйгәнемнең туган көне.) Shäfiqa. Flying is no profession for girls. ... Do you want to perish in a crash? Tänzilä. To fly one hour in the blue sky and perish in a crash is better than to waste away (lit., turn yellow and wilt) for years in work one doesn't like.
- ... – йомгак нәрсәгә кирәк сиңа, – ди. – Аларны **алганчы**, менә шушы алтыннарны **алсаң**, өс-башыңны рәтләр идең, – ди. (Татар халык әкиятләре, Серле балдак.) "... what do you need the balls for," he says. "If you took these gold pieces here rather than those (balls), you would (could) put your wardrobe in order," he says.
- Хәмдия. Син, кызым, кеше сүзен кешегә ташып **йөргәнче**, тот та җыелышка **бар**. Үз күзең белән күр, үз колагың белән ишет. (Риза Ишморат, Якты юл.) Khämdiä. You, my daughter, rather than spreading rumors (lit., going around, carrying people's words to people) go to the meeting right now. See with your own eyes and hear with your own ears. (The matter Khämdiä is upset about is being discussed there.)
- Акбүләк. Айсылу акыллым, мондый хәлдә аларны юатам дип **азапланганчы**, тыныч калдырырга кирәк. Иң яхшысы шул. Уйлансыннар. (Риза Ишморат, Шаулыйлар дулкыннар.) Aqbüläk. Aisylu, my clever girl, in such a situation, rather than trying to console them, one should leave them in peace. That is the best. Let them think.

e) It denotes an action taking place *simultaneously* with, or *parallel* to that of the principal verb.

- Без Гөлҗиһан апа белән аны-моны **сөйләшеп алганчы** Һәдия самавыр куеп җибәрде. Аны тышка чыгарып утыртты. ... Бераздан Һәдия бушады. ... өстәлнең икенче башына – минем каршыма килеп утырды. (Мәхмүт Хәсәнов, Кама таңнары.) While Göljihan and I talked about this and that, Hädiä quickly got the samovar going. She took it outside and set it up. ... After a little while, Hädiä found some free time. ... she came and sat down at the other end of the table, opposite me.

**[1268]** The verbal adverb in **-ганчы**, **-гәнче**, **-канчы**, **-кәнче** may be used with the particle **ук**, **үк** to emphasize its action.

- Мин мәктәпкә **кергәнче үк** укырга өйрәндем. (Мансур Вәлиев, Дулкын.) I learned to read even before entering school.
- Һәр көн иртә белән кояш **чыкканчы ук** Мөхәммәтҗан бабай безне килеп уята. (Мөхәммәт Гали, Көтүчеләр.) Every morning, even before the sun rises, Grandpa Mökhämmätjan comes and wakes us up.

**[1269]** The verbal adverb in **-ганчы**, **-гәнче**, **-канчы**, **-кәнче** may be used in the *dative case* and with a *postposition denoting time* (хәтле, кадәр, чаклы, etc.) and governing that case. This construction has the same meaning as that with the simple verbal adverb. However, it emphasizes the time limit and often connotes urgency of action.

- Кояш **иңгәнчегә хәтле** алар тукталусыз һәм кызу эшләделәр. (Шәриф Камал, Матур туганда.) They worked non-stop and hard until the sun set.
- Сабан ашлыгы **чәчелгәнчегә хәтле** дә рәтле яңгыр булмады. Чәчелгәннән бирле дә булганы юк. (ibid.) Before the spring crops were sown, there was no real rain. Nor had there been any since they were sown.
- Ул аның белән **сөйләшкәнчегә кадәр** килеп чыккан хәлнең төрле якларын уйлап карарга тиеш иде. (Гариф Ахунов, Идел кызы.) Before speaking with him

(i.e., with Urazayev), he (the professor) had to think about and look at the various aspects of the situation which had arisen.

· Кайчан гына бер кием тектерсә дә, ул, искесен ташлап, шул яңасын кия башлый һәм икенче яңа кием **булганчыга кадәр** аны инде салмый иде. (Фатих Әмирхан, Урталыкта.) Whenever he had a new suit made, he (Khäsän) would discard the old one and begin to wear the new one, and he would not stop wearing it (lit., take it off) until he had a new suit again.
· Әйткәнемчә, без Әбүбәкер абзыйларда ике атнадан артыграк – укырга керү мәсьәләсе хәл **ителгәнчегә чаклы** тордык. (Әмирхан Еники, Соңгы китап.) As I said, we stayed with Uncle Äbübäker more than two weeks, until the matter of (my) admission to studies was resolved.

## The Verbal Adverb in -гач, -гәч, -кач, -кәч

**[1270]** This verbal adverb is formed by adding **-гач**, **-гәч** to verb stems ending in a vowel or a voiced consonant, and **-кач**, **-кәч** to verb stems with a final voiceless consonant: аша – ашагач, эшлә – эшләгәч, бул – булгач, кил – килгәч, кайт – кайткач, кит – киткәч.

**[1271]** The verbal adverb in **-гач**, **-гәч**, **-кач**, **-кәч** denotes:

a) An action or state *preceding* the action or state expressed by the principal verb.
  · Таң беленгәндә, алар елга буендагы бер әрәмәлектә иделәр. Көн шунда үтте. Караңгылык **иңгәч**, тагын кузгалдылар. (Хәниф Хәйруллин, Картлык, кемгә шатлык.) When it dawned, they were at a place on the river overgrown with shrubs. The day was passed there. When darkness fell, they moved on again.
  · Яңгыр **туктагач**, яңадан кояш чыкты. (Гадел Кутуй, Яшен.) After the rain stopped, the sun came out again.
  · – Туташ, сезне әтиегез чакыра! – Нигә инде? – **Төшкәч** күрерсең – диде Сабира ... (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) "Miss, your father is calling you!" "Why?" "You'll see when you get down", Sabira said ...
  · Урманга барып байтак эчкәре **кергәч**, бер җиргә туктаганнар болар. Агасы ... әйткән: – Бар, син җиләк җый. Минем балта тавышы ишетелми **башлагач**, килерсең, – дигән. (Татар халык әкиятләре, Үги кыз.) They went to the forest, and after they had gone rather deep into it, they stopped at a certain place. Her (older) brother ... said, "Go, gather berries. When the sound of my ax ceases to be heard, come (back here)."
  · Атна-ун көн **үткәч**, төлке тагын бик иртә торып чыгып китә. (Татар халык әкиятләре, Аю белән төлке.) After a week or ten days passed, the fox again got up very early and left.
  · – Вакыты **җиткәч**, үзем әйтермен! (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) "... When its time has come I'll tell you!"

b) *Cause.*
  · Машинада бик бөркү **булгач**, Заһир ишек пыяласын төшерде. (Таһир Таһипов, Галия.) Because it was stifling in the car, Zahir lowered his door window.
  · Янәшәдән бәхетле елмаеп бабасы атлады. Бабасы **елмайгач**, ул да елмайды. (Ринат Мөхәммәдиев, Беренче умырзая.) Beside him walked his grandfather, smiling happily. Because his grandfather smiled, he smiled too.

c) *Non-committal condition* (see also 1000, 4).

- Җәүһәрия. Сүзем бар сиңа. Зөлфия (гаҗәпләнеп.) Сөйлә, сүзең **булгач**, тыңлыйм. (Риза Ишморат, Якты юл.) Jäwhäriä. I have something to tell you. Zölfiä (astonished). Speak if you have something to tell (me), I'll listen.
- Ишнияз. Барырга кирәк **булгач**, барырга кирәк. (Риза Ишморат, Кайту.) Ishniaz. If it's necessary to go, one must go.

**[1272]** Followed by the intensive particle **та**, **тә** or **ук**, **үк**, the verbal adverb in **-гач**, **-гәч**, **-кач**, **-кәч** indicates that the action expressed by it is *immediately* followed by that of the principal verb.

*Note:* With **та**, **тә** it may also express concession (1002, 5).

- Пәрдә **күтәрелгәч тә**, кулына чыбыркы тоткан Әхмәт сәхнәгә керә. (Мирхәйдәр Фәйзи, Асылъяр.) Immediately after the curtain has risen, Äkhmät comes on the stage, holding a whip in his hand.
- Хәсән, сабактан **кайткач та**, шунда барырга хәзерләнә башлады. (Фатих Әмирхан, Урталыкта.) Immediately after returning from his lesson, Khäsän began preparing to go there (i.e., to the conference).
- Хупҗамал. Камиләттәй җаны-ы-ым, нигә соң аны **кергәч тә** әйтмәдең? (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Khupjamal. Aunt Kamilä, my dea-ear, why then didn't you say that right away when you came in?

**[1273]** The particle **кына**, **кенә**, following the verbal adverb in **-гач**, **-гәч**, **-кач**, **-кәч**, limits or defines more precisely the *time* the action expressed by the verbal adverb ends and the action of the principal verb begins.

- Ниһаять, Бибинур китәргә җыена **башлагач кына** ул самоварын кертеп куйды, әйдәгез, берәр чынаяк чәй эчеп алыгыз, диде. (Габдрахман Әпсәләмов, Яшел Яр.) Finally, only when Bibinur was preparing to leave, did she (Zöbirä) bring in her samovar and invite her to have a cup of tea.
- Алпамша егерме дүрт көн **тулгач кына** уяна. (Татар халык әкиятләре, Алпамша.) Alpamsha awakes only after twenty-four days have passed.
- [Тикшерүче] Шоферга, бу йорт яныннан үтеп, почмакка **борылгач кына** туктарга кушты. (Мәгъсүм Насыйбуллин, Ярканат.) [The investigator] ordered the chauffeur to drive past this house and stop only after turning around the corner.

**[1274]** Taking the suffix **+рак**, **+рәк**, the verbal adverb in **-гач**, **-гәч**, **-кач**, **-кәч** indicates a shade of *incompleteness* of the action, or the *approximate time* of its completion.

- – Һәдия, сез нишләп коенмыйсыз? – дим, ... Һәдия: – Соңрак, эш **беткәчрәк** коенырмын, – дип җавап кайтарды. (Мәхмүт Хәсәнов, Кама таңнары.) "Hädiä, why aren't you swimming (bathing)," I said, ... Hädiä replied, "I'll swim (bathe) later, a little after the work is finished."
- – Өйдә генә уйнап тор әле, улым, – ди. – Урамга соңрак чыгарсың, җылына **төшкәчрәк**. (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел бишек.) "Just play a while longer inside the house, my son," she (his mother) says. "You'll go out into the street later, when it gets a little warmer."
- Кояш кызуы **басылгачрак**, Хәлим тагын урамга чыкты. (Ибраһим Гази, Канатланыр чак.) After the heat of the sun had diminished somewhat, Khälim went out into the street again.

**[1275]** Like the verbal adverbs in **-а**, **-ә** and **-п**, the verbal adverb in **-гач**, **-гәч**, **-кач**, **-кәч** may be reduplicated. This form indicates an intensive action, or the agent's *determination* to carry out the action with the intention to obtain the desired result.

- – **Килгәч-килгәч**, коры кул белән кайтып китәсем килми. (Нурихан Фәттах, Әтил суы ака торур.) "Since I have (decided to) come, I do not wish to return empty-handed."
- Гыйльманов. Ярый. Кыскасы: сезнең, **булгач-булгач**, чын хуҗа буласыгыз килә. Шулай булдырырга тырышырбыз. (Мирсәй Әмир, Миңлекамал.) Ghilmanov. All right. In brief – once you have become it (i.e., chairwoman of the collective farm), you will want to be the real boss. We'll try to have it work out that way.
- Вәлит., ... Миңа атап килдегезме? Бану. **Килгәч-килгәч**, сиңа да күренергә ниятләдем. (Илдар Юзеев, Сөйгәнемнең туган көне.) Wälit. ... Did you come especially to see me? Banu. Since I was here (i.e., Since I did come to this place, town), I decided to see you too.
- – Алайса иртүк шунда юл тотарбыз. Көндез җилли башласа, буш кул белән кайтырга туры килер. – Анысы, **баргач-баргач**, буш кул белән кайтмабыз инде. Бер дә балык капмаса, балыкчылардан алырбыз ..., – диде Нәриманов. (Сөббух Рафиков, Тын елга буенда.) "In that case, we'll go there (i.e., to the lake to fish) early in the morning. If it turns windy during the day, we'll have to return empty-handed." "As to that, once we have gone there, we'll not come back with empty hands for sure. If the fish don't bite, we'll buy some from the fishermen, ..." Närimanov said.

**[1276]** The verbal adverb in **-гач**, etc. followed by an affirmative personal form of the *same verb* indicates that, by dint of great (physical or mental) efforts, the subject succeeds in performing the action.

- Бик озак эзләгәннән соң, **тапкач таптым** шул. After searching for a very long time, I finally succeeded in finding it.
- Рәшидә ... әкрен генә: – Карт үзе больницада ята бит, – диде. Бер мәлгә хәрәктәсез калган Настяның сорашуын көтмәстән, **белгәч белсеннәр** инде дигәндәй, өстәп куйды: – шул, зәм-зәм суыннан инде, әле генә яныннан кайттым. Өченче тапкыр керүе. (Саҗидә Сөләйманова, Йолдызларга йодрык.) Räshidä ... said slowly, "The old man himself (i.e., my husband) is lying in the hospital, you know." Without waiting for Nastya, who for a moment had remained motionless, to ask questions, and as though saying "let them really know it all," she added, "That's so, from (all that) alcohol. I've just come back from him. It's his third time." (Больница – R. хәстәханә, шифаханә.)

## Dialect Forms of the verbal Adverb in -гач, -гәч, -кач, -кәч

**[1277]** In Tatar dialects, the verbal adverb in **-гач**, **-гәч**, **-кач**, **-кәч** has a considerable number of variants some of which occur not infrequently also in literary works as well as in Tatar fairy tales. However, all of these forms do not differ in meaning from the form in **-гач**, **-гәч**, **-кач**, **-кәч**. Variants used in the literary language are:

a) The variant in **-гачыннан**, **-гәченнән**, **-качыннан**, **-кәченнән**. The suffix **+(ы)н**, **+(е)н** is an ancient instrumental[1]), **+нан**, **+нән** the ablative case.

- – Йокла, улым, йокла, – ди әни. – Юып **җибәргәченнән**, хәзер синең кәләпүшең дә бер дә ичмасам яңадан ким түгел! (Гомәр Бәширов, Туган ягым – яшел

[1]) See Ф.Ю. Юсупов, Неличные формы глагола в диалектах татарского языка. Издательство Казанского Университета, 1985, p. 161.

бишек.) "Sleep, my son, sleep," Mother says. "Now, after it has been put through the wash, your skullcap is practically as good as a new one (lit., is by no means inferior to a new one)."

- – Син бит, Хамматова Бану, бик аңлы кеше, мин бит урысчаны сукыр бер тиеннек тә белмим. Ничек итеп укыйм ди инде мин аны шулай **булгачыннан**? (Гариф Ахунов, Идел кызы.) "You, Khammatova Banu, are, after all, a very educated person, but I don't know a bit (lit., one brass kopeck's worth) of Russian. So, how am I supposed to read that then (i.e., the telegram)?"
- Гыймран. Кала кешесе **дигәченнән дә** әллә син мине гомер буе мал күрмәгән әдәм дисеңме? (Гариф Ахунов, Утлар яна учакта.) Ghimran. Although you (may) think that I am (... you may call me) a city man, do you perhaps think that I am a person who has never in his life seen cattle?

b) The variant in **-гачтын**, **-гәчтен**, **-качтын**, **-кәчтен**. The suffix **+тын**, **+тен** is a form of the ablative case.

- ... бераз эндәшми **баргачтын**, «Кара урман» көенә җырлап җибәрде. (Гадел Кутуй, Тапшырылмаган хатлар.) ... after walking for a while without talking, he started to sing the (folk) song "The Dense Forest".
- Ул моңарга бер таяк бирә дә: – Бар, имән башына менеп утыр, җанварлар җыелып **беткәчтен**, уйный башларлар. Алар уйный **башлагачтын**, имәнгә өч рәт таяк белән сугарсың да, аннан килеп чыгар өч егет. ... ди. (Татар халык экиятләре, Патша белән солдат.) She gives him a stick and says, "Go, climb up on an oak tree and sit down (there). After the wild animals have assembled, they will begin to play. When they have begun to play, beat three times with the stick against the oak tree, and three young men will emerge from it. ..."
- Хөснулла, Нәгыймнең иңбашына кулын куеп: – ... Җыелышыгыз **беткәчтен** монда керерсең, бик кирәкле әңгәмәләр бар, – диде. (Шәриф Камал, Матур туганда.) Putting his hand on Näghim's shoulder, Khösnulla said, "... After your meeting has ended, come in here. There are very important things to talk about (lit., important talks)."

c) The variant in **-гачтыннан**, **-гәчтеннән**, **-качтыннан**, **-кәчтеннән**. The suffix **+тыннан**, **+теннән** is a double ablative.

*Note:* The double ablative occurs also with a few words other than verbs. For example: күптәннән 'since long ago', 'long ago'.

- – Ай аллам! ... Әллә сине пәри алмаштырдымы? Аңламыйм, ... Әллә югыйсә Мәскәүдә укып **кайткачтыннан** авыл кызы ошамый башладымы, мине тиң күрмисеңме? (Гомәр Бәширов, И язмыш, язмыш.) "Oh, my God! ... Has some demon changed you? I don't understand, ... Or wouldn't it be that after studying in Moscow, you don't care for the village girl any more, you don't regard me as an equal?"
- **Кайткачтыннан** теге карчык килә дә моңа сөлге бирә. (Татар халык экиятләре, Патша белән солдат.) After he returns (from the bath), the old woman (i.e., the old woman mentioned earlier) comes and gives him a towel.

**[1278]** The verbal adverb in **-гач**, **-гәч**, **-кач**, **-кәч**, immediately followed by **ни**, emphasizes the action or state expressed by the verbal adverb.

- Гөлбикә. ... чөнки мин ул вакытта тиле булганмын, ... Син ни әйтсәң шуны кабатлап утыргынмындыр инде. Синең кимсетеп әйткән сүзләреңә дә җавап бирә **алмагач, ни**. (Гамир Насрый, Яшел эшләпә.) Gölbikä. ... because I must have been crazy at that time, ... It seems I just repeated whatever you said, utterly unable to respond to the humiliating words you spoke.

- Хупҗамал. Камиләттәй дим, исемен генә булса да әйт инде. Камилә. Һи-һи, исемен **әйткәч ни**, син аны хәзер белеп аласың. Бөтен районга атаклы кеше бит ул. (ibid.) Khupjamal. I say, Auntie Kamilä, just tell me his name at least. Kamilä. Hi-hi, if I do tell you his name, you'll know at once who he is. After all, he is a man well known in the entire district. (Kamilä has come to Khupjamal as a matchmaker, but she is not supposed to disclose the man's identity at this time.)

**[1279]** The verbal adverb in **-гач** of **булу – булгач** – placed between a repeated word (in most cases a verb) expresses *strong emphasis,* a *strong belief,* the *firm decision, determination* to perform, or not to perform, the action, or *forcing* someone to perform it.

- – Әни, мин вәгъдәмдә торам, **торам булгач торам** ... **Эчмим булгач, эчмим**, тамчысын да капмыйм, ... (Гомәр Бәширов, Җидегән чишмә.) "Mother, I'll keep my word, I'll definitely (absolutely) keep it, ... I'll positively not drink, I'll not have even one drop, ..."
- – Әйткән сүзем сүз: **пешермим булгач пешермим**! Китүчеләр Көктугайда ашар, монда калучылар теләсә нишләсен. Бүген миңа да ял! (Нурихан Фәттах, Бала күңеле далада.) "What I have said stands, I will not cook! Those who are going away will eat in Köktughai, those who remain here can do what they want. Today I too take a rest!"
- Мөнәвәрә: – Болай да кайтып җитәм, Әсәт абзый, – дип карышып торса да, әтисе яшьләрендәге олы кеше: – **Утыр булгач утыр**! – дип кыстап торгач, утырмыйча булдыра алмады. (Фатих Хөсни, Үтеп барышлый.) Although Mönäwärä resisted, saying, "I'll get back this way too (i.e., on foot), Uncle Äsät," after the elderly man who was about her father's age urged her, saying, "Come now, get on!" she could not but get on (i.e., on the horse-drawn sleigh).
- – Бүген бездә кунарсың, иртәгә ихтиярың, теләсәң кая бар, ди ... Шулай да мин сүземне бирмим: – **Китәм булгач, китәм**, – дим. Исмәгыйль абзый үзенекен: **Җибәрмим булгач, җибәрмим**. (Фатих Хөсни, Йөзек кашы.) "Today you'll stay with us. Tomorrow it's up to you, you go wherever you wish," he says. ... Nevertheless, I don't give in. "I'm leaving!" I say. Uncle Ismäghil doesn't give in (either). "I'm not letting you go!"

**[1280]** The verbal adverb in **-гәч** of **дию – дигәч** – placed between a repeated word (in most cases a verb) indicates *categorical manner of speech.*

Used with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, less often with the verbal adverb in **-а**, **-ә**, **-ый**, **-и**, **салу** expresses the performance of an action *to its full extent,* or it indicates the *sudden, quick, spontaneous,* mostly *unexpected* execution of an action. Furthermore, the construction may imply *courage, boldness, daring* on the part of the agent.

- Майпәрвәз ханым нечкә генә итеп киселгән ак токмачны тәлинкәгә соса, аш өстеннән куе өйрәсен **җыеп сала** һәм Мостафинга суза. (Әмирхан Еники, Саз чәчәге.) Lady Maipärwäz puts a portion of the fine-cut, white noodles on a plate, pours her thick sauce (lit., soup) over the food and serves it to Mostafin.

- Шул көннән соң аңа бер скрипка табып бирү турында хыялланып йөри башладым. Бу турыда әнигә дә **язып салдым**. (Кәрим Әмири, Әсма.) After that day, I began dreaming about finding a violin for her. I even wrote Mother about this.
- – ... Мин сезне шунда очраттым микәнни? ... ул (Байкучатов) хәзер үзе дә ... йөрәге дулкынланыбрак тибә башлавын тойды. Шулай да, алданудан куркып, үткәнне ачыкларга тырышкан соравын **әйтеп салды**: ... (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) "... Perhaps, (Could it be that) I met you there?" ... he (Baiquchatov) himself ... felt his heart begin to beat faster from excitement. Nevertheless, afraid of being mistaken, he put this question to her, endeavoring to throw light on the past: ...
- – Инде хәзер менә монда килдем. Дөресен генә **ярып салырга**, ... (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "And now, you see, I have come here; to tell the truth and only the truth, ..." (The speaker has finally got the courage to do so.)
- Аңа үз хәленең ул уйлаганча гына да түгел, бәлки авыр бер фаҗига /façiʤə/ булуын улы белән булган кечкенә бер сөйләшү **ачып салды**. (Гөмәр Бәширов, Көннәрнең берендә.) A little talk which he had with his son suddenly made it clear to him (i.e., to the father) that his (i.e., the father's) situation was not just as he had thought (i.e., nothing to worry very much about), but that it was a deep tragedy.
- Хуҗасы кушмаса да, ... туры атка печәнлектән яшел печән **төшереп салдым**. (Давыт Юлтый, Бәләкәй Котош.) Although its owner had not given me permission, I threw the bay horse ... some green (i.e., newly-cut) hay from the hayloft.
- – Бәлки шулайдыр. Әмма син мине тыңларга тиеш. – Тыңлыйм! Бөтен игътибарым синдә, әти, – дигән булып каршыма ук килеп утырды бу. Аннары **әйтә салды**. – Ләкин алдан ук кисәтеп куям: ... (Мәхмүт Хәсәнов, Инженерлар.) "Perhaps this is so. But you must listen to me." "I'm listening! You have my full attention, Dad," he said and sat down right opposite me. Then he spoke out, "But I am warning you in advance: ..."

**[1358] Ташлау**.

Together with a verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, **ташлау** indicates:

a) The *rapid, intense,* or *resolute* execution of an action *attaining a result.*
   - Хәзер дию пәриләре тотыналар да егет әйткәннәрне ике сәгать эчендә **эшләп ташлыйлар**. (Татар халык әкиятләре, Өч күгәрчен.) Now the demons set to work and within two hours accomplish (i.e., build) everything the young man had told them to do.
   - Караңгыдан файдаланып бик күп нәрсә **эшләп ташладык**. (Гомәр Бәширов, Мунча.) Taking advantage of the darkness, we accomplished a great deal (i.e., by working rapidly and intensely repairing a telephone line disrupted by an enemy mine).

b) A *sudden,* more often *unexpected,* action carried out *forcefully, violently,* or *unceremoniously.*
   - ... кызганудан, Вазыйфаның йөрәге кысылып куйды. ... Кеше сүзенә карап, гөнаһсыз балага кул сузганы өчен, үз-үзен **өзгәләп ташлыйсы** килде. (Кәрим Әмири, Югалган малай.) ... Wazifa's heart broke with regret. ... She wanted to tear herself apart for having laid hand on an innocent child on the basis of one person's word.
   - Сахрада яткан вакытларында, төннең бер мизгелендә бик каты җил исеп, боларның чатырларын **күтәреп ташлады**. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) At one moment in the night, while they were bedded down in the desert, a very strong wind sprang up (lit., blew) and carried their tents away.
   - Тик әнисе дә, әтисе дә улларының андый гадәтен бер дә яратмыйлар. ... Чын-чыннан ачуланып, **тиргәп ташлыйлар** аны. (Мирсәй Әмир, Анасы һәм баласы.)

But both his mother and his father do not like that habit of their son's at all. ... They really get angry and give him a dressing down.

c) Expresses *erroneousness, exaggeration.*

- Рәис, хатны укып бетергәч, берникадәр вакыт онытылып торды. ... Аннары ул бик зур хата **эшләп ташлаган** кеше сыман кинәт куркынып, айнып киткәндәй булды. (Мирсәй Әмир, Мәхәббәт хаты.) After reading the letter, Räis became lost in thought for some time. ... Suddenly becoming frightened like someone having made a very big mistake, he came to himself.
- Шулай да бер мәлне, саксыз кыланып, чак кына юләрлек **эшләп ташламады** Бибинур. (Аяз Гыйләҗев, Җомга көн, кич белән.) However, on one occasion, Bibinur acted rashly and almost did a foolish thing.
- – Бик затлы эчемлек. Сихәтле әйбер, – дип сөйләп китте Санька. – Чин якларыннан кайтартабыз. Бәһасы алтын белән үлчәнә. Сирәк нәрсә. ... Аны Гөлйөзем бүлдерде: – Йә инде, артык **мактанып ташладың** түгелме? (Флүс Латыйфи, Хыянәт.) "This (i.e., tea) is a very fine (noble) beverage. It is a wholesome (beneficial) thing," Sanka went into explaining. "We have it brought from China. It is worth its weight in gold. It is a rare thing." ... Gölyözem interrupted him: "Oh, come on, you are really overdoing it with your praise, aren't you?"

**[1359] Тору**.

Used with the verbal adverb in **-а**, **-ә**, **-ый**, **-и**, **тору** indicates:

a) An action or state continuing *for a certain period of time.*

- Шулай уйлана-уйлана, Барлас артыннан **бара торам**, ниндидер урамнар аша узабыз. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) Cogitating thus, I keep walking behind Barlas. We are passing through some streets or other.
- – Соңрак белерсең, ашыкма, – диде Барлас, ... – Син биредә ял **итә тор**. Мин бер җиргә барып кайтасым бар. (ibid.) "You'll learn about that (i.e., about Barlas' plan) later, don't be in a hurry," Barlas said. "You keep resting here. I've got to go somewhere and do something (lit., go someplace and return)."
- Кар бер эреп бетә, бер яңадан ява. Кайбер көннәрдә җилләр исә. Төннәрендә бураннар улый. Кыш шулай әкрен генә **уза тора**. (Нәби Дәүли, Язмышка юл.) Now the snow melts completely, now it falls again. On some days the wind blows. At night snowstorms howl. The winter passes slowly in this manner.

b) An action or state continuing *until the beginning of another action* or *state.*

- Озак җавап **бирми тордылар**. ... Ниһаять, ... телефоннан таныш тавыш ишетелде: – Тыңлыйм сезне. (Разил Вәлиев, Иске сәгать дөрес йөри.) For a long time there was no answer. ... Finally, ... a familiar voice sounded (lit., was heard) from the telephone: "Hello."
- – Мин дә шулай уйлый идем. **Үгетли торгач**, моңа бүтәннәрне дә күндердем шикелле. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) I too thought that way. After instructing (teaching) them, I convinced the others too, it seems.
- Бара-бара, җитә бу тагын бер авылга. Бу авылның урамы белән **бара торгач**, бер бай йортын күрә. (Татар халык әкиятләре, Серле балдак.) Going along, he comes to still another village. After walking a while along the (main) street of this village, he sees the house of a rich man.

c) An action *repeated regularly, habitually.*

- Барлас көндезләрен берүзе генә каядыр шулай **китә, кайта торды**. Билгеле, кайткан саен аның куллары буш булмый иде. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) Barlas thus went out (lit., went and returned) somewhere alone during the day. Of course, each time he returned, his hands were not empty.

- Хәзер мин бер ялгыз. Күзләремә яшь тулды. Шунда халык арасында туктап: «Әнием, син кайда?» дип кычкырасым килде. Ә егет миңа һаман әйдә-әйдә, дип **әйтә тора**, аркамнан төрткәли. (ibid.) Now I was all alone. My eyes filled with tears. I felt like stopping (lit., I wanted/wished to stop) right here among the people and cry out, "Mommy, where are you?" But the fellow kept telling me to move on, continually pushing me in the back.
- Инеш ... яз көннәрендә көчле ташкыннар булып, елдан-ел урынын **үзгәртә тора иде**. (Кәрим Әмири, Югалган малай.) In the spring, when strong floodings occurred, the brook ... changed its course (lit., place) from year to year.

**[1360]** Used with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, **тору** indicates:

a) An action or state continuing *unchanged during a certain period of time.*

- **Чатнап торган** кышкы аяз төннәрнең берендә Гәрәй, гадәттәгечә, иптәш егетләре белән урамга чыкты. (Мирсәй Әмир, Тун ачуы.) On a very cold, clear winter night, Gärey went out into the street with his young friends, as was his habit.
- – Бер-ике тәүлектән кәрван килеп җитәр. Багбан коесы янында **көтеп торсыннар**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) The caravan will arrive in one or two days. Let them wait at the Baghban well.
- «Ышанмыйсыз икән, әйдәгез өйне бикләп китик», – ди теге. – Берәр айдан килербез, машина һаман **эшләп тора** торган булыр. (Атилла Расих, Ишан оныгы.) "If you don't believe me, then come on, let's lock up the house and leave," he says. "After one month we will come (back), and the machine will still be working (the same way)."
- Маһирә ... бик озак сүз таба **алмыйча торды**. (Габдрахман Әпсәләмов, Ак чәчәкләр.) ... for a long while Mahirä could not find words.

b) An action or state continuing *temporarily* over a *limited* period of time.

- Аннары чалбар, ялтырап торган яңа түфли, пиджак – ул аларны бүгенге көн өчен кемнәндер **алып торган...** (Әхсән Баянов, Яшьлегемне эзлим.) Then, pants, gleaming new shoes, a jacket – she had borrowed (lit., gotten) them, it seems, from someone for that day...
- ... мәҗлес ясарга безгә бер бүлмәләрен дә **биреп торганнар**. ... they had even given us one of their rooms for the banquet.
- Үзе адымнарын кызулап, Суфияның иптәш кызына юнәлде. Тулай торактан сөрелгәннән бирле Суфия аңарда **торып тора** иде. (Ибраһим Гази, Гаепсез гаеплеләр.) Quickening his steps, he went to see Sufia's girl friend. Since the time Sufia had been evicted from the hostel she had been staying with her.

c) An action *repeated regularly* during a certain period of time.

- Казан белән Уфа арасында көн саен поезд **йөреп тора**. (Мирсәй Әмир, Күңелле сәяхәт.) A train runs every day between Kazaan and Ufa.
- Кызы Җәвиттән хат арты хат **алып торды**. (Мөсәгыйт Хәбибуллин, Чоңгыллар.) His daughter received letter after letter from Jäwit.
- ... Фәрит үзе дә гаилә корып җибәргәч, әнисе акчадан бөтенләй баш тартты! Алай гынамы сиңа! Үзе әле тозлы казын, әле кагын, оекбашын-бияләен, әле башкасын **җибәреп торды**. (Фоат Садриев, Таң җиле.) ... after Färit established his own family, his mother absolutely refused to accept any (support) money (from him)! As if that weren't enough! She herself kept sending, now some of her salted goose, now some of her fruit jelly cake, now socks and gloves, now something else.
- ... атна-ун көн дә узмагандыр, ... җанлы эш башланды. ... Бер төркем йөк машиналары шәһәрдән төзү материлларын **ташып торды**. (Әбрар Шәмин, Камай

күпере.) ... perhaps not even a week or ten days passed, ... when work began in earnest. ... One group's trucks kept hauling building materials from the city.

d) An action carried out by a person or thing *appointed* or *designated* for that purpose.

- Егет, ризалык биреп, болар янында калырга, боларга аш-су **хәзерләп торырга** булды. (Татар халык әкиятләре, Өч күгәрчен.) The young man consented. He promised to stay with them and to prepare the meals for them.
- – Ә теге балаханәле йортта кем яши? – Бер сәүдәгәрнең өлкән хатыны. Айдан артык туган кышлагында сыйланып ята инде, йорт-җиренә күршеләр генә күз-колак **булып тора**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) "And who lives in that house with the balcony?" "The older wife of a merchant. She has been regaling herself in her native village for more than a month now. The neighbors are keeping an eye on her property."
- Менә шунда мич **ягып**, идән **себереп торырга** бер кеше кирәк булды. (Мөхәммәт Гали, Телсез Сәйфулла.) Now, the need arose there (i.e., in the office) for a person to heat the stove and to sweep the floor.
- Шулай итеп бер хак билгеләп, Сәйфулланы канцелярия **җыештырып**, мич **ягып торырга** алдылар. (ibid.) Thus, they determined a wage and hired Seyfulla to keep the office tidy and to heat the stove.

e) Indicates *emphasis, underlines* the action.

- – Алайса юлдашыгыз ял итә торсын, ә без монда **тукталып тормыйк**, кузгалыйк. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) "If that's so, let your traveling companion rest, but let us not stop here, let's get going."
- – Ярар, – мин әйтәм, – бер юлга **әйтеп тормам**. Яңадан тәртипне бозмассыз. (Мирсәй Әмир, Әлтәф исәбе.) "All right," I say, "this one time I'll let it go (lit., I won't say/report it). Don't break the rules again."
- Көзгедән Мәрьямгә утыз биш яшьлек бер хатын **карап тора** иде. Ә тойгылары һаман унҗиде яшьлек кызныкы. (Миргазиян Юныс, Табу һәм югалту.) From the mirror a thirty-five-year-old woman was looking at Märyäm. But her feelings were still those of a seventeen-year-old girl.
- Шәһәрнең бу соңгы еллардагы үсеше бигрәк тә күзгә **бәрелеп тора** бит. (Мирсәй Әмир, Казан урамнарында.) After all, the growth of the city during these recent years is really striking.

f) Indicates an action *coming about* or *changing* at the moment of speaking.

- – Ә минемчә, куркасың. – Юк, – диде Хәмит, катгый рәвештә, – куркак түгеллегемне **күреп торасыз** ич. ... – Курыкмасаң, дөресен сөйлә. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) "But in my opinion, you are afraid." "No," Khämit said categorically, "after all, you (can) see that I am no coward." ... "If you are not afraid, then tell the truth."
- – Яхшы, – диде Ризван, ... – Берничә минутка Дураковны **чыгарып торыйк** әле, ... (ibid.) "Good," Rizwan said, ... "Let's take Durakov outside for a few minutes, please, ..."
- Әһли ... чаршауга якынлашты. Күрәсең, нидер сизенә иде ул. Чаршауга карап, чак кына **уйланып торды**. (ibid.) Ähli ... approached the curtain. He sensed something, it seemed. Looking at the curtain, he thought for a (brief) moment.
- – Балам, бар китер әле миңа шәһадәтнамәңне! – диде әни миңа. Мин моны сабырсызлык белән көтә идем. Урынымнан ничек **сикереп торганымны** белмим. Аягым җиргә тияр-тимәстән чабып, язу өстәленә килдем, ... (Галимҗан Ибраһимов, Яз башы.) "My child, go and bring me your report book, please!" Mommy said to me. I was waiting for that with impatience. How I got up from my seat I don't remenber

(lit., know). My feet hardly touching the ground, I ran over to the desk, ... (The boy has just brought home an excellent school report and is eager to show it to his mother.)

**[1361] Тору**

in the *negative* following a verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, indicates the *continuous non-execution* of an action.

- Көн болытлы, **явып тормаса** да, күңелгә авыр, җилле, салкынча. (Мәдинә Маликова, Ак давылда тал бөресе.) The day is cloudy. Although it isn't raining, it's depressing, it's windy, cool.
- – Утыр, улым, аша, ачыккансыңдыр. Хәйдәр **кыстатып тормады**. (Әбрар Шәмин, Сагындырган сукмаклар.) "Sit down, my son, eat, you must be hungry." Kheydär did not need urging.
- Галимә апа аның сүзләре беткәнне дә **көтеп тормый**: ... (Мәҗит Гафури, Кара йөзләр.) My sister Ghalimä does not even wait for him to finish his words: ...
- Фарукҗан бәхәскә **кереп тормады**, үзен күбрәк кызыксындырган мәсьәләгә күчте. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) Faruqjan did not engage in argument but changed over to a matter which interested him more.

**[1362] Тору**

with the verbal adverb in **-п** of **дию** – **дип** – indicates that the subject has come to a certain *conclusion, opinion, decision.*

- – Аһ, шулаймыни? – диде Аксолтанов шаяртып. – Ә мин тагын шигырь язучыны ачыкларга телисең **дип торам**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) "Ah, is that it?" Aqsoltanov said jokingly. "And I've been thinking that you wanted to find out who the writer of the poem was."
- Рәхим. Я, туйны кайчан итәбез инде? Мортаза. Бер атнадан **дип торабыз**. (Риза Ишморат, Якын дус.) Räkhim. Well, when are we going to have the wedding then? Mortaza. We've been thinking of a week from now.
- Бабай сәламен бирү белән генә туктамады, ... сүзен тагы өстәде: – Мин юк **дип торам**, бер мөселман бар икән әле! (Галимҗан Ибраһимов, Диңгездә.) The old man did not stop with just saying hello, ... he added besides, "While I've been thinking that there were none, it turns out that there is a Moslem here!"

**[1363] Төшү**.

Used with the verbal adverb in **-а**, **-ә**, **-ый**, **-и, төшү** indicates:

a) The *partial* execution of an action *increasing* or *decreasing* in *intensity.*

- Шуннан Әхмәй тагын сөйләде, икенче кат сөйләгәндә әллә ничек тавышы тагын да **көчәя төште**. (Мирсәй Әмир, Пар күгәрчен.) Then, Äkhmey spoke again. Speaking the second time, his voice became somehow still stronger.
- Урманов, ...: – Сез тазаргансыз! **Чибәрләнә төшкәнсез**, – дип, гади мактау сүзләрен әйтеп, аның кулын кысты, ... (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) ... Urmanov, shaking her hand, payed her a sincere compliment, saying: "You look healthier. You have become more beautiful, ..."
- – Без бит якташлар. Болай булгач инде мин тагын да **эри төштем**. (Мирсәй Әмир, Аңлашылды.) "After all, we are fellow countrymen." This being the case, I became still mellower.
- – Рахманкол турында да кайгыртырга кирәк безгә, – диде Юлтай тавышын **экренәйтә төшеп**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) "We must also take care of Rakhmanqol," Yultai said, lowering his voice.

- Шофер машинасын **акрынайта төште**. (Әбрар Шәмин, Күңел күзе.) The chauffeur slowed down his car.
- Верхильо адымын **кызулый төште**. (Миргазиян Юныс, Харара җиле искәндә.) Verkhilyo quickened his steps.

b) An action performed partially, a little, within a *certain period of time* or in a *certain direction.*
- Балҗан бераз **тынычлана төште** ... (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) Baljan calmed down a little ...
- Сәрби дә язга таба бераз **үзгәрә** һәм **ябыга төште**. (Давыт Юлтый, Бәләкәй Котош.) Towards the summer, Särbi too changed a bit and lost some weight.
- Һава бераз **суына төшкән иде**. (Миргазиян Юныс, Харара җиле искәндә.) The air had cooled down a little.
- Томан **тарала төште**, таң ата башлады. (Батулла, Алып батыр маҗаралары.) The fog lifted somewhat. It began to dawn.
- Кояшлы, җылы көн, шәһәрдәге язгы җанланыш аның күңелен бераз **күтәрә төште**. (Закир Садыйков, Ясалма чәчәкләр.) The warm, sunny day, the city's spring awakening cheered him up a little.
- Ризван, башын **күтәрә төшеп**, авыр гына көрсенеп куйды. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) Raising his head somewhat, Rizwan heaved a deep sigh.
- ... җил тына төште һәм циләкләп койгандай яңгыр ява башлады. (Барлас Камалов, Ялыкмаслар.) The wind abated somewhat and the rain began to come down in torrents (lit., as though poured out by buckets).
- – Син ничек уйлыйсың, ә? – Ул, башын чак кына **бора төшеп**, шул ук вакыт карашын алга текәлгән килеш, җавап көтте. (Мәдинә Маликова, Фидая.) "What do you think?" Turning his head just a little bit, and at the same time staring ahead, he waited for an answer. (The speaker is sitting behind the wheel of a car, his interlocutor is in the back seat.)
- – Син аңа өйләнмә. Теләсә кемне алып кайт, аны түгел. Мәңге бәхиллегем юк! диде ул, терсәкләренә **таяна төшеп**. (ibid.) "Don't get married to her. Bring home anyone, but not her. I will never forgive you!" she said, raising up a little on her elbows. (The speaker is lying sick in bed.)

**[1364] Төшү**

with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** indicates:

a) Movement in a *downward direction.*
- Машинадан чыктык. Егетләр дә җиргә **сикерешеп төштеләр**. (Фаил Шәфигуллин, Өй салуның ние бар.) We descended from the truck. The young men too jumped to the ground.
- Бервакытны өч күгәрчен тагын **кайтып төштеләр**. (Татар халык әкиятләре, Тире Такыя.) At some time, the three pigeons returned again (i.e., returned, coming down from the sky).
- Шул минут көрт өстеннән берәү **йөгереп төште** дә минем алга килеп туктады. (Давыт Юлтый, Бәләкәй Котош.) At that moment, someone ran down from the snowdrift and stopped in front of me.
- Аю бүреләрне алып киткән. Болар кәҗә белән сарыкның эзенә **барып төшкәннәр**. (Татар халык әкиятләре, Кәҗә белән сарык.) The bear took the wolves with him. They came upon the tracks of the goat and sheep.

b) The *sudden, unexpected* execution of an action, or an action *completely enveloping* the subject or the object.

- Нәкъ шул вакытта җан-фәрманга чабышып дүрт атлы **килеп төштеләр**. Көтелмәгәндә **килеп төшкән** бу кешеләр сатучының яхшы кәефен боздылар. (Мирсәй Әмир, Машина әкияте.) Exactly at that moment, four riders suddenly came gallopping at a headlong pace. These men, who came unexpectedly, spoiled the salesman's good humor.
- Шулай, ... акчага аптырап йөргәндә, үзенең малаен ияртеп, абый **килеп төште**. (Мирсәй Әмир, Кая китә бу акча.) Thus, ... while I was in a hopeless financial situation, my older brother, accompanied by his son, unexpectedly arrived.
- Шәмсиев шунда ук сизде: бу калын кара кашлы, карчыганыкыдай үткен кара күзле ... кыз, ..., аңа бәя бирергә килгән икән. Бердән **каушап төште** егетебез! (Әмирхан Еники, Ахирәт.) Shämsiev immediately sensed: This girl with thick, black eyebrows, piercing, black eyes resembling those of a hawk, ... had obviously come to judge (lit., evaluate) him ... Our young man suddenly became disconcerted.
- Үткән ел үкенгәннәрем кылт итеп исемә **килеп төште**. (Мирсәй Әмир, Әбелгата күпере.) The regrets I had last year (for having failed to do the things I ought to have done) suddenly came to my mind.

**[1365] Төшерү**.

Used with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, this transitive form of **төшү** indicates that the action is *carried out* in a *downward direction.*

- – Әгәр дә чәйханәдә безгә берәр куркыныч янаса, тавыш-тынсыз юкка чыгарга. Мөшкил хәлдә лампаны **бәреп төшерергә** мөмкин. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) "If some danger should threaten us in the tea house, disappear silently. If things get rough, we can knock out (lit., knock down) the lamp."
- Диңгез суы тәнгә сеңеп калган йокыны **юып төшерде**. (Миргазиян Юныс, Энҗе эзләүчеләр.) The sea water washed away the sleep which had pervaded his (lit., the) body.

*Note:* The above form may also be used figuratively.

- Кинәт шул чакта күз алларым томаланды. Мине кемдер ниндидер бик тирән базга **төртеп төшерде** кебек. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) Suddenly, at that moment, I blacked out (everything went black). It was as if someone pushed me down into some very deep cellar.
- Фәритләр киткәч, Нуриасма казларын Ыкка **куып төшерде**. Алар каңгылдаша-каңгылдаша ярдан аска йөгерделәр, ... (Фоат Садриев, Таң җиле.) After Färit and his family left, Nuriasma chased her geese down to the (river) Ik. Gaggling away, they ran down from the bank, ...

**[1366] Туюю**.

Used with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, **туюю** indicates the agent's *satisfaction* or *contentment* with the action.

- Балалар **уйнап туйдылар**, ашарга сорый башладылар. (Мирсәй Әмир, Аюханов.) The children got tired playing and began to ask for food.
- Чәй озакка сузылды. Балалар, **эчеп туеп**, уеннарына ябыштылар. (ibid.) Tea continued for a long time. The children, having drunk their fill, began to play their games.
- Әле дә **сөенеп туя алмыйм**: миңа зур алабуга эләкте! (Әбрар Шәмин, Олы бөркет.) I still can't get over it (lit., can't rejoice enough)! I caught a large perch!
- Үзе бик әйбәт кеше бит ул Сәйфулла. Инде очрасаң, ... **сөйләшеп туймый**. (Мөхәммәт Гали, Телсез Сәйфулла.) That Seyfulla is really a very pleasant man. Whenever you meet him, ... he can't talk (converse) with you enough.

**[1367] Утыру**.

In conjunction with a verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, **утыру** expresses a *comparatively prolonged, uninterrupted* action or state performed or existing in *one and the same place.*

- ... шул чишмә янында бер каен **үсеп утыра**. (Татар халык әкиятләре, Серле балдак.) ... beside that spring a birch is growing.
- – Биредә бакчаларга **күмелеп утырган** авыл бар иде, кайда ул? – дип сорый миннән сыерчык. ... Бу агач тирәсендә җәй буена чәчәккә **күмелеп утыра** торган гөлбакча бар иде. (Мирсәй Әмир, Сыерчык.) "There was a village here buried in gardens. Where is it now?" the starling asked me. ... "Around this tree there was a flower garden buried in flowers throughout the summer."
- Диңгез төбендә гаҗәеп матур мәрҗән урманы **үсеп утыра иде**. (Миргазиян Юныс, Энҗе эзләүчеләр.) There, on the sea bottom, grew an amazingly beautiful coral forest.
- Еракта елга буенча **тезелеп утырган** зәңгәр тәрәзәле матур ак йортлар күренә. (ibid.) Beautiful, white houses with blue windows are visible in the distance, standing in a row along the river.
- Хупҗамал карчык шулай, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, электр плитә өстендә **кайнап утырган** кастрюля тирәсендә урала. (Мирсәй Әмир, Егет шә-ә-әп.) In that manner, the old woman Khupjamal, talking to herself, busies herself around the casserole which sits boiling on the electric cooker.

**[1368] Узу**, **Үтү**.

Used with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, **узу** or **үтү** expresses:

a) An action performed *in passing, incidentally.*

- ... Давыт, ... китапларны актарып, берәмберәм мактау сүзләре **әйтеп үтте**. (Галимҗан Ибраһимов, Безнең көннәр.) ... David skimmed through the books ... and in passing said a few words of praise about each of them.
- Нуриасманың йөрәге кысылды, тез буыннары йомшады. Башыннан «менә, менә ул сиздергән нәрсә» дигән уй яшендәй **йөгереп узды**. (Фоат Садриев, Таң җиле.) Nuriasma's heart sank (with apprehension), and she went weak at her knees. The thought "here, here is the premonition I was having" flashed through her mind like lightning.
- ... уйнаклый-уйнаклый куышып ике күбәләк **очып үтте**. (Газиз Мөхәммәтшин, Дулкыннар.) ... playfully chasing each other, two butterflies flew past.
- Ниһаять, кояш чыкты. Дөнья дәррәү яктырып китте. Һавада сузылып көмеш тоҗымнар **очып үткәләде**. (Мәхмүт Хәсәнов, Язгы аҗаган.) Finally, the sun came out. The surroundings (lit., world) immediately lighted up. In the air, drawn-out, silvery shreds of gossamer floated past from time to time.
- Билгеле, бу уйлар, бу күренешләр дә минем аңымда яшен тизлеге белән генә **чагылып үттеләр**. (Мирсәй Әмир, Якташ.) Of course, these thoughts, these images flashed through my mind with the speed of lightning.
- Хәер ... алдыннан, киң күңелле бу һәйбәт егетнең үзе турында бер-ике сүз **әйтеп узасы** килә. (Гомәр Бәширов, Мунча.) However, before ... I wish to say a few words about this magnanimous, remarkable young man himself.

b) The execution of an action in an *exhaustive manner* from its beginning to its end.

- Мәсьәлә яхшырак аңлашылсын өчен, мин сине бер вакыйга белән **таныштырып үтәм**. (Гадел Кутуй, Тапшырылмаган хатлар.) In order that you might understand the matter better, I am going to acquaint you with one (particular) event.

- Ул икенче кат уянганда, сәгать тугызны **сугып узган** иде инде. (Мирсәй Әмир, Аюханов.) When he awoke the second time, the clock had already struck nine.
- Ниһаять, мин – фәннәр кандидаты! ... Әйткәнемчә, беренче киртәне **сикереп уздым**. Спортта һәм, билгеле, тормышта беренче киртәне **сикереп үтүе** читен. (Туфан Миңнуллин, Хәсән Вәгыйзович.) Finally, I am a candidate of science! ... As I said, I have overcome the first hurdle (lit., have jumped over the first hurdle). In sports and, of course, in life, overcoming (jumping over) the first hurdle is difficult.

**[1369] Чыгу**.

In conjunction with the verbal adverb in **-п**, **-ыр**, **-еп**, **-чыгү** indicates:

a) The *direction* of an action *from within, through, across* something, or *from one place to another.*
   - Читлек ачылу белән кош **очып чыга** да Арсланга әйтә: ... (Татар халык әкиятләре, Алтын кош.) As soon as the cage is opened, the bird flies out and says to Arslan: ...
   - Хәсән туп-туры әнисе янына килде. – Әни, беләсеңме: әти Каманы тын да алмыйча икенче рәт **йөзеп чыга**! (Мирсәй Әмир, Ялантау кешеләре.) Khäsän came straight to his mother. "Mommy, do you know, Dad is swimming across the Kama a second time without having taken a rest!"
   - Әнә ташлар арасыннан **чаптырып чыккан** салкын чишмә. (Миргазиян Юныс, Энҗе эзләүчеләр.) There is a cool spring gushing out from among the rocks.
   - ... урманнан килгән үзәннең ике тармагы бар. Берсе урман эченнән Иделгә таба китә, ә икенчесе күпергә таба **борылып чыга**. (Әбрар Шәмин, Камай күпере.) ... the riverbed (channel) which comes from the woods has two branches. One runs from inside the woods towards the Volga, the other makes a turn towards the bridge.
   - Мин аны тауларга, урманнарга **алып чыктым**, ... (Галимҗан Ибраһимов, Көтүчеләр.) I took her out to the mountains and forests, ...

b) The course of an action from the *beginning to the end.* Often, the action is performed in an *exhaustive, thorough manner.*
   - Шуннан соң кыскача гына ул, безгә үзенең бездән киткәннән соң кайларда булганын, нишләгәнен **сөйләп чыкты**. (Мөхәммәт Гали, Рәхмәтулла тегүче.) After that, he related to us briefly at which places he had been and what he had done after he had left us.
   - – Әгәр дә эштә сездән ярдәм дә булса, **очлап чыгуны** мин үз өстемә алыр идем. (Әбрар Шәмин, Камай күпере.) "If I should get help from you in this work, I would take it upon myself to see it through."
   - ... Фарукҗан гәзитләрне тулысынча **караштырып чыкты**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) ... Faruqjan perused the news-papers thoroughly.
   - – Яз: «Кадерле иптәш Имтиханов! Хикәягезне **укып чыктым** ...» (Мирсәй Әмир, Имтихан.) Write: "Dear colleague Imtikhanov! I have (thoroughly) read through your story ..."
   - – Сез бу кулъязманы таныйсызмы? – диде [Артур]. Хатын калтыранган куллары белән хатны шәм янына китеребрәк карады. – Әтием кулы! – диде. ... ул, кечкенә генә кәгазь кисәген әйләндереп-әйләндереп, җентекләбрәк **күзәтеп чыкты**. – Шигем юк, – диде. – Әтием үзе кайда соң? (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) "Do you recognize this handwriting?" [Arthur] said. Her hands trembling, the woman brought the letter somewhat closer to the candle and looked at it. "It is my father's hand!" she said, ... turning the rather small piece of paper this way and that way, she examined it more thoroughly. "I have no doubt," she said. "Where is my father then?"

c) An action continuing through a *certain period of time.*
   · Флүр Сәхбиевич кыз тәкъдим иткән урындыкка, өстәл янына утырды. Бүлмәгә күз **йөртеп чыкты**. (Рәфкать Кәрами, Йөрәгемне ут алган.) Flür Säkhbievich sat down on the chair at the table which the girl had offered him. He took a glance round the room.
   · Бу исемне ишеткәч, Хәйдәрнең күңелендә күптәнге хатирәләр **калкып чыкты**. Әйтерсең лә, кичә генә булган хәл. (Әбрар Шәмин, Сагындырган сукмаклар.) When he heard this name, old memories arose in Kheydär's heart. It was as though it had all happened only yesterday.

d) The *final point* of an action, or a *result attained.*
   · Эшнең үзе уйлаганча **барып чыкмаячагын** күреп, Балҗан карыша башлады. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) Seeing that things were not going to come out as she had thought, Baljan began to resist.
   · – Күр дә тор, бергәләп бөтен кыенлыкларны **җиңеп чыгачакбыз**. (Әхсән Баянов, Яшьлегемне эзлим.) "You'll see, together we shall overcome all difficulties."
   · Караңгы төште. Ниһаять, Закир белән Кәримуллин ниндидер юлга **килеп чыктылар**. (Әбрар Шәмин, Югалган кыз.) Darkness fell. Finally, Zakir and Kärimullin came upon some sort of road.
   · Җәйге матур көннәрдә монда йөрү гаҗәп күңелле. Автобустан төшеп әллә ни ерак китмисең, куе агачлыклар арасындагы кыргый урыннарга **барып чыгасың**. (Атилла Расих, Урланган хәзинә.) Walking here on beautiful summer days is amazingly pleasant. Getting off the autobus, you don't walk very far until you come upon some wild places among dense stands of trees.

e) The *unexpected* or *sudden* execution of an action.
   · Көтмәгәндә Шәмсия карчык **килеп чыкты**. (Әбрар Шәмин, Сагындырган сукмаклар.) Unexpectedly, the old woman Shämsiä appeared.
   · Кыям, ..., берничә көрәк чирәмле җирне куптарып ташлаган иде, дәррәү су **килеп чыкты**. (Әбрар Шәмин, Алмагач чәчәге.) Qiam, ..., had taken out a few shovelfuls of the virgin soil when suddenly water appeared.
   · Нәзир бурлаттай **кызарынып чыкты**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) Näzir suddenly turned red like red calico.

f) An action extending to *several persons or things.*
   · Кайнагай белән Әсхәпҗамалны кала күрсәтергә **алып чыгам**. (Мөхәммәт Гали, Кала кешеләре.) I take the brother-in-law and Äskhäpjamal out to show them the town.
   · Хуҗа аларга чәй тулы чәйнекләр **өлешеп чыкты**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) The (tea house) owner served (lit., apportioned to) them teapots filled with tea.

g) The construction of **чыгу** with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп** of certain verbs may indicate a *permanent state.*
   · Без һаман барабыз. Кояш батышы ягында су төбеннән таулар **калкып чыга**. (Галимҗан Ибраһимов, Диңгездә.) We are (i.e., the ship is) still moving. In the west, there are mountains rising up from the bottom of the sea (lit., water).

**[1370] Чыгару**.

In conjunction with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, **чыгару** indicates:

a) The *completion,* the *attaining of a result,* of an action.
   · – Имтиханов – мин **уйлап чыгарган** псевдоним гына, – диде ул. (Мирсәй Әмир, Имтихан.) "Imtikhanov is only a pseudonym I invented," she said.

- – Ай-һай, энем, үзеңнән генә **уйлап чыгармыйсыңмы**? (Мирсәй Әмир, Тун ачуы.) "Well, brother, aren't you thinking this up yourself?"
- ..., чәүкә чәүкәнең күзен **чокып чыгарамы** соң? (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) ..., don't birds of a feather stick together then (lit., does a jackdaw peck out another jackdaw's eyes then)?

b) The performance of an action or movement in a *certain direction.*

- Тикшерүче зәңгәр тамырлы куллары белән ашыга-ашыга кәгазьләрен актарырга кереште һәм берсен **тартып чыгарды**. (Фоат Садриев, Таң җиле.) The investigator hurriedly began flicking through his papers with his blue-veined hands and pulled one out.
- Ул чагында Тимеркәй Котлыяр байның да капкасын буш куймады. Аннан да берничә тапкыр сүгелеп **куылып чыгарылган** иде. (Давыт Юлтый, Тимеркәй фәлсәфәсе.) At that time, Timerkey did not pass up the gate of the wealthy man Qotlyyar either (i.e., he slept at the gate). Several times he had been scolded and been chased away from there.
- Әлфия ханым машина өстәлендә яткан папкадан ике генә битле бер кульязма **китереп чыгарды**. (Мирсәй Әмир, Имтихан.) Lady Älfiä got out a manuscript of just two pages from the folder which was lying on the typewriter table.

**[1371] Язу**.

Used with the verbal adverb in **-а**, **-ә**, **-ый**, **-и**, **язу** indicates a limitation of the action expressed by the verbal adverb. The action does not attain its full completion. With some time element involved the construction denotes that the action has not quite attained its full completion at the point of time indicated. Furthermore, the construction may indicate that the agent comes close to, stops short of, performing the action.

- Карыннары бик ач булганга күрә, әзерләнгән ашны тәмам **ашап бетерә яздылар**. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) As their stomachs were absolutely empty (lit., very hungry), they consumed the prepared food almost completely.
- Капчыкларыбызны төя-төя тутырып, авызын бәйләп торганда, кояш төшлеккә **җитә язган** иде инде. (Хәсән Сарьян, Бер ананың биш улы.) By the time we had filled up our sacks and were tying them up, the sun had already nearly reached its zenith.
- Аның яшь аша әйтелгән сүзләре хәмдүнәне дә **елата язды**. (Кояш Тимбикова, Тын бакчада.) Her words spoken through tears almost made Khämdünä cry too.
- Мин, укытучы кеше, ... башта шул сүзгә **ышана яздым**. (Фатих Хөсни, Кем гаепле?) I, a teacher, ... at first I almost believed that talk.
- Мифтах куанычыннан кычкырып **җибәрә язды**. (Гомәр Бәширов, Сарут.) Miftakh almost cried out for joy.

**[1372] Яту**.

Used in conjunction with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, **яту** indicates the *uninterrupted continuation* of an action *at one and the same place*, or the *habitual state* of a person or thing.

- Тәрәзәдән карасаң, күз алдында Казанка **ялтырап ята**. (Мирсәй Әмир, Кысыр хәсрәт.) When you look out of the window, there is the Kazanka glittering before your eyes.
- Юл буенда машиналар **йөреп ята**, туктап торганнары да бар инде. (Мирсәй Әмир, Беркатлы кеше.) Cars are moving on the road; there are also some which have stopped.

- Артка борылам. Амбар янында Мактый бабай белән малае Габдулла абый утын **ярып яталар** икән. (Шәйхи Маннур, Агымсуларга карап.) I turn around. There, beside the barn, Grandpa Maqti and his son, Uncle Ghabdulla, are cutting wood.
- Шәһәргә якын агым су бар. Шул су буенда хатын-кызлар ... тегесен-монысын **чистартып яталар** икән. (Татар халык әкиятләре, Тире Такыя.) A brook runs (lit., There is a running water) close to the town. And there, along the brook (water) are women cleaning ... various things (lit., this and that).
- Кемнеңдер читтән киңәш һәм күрсәтмә биргәнен **көтеп ятмыйсы** иде, бу эшкә үзебез башлап керешәсе иде. (Фаяз Аунай, Экранда күрсәк икән.) We ought not to keep waiting for someone to give us advice and instructions from afar, but we ought to set about this matter ourselves.
- Менә мин хәзер китәргә, әтигә, әнигә, якыннарымнан беркемгә дә әйтми, чыгып китәргә **җыенып ятам**. (Садри Җәләл, Инде мин аңа рәнҗемим.) I am now preparing to go away, to leave without telling even Father, Mother, or any of my relatives.

**[1373] Җибәрү**.

As an auxiliary verb, **җибәрү** is used with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**. The construction expresses:

a) An *intensive* action *completed quickly, momentarily.*

- Рахманкулов тәрәзәне **ачып җибәрде**. (Миргазиян Юныс, Бозылган тынычлык.) Rakhmanqulov flung the window open.
- Бөркү урамнан салкынча иркен бүлмәгә килеп кергәч, Байкучатов җиңел **сулап җибәрде**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) Upon coming into the cool, spacious room from the sultry street, Baiquchatov breathed a sigh of relief.
- Без һаман бара торабыз. Менә Тәнзилә апа тагын бер ишекне ачып, аркабыздан төртеп эченә **кертеп җибәрде**. (Нәби Дәүли, Кояшка йөз белән.) We continue walking. Here, Aunt Tänzilä opens still another door and, giving us a shove in our backs, quickly made us go in (i.e., go into the room).
- ... Тәнзилә апа үзе малайларның кашыкларына май сала. Эч-эч дип әйтә тора! Малайлар башта күзләрен чытырдатып йомалар, авызларын зур ачып, ... **йотып җибәрәләр**. (ibid.) ... Aunt Tänzilä herself puts (cod-liver) oil on the boys' spoons. "Take (lit., Drink) it, take it!" she keeps saying. The boys first close their eyes firmly, then open their mouths wide and ... quickly swallow it down.

b) An action *beginning suddenly.*

- Юатыр өчен генә әйтсә дә, аның бу сүзләре минем рухымны бердән **күтәреп җибәрде**. (Әмирхан Еники, Гөләндәм туташ хатирәсе.) Although he said it only to comfort (encourage) me, these words of his suddenly raised my spirits.
- Кайсыдыр шунда минем хакта сүз **башлап җибәрде**. (Мирсәй Әмир, Әби васыяте.) Someone then suddenly started to talk about me.
- – Тарт, – диде берсе. Гармончы, шуны гына көтеп торган кебек, өздереп **уйнап та җибәрде**. (Мирсәй Әмир, Тун ачуы.) "Play," one of them said. As if he had just been waiting for that, the accordion player masterfully struck up a tune.

c) An *inceptive* action assuming a *permanent* or *continuous* character.

- Әминә янәшәсендә атлаганда мин шул турыда уйлап бардым. Күңелдә канәгатьлек хисе иде. Янымда Әминә икәнлеген дә **онытып җибәргәнмен** хәтта. (Туфан Миңнуллин, Хәсән Вәгыйзович.) While walking beside Äminä I kept thinking about those things (i.e., the things mentioned previously). I had a feeling of contentment. I even had completely forgotten that Äminä was there at my side.

- «Алтын кошым югалган, кемдер читлекне ачып кошны **чыгарып җибәргән**», – ди. (Татар халык әкиятләре, Алтын Кош.) "My golden bird has disappeared, someone has opened the cage and let the bird out," he says.
- – Бу ашъяулыкның хикмәте бар, ди. **Җәеп җибәрсәң**, ни теләсәң шундый аш була аның өстендә, – ди. (ibid.) "This tablecloth has a magic power," he says. "If you spread it out, whatever food you wish will appear on it," he says.
- – Ярый, мин сезгә рөхсәт бирәм. Мәгәр мин сезне урманнан чыгып киткәнче үзем **озатып җибәрәм**. (Татар халык әкиятләре, Ак бүре.) "All right, I give you permission. But I'll accompany you until you get out of the forest."

d) An *intensive short* action.

- Фангөл дә, Салих та ... кычкырып **көлеп җибәрделәр**. (Газиз Мөхәммәтшин, Дулкыннар.) Both Fangöl and Salikh ... burst out laughing loudly.
- Җәмилә, үзен үзе онытып: – Гыйльметдин, харап! – дип **челелдәп җибәрде**. (Мирсәй Әмир, Җанлы бүкән – читән артында.) Forgetting herself, Jämilä shrieked out, "Ghilmetdin, we are finished!"
- Җайдаклар, таныш тавышны ишетеп, шундук тезгеннәрен тарттылар, атлары кинәт туктый алмый үрә сикереп **кешнәп җибәрде**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) Hearing the familiar voice, the horsemen immediately reined in their horses, and the horses, unable to stop (so) suddenly, reared up and broke out into neighing.
- Мөхәммәтҗан бабай, ... чыбыркысын шартлатып, **сызгырып җибәрә**. (Мөхәммәт Гали, Көтүчеләр.) Grandpa Mökhämmätjan, ... cracking his whip, gives a whistle.
- – Вәли, син түгелме соң? – дип **кычкырып җибәрде** Фатыйма, ... (Кәрим Әмири, Завод мәктәбендә.) "Wäli, isn't that you?" Fatima cried out, ...

e) An action *directed away from the agent.*

- Теге кеше әйтте, ди: – Тукта әле, әнә теге болыт килеп җитсен, шуның өстенә таякны **ташлап җибәрәм**, диде, ди. (Татар халык әкиятләре, Һөнәрле үлмәс.) That man said, so they say: "Just wait, let that cloud there come (here), (and) I'll throw the stick on it."
- Патша, хатынының сүзенә ышанмыйча, аны бик каты ачуланып, **куып чыгарып җибәрә**. (Татар халык әкиятләре, Алтын кош.) Not believing his wife's words, the king scolds her very severely and chases her out (of the room).
- Хөснуллин чыгып киткәч, тикшерүче кереп, бер-ике юк кына сорау бирде дә Хәдичәне **кайтарып җибәрде**. (Фоат Садриев, Таң җиле.) After Khösnullin left (the room), the investigator entered. He asked only one or two trivial questions and sent Khädichä back (home).

f) An action carried out with *force, vigor.*

- – Бу нәрсә? – диде. Минем яңакка берне **салып та җибәрде**. (Давыт Юлтый, Бәләкәй Котош.) "What is this?" he said and slapped me on the cheek.
- Ак күлмәк: – Мин аннан бөтенләй алга чыгып киләдер идем, Мортаза **этеп җибәрде** мине, – ди. (Мөхәммәт Гали, Сабан туенда.) The boy in the white shirt says: "I had been pulling clear ahead of him, but Mortaza pushed me."
- ... сай көймәне икәүләп суга төшерделәр. Ишкәкне комга терәп **этеп җибәргәч**, көймә ... ачык диңгезгә таба шуышты. (Миргазиян Юныс, Энҗе эзләүчеләр.) ... the two together put the flat boat into the water. After they propped the oar on the sand and pushed off, the boat glided towards the open sea.
- Тимергали ага хәзер пенсиядә инде. Үз гомерендә күргән-белгәннәре турында очрашкан саен дәртләнеп-дәртләнеп **сөйләп җибәрә** дә. (Әбрар Шәмин, Олы бөркет.) Sir Timerghäli is now already on pension. Each time we meet he talks with great animation (in a very animated way) about the things he has seen and experienced in his life.

g) An action *increasing* in intensity, force, or increasing, improving an existing quality.

- «Көтермен» сүзе егетне тәмам **эретеп җибәрде**. Миргазиян Юныс, Юылган мәхәббәт.) Her words "I'll wait for you" softened the young man completely.
- Һәрнәрсәгә аек күз белән карый торган бер карчык иде ул. Яшь кызның өй эчен **ямьләндереп җибәрүен** ул тоймады да ... (Миргазиян Юныс, Әрчегән бәрәңге.) She was an old woman who looked at everything with sober eyes. She did not even notice that the young girl was beautifying the interior of the house ...

h) A *momentary* action performed *unconsciously, unintentionally* or *erroneously.*

- – Әйтәм, миңа да Шәрифә диясе урынга еш кына Шәфика **дип җибәрә идең**. (Габдрахман Әпсәләмов, Идел хикәяте.) "I say, you would often call me Shäfiqa too instead of Shärifä.
- Җәмилә дә каушый, калтырый иде. Шулай каушый, калтырый торгач, яңлыш самоварның капкачын кулыннан **төшереп тә җибәрде**. (Мәҗит Гафури, Ярлылар.) Jämilä too became frightened and was trembling. Standing there frightened and trembling, she let the cover over the samovar fall (from her hand).
- Бәдри: «Ирең кайттымы?» – дип сорагач та, [Җәмилә], ..., сулкылдап **елап та җибәрде**. Бу ихтыярсыз чыккан ... күз яшьләре, ..., кемнең дә булса күңеленә, йөрәгенә әсәр итәрлек булганга күрә, Бәдри дә, бергә кушылып, күз яшьләрен түгә башлады. (ibid.) The moment Bädri asked her: "Did your husband return?" [Jämilä], ..., began to weep sobbingly. Because these tears, which flowed unconsciously, ... were capable of affecting anybody's heart and soul, Bädri too joined in and began to shed tears.

**[1374] Җитү**.

As an auxiliary verb, **җитү** is used with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**. The construction indicates:

a) The action or state has *reached* (will reach) an *aim* or a *limit*, or it has rendered a *result.*

- Икенче көнне нәкъ билгеләнгән вакытта Мәдинәнең чакырулы кунаклары **килеп җитте**. (Атилла Расих, Ике буйдак.) The next day, exactly at the set time, Mädinä's invited guests arrived.
- Камил **килеп җиткәндә**, шәһәр бинасы алдындагы мәйданда йөзләрчә кешеләр җыелып торган иде инде. (Мирсәй Әмир, Ялантау кешеләре.) When Kamil was getting there, hundreds of people had already gathered at the square in front of the town hall.
- Юмарт туп-туры әлеге шәһәргә киткән. **Барып җиткәч**, шәһәр читендәге ялгыз йортка кергән. (Татар халык әкиятләре, Саран белән Юмарт.) Yumart left straight for that town (that town mentioned before). Upon getting there, he went into a house which stood alone at the edge of the town. (Юмарт – 'generous', 'open-handed', Саран 'miser', stingly' here used as proper names.)
- Мин баштарак үземнең сәләтемә **ышанып җитә** алмыйча йөрдем. (Гомәр Бәширов, Тормыш сукмаклары.) At first, I was unable to fully believe in my talent.
- – Көтеп торыгыз, хәзер үзем **килеп җитәм**. Бергә барырбыз. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) "Wait one moment, I'll come right now myself. We'll go together."
- Диңгез төбенә **төшеп җитәр** өчен егерме секунд чамасы вакыт кирәк иде. (Миргазиян Юныс, Энҗе эзләүчеләр.) It took about twenty seconds to descend to the bottom of the sea.

b) The *quick completion* of an action, often with a tinge of *surprise.*

- Сүз шушы җирдә тукталып калды: аларны көтмәгәндә йөк машинасы **куып җитте**. (Әбрар Шәмин, Күңел күзе.) Their conversation (lit., the word) stopped at

this point; a truck had unexpectedly caught up with them (and the chauffeur offered them a lift into town).

- ... гайбәтләр бер минут эчендә авылның бер очыннан икенче очына **барып җитәләр**. (Кәрим Әмири, Югалган малай.) ... within a minute the slanderous words spread from one end of the village to the other.
- Егетнең чәче кызларныкы шикелле озын, джинс чалбар. ... Бу мода Караярга да **барып җитәр** дип кем уйлаган! (Миргазиян Юныс, Табу һәм югалту.) The young man's hair is as long as a girl's, and he is wearing jeans. ... who ever thought that this fashion would get to Qarayar of all places!

**[1375] Җиткерү (җиткезү.)**
Used with the verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, **җиткерү** (**җиткезү**) indicates that the action or state *is brought to its limit, its end.*

- Шундый әйбәт сөйләшеп бардык. Егерме-егерме биш километр ара сизелми дә калды. Ә кирәк җиргә **илтеп җиткергәч**... Рәхмәтне әйттеләр, әлбәттә. ... Тик хәзерге заманда ул рәхмәт белән кая барасың? (Мирсәй Әмир, Сәдака.) We went along, having such a nice talk. The twenty or twenty-five kilometer distance was not even noticed. But after I had brought them to the place they had to go to... Of course, they expressed their thanks. ... But in these times, where do you get with (words of) thanks?
- ... Зөһрәгөл ... пылавын **пешереп җиткезде** һәм аны бизәкле зур тәлинкәгә салып, үзен ишек төбендә каршы алган иренә китереп тоттырды. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) ... Zöhrägöl ... finished cooking her pilau and, after putting it on a large, ornamented plate, went and handed it to her husband who took it from her (lit., who met her) at the door (i.e., at the door of the room in which he was having a meeting).
- Бу хакта сүз чыкса, ул шатлыгын, канәгатен **әйтеп җиткерергә** сүз таба алмый. (Галимҗан Ибраһимов, Диңгездә.) Whenever this (i.e., the matter of the subject's having obtained the post of an attendant in a mosque) is brought up in a conversation, he cannot find the words to express his joy, his contentment.

**[1376]** The *negative* of **җиткерү – җиткермәү** – used with a verbal adverb in **-п**, **-ып**, **-еп**, indicates the *incompleteness, imperfection, insufficiency* or *inadequacy* of the action or state expressed by the verbal adverb.

- Егет соңгы сүзләрен пышылдап кына әйткәнлектән, Фарукҗан аны **ишетеп җиткермәде**. (Тәүфикъ Әйди, Елан угы.) Because the young man said his last words in a whisper, Faruqjan could not make them out (hear them).
